ISSN 0206–4189

# Казан утлары

1.2005





Шәехзадә Бабич
(1895—1919)

# Казан утлары
# Qazan utları

2005

**1**

**(987)**

ОЕШТЫРУЧЫЛАРЫ:

*Татарстан хөкүмәте,*
*Татарстан Язучылар берлеге,*
*редакциянең хезмәт коллективы*

*БАШ МӨХӘРРИР*

**Равил Фәйзуллин**

*ИДАРӘ:*

**Харрас Әюпов**
**Зилә Вәлиева**
**Мөдәррис Вәлиев**
**Фоат Галимуллин**
**Тәлгат Галиуллин**
**Миркасыйм Госманов**
**Алмаз Гыймадиев**
*(җаваплы сәркатип)*
**Флүс Латыйфи**
*(баш мөхәррир урынбасары)*
**Мирза Мәхмүтов**
**Туфан Миңнуллин**
**Хатыйп Миңнегулов**
**Гәрәй Рәхим**
**Факил Сафин**
**Ренат Харис**
**Зиннур Хөснияр**
**Розалина Шаһиева**

---

*Мөхәррирләр:* **Мансур Вәли, Наис Гамбәр, Рәдиф Гаташ, Марат Закир, Камил Кәримов, Марс Шабаев.**

*Гамәли хезмәткәрләр:* **Гөлзадә Бәйрәмова, Радик Вәлиев, Лилия Гатауллина, Ихтыяр Гаязов, Флера Сабирова, Тәгъзимә Шиһабиева.**
*Исәп-хисап бүлеге:* **Асия Рәхимова** (баш бухгалтер), **Эльвира Камалова.**

---

420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.
Баш мөхәррир — 92-38-60.
Баш мөхәррир урынбасары — 92-36-49.
Җаваплы сәркәтип һәм компьютер үзәге — 43-56-12.
Бүлекләр: шигърият, фән, сәнгать — 92-38-61,
чәчмә әсәрләр, хатлар, әдәби тәнкыйть — 92-39-63,
гамәли хезмәткәрләр — 92-39-65.
Исәп-хисап бүлеге — 92-93-16.
**Факс** — (8432) 43-56-12.
**E-mail:** kazanutlari@telebit.ru.

# КАЗАН УТЛАРЫ

ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

## *Бу санда*

Şəyexzadə BABİÇ. Xalqım əçen. *Şiğer.* ........ 5

**МӨХӘРРИР СҮЗЕ**

Флүс ЛАТЫЙФИ. Юбилей уңае илә уйланулар. ........ 6

**ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР**

Зиннур МАНСУРОВ. Чыраг тоткан хәтер йөри... *Шигырьләр.* ........ 14
Мәдинә МАЛИКОВА. Чәчкә балы. *Повесть.* ........ 22
ЗӨЛФӘТ. Яшәп түгел, очып үткәндә. *Шигырьләр.* ........ 49
Әсгать СӘЛАХ. Көт син мине... *Повесть.* ........ 54
Мөхәммәт МИРЗА. Яктыртмакчы булсаң халык күңелен. *Газәлләр.* ........ 94
Рашат НИЗАМИ. Бер могҗиза миңа елмая... *Шигырьләр.* ........ 98

**ҖИҢҮНЕҢ 60 ЕЛЛЫГЫНА**

Әдип БИКТАШЕВ. Соңарган сәфәр. ........ 103

**ДИСКУССИЯ: "БЕЗНЕҢ ЗАМАН ГЕРОЕ"**

Айдар ХӘЛИМ. Сез беләмсез кая барганны? ........ 109

**ФӘН**

Адлер ТИМЕРГАЛИН. Миллият сүзлеге. ........ 137

**ТАРИХ**

Нурулла ГАРИФ. Борынгы Чаллы шәһәрлеге бәклек үзәге булганмы? ........ 141

**СӘНГАТЬ**

Шамиль МОНАСЫЙПОВ. Ярыш чишмәләре. *(Музыкант Ильяс Әухадиевнең тууына һәм Казан музыка училищесы оешуга 100 ел.)* ........ 149

**ХӘТЕР**

Наил ГЫЙЗЗӘТУЛЛИН. Әмирхан ага ядкаре. ........ 160

**ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ**

Гөлчәчәк ГАЛИЕВА. Шагыйрь, публицист... ........ 165

**МУСА АКЪЕГЕТЗАДӘНЕҢ ТУУЫНА 140 ЕЛ**

Хатыйп МИҢНЕГУЛОВ. Егетлек күрсәткән Акъегет. ........ 174

**ШӘЙХИ МАННУРНЫҢ ТУУЫНА 100 ЕЛ**

Марат ЗАКИР. Туган як һәм әдип кадере. ........ 179

**ЮМОР ҺӘМ САТИРА**

Алмаз ХӘМЗИН. Үтте гомерләр. *Хикәяләр. Парчалар.* ........ 182

"Казан утлары" архивыннан ........ 186
Язучылар берлегенең яңа әгъзалары. ........ 188
Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан. ........ 189

## В ЭТОМ НОМЕРЕ:

*Журнал выходит один раз в месяц*

"Слово редактора": Ф. ЛАТЫФИ. "Размышления по поводу одного юбилея";
повести М. МАЛИКОВОЙ "Цветочный мед" и А. САЛАХА "Жди меня";
стихи Ш. БАБИЧ, З. МАНСУРОВА, ЗУЛЬФАТА, М. МИРЗЫ, Р. НИЗАМИЕВА.
"К 60-летию победы": статья А. БИКТАШЕВА. "Запоздалая поездка".
Дискуссия "Герой нашего времени": исследование и размышления писателя А. ХАЛИМА о современной татарской литературы.
"Наука": А. ТИМЕРГАЛИН. "Словарь нации".
"История": статья Н. ГАРИФА "Городок Старые Челны был ли центром княжества?"
Статья Ш. МОНАСЫПОВА посвящена к 100-летию Казанского музыкального училища и музыканта Ильяса Аухадиева.
"Память": статья Н. ГИЗЗАТУЛЛИНА "Воспоминания о писателе А. Еники".
"Литературная критика": статья Г. ГАЛИЕВОЙ о творчестве поэта и публициста Р. Юнуса.
К 140-летию Мусы Акъегетзады—статья Х. МИННИГУЛОВА.
К 100-летию Ш. Маннур—статья М. ЗАКИРА "Цена поэта на родной земле".
"Юмор-сатира": А. ХАМЗИН. Рассказы.
Из фотоархива журнала.
Дневник общественно-культурной жизни.
На наших обложках: На рубеже веков. "Часы на улице Баумана в г. Казани";
Поэт Ш. Гадельша.

## IN THIS ISSUE:

*The magazin edits monthly*

"Editor's Word": F. LATYFI. "Reflections about an anniversary";
Stories by M. MALIKOVA "Flower honey" and by A. SALAH "Wait for me";
Verses by Sh. BABICH, Z. MANSUROV, ZULFAT, M. MIRZA, R. NIZAMIYEV.
"To 60th anniversary of Victory": article by A. BIKTASHEVA "Delayed trip".
Discussion "Hero of our time": research and reflections of the writer A. HALIM About the modern tatar literature.
"Science": A. TIMERGALIN. "Dictionary of Nation".
"History": Article by N. GARIF "Was the Town of Stariye Chelny the centre of the Country?"
Article by Sh. MONASYPOV devoted to 100th anniversary of the Kazan Music school and the musician Ilyas Auhadiev.
"Memory": article by N. GIZZATULLIN "Memoirs about the writer A. Eniky".
"Literary criticism": article by G.GALIEVA about creativity of the poet and the publicist R. Yunus
To 140th anniversary of Musa Akegetzady — article by H. MINNIGULOV.
To 100th anniversary of Sh. Mannur — article by M. ZAKIR "Poet's value on native ground".
"Humor-satire": A. HAMZIN. Stories.
From photo archive of the magazine.
Diary of social-cultural life.
On our covers: On the boundary of centuries.
"Clocks in the street Bauman in Kazan";
Poet Sh. Gadelsha.

★Авторлар фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.
★Редакциягә килгән кульязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
★Басмаханә гаебе белән киткән җитешсезлекләр өчен редакция җавап бирми, брак журналларны алыштыру мөмкинлеге юк. Алар хакында 19-44-61 телефоны белән басмаханәнең техник контроль бүлегенә хәбәр итәргә кирәк.

Журнал редакциянең компьютер үзәгендә җыелды һәм битләргә салынды.
Басарга кул куелды 21.12.2004 ел. Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70X108$^1/_{16}$.
Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12 (16,8). Тиражы 7025. Заказ Э—957
Журнал Татарстан Республикасының Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгында теркәлгән.
Теркәлү таныклыгы № 7.

«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды.
Казан, Декабристлар урамы, 2

© «Казан утлары», 2005 ел.

## Şəyexzadə Babiç

(1895–1919)

### Xalqım əçen

Appaq altın cırlarımnı
Cırlamıym danlıq əçen,
Çırlayım altın ilemçən,
Üz tuğan xalqım əçen.

Saf kəmeştik cırlarımnı
Cırlamıym altın əçen;
Cırlayım tik saf kəmeştik
Saf yərək xalqım əçen.

Çəçkə təsle cırlarımnı
Cırlamıym zəwqım əçen,
Cırlayım tik çəçkədəy
Qızlarğa bay xalqım əçen.

Dərtle qaynar cırlarımnı
Cırlamıym dərtem əçen,
Cırlayım tik mənge şat,
Dərtle, kələç xalqım əçen.

Yığlamıym min kənnərem
Sırğaq, suıq, salqın əçen,
Yığlayım tik yarlı, mesken,
Qızğanıç xalqım əçen.

Yəş çağım, altın çağım,
Yalqın çağım bulsın fida,
Xalqım aldında minem
Birgən taza antım əçen.

*1914*

İlemçən—ilem əçen.

## Флүс Латыйфи

# ЮБИЛЕЙ УҢАЕ ИЛӘ УЙЛАНУЛАР

Журналның бу саны кулыгызга килеп кергәндә, хөрмәтле укучым, календарьда инде яңа ел булыр. Егерме беренче гасырның бишенче елы. Бәйрәм табыннары үткән, шау-шулы ыгы-зыгылар артта калган булыр. Шулай гадәткә кергән, яңа елга һәркем әллә нинди яңа өметләр баглый, Кремль курантлары төнге уникене сукканда бер-беребезгә иң җылы, иң самими теләкләребезне җиткерергә ашыгабыз. Алар барысы да тормышка ашар, яңа елда тормышыбыз матуррак, ямьлерәк, баерак, рухи яктан мәгънәлерәк булыр сыман тоела. Шулай... Әмма, уйланган башка уй килә дигәндәй, фикер йомгагым республикабыз, халкыбыз язмышы, милләтнең киләчәге ягына тәгәри башлауга күңелемә шөбһәле уйлар килә дә керә. Алардан котылу юк. Сәбәпләре байтак кынамы, әйтеп бетергесез күп...

Гасырлар кичте китте... кичте еллар!  
Нәбиләр, падишаһлар, сөрде дәрван...  
Гомерләрдер күчеп кәрван вә кәрван,  
Килеп кичте җиһандан канча илләр!..

Моннан нәкъ йөз ел элек, узган гасыр башында татарның бөек шагыйре Дәрдмәнд "Без" дип исемләгән шигырендә әнә шундый юллар язып калдырган. Әйе, Җир шары иксез-чиксез галактика томанлыгында әйләнә дә әйләнә, аның белән бергә без дә әйләнәбез, чорлар кичәбез, яңа гасырларга аяк басабыз; шул рәвешле дөнья картасында берише илләр юкка чыга, икенчеләре барлыкка килә тора. Кайчандыр без газизләргә мәрхәмәтле һәм шәфкатьле булган галиҗәнап тарихның аяныччы елларында дөнья картасыннан татар мәмләкәтләре дә тузанга әйләнгән, шагыйрь әйтмешли:

Исә җилләр, күчә комнар... бетә эз...  
Дәрийгъ, мәхзүн күңел, без дә бетәбез!

Ләкин ничек кенә булмасын, гасырлар буе башка кавемнәрнең уңдырышсыз туфрагына черемә-зәмин итеп салына килгән халкыбыз гарасатлы чорларны кичә-кичә сан ягыннан кими вә азая барса да, рухи яктан исән-сау калды; телебез, йолаларыбыз, гореф-гадәтләребез берникадәр гарипләндерелсә дә, әле бүгенгә кадәр саулыгын-сәламәтлеген саклап килә. Шөкер итәргә дә ярыйдыр...

Менә шулай дип язып куйдым да, янәдән уйга баттым. Бик шөкер итәсе килә дә бит, ләкин соңгы елларда Мәскәү тарафларыннан Татарстанга, татар халкына һәм татар теленә карата алып барылган мәкерле сәясәт һич кенә дә тынычланырга ирек бирми. Күңелне әллә нинди шом баса, хәвефле сизенү көне-төне йөрәкне тырный. Моны кем ничек тоя торгандыр, анысын белмим, бәлки мин ялгышамдыр да... Шулай гына булсын иде дә бит...

---

*Нәби* – пәйгамбәр. *Дәвран* – гомер, чор. *Дәрийгъ* – үкенеч. *Мәхзүн* – аяныччы, кайгылы.

Юкса, артык хафаланыр урын да юк кебек. Әнә, шаулатып-гөрләтеп Казанның мең еллыгын билгеләп үтәргә әзерләнеп ятабыз. Пайтәхетебезнең борынгылыгын, кешелек цивилизациясе үсешендә тоткан урынын дөнья халыкларына танытуның иң үтемле чарасы булган бу мәртәбәле юбилей, тар маңгайлы байтак шовинистларның, хәер, аларның гына да түгел, ә бәлки үзенең моңарчы бозып күрсәтелгән, гариплэндерелеп аңлатылып килүче тарихыннан оялып йөрүче кайбер милләттәшләребезнең дә күзен ачар әле, татар дигән бөек вә шанлы халкының тарихына башкачарак карарга мәҗбүр итәрдер, шәт. Безнең барыр юлыбыз бер генә— Русия кысаларына гына бикләнеп калмыйча, киң дөньяга чыгу, халкыбызны дөнья илләрендә таныту. Шунсыз татарга кимсетебрәк караудан, читкә тибәрергә омтылудан котыла алмабыз, мөгаен.

Егерме беренче гасыр башы олуг юбилейларга бай һәм аларның татарга турыдан-туры кагылышлылары да байтак. Менә ноябрь аенда Казан дәүләт университетының 200 еллыгын билгеләп үттек. Кайчандыр шушы уку йортын тәмамлаган һәм элеккеге Советлар иленең барлык республикаларында диярлек яшәп һәм эшләп ятучы меңнәрчә галим-голәмәгә— физиклар, биологлар, юристлар, математиклар, филологлар вә гайреләргә бернича ел буе көтеп алынган тансык бәйрәм булды ул. Шул бәйрәм кысаларында университетта татар теле һәм әдәбияты бүлеге ачылуга 60, аның татар теле, әдәбияты һәм татар тарихы факультеты итеп үзгәртеп корылуына 15 ел тулуга багышланган тантаналы кичә дә булып узды. Һич арттырмыйча әйтергә мөмкин, татар халкы өчен университет яшьләргә белем бирүче гыйлем вә фән учагы, гап-гади alma mater гына түгел, аның әһәмияте гаять зур, рухи дөньябызда тоткан урыны чиксез киң, милли аңны үстерүдәге өлеше бәяләп бетергесез. Ул байтак еллар татар халкы тарихында һәм әдәбият институты, һәм журналистика бүлеге, һәм сәясмәннәр мәктәбе ролен үтәп килде. Беренче карашка, татар теле һәм әдәбияты укытучылары әзерләргә тиешле һәм шушы максаттан чыгып ачылган бүлек, совет чынбарлыгы шартларында милли фикер учагы сүнеп бетмәгән бердәнбер уку йорты иде; туксанынчы еллар башында Ирек мәйданына "Азатлык! Татарстанга мөстәкыйльлек!" шигарен күтәреп чыгучыларның, ярсулы митинглар, халык җыеннары үткәргән милли каһарманнарыбызның иң кайнар өлеше дә шул бүлекне тәмамлаучылар булды. Әлеге изге юлда гомерләрен фида кылырга әзер булып, сәяси ачлык игълан итүчеләр дә, нигездә, милләтебезнең шушы бүлектә тәрбия алган асыл уллары һәм кызлары иде. Ирек даулаучыларның бер өлеше мәйданда, халык арасында булса, бер өлеше— халык депутаты исеменә лаек булганнары— Югары Совет сессиясендә ялкынлы чыгышлары белән халкыбызның йөз еллар буе хыялланган өметләрен җанландырды. Алар, бәлки, азрак та булгандыр, әмма сүзләре үтемле, әйткән фикерләре меңнәрнең йөрәгенә ятышлы иде.

Әйе, халкыбызга укымышлы, гыйлемле яшьләр кирәк, күп, бик күп кирәк. Дөрес, белемне хәзер теләсә кайсы институтта, университетта алып була анысы. Юристларны, икътисадчыларны, физикларны һәм математикларны, табибларны, авыл хуҗалыгы белгечләрен, химикларны, мөһәндис-инженерларны, укытучыларны һәм тагын әллә нинди белгечләрне меңәрләп кенә әзерлиләр дә, араларында татар егетләре һәм кызлары да бик күп, ялгышмасам, кайбер югары уку йортларында студентларның яртысыннан артыгын милләттәшләребез тәшкил итә.. Әйе, алар күп, әмма татар теле һәм әдәбияты факультетында укыган студентларныкы кебек фикерләүләре милли аң белән сугарылмаса, йөрәкләрендә, бәгырьләрендә "туган халкым" дигән изге хис сулкылдамаса бик аяныч булыр. Менә шунлыктан, бүгенге көндә дә, бүгенге шартларда да— милләтебез язмышы хәл ителгән бер мәлдә татар факультетының яшәп килүе табигать фәннәре буенча белгечләр әзерләүче теләсә кайсы вуздан мөһимрәк әһәмияткә ия.

Татар факультеты юбилее кичәсендә утырганда, нишләптер, күңелемдә шундый хисләр өермәсе уянды. Чөнки мин анда шушыңа охшаш фикерләрне ишетермен, каһәрле сугыш елларында меңнәрчә каршылыклар белән эшли башлаган татар бүлеге эшчәнлегенә, ниһаять, лаеклы бәя бирелер дип ышанган

идем. Дөрес, чыгыш ясаучыларның байтагы күңелне җылытырлык фикерләр әйтте әйтүен, әмма төп игътибар, кичәнең алып барылышы нишләптер таррак кимәлдә булып, факультетның бүгенге көндә ничек яшәвенә, анда кемнәрнең ничек эшләвенәрәк багышланган булып чыкты. Сүз юк, болары да кирәк, әлбәттә. Әмма без, кайчандыр университетның үзебезгә аеруча газиз вә якын бүлеген тәмамлаучылар, киңрәк, колачлырак фикерләүне көткән идек. Факультет халкыбызга кемнәрне биргән, алар кемнәр, кайда һәм ничек эшлиләр, милләт хәзинәсенә нинди асыл җәүһәрләр вә гәүһәрләр өсти алганнар?! Ахыр чиктә, тәгамны авыз итүче өчен аның кухняда ничек әзерләнүе һәм пешерелүе түгел, ә табынга китерелгән ризыкның тәме, матурлыгы, зәвыкълы булуы кыйммәтрәк ләбаса! Беребез дә тәгамга тозның яисә борычның кайчан һәм ничек салынуы белән кызыксынмый, аңа тәм хасиятләреннән чыгып бәя бирә. Татар факультеты тар мәгънәдәге факультет кына түгел, ә милләтпәрвәр белгечләр әзерләүче гыйлем учагы! Төп фикер шулайрак булырга тиеш иде кебек. Юбилей кичәсендә республика җитәкчеләренең катнашмавы, аларның фикере яңгырамау да күңелдә канәгатьсезлек тойгысы уятты. Бу үз кимәлендә бердәнбер булган факультетның асыл бәясен белмәү яисә аны киметеп күрсәтергә тырышуга охшап калды. Бәлки алай да булмагандыр, бигайбә, мин бары тик үзем кичергәннәрне, үзем уйлаганнарны гына кәгазьгә төшереп утырам. Беркем дә иң соңгы инстанциядәге хакыйкатькә ия түгел. Анысын да яхшы аңлыйм. Шулай да...

Татар бүлеге, яшәвенең беренче көннәреннән башлап, партия һәм совет оешмаларының, дәүләт куркынычсызлыгы органнарының даими күз уңында, шик астында булды. Тыелган булуга карамастан, татар теле һәм әдәбиятын укытканда, табигый ки, сүз татар тарихына, аерым алганда, татар дәүләтләрендә фән вә сәнгатьнең нинди югарылыкта булуына, әдәбиятның, шигъриятнең нинди үсеш алуына кагылмый калмый, ә болар исә, милли аңны уятуга китерә, халкың белән горурлану хисләре уята, ирексездән, аны башка милләтләрнең ул чордагы халәте белән чагыштыра башлыйсың. Кол Галинең "Кыйссаи Йосыф"ы, Сәиф Сараи һәм башка олуглар иҗатының дөньядагы теләсә кайсы әдәбият горурланырлык шигърият җәүһәрләре икәнлеге күңелеңә сеңә. Чагыштырасың... һәм таң каласың. Боларны инде яшереп калдыру мөмкин түгел. Ә алар белән горурлану, татар тарихын Орхон-Енисей язмаларыннан өйрәнә башлау, халкыбызның Болгар белән генә чикләнеп калмаганлыгын, Азия һәм Европа киңлекләрен яулаган олуг милләт икәнлеген раслау ул вакытларда милләтчелек хорафаты булып санала иде. Мәгълүм ки, моның өчен баштан сыйпамыйлар. Татар бүлеге студенты фонетика һәм синтаксис ятлап, дөрес язу кагыйдәләрен өйрәнү белән генә шөгыльләнергә тиеш иде! Башкасы, нигездә, тыелган гамәл иде. Ә яшьлек тыелмый— эзләнә, казына, таба, тапканын башкаларга җиткерергә омтыла, яза, сөйли. Һәм, ни гаҗәп, боларны тиешле җирләрдә белеп, ишетеп торалар, әлбәттә, боларның берсе дә җәзасыз калмый. Илленче елларда университет эскәмияләреннән ГУЛАГ лагерьларына барып эләккән олуг әдипләребез Аяз Гыйләҗев, Гурий Тавлин, Адлер Тимергалин һәм башка асыл затларыбызның язмышы шул турыда сөйли булса кирәк. Үзебез укыган алтмышынчы елларда да без бу яшерен күзәтүне, татар бүлеге студентларына органнарның аерым карашы барлыгын тоемлый идек.

1968 ел... Югары уку йортларында яңа буын— "халыклар атасы" Сталинның шәхес культы фаш ителгән, Хрущев "җепшеклеген" татыган, шул елларда фикере, аңы формалашкан яшьләр укый башлаган елларның берсе. Нәкъ шул елны бүлекнең, һәрхәлдә, бер группаның язмышы кыл өстендә калган, аның өстендә утыз җиденче елларның эзе сакланган үткен балта күтәрелгән иде. Аен төгәл генә хәтерләмим, татар бүлеге студентлары, аерым алганда, безнең группа студентлары арасында кулдан-кулга бер бик кызык эчтәлекле хат йөри башлады. Юка папирос кәгазенә машинкада бер интервал белән, кырыйларында ара калдырмыйча тыгызлап язылган әлеге хатта татар халкының бүгенге халәте, аның бездән яшерелгән чын тарихы, культурасы, халык саны, икътисадта тоткан урыны белән союздаш республика булырга

лаек булып та, нindидер юк-бар сылтаулар һәм сәбәпләр аркасында халкыбызга ил корылышында тиешле урын бирелмәве хакында бик тәфсилләп язылган һәм һәр фикер Ленин, Сталин хезмәтләреннән, күренекле партия һәм совет эшлеклеләренең чыгышларыннан цитаталар, партия съездлары карарларыннан алынган өзекләр белән ныгытылган иде. Хатта шулай ук татар халкының дөньяда күпме таралганлыгы, теге яки бу өлкәдә, чит илләрдә күпме яшәгәнлеге күрсәтелгән, киләчәктә республикага союздаш статусы алуга ирешү өчен бүгенге яшьләрнең ни эшләргә тиешлеге, татар культурасын, сәнгатен, әдәбиятын киңрәк тарату, татар матбугатын һәр төбәккә илтеп җиткерү өчен нинди чаралар кулай булыры хакында киңәшләр бирелгән иде. Хат Бакудан, безгә бөтенләй таныш булмаган кешедән килеп ирешкән иде. Студентларның тулай торак адресын, исем-фамилияләрен каян алганнардыр, анысы безгә караңгы иде, әмма ул, группадагы берничә кешегә берьюлы килеп, тиз арада аның белән барыбыз да диярлек танышып та чыккан идек. Утызынчы еллар һәммәбезнең хәтерендә, нәсел-нәсәбенә канлы еллар дәһшәте кагылмаганнарны бармак белән генә санарлык булгандыр. Шунлыктан, бу хат турында ачыктан-ачык сөйләшү юк, аны яшереп кенә, качырып кына укыйбыз, бер-беребезгә саклык чаралары күрә-күрә генә тапшырабыз. Милләтче дигән тамга сугыла калса, алдагы язмышыңда ни буласы, университет белән хушлашасы да (алай гына булса әле) көн кебек ачык иде. Төнлә өй янына шыпырт кына килеп туктаган кара машиналар, теге яки бу әдипнең бер көн эчендә серле рәвештә каядыр югалуы, соңыннан аның "халык дошманы", "милләтче" дип фаш ителүе, әсәрләренең китапханәләрдән, аерым кешеләрдән җыеп алынуы, яндырылуы хакында ишетеп белә идек ләбаса, барысы да хәтердә. Әмма хат ымсындыра, күңелебез түрендә тирәнгә, бик тирәнгә күмелгән хис-өметләрне уята, безнең хыялларыбыз белән бер дулкында иде. Чөнки анда язылганнар безнең матбугатта юк, болар тулы бер фәнни оешма башкарган күләмле хезмәткә охшаган иде. Бүген болар хакында, монда бәян ителгән хәлләр турында уку кемгәдер сәер, артык беркатлы булып тоелырга да мөмкин, чөнки монда әйтелгәннәр барысы да хәзер матбугатта ачыктан-ачык языла, дәүләт оешмалары трибуналарында яңгырый. Ләкин ул вакытта чоры бүтән иде, ил өстендә утызынчы елларның дәһшәтле күләгәсе таралып бетмәгән, матбугатта, радио-телевидениедә катгый цензура, авызларыбыз, телләребез йозакта иде.

Ул хатны укып шулхәтле тәэсирләнгән булганбыздыр, күрәсең, мин фәкыйрегез аны машинкада күбәйтеп алырга ниятләде. Бәхеткә, дигәндәй, "Татарстан кооператоры" дигән газетада эшләп йөрим, машинка кул астында. Редакциядән кешеләр китеп беткәч, ишекне бикләп алам да, иске, калтырча "Прогресс" машинкасында суктырам гына. Бер көн, ике көн шулай булды. Тиз генә бастырып бетерелек түгел, хат озын, артык зур күләмле. Өченче көн дигәндә, сәгать сигезләр тулып киткәч, ишектә таләпчән шакылдау ишетелде. "Дерт" итеп киттем. Бездә болай усал һәм каты итеп шаку гадәте юк. Тиз генә кәгазьләрне өстәл тартмасына шудырдым һәм ишекне ачтым. Каршымда әзмәвердәй өч ир пәйда булды. Мине куллары белән бер якка себереп кенә үттеләр дә машинкага ташландылар. Усал тавыш яңгырады:

— Нәрсә басып утырасың?

Боларның кем икәнен һәм ни өчен кергәннәрен аңлатуның кирәге юк иде инде. Күз алдында утызынчы еллар... Иреннәрем тыңламый башлады.

— Менә, яңа хикәя язган идем, — дидем мин батырлыгымны җыеп.

— Күрсәт!

— Ба-басылып беткәч... — дидем бутай.

Арадан берсе ирен чите белән генә елмаеп куйды һәм язу машинкасы куелган өстәлнең тартмасыннан алты данәдә басыла башлаган хат нөсхәләрен, копирка кәгазьләрен, хатның оригиналын тартып чыгарды.

— Шушымы язган хикәяң?

Бу тентүнең нәрсә белән тәмамланганын, ничек сорау алганнарын һәм үзем өчен тетрәндергеч булган ул сөйләшүнең ничек барганын язып тормыйм. Максатым ул түгел. Мине бик соң, сәгать төнге берләрдә генә чыгарып

җибәрделәр. Үз-үземне кая куярга белмичә шәһәр урамнары буйлап атладым. Тулай торакка кайттым да иптәшләрем яши торган бүлмәгә ташландым. Ләкин алар урыннарында юк иде. Аларны да ниндидер машина килеп, берәм-берәм чакырып чыгарып каядыр алып киткәннәр булып чыкты.

Бу вакыйганың шаукымы бик озак дәвам итте әле, ул студентларга да, укытучыларга да кагылды. Бүлек гарасатлы яңгыр алдыннан сәер тынлыкка чумган урман кебек тынып калды. Безне исә факультетта да тикшерделәр, ахырдан университет парткомына чакырдылар. Түрдә, секретарь урынында җәелеп утырган полковник, аның янында кечерәеп калгандай тоелучы остазыбыз Хатыйп Госман, югалып калган яраткан укытучыбыз Диләрә Тумашева... Боларның барысы да бүген генә булган кебек. Шактый озак сөйләшкәннән соң, дөресрәге, полковникның илдәге вәзгыять, империалистларның Совет иленә карата дошманлык актлары, рухи диверсиясе хакында җәелеп сөйләгәнен тыңлаганнан соң шунысы аңлашылды: без дә шул диверсиягә актив кушылучылар, хәтта турыдан-туры катнашучылар икәнбез, ләбаса! Моның өчен черек яшьләргә даһи Ленин укыган университетта урын булырга тиеш түгел. Без Совет иленең үзебез, милләтебез турында аталарча кайгыртуына төкереп караучы, аның кадерен белмәүче надан "неучлар" икәнбез. Кемдер авызыннан хәтта: "Бу группаны куып таратсаң, башкаларга яхшы сабак булыр",— дигән сүзләр дә яңгырап алды.

Советка каршы әдәбиятны уку һәм таратуның зур җинаятькә исәпләнгәнлеген белмибез түгел, беләбез. Аларны махсус оештырылган лекцияләрдә сөйләп, аңлатып торалар иде. Бу утырышка кергәндә күбебез ни үле, ни тере хәлдә булгандыр. Күңелемдә шик-шөбһәләр өермәсе. Укыган өчен генә әллә ни булмас, хәер, теләгәндә антисоветча әдәбият тарату өчен дигән статьяны да өстәп була, ә менә Советка каршы язманы күбәйтү, ул инде җинаятьләр кодексының фәләненче маддәсенә туры килә, аның өчен ун елга иректән мәхрүм итү җәзасы бирелә. Монысын утырышта ачыктан-ачык әйттеләр.

Ләкин безне чыгарып җибәргәннән соң, партком утырышында катнашучылар артык кискен карар кабул итмәгәннәр булып чыкты. Минем дә бәхетем бар икән, читтән торып уку бүлегенә күчәргә тәкъдим итү белән чикләнделәр. Гариза язып, аның хәл ителгәнен көтеп йөри бирәм. Лекцияләргә, дәресләргә йөрү бетте. Мин җир белән күк арасында.

Бу очракта шунысын да искә алырга кирәк: 1968 ел СССРда гына түгел, бөтен социалистик лагерьда милли күтәрелеш кабынган ел иде. Чехословакиядәге милли-азатлык хәрәкәте, чехларның һәм словакларның социалистик лагерь коллыгыннан чыгарга тырышып бәргәләнүе, бөтен дөнья илләренә оран салуы, анда совет гаскәрләренең бәреп керүе радио-телевидениенең өтек-төтек хәбәрләреннән, газеталардагы цензура тарафыннан туралган язмалардан безгә дә килеп ирешә иде. Күрәсең, болар илдәге милли сәясәтне дә искә алырга сәбәп булгандыр.

Ике айлап вакыт үтте бугай. Шул арада факультетта ниндидер үзгәрешләр башланды. Деканыбыз, профессор Гуляев бөтенләй көтмәгәндә Калинин университетына күчеп китте. Асыл сәбәпләрен белмим. Декан булып студентларга таләпчән, әмма аларны аңлый белүче, хәерхаһлыгы белән аерылып торган Сөләйман Ихсанович Даишев эшли башлады. Һәм нәкъ менә ул язмышымны уңай якка хәл итте дә куйды. Көннәрдән бер көнне лекциягә йөрүче иптәшләрем кайтып әйтте:

— Сине Сөләйман Ихсанович чакырды...

Кердем. Утырырга урын күрсәтте, зачеткамны сорап алды. Бик җентекләп, һәр битен карап чыкты да күтәрелеп миңа карады:

— Билгеләрең начар түгел икән. Яхшы, бик яхшы,— дип үзалдына сөйләнеп торды да мин һич тә өмет итмәгән сорауны бирде:— Укуыңны көндезге бүлектә дәвам иттерәсең, киләме?

— Билгеле,— дидем мин шуны гына көтеп торган кебек.

Ул берни дә булмагандай елмаеп куйды һәм ниндидер кәгазь кисәге сузды, аннары кистереп әйтте:

– Бар! Иртәгәдән дәресләргә йөри башла. Ике айлык стипендияңне университет кассасыннан кереп алырсың.

Безне шактый ук шөлләткән вакыйгага нокта шулай куелды. Барыбыз да университетны уңышлы тәмамлап чыктык. Арабыздан танылган шагыйрьләр һәм язучылар Рәшит Әхмәтҗанов, Клара Булатова, Харрас Әюпов, Равил Вәлиев, Роза Мулланурова, Ләлә Сабирова, журналист һәм җәмәгать эшлеклесе Роза Туфитуллова, Уфа университеты укытучысы Сәгыйть Хафизов, Татар иҗтимагый үзәге рәисе, шагыйрь Рәшит Ягъфәров кебек күренекле шәхесләр үсеп чыкты.

Соңыннан безне кем сатканын да ачыкладык без. Безнең факультеттан түгел иде ул, ә милләте буенча татар кешесе булып чыкты. Күрәсең, коммунистик идеяләрне "тирәннән" аңлаган әлеге иптәш безне шулай ялгыш юлдан "саклап калырга", үзенең киләчәктәге карьерасына ныклы нигезле юл салырга тиеш булган.

Болар хакында ни өчен яздым соң әле?! Бер дә язмас идем дә, бүгенге татар зыялыларының "миллият дәресләре"ннән бихәбәр булуына үртәлеп, ак кәгазьгә шушы юлларны төшерергә мәҗбүр булдым бугай. Мисаллар бик күп бит. Татар имласына латин хәрефләрен кайтару турында җитди сүз башлангач, инде ул законлаштырылып килгәндә, аңа Мәскәүдән бер төркем татар интеллигенциясе вәкилләре каршы төште. Хатларын бөтен үзәк газеталарда бастырып чыгардылар. Араларында хәтта Казанда чакта латинга кайтуны хуплап тавыш биргән, Мәскәүгә күчеп киткәч кенә нишләптер кинәт фикерен үзгәрткән якташыбыз да бар иде. Татар дигәнең үз иптәшен сатмыйча гына Мәскәү каршында дәрәҗәгә ирешә алмыйдыр шул! Менә шундый күңелсез уйлар туды бәйрәм кичәсендә утырганда. Ә инде Россия Дәүләт думасының татарның латинчаны кайтарырга омтылуында "Россия дәүләтчелегенә, сәяси тотрыклыгына янау" күрүе бөтенләй аптырашта калдырды. Үзләрен Рәсәй халкының вәкаләтле вәкилләре санаган депутатларга татарлар үз телләренә ятышлырак, камилрәк имла файдаланса зыян була микәнни? Тулаем алганда, рустан гайре халыкларның ни телен, ни гореф-гадәтләрен, ни асыл тарихын белмәгән һәм еш кына белергә дә теләмәгән депутатлар ни өчен башка бер халык мәнфәгатен санга сукмый?! Юкса, ул халыкның үз республикасы, Конституциядә язылганча, үз дәүләте, үз парламенты, үз депутатлары, халык үзе сайлап куйган Президенты бар лабаса! Дәүләт думасының бу гайре табигый карары акылга сыймый, мантыйкый фикерләүне хәтерләтми. Бөтен илләрнең иң прогрессив язучыларын туплаган Бөтендөнья ПЕН Үзәге аны шулай дип бәяләде дә. Әле 1906 елда иекнче бер бөегебез Габдулла Тукай Россия империясе Дәүләт думасының кылган эшләре хакында бик үтемле итеп, "Әй, бәгърем Нәгыймә" көенә:

Ник бик тиз беттең син, Дума,
Ник җир-ирек алмадың?–
Ах, син, Дума, Дума, Дума,
Эшләгән эшең бума?–

дип язып калдырган булган. Бүгенге Думаның сыра рекламасын чикләү, эш урынында тәмәке тартуны тыю, татарның латин имласына юл куймау кеби "актуаль", берсеннән-берсе вак, ил тормышында мөһим роль уйнамаган мәсьәләләр белән мәш килүен күргәч, ирексездән шул юллар искә төшә. Шуңа өстәп, инде Конституция суды да имла мәсьәләсендә шул карарны яклады. Ләкин боларның барысының да "ак җеп" белән тегелгәнлеге, бары тик татарга "үчләшү"дән килгәнлеге, бернинди мантыйкка сыймавы ап-ачык лабаса! Татар теленә уңайлымы-юкмы, тел үзенчәлегенә җавап бирәме, алары мөһим түгел. Кириллицада язасыз һәм... вәссәлам! Илдә кем хуҗа икәнен белегез!

Соңгы елларда Татарстанга карата Мәскәү үткәргән сәясәт һаман шомландыргыч төсмер ала бармыймыни?! Мөстәкыйльлек Декларациясендә кабул ителгән, Россия белән Татарстан арасында төзелгән Шартнамәдә каралган пунктлар көчсезләндерелә, тешсезләндерелә бара. һәм болар барысы да

ниндидер астыртын, яшерен рәвештә эшләнә. Без республика тапкан, димәк, халкыбыз тир түгеп эшләп туплаган барлык байлыкның 80 ләп процентының Мәскәүгә китеп баруын да яхшы беләбез. Гаделлекме бу? Татар халкына, татар теленә карата Русиядә кайчан да булса бер гаделлек булырмы? Аның өчен тагын әллә нинди тетрәнүләр кирәк микәнни соң?

Тарихтан билгеле, халкыбызның бөек мәгърифәтчеләре, акыл ияләре әле XVIII гасырда ук татарча газета чыгару уе белән яна башлыйлар. Әмма патша хөкүмәте берсеннән-берсе мәгънәсез һәм усал сәбәпләр табып, газета чыгаруны тыеп килә. Бу хыял бары тик 1905 елдан соң, патша строеның нигезен тетрәтә башлаган инкыйлабтан соң гына тормышка аша. Сүз уңаеннан, киләсе елга ул революция булганга да нәкъ 100 ел тула икән.

Бу очракта миңа Россиянең идарәче даирәләре тарих тәгәрмәчен кирегә таба әйләндерергә, һичьюгы аны туктатып торырга тели кебек тоела башлый. Бөтен дөньяда глобализация дигән нәрсәнең таралуы беркемнән дә сер түгел. Мәскәү үзе бүген, рус шәһәреннән бигрәк, Европа, Америка шәһәрләрен хәтерләтә. Адым саен латин хәрефләре белән язылган реклама, һәркайда— инглиз лөгате өстенлеге. Баксаң, руслар үзләре дә латин хәрефләренә мөрәҗәгать итәргә мәҗбүр икән. Шушы шартларда татар телен кириллицага закон белән бәйләп кую мантыйкка, аек акылга сыймый да сыймый инде. Ни гаҗәп, андый гамәлләр уртак илебездә байтак шул.

Шушы көннәрдә генә кулыма нәниләр өчен ярты миллион данә тираж белән чыгарылган бер китап килеп керде. Игътибар белән рәк актара барган саен күңелемдә ничә еллар борынлап килгән шикләрем тагын калкып чыкты. Балаларга рәсемнәрен буяп бизәр өчен "Вместе мы— русские" исемендә чыгарылган китап ул. Игътибар итегез, беренче битендә эре хәрефләр белән болай дип язып куелган (мәгънәсен бозмас өчен оригиналда китерәм): "Дорогие маленькие художники и их родители! Нас, живущих в России, 150 миллионов человек. 200 больших и малых народов нашей страны составляют Великую Русскую Нацию". Юкәдә икән чикләвек! Сиздегезме, кадерле туганнар: татарлар, башкортлар, бурятлар, калмыклар, удмуртлар, мордвалар вә гайреләр билгесез нәшриятның кем тарафыннан чыгарылуы нәмәгълүм китабы нигезендә, барыбыз да бөек рус милләте булдык та куйдык. Ничә йөз еллар буе патша хөкүмәтенең асыл хыялы тормышка аштымыни?! Дөрес, китапны "Русь" берләшкән Россия партиясе чыгаруы әйтелә әйтелүен. Бигайбә, әмма минем андый партия хакында беренче ишетүем. Балаларның милли аңына үтә дә мәкерле диверсия ясаучы бу китапның дөнья күрүендә милләтләргә карата кылынып ятучы бер-бер этлек тоемланмыймыни?! Әле дә хәтердә, СССР заманында да шундыйрак бер талпыныш булган, югары трибуналарда, партия документларында советлар илендә "бердәм совет халкы", ягъни шул исемдәге милләт барлыкка килүе тәкрарлана башлаган иде. Идарәче даирәләрнең бу гамәле безнең шикелле үк СССР дигән уртак бер түбә астында яшәп яткан латышлар, эстоннар, литвалылар, грузиннар, әрмәннәр, украиннар, казакъләр, үзбәкләр һәм башка милләтләрнең күңеленә бер дә хуш килгәндер дип уйламыйм. Совет Социалистик Республикалар Союзының бер төртүдә таралып төшү сәбәпләренең берсе — иң җитдие шунда түгел микән әле?! Әмма, ни генә дисәң дә, ул вакытларда илдә әле милли сәясәт дигән нәрсә, үзләре белән санлашырга мәҗбүр итәрлек, үз тарихларын тирәннән өйрәнгән, яшь буыннарын шул рухта тәрбияләгән көчле милләтләр бар иде. СССР таркалып, ул халыклар суверен дәүләтләрдә яши башлагач, без татарлар рус шовинизмының дуамал һәм астыртын сәясәтенә каршы көрәштә япа-ялгыз тордык та калдык. Япа-ялгыз!.. "Минем кулым түгел, Гайшә Патыйма кулы" дигәндәй, бу сүзләрне каләмем үзеннән-үзе язып куйды шикелле. Аңлыйм югыйсә, без ялгыз ук түгел түгелен, әмма Татарстан белән янәшә, Идел-Урал төбәгендә урнашкан республикаларда: мариларда, удмуртларда, чувашларда, мордваларда милли хәрәкәт артык сүлпән. Башкортстанда исә бөтенләй үзгә вәзгыять. Әле шушы көннәрдә генә 2002 елдагы халык санын алуның ахыргы йомгаклары мәгълүм булды. Алардан күренгәнчә, 1989 елдан 2002 елга кадәр Башкорстанда татарлар саны чирек миллион кешегә кимегән. Ел саен егерме

меңгә якын татар үлеп барган диярсең. Ни булган соң ут куршебездә? Татарлар берәр кая күчеп китмәгәндер, яисә, тьфү-тьфү, үлеп бетмәгәннәрдер ич! Юк шул! Аллага шөкер, милләттәшләребез бар, яратышалар, сөешәләр, гаилә коралар, тормышларына ямь өстәп өйләренә сабый-нарасыйлар алып кайталар. Ә халык санын алу йомгаклары исә Башкортстан идарәче даирәләренең гасырлар буе шул җирләрдә – газиз ватаннарында яшәп яткан милләттәшләребезгә карата алып барган "башкортлаштыру" сәясәтенең аянычлы нәтиҗәсе, шуның саннарда чагылышы. Әлегә кадәр ике республика арасында бу кадәр алдашуны, итәк астыннан ут йөртүне тарих белми иде. "Татарлар безнең ут күршебез, башкорт-татар дуслыгы яшәсен!" дип тәкрарларга яраткан Башкорстан җитәкчелеге, асылда, татар халкын "йоту" юлына аяк басты. Җитлеккән, чуандай сытылырга әзер милли проблемаларны Кавказдагыча хәл итәргә омтылу исә безнең юл түгел. Татарстанның үз юлы бар, сәяси мәсьәләләрне уртага салып сөйләшеп, киңәшеп, фикер көрәштереп хәл итү юлы ул. Шунлыктан, безгә милли мәсьәләдә аеруча уяу булырга, һәр гамәлне тирәннән уйлап, юридик яктан черки дә борынын тыкмаслык дәрәҗәдә нигезләп башкарырга кирәк. Ә моның өчен укымышлы, милли хисле яшьләрнең күп булуы зарур. Киләчәгебез алар кулына каласы. Инде килеп, Россиянең федератив корылышын бетереп, аны сигез губернага калдырырга җыенулары хакындагы имеш-мимешләр күңелгә бер дә җылылык өстәми. Хәер, аны "имеш-мимеш" кенә дию дөреслеккә бик үк туры килеп тә бетмәс. Чөнки мондый чакыруларның кайдан, кайсы трибуналардан яңгыравын күреп, ишетеп торабыз. Беренче тәҗрибәләр башланды да бугай инде. Шулай! Ни кадәр кызганыч булмасын, җавапка караганда, сорауларны күбрәк куярга туры килә. Нишлисең, заманы һәм вәзгыяте шундый. 2002 елда халык санын алу дигән мәрәкәдә татарның санын киметү өчен үзәк хакимиятнең ниләр генә кыланмаганлыгы да исебездә бит әле. Аларны кабатлап язып торуның кирәге юктыр дип беләм. Нигә татардан шикләнәләр, аны күрмәмешкә салышалар икән?! Юкса, Русия дәүләтенә татардан да күбрәк, тугрылыклырак хезмәт иткән бүтән бер кавемне белмим мин. Рус фәнен һәм әдәбиятын алга җибәргән аксөякләрнең, илне саклауда тау булып күтәрелгән рус сәргаскәрләрнең байтагының тамырларында татар каны акканын белмибезмени?! Сугышларда иң кыю, куркусыз яугирләр безнең милләт вәкилләре булмадымы? Борынгы Петербург татар сөякләре өстендә калкып чыкмадымыни? Мәскәү метросы төзелешендә, шахталарда маңгай тирен түкмәдеме милләттәшләребез? Барысы да шулай. Беләбез.

Бүген, кайбер даирәләрдә патша Россиясенең карагруһчыл милли сәясәтен терелтергә азаплану сизелгән көннәрдә, безгә боларны истә тоту белән бергә, милли үзаңыбызны, милли мөстәкыйльлегебезне дә үстерергә кирәк. Дәүләт мөстәкыйльлеге бер нәрсә, дәүләтнең-республиканың киңлекләре чикләнгән, алар картадагы меридианнар һәм параллельләр аша бер кысага утыртыла; ә милли, рухи мөстәкыйльлек бөтенләй башка, аның чикләре юк, ул безнең йөрәкләребезнең кыл уртасыннан бәгыребезне телеп уза. Аны ниндидер кысаларга утыртып чикләү мөмкин түгел. Кеше акылы башкалар ихтыярына буйсынмау сәләтенә ия. Һәм ул хис көчлерәк булган саен, асыл тарихыбызны тирәннән өйрәнеп һәм белеп, аны дөнья халыкларына да таныта алсак, безнең белән исәпләшүчеләр дә арта барыр. Һәм бу изге эштә без галиҗәнап татар китабының, бөек татар әдәбиятының тоткан урынын яхшы аңлыйбыз, аның якты киләчәгенә ышанабыз.

Бер юбилей кичәсендә катнашу күңелдә менә шушындый уйлар кузгатты да ташлады. Кеше уе белән көчле. Уйга килгән, башка кергән әйбер кайчан да булса барыбер тормышка аша, фикерләр, акыл энергиясе буларак, кайчан да булса бер материальләшә бит ул. Мин шуңа ышанам. Ходай кушып, Татар факультетының 100 еллыгын күрергә, Татар милли университеты ачылу тантаналарында катнашырга да насыйп итсен, газиз милләттәшем!

*26 ноябрь, 2004 ел.*



## Зиннур Мансуров

# ЧЫРАГ ТОТКАН ХӘТЕР ЙӨРИ...

### Онытылган төшләрем

Тонык кына иртә таңда күреп,
шундук онытылган төшләрем
төшендерде хәтер төпкелендә
әллә нинди серле төш барын.

Акыл белән аңлап булмый кайчак
хыял уенының мәгънәсен;
фалчы сыман җепкә тезеп карыйм—
зиһенемдә ник бер мәл калсын.

Анык җавап әзли уяу өнем,
(Аллаһ башны гына сау кылсын):
йөрәгемне яман юраулардан
нинди тылсым көче саклый соң?

Сөенчегә торыр төшләремне,
димәк, миннән кемдер күпсенә...
Томан аша сорау белән багам—
белә моны бары Күк кенә.

Тәшвишләнәм: таңгы төшләремә
әллә соң ул табу саламы?!
Гаҗиз чакта кайтып җитми миңа
ишарәле әнкәм сәламе...

Искәртүсез килгән күрәчәктә
ачык бeләм ничә төс барын.
Рәшә кебек арттан калмый бара
онытылган серле төшләрем.

Зиннур МАНСУРОВ (1949) – *шагыйрь, публицист; «Кул бирәм», «Ваем», «Җәрәхәтле йөрәк җылырак»* һ.б. китаплар авторы. Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе. Казанда яши.

## Волынка

*Болгария. Казанлык шәһәре. 1995 ел.*

Казанымны уйлап атлыйм Казанлыкта,
монда мине әйдәп йөртә Яз кызы...
Бәрәкалла: ап-ак чәчле болгар карты
волынка*да уйнап тора ялгызы.

Сурга өргән гарше заттай шундый мәэюс—
җәлләп куйдым моңлы күрек хуҗасын...
Уң як биткә бәллүр тамчы килеп кунды,
апрель күге тота алмый күз яшен.

Яшел тауга әллә дәррәү болыт иңгән,
әллә анда куй көтүе йөриме?
Куенына авыр капчык кыстыргандай,
кардәшемнең төшеп тора бер иңе.

Бәгърендәге барлык-барлык ваемнарны
тыны белән өреп кертә турсыкка.
Гаҗәпләнмәм әче янар волынкадан
сүзсез генә үзәк өзгеч җыр чыкса...

Кызгандыргыч музыкантның күзләренә
озак карап тордым бугай, бигайбә.
Тәкъдиреңә язылганны татыгачтың,
үкенүдән, уфтанудан ни файда?!

Бүленгәнне инде бүре ботарлаган,
аерылганны күптән аю ашаган.
Таралганны көтеп кенә торучылар,
бөрадәрем, бүгенгәчә ач һаман!..

Казанымны уйлап атлыйм Казанлыкта,
монда мине әйдәп йөртә Яз кызы.
Куптарылып чыгар булган Кубратханмы
волынкада уйнап тора ялгызы?!

Моң-зар белән тутырырга язган безгә
язмыштагы аерылышу бушлыгын.
Кыйтталарга сөрән сурын кычкырткалап,
ул җыярга тели бугай биш улын.

Бигрәк кыйбат була икән нәфес хакы—
сыкрап-сыктап елый... сарык карыны;
бүлгәләнгән Бөек Болгар биләмәсен
эзләп китә волынканың һәр өне...

Казанымны уйлап йөрдем Казанлыкта,
ятим җаным Күккә ыграк сыгынды.
Кайтавазы кайта торды көй-моңнарның,
каттый тәкъдир хөкемедәй: «Соң инде!..»

Соң инде...

* Волынка - күреге куй-сарыкның ашказанынннан ясалган халык тынлы уен коралы.

## Язусыз ташбилге

*—Сөембикә ханымның кабер ташы*
*шомартылды—ни яздырыйк?*
*—Берни дә язмагыз!..*
(Р.Батулла. «Сөембикә» кыйссасы).

**Чыраг тоткан тере хәтер йөри,**
**үксез кабер ташын яд кылып,—**
**язылмыйча калган ләүхелмәхфүз***
**тора төсле айдай яктырып.**

**Тәкъдиреңә өстәп иңдерелгән**
**ап-ак бит күк балкый—яз гына;**
**әүвәл кучер кара көннәр гамен**
**күңелеңнең аяз ягына.**

**Хәттин ашкан хәттат кебек үзгәрт,**
**фәрештәдән ал да кавырсын:**
**язмышыңның төзәт ялгышларын,**
**табыш итеп күрсәт кайберсен...**

**Зольмәт тулы өнгә саркып чыксын**
**татлы төшләреңнең яктысы.**
**Әҗер килер—син бит түгел әле**
**үз тәкъдиреӊ өчен ят кеше.**

**Ярлык сүзен юып ала кайчак**
**күздән тамган бары бер тамчы...**
**Карурманга кертеп адаштырган**
**дала атын кире борсаңчы!..**

**Артка чиген, хәтер—дәшеп алсын**
**утрак җанлы мәгърур балбал-сын,**
**Казан белән бергә каза күреп,**
**газап чиккән гаярь баласын...**

**Шулай була—хаким иргә чыгып,**
**уртаклашкач илең язмышын.**
**Нигә әле, яшен, чиста биткә**
**матур йомгак өстәп язмыйсың?!**

**Галибанә күкнең ихтыярын**
**белгерт, әйдә, җиргә сузылып,—**
**төкәнмәгән тәкъдир тактасына**
**тамгаң төшсен соңгы сүз булып.**

**Бәлкем әле, әдип, гөнаһ имәс—**
**каләмеңне якты айга ман;**
**яңа биттән, кызыл юлдан башла:**
**хан исән, дип, дәүләт аумаган.**

**Ханбикәне җанлы ганимәттәй**
**биреп җибәрмәгән ил-көн дә...**
**Инде беркем алай яза алмас—**
**барысы да Аллаһ иркендә.**

---

* Ләүхелмәхфүз - язмыш тактасы.

**Корамадан торыр каралама**
**түгел язмыш—булмый үзгәртеп.**
**Әмма күңел көтә: Хозыр Ильяс**
**узса икән бер-бер сүз әйтеп!..**

**...Чыраг тоткан тере хәтер йөри,**
**үксез кабер ташын яд кылып.**
**Соңга калып кунган һомай* кошның**
**каурыйлары ята яктырып...**

## Ату җае

*Х. турында уйлап*

**Сихри урман. Суер кошны күзлим—**
**и көйли ул, онтып бар гамен!**
**Белми бугай бәгырь мена шулай**
**әҗәленә җырлап барганын.**

**Серле итеп әйткән иде сунар**
**ату өчен мөһим шарт барын:**
**«Җырлар мәлдә генә алып була**
**мондый сизгер киек затларын...»**

**Ышыкланып шомлы ешкынлыкта**
**утырганда иллә сак үзе.**
**Сәер мәкам белән җырлый суер,**
**яшьтәй ага нарат сагызы...**

**Көйләр белән күккә аша кебек**
**барлык keләүләре Җир-суның.**
**...Иләс түгел иблис—көтеп ала**
**моңга оер чагын Җырчының...**

## Озын көй

**Хәтерлимен Донбасс шахтасына**
**кунак булып төшкән чагымны.**
**Моң-зар белән тулып ашкан күңел**
**шундый сизгер, шундый сак иде.**

**Чакрымладым күмер катламнарын—**
**нәкъ шахтерлар кебек эш иттем.**
**Җирнең җиде катын үткән мәлдә**
**синең җырлавыңны ишеттем.**

**Бәргәләнеп татар бәгырендә,**
**язмыш юлын бергә узган җыр!..**
**Тетрәнүдән шахта терәүләре**
**шартлап сынмый ничек түзгәндер?!**

**Иңләп килгән алкын ташу булып**
**забойларга тулды тавышың.**
**Бөтен миргә сыймас татар моңы**
**биләп алды кысан тау эчен.**

* Һомай - бәхет кошы.

Кояш-айдан мәхрүм тирәнлектә,
балкыш ясап, сихри ут яктың.
Шушы озын көең белән, Җырчым,
ыругдашлар рухын уяттың.

Шундый озын иде сузган көең,
күмер базы шундый тын иде.
Кардәшләрнең моңы гарешләрдән
урап кайткан төсле тоелды.

Моң-мәкамең белән көтелмәстән
җирдә тетрәү хасил иткәндә,
үз-үземнән сорап өзгәләндем:
«Аңладыңмы инде, и бәндә?

Язмышыңда өскә ябырылган
моң-зар ташкынына терәү юк...
Төшендеңме тау-таш төпкелендә—
безнең җырда нинди тирәнлек!»

...Хәтерлимен Донбасс шахтасына
кунак булып төшкән чагымны.
Ишеткәндә синең тавышыңны
җаным шундый сизгер, сак иде...

## Уникенче елгы шәраб

*Ни була...*
*Бу ачы гомрем шәрабен эчмәсәм?!*
Г.Тукай.

«Эчеп җибәр,—диде сакый,—Кырым сыен,
үз-үзеңне Хәйям итеп сана да...»
Уйга калдым: ошбу шәраб әзер булган
мең тугыз йөз уникенче сәнәдә!

Тукай инде соңгы җәйгә кереп бара,
сынык саздан саркып чыга мәгърур өн...
Берни белән имли алмый икән бәндә
ачы гомер шәрабенең макмырын.

Башка сыймас хәлгә җитеп тетри акыл,
үз-үзенә урын таба алмый җан.
Сырхау тәнгә тансык дәртен өстәп торыр
энкәң сөте инде тәмам айныган.

Тулы гасыр кичкән кебек була икән,
гәрчә гомер тоелса да өч көнлек.
Йөрәгеңне ахыргача яндырачак
сихри гайрәт биргән шушы эчемлек.

Тәкъдиренең тәдавел*ен тәгамлаудан
кайсы гына шагыйрь заты кача соң?
Дөнья йөзен кайчак читтән күзләр өчен
тоту кирәк сихри Җәмшид касәсен.

* Тәдавел—бүтән халәткә кертә торган тылсымлы ширбәт.

Шулай гына күрә ала үҗәт җаннар
кайгы, шатлык, җәбер-золым, наз төбен...
Кайдан килер иде аңа андый холык,
әгәр Тукай әчмәс булса насыйбын?!

...Йөзем багын җылы яңгыр юып үтте,
тустаганга нидер тамды өстән дә.
Кичер, Аллам: әллә ниләр уйлап куйдым
уникенче елгы шәраб эчкәндә.

## Турылык

Гарьле башка нинди гамьнәр басмый—
телең әйтмәгәнне күз сөйләр.
Туры кеше булу җиңел түгел,
хөкем сөрсә кыек күзгеләр.

Кыек юлдан илең туры барса,
оятына түзми кер утка.
Монафикълар төзгән манараның
эче кәкре булыр кырыкка...

## Ихласлык фаҗигасе

Яңа елда җанвар булып
киенгән нәни улын
сөйде ана: «Тик бел шуны:
битлек астында—уен...»

Балигъ яшьтә балга баргач,
бәлагә тарган улын
аяп, ата: «Нык тор,—диде,—
битлек астында—уен...»

Ике йөзле дөнья белән
пәрмә-пәр килгән улын
дәште күкләр: «Син кал өстен—
битлек астында—уен...»

...Сынчы килеп йөзлек алгач*,
яд кылып Адәм улын,
көлде иблис: «Бар, кит аңлап:
битлек астында—уен,
битлек
астында—
уен...»

## Тәкәбберлек

Булыр икән җирдә башлы токым,
әмма сөйли кайчак чын ялган:
тәгәрмәчне, имеш, мәгарәдә
әүвәл алар уйлап чыгарган.

* Мәрхүмнең йөзеннән битлек (маска) алу күздә тотыла.

Үзен шундый эре итеп тота—
тәкәбберлек анда тау чаклы!
Юкса алар уйлап тапкан бары
тәгәрмәчкә тыгар таякны...

## Гайре юлдан китү

...Комедиян, Мольер, камиллектә
туктар төсле өлге булудан,—
яшәү инде күптән китеп барды
аңга сыймас гайре бер юлдан.

Артта калды хәтта битлек аша
ихлас карый алыр ул заман.
Хәзер гавам эчтән сыкрап елый
ачы көлгән чакта узаман...

Трагедия, Эсхил, чынбарлыкта
инде башкачарак корыла:
һәлакәтле хәлләр ахырында
«герой» исән кала, хор үлә...

Еламсырап иблис елмайгандай
канга батып туган таң аша.
Менә шундый, Мольер, эшләр бездә,
менә шундый, Эсхил, тамаша!..

## Бәхиллек

Көтмәгәндә төшкә кертеп, күкләр кат-кат искәртте:
түшәгендә үлеп ята әүлиядәй ил карты!

Кардәш-ыру, таныш-белеш өзгәләнеп аһ итте,
барчасы да газиз затның хозурына ашыкты.

Гарше көрси хәбәреме: «Ай-яй, җирдә күп күрдең!
Ике тапкыр кичү язган сиңа сират күперен...»

Нишләп була—Хактан узып, кол итүче ил бит ул,
үз халкына кызыл камыт киертүче ил бит ул...

Әһле иләт уза торды җыйнак кына ак өйгә,
ашкындылар аксакалның бәхиллеген алырга.

Нигә әле карт катына гөнаһланган ил килми?
Кылганына гафу сорап, баш очына иелми?

Кирәк түгел мени аңа бәхилләшү нигъмәте?..
Үлеп ята мең бәладән коткарырлык ил карты...

## Ярату хасияте

Рухиятем шулай яратылган:
сөю угы мине тиз ала.
Әмма тәндә мәхзун* җаны бугай—
яраларым озак төзәлә.

Минем халәт, каумем, сиңа бәйле—
яраларым озак төзәлә,—
сабыранә сөеп савыктырам,
ә төбендә барыбер тоз кала...

## Очраклылык

Нигә әле, яшьнәп алмас борын,
черек ташлар ява бу башка?
Фәрештәләр хәтта фаразламас...
Тиеш иде болай булмаска!

Каенсарда яткан әниемнең
алдан керде микән төшенә,—
барыр юлга инде гөлләр тама,
була күрсен миңа төс кенә...

Әмма күңел тынып торган мәлдә
әзәрлекли сәер уй мине:
салмак җанга тәңгәл тәкъдир белән
әллә... очраклылык уйныймы?!

Шундук тәүбә кылам—мондый сүзне
башым уйлап, телем ник әйтте?
Хәерлегә булсын, очраклылык—
ул үзе дә язмыш нигъмәте.

## Атым

Кемдер пычрак аткач, искә төште
күлдә акбүз атны юганым.
Минем әле яшь-яшь егет чагым,
юк дәрәҗәм илдә, юк даным.

Суга җәйгор үзе төшкән иде,
аллы-гөлле нурлар уйнатып...
Балкып торган атка әфсен өрдем,
сихри дога сүзен ун әйтеп.

Кинәт... ике канат үсеп чыкты—
чит атмы бу, әллә үз атым?!
Нихәл итим: менә шулай аны
ак-пакь килеш күккә озаттым.

Үзе өчен лаек очыш теләп,
куптарылды ярсу күңлемнән.
Минем атны җирдә һәрбер кеше
карап калды яхшы күз белән.

Инде хәзер рәхмәт юлын иңли,
түбәнлектә эше юк аның.
...Кемдер пычрак аткач, искә төште
күлдә акбүз атны юганым...

* Мәхдун—гомерлек кайгыга дучар ителгән кеше.



**Мәдинә Маликова**

# ЧӘЧКӘ БАЛЫ

ПОВЕСТЬ

* * *

Җәйге кич үзенең йомшак кара канатын ыгы-зыгылы, тузанлы, гөрелтеле шәһәр өстенә җәеп, аулак ишегалларын җылы эңгергә төргән, ә баганалардагы утлар исә кабынмаган иде әле. Хәлбуки вакыт бик соң—машина кабинасындагы электрон сәгатьтә “22.14” дигән саннар биешә, төн уртасы җитәргә дә күп калмаган иде. “Көн дә озын югыйсә, һаман җитешеп булмый. Сәгъдия тагын турсайгандыр инде, озак тормам, дигән идем”,—дип уйлады Гамил, кызыл күзен акайткан светофор каршында машинасын туктатканда.

Чыннан да, шәһәрдә әллә ни зур йомышы юк, берничә йортка сугылып кына чыгасы иде. Әмма һәрвакытта да син уйлаганча гына барып чыкмый бит ул.

Эш шунда ки, Гамил кечкенә генә “бизнес” белән шөгыльләнә—Мәскәүдән паласлар, келәмнәр алып кайтып сата. Таныш-белеш, күрше-күләнгә, теләгәннәрен махсус эзләп табып, өйләренә илтеп бирә. Бүген дә менә Таллыдагы танышларына дүрт палас алып килгән иде. Син ашыкканда ул кабалана дигәндәй, андый чакта кергән җирдән тиз генә борылып чыгып китеп булмый шул. Берәүләрнең эштән кайтканын көтәргә туры килде. Икенчеләре товарны идәнгә җәеп салып, озаклап карап, тикшереп, тормыш авырлыгыннан зарланып, чәй эчәргә кыстап аптыратты. Җайларына тормый булмый, кашны җыерырга ярамый. Сатучының товары, елмаю нурына манчып, сүз балын ягып бирсәң генә, яхшы үтә.

Хәзер инде ашыгырга кирәк иде. Хатыны Сәгъдия биреп җибәргән күчтәнәчне—бер банка чәчкә балын—балдызы Сәриягә кертеп тапшырасы да тизрәк шәһәрдән чыгып китәсе. Аннары аны Аланлык авылынача утыз чакрымлы юл көтә.

Зәңгәр бөркәвечле күксел “Газель”не урам якта гына калдырып торырга булды Гамил. Тугызар катлы йортлар арасындагы тыгыз ишек алдында

---

Мәдинә МАЛИКОВА—*язучы; “Кар сулары”, “Шәфкать”, “Алтын ятьмә”, “Өермә” һ.б. китаплар авторы. Россиянең һәм Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре. Казанда яши.*

машина белән болганып йөрисе килмәде. Хәвеф-хәтәр булыр, дип шикләнерлек тә түгел: вакыт соң булса да, урамда кеше йөреп тора. Көлешеп-шаулашып төркем-төркем яшьләр уза, бала житәкләгән парлар каядыр бара. Көндез эшләп армаганнар, күрәсең, йокларга ашыкмыйлар.

Ул кабинадан сикереп төште дә, банка салынган полиэтилен капчыкны алып, ишекне шапылдатып япты, сигнализацияне тоташтырды. Аннары ашыгып озын йортның уртасындагы, беренче кат биеклегендә уелган зур аралыкка юнәлде.

Ишегалдына барып кергәч, күнеленен нечкә бер кылы сулкылдап куйды. Ана таныш урам, күнегелгән мохит, жанга якын сукмаклар иде болар. Күп таптады ул биредәге асфальтны. Язгы-көзге өмәләрдә, башкалар белән бергәләп, ишек төпләрен себереп, агачлар утыртып йөрде. Әнә, ул утырткан каеннар, шомырт-миләшләр нинди биегәеп, жанга тынычлык биреп, серле карангылыкка төренеп утыралар.

Каршы яктагы тугыз катлы йортта Гамилнең бер бүлмәле фатиры бар. Биш еллык хезмәтенен жимеше. Хәзерге вакытта анда балдызы Сәрия яши. Өйдә булса ярар иде. Кучтәнәчне бирергә дә, апасыннан сәлам әйтеп, китәргә кирәк булыр...

Ләкин ул ишегалдынын уртасына да житә алмады, урам ягыннан машина сигнализациясенен ачы итеп, өзек-өзек чинаганы ишетелде. Тәрәзәсен ватып, магнитоланы алып китмәсеннәр тагын... Гамил, борылып, кире йөгерде. Ана каршы, йорт астындагы күләгәгә өчме-дүртме малай чабып килеп керде. Ул аларны әйләнеп узмакчы иде, ләкин...

Берәү аяк чалды, икенчесе арттан китереп бәрде. Гамил гөрселдәп егылды, сумкасы шартлап бәрелде, пыяла ватылган тавыш ишетелде. "Бетте бал..."—дип уйлады ул. Һәм шундук сикереп торырга талпынды. Әмма калкынып өлгермәде, арттан башына китереп суктылар. Ул кире асфальтка ишелеп төште. Каты сызлаудан күзе томаланган иде, тирәсендә болганган өч-дүрт адәм затынын чыраен аера алмады. Пырдымсыз хәрәкәтләреннән, өзек-өзек сулыш алуларыннан гына бик яшьләр, ә бәлки, үсмерләр икәнен чамалады. Андыйлар аеруча кансыз, шәфкатьсез була... Башны сарган томан аша берәүнен:

—Готов!—дигәне ишетелде.

Каты куллар кесәләрне актарды—тән буйлап ач күселәр чабышкан кебек тоелды. Ул, сакланырга теләп, кулларын күтәрде.

—Лежи, сука!—диде берәү һәм Гамилнең күкрәгенә ике-өч тапкыр каты итеп төртте. Джинсы күлмәк тукымасы шытырдап ертылды. "Пычак..."—дигән уй узды баштан.

—Атас!—дигән тавыш ишетелде шунда.—Киләләр! Таегыз! Тизрәк! Атас! Башта калын тавыш белән башланган бу кычкыру кинәт кенә балаларча нечкә янгырашка күчте. Һәм бу үзгәрештә, анын борылышында, сулыгып тын алуында бик таныш, бик үз һәм жанга якын аһән янгырап куйды. "Улым...—дигән уй чагылып узды башта.—Газим тавышы..." Бу уй зиһенгә сарылган томанны яшен кебек ярып узгандай итте. Гамил чонгылга убылган кебек булды...

Күпме вакыт һушсыз яткандыр, өстенә иелгән ир кешенен сулышыннан айнып китте ул.

—Ташласана, урамда аунап яткан һәр исерекне без генә кайгыртып бетерә алмабыз,—диде хатын-кыз тавышы.

—Хатыннарнын шул булыр инде. Егылып яткан һәр ир заты исерек, сезнеңчә. Ә бәлки, йөрәге тоткандыр анын. Йә бәреп киткәннәрдер... Чыннан да... канга баткан бит бу!..

—Кагылма!—диде, ярым пышылдауга күчеп, ысылдап, хатын. Үзе бераз читләште дә булса кирәк.—Орына күрмә! Милиция килеп чыкса, ин беренче итеп үзенне тотып алырлар! Ябып куярга да күп сорамаслар!.. Китик тизрәк! Әйдә, дим!

Ир кеше исә Гамилнен йөзенә тагын да якынрак иелде.

—Әй, син мине ишетәсенме?

—Ишетәм. Торырга ярдәм итегез...
—"Скорый" чакырыйкмы?
—Юк... Кирәкми... Мин монда гына...
Гамил, хәлсез кулын көчкә күтәреп, ишек алдына, каршыдагы тугыз катлы йортка ишарәләде..
—И бәйләнден юкка...—диде читтәрәк торган хатын. Ләкин бу юлы тавышы йомшарган иде инде.
Ир кеше күкрәк турыннан тотып күтәрмәкче иде, Гамил каты ынгырашып җибәрде.
—Ә бәлки, сине кузгатырга ярамыйдыр?—диде узгынчы.
—Син мине кулымнан тот... Өйгә генә керим. Лифт эшли анда...
"Өйгә, лифт" дигән сүзләр хатын күңелендәге шомны бераз таратты булса кирәк. Мондый очракта кешене өенә кертеп куюдан да яхшысы юк бит инде. Милиция күзенә дә чалынмыйсың, шәфкатьле булып та каласың. Шуны уйлап булса кирәк, хатын да якынрак килеп, Гамилнең күлмәгеннән тотып алды.
Аллага шөкер, аяклары исән иде. Торып баскач, баш әйләнсә дә, атлап китеп булды. Лифтта җиденче катка күтәрелеп, алтмыш икенче фатирның кыңгырау төймәсенә баскач һәм ишек артында аяк тавышлары ишетелгәч, хатын иренең җиңеннән тотып, баскычтан аска таба сөйрәде.
—Әйдә тизрәк, әйдә-әйдә! Безнең кирәгебез бетте монда!
Гамил сынын турайтып басарга тырышты.
Ишек артыннан Сәриянең:
—Кем у-ул?—дип, нечкә тавыш белән сузып соравына, гадәтенчә шаярып җавап бирде:
—Ач тизрәк, балдызым-ялгызым! Ишек төбендә озак торган җизнәләрнең аягы кәкерәя!
Сәрия җизнәсенең мондый шаяруларын кабул итми. Дәшми генә бикләрне боргаларга кереште.Ялгыз яшәгән кыз балага сак булырга кирәк—өч яна йозакны Гамил үзе куйган иде.
Менә, ниһаять, ишек ачылды, балдызның үсмер кыздай нечкә сыны күренде. Аның кызыл халатыннан күз чагылгандай булды. Гамил, алгы тимер тешләрен елтыратып, киңрәк елмаерга тырышты.
Беренче карашка, чыпчык кебек хәрәкәтчән, җиңелчә акыллы тоелса да, күзе үткен, зиһене ачык Сәрия балдызның. Бу юлы да керфеген бер сирпүгә хәлне чамалап алды ул. Җеп кебек кашларын җыерып:
—Кем кыйнады?—дип сорады.
Гамил бармакларын иреннәренә куйды.
—Ш-ш-ш... Шаулама, балдыз...
—Кем белән сугыштың?
—Апаң сиңа күчтәнәч җибәргән иде... Чәчкә балы... Китереп житкерә алмадым. Әманәтне үтәп булмады... Ачуланма инде... Керергә рөхсәт итәсеңме соң?
Аптырап калган Сәрия, юл биреп, кире чигенде.
—Кер әйдә, кер!
Һәм коридорда ут кабызды. Түшәм астындагы лампочкадан саргылт яктылык бөркелде.
—Канга батырганнар бит сине!
—Егылдым. Юл кырыендагы ташка...
—Эчкән идеңме әллә?
— Жизнәннең эчеп аунаганын кайчан күргәнең бар синең, балдыз, ә?.. Аек кеше дә абына. Урамда караңгы бит. Утларны кабызмаганнар... Авыр булса да, син миңа ярдәм ит инде, балдызкай. Бер кечкә шәфкать туташы бул. Йод-мазар бардыр ич бездә?
—Юынгыч янында сездән калганы бар иде бугай.
Сәрия кабаланып ванна бүлмәсенә кереп китте. Һөнәре буенча бухгалтер кызның монарчы яраларны дәвалаганы булмаса да, жебеп төшә торганнардан түгел—җизнәсенең канлы, ертык күлмәген салдырды, диванга

яткызып, инбашындагы, күкрәгендәге сыдырылган өч урынга йод сөртте. Әмма дүртенчесенә—күкрәкнең сул ягындагысына житкәч, туктап калды. Йөрәк өстендәге бу яраның эченнән сүл саркып тора, ул, мөгаен, тирән иде.

—Монысына орынмыйм,—диде кыз нечкә тавышына тимер ныклыгы биреп.

—Сылап куй шунда!

—Ярань йөрәк турында. Тирән. Ташка бәрелгән генә түгел бу. Пычак тыгып алганга охшый... Врач кирәк. Хәзер "скорый" чакырам.

—Нинди пычак! Бәрелдем генә! Бернинди врач кирәкми!

Сәриянең кирелеге күптән мәгълүм—жизнәсе диваннан кузгалып өлгергәнче, тышкы ишек янындагы тумбочкада торган телефоннан "03" не жыйды, өй адресын, Гамилнең исем-фамилиясен әйтеп тә бирде. Аннары, бераз тынып торгач, курәсең, теге якның соравына жавап итеп:

—Пычак белән кадаганнар,—дип өстәде.

Гамил яткан жирендә сикереп куйды:

—Ни дисең син? Егылган диген! Бәрелгән дип әйт!

Ләкин балдыз трубканы куйган иде инде.

—Дөресен әйттем,—диде ул, кызыл бәрхет халатының түшен ал тырнаклы нечкә бармаклары белән сыпыргалап.—Монда килгәч, барыбер күрәләр.

—Китер әле телефонны!

—Пажалыста! Үзең сөйләш!—диде Сәрия кызыл иреннәрен кысып. Һәм телефон аппаратының бавын сузып, бүлмәгә кертеп бирде.—Килеп йөрмәгез, димәкчеме әллә? Барыбер врачка күренми булмый сиңа...

Ә Гамил шәһәрара телефон номерын жыя иде. Кече улы Газимнең тавышын ишетергә кирәк иде аңа. Һич булмаса, аның кайдалыгын белергә... Ләкин трубкадан өзек-өзек чинау гына килә, анда, өйдә, Сәгъдияме, малайларның берәрсеме кем беләндер сөйләшә иде булса кирәк. Гамил, бераз көтеп торгач, тагын шылтыратты, ләкин телефон, йөрәккә бәргән шикелле, кыска-кыска чинавында булды. Аргы башта ялгыш трубканы урыныннан авыштырганнар инде әллә?

Ун минут үттеме-юкмы, ишек кыңгыравы зыңгылдады, дөбер-шатыр басып, өч ир кеше килеп керде. Арадан берсе милиция киеменнән иде.

—Пычак жәрәхәте алган кеше биредәме?

Мондый чакта милиция өлгер! Исәнме-саумы юк, тузанлы ботинкаларын салу юк, лап-лоп басып түргә уздылар, Гамил каршына килеп бастылар.

—Синме?

Ул, теләсә-теләмәсә дә, иңенә япкан диван жәймәсен ачарга тиеш булды.

—Кем чәнчеде?

—Кая, ниткән чәнчү? Егылдым мин, абынып егылдым!

—Ә-ә, шулаймыни? Егылдыңмыни-и? Кай төштә булды инде бу хәл?

—Кай төштә?.. Ерак түгел...

—Ә бәлки, шушында гынадыр? Син егылган урында, очын өскә каратып кем тотып торган инде ул пычакны? Ә бу кем соң әле? Хатыныңмы?

Кара бөдрәләре астыннан йөзе бөтенләй күренмәслек итеп башын игән Сәрия каты дәште:

—Хатыны түгел, балдызы,—диде.

—Хатын өйдә минем,—дип жавап бирде Гамил.—Аланлыкта яшибез без.

—Аңлашыла-а,—дип сузды егетләрнең яшьрәге, буйга озынрагы, яшел күзләрен мәгънәле елтыратып.—Димәк, хатын анда, балдыз белән син монда. Андый очракларда пычаклар биешкәли шул!

Бу сүзләрдән соң жизни кеше сикереп торырга, балдызы өстеннән гаепне төшерү өчен тырышырга тиеш иде. Ләкин Гамил хәлсезләнгәндәй күзләрен йомды, һушын жуйгандай, бөтенләй хәрәкәтсез калды.

Ул арада егетләрнең берсе идән паласын буеннан-буена күздән кичерергә керешге—мөгаен, кан таплары эзләде, икенчесе диван, өстәл асларын карады, аннары ваннадан канлы күлмәкне табып алып чыкты да Сәриянең битенә үк диярлек терәп:

—Аныкымы?—дип сорады.

—Аныкы...

—Иске гәзит бир әле.

Ул арада яшел күзле егет аш бүлмәсеннән агач саплы озын пычак алып чыкты.

—Бу нинди кан таплары монда?

Сәрия үзенең бик четерекле хәлгә тарыганын, аннан ансат кына котылып булмаячагын аңлый башлады. Бу кешеләр чыннан да аны шик астына алганнар иде ләбаса! Әнә бит, берсе гәзиткә төргән күлмәкне кулыннан төшерми, икенчесе пычакны гәзиткә төреп азаплана.

—Югалта күрмәгез тагын,—диде Сәрия.—Минем иң җайлы пычагым ул. Энекәш ясап бирде. Сатуда андый юк.

—Бездә "вещдок"лар югалмый. Ә бәлки, тиз арада сиңа аның кирәге дә булмас әле.

Бу соңгысы шомлы киная булып яңгырады. "Вещдок"! Җинаятьнең дәлиле, димәк! Кызыл таплар ул пычакка каян килеп ябышкан, диген! Карлыган кайнатмасы йоккандыр инде! Моны тиз ачыкларлар ачыклавын, ләкин тикшерәселәре бар бит әле! Ә тикшерүче-криминалистлар иртәгә генә эшкә киләчәк.

Тик нигә соң әле җизни дигән кеше бер сүз дә әйтми? Сораганга җавап бирми, күзен ачмый. Һушын җуйган булып кылана. Аңлашылмый иде бу, бик сәер иде.

Үч иткәндәй, "Ашыгыч ярдәм" машинасы да шактый көттереп кенә килде.

Урта яшьләрдәге ак халатлы хатын, Сәриягә бөтенләй илтифат бирмичә, Гамилдән:

—Кайчан? Нәрсә белән?—дип сорады.

—Кесәдә пәкем ачылып киткән... Шуңа егылганмын...—диде Гамил хәлсез тавыш белән.—Андый хәлләр булгалый минем белән... Кайчакта аңымны җуеп егылам...

—Һәм сезнең кесәдәге пәкегез, үзеннән-үзе сикергәләп, дүрт тапкыр кадалдымы?—дип сүзгә катышты яшел күзле.—Ә бәлки, ул кесә пәкесе булмагандыр, менә шушы пычак булгандыр?

—Җизни, ник дәшмисең? Мине гаеплиләр бит!

Гамил тагын һуштан язгандай башын салындырды. Хатын килеп аны инбашыннан тотып алды:

—Әкрен... Таяныгыз миңа... Лифтка хәтле бара аласызмы? Әллә носилка алып керикме?

—Күлмәк кигезегез,—диде табибә Сәриягә карап.—Һәм аягына кияргә ярдәм итегез.

Сәрия җизнәсенә ярарлык кофта таба алмый бәргәләнде, ахырда коенгач кия торган буйлы бумази халатын аның җилкәсенә салды. Гамил аягына үзе кимәкче иде, ләкин җәрәхәте иелергә ирек бирмәде. Сандалиларын Сәрия элдерде.

—Апаңа шылтырат,—диде Гамил.—Газим кая икән, бел әле.

—Ник? Өйдә түгелмени ул?..

—Мин киткәндә өйдә иде дә бит...—Гамил тукталып калды.—Бала-чаганы белмәссең,—диде аннары төшенке тавыш белән.—Апаңа, җизнигә пычак кадаганнар, дия күрмә тагын! Синнән булыр! Урамда егылып, ташка бәрелгән, баш тиресе сыдырылган, шуны каратырга больницага китте, диген. Аңладыңмы? Скорый чакырганны әйтмә, үзе китте, дип әйт. Борчылмасын. Бүген үк булмаса да, иртәгә кайтырмын!

Табибә белән шәфкать туташы икесе ике яктан кочаклап, Гамилне алып чыгып киткәч, кырыс егет яшел күзләрен Сәриягә төбәде:

—Киен, балдызкай.

—Нәрсәгә?

—Безнең белән барасың.

—Кая?

Яшел күзле хихылдап куйды:

—Ресторанга түгел инде. Казинога да булмас.

—Опорный пуктка,—диде арттарак басып торган урта яшьләрдәге, милиция киемендәге какча адәм. Сәрия анын погонына карады: бер тасма, дүрт йолдыз. Капитан, димәк. Түгәрәк карасу чырае сабыр, мәрхәмәтле күренә. Сәрия аңа өмет белән текәлде:

—Ә ник барыйм мин анда?

—Сөйләшергә кирәк булыр.

—Сөйләшик сон шушында гына.

—Сез борчылмагыз,—диде капитан.—Бүлеккә барып протокол төзербез, фәкать шул гына.

—Мин... мин... беләсегез килсә, мин "Гайрәтле" фирмасынын баш бухгалтеры...

—Паспортыгызны алырга онытмагыз,—диде капитан.

—Сездәй "баш бухгалтерларны" күп күрдек инде без,—диде яшел күзле. Ул нигәдер Сәриягә аерата каныга иде.—"Директор урынбасарлары"н да, "артистка"ларны да, "студентка"ларны да...

Милиция белән эш йөртмәгән, ябылу урыннарын монарчы беркайчан да күрмәгән кыз куркынып, тәмам бөрешеп калган иде. Каушавыннан ул чалбары белән шакмаклы кофтасын таба алмыйча интекте...

Җәйге айсыз төннең йомшак карангылыгы да шомлы тоелды. Ләкин шулай да күнел яхшыга өметләнә, боз күзле, озын буйлы егет тә, читтәнрәк атлап барган ыспай гәүдәле, йомшак тавышлы капитан да ниндидер уен уйныйлар, шаярталар кебек иде. Бүлмәләренә барып керүгә, көлеп җибәрерләр, гафу үтенерләр... Шулай булырга тиеш иде.

Милиция бүлеге квартал эчендәге бер катлы бинага урнашкан икән. Элек ул азык-төлек кибете иде. Горбачев эчүчелеккә каршы көрәш ачып, аракы талонга сатылган чорда, анын ишеге төбенә идел буе чират тезелә, эчендә ызгыш-талаш куба торган иде. Бер заман прилавка алдына, түшәмгә тоташтырып, сырлы калын тимерчыбыктан рәшәткә ясап куйдылар. Сәриянең андыйны төрмә турындагы киноларда гына күргәне бар. Нервылары чамасыз какшаган сатучы хатыннар шешәләрне алучыларга читлекнең тишекләре аша суза торган иткәннәр иде. Җәйге каникул вакытында апасына кунакка килгән авыл кызы Сәрия, гаиләгә тиешле өч айлык "эчемлек" нормасын күтәрешеп кайтырга дип, апасына ияреп баргач күрде бу хикмәтләрне. Күрде һәм коты очты.

—Бу хәтлене без үзебез эчә икән, дип уйлый күрмә тагын,—диде Сәгъдия, шылтыр-шылтыр шешә тулы сумкаларны күтәреп кайтканда.—"Сыек валюта" дип атала ул, акчадан кыйбат йөри. Машина ялласан да, слесарь чакырсан да, шуны сорыйлар. Шешә белән түләсән, тиз эшлиләр, арзанга да төшә.

Менә хәзер, карангыда каралып утырган бинага якынлашкач, Сәриянең хәтерендәге шул ямьсез хатирәләр кузгалып, күнелдәге шомны тагын да көчәйтте.

Һәр адәм баласы тәкъдиренә язылганны кичергән кебек, биналарның да үзенә генә хас язмышы була, күрәсен. Бу бер катлы корылма, мөгаен, бәндәләрнең бәхетсезлегенә торгызылгандыр. Элекке кибеткә милиция кереп урнашкан, прилавкалар алынган, әмма котсыз рәшәткә үз урынында калган. Аны бераз үзгәрткәннәр генә: читлекләргә бүлеп, кереп-чыгып йөрер өчен һәрберсенә ишек ясаганнар. Түшәм астындагы тузан сарган бердәнбер лампочканың сары яктылыгында, рәшәткә артындагы мәхбүсләр шәйләнде.

Әйе, читлекләрдән, куллары белән тимерчыбыкка ябышып, дүрт үсмер Сәриягә текәлделәр. Һәм ул барган жиреннән сөртенгәндәй туктап калды. Уртадагы читлектән аңа апасы Сәгъдиянен улы Газим тасраеп карап тора иде. Ничек монда килеп эләккән?... Һәм... туктале... кара чәче кай арада муенына салынып, колакларын капларлык булып житкән? Каян килгән аңа бу керле тельняшка? Барыннан да бигрәк, ничек болай ябыккан соң әле ул? Иннәре тар, борыны очлаеп чыккан шикелле...

"Син каян килеп чыктың монда?"

Бу сорау тел очында туктап калды, чөнки Сәриянең карашы малайның

сул як ирен читендәге түгәрәк кара миңенә килеп төртелде. Бик таныш миң... Гамил җизнинең битендә. Нәкъ шул урында чекрәеп тора. Әмма Газимнең андый миңе юк лабаса... Аннары тагын шунысы: бу малайның күз карашы чит, усал, нәрсәгәдер үчле сыман. Газим энекәш Сәрия апасына болай карарга тиеш түгел...

Үсмернең йөзендә сәерсенү, гаҗәпләнү чагылды. Аның янындагы буйга шактый калку, симез чырайлы, киң җилкәле егет авызын ерды да:

—Нәрсә, мамаша, монда керәсең киләме әллә?—дип сорады.—Командир, ачыгыз ишекне! Апакайның безнең белән бергә буласы килә!

—Тынынны чыгарма!—диде аңа яшел күзле.—Ә сез, гражданка, бирегә узыгыз!

Керле ишек артындагы кысан бүлмә тәмәке төтененә сасыган. Таушалган өстәл-урындык, түшәм астында—шәрә лампочка . Кырыс карашлы егет өстәл артына кереп утырды да, кәгазь-каләм алып, Сәриягә сораулар бирә башлады. Исем-фамилия, туган елың, кайда яшисең... Бүгенге хәлләр турында ни әйтә аласың. Сәриянең теле нидер әйтте, ә уйлары бөтенләй башкада иде. Теге малай—кем ул? Монда ничек килеп эләккән?.. Ләкин ни өчендер бу хакта сорап та булмый иде. Тәртип бозучылар, урлаучы-үтерүчеләр белән эш итәргә күнеккән, салкын карашлы бу егет аны аңламас. Әһә, синең шушындый адәм актыклары белән дә уртаклыгың бармыни әле, дип бәйләнер... Әнә, аш бүлмәсендәге пычакка Гамилнең каны йоккан, дип чын-чынлап ышана бугай бит ул...

Менә, ниһаять, егет ике бит кәгазьне язып тутырды, һәр битнең астына Сәриядән кул куйдырды. Аннары зур эш башкаргандай авыр сулап, урыныннан кузгалды. Бу очракта бик урынлы, бик табигый тоелган, күптән көтелгән: "Инде китсәгез дә була",—дигән сүзләрне әйтергә ни өчендер ашыкмады.

Алар коридорга чыкканда, капитан анда тора иде.

—Моны шушында урнаштырып торыйкмы әллә?—диде яшел күзле буш читлеккә таба баш кагып.

Кемне—"моны"? Кая—"шушында"? Монда килеп эләккән бәндәләр өстеннән чиксез кодрәткә ия булган бу адәм Сәрияне читлеккә бикләп кую турында сөйли түгелме сон? Һәм ябар да... Бернишли алмассың...

Ә бәлки, карышырга, дуларга, кычкырырга кирәктер? Әмма читлектән керфек тә какмый текәлгән миңле малайның таныш та, чит тә карашыннан уйлар буталды. Әйтәсе сүзләр тамак төбенә укмашкан, тел кибеп аңкауга ябышкан иде.

* * *

Бу заманда күп нәрсәләр танымаслык булып үзгәрде. Калалар да, салалар да мантыды, киңәйде, бөтәйде. Тик хастаханәләр генә күп очракта үзләренең ярты гасыр элеккеге рәвешендә калды. Шул ук буявы кыршылган диварлар, ярылган идәннәр, ярым-карангылык, тыгынлык, кысанлык.

Һәр почмагыннан шыксызлык, үзенә бер ямансулык бөркелеп торган биек, киң коридорга барып кергәч, ике якка сузылган ятакларда кайсы яткан, кайсы башын иеп утырган, кайсының аягы, кайсының кулы гипска катырып, марляга уралган хасталарны күргәч, Гамилнең башына шундый бер уй килде: "Бөтендөнья сугышы елларында да шушылай булгандыр. Әллә соң хастаханәләр өчен ул сугыш һаман бетмәде микән әле?"

Аны җитәкләп операция бүлмәсенә алып кереп киттеләр. Монда да тыгызлык икән. Ике як дивар янындагы ике өстәл, унында бер ир ята, янында ак халатлы ике кеше мәш килә: күрәсең, операция ясыйлар. Икенчесеннән берәүне әле генә күтәреп алып, ятак-арбага салдылар да, Гамилгә шунда ятарга куштылар.

Табибның битлек өстеннән күренеп торган күзләрендә талчыкканлык чагыла, чал кергән йөнтәс кашлары җыерылган иде, әмма зур кулының юан бармаклары тәнгә җылы һәм йомшак ныклык белән орынды. Ни аяныч,

адәм балаларының йөрәк яраларын дәвалый торган бу табиб шушындый фәкыйрьлектә, кешене кимсетә, кечерәйтә торган мохитта эшләргә дучар ителгән иде.

—Бәхетең бар икән,—диде ул җинел сулап.—Әз генә катырак төртеп, ике-өч сантиметрга тирәнрәк кертсәләр, ярырга туры киләчәк иде сине. Ә бәлки, бу өстәлдә түгел, башка җирдә ярырлар иде.

Врачның әйткәннәре бераздан гына аңа барып иреште. Ничек була инде бу? Тып-тыныч кына, тигез җирдән барганда, һичкем белән бернинди алыш-бирешең булмаганда, үтереп ташлаулары ихтимал микәнни? Пычак төртүченең кул астына "Атас!" дип кычкырмаган булсалар, бу минутта ул моргта ятар, анатом аның эчен актарыр иде микәнни?

Ярага дүрт җөй салганнан соң, табиб талчыккан чыраена елмаю галәмәте чыгарып:

—Туйга кадәр төзәлер,—диде.—Берәр атна бирелә ял итәрсез дә, шуның белән үтәр.

—Доктор, алай куркыныч нәрсә булмагач, хәзер үк китсәм дә ярыйдыр бит?

Табибның чыраеннан елмаю галәмәтләре шундук коелып төште. Кашлары тагын да куерып киткәндәй булды.

—Йөрәк туры бит ул! Андый нәрсә белән шаярырга ярыймыни? Аллага шөкеранә кылыгыз да, әйбәтләп ял итегез!

—Аңлагыз, мин монда ята алмыйм!

—Сез дә мине аңлагыз! Әгәр сезнең белән бер-бер хәл булса...

—Үзем җавап бирермен! Мин расписка бирәм!

—Расписканы монда килеп кергәнче, милициягә бирергә кирәк иде! Ә хәзер җаваплылык миндә! Чөнки мин операция ясадым. Әгәр бер-бер хәл булса, сез мине ике дә уйламыйча судка бирәчәксез.

—Судка? Минме?

—Йә хатыныгыз! Туганыгыз! Сез җиде көн минем күзәтү астында булырга тиеш. Җиде көн! Хәзер мин дежур медсестраны да, каравылчыны да кисәтәм! Урыныгыздан кузгаласы булмагыз! Таптылар мода! Телевизордан әллә нәрсәләр карыйлар да, малай-шалай кебек, шундагыны кабатламакчылар! Сестра! Бу авыруга спазган белән димедрол инъекциясе бирегез!

Хирургия бүлегендә урын юк икән, Гамилне, иртәнгәчә дип, янәшәдәге травматология бүлегенең коридорына, кизү торучы шәфкать туташының өстәле янындагы диванга чыгарып урнаштырдылар. Сәриянең халаты ярап куйды—хастаханәгә килешеп тора, өсне алыштырам дип мәшәкатьләнәсе юк. Хәер, соң иде бит инде, кием-салымны кайгыртучы күптән китеп барган.

—Әйберләрегезне янгызга куеп торыгыз, иртән тапшырырсыз,—диде шәфкать туташы.

Гамил чалбары белән сандалиен бергә төреп, мендәре астына тыкты да, чалкан ятып, хлор исе сеңгән җәймәне иягенә хәтле тартты.

Төн уртасы узган, хастаханә сагаюлы, сызланулы тынлыкка оеган. Почмакта берәүнең аягын күтәртеп беркетеп куйганнар, икенчесенең беләк астына таяк куеп, алга тарттырып бәйләгәннәр. Ул чалкан гына ята ала, инде һич чыдар әмәле калмаса, торып утыра.

Шәфкать туташы, кәгазьләр яткан өстәлендәге лампасын сүндереп тә тормыйча, каршыдагы "Ординаторская" дип язылган ишек артына кереп китте. Кире чыкмады. "Шунда черем итеп алырга булгандыр, күрәсең",—дип уйлады Гамил. Аның да күзе эленде...

Тик онытылып китүе генә булды, кинәт колагында "Атас!" дигән тавыш яңгырады. Урамда кеше талаучыларга гына түгел, Гамилгә дә бирелгән кисәтү кебек иде ул: "Атас, Гамил, атас!" Җәрәхәтле тәннең сызлануларын оныттырып, сискәндерде, йөрәккә бәрде бу тавыш!

Бу шом шулкадәр көчле иде ки, ул балдызына китергән көйсезлекләр турында уйлый да алмады. Аның өчен бу минутларда дөньяда фәкать бер генә кеше—"Атас!" дип кычкырган тавыш иясе генә бар иде... Аның улы Газим генә...

Әйе, бу тавыш һичшиксез анык иде, "Атас" дип талаучыларга, атасына пычак кадаучыларга ул кычкырды. Адәм баласының тышкы кыяфәте башкага охшау ихтимал, әмма тавышлар охшаш булмый, диләр. Охшаса да, кече малай һәр яктан әтисенә, Гамилгә генә охшаячак. Яше унөчкә житеп, үзе үзгәреп, биегәя башлагач, бу бигрәк тә нык сизелә. Һәм Гамил моның белән бик горурлана да. Уларының бусы—башы-күзе белән дә, йөреш-торышы белән дә атасының дәвамы. Шуңа күрә "эһ" дигән сүзе дә, җылы, назлы нур чаткысы булып, җанны иркәләп уза. Әйтеп-аңлатып булмый торган нечкә төсмерләре бар аның, моны Гамил үзе генә сиземли һәм башка берәү белән һич тә буташтыра алмый. "Атас!" дип, шиксез, аның улы кычкырды!

Тик ничек ул монда килеп чыккан? Нишләп бандитларны кисәтә?!

Өйдә булырга тиеш бит ул!.. Шылтыратырга иде...

Бередә телефон бардыр да барын, тик кайда? Мондый урыннарда телефонны врачлар өчен генә диләр, хасталарны якын җибәрмиләр—шунысы да бар бит әле. Ул кулындагы сәгатькә күз салды. Сәгатьнең пыяласы ватылган, уклары кәкрәйгән. Йөрми... Борылып, баш очындагы тәрәзәгә карады. Аннан сыек яктылык саркый иде. Кайчан көн килер дә, кайчан кояш чыгар икән?

* * *

Капитан чыннан да мәрхәмәтле адәм булып чыкты. Яшел күзле оперативникның, Сәриягә ишарәләп:

—Моны шушында гына урнаштырып торыйкмы әллә?—дигән соравына:

—Кирәкми. Өенә кайтсын...—диде.

Сәрия кайтып кергәндә, телефон шылтырый иде. Тик ул трубканы алып өлгермәде. Мөгаен, Аланлыктан Сәгъдия апасы булгандыр.

Әмма Сәрия аңа шылтыратырга ашыкмады, өстен алыштырып, газга чәйнек куйды, суыткычтан аны-моны алды. Үзе уйларын тәртипкә китерергә тырышты. Иң элек, әлбәттә, апасын уйлады.

Һәм аның күнелен кызгану хисе биләп алды. Сәгъдияне бик ярата, Гамилгә кияүгә чыгып кара бәхетсез булды, авыр тормышка дучар ителде, дип исәпли иде ул. Һәм бүгенге хәлләр аның бу фикерен тагын да ныгыта иде шикелле. Монда килеп кай арада хулиганнар белән бәйләнгән дә, ни өчен сугышып канга баткан? Һәм ник дөресен әйтми, ни дип милициянең башын катыра? Аның аркасында Сәрияне читлеккә ябып куя яздылар. Шуны да уйламый, хайван!

Гамилнең, каршыга басып, алгы тимер тешләрен ялтыратып, "балдызым-ялгызым", дип күзләрен шаян кысып торуы исенә төшкәч, Сәрия үзалдына төкереп куйды. Тфү! Апасын үзенә караткан гына җитмәгән, сеңлесенә ниндидер киная ясагандай итә тагын! Үзенең берәр кызыгыр җире булса икән ичмасам! Ни чибәрлеге, ни байлыгы! Тынгысыз тагын үзе! Сугыш чукмары икәнлеге авызын ачуга ялтырап күренеп тора! Өске өч тешен дә күсәк белән койдылар бит аның!

Хәзер менә йөрәк турына пычак кадаганнар... Апага ни диярга инде?

Төн уртасында кайнар кофе эчеп утырган Сәрия, апасы белән сөйләшми торып, йокларга ята алмаячагын анлый иде. Туктале, башта хастаханәгә шылтыратырга кирәк. Ярасы тирәнме, операция ясаганнармы, хәле ничек, шуны белергә. Аннары инде апага ни әйтәсен уйларга булыр.

Күңелендә Гамилне кызгану хисе булмаса да, аның ярасы өстә генә икәнен, җөй генә салганнарын белешкәч, Сәрия җинел сулап куйды. Аннары апасына шылтыратып, шаяргандай җинел сөйләште. Әйе, егылган. Бәрелгән. Юк, бер җире дә сынмаган. Бер төштән тиресе генә суелып киткән.

—Врач белән бик яхшылап сөйләштем,—диде ул.—Җөй салырга туры килгән икән. Шушында гына кунсын, иртән карармын да, чыгарырмын, диде врач. Төн уртасында йөрү җайсыз бит инде. Жизни сиңа борчылмасын дип әйтергә кушты. Килеп-нитеп йөрмәсен, иртәгә үзем кайтырмын, диде.

Соныннан кинәт кенә жизнәсенең ялынычын исенә төшереп:

—Газим өйдәме?—дип сорады Сәрия. Һәм тавышы үзгәреп киткәнне үзе дә сизми калды: күз алдыннан милициядәге малайның шәүләсе чагылып узгандай булды.

—Өйдә булмый, кая булсын,—диде теге баштан Сәгъдия сәерсенеп.— Күптән йоклыйлар инде. Эш күп бит, арыйлар.

Сәгъдия һәрвакыт шулай "алар" дип, ике улын бергә кушып сөйләшә.

—Газим нәрсәгә сина?—дип сорады ул.

—Болай гына... Кайчакта бергә киләләр иде... Бүген юк. Шуңа соравым.

—Гел генә атасына тагылып йөри алмый. Өйдә дә эшләре бар.

Бу сөйләшү Сәриянең тәмам хәлен алды. Ялганларга яратмый иде ул. Ләкин менә кайчакта, кемгәдер яхшылык теләсәң, чын дөресен әйтүдән тыелырга туры килә. Бигрәк тә Сәгъдиянең тормышында дөреслектән тайпылу, ниндидер хатамы, гөнаһмы, әйтергә ярамаган нәрсәдер бар кебек һәм бу—гаиләнең тормышын күләгәле кебек иде. Ул күләгә вакыт-вакыт Сәриянең дә күңеленә төшә иде шикелле.

Бу төнне аның күзенә йокы кермәде. Ул апасы турында уйлады.

Бәхетле булырга тиеш иде аның апасы Сәгъдия. Уйнап-көлеп, җырлап-биеп, башкаларның сокланулы карашында коенып, рәхәт-җинел яшәргә тиеш иде. Аның мона бөтен мөмкинлекләре бар иде. Авыл мәктәбен тәмамлап, Тәтешкә, бухгалтерлар курсына укырга кергәч тә, аннан: "Син нишләп монда йөрисең? Нигә театр училищесына кермисең? Артистка булырга кирәк сина!"—дигәннәр. Андагы буй-сын...Үзенә бер мәһабәт затлылык... Иннәренә ишелеп төшкән куе кара чәч дулкыннары... Бераз озынчага уелган, көлемсәр кара күзләр, тулы иреннәр арасыннан балкып торган энҗе тешләр... Ни өчендер чибәрлек ике кыз туганның өлкәненә мулрак бирелгән. Дөрес, Сәриядә дә бар ул кара чәч, кара күз, төз буй-сын... Ләкин апасы янында ул ничектер гадәтирәк, уртачарак, бик үк күзгә ташланмый торган булып кала. Ә бәлки бу—Сәгъдиянең эченнән бөркелгән яктылыктан киләдер. Үзенә бер рухи бөтенлек, күңел хөрлеге бар анда. Турысын әйтә торган һәм үз сүзен итә торган үзе.

Андый кыз авылда калырга тиеш түгел иде. Биек күтәрелеп, киң мәйданда балкырга тиеш иде ул.

Әмма еракларга очар өчен яратылган аккош йорт казы язмышын сайлады... Канатлары ныгып, оясыннан китәр чак җиткәч, бер җилпенеп алды да, Гайнуллиннар турына барып төште. Капкадан ук кереп китте һәм шушы Гамил кочагына сенде... Шуның белән юкка да чыкты, диярга була. Матурлыгының, тирә-юньгә сирпелеп торган тылсымлы яктысының, уңганлыгының әҗерен күрмәде. Кем ул менә хәзер? Гап-гади бер авыл хатыны. Иртән торып сыер имиенә ябыша, көндез колхоз идарәсендә баш күтәрми саннар чүпләп, миен черетә—ничә гектар җир сөрелеп, ничә литр сөт савылганын саный. Аннары кайтып, ике малаеның маңкасын сөртә, тамагын туйдыра, киемен юа. Шуңа өстәп ирен көйли. Ягъни шушы тимер тешле, ерык авызлы Гамилне. Менә сиңа сәхнә күрке булырлык чибәр кызның язмышы!

Шунысы үкенечле, бу язмышка үзен-үзе дучар итте ул. Алдан ук шулай планлаштырды. Егет армия хезмәтен бетереп кайтуга, ул монда укуын тәмамлап, авылга ярашлы һөнәр алып куя, имеш. Берәү булса, аралар ерагайгач, күзен бераз ачып, көзгегә текәлебрәк карар иде. Аннары тегенең армиядә солдат шинеле киеп, погон тагып төшкән карточкасына. Чагыштырыр иде дә уйланыр иде. Ә ул уйлый белмәде. Биргән вәгъдәсендә торды.

Юләр. Артыннан җаның бирердәй булып Зөфәр йөргәндә, Гамилгә карыйлармыни? Аның белән вәгъдәләшәләр димени?

Бөтен урамны дер селкетеп торган туры муенлы, җирән бөдрәле Зөфәрдән дә шәпне табып буламыни? Мәктәптә укыган чагында ук йөри башлады ул Сәгъдия артыннан. "Апаңа әйт әле, кояш баегач, су буена төшсен",—дип, Сәрия аркылы чакырган чаклары да булды. Тик Сәгъдия тешләрен җемелдәтеп көлә генә иде: "Бар, чыгып әйт, чакырган бер җиргә баручы мин түгел, көтеп мәшәкатьләнмәсен, дип әйтте апа, диген". Ләкин Зөфәр

дә үз дигәненнән алай гына чигенә торганнардан түгел, авылда: "Сәгъдиягә якын килгән кеше минем белән эш итәчәк",—дип сүз таратты. Аның белән санашмыйча, кызны озатып йөргән Гамилнең авызын кара канга батырып, тешен койды...

Шуннан соң да акылга утырмады Сәгъдия. "Мин ана болан түгел, сөзештә жиңгән ата боланныкы булырга...Үзем теләгәнне үзем сайлыйм!"—диде.

Дөрес сайладымы соң? Хәзерге вакытта Гамил кайда да, Зөфәр кайда? Егетнең жирән бөдрәле башы әледән-әле телевизорда балкып чыга: Казаннан да күрсәтәләр, Мәскәүдән дә. Заводлары, фирмалары, кибетләре бар. Хәтта Мәскәүнең Кызыл мәйданына да киоск илтеп бастырган, диләр. Таллыда да, Казанда да бик шәп йортлар сатып алган икән. Харап модный киенгән, чикерткәдәй нечкә билле хатынының озын тырнаклары шәп-шәмәхәгә буялып, алтын бөрчекләр белән чуарланган. Сыер имие генә түгел, идән чүпрәге дә тотканы юктыр, мөгаен. Ул ике кызы тагын! Өлкәне, унөче дә тулмас борын, илгә танылды, чөнки әледән-әле телевизорда күренә, күз явын алырлык күлмәкләр киеп, боргаланып-сыргаланып жырлый...

Зөфәр заман биргән мөмкинлекләрне бик оста файдалана белде, һәр яна законны тиз эләктереп алды. Күпләр совет сендергән, безнең илдә һәр өлкәдә—тигезлек, гаделлек; дәүләт милке—халык байлыгы, дигән сафсаталардан арына алмый миңгерәп йөргәндә, ул мөмкин булган һәрнәрсәгә барып ябышты һәм үзенә таба тартты. Бер заман кооперативларга кредит бирү турында закон чыкты. Аны алу өчен, әлбәттә, танышлык, жаен белү кирәк иде. Зөфәр танышларны булдырды, булганын жайлады-майлады. Кредитлар алынды, кире түләр чак житкәнче, акчалар котырып, бурычлар юкка чыкты, тик шул кредит бәрабәренә төзелгән биналар, сатып алынган товарлар торып калды. "КамАЗ"лар белән сату итү мөмкинлеге туды—бер иш эшкуарлар берләшеп, машиналарны заводтан арзан хакка алып, калмык далаларына яхшы атлар бәрабәренә озаттылар, аргамакларны исә Мәскәүгә илтеп саттылар. Ат жанлы байлар анда да житәрлек икән. Инде бу эшнең сасысы таралган иде, аракы сату бик файдалы булып китте. Аннары халыктан ваучер дигән кәгазьләрне ипилек акчага яисә бер ярты хакына жыеп, шулар бәрабәренә зур-зур завод-фабрикаларга хужа булу жае чыкты. Зөфәр бу мөмкинлекне дә ычкындырмады.

Хәзер кайсы ана сокланып туймый, рәхмәт укый, бәгъзеләре артыннан каһәрләп кала. Ә менә Сәриянең тимер тешле жизнәсе мондый яшәү рәвешен кабул итә алмаучылардан иде. Кинәт ишәеп киткән, болганчык елларда дәүләтне талаган, гомумхалык милкенә хужа булган намуссыз кешеләр дип карый иде ул андыйларга һәм, бик якын кешеләр белән бу хакта сөйләшкәндә, элекке классташын "сасы көзән" дип атый иде. Авылга кайткач, бер иртәне сасы көзәнне Аккашның сыртында күргән иде Сәрия. Бичара мал нишләргә белми тыпырчына, ә нәни ертлачның исе дә китми. Кеше кергәнен күргәч кенә, ялт итеп сикереп төште дә кайсыдыр ярыкка кереп гаеп булды.

Ә нәрсәсе начар? Көзән—кимерер өчен, ат эшләр өчен яратылган. Арбага жигелгән ат булып яшәү бик яхшымы әллә, дип уйлый Сәрия.

Зөфәрне йә аның кызын телевизордан күргән саен, жизнәсенә ачуы кабара анын. Гамил булмаса, хәзерге вакытта "Гранд-чероки" дигән елтыравык зур машинага Сәгъдия утырып йөрер иде. Шәһәрдәге "коттедж"ыннан авылга кунакка кайткан чакларында көмеш бөрчекле озын шәмәхә тырнаклары белән күрше-күләнне шаккатырыр иде. Ә бәлки, телевидение тирәсенә дә елышып китәр иде! Сеңлесенә дә яхшылыгы тими калмас иде. Һәрнәрсәдән файдалана белә Зөфәр: законнан да, законсызлыктан да, тәртиптән дә, тәртипсезлектән дә. Менә нинди кешене сайларга кирәк гомер юлдашы итеп!

Дөрес, Гамил дә нәрсәдер майтарырга тырышып карады. Читтән торып институтка керде, Таллыга килеп, заводта мастер булып эшли башлады. Шушы бер бүлмәле фатирны алды. Ләкин...

Берзаман, тыныч тормыш аланын тузанга күмеп, кыргый ат көтүе чабып

килеп кергәндәй булды. Зөфәр ишеләр аларнын ялына ябышып, сыртына менеп атланды, күпләр исә тояк астыннан бөркелгән тузанга тончыгып, егылып калды... Берәүләр заводта эшләнеп чыккан машиналарны бер алып, бер сатып мал туплады, икенчеләр айлык эш хакы ала алмыйча тилмерде. Ахыр чиктә дистәләгән кешеләр монарчы күрмәгәнчә баеды, меңәрләгән эшчеләр исә бер нәрсәсез, хәтта эшсез калып, урамга чыгарып җибәрелде. Гамил һәм заводнын бухгалтериясендә эшләгән Сәгъдия сонгылары арасында калдылар. Бар байлыклары—берсе җирән чәчле, берсе кара ике малай. Өлкәне—озынча ак чырайлы Җәмил—баштан ук сәламәтлеккә туймады тагын.

Уйлар балаларга барып тоташкач, Сәриянен хәтеренә кылт итеп милиция читлегендәге малай килеп басты. Тач Газим инде. Тик арык. Һәм ирен читендә, сул якта, түгәрәк мине бар. Анысы нәкъ Гамилдәге төсле... Нинди малай ул? Кем баласы? Әллә соң... Гомере буе хатынын Зөфәрдән көнләшкән Гамил үзе читкә сугылгалады микән? Булыр да... Ирләргә ышаналар димени... Сәрия күптән инде балигъ булган, яше егерме бишкә җиткән. Ирләрнен нинди азгын икәнен чамалый...

Нишләргә? Сәгъдиягә әйтергәме бу хакта, юкмы?

Сәрия бу сорауга җавап таба алмады.

* * *

Ул аяк тавышларыннан айнып китте, сискәнеп калкынды, терсәгенә таянып, борылып карады. Коридорнын аргы башыннан икәү килә, берсе—ак халатлысы—Гамилне караган табиб, икенчесе бая фатирга килгән милиция капитаны иде. Култык астына калын кара папка кыстырган. "Ординаторская" бүлмәсеннән, чәчләрен төзәткәләп, шәфкать туташы килеп чыкты.

—Бирегез әле, сестра, бу авырунын тарихын,—диде табиб.

—Хәзер, хәзер... Шуны гына тутырып утыра идем...

—Ә сез, больной, ятыгыз да күкрәк турыгызны ачыгыз!

Табиб, Гамилнен пластырь ябыштырылган түшенә ишарәләп:

—Күрдегезме?—диде.—Нәкъ йөрәк турында. Кабырга арасына ук кергән. Тагын ике-өч сантиметрга тирәнрәк үтсә...

—Тормыш өчен куркыныч җәрәхәт булыр идеме?—дип сорады капитан.

—Ахырын әйтү дә кыен булыр иде.

—Димәк, бу очракта тормыш өчен куркыныч җәрәхәт турында сүз алып барып була?

—Әйтәм ич, тагын аз гына тирәнгәрәк кергән булса...

—Димәк, кемдер кадаган? Зыян күрүче, кесәсендәге пәкесенә ялгыш кадалып, шундый җәрәхәт ясый аламы?

—Кеше көлдермәгез,—диде табиб.—Мин сезгә әйтәсен әйттем. Кирәк булса, эксперт чакырыгыз. Мине көтәләр анда.

Анын китәргә борылганын күреп, Гамил тагын калкынды:

—Доктор! Өйгә шылтыратырга мөмкин булмас микән? Борчылалардыр анда!

—Үзләре шылтыраттылар инде. Куркыныч нәрсә юк икәнен белделәр,—диде табиб һәм авыр атлап китеп тә барды.

"Ә малайлар? Газим? Анын турында әйтмәделәрме?" Эченнән ургылган бу сорауны Гамил тел очында туктатып калды. Анысын табибка кем әйтсен?

Капитан шәфкать туташына борылды.

—Урындык бармы сезнен монда?

—Рәхим итегез...

Хатын үз урындыгын тәкъдим итте дә, кире бүлмәгә кереп китте.

Капитан урындыкка иркенләп утырды, фуражкасын өстәлдәге кәгазьләр өстенә куйды да, чигә турына чал кергән кыска кара чәчләрен сыпырып алды, аннары пинҗәгенен төймәләрен ычкындырып, кара папкасын тезенә җәеп салды. Түгәрәк чырае шома, калынча иреннәре алланып тора. Яшькә

Гамил белән бер чама—утыз бишләр тирәсе булса кирәк.

—Таныш булыйк. Мин участковый,—диде ул.—Фәхриев. Ринат Фәритович.

—Гайнуллин Гамил Нәбиулла улы... Юкка борчылып йөрисез түгелме? Төн уртасында...

—Нишлисең, кайчакта шулай туры килә... Ну, зарар күргән гражданин,—диде капитан ничектер үз, якын итеп, йомшак тавыш белән,—гариза язабызмы?

—Нәрсә турында?

—Милициягә гариза язарлык берни дә булмадымыни? Төнлә сезгә һөҗүм итмәделәр, таламадылар дамы?

Гамил чалкан ятып, карашын түшәмгә төбәде. Кызганыч, бу юлы ул һуштан язган булып кылана алмый иде. Табиб монда гына... Талавын таладылар анысы... Бумажник юкка чыккан. Эчендәге ике мең сум акча, документлар белән бергә...

—Яныгызда документыгыз бармы?

Бу кеше аның уйларын укып утыра инде әллә?

—Үзем белән түгел...—дип мыгырдады Гамил.

—Ә кайда?

Бераз тынлыктан соң, Гамилнең дәшмәвен күреп, капитан дәвам итте.

—Җиде йөз туксан алтынчы номерле "Газель" сезнекеме?

—Минеке...

—Ә правагыз кая? Паспортыгыз? Башка документларыгыз?

—Бумажнигым егылган җирдә төшеп калган, ахрысы. Башым бәрелгән бит, сизмәгәнмен...

—Тигез җирдән барганда нишләп егылдыгыз соң сез?

—Поребрикка абындым.

—Кайсы поребрик инде ул?

—Шунда... "Газель" янында...

—Ә пәкегез кая?

—Нинди пәке?

Капитанның туры калын кашлары астындагы кысык күзләре тагын да кысылып, елтырап куйды.

—Анысы да шунда төшкәндер инде...—дип мыгырдады Гамил.

Капитан папкасыннан паспорт, права, вак-төяк кәгазьләр алды.

—Боларны таныйсызмы?

—Шушылар инде... Минекеләр...

—Бумажнигыгызда тагын нәрсәләр бар иде?

Гамил, хәтерен барларга тырышкандай, күзләрен йомды. "Акча турында әйтергәме, юкмы?.. Әйтсәң, һичшиксез, теге малайларга бәйләнәчәкләр... "Атас!" дип кычкырганына да... Тотып алсалар..."

—Юк, башка әйбер юк иде.

—Акча да юк идеме?

—Юк... Нindидер тиеннәр генә бар иде... Коелып калгандыр...

—Ә беләсезме, без сезнең документларны каян табып алдык?

—Бәлки, өйгә кергәндә, ишегалдында төшеп калгандыр... Төгәл генә хәтерләмим... Әйтәм бит... башым...

—Юк шул, сез әйткән җирдән түгел, ике квартал арырак! Бер төркем малай сезнең ишегалдыннан атылып чыктылар да бездән качып чаба башладылар. Котыла алмасларын белгәч, боларны куак арасына томырдылар.

—Ну... Бәлки, урамнан тапкан булганнардыр...

Гамил башын читкә борды. "Малайларның берсе сезнең үз улыгыз!—дигәнне көтте ул.—Шуңа күрә сез аларны яклап калырга маташасыз да!"

—Димәк, сезгә кагылучы булмады?

—Юк!

—Карагыз әле, боларның берәрсен танып алмыйсызмы?

Капитан папкасыннан берничә фоторәсем чыгарды. Һәммәсендә үсмер

малайлар. Алгы яктан һәм яннан төшерелгән, ягъни "фас" һәм "профиль". Җинаятьчеләрне рәсемгә шулай төшерәләр. Арада тельняшка кигән, мангаен куе чәч каплаган, сул як ирен читендә мин чекерәеп торганын күргәч, Гамилнен кулы калтыранып куйды.

Гамил армиядә артиллерист иде, хезмәтен тәмамлагач, авылга һиммәт фуражка белән шәп каеш кына алып кайтты. Уллары кайчакта шуларны бер-берсеннән тарткалап алып кия... Ә бу тельняшка Газимгә каян килгән? Чәче нишләп болай җиту күренә? "Сина озын чәч килешми",—дип, еш кистереп торалар бит югыйсә! Күз карашы тагын... Гадәттәге үзсүзлелек, үҗәтлек астыннан бу нинди катылык, салкынлык бәреп чыккан?

—Кем бу?—дип сорады Гамил, тавышы калтыраганны сиздермәскә тырышып. Капитан сурәтнен арткы ягын әйләндереп карады.

—Харитонов Макар Геннадьевич бу.

—Харитонов дисезме?!

—Ә сез Харитоновларны беләсезме әллә?

—Таныш кебек...

—Ә бәлки, сез шул таныш булганга аны йолып калмакчыдыр?

—Мин һичкемне күрмәдем. Сөрлегеп егылдым, аңлыйсызмы... Баш белән ташка... Анда үтеп-сүтеп йөргәннәр булгандыр...

Шулай әйле-шәйле сүз көрәштереп утырганнан сон, капитан урыныннан кузгалды. Ачы көлемсерәп, башын чайкады:

—Анламассын безнең халыкны! Күрә торып талаучыларны, кыйнаучыларны яклыйлар! Ә үзләре, җинаятьчелек арта бара, дип милицияне гаепли. Шушы малай-шалайдан куркасызмы әллә? Курыкмагыз! Болары азу ярган рецидивистлар түгел әле! Төрмә юлларын таптап өлгермәгәннәр. Олы юлга чыгып, кеше таларга өйрәнеп кенә килләр.

—Документларны бирегез,—диде Гамил анын сүзен бүлеп.

—Юк шул әле,—диде капитан йомшак кына.—Бераз сабыр итәргә туры килер. Безгә иртәнгә чаклы теге малайлар белән мәсьәләне хәл итәргә кирәк. Чыгарыргамы, юкмы...

Гамил сискәнеп калкынды:

—Алар ябылудамыни?

—Башларыннан сыйпаргамы әллә? Ә сезнең кәгазьләрнең "вещдок" булып чыгуы ихтимал...

—"Вещдок"?

—Әйе шул, "вещдок". Бер төркем гражданнарның, үзара берләшеп, алдан сүз куешып, талау нияте белән кешегә һөҗүм итүе, пычак белән авыр тән җәрәхәтләре ясавы һәм шәхси милкен тартып алуы. Бандитизм һәм разбой! Кылганнарының әҗерен алырга тиешләр. Кеше үтергәннәрен күтәргәме әллә?

—Балигъ булмасалар дамы?

—Андыйларының ата-аналары җавапка тартылыр. Кемне үстергәннәрен белеп торсыннар. Ә сез ни сәбәптәндер аларны якларга маташасыз. Моны да ачыкламый булмый... Әгәр безнең белән элемтәгә керергә ниятләсәгез, яки берәр нәрсә исегезгә төшсә, шундук шылтыратыгыз. Йә килегез. Менә сезгә телефон, менә адрес.

Анын киткәнен сизенеп, ахры, шәфкать туташы бүлмәдән чыкты.

—Әгәр теләсәгез, мин сезгә тагын бер укол ясыйм, спазган белән димедрол,—диде ул.—Тынычлап ял итәрсез.

* * *

Шәфкать туташының даруы ярдәм итмәде, күзгә йокы кермәде, "Атас!" дигән таныш тавыш колакта чыңлаудан туктамады, капитан күрсәткән карточкадан, гүяки, салкын карашлы таныш малай аңа керфек какмый текәлеп карап тора иде.

Кем ул?

...Бер дусты Гамилнең күзенә карап: "Дуңгыз тиресе синдә, тиз генә тишә алмаслар",—дип әйткән иде. Борчу-мәшәкатьләрне йөрәгенә якын

алмый, авырлыкларга бирешми, янәсе. Ә ник бирешеп торсын әле? Олы хәсрәт килгәне юк лабаса. Тормышы житү, хатыны чибәр, ике малае үсеп килә. Заводлар ябылып, ир-атнын шактые көннәр буе урамда болганып, эчеп йөрүгә калгач, хәтта кайберәүләр өметсезлеккә бирелеп, үз-үзенә кул салуга житкән чакта, ул бирешмәде. Авылга кайтып урнашты, мал-туар тулы ихата булдырды. Хәтта үзенә күрә "бизнес" белән дә шөгыльләнә башлады. Кайберәүләр кебек, Ельцинны каргап, коммунистлар тәртибенең кире кайтканын көтеп, кул кушырып утырмады. Заман жилләре аны аударып ега алмады.

Әйе, шулай. Тыштан караганда. Ләкин тирәнрәк, күнел төпкеленә күз салсаң... Анда вакыт-вакыт бәгырьне көйдереп ала торган утлы кисәү бар. Була шундый минутлар, "уф" дисәң, авыздан ялкын бөркелеп чыгар иде. Уфылдарга ярамый гына. Түзәргә туры килә.

Ул кисәү—бала китергән хәсрәт...

Хәер, Гайнуллиннар гаиләсенә бала хәсрәте килгән, дисәләр, һичкем ышанмас. Ике малай—Жәмил белән Газим—бертигез үсеп киләләр, күзгә чүп керткәннәре юк.

Бусы өстән караганда. Ә игътибар белән, текәлебрәк күз салсаң... Буйга бертигез, яшькә дә бер булып тоелган бу икәүне бертуганнар дип кем әйтер? Икесе дә кара чәчле Гамил белән Сәгъдиядән, битен сипкел баскан, жирән чәчле Жәмил ничек туган? Бу гаиләне белгән кешенең күнелендә мондый сорау тумый калмыйдыр. Һәркемнең күрер өчен күзе, уйлар өчен башы бар. Адәм башына исә уйларнын төрлесе килә, кайчакта шаян мәзәкләр дә искә төшә. "Бер адәмнең хатыны негр тапкан икән дә, врачлар, кайсыдыр буында берәр бабагыз йә әбиегез негр булгандыр да, шунын төсе нәсел геннарында сакланганды, дип юата икән..."—дип башлана аларның бәгъзеләре.

Дөрес, бала тудыру йортында нәни төенчекне Гамилнең кочагына салганда, табиблар аны-моны әйтмәде әйтүен. Ни дисеннәр? Сабыйның каш-керфеге бөтенләй юк иде бит. Аңа инде текәлеп каралмады да, чөнки чәченнән бигрәк исәнлеге борчый иде. Башка хатыннар тудыру йортыннан атна узуга кайтып киттеләр, ә Сәгъдия ай буе ятты. Әле сабыйның температурасы төшми, әле имә алмый, диделәр.

Инде рәтләнгән, авырлыгы да арта башлаган, дигәннәр иде. Ләкин ул әтисенә куаныч кына түгел, олы бер башваткыч та алып кайтты. Беренче төндә булган хәлләр күнелгә онытылмаска уелып калды. Һәм яшәешнең тәртибен генә түгел, ир белән хатынның мөнәсәбәтен дә үзгәртеп жибәргәндәй итте.

...Төн уртасында аларны баланың ачыргаланып елаган тавышы уятты. Чистага төрде аны Сәгъдия, имезергә маташты, кулында тирбәтте, эче белән иненә салып, әрле-бирле йөренде. Юк, туктамый нарасый, кычкыра да кычкыра. Ул бит әйтүе генә ансат. Бала никадәр генә газиз булса да, аны ничаклы гына яратсаң да, түзүнең чиге бар. Баштагы бер сәгатьтә кызганасың, өзгәләнәсең... Икенче сәгатендә чарасызлык баса башлый, башынны мендәр белән капларга маташасың... Өченче сәгатьтә бәгырьнең катыланганын тоясын, чөнки үзәк тамырынны үтмәс пычак белән бертуктаусыз ышкыгандай бу тавыш хырылдык чинауга әверелә. Аннан ничек тә булса котыласы килә. Авызына бөке тыгып куясымы әллә? Сулышы киселмәслек итеп кенә... Хәер, сулышы болай да киселә түгелме? Йодрык хәтле генә чырае да, әнә, кызарунын ахыр чигенә житеп, күгәрә үк башлады түгелме? Хырылдавы да көчәя... Үлә күрмәсен тагын!

Сәгъдия нишләргә белми, ишекне, тәрәзәне ачып ташлады. Һава керсен дип инде. Аннары кинәт туктады да:

—Аракы бир!—дип кычкырды.

Гамил аны аңламады.

—Нәрсә?

—Аракы бир, дим!..

—Нәрсәгә?!

—Күрмисенмени, үлә бит! Бир!

Калтыранган куллар шешә муенындагы чуар кәгазь тасмасын сүтә алмый азапланды. Колак төбендә исә сабыйның хырылдау аша нәзек чинаштыруы һәм Сәгъдиянең карлыккан тавыш белән:

—Тизрәк бул инде, нәрсә мыштырдыйсың!—дигәне янгырап торды. Ул, бармагын канатып, тимер капкачны каеруга, Сәгъдия шешәне тартып алды. Әллә бугазыннан чөмермәкче инде? Юк икән... Яулык почмагын йомарлап, шуңа аракы койды да, сабыйның авызына каптырды. Анасының күкрәген рәтләп имә алмаган бала, йотлыгып, шул сасы чүпрәкне суыра башлады. Гамил, аның сулышы тигезләнүен, әкренләп йөзенә нур инүен күреп, шаккатып басып торды.

—Ни дигән сүз инде бу?

—Курыкма, аннан гына зыян булмас. Күрмисеңмени, файдасы тиде,—диде жинел сулап Сәгъдия.

Һәм, талчыккан чыраена елмаю галәмәте чыгарып, гадәттәге шаянлыгын кайтарырга тырышты. Аннары тулы ак күкрәгенең күгелҗем төймәсен бала авызына терәде.

—Бер айлык сабыйны хәмер белән дәваларга... кем өйрәтте сиңа?—дип сорады Гамил.

—Наилә апа.

—Тумас борын башын төзәтергә кирәк булганмы әллә ана?

—Каян белим инде... Шулай иткәч, тынычлана бит әнә...

—Ни булды сиңа ул роддомда? Берәр төрле ярамаган укол кадамаганнардыр бит?

—Кычкырма. Баланы уятырсың.

Чыннан да, сабый имеп туйган, әнисенең күкрәк очын капкан килеш йокыга талган иде. Сәгъдиянең якты сибеп торган ак күкрәге, күзләре йомык сабыйның алланып киткән йөзе, аның сизелер-сизелмәс тигез сулышы Гамилне тынычландырып җибәрде. Чамасыз арыган, йокы килә, өч-дүрт сәгатьтән кузгалып эшкә чабасы бар иде. Сораулар шул килеш җавапсыз калды. Хәзергә хәтле аларга җавап табылганы юк.

Дөньяның мәшәкатьләре күп бит аның, бигрәк тә өйдә яшь бала булганда. Сабыйның көйсезләгән башлыча анасы күтәрә, әти кешегә төнге тынгысызлык кына эләгә эләгүен. Ләкин шунысын гына үткәрү дә читен. Хатыннар өчен иң үзәккә үткәне "үтмәс пычак, чи утын, елак бала" дигәннәр борынгылар. Гайнуллиннар өендә пычаклар унайлы, утын ягасы юк, әмма "елак бала" дигән бәхетсезлектән хатынны бер генә ир дә коткара алмый икән шул. Ахыр дәрәҗәдә гаҗизләнгән чакларда шул бер чараны кулланмый булмый иде... Төн көнгә авышкан сәгатьләр җитеп тә, нарасый елаудан туктамаса, инде хәле китеп, тәмам сулышына буыла башласа, тагын, тагын теге шешәне ачтылар. Ләкин моны алар мөмкин кадәр сирәк һәм азрак микъдарда кулланырга тырыштылар. Сәгъдия сасы, юеш чүпрәкне баланың ирененә тигезеп кенә ала да, күкрәк очын китереп тери, аннан сөт тамчылары чәчрәп чыга. Бала, чүпрәк исенә алданып, голкынып суыра башлый. Шулай итеп, малайны начар гадәтеннән әкренләп биздерделәр. Бу хәлләрне кешегә сөйләп, кемнәндер киңәш сорап та булмый иде кебек. Тик берәр җирдә яшь балалар, аларның сәерлеге турында сүз кузгалса, Гамилнең колаклары тырпая торган булды. Берзаман гәзиттә "Нәсел тамырын корыткан—хәмер" дигән мәкалә күзгә чалынды. Соңгы елларда балаларның шактые зәгыйфь булып дөньяга килә, моның төп сәбәбе—эчүчелек, кайбер сабыйлар күзен ачканчы ук махмырдан интегә башлый, дип язылган иде анда. Һәм, бала булдырырга ниятләгән ир белән хатынның икесенә дә хәмердән тыелырга кирәк, дип катгый кисәтелгән иде.

Ләкин Гамил белән Сәгъдия һич тә хәмергә хирыс кешеләр түгел бит! Аларның сабыена бу афәт каян килеп ябышкан соң? Ул гына да түгел, әкрен мантыды, яшьтәшләреннән шактый соңга кала торган булып та чыкты ул. Һәммә чүпрәкләре юеш кенә түгел, сары таплы... Муенын да алтынчы

ае житкәч кенә тота башлады... Анасының сөте артып калуга карамастан, авырлыгы да әкрен артты...

Бер көнне Гамил эштән кайтканда, аларда Наилә апа утыра иде. Мөлаем чырайлы, тулы гәүдәле акушерка, элеккечә әйтсәң, кендек әбисе.

—Күрми түзеп булмады,—диде ул.—Ерак араны якын итеп, махсус килергә булдым.

Наилә апа шәһәрнең икенче ягында яши иде. Заманында, Таллыда гына түгел, бөтен районда бала табу йорты бердәнбер генә чакта, балаларның күбесен ул кабул итә торган булган. Гамилнең дә, Сәгъдиянең дә кендек әбисе ул. Әниләреннән кала иң якын кеше. Аны онытырга ярамый, бик үк еш булмаса да, очрашып, хәлләрне белешеп яшиләр. Дөрес, соңгы елларда шәһәр үсеп, тагын бер бала табу йорты ачылгач, күрешүләр сирәгәйде, чөнки Наилә апа элек эшләгән җирендә калды, ә Гамилгә фатирны яңа шәһәрдән бирделәр.

Кешене күрүгә, күнел ярасын ачып салып булмый. Шуңа күрә кичкә авышкан кояш нурлары белән яктыртылган чәй табынында тегене-моны сөйләшеп утырдылар.

—Син безгә дә әни кебек, безнең балабызга да,—диде Гамил.

—Шулай теләдегез бит, мин эшләгән җиргә киләсе иттегез,—диде Наилә апа.—Үзегезнең роддомда да начар булмас иде югыйсә...

—Күнел сиңа тартты шул!—диде гадәтенчә тешләрен елтыратып Сәгъдия.

Бер чынаякны бушатып, хуҗабикә кунакны икенчесенә кыстый башлагач, Гамил шаярган кебек кенә итеп:

—Анда хәзер малайларның тәпиен дә югалыйлар икән,—диде.—Яңа туган сабыйның үзе белән бергәләп.

Наиләнең кулындагы чынаягы чайпалып, аклы күлмәгенең итәгенә түгелде.

—Заман шундый бит, нишләтәсең, заман,—диде.

—Кая, Наилә апа, тоз белән ышкыйк,—диде Сәгъдия сикереп торып.—Аннары су белән юып җибәрербез.

—Кирәкми лә... Өйгә кайткач хлор белән...

—Ул соң бөтен балаларга шулай тиешме? Безгә дә хәмер суырттырган идегезме, әллә яна инструкция чыктымы?—дип каныкты Гамил.

Наилә, башын иеп, тастымал белән итәген ышкый, сыек чал бөдрәләре генә күренә иде.

—Андый кагыйдә юк та ул,—диде гаепле кеше сыман.—Бик күпне күрдек бит инде... Эчкечелек көчәя бара. Кайбер балалар махмыр белән туа... Врачлар нишләтергә икәнен белми...

—Махмыр белән? Безнең баламы?..

—Исерек ата-анадан туган бала гына шулай, дип тә әйтеп булмый. Ә бәлки, башка берәр сәбәптәндер. Медицина бик катлаулы бит ул... Кем белеп бетергән. Бәлки, нәселдән берәрсе...—диде Наилә, җыерчыклы кулларын угалап һәм, карашын бармакларына текәп, тукталып калды.

—Нәселдән?—дип сорады Гамил.—Әллә мине дә туугa шулай сыйлаган идегезме?

Наилә ачылып китте.

—Син бүтәнчә сыйландың! Гел онытасым юк: кычкыргалап алдың да, бармагыңны кабып суырырга да керештең. Ананның күкрәген каптырудан бүтән чара калмады.Үзенә тиешлене беренче минуттан ук даулап ала белә идең! Булырдайның туганда ук билгеле! Улыгыз да, менә күрерсез, туп кебек тупырдап үсеп китәр әле. Бишектәге бишкә төрләнә!

Аннары йоклап яткан сабыйны юка юрганы өстеннән генә сыйпап куйды да:

—Менә, үзен күргәч, җаным тынды,—диде.—Бәхетенә күрә, бик яхшы гаиләдә үсәчәк. Сез аны аякка бастырасыз инде! Чын баһадир итәсез!

Ул тагын нидер әйтергә тиеш иде. Гамил текәлеп көтте. Ләкин Наилә апа күтәрелеп карамады, башын аска игән килеш, күнелдәниндидер бер борчулы билгесезлек калдырып, чыгып китте.

* * *

Коридорның аргы башындагы бүлмә эченнән тоник кына кычкырган тавыш ишетелде. Кемгәдер ярдәм кирәк иде, ахрысы. Әмма башын беләкләренә салган шәфкать туташы кыймшанмады, лампа яктысы астында алтынланган бөдрәләре генә яктырып күренә иде. Тавыш бер көчәйде, бер тынып торды, аннары шакылдата башладылар. Гамил калкына төшеп, шәфкать туташының халат җиңенә орынды:

—Анда берәрсенең хәле авыраеп китмәдеме икән...

Хатын башын калкытып, керфекләрен угалады, аның җыярга тырышты, бераздан гына кайда икәнен чамалап алды. Ниһаять, салмак хәрәкәт белән кузгалды да, аргы башка юнәлде. Гамилнең уй сүреше буталды, күңелгә аңлап булмый торган авыр бер сагышлы хис бәреп керде. Ул үткәннәрен уйлап ята, сызлануы да көчле түгел, чыдарлык. Ә анда, аргы бүлмәдә, шушы минутта берәрсенең җан тәслим кылуы да ихтимал бит. Больницада кеше үлми тормый... Әҗәлдән дәва юк, диләр. Ә менә Наилә апа, ничек кенә булмасын, баланы үлемнән коткарып калган иде, мөгаен.

Әйткәне дөрескә чыкты: малай, яшьтәшләреннән бераз соңарыбрак булса да, мантыды, күрәйде, әкренләп һөнәрләрен арттыра барды. Үзе генә түгел, бер яшькә кече энесе Газим белән бергәләп.

Әйе, аларның ике улы рәттән туды. Күп ирләр моның белән мактаныр иде. Тик олы малайны башкалардан ким итми үстерүнең ничек авыр булганын бер Алла белә дә, Гамил белән Сәгъдия үзләре генә белә. Җитмәсә заманасы да ябык килде бит аның! Завод бөлде, эш хакы алу бетте. Бик күп ир-ат, иртәнге сәгатьтә ишек алдындагы эскәмияләргә чыгып утыра да, көн буе шул тирәдә болгана. Гамил дә шулар арасында чуалып гомерен уздырган булыр иде, бәлки. Әмма аның ике яшь баланы, бигрәк тә исәнлеккә туймаган олы улын аякка бастырасы бар иде.

Чирләшкә бала өчен сулаган һаваның саф булуы бигрәк тә мөһим, диделәр. Гамилнең атасы вафат булып, анасы Казанга, кызының баласын карарга киткәч, авылдагы йортлары буш калган иде, Сәгъдия белән кинәштеләр дә, шунда кайтып урнаштылар. Аның тагын шунысы да бар бит әле: җирдәге кеше ач булмый, чөнки ул, заводтагы шикелле, аена ике тапкыр бирелгән акчага гына карап тормый. Бәрәңгесе, яшелчәсе, ите, сөте-мае табында була.

Дөрес, алар да җиңел генә бирелми, олы хуҗалык тотуның мәшәкате бетмәс-төкәнмәс бит аның. Гамил колхозда инженер булып урнашты, шуның өстенә, кешедән күрмәкче дигәндәй, аз-маз сату-алу белән дә шөгыльләнергә кереште. Шулай итеп, ул заманның ачы җилләренә бирешмәде, аяктан егылмады.

Бусы тыштан караганда шулай. Гаилә тормышының тышка бәреп чыкмаган, ятлар күзенә бәреп кермәгән төсмерләре дә була. Мир алдында анадан тума чишенеп, тәндәге бар бетчәләрне күрсәтү ярамаган кебек, ир кешегә күңелен ачып салу да килешми. Авызың тулы кан булса да, кеше алдында төкермә, дигәннәр. Гамилнең дә кешедән яшерергә тырышкан күңел сызлавыгы бар. Аның урынында башка берәү булса, нишләр икән, әйтүе кыен. Хатынның ят кыяфәтле зәгыйфь бала алып кайтып, колагына читтән: "Синеке түгел ул, башка берәүдән"...—дип сүз ирештереп торсалар, менә чыдавы җиңел түгел. Чирләшкә баладан, кеше гайбәтеннән туеп, койрыкны читкә борган ир-атлар да азмы әллә? Гаилә тормышын иплә итеп кору ул майлы ботка ашау гына түгел... Әгәр берәр ир: "Хатыныма караган саен ләззәт хисе кичереп, тавышын ишеткән саен күңелем хушланып кына яшәдем, ул миңа беркайчан да ямьсез булып күренмәде, сүзләреннән күңелем болганмады, өйдә бала елаган тавыштан колагым тонмады",—дип сөйли икән, ул чеп-чи ялганчы. Яки чиктән тыш хәйләкәр...

Шулай да, бераз бозылышып йөргәч килешеп, суынып торганнан соң, сөешеп була. Ә менә күңел түренә шик корты, көнчелек корты кереп ояласа

һәм ул, әледән-әле уянып, бәгыренне кимергәләп торса, нишләргә? Их, ул бала никләр генә анасына йә атасына охшамады икән? Ник ул әле капитан күрсәткән карточкадагы малай төсле булып тумады икән?.. Ник? Бу сорауга җавап табу мөмкин түгел иде һәм шунлыктан шикне дә куып булмады.

Баштарак бу корт үзен сирәк сиздерде. Чөнки аннан тыш та гамьнәр күп иде. Сабыена өч ай тулдымы-юкмы, хатынның тагын йөккә узганы беленде. Сакланырга кирәк булгандыр да, Сәгъдия, татар хатыннарына хас буганча, бу хакта ире белән ачыктан-ачык сөйләшергә оялды. Мәхәббәткә оят килешми дә бит, нишлисең... Үз чиратында Гамил хатынына, монысы белән нишләргә белгән юк, больницага кереп чык, дип турыдан әйтә алмады. Ә вакыт дигәнең уза да китә бит ул. Аннары соң булып чыкты... Кыскасы, туасы җан туды... Һәм, әйтергә кирәк, атасының бәхетенә туган булып чыкты.

Бу бала тудыру йортыннан ук йомры башында кара чәч, әлегә төсе ачылмаган күк күзләре тирәсендә кара керфекләр алып кайтты. Калын тавыш белән үзенә кирәкне сорый, әнисенең күкрәген томырылып каба, имгәндә тырышканнан киң борыны тирәсенә, нәни бөрчекләр булып, тир бәреп чыга. "Үзебезнең нәсел",—дип уйлады Гамил аны күрүгә. Һәм баш түбәсен сирәк сары төк каплаган, озынча йөзендә зәңгәр күзләре дымланып торган өлкән малаена сәерсенеп карап куйды.

"Берәр бабабыз блондин булгандыр!—диде Сәгъдия анын карашын сизеп.—Кил әле, улым, син дә. Анагыз сөтле сыер бит сезнең, ике бозауга җитәрлек". Һәм җирән чәчле малайны тезенә утыртып, кара чәчлесен сул терсәгенә салып, түш сәдәфләрен ычкындырды.

Ун көнләп әнисен күрми торган Җәмил, энесеннән көнләшеп, үрсәләнеп имәргә керешге.

Яше тулып теше дә чыкмаган, рәтләп тәпи басып торырга да өйрәнә алмаган малай, энесенә ияреп, дигәндәй, бик тиз ныгып китте, көчен арттырды. Өч-дүрт яшьтә алар тәмам тигезләшеп киттеләр. Шул ук вакытта аерма да нык күзгә бәрелә башлады. Җәмилнең башына алтынсу кызыллык йөгерде, озынча яңакларына сары сипкелләр сибелде. Газимнең исә, чәч-каш каралыгын көчәйтеп, күзләренә күмер төсе сеңде һәм бәбәкләрендә әнисендәге чаткылар кабынды. Гамилнең ике кулына ябышкан ике малайны беренче күргән кеше: "Күрше малаен да калдырмыйсыз, ә!"—дип куя. "Икесе дә үземнеке",—дисәң, аптырап: "И-и, бу табигатьнең хикмәтләре, игезәк балаларны нинди төрле итеп яраткан, әйтсәң, адәм ышанмас",—дип баш чайкый. Арттан: "Җирән чәчлесе тач Зөфәр инде!"—дигән сүзләр йөргәне дә колакка килеп ирешкәләде.

Хәтерендә, әле Таллыда яшиләр иде, бер якын танышы кунакка килде. Бераз капкалап алгач, балконга тәмәке тартырга чыктылар. Гамилнең, яшь балага зыяны тияр дип, бер ай инде тәмәкене ташлап йөргән чагы иде. Кунак кесәсеннән затлы сигарет кабы чыгарды да, берсен авызына кыстырып, кыйбатлы зажигалкасыннан нәни ялкын теле сикертеп кабызды, ләззәтләнеп, пошкырып, татлы төтенне йолдызлы күккә өрде. Һәм:

—Эти булуның четерекле яклары бар инде аның,—дип куйды.

—Нәрсәсе четерекле булсын? Табигый хәл,—диде Гамил.

—Табигыен табигый да бит... Табигатьнең хикмәтләре күп шул аның. Хатын кеше баланың үзенеке икәнен тәгаен белә. Чөнки үзе таба. Ә ирләрнең хәле четереклерәк... Әйтәләр бит әле, урамда берәр бала күрсәң, башын сыйпап уз, бәлки, ул синекедер, дип... Әйтик, менә синең малайның башын Зөфәрнең сыйпап узуы бар....

Һәм ул ямьсез итеп көлеп куйды.

—Бир әле миңа берне,—дип дустыннан тәмәке сорап алды Гамил һәм үпкәсенең бөтен көченә ачы төтен суырды.

Андыйларны ишеткән чакларда күңел түрендәге шик корты аждаһага әверелгәндәй була, авызыннан тәмуг ялкыны өреп, бәгырьне яндыра кебек иде.

Әйе, аргы урам Зөфәрнең дә чәче җирән иде шул. Авылда бердәнбер җирән баш аныкы иде.

Гамилләрдән бер сыйныф алданрак укыды ул һәм соңгы елында Сәгъдиягә күнеле төшкәнен беркемнән дә яшереп тормады. Аның мәхәббәте утлы, үчле, ташу кебек аяусыз иде. Шул ташуның ярсуы Гамилнең авызында мәңгелек эз калдырды—Зөфәр аның битенә тимер кусәк белән орды. Йодрык белән сугышканда, кычыткан арасыннан суырып алды да, бәрде. Алдан яшереп куйган булган, күрәсең. Гадел сугыш түгел иде бу, сабан туе көрәшендә аяк чалудан күпкә хәрәмлерәк, яманрак иде. Астыртын хәйлә белән жинде, әмма морадына ирешә алмады—Сәгъдия барыбер аны үзенә якын китермәде. "Ачуын чыкса, минем тешләрне дә кояр идеңме әллә?"—дип аннан көлде генә.

Күпләр, Зөфәрнең мәхәббәтен кире кагып, Сәгъдия зур хата ясады, дип саный, бу хакта йөзенә бәреп әйтүчеләр дә юк түгел. Чөнки унган егет булып чыкты җирән башлы Зөфәр, югары күтәрелде. Болгавыр елларның болганчык суына җәтмәне киң салды һәм балыкны мул эләктерде. Казанда да, Мәскәүдә дә бик зур кешеләр белән эш итә, авылга "Гранд-чероки"га утырып кына кайтып төшә.

Әгәр Сәгъдия белән борчагы пешкән булса, нур өстенә нур гына булачак иде ана. Зур шәхесләрнең күзен кыздырырлык чибәрлек өстенә затлылык, күзләрендә яктырып торган рухи бөтенлек бар Сәгъдиядә. Сәхнәләрдә балкырлык, манекенщица булып, мода салоннарда яна күлмәкләр күрсәтеп йөрерлек. Төз аякларының озын-нәфислеген, күкрәкләренең муллыгын яшереп тә тормый, сыланып торган чалбарын да, бик кыска итәген дә, ачык түшле кофтасын да кия торган иде. "Артистка булырга тиеш син!"—дип еш әйтәләр иде ана.

Ә ул гадәтенчә шаярып көлде генә: "Мин театрны бер генә тамашачы өчен уйнаячакмын. Ә ул Мәскәүнеке дә, Казанныкы да түгел".

Аның тамашачысы—Гамил ерак көнчыгышта, армиядә иде ул чакта.

Әллә соң, ул Себер урманнары уртасында, гимнастерка киеп, мылтык тагып йөргәндә, монда, Зөфәр белән Сәгъдия арасында, берәр төрле сөйләшү-аңлашу булдымы икән? Шулай булса, аларның бит, Алла сакласын, кыз кияүгә чыккач та берәр тапкыр очрашып куюы ихтимал! Озын телләр шуңа киная ясый! Җирән чәчле егет үзе дә андый сүзләрне юкка чыгарырга тырышмады. "Сәгъдия белән минем арада берни дә булмады",—дип чын дөресен әйтеп, кырт кистереп куймады. Сары керфекле зәңгәр күзләрен серле кысып:

—Хатыннарыгызга хуҗа була белегез,—ди торган булды.—Минем күз карашымнан да буйга узулары ихтимал!

Аның мондый сүзләре колактан-колакка күчә-күчә Гайнуллиннарга да килеп ирешә, йөрәккә тузан булып сарыла иде.

Ләкин алар сүз артыннан чапмыйлар, акланып йөрмиләр. Актарына башласаң, гайбәт тагын да ныграк үрчи бит ул.

Әйе, эчендәге утны тышка чыгармады Гамил, Сәгъдиянең дә, балаларның да күзенә төтен җибәрмәде, гаиләнең һавасын агуламады. Гомер юлдашына ышанмаган булса, бер рәхәт тә күрмәсләр иде. Ә бит, яраткан кешеннән яшерен сер сакларга кирәкми, диләр. Дөрес микән?

Әгәр бар ишеткәненне, белгәненне җәмәгатеннең башына коя торган булсаң, ул баш ничек чыдар? Күңелдәгене дә барыбер әйтеп бетереп булмый, аларны аңлата торган сүзләр табылып та бетмәгәндер әле. Хикмәт эчендәгенне чыгарып аударуда түгел, хикмәт бер-береңне аяуда, саклауда, хәленә керә белүдә. Адәм баласы икенче берәү белән бөтенләй бер булып та, ана берегеп тә бетә алмый. Ул бу дөньяга кем беләндер кочаклашып түгел, берүзе килә. Һәм киткәндә дә кем беләндер җитәкләшеп китмәячәк. Гомер сәгате һәркем өчен аерым суга. Шуңа күрә яшәгәндә дә ул үз йөген үзе күтәрергә тиеш.

Аннары шунысы да бар: гайбәтчеләрнең ясы теле нинди агу чәчмәс? Сәгъдиянең ниндилеген беләмени алар? Асылда моны фәкать Гамил генә белә! Тыныч акыл белән уйлап карасаң, гайбәткә, шиккә берниди нигез юк лабаса!

* * *

Әлбәттә инде Сәгъдиянең үзенә дә киная ясаучылар да, турыдан-туры сораучылар да аз булмады.

—Ике улың нишләп шул хәтле ике төрле?

—Үзебез шулай теләдек,—дип җавап бирә ул.

—Ничек алай?

—Минутын туры китердек.

—Нәрсәнең минутын?

—Нәрсәнең икәнен белмисезмени? Беренчесе кояш нурыннан ярылсын, икенчесе төннең иң карасыннан булсын, дип тырыштык! Сез дә шулай итеп карагыз! Хи-хи-хи!

Шулай ди дә, башын артка ташлап, күзләрен кысып, тигез тешләрен җемелдәтеп кычкырып көлә ул.

—Ишеткәнегез юк идеме әллә? Җыры да бар бит анын.

Һәм кайчандыр радиодан отып алган бер җырны җырлап бирә:

*"Ике канаты кебек ике бала,*
*Тик берсе ак, икенчесе кап-кара.*
*Чеметтереп әйтүчеләр бар иде:*
*"Төрле агачтан өздең мәллә",—диеп;*
*Яңгыратып көлә генә иде ул:*
*"Орлыгы кояш нурыннан төште шул".*
*"Ә бусы соң, икенчесе ник кара,*
*Абыйсына охшамаган бу бала..."*
*Күз кысып, серле елмая иде ул:*
*"Төне бәрхеттәй караңгы иде шул"...*

Мондый сөйләшүләр турында ул кайтып иренә әйтә, җырын да кабатлап җырлап куя. Һәм Сәгъдиянең шук карашы, шаянлыгы Гамилнең күнеленә сары май булып ята. Чөнки "малайның орлыгы кояш нурыннан төште" дигән сүзләрнең алар гына белә торган асыл мәгънәсе бар.

Хикмәт шунда: аларның зөфаф киче чынында кояшлы көн үзәгендә булды. Бу—ике арада гына саклана торган сер, чөнки сөйләсәң, кеше ышанмас, мөгаен. Өйләнешкәндә, Гамил—армиядә хезмәт итеп кайткан завод эшчесе, Сәгъдия, мәктәпне тәмамлагач, бухгалтер курсларыннан кайтып, колхоз идарәсендә кассир булып эшли иде. Егермегә житкән егет белән кызның сафлыгы сакланган булуына бу заманда күпләр ышанмас та, бәлки. Ләкин бу шулай иде, алар бер-берсенә беренче булдылар.

Барысы да күптән килгән тәртип буенча барды. Ярәштеләр, загска барып язылыштылар, туй табынының түрендә утырдылар. Кияү келәте күрше йортта җиһазланган иде. Хуш ис сибелгән урын-җир; электр самавыры янында матур чынаяклар; чәкчәк, талкыш кәләвә, җимешләр куелган затлы табын. Уртасында,бәллүр савытта—сап-сары кәрәзле бал. Чәчкә балы.

Яшь парның зөфаф киче ләззәтле булсын өчен, дус-иш, кардәш-ыру бик тырышкан иде. Кияү белән кәләш үзләре дә бу турында күптәннән хыялланган, күп төннәрне йоклый алмыйча, кавышу минутларын күз алдыннан мең кат уздырып, тәннәре кызышып, зиһеннәре чуалып үткәргәннәр иде. Җәннәтнең җиденче катына менгерергә тиеш иде бу мизгелләр... Чиксез бәхетле һәм ифрат кыска булырга тиеш иде бу төн...

Тик, ни хикмәт, ничек кенә зарыгып көтеп алсалар да, ничә еллар буе шул хакта хыялланып йөрсәләр дә, кавышуның иң татлы, иң ләззәтле минутлары ул кичтә түгел, соңрак булды... Бу төн исә хыялдагыга тәңгәл килеп үк җитмәде... Гамил калтыранган куллары белән кәләш күлмәгенең төймәләрен ычкындыра башлагач, Сәгъдиянең күз төпләрендәге гадәти шаян очкыннар сүнеп, күмер каралыгы гына калды, куе керфекләренә тамчылар кунды. Елмаючан иреннәре тартышты һәм ул сөйгәненең үбүенә гадәттәгечә эссе, татлы итеп җавап бирә алмады. Бөтен тәне хәрәкәтсез калгандай булды. Шат күнелле, җор сүзле, ачык йөзле, эшкә батыр бу

кызны бирәү дә мондый ук тыйнак, оялчан димәс иде...

Кияү үзе дә кызлар алдында батырлыгы-кыюлыгы белән масая-мактана торганнардан түгел. Гөнаһсыз егетнең сөйгәне белән беренче кавышканда каушап калуын, йомшаклыгын күрсәтмәс өчен артык каударлануын аңлап була...

Һәммәсе, өермәгә эләккәндәй, баш әйләндергеч һәм бик тиз булды. Күпмедер мизгелдән соң, бөтен вөҗүден биләп алган татлы талчыкканлык тоеп, таралып чалкан яткан Гамил күңеленең бер почмагын канәгатьсезлек хисе тырнаганын тойды: онытылып күккә ашканда, сөйгәнен дә үзе белән бергә, гайрәтле канатларында очыртып, җәннәт капкасыннан алып керә алмады кебек ул.

Ул кичтә бу хакта кинаялап булса да сорау мөмкин түгел кебек тоелды— сүзләр артык тупас яңгыраячак иде. Хәер, тел тибрәтүнең кирәге дә юк: башын аның култык астына салып, посып яткан Сәгъдия сүзсез сорауга кайнар сулышы белән җавап бирде. Ничек кенә булса да, ул ярыннан разый иде...

Соңыннан аңлашылды: тылсымлы капкадан бергә керер өчен, бер-береңә күнегергә, ияләшергә кирәк икән. Инсаф иясе Сәгъдия моның шулай икәнлеген табигате белән тойды, парының хәленә керә белде.

...Иртән көн яктыра башлагач, Сәгъдия пычак очы белән беләген сызып җибәрде.

—Нишлисең син?!

—Мондый чакта тикшерүче күп, күңелләре булсын, —диде ул һәм беләгеннән саркыган кан тамчыларын ятакның ак җәймәсенә сөртте.

Ә көндезен алар, мотоциклга утырып, авыл очындагы буа буена киттеләр. Сәгъдия аны арттан кочаклап, тулы күкрәкләре белән сыенып утырган иде.

Мотоциклны яр читендәге карт өянке төбенә куеп, чишенгәндә, Сәгъдия бернинди тартыну, кыенсыну сиздермәде. Ул ялтырап яткан суны чәчрәтеп, йөгереп керде дә, кулларын егетләрчә селтәп, йөзеп китте. Гамил арырак барып, бетон буадан сикерде. Ул, су астыннан йөзеп, кәләше артыннан җитмәкче иде. Ләкин Сәгъдияне алай ансат кына тота алмассың, ул шактый ерак киткән булып чыкты. Егет, башын чыгарып, тирән итеп сулыш алды да, кире чумып, яр буендагы камышлыкка таба борылды. Анда, корыган ботакларын тырпайтып, ярым баткан өянке кәүсәсе сузылып ята иде. Гамил шуның артына посты да, борыны белән сыңар колагын гына чыгарып, тынып калды.

—Гамил, син кайда?—диде бераздан Сәгъдия. Тавышы башта көр иде. Ләкин икенче тапкырында сагаю сизелде.

—Гамил дим, шаярма инде...

Аннары инде борчылу, курку чалымнары яңгырады:

—Ай ходаем, буадан сикергәндә башы бәрелде микән әллә...

Гамил, аның якынайганын сизеп, башын суга, камышлар арасына тыкты. Сәгъдия ашыгып аның янына килде.

—Гамил, җаным, ни булды сиңа? Әйт инде бер сүз генә, ә?

Ул, егетнең башын судан чыгарып күкрәгенә кысты, аннары комлыкка таба йөздереп алып китте. Су сай, тик аяклары ләмгә бата, ашыгудан ул еш-еш сулый, йөрәге шашып тибә иде. Гамил өчен аның шома беләгенә муенны, арканы салып йөзеп бару шундый рәхәт иде... Тик ул моны чыраенда күрсәтмәскә тырышты, күзен дә ачмады.

—Я инде, бәгърем, шаярма инде. Юри генә кыланганыңны белеп торам бит...

Ул, дулкынланудан кайнарланган иреннәре белән аның иреннәренә беректе. Монысына инде чыдап булмады, Гамил сикереп торды да Сәгъдияне кочаклап алды.

—Хәзер менә мин сине...

—Син мине юри шулай куркытасыңмыни әле?

—Курык, курык! Син дә бер куркырга тиеш бит инде!..

—Курыккан ди менә! Көт!

Сәгъдия иелеп, аның юеш кочагыннан шуып чыкты да, чирәм баскан үргә каршы йөгерде. Дымлы, тыгыз, шома балтырлары кояшта елык-елык ялтырады.

Гамил аның артыннан томырылды. Сәгъдия борылып карап шаркылдап көлә, мөгаен, тоттырмаячагына ышана иде. Сабан туйларында йөгерештә аны җиңгән юк. Тик дәрте кузгалган егетнең аякларына нинди канатлар үскәнен белми әле ул. Ә бәлки, үзенең дә тотыласы килгәндер, кызлар йөрәген җилкеткән хис мондый минутларда иң җитез аякларның да хәлен ала бит ул.

Яр өстендә рәт-рәт утыртылган агачлык, аның алдында җиләкле алан. Алдарак үскән яшь каенга тотынып берничә тапкыр әйләнде Сәгъдия. Ниһаять, егетнең кулына килеп эләкте, кайнар, татлы сулышы битне өтте...

Менә шунда, кояш нурыннан сырылган юрган астында булды аларның зөфаф киче. Сөйгәне өчен башта курку, аннары сөенү, шаярып куышу кызның күңел бикләрен ачкан, хисләренең кайнарлыгын ургытып өскә чыгарган һәм оялу-тартынуны оныттырган иде. Ул күзләрен йомды да, Гамилнең татлы сүзләреннән исереп, аңа буйсынды... Аның кочагында ләззәттән һәм татлы сызланудан ыңгырашып бәргәләнде.

—Чибәрем, чибәркәем,—дип пышылдады ул күзләрен йомган килеш.

...Күпмедер вакыттан соң Гамил буа суында аның иң затлы сыннардан камил, төз аякларын үзе юды. Ир кешегә гомер иткәндә бирелә торган иң бәхетле минутлар менә шулдыр да, бәлки. Һәм андый бәхет күпләргә тәтеми дә...

Ә "чибәрем" сүзе шушы көннең билгесе булып калды. Иренең күңелен нечкәртәсе килгән чакларда Сәгъдия шулай дип эндәшә. Моны ишеткән кайберәүләр көлә көлүен:

—Гамилме чибәр? Улмы?—диләр. Чөнки киң битле, җәенке борынлы, янаклары яшьлектә чыккан бетчәләрдән бераз чуарланып калган Гамилне, ямьсез булмаса да, чибәрләр рәтенә дә кертеп булмый.

—Аның матурлыгы мин генә күрә торган,—ди Сәгъдия.—Эчендә. Бүтәннәр темиен бик сузмасын өчен махсус яшерелгән.

Туй табынында әдәпсез кодаларның берсе, кулларын алга сузып, тугыз бармакка тугыз айны туры китереп, санаганнан соң: "Киләсе елның апрелендә бәби туена килербез",—дигән иде.

Малай ул әйткән вакыттан дүрт айга сонарып туды. Гамилгә бөтенләй охшамаган, нәкъ Зөфәр төсле җирән чәчле малай... Сәгъдиянең шаян жыры да белмәгәннәр-санамаганнар өчен генә... Баланың чәчен-битен яралганда ук кояш нуры ундыргандыр, дип фараз итеп булмый... Әлеге дә баягы шул геннарның шаяруыдыр дисән генә инде.

Балалар мәктәпкә керер чак җиткәч, сәламәтлекләрен тагын бер тапкыр тикшерделәр, бер очтан кан группаларын да язып җибәрделәр. Кыяфәтләре бер-берсенә бөтенләй охшамаган ике малайның каны төрле булу гаҗәп түгел иде: Җәмилнең икенче группа, Газимнең өченче. Гаҗәбе шул: олы малайның каны үзенә аерым булып чыкты. Чөнки әти кешенең каны—өченче группа, ә әниләренең—беренче. Кече малайның каны—атасыныкы. Олысыныкы кемнеке?

Бу хакта әйткәч, Сәгъдия озын керфекләрен аска төшереп, кәгазьгә карады да:

—Ә-ә, син аны тикшереп утырасыңмыни әле?—диде.—Ә мин бөтенләй игътибар да итмәгән идем. Карале, чибәркәем, безнең өйдә кан группаларның һәммәсе диярлек бар икән бит! Берәребезгә кан салырга туры килсә, күршегә кереп ялынасы юк! Сөенергә кирәк моңа!

Һәм, гадәтенчә, йомшак кына итеп хихылдап куйды да ашыгып ишегалдына чыгып китте. Сыер савасы бар иде. Бүтән чакта күңелгә сары май булып ята торган көлү авазы бу юлы Гамилнең җанын наждак кебек тырнап узды. Һәм күз алдына күп сораулар килеп басты. Алар нәселендә кем җирән, сипкелле булган? Һәм кемнең каны икенче группа?

Соңгы елларда гәзитләрдә, баланың кайсы атадан туганлыгын геннарыннан

белеп була, дип язалар. Әгәр Сәгъдиянең хәтерен калдырудан курыкмаса, Гамил, мөгаен, геннарны тикшерү чарасына да керешкән булыр иде.

Нигә табигать үзенең балалары белән бу төсле итеп шаяра икән? Нигә ул Гамилнең улын ят кыяфәтле итеп яраткан да ни өчен Харитонов дигән адәмгә нәкъ аның төсле малай биргән? Бәлки, Харитонов үзе яисә аның хатыны Гамилгә охшагандыр? Бер-берсенә охшаш адәмнәр күп, диләр бит. Әйтик, Мәскәү урамнарында хәзер дә нәкъ Сталин, Гитлер төсле бәндәләр йөри икән. Ләкин тавыш бар бит әле. "Атас!" дип кычкырган үсмер бар. Шул Харитонов булды микән ул? Алайга китсә, бөтенләй сәер булып чыга бит әле бу...

Гамил какшау диванны шыгырдатып, сабырсызланып боргаланды. Тизрәк таң атсын иде. Теге малайны барып күрергә, бу табышмакны чишәргә кирәк. Шунсыз җаны тынгы тапмаячак иде.

* * *

Иртәнге сәгать уннан соң, ятып торган хасталар янына якыннарын кертә башлыйлар, үз аягындагылар ишегалдына чыга. Гамил мендәр астыннан чалбарын, сандалиларын алып киде дә, урамга ук чыкты, аннары трамвайга утырды. Тукталышта да, трамвайда да һәммәсенең карашы ана төбәлде: буйлы халат сәерсендерә иде, әлбәттә.

Гамил элекке фатирына китте. Анда берәр кием булырга тиеш иде.

Ачкычның берсен алар күрше карчыкта тоталар. Бәхеткә, әби өйдә иде, Гамил, аның аптыраган карашын сизмәмешкә салышып, йомышын йомышлады да тиз генә борылып чыгып китәргә ашыкты.

Ишектән керүгә телефонга ябышты. Сәгъдия идарәдә булса гына ярар иде... Әйе, ул урынында! Трубканы да үзе алды. Бар шул аның шундый сыйфаты, Гамилнең хәлен әллә каян тоеп тора. Әнә бит, янгыравык, моңлы тавышы нинди борчулы:

—Ни булды анда? Барыйммы әллә?

—Газим кайда?—дип сорады Гамил сабырсызланып.

—Газимме?..—Сәгъдиянең гаҗәпләнгәне сизелде.—Нәрсә сез Газим дә Газим? Кичә Сәрия дә шуны сорады.

—Кайда соң ул?

—Кайда булсын? Мастерскойда! Комбайн ремонтлыйлар лабаса. Син үзеңне әйт: башын ничек?

—Баш урынында ла. Ә кичә кайда иде Газим?

—Мастерскойда иде.

—Ә кич белән?

—Нәрсә кич белән?

—Өйдән чыгып йөрмәдеме?

—Чыкмады беркая да. Аптыраттыгыз инде. Ни булды соң анда? Кайчан кайтасың?

—Кайтырмын,—диде Гамил.—Килеп йөри күрмә тагын. Минем бераз эшем бар әле.

—Нинди эшең?

—Кайткач сөйләрмен.

Шулай диде дә, телефонны куйды Гамил. Димәк, теге "Атас!" дип кычкырган малай Газим булмаган...

Сәрия өйдә үзенчә тәртип урнаштырган, апасыннан калган кием-салымны юып-үтүкләп шкафка элеп куйган. Сөйкемсез җизнәсенең әйберкарасына андый игътибар эләкмәгән, әлбәттә. Гамил шкафны ачуга моны аңлады һәм тар, эссе балконга чыкты. Әйе, чыннан да, аның заводка йөргән киемнәре катыргы тартмада бөгәрләнеп ята икән. Ул үзалдына елмаеп куйды: "Чүплек башына чыгарып ташламавына рәхмәт инде, балдызым-ялгызым!"

Тартмадан кара футболка килеп чыкты. Алдына да, артына да кызыл буяу белән кайсыдыр илнең җырчы егетләре ясалган. Чәч-башлары тузгыган,

киемнәре кеше карарлык түгел. Пәри дә пәри, болар да пәри. Ләкин башкасы юк, Гамил шул женле җиләнне киеп куйды да, ишек янындагы көзгегә карап, маңгаена төшкән тыңлаусыз кара чәчләрен төкереге белән сыпыргалады. "Чын братаннан кай җирем ким?"—дип уйлап куйды.

Хәзер милиция бүлегенә барырга кирәк, Харитоновны алар аша гына табып булачак иде.

Ишегалдында, каеннар күләгәсендәге өстәл тирәсендә, берничә ир-ат доминомы, кәртме сугып утыралар иде. Танышлар, элек заводта бергә эшләгән кешеләр. Бер-икесе, Гамилне күреп, урыныннан калкынган иде, ләкин ул тукталмады, ашыгам, соңыннан, дигәнне белгертеп, кулы белән сәлам биреп кенә узып китте.

Капитан Фәхриев милиция бүлегенең ишек төбендә ике кеше белән сөйләшеп тора иде, Гамилне күргәч, шундук сүзен бүлеп, каршыга ашыкты.

—Әйдәгез.

Бүлмәгә керүгә, кыршылган өстәл тартмасыннан берничә бит кәгазь белән ручка чыгарды.

—Гариза язабыз, димәк?—дип, утырырга урындык күрсәтте.

Аннары, озак эшләргә җыенгандай, өстәл артына кереп, терсәкләрен киң җәеп, иркенләп утырды.

—Юк, мин язарга түгел әле,—диде Гамил кәгазьне аңа таба этеп.—Документлар кирәк.

—Язмыйсыз, димәк?—Капитанның кара кашлары канәгатьсез җыерылды.

—Нәрсәгә гариза? Ни булган әле? Мин документларны төшереп калдырганмын, сез тапкансыз, фәкать шул гына лабаса.

Капитан шатырдатып өстәл тартмасын тартып чыгарды да аннан кара күн бумажник алды.

—Берни булмаганмы? Үтерергә кирәк идеме әллә сезне?—диде ул ачу белән.—Ул Корбанаевларның, Харитоновларның малайлары үсеп кенә житсен. Көч кенә җыйсын. Күрсәтәчәк әле алар барыбызга да.

—Шулай бик куркынычмыни?

—Без аларны җинаять өстендә диярлек тоттык! Берләшеп, кеше талаганнар! Кулларында кусәк, пычак булган! Ләкин җавапка тартып булмый, чөнки, алардан каза күрдем, дип гариза бирүче юк. Чыгарып җибәрергә тиеш булдык без аларны! Ә кичен алар янә җыелып укмашырлар да карангы почмакта тагын сезнең ише берәрсен сагалап торырлар. Ә ник шулай итмәсеннәр? Кеше талаган өчен дә, кыйнаган өчен дә берни булмый бит. Шулай түгелмени?

Дөрес сөйли иде капитан. Тик Гамилнең гамендә бөтенләй башка иде шул. Хискә мавыккан бу милиционердан Харитоновның адресын ничек итеп җай гына сорап алырга икән?

—Заводта безнең белән бер Харитонов эшләгән иде. Әллә шуның малаемы микән?—дип җиңел генә сорап куйды ул.

—Геннадий Макаровичны әйтәсезме? Двигательләр заводында эшләгән шул ул. Завод янгач, бүтән җирдә төпләнә алмаган. Сез дә шунда эшләгән идегезме әллә?

—Мин инде байтактан киттем,—диде Гамил туры җавап бирмичә.—Авылга кайтып төпләндек.

—Һәм дөрес эшләгәнсез дә,—диде Ринат һәм уйчан карашын рәшәткәле тәрәзәгә, керле пыяла артындагы тузанлы өрәңгегә текәп.—Монда балаларны үстерү жиңел түгел. Ирләргә эш юк. Иртән чыгып, ишек алдындагы эскәмияләргә тезелешеп утыралар да, бер шешә сырага йә йөз грамм аракыга ничек акча юнәтергә, дип гәп коралар. Бар уйлаганнары, шөгыльләре шул. Ул заводны яңадан эшләтә башласалар, рәтле һөнәр иясен таба алмый интегәчәкләр әле. Ничә ел тик утырып, эштән бизеп бетте халык. Шул ук Харитоновны менә дигән моторист булган дип сөйлиләр. Колагын куеп тыңлый иде дә, кайсы клапаны эшләмәгәнен төп-төгәл әйтеп бирә, диләр. Хак шулаймы?

Гамил, әйе дигәнне аңлатып, ияген кагып куйды.

—Алтын куллы оста иде, диләр,—дип дәвам итте капитан.—Хәзер, әнә, сизгер колагының да, унган кулының да кирәге калмаган. Бугазы гына ходта.

—Эчәмени?

—Монда шактый халык шуна сабышкан лабаса. Кем булып үсә инде андый аталарның балалары?

—Машина ремонтлый торган мастерскойлар күп бит. Барсын иде шуларның берәрсенә.

—Урнаштырып карадык. Куалар. Анда заводтагыча түгел шул, яна хуҗаларның талканы коры. Бер тапкыр эчеп килсә, икенче көнне капкадан кертмиләр. Ә ул кайта да кайгыдан тагын эчә. Балаларын уйлау юк. Малай урамда. Үз ишләре белән. Һәр кварталда бер төркем булып оешканнар. Теләсә нишлиләр. Сүз әйтүче юк, каршы торучы юк...

Ул кесәсеннән сигарет кабын чыгарды да, Гамилгә таба сузды.

—Тартмыйсызмыни?—диде Гамилнең баш чайкаганын күреп.—Ә мин менә тартам. Ташлый алмыйм. Бер күнеккәч авыр икән ул.

—Мин дә армиядән өйрәнеп кайткан идем,—диде Гамил.

—Ничек ташладыгыз соң?

—Әйтәм ич, ике малай үсеп килә. Олысы тумыштан ук исәнлеккә туймады. Малайларга ияреп тарта башлаган иде. Тартмаска дип, икәүләшеп сүз куештык.

—Сүзегездә тордыгызмы?

—Малайлар белән икеле-микеле сөйләшеп булмый,—диде Гамил.—Улыгыз булса, үзегез дә беләсездер.

—Минем кыз шул. Икенчесен алып кайтып булмады әле... Хатынның кешечә яшисе килә, ә безнең эш хакын үзегез беләсез...

Ринат, тәмәкесен йотлыгып суыра-суыра, шактый вакыт тәрәзәгә карап торды.

—Сез ничектер, мин үземнең кызым өчен куркам,—диде аннары.—Мәктәпкә илтеп куябыз, алып кайтабыз. Өченче класста инде югыйсә, ерак та түгел. Ярый, хәзер без саклап йөрибез. Ә үскәч ничек яшәрләр? Шул хулиган-бандитлар белән бер шәһәрдә гомер итәргә кирәк булачак бит аларга. Шулай түгелмени?

Ул кире урынына утырды да төпчеген китек тәлинкәгә сытып сүндерде. Аннары өстәл тартмасын шудырып ачып, фоторәсемнәр чыгарды. Арадан нишләптер Макар Харитоновны сайлап аласы итте.

—Менә шушылар белән яшисе,—диде фотога текәлеп.—Хулиганнарның, бандитларның маңгаенда тамгасы юк шул. Карап торышка бер дә начар димәссең үзләрен. Сезнекеләрдән кай җире ким моның югыйсә?

Капитан фотоны Гамилгә таба сузды да, кинәт тынып калды. Маңгай сырлары тирәнәйде, коңгырт күзләре түгәрәкләнеп килде.

—Берәр туганыгызмы әллә?—дип сорады ул чиктән тыш гаҗәпләнеп. Аннары аңлатырга кирәк тапты.—Фамилиясе Харитонов та бит... Хәзер халык буталышып бетте. Татарның урыс кияүләре, марҗа киленнәре җитәрлек...

Гамилнең дә теле аңкавына ябышкандай булган иде. Кысан бүлмәдә тынлык урнашты, тыштан машиналарның сирәк кенә гүләп узганы гына ишетелеп торды. Ниһаять, Гамил зиһенен җыеп:

—Нигә алай дисез?—дия алды.

—Кинәт кенә... сезгә охшаган төсле тоелды. Ирен өстендәге миңенә хәтле... Борын очына чыккан бетчәсе менә...Сезнең ул төштә шадра, әнә... Икегезнең дә чәч кара, йөз түгәрәк... Атасы озынча чырайлы җирән адәм аның югыйсә...

Моңа каршы нидер әйтергә кирәк иде. Гамил сүзне шаяртуга борырга тырышты.

—Дөньяда ни булмас та кем кемгә охшамас... Борынгылар да, их, яшь чаклар бар иде, киң урамнар тар иде, шәһәр саен, авыл саен сөйгән ярлар бар иде, дип җырлаган бит. Без алардан кимме әллә? Егет кеше кайда

нинди малае үсеп килгәнен үзе дә белми,—дип сөйләнде ул, чыраена шуклык галәмәте чыгарырга тырышып. Тик үзе үк чыраеның тартышканын, елмаюының чалыш чыкканын тойды.

Капитан аңа текәлгән килеш дәшми утыруында иде.

—Сез шулай дигәч инде... барып күреп кайтмый булмас,—дип дәвам итте Гамил.—Харитоновның да хәлен белешермен. Күптән очрашкан юк. Ни әйтсәң дә, бер заводта эшләгән кеше бит.

—Барыгыз шул! Күрми китмәгез! Геннадий үзе өендә булмаса, шул тирәдәге пивнушкададыр. Ерак йөрмәс... Кайда яшәгәннәрен беләсезме?

Һәм капитан гариза яздырырга дип әзерләнгән кәгазьгә эре хәрефләр белән Харитоновларның адресын сызгалады.

—Алар бу участокка күптән түгел генә күчеп килделәр әле.

—Яңа фатир алдылармы әллә?

—Кем бирсен аларга яңа фатир? Искесеннән колак кактылар. Өч бүлмәлене берлегә алыштырып килделәр... Монда ерак түгел. Мәгез, документларыгызны да алыгыз. Машинагыз милиция стоянкасында.

Ул кискен хәрәкәт белән күн бумажникны өстәл аша Гамилгә таба шудырды.

Документлар урынында, тик бер тиен дә акча юк иде. "Балдызкай янына банкка сугылып чыкмый булмас,—дип уйлады Гамил.—Яратмасаң яратмассың, ярдәменнән ташлама, дияргә. Әҗәткә акча сорап, тагын кемгә барып баш иим? Стоянка өчен штраф түлисе... Бензинын да агызып алмадылар микән әле"...

*Ахыры киләсе санда*

---

## Хөрмәтле укучыларыбыз һәм авторларыбыз!

**Журналыбыз белән даими танышып баручылар белә булыр: бездә «Казан утлары» архивыннан» дигән рубрика бар. Бу сәхифә байтак еллар гамәлдә булса да, элегрәк елларда материаллар сирәгрәк чыга иде. Соңгы вакытта «архив» активлашты, журналның һәр санында диярлек татар тарихыннан иҗтимагый әһәмияткә ия булган фотосурәтләр басылып килә. Теләгебез—алга таба да рубриканы кызыклырак һәм мәгънәлерәк итү. Бу эшне уңышлы дәвам итү өчен сезнең дә булышлык кирәк. Сезгә мөрәҗәгать-гозеребез шул: үзегезнең шәхси, гаилә альбомнарында яки оешма-учреждение архивларында сакланган кызыклы, тарихи-иҗтимагый кыйммәте булган (әдәбият һәм сәнгатебезнең мәшһүр шәхесләре, истәлекле мәдәни вакыйгаларга караган күренешләр, Казан һәм Татарстан тарихын яктырткан сурәтләр һ.б.) фоторәсемнәрне безгә юлласагыз икән! Шул рәсем турында аңлатма-комментарийларның булуы да шарт, әлбәттә. Без аларны журналда файдаланганнан соң, кире иясенә кайтара алыр идек.**

**Әйдәгез, кадерле укучылар, мөхтәрәм милләттәшләр, кайдадыр киштә-шкафларда, альбом-папкаларда ябылып яткан истәлекле ядкярләрне яктыга чыгарыйк, халкыбызның рухи елъязмасы сәхифәләре булып киләчәк буыннарга хезмәт итсен алар! Сездән кызыклы фотоматериаллар көтәбез.**



Зөлфәт

# ЯШӘП ТҮГЕЛ, ОЧЫП ҮТКӘНДӘ

## Сөю шаукымы

Иртәнге як авазларын
Бер генә тыңла әле...
Бу—тургай белән былбылның
Бергә сайраган мәле!

Бар бит, бар җәйге чорларның
Тулган-тулышкан чоры!
Җир хәбәре—Җир кошының
Галәмгә ашкан җыры!

Кушылып шаулый ташкынга
Елганың да таш-комы—
Таш булып хәтта ташны да
Уята хис шаукымы!

Сөю шаукымыннан мәллә
Кузгала таш ташкында?
Ташлар хәтта ашкынганда,
Йә, син ничек ашкынма?!

Ташый сөю ташкыннары—
Гашыйкның шундый хәле!
Бу—тургай белән былбылның
Бергә сайраган мәле...

## Шау

Шаккатып, һушсыз калырлык
Берни дә юк монда.
Тукталдым да уйга калдым
Урман аланында.

ЗӨЛФӘТ (1947) — *шагыйрь; "Утлы бозлар", "Адашкан болыт", "Йөрәгемне былбыл чакты" һ. б. китаплар авторы; Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты. Казанда яши.*

Аланда мәгърур агачтан
Ялгыз бер төп калган.
Утыр шул төпкә. Уйлан бер.
Уйдаш булсын алан.

...Хәер, бездә ни аерма
Шушы ялгыз төптән?
Төп калган. Шаулы агачны
Вакыт алып киткән!

Сораганмы, урлап кына
Алган микән Вакыт?
Инде күпме уйлансаң да
Шул аланга ятып,

Җавап тапмассың... Гомерне
Уйла, төшер искә.
Инде күптән юкка чыккан
Агач шаулый өстә.

Кай арада узып гомер,
Кая күмелде соң?—
Гомерең дә шул агачның
Шавы түгелме соң?

## Сүтелгән толым җиле

Аръякка килгәч күченеп
Һәм барлык чыккач юкка,
Сорарлар: "Сагынырлыгың
Калдымы дөньялыкта?"

Күз алдыма килер шулчак:
Куерып яфрак ява...
Көзге кошларның әзеннән
Серләнә зәңгәр һава...

Куе яфрак явымнары
Күлләрне каплап китә.
Күзгә күренмәс фәрештә
Гүяки толым сүтә,—

Җиңел, җылы пәрвезләр—
Сүтелгән толым җиле...
Фәрештәнең күзләренә
Төбәп карарга иде!..

И, көзнең шушы мәлләре
Сагышка сала мине...
Фәрештәнең күз карашы
Җылыткан чагы көнне.

Минсез калгач бу гүзәл мәл
Һәм "барлык"—чыккач "юкка",
Шушы мәлләр дәшәр һаман
Мине бу дөньялыктан...

## Тозак гомер

Баласы яшәр куанып,
Кылмас явызлык,
Бозмаса әнкә канынннан
Күчкән ялгызлык.

Коткаргандай гарасаттан,
Давыл-утлардан,
Яшер, язмыш, хатын-кызны
Ялгызлыклардан!

Ялгызга язмышның язы
Бик озак килер...
Озак гомер—тозак гомер—
Ялгызак гомер!

## Шаукым

Төбе микән, дулкыннары микән?—
Дәшә дә гел дәшә күңелне!
Су тарта гел, һаман су тарта гел!
Чиксез сулар дәшә гел мине...

Гел сихерле мине сәер шул көч!—
Шомланам мин аның алдында...
Дулкыннары, бәлки, айкап йөртер,
Йә чоңгылы убар тын гына...
Диңгезчене шашындырган шаукым
Бармы әллә минем канымда?

Нәкъ шул шаукым каргый мәллә мине,
Ялгышларга баттың, бәндәм, дип,
Су төбе йә менә дулкын гына
Йолыр сине мондый хәлдән, дип?

Мин аңлата алмыйм бу халәтне...
Зур су шаулый ерак-еракта!—
Мине—аулак кара урман улын—
Ни хикмәттер?—һаман су тарта!

## Талпыныш

Моңлы бер аһәң кагылып
Уятты да утны,
Күңелемә оялаган
Кош кузгалды. Купты!

Сүзләр аһәңгә уза да
Үз сәгатен көтә...
Күңелдәге гыйшкый сүзләр
Шигырьләнеп бетә!

Булдым гаҗиз: ни соң мине
Иләсләтә күптән?
Баксаң, бу сүзнең җан кереп
Калкынуы икән!—
Җанга оялаган кошның
Талпынуы икән!

Тыеп кара, аяк тибеп,
Канат каккан кошны!—
Мәхәббәт дип әйтәләрдер
Нәкъ шул талпынышны...

Җанда шул кошың җилпенгән
Гыйшкый минутларда
Йә, шагыйрь булмый кара син,
Шагыйрь булмый кара!

## Иң яшерен шигырь

Бар ул, бар ул—иң яшерен шигырь!—
Миндә килеш гомер итәчәк,
Һичкемгә дә сизелмәгән килеш
Сизеләсе чагын көтәчәк!

Белмим, белмим... Кайчан да бер аны
Кемгә дә бер әйтеп булырмы—
Һичкайчан да һәм һичкайда да
Сиздермәскә дигән шигырьне?

Әллә инде... әйтеп бирим микән?
Мин бит аннан гына тилермәм?
Бер котылу кирәктер бит инде
Иң-иң яшерен шул шигырьдән?

...Бар ул, бар ул иң яшерен шигырь!
Ачыласы көнен көтәчәк!
Көтәчәк... һәм ачылмаган килеш
Үзем белән бергә китәчәк.

Иң төп сүзем ләбаса ул минем!
Шуның өчен килдем мин җиргә!
Әйтмим. Куркам.
Ник тилертим сезне?
Төрдем сүзне яшрен шигырьгә!

Бар ул, бар ул—иң яшерен шигырь!
Сиздермәскә иттем мин тәүбә.
Үзе килер сезнең күңелгә ул...
Нәкъ мин язган килеш...
Бигайбә!

## Бөек сер

Кеше күңеле меңгә төрләнсә дә
Мәхәббәтле караш бер булыр—
Мәхәббәт ул бөек ачыш булмас,
Ачылмаслык бөек сер булыр.

Күпме яшәсәң дә аңламаслык
Күңел ашкындыргыч шул серең
Һәр яшәгән көнгә әфсен өрер,
Тылсымы шул булыр гомернең...

Һәммәсен дә аңламакчы кеше—
Акыл белән, әйе, бөекләр...
Аңлашылмас ләкин чын мәхәббәт—
Мәңгелектән килгән бөек сер,
Мәңгелеккә калган бөек сер...

Аңлашылса беркөн сөю сере,
Кешелеккә килер зур афәт—
Җиһан үзе юкка чыккан сыман
Юкка чыгар бөек мәхәббәт!

...Ярый әле, язмыш, насыйп иттең
Сөю дигән чоңгыл-үткелне,
Юкса, узып китәр, бетәр идем
Сердән мәхрүм дөнья шикелле...

***

Офыгыңда инде бүтән таңнар
Изри бүтән былбыл тавышыннан...
Күккә ашкан хыял шикеллерәк
Югалдың син минем тормышымнан.

Синең хыял белән минем хыял
Югалсыннар инде биек күктә...
Әйтер сүзләр әйтелмичә калсын
Югалтышкан чакта гомерлеккә!

Яшәмичә без калдырып киткән
Бәхетле бер гомер, эзләп безне,
Бәргәләнгән чакта өнсезлектә.
Җанда бер пакьлек тә сизмәбезме?

Еракларга киткән юл күренер,
Таралыр да бу гомерлек томан...
Юл ахыры безне алгысытыр
Әйтелмичә калган сүзләр сыман!

Офыгымда минем бүтән таңнар
Изри бүтән былбыл тавышыннан...
Пар канаты сынган хыял сыман
Мин егылып төштем язмышыңнан...

Мин егылып төшеп калдым кинәт...
Булды бугай очыш артык текә...
Пар канатлар сына төпсез күктә
Югалтышкан чакта мәңгелеккә!

# Çəçmə əsərlər
# Чәчмә әсәрләр

*Прозаик һәм публицист Әсгать Сәлах (Әсгать Сәхабетдин улы Сәлахов) әдәбиятыбызга узган гасыр азагында килеп кергән язучыларның берсе. Күпләрне гаҗәпләндереп һәм сокландырып туксанынчы еллар азагында һәм гасыр башында республика вакытлы матбугатында бербер артлы аның хикәяләре һәм повестьлары, әдәби очерклары, публицистик язмалары күренә башлады, нәшриятларда берничә китабы дөнья күрде.*

*Бер нәрсә дә юктан бар булмый. Баксаң, Әсгать Сәлах һәм икътисади, һәм мәдәни тармакларда эшләп, тормышның эчендә кайнап, гади эшчеләр һәм күренекле шәхесләр, язучылар һәм хезмәт каһарманнары белән аралашып, әдәбиятка бай тормыш тәҗрибәсе туплап килгән шәхесләребездән икән. Ул 1935 елның 5 гыйнварында Татарстанның Беренче Май районы Елховой авылында (хәзер Әлмәт районына керә) колхозчы гаиләсендә дөньяга килә. Язмышы шул чор кешеләренекенә хас булганча, фаҗигале дә, катлаулы да. Михнәт, кайгы-хәсрәт эчендә, әрнүсыкрау белән үткән балачак, үз тырышлыгы, үҗәтлеге белән белем алу, туган халкына хезмәт итү юлына басу. 1938 елда гаиләнең төп терәге булган бабасы Сәлах "колхозлашуга каршы агитация алып барганы өчен" репрессия корбаны була, "өчлек" карары нигезендә Бөгелмә төрмәсендә атып үтерелә. 1941 елның көзендә әтисе Сәхап һәм аның бертуган энесе Әгъзам сугыш тәгәрмәченең бөтен Европаны изгән, ботарлаган дәһшәтле тәгәрмәчләре арасына эләгеп һәлак булалар.*

*Авылның башлангыч мәктәбендә укыгач, Әсгать егерме биш чакрым ераклыктагы Лашман урта мәктәбенә йөреп урта белем ала, аннары Елховой сельпосында хисапчы булып эшли, армия хезмәтендә булып кайта, бораулаучылар әзерләүче мәктәптә укый, буровойда эшли башлый. Тырыш егетне Социалистик Хезмәт Герое Мөгаллим Гыймазов бик тиз күреп ала һәм үз бригадасына чакыра. Татарстандагы кара алтын ятмаларын үзләштерүчеләр арасында булачак язучы кешеләр язмышын өйрәнә, киләчәктә язылачак әсәрләренең каһарманнары белән иңгә-иң торып эшли.*

*1965 елда читтән торып Казан дәүләт университетының татар журналистикасы бүлеген тәмамлаганнан соң, аның бөтен хезмәт юлы вакытлы матбугат белән бәйле. Егерме биш елга якын Әлмәттә рус телендә чыгучы "Знамя труда" газетасында сәнәгать бүлеге мөдире булып эшли. Татарстанда милли яңарыш башлангач, нефтьчеләр башкаласында, ниһаять, татар телендә беренче мөстәкыйль "Әлмәт таңнары" газетасын оештыра һәм пенсиягә киткәнче аның баш мөхәррире була. "Бар көчен, сәләтен һәм белемен татар халкына хезмәт итүгә багышлаган "Әлмәт таңнары" газетасында эшләгән шау-шулы елларымны гомеремнең иң бәхетле, иң мәгънәле һәм иң бәрәкәтле чоры дип саныйм",—дип яза Әсгать Сәлах "Бараҗ токымы" ("Матбугат нәшрияты", Казан, 2003 ел) исемле китабында.*

*Әдәби иҗат белән ныклап торып шөгыльләнә башлавы да шул елларга туры килә. Газетада бер-бер артлы хикәяләре, әдәби очерклары дөнья күрә. 1997 елда "Мирас" журналында "Аккан сулар" дигән хатирә-повесте басылып чыга. Аннан соң язучы иҗатына татар әдәбиятының төп журналы "Казан утлары" да игътибар итә: бу мәртәбәле басма аның "Балыкчы малайлар" хикәясен (1998, № 11), "Соңгы вальс" (2002, № 10), "Каеннар юлы" (2003, № 6) повестьларын киң катлам укучыларга ирештерә. Соңрак алар төрле нәшриятларда китап булып дөнья күрделәр. Язучы буларак танылуны Әсгать Сәлахка нәкъ әнә шул әсәрләр алып килде дә инде. 2001 елда ул Татарстан Язучылар берлегенә кабул ителде.*

*Быелның гыйнварында каләмдәшебез Әсгать ага Сәлахка 70 яшь тулды. Без, хөрмәтле укучылар, сезгә әдипнең "Көт мине" исемле яңа повестен тәкъдим итәбез, аңа ныклы сәламәтлек, яңадан-яңа иҗат уңышлары телибез.*



## Әсгать Сәлах

# КӨТ СИН МИНЕ...

ПОВЕСТЬ

*Ике дә генә җирән, ай, бер көрән,*
*Әйдәп алып булмый юл белән;*
*Маңгаеңа язган хак язмышын*
*Җуеп кына алып булмый кул белән...*

Халык җыры.

## КОШЛАРДА ДА КЕШЕ ЯЗМЫШЛАРЫ

*Кереш сүз өчен*

Кешеләр нигә йорт сала? Аларга торыр урын кирәк, шунда яшәр өчен йорт сала, диярсез сез һәм хаклы булырсыз. Ә мин: аларга тәрәзә кирәк, шуңа йорт җиткерәләр, дияр идем. Тәрәзә!.. Тәрәзәләр ачылып китә дә, өйгә ашкынып талгын яз исе керә башлый. Аһ, шул язгы хуш ис! Тулышып аккан инеш тирәли котырып үскән зирек һәм тал-тирәкләр, су буен камап алган шаулы камыш дәрьясы, яр астында эреп бетмәгән кар, инеш суы, зәңгәр томан, туган якларын сагынып кайтучы киек казлар тавышын моңлы да, яңгыравыклы да иткән саф һава—аларның барысы да бай, тәмле, кабатланмас яз исен тудыра. Тормыш яме, яшәү дәрте, илһам, рух күтәренкелеге, күңелләрне канатландыра торган яз исе...

Иркен әрәмә өстеннән җилдә җилпенеп кәрваннар үтә: "Тор-рыйк, тор-рыйк!"

Һаваларда торна тавышлары,
Чит җирләрдән кайтып барышлары...

Камышлыкта үрдәкләр аваз сала: "Нарт, нарт, нарт..."

Зәңгәр күктә, кайдадыр өстә, тургай ярсып сайрый. Үзе күзгә күренми, ә җыры тирә-якны моңга сала.

Зирек агачлары башында тупый-тупый ала карга оялары: "Кар-р, кар-р...". Таныш аваз, тик бүген аларда да язгы аһәң бар сыман.

Ояларына беркеткән тал чыбыгында дәртләнеп, канатларын җилпи-җилпи

сыерчыклар сайрый. Алар быел да сагынышып кайтып кундылар туган ояларына. Әнә, ишетәсезме, тәрәзәдән сыерчык сайравы ишетелә? Әйе, тәрәзәләр дөнья матурлыгын күрер өчен генә түгел, кошлар сайравын ишетер өчен дә кирәк.

Бер сыерчык оясы минем тәрәзәм каршында гына. Кошлар кайту белән, челтәр элгән тәрәзә аша шул ояда барган тормышны күзәтәм. Анда гаҗәпкә калырлык хәлләр белән танышырга була...

Пар сыерчык, кайтып төшү белән, ояны карап чыкты. Эченә кереп-кереп тә, арткы ягын да, ян-яннарын да карап-тикшереп чыктылар. Тал чыбыкка кунып сайрыйлар да, тагын ояны тикшереп чыгалар, ә кичен шунда кереп, тынычлап куна калдылар. Иртән иртүк берсе тал чыбыгында сайрап утыра, ә икенчесе оя тишегеннән башын тыгып, парының аңа атап башкарган ариясен тыңлый. Ул тишек алар өчен бер үк вакытта ишек тә, тәрәзә дә. Тәрәзә! Әле кошларга да тәрәзә кирәк икән бит...

Аннары кошлар өй-ояны җиһазландырырга керештеләр—ашыгып-ашыгып корыган үлән сабаклары, кош-корт мамыгы ташый башладылар. Икесе дә бик уңган икән, җан-фәрманга эшлиләр дә эшлиләр. Эшлиләр дә канатларын җилпи-җилпи тагын сайрап алалар. Исән-имин кайтып житү шатлыгыннан, дөньяның ямьлелегеннән, тормыш матурлыгыннан, яшәү бәхетеннән оста итеп, бирелеп җырлыйлар алар.

Әнә шулай тыныч кына җырлы-моңлы берничә көн үтте. Сайрар кошкайларымның тормышы җайланды дип, мин дә иркен сулап куйдым. Тик...

Бер көнне оя өстендәге тал чыбыгында бер генә сыерчыгым утыра. Сайрамый да, талпынмый-җилпенми дә, бөтенләй пошаманга калган, боек. Үзе әле бер, әле икенче ягына карап-карап ала—парын көтә. Инде эңгер төшә башлады. Сыерчыклар, гадәттә, басу-болыннардан шуннан да соңга калмый кайталар ояларына. Ә моның пары һаман юк. Ботактагы сыерчык кына түгел, инде үзем дә борчыла башладым: нишләп кайтмый?

Икәүләшеп караңгыга хәтле көттек, ә кошчыгымның пары кайтмады. Ул иртән дә, көндез дә, икенче кичне дә күренмәде. Башта кошкаем берничә тапкыр болынга барып кайтты—анда эзләде булса кирәк, аннары оя өстендә зарыгып көтте тагын, тик пары барыбер күренмәде. Ниһаять, мин сыерчыккаемның кайдадыр, без белмәгән җирдә харап булуына төшендем. Шулай ук явыз карчыга тырнагына эләгепләр харап булды микәнни сайрар кошым?

Ә оядагы ялгыз сыерчык зарыгып көтүен дәвам итте. Озак көтте ул. Көтте, көтте дә, пары кайтмагач, ояны ташлап, очып китте.

Кадерле укучым! Мин сиңа тәкъдим иткән әсәрдәге вакыйгалар да әлеге мизгелне исегезгә төшерер. Кошларда да кеше язмышлары... Әсәрдә дә олы сабырлык, зур түземлек, зар-интизар булып озак еллар буе бер-берсен көткән авылдашларым язмышы.

*Автор*

Аппакай Вәлинең юлга чыгып китүен хатыны Зөләйха күптән көтә иде. Ниһаять, андый көннең дә килеп җитәсе бар икән. Сигезенче Март, Хатын-кызлар бәйрәме дип тормадылар, авылның еллар буе юл йөрүдә сыналган уңган-булган йөкчеләрен, шул исәптән Вәлине дә, сельпо товарларын алып кайтырга дип, Бөгелмәгә чыгарып җибәрделәр. Зөләйха моңа эчтән генә кинәнеп, җиңел сулап куйды, чөнки күрше-күләннең, җитеп килсәләр дә, башлы-күзле булырга өлгермәгән чая кызлары аны күптән аулак өй үткәрергә кыстап йөриләр. Әле биш-алты ел гына элек үзе дә шул кызлар кебек ашкынып-талпынып, качып-посып аулак өйләргә йөргән гүзәл Зөләйха, җае чыкса, үзенә һич тынгылык бирмәгән кызларның теләген үтәргә уйлап йөри иде. Юк, беркатлы, саф күңелле, тугрылыклы ир хатыны серен яшереп тормады, аулак өй җыярга иренең фатихасын алып калды.

—И-и, атасы, кызларның бездә бик җыелышып утырасылары килә. Өегез зур, җылы, якты, Вәли абзый да, син үзең дә. Зөләйха апа, киң күңелле кешеләр, бер генә кич утырыйк инде, дип өзгәләнәләр,—диде сүзгә оста Зөләйха, салпы якка бераз салам кыстырып. Вәли бу сүзләрне болай да олы күзләрен тагын да зурайтып тыңлап торды. Карап торуга кыяфәте усал кешенекенә охшаса да, Вәли җайлы, күндәм, хәт-

та юаш та иде. Майлап-жайлап, оста сүзе белән юмалап, ирен авызына гына каратып тоткан Зөләйханың теләгенә Вәли каршы киләмени инде? Авылда бер чибәр Зөләйханы яратып алды бит ул...

—Ярар, анысын үзең кара! Тик ул-бу булырлык булмасын,—диде дә Вәли, атына дилбегәсен селтәп капкадан чыгып китте.

Кич җитүгә Вәлинең гүнича кебек зур һәм яна ызбасында гөлт итеп пыяла куыклы унлы лампа кабынды. Ул арада берәм-берәм кызлар да җыела башлады. Бу—авылда чибәрлеге, көе-моңы, сүзгә осталыгы, тәртибе, итагатьлелеге белән танылган, абруйлы кызлар иде. Алар арасында иң гүзәле, күз өстендә каш—түгәрәк көләч йөзле, Борһан күлендәге камыш сабагы кебек зифа буйлы, нечкә билле, үзенә әле уналты гына яшь булса да, алсу алма кебек өлгергән Палта Нурислам абзый кызы Миңнур да бар иде. Кызның өстендә әле бик күп кызларның төшенә дә кермәгән сигез балитәкле кара сатин күлмәк. Изүдә ияк астыннан алып балитәккә чаклы тигез итеп берсе икенчесенә янәшә кадалган өч дистәләп энҗедәй ак сәдәф. Кызның сылу гәүдәсенә сыланып тора затлы күлмәк. Ике калын толымга үреп салган кара чәч, зөбәрҗәт кебек зәңгәрсу күзләр... Юк, Палта Миңнуры гына димәссең! Авылда гына туып-үссә дә, борынгы Болгар гүзәлләреннән һич кенә дә калышырлыгы юк. Берсеннән икенчесе чибәррәк күрше кызлары Нурия, Зөһрә, Миңнурның җансөяр ахирәте Суфия, җанйөрәк ахирәте Фатыйма, тагын әллә кемнәр арасында Миңнур исә аерым бер гүзәл зат, чын мәхәббәт алиһәсе иде.

Авылда тире җыеп, вак товар сату белән шөгыльләнгән Палта Нурислам абзыйның икенче кызы Миңнур кинәттән генә үсеп китте, кинәттән генә җиткән кызлар арасына керерлек булды, чөнки кыз күбрәк атасына охшаган—эре сөякле иде. Нурислам абзый исә авылда бер таза гәүдәле кеше. Баһаветдин картның икенче хатыныннан алтынчы, үзенең исә уникенче баласы булып туды Нурислам. Тик атасы канаты астында озак үсәргә вакыт тимәде—Баһаветдин карт, сиксән яшен тутырып, якты дөнья белән хушлашканда иң кече улына унбер генә яшь иде әле. Ләкин берсеннән-берсе әрсез, эшчән, булдыклы олы ир туганнары яраткан энеләренә югалып калырга бирмәделәр, эшкә, көн күрергә, дөнья көтәргә өйрәттеләр—бергә-бергә җир эшкәрттеләр, иген иктеләр, урман кистеләр. Хәтта аларның "Палта" кушаматлары да әнә шул урман кисү белән бәйләнгән иде. Алты туган, көн буе урман кисеп, кайтыр юлга чыкканнар. Ашыгулык белән Җамалетдин балтасын онытып калдырган.

—Ул палта имән төбендә калды,—дигән Җәләлетдин шунда, әллә ничек теле бәйләнеп. Әнә шул сүз җор телле мишәр дөньясында аларның кушаматына әйләнгән.

Нурислам туганнары канаты астында эшчән, тырыш, һиммәтле ир-егет булып житә. Малын да таба, тормышын да әйбәт кенә көйләп җибәрә. Хатыны Фәрхинур да бик уңган, ул аңа бер-бер артлы сигез бала табып бирә, тик биш баланың гомере бәләкәй чакта ук өзелә, аларын саклап кала алмыйлар. Нурислам:

—Син, аналары, булдыра алсаң, тап инде балаларны. Икесенең берсе үлсә, берсе кала, ялгызның егылып үлсә кеме кала?—ди.

Шөкер, өч кыз исән-имин үсәләр. Нурислам аларны үлеп ярата, иркәли, назлый, бөтен игътибарын аларны тәрбияләп үстерүгә бирә. Авыл кызларының күбесе киндер күлмәк киеп үскәндә, Палта Нурислам кызлары затлы киемнәрдән генә—ефәк, атлас һәм сатиннан гына йөриләр. Киемнәрне исә Миңнур тегә. Бу сәләтле бала тугыз яшьтән үк тегү һөнәренә өйрәнә. Кыз кеше бит—аның кемнәндер күреп яңа тегелештәге, яңа модадагы киемнәрне дә тегәсе, киясе килә. Бервакыт ул анасыннан сорап-нитеп тормыйча гына аның калын шәлен кискәләп, үзенә итәк тегә. Базарга килеп йөри торган маржалардан күреп калган була ул итәкне. Фәрхинур абыстай әрняңа калын шәлен бозган кызын ду-у китереп йорт әйләнә куып йөри, ә тегесе тоттырмый, кача. Кисәү агачы тоткан хатыны артыннан: "Тимә кызыма, тимә кызыма!"—дип Нурислам абзый үзе тырыклый.

Утызынчы еллар уртасында авылга Чулман арьягыннан Хәмзә исемле урта яшьтәге бер тегүче абзый килеп йөри. Нурислам аңа вакытлыча өенең бер почмагын бушатып бирә. "Зингер" дигән аяклы тегү машинасында бу агай тирә-юнь авыллары кешеләренә бишмәтләр, пальтолар, туннар, толыплар тегеп бирә. Елы-елы белән ул берничә ай торып эшли. Ләкин бер елны Хәмзә, нигәдер, эшен кыска тота, китәргә ашыга.

—Нурислам, бу—соңгы килүем, башкача сезнең якларга килеп чыгалмам ахры. Тегү машинасын, теләсәгез, кызыңа калдырам,—ди ул. Бу сүзгә уникенче яше белән

барган Миңнурның шатлыгы эченә сыймый. Тегүче юлга чыгып китү белән ул машина артына утыра һәм, күп тә үтми, үсмер кыз авылда бер оста тегүчегә әверелә.

Бүген аулак өйгә киеп килгән сигез балитәкле, төнге күктәге Киек каз юлы кебек изү буйлап сузылып киткән ап-ак сәдәфле кара сатин күлмәкне дә үзе тегеп кигән иде Миңнур.

Аулак өйгә кызларның барысы да кул эше белән килгәннәр. Зөһрә белән Нурия кульяулык чигә, Суфия пирчәткә бәйли, Фатыйма йон эрли, Миңнур исә бәләкәй күрше кызына тегәсе күлмәкне чүпчеп утыра.

Үз шөгыльләре белән артык мавыкмыйча, тыныч күңел белән, бер-берсенә игътибарлы-дустанә караш ташлаштырып, кызлар башта үзләренең көндәлек хәлләре белән уртаклаштылар. Аннары, җыр остасы Нурия, һич кыстатмый, тыйнак, басынкы тавыш белән җыр сузып җибәрде:

Җырлыйк әле, җырлыйк әле,
Җыр күңелне ача ул,
Җырлау күңелне ача ул,
Кайгыларны баса ул.

Җырның ахырына, дәртләнеп китеп, башка кызлар да кушылды. Әнә шулай аулак өйгә җыр белән бергә моң сибелде, кызларның күңел яктылыгыннан унлы лампа уты да яктыра төшкән кебек булды һәм әлеге садәлектән өйдәгеләрнең барысы да ямьле, рәхәт минутлар кичерде.

Шулчак тын урамда, март киченең талгын һавасында тальян гармун тавышы яңгырады. Кызлар җанланып китеп, елмаешып куйдылар: "Егетләр килә"... Миңнур гына сабырлыгын җуймады, елмаймады, гәрчә дикъкать белән караган кеше аның йөзе кызарып киткәнен абайламый калмаган булыр иде. "Минәхмәт!"—дип уйлады кыз. Сыйныфташы Минәхмәтнең тальянда уйнавын ун гармунчы арасыннан да таный ул. Болай оста һәм моңлы итеп авылда Минәхмәт кенә уйный ала торгандыр. Оста гармунчы булуы белән биләде дә инде егет Миңнурның күңелен. Югыйсә үзе какча гына гәүдәле, төскә-биткә дә кызлар һуштан язарлык түгел. Тик сүзгә, җырга оста. Киң күңелле, йомшак бәгырьле егет. Мәктәптә бергә укып йөргән еллардан ук белешәләр алар бер-берсен. Җидееллыкны тәмамлагач, Миңнур да, Минәхмәт тә Лашман авылына, районда берданбер татар урта мәктәбенә укырга китәргә уйлаганнар иде. Нурислам абзый да каршы түгел иде уртанчы кызының укуын дәвам иттерүенә. Тик Фәрхинур, олы кызы Мәдинурны Нәсип башкисәре Хәбибуллага олактыргач, Миңнурны укырга чыгарып җибәрәсе килмәде, кул арасына керер кешем калмый дип, каршы төште.

Мәдинуры турында "олактыргач" диmi ни диясең инде. Ул кыз артык дәртле булып үсте, аңа иртә ис керде. Чибәрлеге, килеш-килбәте дә булгангамы, егетләр дә тиз күреп алдылар үзен. Тик Нәсип Хәбибулласы, ярпач, җиңел-җилбәзәк егет кисәге , барыннан да алда өлгерде: барысыннан да алда кызның ышанычына керде... Һи, булды инде хәлләр. Ярый әле койрыгын чәнчеп чапкан кырыкмыш тайга үз вакытында камыт кигертә алдылар, ату адәм көлкесенә каласылары иде барысы да.

Миңнур укырга китмәгәч, Зиннәт малае Минәхмәт тә авылда калды. Ярата, бик ярата иде ул Миңнурны. Миңнурның үзенең дә йөрәге күптән инде: "Минәхмәт, Минәхмәт",—дип тибә. Бу турыда, һичшиксез, аулак өйдәгеләрнең дә күбесе белә иде инде...

Миңнурга хәзер ишектән гармунын тотып Минәхмәт килеп керер сыман тоелды, сабырсызланып ул шуны көтте. Менә ишегалдында аяк тавышлары...

Ни гаҗәп, ишектә башта хәрби киемле кеше күренде. Әстәгъфирулла! Бу бит әле ике-өч кенә көн элек армия хезмәтен тутырып кайткан Мифтах. Аннан соң гына өйгә муенына ике башы чуклы озын ефәк шарфын ураган Минәхмәт, аның яшьтәш дуслары Голүм белән Рәхимҗан килеп керде. Егетләрне шау килеп каршы алдылар. Игътибар үзәгендә хәрби киемдәге Мифтах иде. Аның армиядән кайтуы, өйләнергә кыз эзләве турындагы хәбәр авылга көне белән таралган һәм аны Миңнур да ишеткән иде инде. Урта буйлы, киң җилкәле, төп кебек таза Мифтах егетләр арасында иң чибәре дә иде бугай. Түгәрәк кара-туткыл йөзле, коңгырт күзле, дулкынланып, күпереп торган кара чәчле. Үз вакытында кияүгә чыгып калырга хыялланган кызлар өчен менә дигән егет! Тик Миңнур өчен түгел. Кияүгә чыгарга аңа әле иртә. Инде ул ва-

кыт җитә икән, аның, әнә, күзләгәне—Минәхмәте бар. Ана Минәхмәттән башка кеше кирәкми...

Ләкин аулак өйгә килеп керү белән унҗиде яшьлек Минәхмәтнең генә түгел, егерме өч яшендәге Мифтахның да күзләре кара сатин күлмәкле, зәбәрҗәт кебек зәңгәрсу күзләрен аска төбәп, тын гына эшләп утыручы яшь кызга төште. Аңа сәке кырыеннан урын күрсәткәч тә, күзләрен кыздан алалмый торды. Ул Вәли абзыйның Бәркәтәдән утырмага килгән кыз туганы Мөгаззәмә апа янына барып утырды һәм аның колагына:

—Бу нинди асыл кош соң әле, кем кызы?—дип пышылдап кына Миңнурга ымлады.

—Әйтәсең бармы: бигрәк матур шул, бу яшемә житеп мондый да сылу кызны күргәнем юк иде әле үземнең дә. Уңганлыгына да исең-акылың китәр, кулыннан килмәгән эше юк. Палта Нурислам абзыйның икенче кызы, Миңнур бит инде, танымыйсыңмы әллә?—диде Мөгаззәмә апа, шулай ук пышылдап.

—Шулаймыни? Танырга бит... Мин киткәндә... Менә сиңа гомерләр... Булды бу алайса. Менә кемне каптырырга кирәк миңа,—диде Мифтах, ниһаять, фикерен очлап.

Чыннан да, гүзәлләрнең гүзәле Миңнурны күрү белән Мифтах тынгылыгын җуйды. Кай арада үсеп житкән диң син аны? Һәм ул кич буе, кызлар түгәрәкләнеп әйләнгәндә дә, йөзек салышкан, табышмак әйтешкән, җырлап кына утырганда да Миңнурдан күзен алмады. Ләкин кыз үзе Мифтахка күтәрелеп тә карамады. Аның каравы тальян гармун тартып утырган Минәхмәткә еш ташлады ул серле күзләрен. Шул карашлары белән егетенә нәрсәдер аңлатасы килгән иде аның, ә тегесе аңлап житкермәде бугай, әллә инде хәтәр киләсен жаны сизмәде.

Шунысы гаҗәп булды: күзе төшсә дә, армиядә хезмәт итеп, буын ныгытып, буй үстереп, кыюланып кайткан егет кызга, нигәдер, ым ясамады. Югыйсә, житди нияте булган егеткә кыз белән очрашып сөйләшү кирәк иде. Миңнурга: «Юк, Мифтах абзый, өметеңне сузма, минем күзләгән, жаным тарткан егетем бар»,—дип әйтер өчен кирәк иде бу сөйләшү. Ә Мифтах, кичәнең башыннан ахырына кадәр Миңнурга текәлеп, аның белән сокланып-сихерләнеп утырды да, мыштым гына өенә кайтып китте. Миңнур исә: «Баладән башаяк»,—дип калды. Әмма тынычлана алмады.

—Ай, кызый, Мифтахның сиңа күзе төште бит. Бу кызны каптырырга кирәк миңа ди, билләһи менә, — Мөгаззәмә таралышыр алдыннан шулай диюгә, Миңнур коелып та төште...

Аны капка төпләренә чаклы Минәхмәт озатты. Кыз да уйга баткан, егетнең дә кәефе китек иде.

—Мифтах абзый ач козгын кебек гел синнән күзен алмады,—диде Минәхмәт, көрсенеп.

—Күрдеңмени?

—Күрмичә...

—Ә мин сине бернәрсә дә күрмисең, сизмисең дип торам,—диде Миңнур бераз үпкәле тавыш белән.

—Мин сине беркемгә дә бирмим, белеп тор! Иртә исемдә, кич төшемдә син минем.

—Әллә мине кемгә дә булса китәр, дип уйлыйсыңмы?

—Уйламыйм да бит...

—Уйлама да!—диде Миңнур һәм җиңелчә генә Минәхмәткә сыенды.

Алар шулай бер-берсен тынычландырырга, юатырга тырыштылар. Әмма икесенең дә күңелендә шом калды.

Һәм бу шомлану нигезсез булмаган икән. Икенче көнне төш житәрәк Палталарга Кыр капка Хәертдине килеп керде. Аның килүенә болай артык гаҗәпләнәсе дә юк иде кебек. Нурислам абзый белән Хәйринең яшь аралары шактый булса да, бер-берсеннән ерак яшәмәгән бу ике эшлекле ирнең уртак мәнфәгатьләре житәрлек, боткалары пешә: алыш-биреш итешеп, мал суешып, булышып, дус яшиләр алар.

Ләкин Хәйринең бу килүендә Миңнур хәвеф сизде: Мифтахның терәлеп торган күршесе ләбаса... Хак, шулай икән бит: башкода булып, кызның башын ашарга килгән икән бит ул.

Башта Хәйри серен Нурислам белән Фәрхинурга гына чиште. Миңнур бу вакытта

алгы бүлмәдә тегү белән мәшгуль иде. Аннары сүзгә аның үзен дә чакырдылар.

—Менә, кызым, Хәертдин абзаң сине Мифтахка сорап килгән. Барыбыз бергә киңәшләштек тә, Ходайга тапшырып, сине бирербез, дидек...

—Сарык бәрәнен сатып җибәргән кебекме?—диде Миңнур атасын ярты сүздә бүлеп. Моңа чаклы аның атасы белән болай хөрмәтсез сөйләшкәне юк иде. Ә бу юлы түзмәде. Ата-ана сүзеннән чыкмыйча, гел аларның сүзен тыңлап, баш иеп яшәгән кыздан Нурислам белән Фәрхинур да аның болай әйтерен көтмәгәннәр иде.

—Мине шул Мифтахка кияүгә бирер өчен үстердегезмени?—дип дәвам итте Миңнур.—Үзегез яхшылап уйлап карадыгызмы соң? Мин бит аны рәтләп белмим дә. Ул да белми. Безнең аның белән бер-беребезгә сүз дә катканыбыз юк. Кияүгә, белгәнемчә, яраткан, һич югында яхшылап холык-фигылен, тормышын, көнкүрешен белгән кешегә бирәләр кебек. Юк, мин сезгә сарык бәрәне түгел бау белән бәйләп җибәргергә, ә адәм баласы—үз акылым, үз фикерем, үз сүзем, теләгем бар...

Кызның кинәт күңеле тулып китте һәм ул еларга тотынды. Бу хәлдә сүзне дәвам итү файдасыз булганын барысы да аңлады. Нурислам ахирәтенә ым ясап, аны ишегалдына алып чыкты:

—Тынычлансын инде. Әллә ничек килеп чыкты әле. Сүзне иртәгә дәвам итәрбез. Күнәр, кая китсен,—диде.

—Син, Нурислам абзый, күндер инде аны. Булачак кияү—дастуйный парин. Армиясен үткән, кулыннан эш килә, уңган, булдыклы. Сиңа, малайсыз кешегә, бүгеннән үк настаяшшый памушник булыр,—диде башкода. Малай чактан бәхет эзләргә Урал якларына китеп, урыс арасында шомарган Хәйри сүзгә кеше кесәсенә керүчеләрдән түгел. Нурисламның авырткан җирен белә: улларың юк, булышчың, терәгең булыр кияү-балакай карт көнеңдә...

* * *

Мәсләх Мифтахының Палталарга башкода җибәрүе турындагы хәбәр авылга яшен тизлеге белән таралды. Ул Минәхмәтләргә дә тиз килеп җитте: башкода китү белән Миңнур аларга күрше кызын җибәргән иде: «Бар, сеңлем, Әхмәт абыеңа: Мифтах абзый Миңнур апаны сорап башкода җибәргән, диң. Калганын үзе аңлар»...

Кызның сүзләре Минәхмәтнең йөрәген ярып үткәндәй булды. Башта ул хәтта югалып ук калды. Тик тиз айныды.

—Мин Миңнурны беркемгә дә бирмим, ул—минеке,—диде ул анасы Маһиҗамал абыстайга хәлне ачып. Маһиҗамал абыстай да бу хәбәргә аптырап китте. Миңнурны ул күптән белә, күз алдында үскән бер үк урам кызы ич. Алай гына да түгел. Үзенең кул арасына керердәй кызлары булмагач, шул урам кызлары Суфия, Фатыйма һәм Миңнурны еш кына ызба юарга чакыра ул. Бу уңган кызлар бүрәнәләрне, идәннәрне кыргыч белән кыра-кыра юып чыкканнан соң өй эче яктырып, ямьләнеп кала. Юмарт куллы Маһиҗамал абыстай игелекле кызлар өчен итле бәлешен дә сала, пилмәнен дә пешерә, коймагын да коя, йомыркасын да куыра, чәен дә баллап эчертә. Матурлыгы да, уңганлыгы да, акылы да ярылып яткан Миңнурны исә ул бигрәк тә ярата, аның белән Минәхмәте арасында кабынган хискә куана, киләчәккә күркәм өметләр баглый—бу сылу кызда үзенең беренче киленен, булышчысын, киңәшчесен күрә иде.

Җиткән улының аяныч хәлен яхшы аңлаган ана алгы бүлмәгә, ире Зиннәт янына кереп китте.

Бер карашка бик кырыс холыклы булып күренгән Зиннәт абзый авылдашлары арасында олы язмышлы, абруйлы кеше иде. Үз чоры өчен укымышлы, алдынгы карашлы егет башта туган авылында, аннары тирә-юньдә совет власте урнаштырып, соңыннан Себер якларында Кызыл Армия сафында Колчакка каршы сугышып йөргән, җәрәхәтләр алган, бер күзсез калган. Гражданнар сугышыннан соң Казанга кайтып, төрле хуҗалык тармакларында зур җитәкче булып эшләгән. Дәҗҗал Сталинның кара репрессия елларында партия, совет, хуҗалык җитәкчеләрен бер гаепсезгә берәмберәм алып китеп ата, төрмә-лагерьларга олактыра башлагач, акыл белән яшәгән Зиннәт бер төн эчендә гаиләсен алып, Казанны ташлап Норлатка китә. Ләкин анда да озак туктамый, бәладән башаяк—урынын югалта, тавыш-тынсыз гына туган авылына кайтып төшә. «Мин пенсиядәге кеше, сәламәтлегем начар»,—дип, бар яхшы тәкъдимнәрдән ваз кичеп, гаиләсе белән тыныч кына яши башлый ул.

Хатынының кайнарланып, хәвефләнеп сөйләгәнен ул укый торган газетасыннан аерылмый гына тыңлады һәм килеп туган мәсьәләне ике сүз белән хәл итте:

—Әнә, Габделкадыйр картны башкода итеп җибәр!..

* * *

Тырыш хезмәт, дин-иман, төпле акыл белән тормыш иткән, авыл картлары арасында абруй казанган Габделкадыйр карт, өйләнергә җыенган ир-егетләр үтенече буенча еш кына алар күзләгән кыз-кыркын йортына башкода, яучы-димче булып та йөри иде. Ыспай гына киенеп, ничек сөйләшергә кирәклеген алдан ук уйлап, үз дәрәҗәсен белеп, шулай ук Палта Нурисламның да авылда кем икәнлеген истә тотып, итагать белән ишек шакып барып керде. Аны Фәрхинур үзе генә каршы алды—Нурислам, һәрвакыттагыча, үз эше белән чыгып киткән иде. Башта утырып дога кылдылар. Өч кыз үстергән, берсен инде кияүгә дә биргән, бу эштә азмы-күпме тәҗрибәгә дә тиенгән Фәрхинур чамалады: Габделкадыйр карт тикмәгә генә йөрмәс. Ләкин аны ашыктырмады, үзенең сүз башлавын көтте.

—Фәрхинур кызым, мин бит әле бик зур гозер белән килдем үзегезгә,—дип башлады Габделкадыйр карт, пөхтә, түгәрәк сакалын сыпырып.—Бик җаваплы гозер. Күршем Зиннәтулланың улы Миннәхмәтне беләсез, авылга бер оста гармунчы. Бик акыллы, ир җиткән, булган егет. Сезнең Миңнурны да бик яхшы беләм: сокланып туймаслык кыз. Андый да гүзәл затны үстергәнегез, тәрбия кылганыгыз өчен Ходай үзегезгә мең-мең игелек кылсын! Инде, Фәрхинур кызым, тел төбемне аңлагансыңдыр. Кыз да, егет тә бүген бер-берсе турында уйлап яшиләр. Мин уларының теләге белән күршем Зиннәтулла, аның хәләл җефете Маһиҗамал исеменнән башкода булып килдем. Белүемчә, кызың Миңнур да моңа риза. Аллага тапшырыйкмы әллә? Кавыштырыйк ике яшь йөрәкне, пар күгәрчен булып яшәрләр, иншалла. Уңай җавабыгызны көтәм,—диде һәм тынып калды. Фәрхинур: "Бу картка ничек итеп әйтергә инде?",—дип бераз уйланып утырды. Ләкин югалып кала торган хатыннардан түгел иде ул, җавапны тиз тапты:

—Габделкадыйр абзый! Син инде безгә бер башкода килеп киткәнен беләсең. Әле аңа да сүзебезне кистереп кенә әйтмәдек, уйланабыз. Шуны гына искәртәм: Нурислам Миңнурыбызны Мифтахка бирербез, диде. Олы башыңны кече итеп килгәнеңә рәхмәт. Нурислам кайткач та тагын бер кат уртага салып сөйләшербез. Тик, үзең беләсең, мин—ир хатыны. Ир хакы бар, ир ничек әйтсә, шулай булыр.

—Шулай да, кызым, тагын бер кат яхшылап уйлагыз әле. Балаларның бер-берсенә тартылуы, яратышулары турында да онытмагыз. Миңнурыгыз да Миннәхмәтне үз итә икән. Егет ярамаслык түгел бит. Мифтахка бирсәгез, аның белән кызыгызның ярмасы бүртерме соң? Әйе, яхшылап уйлагыз! Ашыкмый-кабаланмый. Ашыккан ашка пешкән, диләр бит...

—Ярар, уйларбыз, Габделкадыйр абзый,—дип, Фәрхинур сабырлык белән озатып калды башкоданы. Ләкин ул чыгып китү белән:

—Мин сукыр Зиннәт Мачугына ялчы үстермәдем,—диде ярсып. Бу вакытта Миңнур үзе дә өйдә иде.

—И-и, әни, бирегез инде мине Минәхмәткә. Гомерем буе рәхмәтемнән ташламам үзегезне. Яратам бит мин аны...,—диде дә, тагын елап җибәрде. Ләкин Фәрхинур кызының ялваруына колагының бер читен генә салды:

—Атаң Мифтахка бирәбез, диде...

Фәрхинур каттый иде.

Нурислам карт каядыр чыгып киткән иде, яңа башкода киткәч тә, кайтып керде.

—Кызым, ярату өчен, чыннан да, гармунчы кирәктер, ләкин тормыш итәр өчен булдыклы ир кирәк. Анысын, әнә, анаң яхшы белә,—диде ул Миңнурга. Бераздан тавышын йомшартты да, сүзен дәвам итте:

—Тыңла әле, кызым, син акыллы бала, үзең уйлап кара. Без дә бит сиңа начарлык теләмибез, булдыклы, акыллы ир белән яхшы, таза тормышта яшәсен, дибез.

—Белмим бит мин Мифтах абзыйны...

—Яши башлагач белерсең дә, яратырсың да. Без дә анаң белән яратышып өйләнешмәдек...

Күпне күргән, тормыш тәҗрибәсен хәтсез туплаган Палта Нурислам кызының киләчәге, бәхете турында бер генә төн уйламады, әлбәттә. Балачагы Казанда үткән, эшкә өйрәнеп үсмәгән, авылда яшәү рәтен белмәгән Зиннәт малаеннан ябәлә чык-

мас, атасы да, әнә, тавык та суйган кеше түгел...

* * *

Миннур, сызланып-моңланып, бүлмәсенә кереп китте. Тегәсе әйберләре җитәрлек булса да, эшкә тотынасы килмәде—күңеле төшкән, кәефе юк, һәрнәрсәгә дәрте сүнгән иде. Әллә ничек шунда элек кызлар белән җырлаган моңсу җырлар исенә төште дә, шуларны шыңшып алды:

Кызыл төлке—кыр күрке,
Кыз балакай—өй күрке;
Кыз бала ул бик бәхетсез,
Юк бит аның үз күрке.

Җитеннәр чәчтем тигезгә,
Алып китте диңгезгә;
Әткәй, бирәсез тиңсезгә,
Гомер елармын сезгә...

* * *

Миннурның Мифтахка чыгарга теләмәве, көн-төн борчылуы, елап чыгуы, ата-анасына ялваруы турында да халыкка ишетелә торды. Моңа Мифтахның абыйсы Имам да бик хафаланды. Әле үзе дә берничә ел элек кенә өйләнеп, яңабаштан тормыш башлаган бу зирәк акыллы, төпле ир энесенең сайлаганын хупламады, аның Миннурга өйләнү уеннан кире кайтуын сорады:

—Дөрес эшләмисең, энем. Кешегә дигәнне алма, уңмассың! Өйләнү—җаваплы, зур эш ул. Мондый вакыйга шатлык, бәхет белән өртелгән булырга тиеш. Ә монда күз яше... Кеше яше төшми калмый, белеп тор шуны!

Ләкин Мифтахның хәле абыйсының акыллы киңәшен тыңлаудан үткән, аның ташы кызган иде:

—Зиннәт малае гына түгел, мин дә бик яратам, миңа да бик ошый ул кыз. Вакыт үтәр, айныр. Гөрләтеп яшәп китәрбез әле менә...

—Мин үземнең эчемдәгене әйттем. Гөлсем белән без, үзең беләсең, Хәлил белән Галиябану кебек үк булмасак та, бер-беребезне аңлап өйләнештек. Кияү белән кыз арасында баштан ук аңлашу булырга тиеш. Юк икән, димәк, мондый тормыш баштан ук бәхетсезлеккә корылган дип сана...

Мифтах бераз уйланып утырды, ләкин барыбер үзенекен әйтте:

—Соң инде, абзый. Тегермәннең ташы җибәрелде, бөртек кенә саласы калды...

* * *

Габделкадыйр карт җылы хәбәр алып кайта алмагач, Минәхмәтнең өмете өзелде. Зур ызбаның бер бүлмәсенә бикләнеп, егет башта үксеп-үксеп елады, аннары гармунын алып моңлы-сагышлы җырлар җырлады, тик башка чара кыла алмады.

—Ярар, улым, бетеренмә әле, бу дөньяда Палта Миннуры гына димәгән, сиңа да насыйбы табылыр,—диде Маһиҗамал абыстай улын юатып, гәрчә үзе дә уңган-булган, акыллы, сылуларның сылуы Миннурның үзенең килене булуын бик теләсә дә.— Нишлисең бит, насыйп булмагач...

Ә бу кичне, Миннурның ирегең сындырып, аның ай-ваена карамыйча, кияүне бикәч янына, чыбылдыкка керттеләр. Шунда алар дүрт көн бергә булдылар. Дүрт көн буена сөймәс кешесе—булачак ире белән тарткалашып, кияү ирегенә буйсынырга теләмичә, җаны-тәне тартмыйча көн-төн үткәрде Миннур. Бишенче көнне кичке якта Мифтах өенә кайтып китте—аның арчига, туй төшерергә әзерләнәсе бар иде. Дүрт көн беркая да чыкмаган Миннур да, караңгы төшкәч, көянтә-чиләк алып, кизләүгә суга төшеп китте. Саф һава сулап, күңелен баскан авыр уйларны таратып, дөнья күреп кайтасы килде аның. Ашыкмыйча гына барды, ашыкмыйча гына чиләкләренә су алды, ашыкмыйча гына өенә таба атлады. Әллә ничек, Минәхмәтне күрәсе, аның белән сөйләшеп аласы килде аның. Күңеле гел аңа тартылды...

Йа Хода, бар икән могҗизаларың: үзләренең урамына борылган җирдә аны бер ялгызы Минәхмәт көтеп тора иде. Бу очрашудан алар икесе дә бик дулкынланып

киттеләр, сөйләшергә сүз таба алмый азапландылар. Вакыты да бик кыска бит аның. Карлар эреп барган апрель киче карангы булса да, кеше күрүе бар. Ишеттерсәләр, инде бикәчкә кергән кияү егете ни дияр?

Ләкин Минәхмәт бүген тәвәккәл иде. Ул, озын-озак уйламыйча, тальянын тартып җибәрде һәм җыр башлады:

Пәкеләремне бирмәдем
Лимон кисмәссен, диеп;
Исәпләмичә дә йөрдем,
Быел китмәссен, диеп.

Китәм дисең, китәм дисең,
Кемнәргә калдырасың?
Бәгърем, гыйшык утларында
Ник мине яндырасың?..

—Җибәр, Минәхмәт җаным, тоткарлама, яхшы түгел. Кеше күрсә, нишләрбез? Соң инде, барысы да соң,—диде Миннур һәм өзгәләнеп өенә таба атлады. Минәхмәт исә кайчандыр Миңнур бүләк итеп биргән чиккән кульяулыгы белән яшьле күзләрен сөртеп калды...

Шулай да, аның бүгенге тәвәккәллеге Миңнурны таң калдырды. «Элегрәк шулай батыр, бәйсез, тәвәккәл булсаң икән, Минәхмәт җаным! Өйгә килеп, кулымнан тотып алып киткән булсаң, сиңа ияреп дөнья читенә барырга да риза идем бит мин. Ә син югалып калдың, беренче сынауда ук җебеп төштең. Әнә, Мифтахны кара: нәсел үгезе кебек киртәләрне сындырып килеп керде. Аның кебек әрсез буласы иде сиңа да..."

Судан өенә кайтышлый Миңнурның башыннан әнә шундый уйлар үтте. Ләкин, сөйгән егетенә аз-маз үпкәсе булса да, аңа булган якты, саф хисләре дә таркалырга өлгермәгән, һаман шул көе саклана иде аның күңел түрендә.

* * *

Арчи май уртасында төште. Соңлап килгән, тартылган-сузылган салкын яздан, аның беренче яңгырларыннан соң авыл урамнары һаман кибеп, корып бетмәгән, арчи төшәр өчен бик үк уңай булмаган көн иде ул. Ләкин вакыты билгеләнгән—аны кичерү мөмкин түгел, моны китап та кушмый.

Язмыштан узмыш юк. Ихтыяры сындырылган Миңнур да, кеше арасында кимхур булмыйм дип, туйга, арчига кешечә әзерләнде.

Күз яшьләренә тыгылып җырлый-җырлый, алсу сатиннан ун балитәкле матур күлмәк, тагын нәрсәләрдер текте.

Биек-биек ызбада
Тегү тегә кыз бала;
Киләчәк көннәрне уйлап
Йөрәккәем сызлана.

Шушма елгасы суында
Биткәемне юдым мин;
Үзем былбыл, чәчем чылбыр—
Ник бәхетсез булдым мин?

Һич күрмәгән-белмәгән, яратмаган кешегә кияүгә чыгармын (дөресе—бирерләр!) дигән уй аның башына да килмидер иде. Тормышта әле аның монысы да була икән бит. Зөбәрҗәт кебек зәңгәрсу күзле, түгәрәк матур йөзле, Борһан күлендәге камыш сабагы кебек зифа буйлы, нечкә билле, үзенә уналты гына яшь булса да алсу алма кебек өлгергән кызның игътибарына лаек булырга тырышып караган егетләр авылда бер генә түгел иде бит югыйсә. Шуларның кайсыберишләре арасында Миңнурга ошардайлары да бар иде, бүген дә бар алар. Ә менә Минәхмәт...

"Ах, яраткан егетемә чыга алмадым"... Бу авыр уй аңа иртән дә, көн буе да, кичен дә тынгылык бирмәде.

Арчи ыгы-зыгысы берничә көнгә сузылды. Аннан соң елап-сыктап озатулар, кемнеңдер тальян шыңшытуы, тарантаска җигелгән бизәүле күк атларның көйсезләнеп тыпырчынуы, дугадагы җиз кыңгырауның хәсрәт тавышы белән туй төшү... Әйе, туй төшкәндә һич уйламаган, һичкем көтмәгән вакыйга булып алды. Арчилап килгән җигүле тарантаска кияү йортына кайтып җитәргә барлыгы илле-алтмыш адым калган иде. Сукыр Сәхап, Таз Нуркайлар йорты яныннан гына үтсә дә, уңга борылып Мифтах йорты турысына барып туктыйсы. Юк икән шул әле! Атларны салмак кына йөгертеп кайткан бер вакытны, әнә шул Сукыр Сәхаплар турысын үтеп барганда, кинәт тарантасның арткы уң як тәгәрмәче күчәреннән чыгып, бер якка тәгәрәп китте. Тарантас кыйшайды, анда утырып кайткан кияү белән кәләш, кияү егете һәм башкалар чак кына егылып төшми калдылар. Арчи кайтканын карап торган авыл халкы «аһ» итте:

—Әстәгъфирулла!

—И-и, Ходаем, ахыры гына хәерле булсын!..

—Күрәселәре бар икән әле мескенкәйләрнең...

Арчины озата килгән егетләр, арбадан сикереп төшеп, тәгәрмәчне күчәренә кую хәстәрен күрделәр. Кемдер:

—Моның чәкүшкәсе төшеп калган бит, чәкүшкә кирәк,—диде. Кайсыдыр чыбык кисәге табып китерде.

Миңнурның ансыз да телгәләнеп беткән йөрәген шом катыш курку алды: «Шулай ук ирексезләп кияүгә бирүләре хәерлегә булмас микәнни?»—дип көенде ул эчтән генә. Миңнур җыелган халык арасында шахтер башмаклары киеп басып торган Бүсер Хатыйп Минәхмәтенең: «Ах, парин, алманың асылын аю ашый. Ә кызы, кызы!.. Бигрәк җәл»,—дигән сүзләрен ишетеп алды. Ә Мифтах бу сүзләрне ишетмәмешкә салышып:

—Тизрәк маташыгыз, егетләр,—дип кычкырды. Шунда гына арчи теләр-теләмәс яңадан кузгалды.

Җыелган халык бу хәлгә борчылып, пошаманга калып, аны хәвеф-хәтәргә юрап таралды.

Туй төшкәндә күчәреннән чыккан тәгәрмәч вакыйгасы әле соңыннан да бик озак авыл кешеләре теленнән төшмәде, күңеленнән китмәде, шомландырып яшәтте.

* * *

Бер казанга ике тәкә башы сыймый. Дүртпочмаклы бәләкәй генә өйдә ике ир туган, ике килендәш, олы туганның ике баласы. Дөрес, Имам белән Мифтах, өем тар булса да күңелем киң дип, күз тимәсен, дус, аңлашып, ярдәмләшеп яшиләр. Начар гадәтләре юк. Авылда урыс аракысын яратып чөмерүчеләр арта бара, ә ике туган аның барлыгын да белмиләр. Тәмәке дә пыскытмыйлар. Тыныч холыклылар. Киләчәккә булган ниятләре дә изге. Иң тәүгесе—Мифтахка йорт җиткерү, аларның үз куышларын булдыру. Көннәр яхшырып, язгы кыр эшләре тәгәлләнгәч һәм Сабан туйлары узгач та, урманда диләнке алып, бер ызбалык бүрәнә әзерләргә һәм күзгә чаклы бураны бурап, такта ярып, башка хәзерлек эшләрен карап куярга. Өй салуның ние бар—бурыйсы да чүтләсы... Шаярып кына әйтелгән бу сүзләр артында тирән мәгънә ятканын һәркем белә: алда әле никадәр күп тырышлык, көч куясы, мал түгәсе, кәҗә мае чыгарасы бар ике туганның. Ләкин алар аңа артык пошынмыйлар: Ходай сәламәтлекне бирсен дә, дөньялар тыныч булсын. Мал табыла ул! Икесенең дә кендеге җиргә береккән, тырышлыклары җитәрлек. "Салырбыз. Авылда бер матур ызба салып куярбыз, энем, Алла теләсә. Кайгырма!—дип Имам бер генә әйтмәде инде Мифтахка, үзен дә, энесен дә дәртләндереп.—Быел өлгертеп булмас-булуын, аның өчен, үзең беләсең, көч кирәк. Ә менә киләсе елга өлгертергә мөмкин, моңа тырышып карарбыз"...

Әйе, ике туганның дуслыгына сокланып туймаслык. Моның сәбәбе дә бар. Аналары, Гыйльминур абыстай, вафаты алдыннан: улларым, бер-берегезне ташламагыз, дус, терәк булып, ярдәм итешеп яшәгез, кеше арасында ким-хур булмагыз—минем сезгә соңгы сүзем шул,—диде.

Гыйльминур абыстайның фаҗигасе балаларын һәм якыннарын гына түгел, барлык авыл халкын тетрәндерде. Иртә дөньясын ташлап киткән Мәсләхеннән тол калгач, үсеп килгән балаларның кайгыртучан аналары, киңәшче-уңашчы, авыр тормышның бер чабуыннан өстерәүче дә иде ул. Әле иллесен дә тутырмаган хатын гел эш белән мәшгуль, үз әүхәтендә.

Сентябрьнең ахырлары иде бугай, һәрхәлдә бакчадан бәрәңгеләрне алганнар иде. Мифтах төнлә генә Шонталыдан колхоз тракторлары өчен керосин алып кайтты. Тартып-йолкып яшәргә өйрәнгән Гыйльминур абыстайның да үз башына кайнашуы булгандыр—малае йоклап яткан арада тан тишеге белән чыгып арбадагы мичкәне ачты һәм ярты чиләк керосин агызды. Хәзер керосинны почмакта әзерләп куйган шешәләргә тутырасы гына калды. Өйгә кереп, почмакка үтте. Анда әле караңгы иде, жиделе лампаны кабызып жибәрде. Лампада да керосин беткән икән—тутырырга булды һәм шуның белән маташканда шешәсе авып китте дә, хатынның күлмәк чабуына да керосин эләкте һәм якын гына ягулык салырга дип кыйгайтып куйган лампы филтәсеннән күлмәккә гөлт итеп ут капты. Гыйльминур абыстай чыр-р итеп кычкырып жибәргән тавышка, озын юлдан соң изрәп йоклап яткан Мифтах, сикереп торды да, су дип уйлап чиләктәге керосинны анасының өстенә тондырды. Гыйльминур абыстай бер мизгелдә утлы факелга әйләнде һәм ачыргаланып тышка, аннан бакчага ташланды. Ә бу вакытта Мифтах дөрләп яна башлаган өйне сүндерә башлады.

Күрше Сәхап фермадан ат алып кайтканда, Гыйльминур абыстай үз бакчасы туфрагында ауный-ауный өстендәге утын сүндереп маташа иде.

—Йа Хода! Гыйльминур абыстай, нәрсә булды, нишләдең?—дип сорады ул ике бакча аша урамнан торып.—Ярдәм кирәк түгелме?

—Яндым, Сәхабетдин, яндым. Үз башыма тотындым шул красинга, үз башыма,—диде дә, янып телгәләнгән күлмәк калдыкларын сөйрәп, жирдә ауный-ауный туфракка батып, кара янып беткән хатын ыңгыраша-ыңгыраша өенә кереп китте.

Гыйльминур абыстай кичкә таба жан бирде. Икенче көнне аны бөтен авыл халкы жыелып соңгы юлга озатты.

Бу фажига ике туганга нык тәэсир итте. Анасының үлемендә Мифтах үзен гаепләде: әйе, ул чиләктәге керосинны анасы өстенә ташлады ла. Дөрес, су дип сипте. Ләкин...

—Мин, мин генә гаепле, кичер әни,—дип елады ул үлем түшәге өстендә яткан анасына.

—Юк, улым, син түгел, үзем гаепле, үзем. Синең мыскал да гаебең юк,—диде ул соңгы минутларында. Имам да Мифтахны тынычландырды: син гаепсез, синең урыныңда мин дә шулай эшләр идем, диде.

Аналары белән булган тирән фажигане кичерү аларны бер-берсенә тагын да якынайтты.

Ә менә ике килендәш арасында уртак тормышның башыннан ук киеренкелек туды. Яшь килен килеп кергән көнне үк туды ул киеренкелек. Миңнур урнашырга өлгермәде, Өммегөлсем килендәш, баш булып, төксе генә:

—Әпәй сал!—дип әмер бирде. Миңнур аптырап китте. Имәндә икән чикләвек—холыксыз икән бит өйдәш-килендәш. Аптырарсың да... Миңнурның, авыл кызы булса да, әле гомерендә дә ипи салганы юк иде, ул үзе дә анасы салган ипине генә ашап үсте. Нишләргә? Шөкер, кызның коелып төшә торган гадәте юк—бу яклап ул анасы кызы, зирәклеге дә бар. Тиз генә жыенды да, бакча аша гына анасы янына йөгерде.

—Миңа ипи салырга куштылар, әни, аны ничек салалар?—диде, килеп кергәч тә. Фәрхинурны бу хәл каушатып жибәрде: "Син дә үзеңне кызлар тәрбияләп үстергән ана итеп саныйсың инде, әпәй салырга да өйрәтмәгәч..."—дип эчтән генә үзен-үзе битәрләп алды.

—Соң, кызым, син бит авылда бер булган һөнәр иясе. Балачактан тегү эше белән хыялланагач, шуның белән шөгыльләнгәч, мин аш-су әзерләү, өй жыештыру, бакчада казыну, камыр пешерү кебек эшләр белән вакытыңны алмадым синең, тегә икән—тексен, дидем. Мин гаепле инде аңа.

—Әнкәем, кем гаепли сине? Син түгел, мин үзем гаепле. Иртәме-соңмы, андый нәрсәләргә өйрәнергә кирәк. Менә килдем—өйрәт, әле соң түгел, тормышымның башы гына...

Анасыннан өйрәнеп кайткач та, Миңнур камыр басты, кунасын пич башына куйды. Шөкер, ипи уңды, калачтан ким булмады. Тик бер генә кимчелеге беленде соңыннан—Миңнур аңа тоз салырга онытканн булып чыкты. Гөлсем бу вакыйгага аерым төсмер бирергә тырышты:

—Аня, уңган килененнең әпәен ашап кара,—дип, Имам каршына китереп куйды яна пичтән чыккан ипине.

Имам, кискән икмәкне сындырып, авызына капты, чәйни башлады һәм аның

тозсызлыгына төшенде.Мифтах та авыз итте, кызарып китте, ләкин эндәшмәде. Ә Имам эндәште. Хатынына эндәште:

—Бик ашыйсың килсә, тоз сибеп ашарсың,—диде катгый итеп. Аннары Миңнурга:

—Рәхмәт, килен, ундыргансың ипиеңне. Килендәшеңнән дә уздыргансың. Киләчәктә тоз салырга да онытмасаң, тәмле ипи ашаячакбыз икән әле, борчылма юкка,—диде. Каенагасының изге күңелле кеше булуы турында ул элек тә ишетеп белә иде, хәзер исә үзе моңа инанды.

Шулай да яшь киленгә сөймәс иргә, яңа гаиләгә ияләшү җиңел булмады. Озак вакыт ул никахлы иргә "Мифтах абзый" дип эндәшеп йөрде. Югыйсә, сирәк тә эндәшә ул аңа, ләкин барыбер: "Мифтах абзый, Мифтах абзый"... Мифтах исә моңсу гына, әмма мәгънәле итеп хатынына карап тора. Озак карап тора ул аңа, тик эндәшми, үзе бер аңлар әле, дип уйлый бугай. Өйдә алай әйтүенә күнеккәнсең инде, әле бит...

Бер көнне шулай Мифтах урамдагы бүрәнәләр өстендә күрше ир-атлары белән сөйләшеп утыра иде. Өйдә аш пешкән булган күрәмсең, яшь килен чыкты да:

—Мифтах абзый, ашарга кер,—дип эндәште. Мифтах күршеләре янында уңайсызланып, кызарып китте. "Хәзер керәм, Миңнур абыстай",—дип шаяртып кына алырга да бит, яшь шул әле, тәҗрибәсе җитми. Ә менә күршеләр арасында шаяртучылар бар. Сукыр Сәхап, Мифтахтан унбер яшькә олы булса да: "Бар, бар, "Мифтах абзый", ашың суына",—дип, "абзый" сүзенә аерым басым ясап, төрттереп алды. Ләкин Мифтах авыл сәхнәсендә спектакльләрдә уйнап, бик матур җырлап, шаян сүзгә дә оста күршесенә үпкәләмәде—дуслар иде алар.

—Син мине уңайсыз хәлгә калдырма инде, Миңнур, ничектер башкача эндәшергә тырыш,—диде Мифтах өйгә кергәч, йомшак кына битәрләп. Тик Миңнур аның бу сүзләрен әллә онытты, әллә аларга игътибар итмәде—"Мифтах абзый" дип эндәшүен дәвам итте.

* * *

Шундый үзенә хас бер халәттә биш атна вакыт үтте. Әйе, бары биш атна вакыт калган булган сугыш башланырга, дөньяның астын-өскә китерергә, изге ниятләрне җимерергә, тыныч тормыш иткән, ачлы-туклы көн күргән халыкның бүгенгесен дә, киләчәген дә кара язмыш кочагына ташларга...

Тагын ике атна вакыт борчылып, янып-көеп, китәр көнне санап үтте. Ләкин тиз үтте ул. Сигезенче июльдә Мифтах, бер төркем авылдашлары белән, сугышка чыгып китте.

—Мин монда яши алмам, син миңа атам-анам янына кайтып яшәргә рөхсәт ит инде үзең кайтканчы,—диде Миңнур Мифтахны озатканда.

—Әйе, әйе, кайтып тор, шулай дөрес булыр,—диде Мифтах та. Юк, алай җәйсыз, киребеткән, усал кеше түгел бит үзе. Тыныч, гел кайгыртып, җайлы гына сөйләшеп, хәлен сорашып, киңәш итешеп тора. «Син, Миңнур, борчылма! Без синең белән бик матур яшәрбез әле. Яме? Йорт торгызырбыз, мал-туар булдырырбыз. Син миңа малайлар, кызлар табып бирерсең. Аларны бергә үстерербез, укытырбыз. Мин бит сине бик яратам. Күрерсең: мин сине һич кимсетмәм, кул тидермәм, сөеп кенә торырмын",—дип кенә әйтә дә бит, яратып булмагач нишләсен соң?..

* * *

Анасы моңа шатланды гына. Йортта аның кул арасына керердәй кеше дә калмаган, кече кызы Минхәяткә әле ундүрт тә тулмаган иде. Инде тормышка чыгып, ирен сугышка озатып, аерылу-каерылу сагышларын татыган, кайгылардан басынкыланып киткән, еш кына уйланып йөри башлаган кызының үз яннарына кайтуы, кабат алар белән бергә яшәве Палта Нурисламның үзе өчен дә, Фәрхинуры өчен дә, зур шатлык булмаса да, күңел тынычлыгы бирә иде: "Үз канатыбыз астында, зур афәт—сугыш барган чорда бар авырлыкларны, кайгы-хәсрәтне бергә-бергә кичерү җиңелрәк булыр"...

Иң яшь, иң һиммәтле ир-егетләре, колхозның көтү-көтү иң көчле, "РККА" категориясен алган иң көчле көтү-көтү атлары фронтка озатылгач, авыл бушап, шыпшыр булып калды. Колхоз эше хатын-кыз, малай-шалай, карт-коры җилкәсенә төште. Миңнур да хәзер һәр көн, иртәдән алып кичкә кадәр, кырда, басуда, йә булмаса ындыр табагында булды. Иген өлгерде дә уракка төштеләр. Авыр тимер ургыч-

лабогрейкаларга жигәргә атлар калмагач, арышын да, бодаен һәм башка игеннәрне дә урак белән урырга керештеләр. Ә урак өсте—авылда эшнең ин тыгыз, кызу чагы ул. Башкалардан бераз калку, инде ныгып килгән яшь Палта Миңнуры урагын да урды, көлтә дә куйды, аны ындырга да ташыды, сугуда да катнашты, салам да өйде.

Илдә сугыш бару тормышны нык үзгәртте. Шатлыклы көннәр, күңел күтәренкелеге юкка чыкты. Кешеләрнең тирән хәсрәтле, уйларга уелып киткән чаклары. Аларның бар белгәне—тырышып эшләү. Эш арасында хатын-кызның бар сөйләшкәне дә—сугыш турында. Башта халык арасында: "Кызыл Армия—көчле, аңа немецлар гына каршы тора алмас, алар үз башларына башладылар сугышны, безнекеләр ике-өч атнада акылга утыртырлар килешүне бозып кергән дошманны",—дигән юатулы сүзләр йөрде. Ләкин көн артыннан көн, атна артыннан атна уза торды, ә Германия гаскәрләре, кала-салаларны җимерә-җимерә, илнең үзәгенә таба үтә торды. Мондый хәл барысының да күңеленә шом салды. Ул Миңнурны да уйландыра—шомландыра иде.

Хатыннар сугышка чыгып киткән ирләреннән, туганнарыннан инде хатлар да ала башладылар. Кайсының хаты юлдан, кайсының инде фронттан килеп төшә.

Бер көнне кич белән почтальон Миңнурга да өч почмаклы бәләкәй генә хат биреп китте. Яшь хатынның гомерендә тәүге тапкыр хат алуы иде бу. Моңа кадәр аның әле үзенең дә кемгә булса да хат язганы булмады, җавап та алганы юк иде. Бу вакыйга күңелендә аерым бер халәт тудырды. Ашыгып хатны ачты һәм укый башлады—ул Мифтахтан иде.

"Сагынычлы хат башы, яз каршы!

Бу дөньяда минем өчен иң кадерле кешем булган газиз хатыным Миңнур! Сиңа ашыгыч чапкан эшелонда баручы ирең Мифтахтан кайнар сәлам! Шулай ук бабай белән әбигә, Минхәяткә, мине сораган күрше-күләнгә, туганнарга сәлам тапшырырсыз. Вакыт тар, кыска гына үзем турында: Казанда озак тормадык, безне—кадровый армиядә хезмәт иткәннәрне ашыгыч рәвештә фронтка озаттылар. Юлыбыз—көнбатышка таба. Башта төрле уйлар гизә, Миңнур, күңел дә тыныч түгел. Сине дә сагынырга өлгердем, тик кайчан кайтулары билгесез. Дөресен әйтим: алда шундый язмыш көтәсен мин күптән белдем. Минем кебек армия хезмәтендә булганнарның барысы да сизенә иде сугыш буласын. Шуңа да бит мин, тизрәк кайтып, өйләнеп калуны хуп күрдем. Дөрес, минем элек авылда күзем төшеп йөргән кызым булмады—син аны яхшы беләсең. Ә менә кайткач, сине күрдем дә, исем-акылым китте, гашыйк булдым. Ләкин син мине кичер: синең артыңнан йөрергә, ышанычыңны акларга минем вакытым калмаган иде—өйләнүне башкода белән генә хәл итәргә уйладым. Билгеле инде, син моңа риза булмадың... Моның өчен мин синең каршыңда үземне чын-чынлап гаепле саныйм, ләкин ул вакытта башка чарам юк иде. Иң мөһиме, мин бит сине бик яраттым, бүген дә яратам, Ходай гомерләремне биргән булса, киләчәктә дә бик-бик яратып яшәрмен. Бу дөньяда син минем өчен бердәнбер—шуны онытма!.. Тизрәк дошманны җиңеп, кайтып керүләр насыйп булсын! Яшисе иде әле, яшисе иде"...

Үз исеменә тирән ярату хисе белән язылган хатны укыганнан соң, Миңнурның күңеле тулып китте. Өйләнгән чорда Мифтахның өсте-өстенә: "Мин сине яратам бит",—дигән сүзләренә әллә ни ышанып та бетми иде Миңнур, ә менә бу хатны укып чыкканнан соң аның күңел түренә ниндидер бер өмет, тынычлану хисе кереп урнашты. Күңел алмак—бер турам. Җылы итеп язылган хат та җанга үзгәреш кертә ала икән бит...

Миңнур барысы турында да уйлый, башы аның һәрвакыт уйда. Мифтах сугышка чыгып китте, ә Минәхмәт әле авылда. Ләкин теге апрель кичендә судан кайтканда очрашканнан соң аларның юллары әле бер генә мәртәбә дә кисешкәннәре юк. Бер авылда яшәп тә очрашма инде! Әллә Минәхмәт үпкәләдеме аңа? Ә нигә соң әле үпкәләргә тиеш ул? Миңнурның нинди гаебе бар аның каршында? Үз язмышын, сөйгән кызы язмышын икесенең файдасына хәл итәргә кирәк булган җитди көннәрдә җебеп төшкән, бүлмәсендә үз гармунына үзе сидрәп утырган кеше үзе гаепле була түгелме соң? Беренче сынауда ук егетлеген исбат итә алмаган кеше белән бу катлаулы тормыш юлын иңгә-иң торып үтә алырлар иде микән соң? Бәлки, үзе теләмәсә дә, Миңнурның ата-ана иркенә буйсынып Мифтахка чыгуы дөрес тә булгандыр?

Мифтах, әнә, үз-үзенә нык ышанган, бәйсез, үз эшен алдан ук уйлап башкара торган кеше. Тормышта да аңа таянып яшәү мөмкин булачак. Сугыштан гына исән-имин

әйләнеп кайтсын. Аның өйләнгәч тә: "Син, Миңнур, борчылма! Без синең белән бик матур яшәрбез әле. Яңа йорт торгызырбыз, мал-туар булдырырбыз. Син миңа малайлар, кызлар табып бирерсең. Аларны бергә үстерербез, укытырбыз"...—дигән сүзләре бүген дә Миңнурның колак төбендә.

Юк, юк! Минәхмәт турында, ничек кенә ул исенә төшмәсен, уйламаска тырыша. Никахлы хатынның тормышка чыкканчы яратып йөргән егете турында уйлавы да ярый торган эш түгел бит әле аның. Нишлисең соң инде язмышның шулай булгач? Өлешенә тигән көмеше Мифтах булды аның, Минәхмәт түгел. Хәзер инде ул Мифтахы турында гына уйларга, аның турында гына кайгыртырга тиеш. Инде Ходай гомер биреп, аңа Мифтахы белән яшәү насыйп иткән икән, бәлки әле аны чын-чынлап яратып та куяр. Бер мәхәббәт бетә, икенчесе килә, дигәннәр бит борынгылар.

* * *

Көз җитте. Көннәр салкынайтып, туңдырып җибәрде, ләкин колхозның эше тәмамланмады. Хатыннар ашлык җилгәрделәр, фронтка дип икмәк әзерләделәр.

Мифтахтан хатлар килеп торды: «Сугышабыз, ләкин дошман көчле булып чыкты. Чигенә-чигенә сугышабыз»,—дип язды бер хатында. Аннары декабрь ахырында, һич көтмәгәндә, үзе кайтып төште. Уң кулының беләзеге яраланып, госпитальгә эләккән булган икән. Төзәлгәнче дип, өенә кайтарып җибәргәннәр.

Аерылышып торган дүрт ай ярым вакыт эчендә тәмуг утыннан кайткан Мифтахны танырлык та түгел иде. Ул бик ябыккан, каралган, күзләре төпкә төшеп утырган, үзе кырысланган, уйчанланган. Шул ук вакытта яшь хатынын бик нык сагынган, аның эче-тышы тулы наз иде.

—Сине бик ратканга, өзелеп сагынганга Ходай минем җанымны саклагандыр, сине кайтып күрергә насыйп иткәндер. Ә анда... Анда мәхшәр, Миңнур, тәмуг мәхшәре. Көне-көне белән, бигрәк тә каты бәрелешләрдән соң, ничек исән калуыма гаҗәпләнеп тора идем. Әгәр кабат кайталмасам... Кабат кайталмасам... Көчләп өйләндем бит мин сиңа, зинһар, бәхилләрсең инде...

Миңнур үзе дә юксынып торган иде. Яраланып, сугыш михнәтен кичеп, бөтенләй үзгәреп кайткан иренә карата мөнәсәбәте кинәт үзгәрде, күңеле йомшарды, бар игътибарын аңа юнәлтте. Ир хакы—тәңре хакы. Көн саен су җылытып, булган дарулар белән аның ярасын юып, дәвалап торды ул. Тәмле-тәмле аш-су әзерләде. Шөкер, Нурислам йортында ризыкка кытлык юк иде әле ул вакытта.

Шушы бергә булган көннәр Мифтах белән Миңнурны уйламаганча якынайттылар. Өйләнешеп тә, назлашып, упыкый-чупыкыйлы рәхәт көннәр күрергә насыйп булмаган яшь ир белән хатын тормышында яңа чор башланды бугай. Яу кырының ачы газапларын татып кайткан Мифтах бертуктаусыз күргәннәрен сөйләде. Элек ул бик ачылып сөйләшми торган иде, ә хәзер ни гаҗәп, уйлана да сөйли, уйлана да сөйли, әйтерсең лә теле ачылган бала. Өйләнгәч, бер дә армиядә күргәннәре турында сөйләмәгән иде.

—Миңнур, беләсеңме... Беләсеңме, мин бит сугышка барып кермәс борын ук бетә яздым!

"Бетә яздым" дигән сүзне ул ничектер тупас итеп, ачу белән әйтте сыман.

—Ә ничек?

—Сөйлимме соң?

—Нишләп сөйләмисең ди инде, сөйлә, билгеле.

Мифтах хатынына эчкә баткан, моңсуланып киткән күзләрен текәде.

—Сөйлә, мин тыңлыйм,—диде Миңнур һәм ниндидер бер аерым якынлык белән иренең кыска чәчләреннән сыйпап алды.

—Мин сиңа Смоленск турында әйткән идем инде. Безнең Казанда оешкан полкны шуның тирәсенә илтеп ташладылар бит. Анда... Анда, Миңнур, коточкыч хәлләр иде ул көннәрне. Кыскасы, безне тәмуг утына илтеп керттеләр. Шулай... эшелон Көнбатышка үрмәли. Башта хәвеф-хәтәрсез генә бардык. Эшелон еш кына туктап тора башлады. Бер көнне иртәнге якта ачык вагон ишекләреннән күрсәк, "ah" иттек: тимер юлның ике ягында безгә каршы, ягъни кире юнәлештә качаклар ташкыны агыла. Очсыз-кырыйсыз җигүле арбалар, җәяүле халык: картлар, карчыклар, хатын-кыз, балачага. Кайсылары бәләкәй арба тартып баралар, аркаларында биштәр, кулларында эреле-ваклы төеннәр, көтүе белән мал-туар куып киләләр—сыерлар, бозаулар, кәҗә-

сарыклар, чиный-чиный чабучы дуңгызлар. Иң кызганычы—аналары, әбиләре белән бергә атлаучы өч, дүрт, биш яшьлек балалар. Алары да төенчек белән. Йөрәк өзгеч күренеш, кызганып үләрсең, Миңнур...

—И-и, Ходаем, кая баралар соң алар?

—Соң, кая булсын инде: сугыш астыннан качалар. Кая барып җитәселәрен алар үзләре дә белмиләр, мескеннәр. Бөтен максатлары—сугыш жиреннән ераккарак качу, исән-сау калу, һәрберсендә җан асрау кайгысы.

Качаклар ташкыныннан ерак та китмәдек, безнең өстән берничә дошман самолеты очып үтте. Алар эшелон өстендә әйләнә башлаганнар иде дә, ачык платформага урнаштырылган ике зенитка тегеләргә ут ачты. Тиз шылдылар, каһәрләр, ут астыннан. Самолетлар көнчыгышка таба очып киттеләр. Бераздан без ул якта бомбалар шартлаганын ишеттек—фашистлар, уйлавыбызча, качакларны бомбага тоттылар. Менә шундыйлар алар—фашистлар, Миңнур. Аларда бернинди дә иман әсәре юк. Теге төенчек тоткан бәләкәй балаларның, бүтән качакларның да язмышы ничек булгандыр, белмим. Шуларны күз алдыма китерәм дә, йөрәккәйләрем сулкылдап куя.

—Мифтах, ә син сугышта немецларның үзләрен күрдеңме соң?—дип сорап куйды Миңнур.

—Бик күп.

—Аттың дамы?

—Ә нигә атмаска? Аттым.

—Аларга тидеме соң?

Мифтах хатынына карап куйды, уйланып торды. Аннан башта тыныч кына, аннары тукталыш ясап һәм ярсып:

—Мин, Миңнур, кадровый красноармеец—дошман белән кети-кети уйнарга минем хакым юк. Алар, әнә, бер гаепсез качакларны, шул исәптән, әле яңа гына тормыш ямен татый башлаган сабыйларны да бомбага тоталар. Ә нигә миңа атмаска? Алар кырып-себереп, утка тотып, яндырып-җимереп, җирнең астын-өскә әйләндереп киләләр, ә безгә нишләргә? Дошманның арт сабагын укытырга һәм булдыра алган кадәр аны юк итәргә тиешбез.

Мифтах беравык уйланып, эндәшми торды. Аннан соң, тынычланып, исенә нәрсәдер төшкән сыман, сүзен дәвам итте:

—Мин, Миңнур, ул сугышның, ул фаҗига, газапларның безнең якларга килеп җитмәвенә эчтән генә куанып та куям. Сугыш астында калган халыкның күргән газаплары, кайгы-хәсрәте дә хәттин ашкан, инде безнең якларга да дошманны җибәрмисе, ничек булса да тоткарлыйсы иде. Шуңа бит инде, көчтән килгәнчә, каршы торабыз.

—Йә, сөйләп бир инде, син бит беренче көнне үк һәлак була яздым, дигән идең...

—Ә, әйе... Фронт сызыгына якынлашкан саен безнең өстә самолетлар ешрак оча башлады. Үзебезнекеләр түгел инде, дошманныкы. Башта берсе килеп чыга да, разведка ясап—тикшереп китеп бара, үзәккә хәбәр бирә: фәлән-фәлән җирдә хәрби эшелон күрдек. Анда мондый хәлне күргән-белгән сугышчылар алдан ук кисәтеп куялар: "Егетләр, чамалап торыгыз, хәзер бомбага тотарга килеп җитүләре мөмкин. Исән калыйм дисәгез, поезд туктауга, аннан ераккарак, мөмкин булса — урманга, куаклыкка качарга тырышыгыз..." Кич була башласа, тизрәк караңгы төшкәнне теләп барасың, чөнки төнлә юлда тынычрак, каракошлар өстеңдә очмыйлар. Бер көнне шулай безнең поезд, тәгәрмәчләрен рельс башларына бәрә-бәрә, алга үрмәли. Минем башта иксез-чиксез уйлар гизә: бу сугыш күпмегә сузылыр икән, азагы бер булырмы, исән кала алырбызмы, авылда нәрсәләр бар... Син гел искә төшеп торасың, Миңнур. Анда бик сагындыра... Шулай уйлый-уйлый йоклап киткәнмен. Бер заман тормозларның шыгырдавына, вагоннарның бер-берсенә бәрелә-бәрелә туктавына, сиренаның ачы тавышына сискәнеп киттем. Өстә самолет моторлары гүли. Аларның тавышы якынайганнан-якыная бара. Котүләре белән киләләр. Командирлар әмер бирделәр: "Быстрее покидать вагоны!.." Без тышка ташландык. Самолетлардан бомбалар коела башлады. Беләсеңме, Миңнур, бомбалар күктән чыелдап төшәләр. Җиргә якынайган саен аларның чыелдавы көчлерәк, куркынычрак яңгырый. Моның кайсысы минем башка төшә инде дип, башыңны тотып чабасың. Кешенең йөрәгенә курку, хәвеф салу өчен немецлар бомбаны чыелдап төшә торган итеп ясыйлар икән. Әйтәм бит, шул тавышны ишеткәч тә зиһенең тарала, тәнеңне курку биләп ала, берише

кеше бөтенләй югалып кала. Аны бөтен кеше шулай ди. Ә шартлый башлагач... Җир белән күк бутала. Юк, бу сугышны бернәрсә белән дә чагыштырып булмый. Коточкыч!..

Без вагоннан күршем, Шонталы егете Гаяз белән сикереп төштек. Ә якын-тирәдә урман да, куаклар да юк. Кая качарга да белмибез. Шулай да андый вакытта сизгерлек арта икән. Инде бомбалар сызгырып-чинап төшә башладылар. Мин Гаязны эләктереп бердәнбер качып котылу урыны—тимер юл астындагы чокырга — туннель кебек итеп ясаган корылма астына чаптык һәм шунда яшерендек. Безнең янга тагын берничә кеше атылып килеп керде. Бәхеткә, бу корылма безнең өчен чын-чынлап үлемнән котылу урыны булып чыкты. Шул бәләкәй генә тишектә без унбер кеше сау-сәламәт калдык. Ә башкалар...

Самолетлар китеп барды, бомбалар шартлавы тынды. Без тонган колакларны уч белән уа-уа астан чыктык. Ә монда... Шатыр-шотыр килеп вагоннар яна, җирнең астыөскә килгән, әйләнәдә кеше гәүдәләре, аяк-куллар, кан. Яралылар ыңгырашып ята. Мәхшәр... Бер полк, ягъни мең ярым кешедән без барлыгы сиксәнләп кеше калган булып чыктык. Аларның да күбесе яралы иде. Ишетәсеңме? Мең ярымнан сиксән кеше... Ә бит әле сугышка кермәдек, анда барып җитәргә дә өлгермәдек. Менә шундый, башка да сыйдырып булмый торган коточкыч хәлләр...

Тагын бераз тынып торганнан соң, Мифтах ниндидер бер көенеч белән:

—Дошман көчле, Миңнур,—мин шуңа инандым,—диде .—Ә безнекеләр мактандылар. Мактанчыкның арты ачык, дип бер дә юкка гына әйтмиләр шул. Немец самолетлары күктә (безнең күктә!) рәхәтләнеп очып йөриләр, ә безнекеләр... чурт знает кайда—юк алар. Син инде тагын кешегә чыгып сөйләп йөри күрмә, ул эштә сак бул—бездә бит артыгын лыгырдаганны яратмыйлар...

—Юк инде, анысына гына башым җитә,—диде Миңнур тыныч кына, ишетелеришетелмәс тавыш белән.

—Беләм, син уйлы, ялгышлык эшләмәссең... Тегеләрнең танклары ыжгырып килә, ә безнекеләр... Алары да юк. Мин хәзер бик күп нәрсәгә төшендем, кычкырып әйтеп кенә булмый. Финляндияне аркылыга-буйга чыгаргадыр иде исәпләре. Тот капчыгынны! Җиңелүдән көчкә котылып калдылар. Ә Маннергейм сызыгында күпме кеше кырылды безнекеләрдән. Монда да шулай. Кырыла безнең халык—солдаты да, качаклар да, сугыш астындагы җирләрдә калган халык та. Халык кына түгел—авыллар, калалар кырыла, дөрләп яна, җимерелә. Мал-туар, хайваннар кырыла... Коточкыч!

Миңнур иренең сөйләгәндә торып-торып "коточкыч" дигән сүзне кабатлавына игътибар итте. Димәк, анда хәлләр чыннан да кот очарлык булганга шулай әйтә торгандыр инде.

Ир белән хатын шулай соңгы көнгә кадәр аралашып-аңлашып, туйганчы сөйләшеп, киңәшеп-уңашып яшәделәр. Ләкин көн артыннан көн үтеп торды, аерылу сәгатьләре кабат якыная барды. Ярасы төзәлеп беткәч тә, Мифтах Бөгелмәгә, хәрби комиссиягә китеп барды.

—Бәлки әле комиссиядән соң яңадан кайтып төшү мөмкин булыр,—дип, Мифтах үзенең дә,Миңнурның да йөрәгенә өмет уты салып китеп барды. Бу—кырык икенче елның март башы иде. Язның беренче ае. Көне-көне белән кояш ялтырап чыга да, аның җылы нуры түбәдәге карларны эретә һәм тып-тып тамчы тама башлый. Һавада яз исе аңкый, Мифтах йөрәккә салып киткән өмет утына шулай ялкын өсти...

Ләкин Мифтах Бөгелмәдән кайта алмады. Кеше аркылы: "Мине озаталар, булдыра алсаң Шонталыга килеп тор, бәлки очраша алырбыз",—дип хәбәр җиткерде. Иртә таннан Нурислам карт белән кызы Миңнур атлы чанага утырып алтмыш чакрымдагы Шонталыга чыгып киттеләр. Соңга кала күрмик дип, Нурислам карт әледән-әле атын дәртләндереп, ашыктырып атлатты. Ниһаять, станциягә дә барып җиттеләр.

—Бөгелмәдән поезд килмәде әле, тоткарлана,—диделәр аларга. Көттеләр-көттеләр, өшеп, туңып беттеләр, чөнки март башы булса да, салкын, җилле көн иде.

—Әллә, кызым, фатирга кереп берәр чынаяк чәй эчеп чыгыйкмы?—диде Нурислам карт.

Фатирлары ерак та түгел, кул сузымында гына иде югыйсә. Капкаларын ачып кергәндә урман артыннан гудогын кычкырта-кычкырта поезд килеп туктады. Миңнур белән атасы кабат поездга таба чаптылар. Тик барып җитә алмадылар—ул кузгалып китте. Миңнурның тирләп-пешеп йөгергәнен күргән бер әби, сагаеп:

—И, балакаем, бер ваянный: «Минем семья килергә тиеш иде, күрмәденме, әби?»—дип сорады. Сез идегезме әллә?—диде.

—Без идек шул...

—И, балакаем, күрә алмадыгыз инде. Мин менә көн саен пуезны каршы алырга киләм. Өч баламның берәрсе булса да кайтмасмы дип. Тик кайтмыйлар шул әле, кайтмыйлар, вакытлары юк, сугышлары авыр ахыры, бик авыр...

—Эх, тагын ике-өч минутка гына түзгән булсак... Мин гаепле, кызым, мин чәй дип алып киттем сине,—дип уфтанды Нурислам карт һәм тире бияләе белән яшьле күзләрен сөртеп алды.

—Икебез дә гаепле, әти, икебез дә. Син китсән дә, миңа каласы иде поездны көтеп, каласы иде. Үкенечкә шулай булгандыр инде, үкенечкә...

Мифтах белән очраша, аны озатып кала алмаудан сызланып, сыкранып, тирән үкенү хисе белән ачынып, алар кайту юлына чыктылар. Юл буена икесенең берсе дә сүз башламады, бер-берсенә эндәшмәде. Миңнур аркасын атасына таба куеп, тавышсыз-тынсыз гына елап кайтты. Авылга житкәндә генә Нурислам карт, тирән көрсенеп:

—Язмыштыр инде бу, кызым, язмыштыр. Язмыштан узмыш юк. Ходай язганны күрми калмый адәм баласы. Башы исән булсын кияүнең, башы исән булса, иншалла, бер кайтыр. Кайтыр исән булса, безнең тәрәзәгә тагын кояш төшәр,—дип куйды, үзләрен тынычландырып.

* * *

Кырык икенең апрель уртасы житте. Илнең көнбатышында коточкыч сугыш-кырылыш дәвам иткән көннәр. Бу афәткә бөтенләй битараф кояш кайнар сулышын жиргә юнәлдерде. Санаулы көннәрдә кыш буе гадәттән тыш зәмһәрир суыклар һәм күз ачкысыз бураннар котырынган киң басуларда, кала-салаларда көрт-көрт булып өелеп яткан карлар эреп, тау араларындагы чокырларга былкылдап су төште, аннары болыннарга, елга-күлләргә ашкынып гөрләвекләр ташланды. Күзгә күренеп, Шушма елгасы үзәне диңгезгә әйләнде, Чиялек һәм Югары әрәмәләре, Бүстрәй буйлары, авыл тирәли жәйрәп яткан олылы-кечеле күлләр тоташтан су астында калды. Ул шул кадәр тиз һәм тулып төште ки, хәтта Тугайдагы кайбер йортларны да су басты. Калын-калын елга һәм күл бозлары, шаулап килеп, Борһан күле аркылы салган агач күперне дә жимереп, үзләре белән алып киттеләр. Авыл күперсез калды.

Нәкъ шул көннәрдә авылның 1923 елда туган алты егете бер үк көнне, бер үк вакытта сугышка чыгып китте. Алар арасында Палта Миңнурының күзләгәне—яратканы гармунчы Минәхмәт, аның якын дуслары Голүм, Рәхимжан һәм башкалар да бар иде. Күл аркылы салган күперне язгы бозлар алып киткәнгә һәм чокырларда ташу шаулаганга, егетләр юлга жәяүләп, кулларына озын таяклар тотып чыктылар да, Юкәле тавы ягыннан Бәркәтә авылына таба, аннан район үзәге Чирмешәнгә юнәлделәр. Аларны Борһан тавына чаклы әти-әниләре, якын туганнары озата килделәр һәм авылдан ике чакрымдагы Бүре базы тавы артына төшеп китеп, күздән югалганчы карап калдылар.

Миңнур Минәхмәтнең һәм аның яшьтәшләренең китүе турында ишеткән иде. Озак та үтмәде, күрше Минжамал ахирәте, хәл генә белергә кергән атлы булып, өйдәгеләр күрмәгәндә генә бер кәгазь кисәге сузды. Бу—Минәхмәтнең Миңнурга атап язган саубуллашу хаты иде:

"Миңнур! Менә безгә дә чират житте, без дә китәбез. Кабат кайтулар, күрешүләр насыйп булырмы, юкмы—безгә караңгы. Үсеп, ныгып житәргә дә өлгермәгән килеш, сугыш корбаны булырбыз ахры. Гомеремнең соңгы елы гел үкенечләрдән генә торды. Башта сине югалттым, хәзер сугышка китәбез... Яратсам да, рәхәт сөю бәхетенә ирешеп булмады... Гомерем булса, мин гел синең турыда гына уйлап яшәрмен инде.

Китәм инде, китәм инде...
Китсәм кайталмам инде;
Бер китсәм кайталмам инде,
Сине оныталмам инде...
Хуш, бәхил бул!
Минәхмәт".

Миннур, йомшарып китеп, кеше күргәнче дип, күз яшьләрен сөртеп алды.

Минәхмәтнең китүе турында ишеткәч, күнелендә аның белән соңгы тапкыр очрашып калу теләге дә туган иде. Ләкин никахлы ир хатынының элек яратып йөргән егете белән очрашуларның мишәр дөньясында ярамаганын Миннур яхшы белә, гасырлар буе урнашкан бу тәртипне ул гына боза алмый. Мондый эшеңне кеше күрсә, авылга таралса, ул Мифтахның туганнарына, аннан үзенә дә барып җитсә оятыңнан ни кылырсың да, кеше күзенә ничек күренерсен? Юк инде, Палта Миңнуры үз намусына тап төшермәс...

Озак та үтмәде, Мифтахтан хат килеп төште. «Фронт сызыгына килеп җиттек, көне-сәгате белән сугышка керәбез»,—дигән иде ул. Аннан соң шактый вакыт хәбәр килми торды. «Әллә соң бер-бер хәл булдымы?» дип шикле уйлар белән яшәде Миңнур, ләкин борчылырга сәбәп юк—төшләрне матур күрә иде.

Ниһаять, июнь ахырында тагын бер өчпочмаклы хат килде. Мифтах тагын яраланган, Казанда, госпитальдә ята икән. «Килеп китә алмассызмы?»—дигән. Миңнур белән атасы тиз генә җыенып, тагын юлга чыктылар. Юл газабы—гүр газабы. Кайда машина, кайда ат, кайда җәяү—шулай өч көн бардылар алар Казанга. Мифтахның аягындагы ярасы төзәлгән, яңадан фронтка озатырга тиешләр икән. Гаиләм килде дип, ул госпитальдән ике көнгә рөхсәт алып чыкты да, алар Нурислам абзыйның Казандагы дусты Габдулла абзыйларга киттеләр, шунда ике төн кундылар.

* * *

Бер көнне Мифтах яшь, гүзәл хатынын Казанны күрергә алып чыгып китте. Үзе аксый, кулында таяк, ләкин Миңнурын шәһәрнекеләр кебек култыклап, һаман җәяү бара.

Габдулла абзый йорты базардан ерак түгел иде. Башта алар базарга керделәр, халык арасында, төрле әйбер карап, озак йөрделәр. Аннары Мифтах серен ачты:

—Минем сиңа истәлеккә бүләк алып бирәсем килә, Миңнур. Хәлемне беләсең, кабат очрашырга язганмы-юкмы, кайта алмасам, истәлегем итеп сакларсың. Мәңгегә...,—диде ул, моңсу елмаеп.

—Миңа бернинди дә бүләк кирәк түгел, Мифтах. Син үзең бүләк, олы бүләк, син үзең кайт, үзең...

Миннур артык дулкынланган иде, күзләреннән яшь атылып чыкты, башка сүзләрен әйтеп бетерә алмады.

—Ярар, ярар, кайтырмын. Син әйткәч, кайтмый булмый инде алайса,—дип шаяртып алды Мифтах.—Тик сүземне тыңла, яме? Алыйк сиңа бүләк. Ризамы?

Бирим дисә колына, чыгарып куя юлына: бер татар хатыны, тормышы авырая башлагач, сандык төбеннән әр-яңа, ап-ак ефәк шәлен сатарга алып чыккан—алар шуны күреп алдылар. Шәл икесенә дә бик ошады. Мифтах сатулашып та тормады, теге хатын никадәр сораса, акчасын биреп, ефәк шәлне күңеле күтәрелеп киткән Миңнурына тоттырды.

Шуннан соң алар Казанның үзәк урамнарының берсенә килеп чыктылар, күз атып, Миннур өчен әле күрелмәгән бик күп нәрсәләрне карап йөрделәр. Ләкин тагын да истәлекләрәгә—фотографиягә кереп, рәсемгә төшү булгандыр. Бергә яшәү гомерләрендә тәүге һәм соңгы мәртәбә рәсемгә төшү! Икесе дә яшь, икесе дә искиткеч матур. Тик күзләренең моңсулыгы гына аларның очрашуларының сагышлы булуы турында искәртә. Теге кайтуында Мифтахның чәче кыска иде, ә бу юлы ул өйләнгәндәгечә кара болыт кебек дулкынланып, күпереп торган чәч белән төште рәсемгә. Ә Миннурның башында Мифтахы бүләк иткән ап-ак ефәк шәл. Хәләл җефетенең иң кыйммәтле, иң кадерле, иң истәлекле бүләге! Ул аны соңгы гомеренәчә кадерләп тотачак... Менә мондый фоторәсемне чын-чынлап мәңге онытылмас, мәңге истәлекле рәсем дисәң дә була...

* * *

Менә тагын аерылышу сәгате килеп житте. Мифтах хәләл җефете Миннур белән кайнатасын шәһәр читенә кадәр озата килде. Машина көтә-көтә шактый вакыт үтте. Бу арада ике яшь йөрәк бергә калып соңгы сүзләрен сөйләштеләр, серләрен уртаклаштылар:

—Сугыш бик авыр бара, Миннур. Аның тиз генә туктавына өмет юк. Ярты ил

немец итеге табаны астында. Шуна күрә минем сина әйтәсе сүзем бар,—диде ул һәм уйланып торды.—Син яшь, чибәр. Әгәр мин сугыш кырында башымны салсам, кайта алмасам, син кабат тормышка чыгарсың. Ләкин бу унайдан минем сина үтенечем бар: син мине биш ел көт. Дөнья хәлен белеп булмый, бәлки мин һәлак булмамын, әсирлеккә генә төшәрмен дә, хат-хәбәр яза алмамын. Көт бер биш ел! Вәгъдәме?

—Вәгъдә, вәгъдә! Тик син харап булма, әсирлеккә дә төшмә, тизрәк кайт! Мин сине күпме кирәк—шулай көтәрмен,—диде Миңнур, чиксез дулкынланып.

—Менә бусына рәхмәт! Шуңа бик яратам да бит үзеңне...

Мифтах Миңнурны күкрәгенә кысты. Нурислам карт, бер якка борылып, аларны күрмәмешкә салышты.

Юл кырыена бер иске йөк машинасы килеп туктады. Алар ашыгып саубуллаштылар да, утырып киттеләр. Ә Мифтах хәрби киемдә, кул таягына таянган килеш кулын болгый-болгый тузанлы юл буенда басып калды. Бу очрашу алар өчен соңгысы булды. Моннан соң Миннур ире Мифтахтан хәтта хәбәр дә алмады. Бар иде Мифтах—юк булды...

* * *

Кайгы-хәсрәт берүзе генә йөрми дөньяда. Көзге көннәрнең берсендә Өммегөлсемнең салам түбәле дүртпочмаклы бәләкәй ызбасына ут капты. Имам күптән юк, Мифтах энесе китеп барганнан соң озак тормады, бер төркем яшьтәшләре белән фронтка озатылды. Соңгы хаты Ленинград артыннан, Карелия тирәсеннән килгән иде, шуның белән хәбәре тукталды: әллә харап булды шунда, әллә әсирлеккә төште инде?

Салам түбә, авыл халкын гаҗәпләндереп, төрле фараз-юрауларга урын калдырып, эчтән дә, морҗа төбеннән дә түгел, ә болдыр ягыннан яна башлады. Ярый әле янгын көпә-көндез, әле төш тә җитмәс борын чыкты, чөнки төнге янгын бик куркыныч, аннан котылулары ике сарылы. Өммегөлсем үзе өйдә юк, хатыннар белән ындыр табагына арыш җилгәрергә җибәрелгән иде. Ызбада берсеннән-берсе бәләкәй ике сабый—улы белән кызы. Рәхмәт инде күршеләргә, алар янгынны күреп алып, бөтен авылга сөрән салдылар: “янабыз, пожар”... Күрше-күлән, авылдашлар ут сүндерергә күтәрелде. Ялкын кыегына үрли башлаган ызба янына барысыннан да алда сугыштан биртелеп, яралар алып кайткан яшь лейтенант Мәгъсүм килеп җитте һәм ут сүндерүне оештырып җибәрде, ә үзе тәрәзәдән кереп башта балаларны коткарды, аннары өй эчендә булган бар кием-салымны, җиһазларны урамга ташлый башлады. Соңгарак калсалар да, бераздан ут сүндерүчеләр дә килеп җиттеләр һәм дөрләп яна башлаган салам кыекны тиз сүндерүгә ирештеләр: ялкын өйнең эченә үтә алмады, артык зыян салмады.

Тикшерә торгач, Өммегөлсем өенә “кызыл әтәч” җибәрүче дә фаш ителде. Бу Өммегөлсемнең якын туганы Һадия абыстайның житеп килгән Мөгаллимә кызы булып чыкты. Бер кичне утырмага килгәч, җаен табып, Мөгаллимә Гөлсем абыстасының кадергә генә кия торган яшел ластик күлмәген киеп караган икән һәм, йөзе кара булгыры, чәлдереп тә киткән. Аны Өммегөлсем белми дә яши икән. Ә Мөгаллимә яшел ластик күлмәк белән аулак өйләргә йөри, килешле итеп сикерепсикереп бии, үзенә әле сугышка озатылып бетмәгән егетләрне карата, кәпрәя, куык очыра.

Мөгаллимәнең кинәттән генә бик матур яшел күлмәк киеп йөрүе турында ишеткәч, Өммегөлсем, күңеленә шик төшеп, сандыгын ачып караган. Ә күлмәк юк, аңардан җилләр искән. Ул, тәмам хафага калып, Мөгаллимә янына йөгерә. Ә тегесе йөзен дә чытмый: “Юк миндә андый күлмәк, минем аны күргәнем дә, тотканым да юк”,—дип җан сата, өстәп: “Миңа яла якканың өчен мин сиңа күрмәгәнеңне күрсәтәм әле”,—дип, янап та куя. Күршеләре янгын алдыннан гына Мөгаллимәнең Өммегөлсем йортыннан чыгып, бакча аша гына арткы урамга йөгергәнен дә күргәннәр икән.

Уналты яшьлек җилбәзәк кызны әнә шундый җинаятьләре өчен алып китеп, әллә биш, әллә алты елга утыртып та куйдылар. Ул елларның “кулы каты” иде шул. Кешенекенә кул сузып, үзеңнекеннән коры калырсың. Шул китүдән Мөгаллимәнең эзе дә булмады туган авылында, төрмәдән чыккач та чит-ят яклардан кайтмады. Оятыннан кайтмагандыр инде.

Миңнур Өммегөлсем килендәшенең бәлагә таруын үз кайгысыдай кабул итте.

Хәленә керим дип, калган тукымалардан балаларга күлмәк-ыштаннар тегеп, Өммегөлсемнең үзе өчен өр-яңа ак яулыгын алып, күчтәнәчкә тегермән ташы чаклы бер ипи кыстырып, янгыннан соң әле һаман рәтләп җыештырылмаган таныш өйгә барып керде. Ике сабый, шатланышып, яңа киемнәрне киеп куйдылар һәм тәмләп ипи ашарга тотындылар. Ә Өммегөлсем, юмарт куллы, киң күңелле килендәшенең игелегенә йомшарып китеп, яшен сыгып алды:

—Син, Миңнур, миңа үпкәләп яшисеңдер инде. Теге вакытта, әллә ничек шунда, уртак тел табып яши алмадык, мин авыр сүз әйтеп рәнҗеттем бугай үзеңне. Үпкә тотма инде, зинһар, мин ахмакка. Югыйсә үзең миңа карата мыскал да яман эш кылмадың, рәхмәт,—диде дә ул, яулык чите белән яшьле күзләрен сөртте һәм кул арты белән битләрен ышкып-ышкып алды. Аның шулай, учлары белән түгел, ә кул арты белән битләрен, маңгаен ышкый торган сәер гадәтен Миңнур күптән белә иде.

—Үткәннәргә салават, Гөлсем апа! Кешенең ялгышкан чаклары була инде ул. Киләчәккә сабак булсын. Ә мин синә үпкә сакламыйм, моңа вакытым да юк. Безгә хәзер ирләребезнең сугыш кырыннан исән-имин кайтуларын теләргә, Ходайдан шуны сорарга кирәк. Алар кайтып, бергә-бергә аралашып, кошлар кебек сайрашып яшәргә насыйп итсен. Йомышың төшсә, кил, безнең капка да, ишек тә һәрвакыт ачык. Авыр минутларда терәк булырга килендәшең барлыгын онытма,—диде Миңнур һәм хәсрәтле көннәрдән соң бөкшәеп калган килендәшенең аркасыннан сөеп, изге теләкләр теләп, җиңел сулап чыгып китте.

* * *

Сугыш елларының авырлыгы... Ул ир-атка да, хатын-кызга да, балаларга да тигез төште. Мифтахы турында исәнме, үлгәнме, әллә әсир генә төшкәнме, дип баш ваткан бер чорда, авылның берничә хатын-кызын Ярославль өлкәсенә торф чыгарырга җибәрделәр. Исемлекнең башында—Палта Нурис кызы Миңнур. Аның белән бергә Насретдин карт кызы Фатыйма, Кара Нәсип кызы Әфрүзия, Мәхтүмә... Һич белмәгән, һич күрмәгән Ярославль өлкәсенең Данилов авылындагы торф предприятиесенә килеп төштеләр. Урысча ике авыз сүз белмәгән мишәр кызларын Варвара дигән бер марҗага фатиргә урнаштырдылар. Нараттан салган дүрт бүлмәле алаңгыр кебек зур ызбада марҗа япа-ялгызы яшәп ята. Берданбер кызы Вера очучы икән, сугышта.

Җәйнең берничә аенда кызлар буйдан-буйга сузылган сазлымыкта торф чыгардылар. Торфны фронт өчен кирәкле кыйммәтле чимал дигән булдылар. Фронтның кайсы җиренә кирәк булгандыр инде ул тирес кебек нәмәрсә? Миңнур бу сорауга алты дистәдән артык ел узгач та җавап бирә алмый. Торфны шакмаклап кисәкләргә бүләләр дә, әйләндерә-әйләндерә киптерәләр, ә көзен ул кисәкләрне әрдәнәләргә өяләр.

Чыгырдан чыккан ярлы авыл балаларының өсләрендә рәтле кием дә юк иде, булганы да тузып, тетелеп бетте. Ярый әле сазлымыкта кияргә брезент оеклар бирделәр.

Ашарга да житми. Ашханәдә кышкы салкыннарда туң кергән бәрәңге шулпасы гына. Көненә ярты кило ипи.

Эштән эт кебек арып, тәмам талчыгып кайткач, кызларның бар теләге—утырып бер туйганчы ашап алу. Тик туйганчы ашарлык итеп әзерләргә ризык кирәк шул. Беркөнне алар шулай көчкә өстерәлеп кайтып керделәр, ә әзерләргә бернәрсә дә юк. Әфрүзия, түзә алмыйча:

—Ачка бетәбез бит, кызлар, урыс арасында дөмегәбез бит,—дип елап җибәрде. Ярый әле Варвара өендә юк иде—горур татар кызларының елаганын ишетмәде. Сүзгә Фатыйма кушылды:

—Зинһар, бер-бер хәл кылыйк. Миңнур ахирәтем, бөтен өмет синдә. Марҗаларча сукалый башладың, сөйләш—без аларның теләсә нинди эшләрен эшләргә риза, ризык кына бирсеннәр...

Миңнур бу турыда үзе дә уйлап тора иде. Әмма аның Палта Нурислам кызы булуы, мишәр-татар дөньясының милли горурлыгын җанына, тәненә сеңдереп, шушы мохиттә тәрбия алып үсүе моңа юл куймый иде. Аннан соң, көн буе сазлыкта арып-талып торф чыгарып кайткан арык, хәлсез кызлар ничек шул марҗаларга ялланып эшләр соң? Ул бу ягын да уйлый иде. Шулай дип ул кызларга да әйтте.

—И-и, Миңнур... Туйганчы ашарлык ризык тапсак, мин төн йокыларымны калдырып та эшләргә риза,—диде Фатыйма.—Аңла әле, дускаем, без бит, хәерче кебек теләнеп ашарга димибез, эшләп, көч түгеп, хезмәт күрсәтеп... Аның нинди ояты

бар? Менә ачлы-туклы торф чыгарабыз. Кемгә аны чыгарабыз, йә әйт әле? Шул ук урыска түгелме соң? Инде сугыш дисең икән, аның анысы да урысныкы. Без—татарларга—кайгы да хәсрәте генә. Әнә, авылда яшь маржалар житәрлек, ә торфта эзләре дә юк, азаплана-азаплана татар кызлары чыгара...

Аның сүзләренә Әфрүзия белән Мәхтүмә дә кушылды.

Кызлар арасында иң кыюлары—шул ук Миңнур да Фатыйма. Урыс телен икесе дә бер чама бе... Әйе, белмиләр. Ләкин, башыңа төшсә, башмакчы буласың. Күрше йортларга кереп, тегеләрнең телен вата-җимерә гозерләрен җиткерделәр. Иң мөһиме, Миңнур: "Работа жис?"—сүзләрен яхшы белә. Алар янына "кушать надо" дигәннәрен дә өстәсәң, башка урыс сүзенең кирәге дә калмый—татар кызларының барлык үтенәкләре маржа акылына тиз барып ирешә.

Уңган кызларга эш булсын да, ашы булсын: шушы көннән башлап алар берәүләргә утын әзерләшергә—кисәргә, ярырга, өяргә тотындылар, икенчеләрнең бәрәңге бакчасында җимертеп эшләделәр, өченчеләрнең идәннәрен кырып-кырып юып чыгардылар.

Ләкин иң төшемле эш—Миңнурныкы. Сугышка кадәр Ярославлда яшәгән Варвараның, бик үк шәп булмаса да, тегү машинасы бар. Тик ул үзе тегә белми. Миңнур шул машинада авыл халкына кием—күлмәк-ыштаннар, кофталар, итәкләр тегеп бирә башлады. Кием тектерүчеләр юк дигәндә дә тамак ялгарга нәрсә булса да алып киләләр. Хәзер инде кызлар да: "Миңнурыбыз гына исән-сау булсын, ачка тилмермәбез, иншалла",—дип торалар. Моның өстенә Миңнур чирләштереп торган хуҗа хатынның сыерын саварга, ызбасын җыештырырга да иренми. Варвара кызларга сөт бирә.

Туган авылыннан, үзенең милли мохитыннан аерылган бер төркем татар кызларының бөтен юанычлары—утырып авылга, йә булмаса фронттагы якын кешесенә хат язу. Инде кемнән дә булса каршы языйлган хат килсә, кызларның күнеле тагын да күтәрелә. Тик хатлар гына сирәк килә...

Бер көнне Миңнур өчпочмаклы хат алды. «Мифтахныкымы әллә?»—дип шатланган иде. Минәхмәттән булып чыкты, дулкынланып китте. Миңнур Минәхмәтенең һәм аның белән бер елгы башка авыл егетләренең бераз соңарып сугышка китүләре турында белә, ләкин яшьлектә сөйгән егете аңа хат язар дип уйламаган иде.

Минәхмәт әле фронтта түгел, Суслонгер дигән алланың каһәре төшкән бер җирдә сугышка озатуларын көтеп яталар икән. Яшь солдатларның хәле аяныч. Көннәр буена урманнан күтәреп агач ташыталар, ач торалар, фронтка китәргә теләгәннәрне дә җибәрмиләр. Солдатлар ачка кырыла.

"Безнең дә хәл бик начар, Миңнур. Бу мәхшәрдән котылсак, сугышта да болай авыр булмас иде кебек. Еш кына сине искә алам. Мин сине элеккечә яратам. Миңа Мифтах абзыйның хәбәрсез югалуы турында яздылар. Сиңа авырдыр инде. Әгәр сугыштан исән-имин кайта алсам, без синең белән барыбер бергә булырбыз. Син көт мине»...

Миңнурның күңеле йомшарып, хисләре яңарып китте һәм ул елый-елый Минәхмәткә бик җылы, кызганулы хат язды. Тик җавап кына ала алмады. Бәлки Минәхмәтне сугышка озатканнардыр да, шуңа җавап хаты яза алмый тора торгандыр, дип уйлаган иде Миңнур. Әмма алай булып чыкмады. Тәмуг мәхшәреннән дә газаплы Суслонгер корбаны булган икән мескен Минәхмәт һәм аның яшьлек дуслары...

Көз җитеп, торфларны әрдәнәләргә салгач кына кызларга өйләренә кайтып китәргә рөхсәт иттеләр.

Ләкин икенче елны да Миңнурны шул ук ачы язмышка дучар иткән дускынайлары Әфрүзия, Мәхтүмә һәм тагын Кара Хәертдин кызы Хәйрия, Тәзкирә һәм Хәдичә белән бергә этеп-төртеп торф чыгарырга чыгарып җибәрделәр...

* * *

Ниһаять, олы югалтулар, иксез-чиксез кайгы-хәсрәт, газаплары белән сугыш тәмам булды. Тик җиңү шатлыгы бик күпләргә яшь аралаш килде. Миңнур да ике канаты сындырылган кыр казы хәлендә калды: ире хәбәрсез югалды, яшьләй сөйгән егете дә кайта алмады, чит җирдә башын салды. Әмма яшь хатын, ничек кенә авыр булмасын, өметен өзмәде. «Сугышта төрлесе булуы мөмкин, син мин кайтмады дип ки-

яугә чыгарга ашыкма, бер биш ел көт»,—диде бит Мифтах һәм аның вәгъдәсен алды. Ә вәгъдә—намус көзгесе, вәгъдә—иман. Миңнур беркайчан да үз вәгъдәсенә хыянәт итмәячәк. Күктән кызыл карлар яуса да әйткән сүзенә тугрылыклы калыр Палта Нурислам кызы. Һәм көтте ул Мифтахын...

* * *

Сентябрь керде. Көзнең тәүге ае. Җәйге көннәр кебек җылы, коры—әбиләр чуагы. Һавада пәрәвез җепселләре—тоҗым оча. Көндез Миңнур белән сеңлесе Минхәят бакчадан бәрәңге алдылар, аналары да чүпләште. Ашыкмый гына эшләп, бәрәңгене кояшта һәм җилдә киптереп, кабыктан тәгәрәтеп базга салдылар. Алда әле тагын аласы бар ул бәрәңгене—бакча зур, эшнең яртысы да бетмәгән. Ләкин инде кич житкән, эңгер төшеп килә, ял да кирәк. Ә тыкрык ягында коштабак чаклы тулган ай бакчага үзенең монсу, сер тулы нурларын сибә.

Миңнур айны балачактан яратты, хәзер дә ярата. Үскән чакта күрше кызлары белән алар тулган айдан көянтә-чиләкләре белән Зөһрәне күзәтәләр иде. Ул вакытта риваять йөри иде. Үги анасы җәберләүгә түзә алмаган кыз, төнлә урамга чыккан да, айның аны үзенә тартып алуын ялварып сораган. Ай аның үтенечен кире какмаган... Балачага барысы да кызганалар иде ялгызы айга менеп киткән ятимә Зөһрәне...

Бүген дә ул, өй алдындагы баскычта утырган килеш, озак итеп тулган айга карап торды, төрле уйлар уйлады, сагышланды-моңланды. Зөһрә-кыз язмышы кебек булмаса да, Миннурның үзенең дә язмышы сокланырлык түгел. Әллә соң бер җырлап куясымы? Күңел басылыр иде хет...

Ай югары, ай югары,
Ай югары—мин түбән;
Кайгы күлләрендә йөзәм,
Шуңа күңелем сүрән.

Ай югары, ай югары,
Ай югары салкынга;
Агач булса, янар иде
Эчемдәге ялкынга...

Сугыш алдыннан авылга бик еш саилче карчык килә торган иде. Бер үк вакытта аның китап та ача торган гадәте бар иде. Өйдә әтисе дә, әнисе дә юклыктан файдаланып, Миңнур беркөнне әлеге карчыктан ярты ипигә үзенә атап китап ачтырды. Аның юравы буенча, Миннурны алда бик кайнар һәм бәхетле мәхәббәт, бәхетле гаилә тормышы көтәргә тиеш иде. Ә кайда ул кайнар мәхәббәт, кайда ул бәхет, кайда ул бәхетле гаилә тормышы? Авылдагы иң гүзәл кызларның да гүзәле Палта Миңнурының мәхәббәте Зөләйха, Зөһрә, Ширин, Ләйлә, йә булмаса Галиябану мәхәббәте кебек дастаннарга язарлык мәхәббәт булырга тиеш иде югыйсә. Юк, булмады ул. Әллә соң авылда Йосыфлар, Таһирлар, Фәрхадлар, Мәҗнүннәр, Хәлилләр булмадымы?

Миңнурга кызыгып, аңа күз атып, күңеле төшеп, аның белән хыялланып йөргән егетләр булмады түгел, булды. Әнә күрше Әсәдулланы гына алыйк. Аның күңеле Миңнурга тартылганын кыз баштан ук сизде. Ә егет ярамаслык түгел иде—чибәр, унган. Дөрес, артыгы белән тыйнак, кыюсыз. Аның: “Яратам”,—дип әйткәнен гомереңдә дә ишетә алмассың кебек иде ул вакытта.

Нәгыймә абыстайның ишле гаиләсендә Әсәдулла—балаларның иң олысы, тол калган аналарның терәге, шуңа да тормыш йөген иртә тарта башлады, яше житәр-житмәс, авыл егетләренә ияреп, Урал якларына бәхет эзләп чыгып китте. Егетләр Түбән Тагилга барып җиттеләр, эшкә урнаштылар. Тик Әсәдулланы гына алмадылар, яшең житми дип, борып җибәрделәр. Әсәдулла кире авылга кайтты да, Нурислам абзый янына керде:

—Миңа яшемне олырак иттереп күрсәткән белешмә аласы иде, Нурислам абзый. Барып төртелер башка кешем юк, булыша алмассыңмы икән күрше хакына? Игелегеңне һич онытмас идем,—диде. Нурислам абзый бөтен авылга абруйлы кеше, авыл Советында да сүзе үтә, шуңа да Әсәдулла аңа керде, аңа барлык ышанычын баглады. Нурислам абзый да күз алдында үсеп килгән егетне күреп тора. Кечкә

эңгерләрдә тыкрыкта, читән буенда еш кына Миңнуры белән дә сөйләшеп-серләшеп басып торалар. Белмәссең, киявең булып та куюы бар. Булса да үкенерлек түгел: егет уңган-булган, тырыш, гаиләдә—анасының олы булышчысы. Аның кебек егетләр бик күренмиләр әле авылда. Тәскә-биткә, гәүдәгә дә күркәм—кызлар юкка гына кызыкмыйлардыр. Читән буенда Миңнуры белән очрашулары да тикмәгә генә түгелдер әле...

Нурислам абзыйның булышлыгы белән яңа белешмәдә үзен ике яшькә олыгайтып, Әсәдулла кабат Түбән Тагилга ашыкты.

Кырыгынчы елның җәендә Әсәдулла, киенеп-ясанып, тагын кайтып китте. Үзенекеләр белән бергә Палталарга да кучтәнәчләр алып кайткан икән, Нурислам абзыйга рәхмәтләрен әйтеп, аларга да кертеп бирде. Нурислам абзыйның да, Фәрхинур абыстайның да моңа күңеле булды. Унҗиденче яшендә генә булса да, тәртипле, акыллы, булдыклы—менә нинди ул күрше егете! Бер ел эчендә тагын да үсеп, тазарып киткән.

Ә күрше егете бу вакытта тыкрыктагы читән буенда Миңнур белән тагын да мөһимрәк мәсьәлә турында сөйләшеп торалар иде:

—Эшем яхшы, акчаны да әйбәт алам. Әйдә, чык миңа, бергә китик. Үзең беләсең, мин сине гомерем буе яраттым, бүген дә яратам. Курыкма, бергә булганда тормышыбыз уң булыр...

—И-и, Әсәдулла, нәрсә сөйлисең? Әзрәк уйлап кара әле: үзең ничә яшьтә дә, мин... Соң бит, миңа унбиш кенә әле. Юк, юк, мин бу яшьтән үк камыт кия алмыйм муеныма. Син дә ашыкма.

—Көтәсем килми шул, Миңнур. Гаиләле яшьләр тиз аякка басалар. Аларга фатирны да тиз бирәләр. Тыңла инде, җаным, китик бергә. Гөрләтеп яшәп китәр идек. Эшлим дисәң, анда тегүчеләргә дә эш җитәрлек.

—Юк, юк, Әсәдулла, бүген мин риза түгел. Көт бер-ике ел... Ашыккан ашка пешкән. Көт иң кимендә тагын бер ел. Аннан күз күрер...

Әсәдулла Түбән Тагилына сөмсерен коеп китеп барды. Озак та үтмәде, авылга аның анда өйләнүе турында хәбәр килеп иреште. Моңа Миңнур гаҗәпләнеп кенә калмады, бик нык кимсенде дә. Әллә Миңнурга ачу итеп өйләнде инде ул анда? Менә сиңа — "яратам"...

Шуннан соң бит инде Миңнур артыннан Минәхмәт йөри башлады. Миңнур үзе дә Минәхмәткә тартылды. Тик, әнә, аңа да насыйп булмаган икән...

Әй, бу дөньялар! Гел син дигәнчә, син уйлаганча, син ниятләгәнчә генә бармый шул. Син уйлыйсың алтыга, ул кала ятыга. Бәлки Миңнур ялгышкандыр, Әсәдулла аңа кулын сорап кергәндә бернигә карамый ризалык бирәсе һәм ияреп китәсе калгандыр? Югыйсә, күңеле белән үз итә иде ул күрше егетен, хәтта вакыт-вакыт аның йөрәгендә ярату хисләре дә балкып-балкып китә иде. Нурислам абзый белән Фәрхинур абыстай да гел мактап кына торалар иде. Димәк, язмаган. Язмаган! Минәхмәте насыйп булмаган. Ә Мифтахы... Ах, анысы белән бигрәк тә катлаулы мөнәсәбәт килеп чыкты. Башта һич яратмаган иде. Аннары күңеле йомшарды, ирендә күркәм генә сыйфатлар таба торды, аны якын итә башлады. Төнге күктә чәчрәп чыгардай булып балкыган йолдызга тиң якты мәхәббәт һәм татлы ярату булмаса да, якын итү хисе дә ярап тора икән кайвакыт. Тик... Югалды Мифтах, суга төшкән кебек юк булды...

Озак уйланып утырды яшь хатын моңсу айга карап. Соң гына кереп ятты.

Ә төнлә ул төш күрде. Киң болын—ул да тулган ай нурына төренгән. Болын өстендә сыек буак йөзә һәм шул буак[1] эчендә ат көтүе йөри. Кинәт кенә шул көтүдән бер күк ат аерылды да, Миңнурга таба килә башлады. Килде, килде дә, туктап калды һәм Миңнурга карап торды. Аннары тыныч кына яныннан үтеп китте. Кешнәмәде-нитмәде, үтеп кенә китте яныннан...

Шул урында уянып та китте Миңнур. Ап-ачык төш, гаҗәпкә калырлык! Нәрсәгә булыр бу? Әллә соң Мифтах кайтамы? Шулай ук исәнмени ул? Кайтса, нинди олы шатлык, нинди зур бәхет булыр иде. Бирсен Ходай!..

Миңнур белә: төшкә ат керсә, очрашуга, шатлыкка. Кешенең гомерлек терәге, дусты, булышчы-ярдәмчесе булган ат төшкә дә матурга, яхшыга, игелеккә юрала.

[1] Буак—томан

Таң атып килә. Ул, күңеле булып, урыныннан торды, юынып-җыенып, тегү машинасы артына барып эшенә утырды. Анда аның кичтән тәгәлләнмәгән эше бар иде. Эше тәмамланмаган килеш тыныч кына утыра аламыни соң инде?

* * *

Иртә белән авылга сугышка китү белән эзсез югалган Мәсләхов Имамның кайтып төшүе турында хәбәр таралган иде. Мифтахның абыйсы, Миңнурның хөрмәт иткән кайнагасы, киң күңелле, мәрхәмәтле-шәфкатьле Имам абзый... Төшнең рас килүен әйт әле син! Мифтах түгел икән бит, Имам кайтырга булган ул төш... Өммегөлсем килендәшнең шатлыклары эченә сыймый торгандыр инде. Тигез, тату тормыш итә күрсеннәр...

Икенче көнне үк Имам Палталарга үзе килеп, Нурислам кодасы, Фәрхинур кодагые һәм Миңнур килене белән озак итеп сөйләшеп утырдылар. Сугышның башы белән югалуы хак булган—Карелия җирендә барган бәрелешләрдә үк армияләре камалышта калган. Сазламык һәм баткаклыкларда бик күп сугышчы кырылган. Очсыз-кырыйсыз сазламыкка юлыгып, һич чыгар юл таба алмыйча, ач-ялангач килеш Имам һәм аның унбер иптәше урманда озак адашып йөриләр. Шул уникe кешедән фәкать төп кебек таза Имам гына исән-имин чыккан ул урманнан.

—Мин баткаклыкта аякка басып йөрүнең һәлакәтле икәнен аңладым һәм судагы кебек йөзеп кенә чыгу әмәлен таптым, аннан шулай котылдым,—диде Имам, уйланып.—Мин үземнең иптәшләргә һәрвакыт: "Паникага бирелмәгез, каушап калмагыз, үзегезне баткаклыкта хуҗа итеп тотыгыз, өстен итеп сизегез",—дия идем. Үзем мин кулдан бервакытта да озын колганы төшермәдем. Бик хәтәр урыннарда гел ботаклары җәелеп киткән агачлар тирәсеннән үтә идем—төпкә китә башласаң, шул ботаклар сине коткара. Мөмкин булган җирдә бик күп мәртәбәләр коткардым иптәшләрне. Миннән ике буйга озын-озын урысларны акыртып-бакыртып төпкә тартып алды фин сазлыклары... Ә мин... мин үләргә җыенмадым, хәтта уйламадым да. Бер үзем генә калгач та: "Юк, шаярмагыз, мине җиңә алмассыз, мин барыбер бирешмәячәкмен, мин барыбер бу мәхшәрдән исән-сау чыгачакмын",—дип, үземә-үзем көч биреп алга үрмәләдем. Һәм, күрәсез, мин исән...

Имам моңсу итеп елмаеп куйды. Аннары сүзен дәвам итте:

—Нурислам абзый, мин сезгә генә, сер итеп кенә әйтәм: армиядә димме, әллә сугышта димме, анда безнең кебек гади солдат, сугышчы турында кайгырткан кеше юк. Нигә безнең армия тар-мар булды дип уйлыйсыз? Чөнки командный состав, армия камалышта калгач, "кукурузник"ларга утырып тылга очты. Кыскасы, качтылар армия башлыклары. Ә безне немец баткаклыкка куып кертте. Кермәс тә идек, аталар, үләсе килми... Бөтен бер армияне кертеп батырдылар шул сазлыкларга. Минем кебек исән калу бәхетенә ирешкән кешеләр бик аз, санаулы гына булгандыр, дип уйлыйм мин, моңа иманым камил.

Яшәү өчен көрәшә торгач, Имам беркөнне чагыштырмача корырак җиргә килеп чыга. Бу инде аның өчен үлемнән котылу була. Бара-бара ул чикләвеклеккә килеп төртелә. Ә андагы чикләвек! Капчыклап җыйсаң да җитәрлек. Имам, бөтен дөньясын онытып, чикләвек ашарга тотына, чөнки аның ике атналап рәтле ризык күргәне юк, ач, тамакны туйдыру аның өчен хәзер иң мөһиме. Көн буена Имам чикләвек ашый һәм тәүге тапкыр ылыслы нарат ботакларын түшәк итеп җәя дә, аякларын сузып ятып йоклый. Иртән торып ул тагын чикләвеккә тотына. Моның өстенә ботакларда кып-кызыл җимешләре сыгылып торган камыр агачын да очрата, анысын да җыеп авызына тутыра. Имам әле үзенең шулай адашып Финляндия җиренә барып чыкканын белми. Чикләвек, камыр җимеше ашап йөргән җиреннән аны фин чик сакчылары тотып алалар. Сазга буялып, пәри төсенә кергән, сакал-мыек үскән, ялан аяклы арык бу кешенең данлыклы Кызыл Армия солдаты булуына фин сакчыларының исләре-акыллары китә.

Имамның бәхетенә, аны сак астында озак тотмыйлар. Юындырып, киендереп, бер җирбиләүчегә батрак итеп биреп җибәрәләр. Батрак булса да, анда аны беркем дә җәберләми-кыерсытмый, ач-ялангач тотмый. Җирбиләүченең хуҗалыгында йорт эшләрен башкарып—утын әзерләп, йорт себереп, су ташып, мунча ягып, мал-туар карап гомер итә. Бу йортагы кешеләр аңа гел үз гаиләләре кешесе итеп карыйлар: үзләре белән бергә ашарга утырталар, хәтта бәйрәм һәм ял итү чараларыннан да

калдырмыйлар. Ләкин Нурислам гаиләсе өчен иң кызыгы—Имамның финнарда ничек мунча керүе турында сөйләве булгандыр. Һәр фин-угыр кабиләсенең борынгы гадәтенчә, гаиләдәге барлык ир-ат, хатын-кыз һәм бала-чага мунчага бергә, берьюлы баралар. Мунчалары гадәттән тыш иркен. Барысы да чишенеп, анадан тума калалар, бездәгечә себерке белән чабыналар, берьюлы юынып чыгалар. Татар—мөселман өчен ул, әлбәттә, гыйбрәтле хәл, ләкин аларда менә шулай икән. Тора-бара Имамга да күмәк мунча керүгә ияләшергә туры килә.

Сугыш тәмамлангач, хәрби әсирләрне үз илләренә озаталар. Имам да, дүрт ел буена Финляндиядә батраклыкта ятканнан соң, СССР чиген үтеп керү белән "сортировка"га эләгә. Аны "сатлык" дип гаепләмәкчеләр, ләкин дәлил таба алмыйлар: аларның армиясеннән эз дә калмаган, документлар да юк ителгән. Мәсләхов "сортировка"дан шахтага эшкә җибәрелә, күмер чыгара. Әнә шулай, мәҗбүри хезмәт срогын үтәп, кайтып төшкән икән ул туган авылга.

Миннур аңа Мифтахның сугышта яра алып, бер тапкыр авылга кайтып китүе, икенче тапкыр Казандагы хәрби госпитальдә дәвалануы, сугышта күргән-белгәннәрен сөйләве, ә Казаннан киткәннән соң, 1942 елның июнь азакларында, аның яу кырында батырларча һәлак булуын хәбәр иткән "кара кәгазь" килүе турында сөйләде. Имам исә:

—Мин аны һәрвакыт исән-имин дип уйлап яшәдем. Кайткандыр, өй салу хәстәре белән йөридер кебек тоелды. Аз-маз үзсүзле гадәте бар иде барын, ләкин үзе яхшы малай иде,—диде, "малай" сүзен авылдагыча җылы итеп әйтеп.—Аның белән синә тормыш итү, килен, һич кенә дә авыр булмас иде. Дөнья хәлен белеп булмый, бәлки әле исәндер дә. Шәп булыр иде минем кебек кайтып килсә...

* * *

Кайнагасы да өметләндергәч, Миңнур тагын көтте Мифтахны: бәлки чыннан да исәндер, бәлки ул да искәрмичә генә кайтып керер... Шулай көтү газаплары белән акрын гына атналар, айлар, еллар үтә торды.

Уйланып-сагышланып йөри-йөри, ялгыз хатын кинәт үзендә җыру, әллә шигырьме чыгару сәләте барлыгын белеп алды.

Ак беләгемне талдыра
Шушма суы салкыны;
Икебезне аеры итте
Шушы сугыш ялкыны.

Ак булса да мамык булсын
Кулларыңа кигәнең;
Һич онытмыйм, гел исемдә:
"Син мине көт!" дигәнең.

Ак каеннар яфрак коя
Сентябрь җилләрендә;
Сине уйласам төшләр күрәм
Утырган җирләремдә.

Ак каенның яфрагы
Нигә саргая болай?
Көне-төне сине уйлап
Мин дә саргаям шулай...

Йөрәккәйләре сулык-сулык итеп язган шигырьләрне кемгәдер укып та күрсәтәсе, уртаклашасы килә. Ләкин сугыштан соң да һаман авыр, һаман житешсез тормыш белән яшәгән авыл кешесенең кайсына аларны күрсәтәсең, кемгә хаҗәт алар? Шулай да ул бер көнне вакыт табып, авылның фельдшер-акушерлык пунктына, зур бер төбәк халкының карап торган өмете, ышанычы булган табибә Сажидә янына төшеп китте. Ике тол хатынның язмышы уртак, икесе дә ирләрен сугышта югалттылар, икесенең дә баласы юк, серләре килә, бер-берсенә терәк булып яшәргә тырышалар. Сажидә

Миңнурдан өч яшькә олы. Миңнур аңа зур хөрмәт белән: "Сажидә апа",—дип эндәшә. Унсигез яшьлек Сажидә сугыш алдыннан, 1939 елда, Чистай фельдшер-акушерлык мәктәбен тәмамлап, Биләр районына эшкә җибәрелә. Ләкин озакламый үзе белән бер сыйныфта укыган, аның белән бер үк вакытта Чистай авыл хуҗалыгы техникумын тәмамлап, армиядә офицер булып җитешкән яраткан егете Сибгат кайтып, аңа өйләнеп, Украинага алып китә. Тик аларның да бәхетле тормышын шул ук каһәрле сугыш өзә. Өлкән лейтенант Сибгат Насыйров дошман белән очрашуларның берсендә һәлак була. Сажидә көч-хәл белән туган авылына кайтып егыла. Кырык бернең августында ул шушы медпунктта тәүге авыруларны кабул итә башлый.

Бөтен холкы-фигыле, җаны-тәне, эчке рухы белән табибә булган бу ачык йөзле, йомшак тавышлы, олы җанлы шәфкать иясе авыл халкының бәхетенә бирегә кайтып төшкәндер. Кайгы-хәсрәтен, моң-зарын бушатырга кирәк булганда Миңнур Сажидә янына төшә.

Ләкин Сажидә апаның вакыты шигырь тыңлап утырумы соң?! Медпункт тулы авырулар җыелган. Миңнурны күрү белән, Сажидә елмаеп куйды:

—Килденме?

Аннары пышылдап кына: "Су кайнат әле, Миңнур. Монда эшләр өйләнеп чыккысыз",—диде.

Әнә шулай: көне-көне белән Сажидәнең утырып сөйләшергә вакыты да булмый—авырулар күп, алар якындагы мишәр һәм урыс, чуаш һәм мукшы авылларыннан да килеп кенә торалар. Ә табибә медпунктта берүзе, аның булышчысы юк, ул штатта да каралмаган. Бер үзенә бер челле, дигәндәй, Сажидәнең ике кулына мең эш.

Миңнур да, җиңнәрен сызганып, эшкә тотынды: башта самавырда су кайнатты, бер юлы медицина җиһазларын да суда кайнатып алды, аннары йөгереп кенә кизләүдән су алып кайтты, чөнки медпунктта су бетеп килә иде. Ул гына булмады, әле юасы керләр дә бар икән—аларны юып-сыгып чыгарып элде, бер уңайдан медпунктны да җыештырып, идәнен юып, һавасын сафландырып җибәрде.

Инде соң. Авырулар берәм-берәм таралды. Ике тол хатын тынычлып Миңнур пешергән бәрәңгене ашап, коры гына—шикәрсез-сөтсез чәй эчтеләр. Хәзер сөйләшеп-серләшеп алсалар да гөнаһ булмас. Уртак сүзләре күп аларның...

—Эшнең күплеген син күреп торасың, Миңнур. Санитар штаты бирсәләр, килерсең. Инде күптән вәгъдә итәләр. Киләсеңме?

— Миңа киләсе юк, бүген үк биредә, куш кына.

—Сиңа кушасы да юк, барысын да үзең белеп, үзең теләп эшлисең, шуңа бөтен өметем синдә минем. Йа Хода... Нинди уңган-булган, нинди матур, килеш-килбәтле үзең. Ә бәхетең... Хет бала табып каласы идең Мифтахыңнан.

—Булмады бит. Балам булса торфка да җибәрмәгән булырлар иде.

—Минем дә булмады шул...

—Ә син миңа бәхетең булмады дисең. Ә үзеңнең?..

Сажидәнең йөзе аптырашлы көлемсерәү белән бизәлде. Юк инде, аның да юк бәхете. Дөрес, ярата ул берәүне. Хатыны, өч баласы бар. Серен эчендә тотса да, Миңнур белә ул турыда. Вакыт-вакыт район үзәгенә алар бергә утырып китәләр. Һәм бу "сәяхәт" аларның икесе өчен дә бәхет китерә бугай, чөнки гыйшык тоту бит ул уртак була. Тик Сажидә өчен киләчәктә бергә булу өмете күренми. Ул моңа өмет тә итми, чөнки аны өметләндергән кеше юк. Бүләге кыйммәт түгел, яратуы кыйммәт... Шул яратуга алданып яши инде йомшак бәгырьле табибә, шуңа риза. Югыйсә мәктәптә бергә укыган сыйныфташы, очучы егет, яшьлек хисләрен күңелендә саклап, аның артыннан килеп, кулын да сорап йөрде. Китәсе генә бит аның белән гаиләле иргә алданып яшәгәнче. Тумаган тайга атлану—шул үзе була инде. Мәхәббәтнең күзе сукыр, күрми ул күп нәрсәне...

Миңнурның Сажидәгә кистереп кенә әйтәсе дә килә ялгышуы турында. Ләкин ул аны бик якын күрә. Үз ул Сажидә, гөнаһысы булса да үз. Ә үзеңнеке — үзәктә. Килер бер көн—табибә ялгышын аңлар, башына тай типмәгән. Әгәр дә аңламаса, Миңнур бер җае белән генә әйтеп куяр.

Сөю—бәхет. Шуның белән бәхетле сизә торгандыр аның үзе кебек ялгыз сердәше. Тик озакка булырмы?

* * *

Урак өстендә медпунктка җил-җил атлап Илгизә килеп керде. Уракта артыгын тырышып ташлаган ахры—кулына гереш төшкән, шешеп киткән. Кысылганга дару юк дигән кебек, герешкә дә юк ул дару. Соңгы вакытта андый шешкә компресс ясыйлар, ә теге елларда Сәҗидә гереш белән килгән кешеләргә үз бәвеле белән чылатылган чүпрәк урап куюдан башка киңәш итә алмый иде. Илгизәгә дә ул ысулны тәкъдим итте. Ә Илгизә табибә киңәшен үзен мыскыл итү дип уйлады ахры—чәчрәп чыгып китте:

—Шуны да дәвалый алмагач, ни өчен сезне монда дәүләт акчасын түләп тоталар? Ярар, үзем җаен табармын. Сезгә калмаган...

Сәҗидә дә, Миңнур да бик уңайсыз хәлдә, хәтерләре калып утырдылар Илгизә киткәч. Хәтер калырлык та шул! Кешесе кеше булса иде...

Илгизә, Илгизә... Холыксыз, мәгънәсез. Аларына әле түзәр дә идең. Йөзе кара, вөҗдансыз, бөтен авылны шаулаткан хатын...

Яшьлекләрендә Миңнур белән Илгизәнең юллары кисешә тора иде.Бер авыл кызлары ич! Еш кына аулак өйләрдә дә очрашкаладылар, бергәләшеп күңелле итеп кичләр утырдылар. Ул елларда Илгизә үзен бик тыйнак тота иде. Егетләргә ошарга тырышкандыр инде. Җырга-моңга да осталыгы юк түгел. Ләкин намуслы хатын булу өчен болар гына җитми икән шул.

...Сугыш алдыннан шаулап үткән туйларның берсе—Хисаметдин белән Илгизәнеке булгандыр. Арчилары да матур төште.

Хисаметдин армиясен тутырып кайткач та тиз генә өйләнмәде—сайланды. Егет үзенә дә, кызларга да таләпчән: җилбәзәкләрне өнәми, чәнечкеле-төртмәле теллеләрнең янына да килми, иренчәк-шапшаклар белән сөйләшеп тә карамый. Үзе уңган-булган, колхоз бригадирлары арасында иң яше һәм алдынгысы. Авылга бер абруйлы егет. Үзен колхоз рәисе итеп әзерлиләр икән, дигән сүз дә йөри башлады.

Өйләнергә күптән вакыт җиткән—егеткә егерме җиде тулып килә. Тик кемне сайларга? Вакыт көтми. Күбрәк чарасызлыктан, Хисаметдин соңгы мәлдә Сукыр Садыйк кызы Илгизәдән дә кулайрак парны тапмады. Матурлыкка хан кызлары кебек үк булмаса да, өсте-башы чиста, сүз сөрешендә зыян чагылмый, үзен тыйнак тота. Дөрес, бераз кылтая торган гадәте бар. Алай гына мулла кызында да була инде ул.

Сайлаган сазга—очраган тазга. Мескенкәем, Хисаметдин бу турыда белми дә калды. Белә калса, ни эшләгән булыр иде икән?

Илгизә Хисаметдинне сугышка озатканда кыз табып калды. Ирдән аңа әллә ике, әллә өч хат килде—шуның белән тукталды. Зур бер ил иненә җәелгән, әлегә тиңе булмаган сугыш кырында, сугу машинасына эләккән көлтә кебек, Хисаметдин дә тапалды, юк булды.

Һай, Мифтахлар, Хисаметдиннәр кебек тапалганнар аз булмады инде авылдан. Ләкин яраткан хатыннары, сөйгән кызлары олы сабырлык, зур түземлек һәм өмет белән хәләлләрен көткән бер чорда, кайбер тол калган яшь хатыннар арасында, вакытны заяга уздырмыйм әле дип, итәк асларын җилләтеп алучылар да булды.

Кечкенә, җыйнак кына ызбада Илгизә бәләкәй кызы белән генә калды. Бер көнне Илгизә өенә колхоз рәисе Аксак Мотыйк: "Кундырып чыгар әле",—дип, очлы йөзле, күсе борынлы райком вәкилен алып керде. Башта Илгизә вәкилгә урынны идәндә генә җәйгән иде, ләкин әрсез алабай вәкил, идәндә өшим, дигән булып, Илгизә янына ук менеп ятты. Намуслы, пакь хатын булса, өрдереп кенә чыгарыр иде күсе борынны, ләкин Илгизә алай эшләмәде. Ир затын тансыклаган яшь, кайнар хатын, райком азгыны капшана башлауга ук эреп төште, кочагын ачты, түземлеген җуйды.

Күндәм хатын ошап китте бугай, вәкил колхозга тагын да ешрак килеп, Илгизә кочагында куныл йөри башлады. Ләкин кыңгыр эш кырык елдан соң да беленә. Вәкилнең шухыр-мухыр йөргәнен райкомда тиз сизделәр һәм тырпылдатып фронтка озаттылар. Әмма Илгизә югалып калмады, бер авызланган хатын, нәфесен тыя алмыйча, утын ярып бир әле дип, уналтысын тутырып килгән Вакташ Мисхәтен чакырып кертте. Тегесе утынны ярды. Шуның өчен дип, Илгизә сызлаган җирләргә сөрткәләргә алып куйган аракысыннан егеткә дә өлеш чыгарды. Шайтан суын капкан егет, кыюланып китеп, Илгизә белән шаярырга тотынды...

Аннары авылга Илгизә янына Азьдакы* Ибрай да кергәли икән дигән сүз таралды.

---

Азьдакы – Аждаһа сүзенең мишәрчә әйтелеше.

Анысы да булгандыр. Урман—колак, кыр—күз, дигән кебек, авылның да күзе зур, үткен—күпне күрә, күпне ишетеп тора. Яхшысын да , яманын да.

Шулай, бер көнне Харис, икенче көнне Варис белән дигәндәй, яшь хатын кулдан кулга китте, Илгизә "ил гизә" башлады.

Ә бер заман Илгизә янына сугышның башы белән бер кулын имгәтеп кайткан Чамалы Хөснелгата килеп йөри башлаган, дигән сүз чыкты. Хөснелгатаның авылда бер киң күңелле, йомшак бәгырьле, уңган Нурбикәсе бар, тупырдап торган өч малае үсеп килә. "Имгәнеп кайттым", дигән сылтау белән кибет тирәсендә уралган Хөснелгата беркөнне битенә иннек сылап, елтыр күзләренә сөрмә тарткан, ерык авызлы, артын биетеп урамнан үтүче Илгизәне күрде дә, һушсыз калды. Азгынга ияргән азар, бозгынга ияргән бозылыр. Хөснелгатаның кушаматы "Чамалы" булса да, үзеннән шактый яшь азгын хатын тирәсендә чамасын онытып, Нурбикәсе белән өч бәләкәй баласын ташлап, Илгизәгә йортка барып керде. Түзеп тормас бу хәлгә авыл ду-у килде.

Нурбикәнең өченче баласына ул кайгылы көннәрдә әле икенче генә яшь иде. Аның кайнар күз яшьләрен түгә-түгә нарасыен имезеп утырулары турында ишетеп, йомшак күңелле авыл хатыннарының йөрәккәйләре өзгәләнде. И-и, Нурбикәнең сабырлыклары! Ир бирмәк—җан бирмәк. Шулай да ул бармады, йөрмәде ире артыннан, олы башын кече итмәде, горурлыгын җуймады. "Башына тай типмәгән булса, үзенең адәм мәсхәрәсе бер өстерәлчеккә барып кергәнен аңлар әле бер, тик соң булыр",—дип әйтә иде Нурбикә. Һәм аның шулай әйтүе хак булды. Хөснелгата башын иеп, мескенләнеп әллә ничә мәртәбә кайтты, гафу сорады, кабул итүләрен үтенде. Тик Нурбикәнең сүзе бер булды:

—Йөрмә! Мондагы өч баланы ятим итүең җитмәгән, хәзер тегендәгеләрне дә кан елатасың киләме?

Илгизә, Хөснелгатаны йомарлап кулына алгач, тиз генә чыгып ычкынмасын әле диптер инде, бер-бер артлы әллә ике, әллә өч кыз тапты. Ләкин аңа карап авыл халкының Илгизәгә булган мөнәсәбәте үзгәрмәде, бәгыре йомшармады. Һәр уңайлы очракта аңа үзенең кемлеген таныта тордылар. Бик озак вакыт Илгизә кизләүгә суга да кара төндә генә йөрде. Кеше күзенә күренгән очракта аның ишетмәгәне калмады:

—Оятың юк икән...

—Зиначы, сине авылдан сөрергә кирәк!

—Хурлык сөягең кайда, ыштыр бит?..

Шулай, авыл әйтсә каты әйтер. Йөзе кара, намусын югалтканнарга аның каһәре зур.

Миңнур да бу хәлгә кимсенеп, йөрәге әрнеп йөрде шактый вакыт. Юк, Илгизә белән бергә үскәнгә, бергә аулак өйләргә йөргәнгә түгел, ә аның авылдагы барлык саф, пакь, намуслы хатыннарның исеменә тап төшергәненә әрнеде йөрәге. Акылың сукыр булса, күзнең файдасы юк икән шул. Тыйнак кына күренгән Илгизә нинди әхлаксыз, яман хатын булып чыкты. Яшьлегендә шуның белән аралашып, бергә аулак өйләргә йөргәннәренә Миңнур үкенеп туя алмады. Хисаметдин мәрхүмнең дә рухы чапалана торгандыр инде хатынының вөҗдансызлыгына.

Инде Сәҗидә апа гына ялгыша күрмәсен Илгизә кебек. Алла сакласын! Ул да авылның каһәренә юлыкмасын иде инде...

* * *

Ниһаять, Сәҗидәнең тырышып йөрүе нәтиҗәсез калмады. Тырышкан — ташка кадак каккан!

—Әйдә, дускаем, тотын эшкә! Штат бирделәр...

Әнә шулай каршы алды ул күрше кызы аркылы чакырткан Миңнурны бер көнне.

Сугыштан соңгы тәүге тыныч ел. Ә авылларда — трахома, корчаңгы һәм башка юк-бар чир. Ярлылык, үтә хәерчелек елларына гына хас йогышлы авырулар. Шуларны тамыры белән бетерү бурычы куелган чор. Сәҗидә белән Миңнурның иртә таңнан кичке караңгыга чаклы медпункттан китми, хәтта еш кына якын тирәдәге авылларга да барып, әнә шул авыруларга каршы көрәшеп йөргән еллары. Эш өстенә эш, үзен турыда уйларга да вакыт җитми.

Шундый көннәрнең берсендә медпункт ишеге алдында таза гәүдәле, күрер күзгә дә ярыйсы, ыспай гына киенгән бер кеше пәйда булды. Ул Миңнурның кайсыдыр бер авылдан кайтканын көтеп торган икән.

—Сез—Миңнур буласызмы?—диде әлеге кеше.

—Мин идем...

—Гафу итегез, минем сезгә бик мөһим сүзем бар иде.

Юлда арып-талып кайтуына карамастан, Миннур таныш булмаган кешене тыңларга мәҗбүр булды. Ярый әле (каян белгән диң син аны?) Сажидә апа каршы чыкты һәм аларны, кеше күзеннән ераграк булсыннар диптер инде, үзе яши торган якка кертеп җибәрде, гәрчә Сажидәнең болай итүе Миңнурга бер дә ошамаса да. Бәлки шуңадыр, ул илтифатсыз гына:

—Тыңлыйм сүзегезне,—дип килгән кешене ашыктырды.

—Мин үзем Туймәтнеке. Сугыштан, шөкер, исән-имин кайту насыйп булды. Әле өйләнмәгән. Хәзер менә өйләнү турында уйлап йөрим. Сезнең турыда күп ишеттем болай. Риза булсагыз, мин сезгә өйләнер идем...

Гомерендә тәүге тапкыр күргән кешедән шушы сүзләрне ишетеп, Миңнур аптырап, хәтта бераз исәнгерәп китте: "Әстәгъфирулла!". Үзе сугышта да булган, димәк, дөнья күргән кеше булырга тиеш. Тышкы кыяфәте дә ярыйсы гына, ә менә сүз сөреше... Юк, мондый ирнең булуыннан булмавы артык! Туң йөрәкле, агач авызлы, төерле телле. Өйләнергә килгән кеше нәрсәсе белән булса да кәләшнең игътибарын җәлеп итәргә, аңа ошарга тырышырга, күңелен кузгатырга, уйландырырга тиеш ләбаса. Инде ирдә булырга өлгерсә дә, әле яңа гына егерме икесен тутырган, керсез күңелле, кына гөле чәчәге кебек алсу йөзле, аяз күк кебек зәңгәрсу күзле, камыш сабагыдай зифа буйлы, елмайганда карап туймаслык гүзәл Палта Миннурының кулын сорап килгәнсең икән, син телең белән кош тота торган егет булырга тиеш. Һәм синең сайравыңда булачак кәләшең, аңа булган күңел яктылыгыңны, кайнар хисләреңне тоярлык булсын. Әгәр алар синдә юк икән, ничек бу асыл зат үз язмышын сиңа ышанып тапшырсын да, каян аның сиңа сыенып яшәргә өмете бөреләнсен?

Җан җылысы... Башта ул Мифтахта да бик сизелмәде, ләкин соңыннан, бигрәк тә сугыш газапларын татып кайткач, аңарда ул туды. Сөеп алган, сөеп барган—анысын Ходай насыйп итмәде Миннурга. Ә алдагысы... Алдагысын Алла белгән. Булачак туй өчен хәзердән үк биеп торып булмый...

—Мин бит инде ирдә булган кеше, ә сез өйләнмәгән егет. Авылыгызда кызлар беткәнмени?—дигән булды Миңнур, әңгәмәне кырт кисмәс өчен.

—Миңа сезнең кебек яхшы хатын кирәк...

—Анысы үзегездән тора инде. Ирне ир иткән—хатын, хатынны хатын иткән—ир, дип белми генә әйтмиләрдер.

—Миңа сезне алырга киңәш иттеләр.

—Шулайдыр да бит... Минем әлегә җавабым бер: ирем сугышта югалды. Исәнме, әллә юкмы—мин белмим. Ләкин мин хәбәре килми башлагач биш ел көтәргә вәгъдә биргән идем. Әле минем көтәсем бар. Вәгъдәмне боза алмыйм!

—Юк, мин алай озак көтәлмим.

—Анысы сезнең ихтыярда...

Тагын да сүз куерту файдасыз булуын аңлап, ир, кырт гына саубуллашып, чыгып китте.

Шушы вакыйгадан соң озак та үтмәде, авылга тагын бер яңа хәбәр таралды: Макар Кәшифе кайткан. Кайдадыр Өркет* ягында, Слюдянка дигән калада яши икән. Миңнурдан бер яшькә генә олы Кәшиф белән алар мәктәптә бер сыйныфта укыдылар һәм шул вакытта ук ул Миңнур артыннан йөргән иде. Ләкин Миңнурның алкы-салкы укып, тәртипне санга сукмаган бу малайга беркайчан да исе китмәде. Аның дөньяда барлыгы турында да бихәбәр иде Миңнур. Ә менә Кәшиф онытмаган. Ул да, әнә, тәкъдим белән килеп җиткән: "Әйдә, миңа чык, Слюдянкага алып китәм үзеңне"...

—Юк, юк Кәшиф, минем иремә биргән сүзем, вәгъдәм бар, аны боза алмыйм...

Син теләмәгән кеше белән бәйләнмәс өчен дә шәп җавап икән ул: "Вәгъдәм бар"...

Аптырагач, Кәшиф Нурислам абзый белән Фәрхинур абыстай янына килеп, аларның ризалыгы белән, алар аркылы үз дигәненә ирешергә теләде: "Әнә бит теге вакытта, Миңнур теләмәсә дә, Мифтахка тотып биргәннәр"...

Картлар исә, теге елларның ялгышын кабатламас өчен:

—Аңа хәзер унбиш-уналты яшь түгел, үзегез уртак тел тапсагыз—без риза,—

* Өркет — Иркутск.

диделәр. Әнә шулай Кәшиф тә буш кул белән генә китеп барды...

Ишек кагып, Миңнурның кулын сорап әле тагын килгәләделәр. Аларга да җавап бер булды: "Вәгъдәм бар"...

* * *

Авыл... Ул иртә уяна, иртә тора, иртә ыгы-зыгы килә башлый, чөнки авылга яшәргә кирәк. Тырышып яшәргә. Палталар да шулай тырышып яшиләр. Нурислам абзый үзе, карт атын җигеп, вакыт-вакыт берәр атналык юлга чыгып китә, авылларны әйләнә, шулай көн күрә, дөнья көтә.

Фәрхинур абыстай иртәнге намазга торганда Миңнур да урыныннан кузгала. Анасы:

—Таң тишегеннән тормасаң... Кем сине куа? Йоклар идең әле рәхәтләнеп...—ди.

—Эшем күп, әни, аны кем эшләр?

—Әй, бала, бала! Эш дип ярыласың инде...

Юк, Фәрхинур абыстай кызын битәрләми, орышмый, болай гына—үз итеп, яратып әйтә бу сүзләрне. Ана бит—кызгана да ул кызын. Уңганлыгына, эшчәнлегенә, тырышлыгына сокланса да кызгана.

Юынып, чистарынып, Миңнур тегү машинасы артына барып утыра. Авыл кешеләре эшне аңа китереп кенә торалар. Диварда, әйтерсең лә бер җан иясе, келт-келт итеп сәгать йөри. Эш арасында да Миңнурның бер күзе сәгатьтә: мавыгып китеп соңга калмыйммы? Медпунктка киткәнче аның әле бер көянтә су да алып кайтасы бар. Суга бару—Миңнур өчен дөньяга чыгу. Аны бит анда саф, эчеп туймаслык тәмле, мул сулы Кизләү көтә. Ах, ул Кизләү!.. Андый гаҗәеп мул сулы чишмә башка бер җирдә дә юк бугай. Миңнурлар авылының чын горурлыгы, олы байлыгы, халыкның терәге. Печән өсте дисеңме, әллә урак өстеме, янып-пешеп, сусап шул Кизләү суы аккан улакларга ятып эчкәндә дә ул суның тамакка зыяны тими. "Ярый әле кизләвебез бар",—дип уйлый Миңнур еш кына. Эчең пошканда да, чиләк-көянтәләреңне аласың да, кизләүгә төшәсең. Ә су юлыннан кеше өзелми.

Кизләү—ул әле тәмле су гына да түгел. Ул авыл халкының даими очрашып, сөйләшеп, хәбәрләшеп тора торган җире. Ә очрашып сөйләшү ул—үзе бер гомер...

Тегеп бетерәсе әйберен тәмамлады да, Миңнур ашыга-ашкына кизләүгә суга төшеп китте. Бура эчендәге зур чаннан улакларга тулышып агып яткан саф су белән чиләкләрен тутырып торганда, Миңнурның артында таныш тавыш яңгырады: "Ахирәтем!" Минҗамал икән. Ике күрше, ике дускынай, дулкынланып, кочаклашып алдылар, аннары, икесе дә су алып, кайтып киттеләр.

—Киңәшем бар сиңа, ахирәтем. Олы киңәш...,—диде Минҗамал, кайта-кайтышлый.—Син минем иң якын дускынаем, ахирәтем. Син генә мине аңларсың да, син генә миңа ипле киңәш бирерсең дип уйлыйм...

Миңнур Минҗамалның бик мөһим сүзе барын тиз аңлады. Су юлында гына сөйләшеп аңлаша торган түгел, иде. Шуңа да:

—Эштән кайткач та кер үзебезгә, иркенләп сөйләшербез,—диде дускынаена йомшак, җылы итеп.

—Үзем дә шулай уйлаган идем. Керәм алайса?

—Кер, кер, сөйләшербез. Соңгы вакытта очрашканыбыз да юк...

Алар икесе ике капкага юнәлде.

* * *

Медпунктта, һәркөндәгечә эш тыгыз булса да, Миңнур дускынаеның: "Киңәшем бар",—дигән сүзләре турында да уйламый булмады. Минҗамалның болай ук хафага батып сөйләшкәнен күргәне юк иде әле Миңнурның. Ни булды икән?

Палта Нурислам белән Бәләкәй Нургата гомер буе янәшәдә генә, терәлеп тормасалар да, якын күрше булып яшәделәр. Аларның икесе тиң чибәр кызлары Миңнур белән Минҗамал да бер үк елда тудылар, бер сыйныфта укыдылар, бергә үстеләр, ахирәт булып яшиләр. Ләкин соңгы вакытта, чыннан да, сирәк очрашалар алар. Әйе, һәркемнең үз эше, үз мәшәкате, үз катыу*.

Кичен Миңнур медпунктта озак тоткарланмады, Сәҗидәнең рөхсәте белән өенә

* Катыу—хәсрәте

ашыкты, чөнки ахирәтенең:"Кинәшем бар",—дигән сүзләре колагыннан китми иде.

Минжамал да Миннурның кайтуын сабырсызланып көтеп тора икән, кереп тә җитте. Алар, Миннурның бәләкәй тегү бүлмәсенә кереп, аулакта калдылар.

—И-и, ахирәтем... Сүземне ничек дип башларга да белмим. Егылып китә күрмә, зинһар,—диде Минжамал еламсырап һәм яулык чите белән күзләрен каплады.

Миннур аш бүлмәсенә чыгып, чәйнектән чынаякка чәй агызып керде.

—Әйдә, эчеп җибәр әле! Тынычлан, Минжамал,—диде Миннур. Минжамал чәйне кабып куйды һәм дускынаена текәлде. Аның күзләрендә аптырашлы елмаю чагылды. Аз аптыраган елый, күп аптыраган көлә...

—Башкода килде бит кичә,—диде дә, Минжамал яшь аралаш көлеп җибәрде.

—Кемнән?

—Потый Шәфикътан...

"Нигә әйттем инде?"—дигән кебек, Минжамал кулы белән авызын каплады да, тагын Миннурга текәлде: дускынае ничек кабул итәр бу хәбәрне? Миннур аптырап та китте, тик Минжамалга моны белгертмәскә тырышты.

...Балачактан чирләшкә Потый Шәфикъ сугыш башланганда сазап беткән, мишәр кызлары әйтмешли, "карт егет" иде. Җан биргәнгә юнь биргән. Җанын биргәч, бәлки юнен дә бирер әле, дигән өмет белән, Потый өйләнү турында да уйламый йөрми. Ләкин авыл кызларының берсенең дә шөкәтсез өрәккә генә чыгасы килмәде. Аптырагач, Шәфикъ читт авыллардан да белешеп карады, тик кыз табылмады. Шуннан соң ул, язмышына буйсынып, өйләнү ниятләреннән кире кайтып, тагын көтәргә булды. Чире-чир, әмма Потый Шәфикъ тормышка берегеп яши: колхозда келәтче, эшен тырышып башкара, исәп-хисапны да төгәл алып бара—башын ярыйсы йөртә, комиссия аның эшен гел тикшереп торса да, келәтчегә дәгъва юк. Дәгъва булмагач, аңа ышаныч та елдан-ел арта бара, абруе үсә. Шулай булса да, кызларның ана бер дә исләре китмәде.

Авыл ир-атларын рәттән сыпырып сугышка алып киткән чорда да Потыйны алмадылар, тәүге комиссиядән үк, чүпкә чыгарып, өенә кайтарып җибәрделәр дә, башкача чакыручы булмады.

Ә сугыш корбансыз булмый. Соңгы сугышның исә корбаннары исәпсез-хисапсыз иде. Авылның Мифтах, Хисаметдин, Голүм һәм башкалар кебек чатнап торган иң гаярь егетләре дә яу кырында башларын салдылар, хәбәрсез югалдылар. Түгәрәк көләч йөзле, коңгырт күзле, томрап торган кара чәчле, килеш-килбәтле, тулышып торган күкрәкле Минжамалның да җан сөйгәне—Рәхимҗаны әнә шул дөньякүләм афәт корбаны булды, аны кара кайгыга салды, киләчәк бәхетенә өметен өзде, канатын сындырды.

Потый Шәфикъ исә, сунарчының киек саклаганы кебек, сугыш беткәнен көтте: "Бетсен әле, бәлки миңа да бәхет елмаер"... Һәм астан гына ул тагын кызлар күзли башлады. Ә кызлар күп. Араларында абруйлылары да бар. Шуларның берсе—Минжамал. Ындырда бөртек җилгәрергә йөрүче кызлар арасында Минжамалдан да уңганы, Минжамалдан да өлгере, Минжамалдан да күндәме юк. Сугышка кадәр бу кыз артыннан йөргән егетләр бер Рәхимҗан гына да булмады. Потый Минжамал белән Рәхимҗанның вәгъдәләре барлыгын да белә. Ә егеттән, инде күпме вакыт, бер хәбәр дә килгәне юк. Бу хәл, әгәр Минжамал белән сөйләшә-нитә калганда, Потыйны өметләндерми дә түгел. Кемгә нәрсә, корчаңгыга мунча, дигән кебек килеп чыга да бит. Булса була инде, Минжамал гына ризалыгын бирсен, бигрәк шәп кыз, калышса да, Палта Миннурыннан гына калыша торгандыр...

Бәләкәй Нургата абзый йортына яучы килеп кергәч, барысы да шатланышканнар иде кебек башта, ләкин кияү егетенең кырыгын тутырган, җан биреп, җан алып яшәүче Потый Шәфикъ икәнен белгәч, һушсыз кала яздылар. Ярый әле дөнья күргән Нургата абзый югалып калмады: "Безгә бу турыда бергәләшеп уйлыйсы бар, шуннан соң җавабыбызны бирербез",—дип, яучыны тынычлындырып, чыгарып җибәрде...

Минжамал ахирәтенә озак карап торды, ә тегесе эндәшми утыра.

—Нигә дәшмисең, ахирәтем? Потый дигәч, өнең бетте ахры. Шулай шул, бетәр дә. Ә миңа нишләргә, миңа?.. Өзгәләнүләремне белсәң иде!..

Минжамал сулкылдап елап җибәрде. Елый-елый сүзен дәвам итте, эчендәгесен актарды:

—Кара инде, Ходай мине нинди көнгә калдырды! Хурлыгыңнан Шушмага ташланырсың. Әй, Аллам! Нигә бәхет бирмәдең миңа? Нигә минем Рәхимҗанымны хараплар иттең? Мин бит аны бик ярата идем...

Миннур Минҗамалны кочаклап алды да, аркасыннан сөеп, тынычландырырга теләде. Аннары чынаякны тагын Минҗамалга сузды, ләкин тегесе аны кулына алмады. Шунда Миңнур үзе ярты чынаяк чәйне эчеп куйды да, кайнарланып:

—Тынычлан әле, Минҗамал, тынычлан! Бер синең Рәхимҗаның гына харап булдымыни бу каһәр төшкән сугышта? Үзең беләсең, минекеләрнең... Минекеләрнең икесе дә югалды! Мөсәвәрә абыстайның Сәхабы, Нурхая абыстайның Сөнгате, Салах Миннурының Зиятдины, Өмминең Нуркае, әллә кемнәрнең әллә кемнәре—башын салганнарның, хәбәрсез югалганнарның исәбе юк хәзер. Ил белән, ил белән ул кайгы-хәсрәт...

Минҗамал елый-елый ярсыган иде—битен яулыгы белән каплап чыгып китте. Сүзнең очына чыга алмадылар. Миңнур ахирәтен эче пошып озатып калды...

Өйдә Нургата абзый:

—Кызым, хәлеңне бик яхшы аңлыйбыз, шуңа да безнең сиңа: "Үзең яхшылап уйла, үзең хәл ит",—дигән сүздән башка киңәшебез юк. Инде өлешеңә тигән көмешең Потый Шәфикъ икән, ни хәл итәсең?..—диде икеле-микеле генә.

—Юк, юк! Дуадак каз кебек ялгыз яшәсәм яшәрмен, тик Потыйга чыгасым юк,—дип ярсуын дәвам итте Минҗамал.

Шулчак ишектән ялт итеп Миңнур килеп керде. Ахирәтен бу хәлдә калдырасы килмәгәнгә, аны тынычландырырга, юатырга, башлаган сүзне дәвам итәргә кирәк булганга килеп керде ул.

—Башкайларымны кая куярга да белмим, ахирәтем. Зинһар миңа үпкәләмә,—диде Минҗамал, бераз ярсуын тыеп.—Очрашмаган, сөйләшмәгән, киңәшмәгән туганнар, якыннар калмады, нинди уйга килергә дә белмим. Шуңа синең янга кергән идем. Хәлемне аңлый торгансыңдыр...

—Аңлыйм, бик аңлыйм, Минҗамал. Бетеренмә әле, юкка борчыласың. Әйт әле: син менә Потыйның үзе белән очрашып сөйләштеңме?

—Ю-у-ук... Кайчан сөйләшим ди?

—Алайса, Минҗамал, син Шәфикъ абзыйның үзе белән очраш! Сөйләшегез, озак итеп, яхшылап сөйләшегез, бәлки икеләнүләрең бетеп китәр. Язмышы җиңел түгел аның, ә андый кешеләр яхшы, йомшак күңелле, рәхимле булалар. Үзең уйлап кара: авылга аның зыяны тигәне булдымы? Әшли, үз көнен үзе күрә, күршеләре дә аның турында начар сүз әйтмиләр,—диде үз башыннан үткәннәр турында уйлап.

—И-и, ахирәт, нәрсә сөйлисең син? Яраткан, һич югында сиңа кайсы ягы белән булса да ошаган кешегә кияүгә чыгарга кирәклеге турында акыл сата идең бит әле безнең ишегә,—диде Минҗамал, аптыраулы көлемсерәп.—Теге ничек әле синең: "Җан жылысы, җан жылысы"...

—Булгандыр, Минҗамал, сөйләгәнмендер, үзем дә яраткан кешемә чыга алмаганга сөйләгәнмендер. Беләсеңме, гел без уйлаганча гына булса икән бу дөньяда. Булмый шул! Мин Мифтахка атам-анам сүзенә каршы килмим дип чыктым, аларны рәнҗетәсем килмәде. Шулай да Мифтахны соңыннан мин үз иттем, аны җаным-тәнем белән кабул иттем, чөнки ул йөзгә-биткә дә, гәүдәгә дә, кеше буларак та ярамаслык түгел иде. Ул гына да түгел: йомшак бәгырьле, назлы иде ул. Хатын-кызга тагын ни кирәк? Андыйны яратмау мөмкин түгел. Торган саен, аны күбрәк белгән саен яраттым мин аны. Шуңа да мин аны бүген дә өзелеп көтәм. Вәгъдәм бар, вәгъдәмне үтим, дип кенә түгел, үз кешем дип көтәм мин аны. Ул кайтса, миңа башка берәү дә кирәк булмас иде...

—Мин дә Рәхимҗанны көтәм дә бит... Күңелем белән көтәм.

—Соң, алай булгач, көт! Ә Шәфикъ... Ул беркая да китмәс, сине көтәр...

Өч-дүрт көннән Минҗамал тагын ахирәте янына йөгереп керде:

—Киңәшеңне тоттым бит, Миңнуркаем, тегенең белән очрашып сөйләштек. Бик куркып торган идем шул карачкы белән ничек очрашыйм дип. Куркасы калмаган икән, тотып ашамады... Мескен Потый, артык дулкынланып, кызарып-бүртенеп чыкты, үзе еш-еш сулый. Юк, суламый, ә гыж-гыж килә, әледән-әле ютәлгә буыла. "Менә, Минҗамал, минем бар сәламәтлегем, бар булдыгым шушы инде. Сәламәтлегем

булса, мин, бәлки, мондый гына Потый Шәфикъ булмас идем. Менә мина кара да, уйла, уйлан, аннары үзең хәл ит. Барысы да үз иркеңдә, үз ихтыярыңда булсын. Инде очрашу насыйп булган икән, яшермим, әйтәм: соңгы елларда мин гел синең турыда уйлап, хыялланып яшәдем. Әйе, мин чирләшкә, гарип. Сиңа ишетүе гаҗәптер дә, әмма чирләшкәләрдә дә хис, тойгы бар. Мин дә хыяллана, уйлана, хәтта ярата да беләм. Шул ук вакытта мин синең буем җитмәс кыз икәнлегеңне дә аңлыйм. Әгәр минем бәхеткә син ризалыгыңны бирсәң, мин сине фәрештәләргә тиңләп яшәрмен, соңгы сулышыма чаклы бәхетле итәргә тырышырмын",—дип, йомшарып китеп, елап җибәрде. Үземә дә җәл булып китте, малакаем, җаннарым җәрәхәтләнде. Бөтенләй икенче тәэсир алып кайттым бит әле мин, ахирәткәем. Уйланам, сызланам.

Минҗамал үзе дә яшьләнеп алды, яулык чите белән генә күзләрен сөртте.

—Безнең сайланасы юк шул, Минҗамал.

—Менә син сайланасың бит әле,—дип бүлдерде Минҗамал.

—Дөрес, сайланам. Менә син: Шәфикъ абзый яратам дип әйтте, дидең. Ә минем Мифтахтан соң кулымны сорап килгәннәрдән "яратам" дигән сүзне ишеткәнем юк әле. Аерма бармы?

—Әй, ахирәтем, син күрдең шул ул "ярату" дигән нәрсәне, ә без?..

—Үзең беләсең, Минҗамал, мин синең бәхетле булуыңны телим. Шулай да: "Тот та чык шул Потыйга",—дип әйтә дә алмыйм. Синең үзеңнең дә башың түгәрәк, уйла!—диде Миңнур соңгы сүзе итеп.

Моннан соң да Минҗамал шактый вакыт уйланып йөрде һәм, ниһаять, башка кешегә кияүгә чыгу мөмкинлеге күренмәгәч, Потыйга чыгарга ниятләде...

Шуннан соң әллә ике, әллә өч атна вакыт үтте—ике ахирәт кизләү янында тагын очрашты.

—Хәлләрең ничек соң? Күнә аласыңмы? Сүзеңдә торамы?—дип тезеп китте Миңнур.

—И-и, ахирәтем! Күнәсең икән аны. Болай бер дә ярамаслык түгел үзе, гел уңайга гына сыпырып яши. Игътибарлы. Соңгы вакытта чире дә үзен бик йөдәтми, әллә өйләнүнең файдасы булды инде шунда... Балага уздым бит! Шатлануларын белсәң... Сиңа рәхмәтләремне әйтәсем килеп йөри идем әле. Синең киңәшең хәл итте дә салды бөтен эшне. Үзеңә дә бәхет бирсен Ходай!..

* * *

Миңнурны еш кына төрле уйлар чолгап ала. Мифтах та аңа: "Син уйлы",—дия торган иде. Уйламыйча яшәп буламы? Әнә, Минҗамал малай тапкан...

Ике ахирәтнең тормышында охшашлык ярылып ята: Миңнур да, Минҗамал да сөймәгән, яратмаган кешесенә тормышка чыктылар. Кая инде монда сайлану? Тик кияүләр арасында җир белән күк арасы: Мифтах һәр яклап сау-сәламәт, чатнап торган көчле, чибәр егет иде. Ә Минҗамал өлешенә чыккан "көмеш" көчкә сулыш ала, үпкәсе гыж-гыж килә, йөзе кара-сары—өрәк тә өрәк. Һәм шул ук вакытта алар икесе дә ярату хисе белән яшәргә сәләтле буларын дәлилләгән кешеләр. Яңып торган, тап-таза Мифтах белән Миңнур аерылышканчы да берничә атна бергә яшәделәр, аннары Мифтах яраланып авылга кайткач та шактый бергә булдылар, Казанда очрашкач та назлашмый кунмадылар, ә Миңнур балага узмый калды. Чирләшкә, җаны: "Менә чыгам, менә чыгам",—дип көчкә яшәгән Потый Шәфикъ белән Минҗамал тормыш башларга өлгермәделәр, бусы: "Балага уздым бит",—дип шәрран ярды. Озак та узмады, тупырчык кебек матур малай тапты. Менә бит нинди хикмәтләр бар бу дөньяда! Юк, Миңнур ахирәтеннән һич тә көнләшми, ләкин гаҗәпләнми дә булмый. Әллә соң бу да бәхет эшеме? Минҗамал өчен Потый Шәфикъ чын мәгънәсендә бәхет күгәрчене булып чыкты ла... Йа Хода, бәхетле генә яши күрсеннәр. Барлык авыл кызлары кебек Минҗамалга да, ай-һай, күп газаплар кичерергә туры килде. Калган гомерләре газапсыз, тыныч, рәхәттә үтсен иде инде...

* * *

Бер көнне иртән Саҗидә Миңнурны елмаеп каршы алды:

—Күрдеңме яшьлек мәхәббәтеңне?

—Юк, беркемне дә күрмәдем әле. Анысы кем инде тагын?

—Соң, әле яңа гына шунда иде бит Әсәдуллаң...

—Әле ул да исәнмени?

Соңгы сорауны Миңнур сүз рәвеше өчен генә әйтте. Әсәдулланың исән-сау булуы, аның сугышта катнашмавы, паровоз машинисты буларак бронь белән калуы, Түбән Тагилдан Свердловскига эшелон-эшелон сугыш кораллары ташуы, бүген исә бер заводта механик булып эшләве турында ишетеп торды, чөнки Нәгыймә абыстай олы улының тормышына Миңнурның һич тә битараф булмавын истә тотып сөйли иде бу яңалыкларны. Үзеннән сигез яшькә олы бер хатынга өйләнеп, кызлары тугач, хатын ниндидер бер кырын эше өчен хөкем ителгән дә, Әсәдулланың кулында яшь тә җиде айлык Нуриясе калган. Кыскасы, яшьлек җүләрлеге белән ялгышкан Әсәдулла шул ялгышлыгы өчен иза чигә. Аның да хәзер Миңнурның кулын сорап кайтуы түгелдер бит? "Ярар, килсен, очрашыйк, сөйләшик, мин аңа үпкәмне әйтеп җибәрермен",—дип уйлады Миңнур. Шулай дип уйлап та бетермәде, бусагада Әсәдулла пәйда булды. Үзгәргән: тазарып, олыгаеп киткән, йөзе дә бала-чаганыкы түгел—кырысланган. Шулай да, елмаюы матур үзенең...

—Син мине ачулана торгансыңдыр инде,—диде Әсәдулла гади генә итеп.

—Каян беләсең?

—Ишетә торам. Язалар бит...

Хак: тормышы бозылган Әсәдулланың тагын Миңнур каршына кайтып тезләнүе икән бу.

—Инде икебез дә бер ялгыштык, тагын да ялгышырга димәгәндер. Шуны бел: Ходай сине миңа язган!

—Минем вәгъдәм бар...

—Беләм вәгъдәң барын. Мин, синең яшьлек дустың, Мифтах абзыйга биргән вәгъдәңдә торуың өчен алдыңда баш иям, моңа чиксез сокланам, шуңа сине хөрмәт итәм, яратам. Мин дә синең кебек тугрылыклы хатыным булуны телим. Калган бөтен тормышымны сине бәхетле итүгә багышлармын. Теләгемә каршы килмә!

—Вәгъдәм бар, Әсәдулла, вәгъдәм... Әле тагын берничә ел көтәсем бар. Әнә бит, уйламаган-нитмәгән кешеләр кайтып-кайтып төшә авылга. Имам абзыйны гына алыйк...

—Соң, Миңнур, һәлак булуы турында "кара пичәт" килде диден бит. Тагын күпме көтәргә була?

—Әйе, килде. Ә кешеләр кайта. Көтмичә булмый. Мин сиңа теге вакытта да бер ел булса да көт дигән идем. Синең сабырлыгың җитмәде, киттең дә... өйләндең. Хәзер менә шуның җәзасын аласың,—диде Миңнур, элеккеге үпкәсен Әсәдуллага әйтеп.—Инде тагын ялгышмыйм дисәң, сабыр итеп көтәргә кала. Теге вакытта без икебез дә артык яшь, бала-чага гына идек, аягыбызга сыер басмаган иде. Хәзер без олы дөньяны күргән кешеләр. Әйтсәм әйтим, мин синең теләгеңә каршы түгел. Ләкин син дә мине аңларга тырыш...

Әсәдулла Миңнурны ничек кенә күндерергә теләмәсен, килеп чыкмады—китеп барды. Әмма бу юлы ул өмет уты кабынган килеш китте. Әнә бит, Миңнур: "Әйтсәм әйтим, мин синең теләгеңә каршы түгел",—диде ич. Әллә шуңамы, озак та үтмәде, Әсәдулла тагын кайтып төште. Шул кичне, бүләкләр, күчтәнәчләр тотып, Нурислам карт белән Фәрхинур карчык йортына килеп керде, җылы итеп исәнләште, хәл-әхвәл сорашты, үзенең уй-ниятләрен, теләген әйтеп салды, фатиха бирегез, без Миңнур белән язмышыбызны бәйләргә булдык, диде. Миңнур медпункттан кайтырга өлгермәгән иде, кайтып керде дә:

—Ашыкма, Әсәдулла, ашка пешәрсең... Мин Мифтахны көтәм. Төшләрне бик матур күрәм: исән ахры. Бәлки кайтып төшәр... Тагын бер ел гына көтим инде,—диде, Әсәдулланы тәмам аптырашта калдырып.

Аннан соң кайткач та Миңнур Әсәдуллага шул ук сүзләрне әйтеп, борып җибәрде. Әсәдулла да олы сабырлык белән Миңнурның уңай җавап биргәнен көтте. Аны тирән ихтирам, хөрмәт итеп көтте. Әйе, дәһшәтле яу кырында башын салган иң якын кешесе—иренә биргән мөкатдәс вәгъдәсен соңгы чигенә чаклы намус белән үтәп, бар көчен, бөтен сабырлыгын, көне-төне сызлаган-сыкраган йөрәк ялкынын биргән изге затны ничек хөрмәт итмисең дә, ничек ригая кылмыйсың?..

* * *

Эш күп булганга, Миңнур медпунктка бик иртә төшә. Йөгереп кенә Кизләүдән су

алып кайта, идәнне юып, бүлмәләрне сафландырып ала, дәвалау җиһазларын кайсын кайнатып, кайсын болай гына чистартып, тазартып, әзерләп куя.

Бер иртәне шулай медпунктка барып керүе булды, дәвалау бүлмәсендә Сажидәнең кара коелып утырганына гаҗәпләнде. Гадәттә, аның кәефе һәрвакыт күтәренке була, елмаеп каршы ала

—Нәрсә булды, авырыйсыңмы әллә?—дип сорады Миңнур, табибәнең хәленә кереп.

—Әнә, кара әле бүлмәне,—диде табибә, үзе яши торган якка башы белән изәп. Керсә, тәрәзә ватык, идәндә пыяла ватыклары белән бер зур таш ята.

—Кайчан булды соң әле бу?

—Төнлә... Йөрәкләрем ярылды. Тегенекеләрнең берсе инде—хатынымы, әллә малаемы?..

Миңнур: "Ташла әле шул якырыйны[2], беткәнмени сиңа торырлык ир заты?"—дип әйтмәкче иде, сабыр итте, табибәнең яралы күңеленә каты орынырга кыймады, фәкать: "И-и, Сажидә апа, Сажидә апа...",—дип, күп мәгънәле итеп көрсенеп кенә куйды. Сажидә аны аңлады әлбәттә, аңламый калмады.

—Син хаклы. Юк, юк, бетте! Башкача мин аны яныма да сөртелдермәм. Югыйсә, болай да бик якын җибәрмим бит мин аны. Тик... Сөйкемле сөяге бар шунын, сөйкемле сөяге... Әллә ничек, яратып җибәрдем... Ялгышам—шуны аңладым. Хәзер бетте...

—Аны күптән шулай итәсе иде, Сажидә апа!

—Әйе, күптән шулай итәсе иде. Йомшак шул мин, йомшак күңелле, кешегә каты орына алмыйм. Ә йомшак агачны корт баса. Үзем дә гаепле инде, гаепле... Үрнәк алырдай кешеләр янымда гына бит югыйсә. Сине әйтәм... Сокланып туймаслык сыйфатларың бар синең, Миңнур дускынаем. Үлгәч ун чакрымнан күренеп торырлык һәйкәл куярлык зат син. Ярый әле янымда син бар. Мине гаепли торгансыңдыр инде...

Сажидә, үзе турында йомшак күңелле дисә дә, Миңнурның үзе кебек көчле ихтыярлы иде. Миңнурның әле бер генә тапкыр да яшьле күзләрен күргәне юк аның. Һәм нәкъ шул характерын җөпләгән кебек, ул кабат:

—Ә тегенең белән бетте! Башкача син аның турында ишетмәссең. Мәсхәрә булып...

—Рәхмәт, Сажидә апа, мең рәхмәт! Дөрес эшлисең. Мин сине бик хөрмәт итәм, яратам. Гаебеңне таныдың, анысына да рәхмәт. Бер мин генә түгел, бөтен авыл, хәтта башка тирә-як авыл халкы да сине үлеп ярата, хөрмәт итә, гәрчә ишетми калмаганнардыр... Барыбер хөрмәт итәләр. Ләкин абруеңны саклау турында да уйламый ярамый. Әнә очучың һаман ялгыз яши икән бит. Яз үзенә! Кайтып алсын. Бәхетле гомер итәрсез...

—Уйлап карармын. Рәхмәт сүзеңә!

Миңнур пыялачы Илалетдин абзый янына йөгерде.

—Малайлар бер-берсенә таш атып уйнаганнар да, безнең тәрәзәгә килеп тигән,—дип аңлатты ул пыялачыга. Илалетдин абзый, озын-озакка сузмыйча, пыяла алып килде дә, тәрәзәне куеп китте.

Медпунктта иң кайнар чак—иртәнге як. Дәвалау бүлмәсе ишеге төбендәге тар коридорда иртән көн саен алты-җиде кеше була. Һәркемнең үз кайгысы: берсе кулын кискән, икенчесе аягын бәргән, өченчесенең ашказаны авырта, аягын көзән җыера, кулбашы сызлый... Берәүләр, дәва алып, китә тора, алар урынына икенчеләре килә тора. Төштән соң, йә булмаса кичке якта гына халык сирәкләнә төшә— тын алырга мөмкинлек туа. Гадәттә, бу мөмкинлекне файдаланып, Сажидә белән Миңнур тиз генә капкалап, чәй эчеп алалар. Аннары тагын эшкә тотыналар.

Нәкъ шундый вакытларның берсендә медпунктка бер үсмер малай йөгереп килеп керде:

—Әти авырый...

Миңнур малайны тиз таныды—Имам абзыйныкы ла. Сажидә белән Миңнур, хәтәр сизеп, Имам йортына чаптылар. Урамда сентябрь ахыры булуга карамастан, кояшлы җылы һәм коры көн. Мондый матур көнне кешегә һич кайгы-хәсрәт килергә тиеш тә түгел сыман. Ләкин килә икән. Имам ятакта, ах-ух килә. Күршеләр җыелган, Өммегөлсем сыктый. Сажидә авыруга уколлар кадады, төймә дарулар бирде. Тәне кайнар түгел. Ләкин йөрәгә дулап тибә. Инфарктка охшаган. Юк, аның да иң хәтәре ахры...

[2] Якырый—аксак, чатан

Иртән Имам, күрше малаен алып, Түбән әрәмәгә читән тотар өчен тал чыбыгы кисәргә төшеп киткәннәр. Шактый тал чыбыгы кискән ул, тагын әз генә кисәсе калган. Шулчак әллә ничек йөрәге кадап куйган һәм хәле бетә башлаган. Эшнең куркыныч булуын чамалап, Имам арбага менеп яткан да, күрше малаена атны куарга кушкан. Башта фин сугышында катнашып, аннан соң Германныкына китеп, камалышта калып, шул ук финнәргә әсирлеккә төшеп, авыр елларның газапларын татып кайткан, әле кырыгын да тутырмаган Имам әҗәлдән котылып калырга теләгәндер. Яшисе дә яшисе генә дә бит ул яшьтә! Тик... Әҗәлләрдән калу юк икән шул. Миңнурның хөрмәт иткән кайнагасы, һәлак булган ире Мифтахның бердәнбер туганы аларның күз алдында, санаулы минутлар эчендә мәңгегә күзен йомды. Йөрәкләрне сыкратып китеп барды аның якын күргән, үз иткән, гадел, киң күңелле, олы җанлы кайнагасы. Ул үзе дә якын күрә иде шул тол калган киленен, кызгана: “Бигрәк бәхетсез булдың инде, килен”,—дип әйтә торган иде. Инде хәзер кем аны шулай юатыр?..

* * *

Кичкә авышкан, авырулар таралышкан бер көнне медпункт бусагасында тагын берәү күренде. Утыз яшьләрдәге ир-ат:

—Миңа, сеңелләрем, Миңнур дигәнегез кирәк иде. Соңладым да инде—юлым озын булды,—дип нигәдер акланды әлеге кеше. “Әллә тагын өйләнүчеме?”—дип уйладылар бер үк вакытта Сажидә дә, Миңнур үзе дә. Юк, өйләнүче булмады. Мифтах белән иңгә-иң торып дошманга каршы торган сугышчан дусты, Мифтахның күз алдында һәлак булуына шаһит, Камышлы районының Иске Ярмәк авылыннан Әбрар атлы кеше икән.Ерак юл үтеп, һәлак булган Мифтах дустын үз куллары белән мөселманча җир куенына иңдергән кеше. Мондый кунакны олылап каршылау кирәген тиз абайлады Миңнур һәм аны Нурислам йортына алып кайтты. Кияве турында соңгы хәбәрне китергән кунак белән Нурислам карт та, Фәрхинур абыстай һәм Миңнур да ярты төнгә чаклы кич утырдылар, кунакны тыңладылар, еладылар-сыктадылар.

—Без Мифтах белән кырык икенең җәендә таныштык,—дип башлады сүзен Әбрар.—Безнең полкка Казанда госпитальдә дәваланып чыкканнан соң килеп төште. Анда сезнең белән очрашуын искә ала иде. Аны безнең отделение командиры итеп куйдылар. Бу көннәрдә икенче эшелонга күчерелгән безнең полк оборонага яңа позиция әзерли иде. Траншеялар, окоплар казыйбыз, блиндажлар ясыйбыз. Бер өч көннән эшне бетерергә чамалап тора идек. Буламы соң? Икенче көнне иртә белән карыйбыз—дошман безнең янга килеп җитә язган, йөзгә-йөз торабыз. Әй, сугыш каты булды да соң! Мондый ук каты сугышны әле минем күргәнем дә юк иде. Җиңнәрен сызганган, акайган күзле, чалшайган йөзле исерек фашистлар әллә ничә кат атакага килделәр. Ләкин без нык тордык, бирешмәдек, урыныбыздан кузгалмадык. Шунда мин безнең отделение командиры Мифтах Мәсләховның батыр йөрәкле егет, оста сугышчы, кыю командир икәнен таныдым.

Кичке якта немецларның атакасы тукталды. Сугышта ул һәрвакыт шулай—төнлә дошман ял итә, көчләрен барлый, ә иртән яңадан һөҗүмгә ташлана. Безнекеләр дә төнге тын алудан файдаланалар: кайнар ризык килә, яралыларны алып китәләр, сугыш кирәк-яракларын туплыйлар, бәрелешкә әзерләнәләр.

Әле күптән түгел генә сугыш барган кыр өстендә гадәти булмаган тынлык. Хәтта кошлар да күренми, алар бу куркыныч җирдән күптән еракка очканнар. Барыбыз да таң атканчы шулай тыныч булыр дип уйлап торабыз, төнлә йоклап алу өчен траншеяларда үзебезгә тишек әзерлибез, кайнар ботка көтәбез.

—Күңел тыныч түгел,—диде Мифтах.

—Сугышта ничек тыныч булсын инде ул күңел?—дигән булдым мин дә.

—Юк, әллә ничек эч поша...

Тагын нәрсә әйтергә теләгәндер Мифтах, шул минутта һичкем көтмәгән хәл булды. Фашистлар, үзләренең кагыйдәләрен бозып, безгә кич белән ташландылар. Аларның качып-посып, шуышып килүләрен беркем күрми калды ахры, безнең траншеяларга күктән төшкән кебек килеп төштеләр, әйтерсең лә шушы җирдә генә булганнар. Офыкка төшеп барган кояш безнең күзәтчеләрнең күзләренә тереп яктыртканга, алар дошманның якынлашуын күрми дә калганнар. Моның өстенә безнекеләрнең дә, дошман туптан атмыйча һөҗүмгә күтәрелмәс дип, дикъкате югалган булып чыкты. Көндезге уңышсызлыкка хурланып котырынган исерек фашистлар траншеяга сикереп

төштеләр дә, безнең белән изүгә-изү килеп кул белән сугыша башладылар. Каршы атып та булмый, чөнки үзебезнекеләрне атып егуың мөмкин. Хәнҗәрләр, штык, винтовка түтәсе белән сугышабыз, буышабыз. Ничек булгандыр, ул көнне безнең отделение командирына да пистолет биргәннәр иде. Мифтах якыннан торып бер немецны, икенчесен, өченчесен чөңкәйтте. Дүртенчесенең башына пистолет белән сукты, тегесе мәңгеп ауды. Аннан соң мин аның ничек сугышканын абайламый калдым, чөнки үземә дә каты чәкәләшергә туры килде. Көчкә җиңдек.

Сугыш тагын тынып калды. Күзләрем белән Мифтахны эзлим, ә ул юк. Эзләп ары киттем. Карыйм, Мифтах траншеяга аркасы белән терәлгән, күзләре йомык, авызыннан кан саркый. Әйләндерсәм, аркасында фашист хәнҗәре, сабына чаклы батырылган. Йөрәк тибешен тыңлап, кулын тотып пульсын карадым—тыны да юк, йөрәге дә типми. Шулай да, мин аны аерым алып, траншеяның иң аулак почмагына илтеп яткырдым, өстенә шинель ябып һәм төн буе саклап чыктым. Бәлки мин әйтәм, әле исәндер, үлмәгәндер. Юк, иртән дә һичбер хәрәкәтсез, йөзе дә нык үзгәргән иде. Өметем акланмады. Таң атканда, иптәшләр белән чыгып, Мифтахны снаряд чокырына җирләдек. Аннары мин, бар белгәннәремне укып, дога кылдым. Ай, шәп егет иде, харап булды. Ә миңа Ходай исән-сау кайтырга язган булгандыр. Менә аның документлары, үзегез бергә төшкән фотогыз, кесә блокноты,—дип Әбрар өстәлгә бер бәләкәй төргәк чыгарып салды.

Ниһаять, Миннур үзенең шулай озак еллар Мифтахын көтүенең заяга булуын аңлады. Әйе, үлгәннәргә, һәлак булганнарга теге дөньядан кайту юк...

Әбрарны үзенең Камышлысына иртән генә озаттылар.

* * *

Илле икенең башында Әсәдулла тагын кайтып төште. Миннурның, ниһаять, бирәсе җавабы әзер иде. Мифтахка: "Мин көтәрмен сине",—дип вәгъдә биргәненә унберенче ел китте. Тагын күпме көтәргә була? Мифтах биш ел көтәргә вәгъдәсен алды. Тагын да көтүнең файдасы, нәтиҗәсе булса иде. Юк бит өмет, сүнде ул...

"Ходай сине миңа язган",—дигән иде Әсәдулла бер кайтуында. Күрәмсең, язган инде. Теге вакытта яшьлеге белән ялгышмыйча, бер генә ел көткән булса, алар кимендә ун-унике ел бергә яши алган булырлар иде. Әлбәттә, язган булса... Юк, язмаган булган шул. Инде моннан соң ялгышырга булмасын. Икесенә дә...

Әсәдулла да сыната торганнардан түгеллеген раслады. Миннурның уңай җавабын биргәнен олы сабырлык белән биш ел буена көтте ул. Биш ел! Сабыр иткән морадына ирешкән. Аның шушы сыйфаты гына да киләчәк тормышта ышанычлы ир буласын танытты.

—Мин тагын кайттым,—диде Әсәдулла, гыйнвар суыгыннан кызарган колакларын, битләрен ышкыштыргалап. Миңнур аны аңлады: "Мин тагын кайттым. Бәлки бу юлы синең җавабың әзердер?"—дигән сүз иде бу.

—Ярар, кайткансың, бик әйбәт. Мин риза...

—Син риза? Дөрес ишетәмме мин?

—Дөрес ишетәсең, дөрес.

Әсәдулла Миңнурга тәүге тапкыр бик якын килде һәм тәүге тапкыр аны кочаклап алды. Табибә бүлмәсендә кеше юк иде—Миннур да Әсәдулланың талпынуына каршы килмәде...

Февраль уртасында никах укытып, авыл Советында язылыштылар һәм тыйнак кына туй мәҗлесе уздырдылар.

Алда аларның әле башланмаган шатлыклы-бәхетле, олы мәшәкатьле, ә кайчак, кайгылы-хәсрәтле гаилә тормышы, озын еллар көтә иде...

* * *

Аккан сулар кебек уза гомер. Аулак өйләргә йөреп, хисләр дәрьясында гизгән гүзәл яшьлеге дә, чиксез авырлыклары, кайгы-хәсрәте белән көйдереп үткән сугыш еллары да, шул сугышта югалып калган ирен озак вакыт көтү газаплары да, аннан соңгы еллар мәшәкате дә әллә кайда, артта, әйтерсең лә томан эчендә калды. Артта калса да, бүгенгедәй хәтерендә саклана алар һәм, әледән-әле искә төшеп, йөрәк маен сызып-сызып алалар.

Ә Минәхмәте дә, Мифтахы да, Әсәдулласы да еш исенә төшә аның. Уйлаганга

төшәләрдер инде, уйламаса төшмәсләр иде. Һәм еш кына аларны төшләрендә дә күрә. Уйлары кебек, төшләре дә борчулы. Әле менә кайчан гына аның төшенә арчи керде. Гел кырык беренче елның быелгыдай салкын яңгырлы язында төшкән арчи инде! Атлар гына ак, кырык бердә алар башка төсләләр иде. Атлар гына түгел, тарантас та ак япмага төрелгән. Мифтах та, кияү егете дә, хәтта гармунчы да ак киемнән. Гармунчы гармунын уйный. Миңнурга бик таныш көйне уйный ул. Гармун тавышы да бик таныш. Йа Хода! Минәхмәт бит бу! Ләкин Миңнур аны барыбер танып бетерә алмый азаплана, чөнки Минәхмәтнең йөзе танымаслык булып үзгәргән, боек. Кайгыдан шулай үзгәргәндер инде ул, Миңнурның башкага чыгу кайгысыннан. Миңнур аңа якынрак килә имеш, һәм: «Хәлең ничек, кайда югалдың?» — дип сорый. Минәхмәт эндәшми, кулын гына селти, гүя ул: «Сорашма, шәптән түгел», — ди. Аннары ул, гармунын тартып, җырлап җибәрә:

Биек тауга менмәс идем —
Биек тауда атларым;
Кычкырып җырламас идем —
Бик ямансу чакларым...

Ак киемле кияү егете дилбегәсен баш очында болгый-болгый, ак аргамакларны куалый. Ә Миңнур: «Кума инде, тый, тагын тәгәрмәчебез күчәреннән чыга бит», — дип ялвара. Ә Мифтах: «Юк, төшми, син бит вәгъдәңдә тордың, шулай булгач төшми»... — ди, имеш. Шул урында Миңнур уянып китте. «Әстәгъфирулла! Өнемме бу, әллә төшем генәме? Булса да булыр икән...» Уянса да, колагына Мифтахның йомшак, назлы тавышы ишетелгән кебек тоелды: «Бер дә юкка гына яратмадым инде мин сине, белдем ышанычымны акларыңны»...

Миңнур, әлеге төшне яхшыга юрап, торып дога укыды, яшьләнде-ямьләнде, аннары, тынычланып, моңсу гына елмаеп куйды. Мифтахы төшенә тагын матур керде, шуңа елмаю балкыды аның җыерчыклы, ләкин һаман түгәрәк, якты, ягымлы йөзендә...

### *Соңгы сүз*

Бу әсәрнең геройлары—күпчелек реаль кешеләр. Алар минем авылым Елховойда яшәгәннәр, кайберләре бүген дә яши. Төп герой—Палта Миңнуры: ул бүген дә исәнсау, быел аңа, озакламый, сиксән яшь тула. Әйе, Миңнур апа үз авылының тере легендасы, горурлыгы, чын-чынлап тарихи шәхес. Хәзер аның яшьлек елларындагы матурлыгын тирән сырлар баскан, чәчләренә ак бәс төшкән.

Ах, аның гүзәл яшьлеге!.. Искиткеч матур, уңган, чиста-пөхтә... Хан кызлары да алай ук гүзәл була алмаганнардыр. Урамга, йә булмаса кизләүгә суга чыкканда, медпунктка эшкә килгәндә авыл халкы аңа соклануын яшерә алмыйча карап тора иде. Юк, аның тышкы матурлыгы гына түгел, эчке дөньясының, күңел байлыгының, башка бер кешедә дә булмый торган күркәм сыйфатларының аклыгын, пакьлеген танып, шуңа сокланып карап тора иде халык Палта Миңнурына.

Әсәдулла да, Миңнурның үзе кебек, сүзендә торучан, үҗәт, тормышка тешетырнагы белән ябышкан кеше булган. Сүзен дә сөйли белгән, эшкә дә уңган—кулыннан килмәгән эше булмаган: ул токарь да, эретеп ябыштыручы да, механик та, балта остасы да, пыялачы да... Эштән кайткач та тик тормаган, нәрсәнедер төзәткән, нәрсәнедер үзгәрткән, шомарткан, буяган.

Башта Миңнур Әсәдулла белән Түбән Тагилга китә. Шунда бер ел яшәп, беренче балалары Рәйсәне тапкач, сагынуга түзә алмый Миңнур, туган якка кайту турында сүз кузгата. Әнә шулай алар кабат туган авыллары Елховойга кайтып төшәләр. Әсәдулла колхозда механик булып эшли башлый. Эшен белеп эшли ул, авылның абруйлы кешесенә әверелә. Рәйсәсе артыннан Рәисе туа, аннары Рәфисәсе, Ринаты, Рамиле. Алтынчыга Әсәдулланың беренче хатынынннан туган Нурия даими кайтып йөри. Ул әтисен генә түгел, аның яшь хатыны Миңнурны да үз анасы кебек якын итә. Бу Әсәдулла өчен дә, Миңнур өчен дә иң бәхетле еллар була. Балалар үсә торалар, бер-бер артлы укырга китәләр. Өй, йорт эшендә кан кайнашалар. Миңнур үзе дә вакытлыча бүленгән эшен дәвам иттерә—көнкүреш комбинатына куфайкалар, күлмәкләр, туннар, курткалар тегә, матрацлар сыра.

Унган хатын кар өстендә казан кайната. Гомер агышында анын эшләмәгән эше калмаган. Сугыштан соң авыл ашханәсендә официант булган, аннары колхозда бригадир ярдәмчесе итеп куйганнар. Озак кына вакыт фельдшер-акушерлык пунктында санитар булып эшләгән. Колхоз эшенең исә ниндиен генә башкармаган ул. Печән әзерләгән чорда чалгыны ин оста көйләүчеләрнең берсе Миннур булган. Утын әзерләргә барыр алдыннан пычкыларны тешләргә, үткәрергә, тешләрен аерырга да әллә кемнәргә ялынып йөргәне булмаган, үзе үткәргән, үзе аерган. Авылга газ килгәч, сеңлесе Минхәят белән бик күп авылдашларының утын мичләрен сүтеп газга көйләп салганнар. Бәлки шунадыр, Нурислам карт: "Минем кызларым арыслан кебекләр",—дип горуланып йөргән.

Әсәдулла белән Миннур утыз елдан артык бәхетле гомер кичергәннәр. Ире ир булган, үз сүзендә торган, хатынын бәхетле итү өчен булдыра алганның барысын да эшләгән. Бер генә мәртәбә дә начар сүз белән эндәшмәгән, хәтта тавышын да күтәрмәгән, ихтирам итеп кенә яшәгән, хәрмәтеннән, игътибарыннан ташламаган. Шунысы кызганыч, иртәрәк киткән ул дөньядан...

Миннур апа аңа багышлап шигырьләр яза:

Урманнарга барып, аланнарда
Җиләк җыйган идек бергәләп;
Шул чакларны искә төшерәм дә,
Бәгыремне китә телгәләп.
Икәү бергә йөрербез әле дип,
Уйсу жиргә сукмак салдырдың;
Тик син генә минем кадерлем, дип
Йөрәгемә язып калдырдың...

Алты бала, килен-кияүләр, унөч оныж-оныкасы бар анын. Инде сиксәнен тутырып килсә дә, һаман үткән гомернең һәрбер мизгелен кабат-кабат искә ала, уйлана, сызлана, моңлана.

Минҗамал белән Потый Шәфикъ та бәхетле яшәгәннәр. Минҗамал апа ике ул табып үстергән. Хәзер аларның да уллары һәм кызлары, кияүләре-киленнәре, оныконыкалары дөнья иңләп киләләр. Тик Шәфикъ абзыйның гомере озын булмаган. Минҗамал апаның дөнья куйганына да хәзер ун ел икән.

Сәҗидә табибәнең прототибы безнең авылда ялгызы сиксән яшькә чаклы яшәде. Халыкка күрсәткән күркәм хезмәте дәүләт тарафыннан бик югары бәяләнде—аңа Ленин ордены бирелде. Соңгы юлга аны олы хөрмәт белән биш-алты авыл халкы бергә җыелып, бөтен урам тулып озатты. Аны ислам йолалары белән соңгы юлга әзерләүчеләрнең берсе, әлбәттә инде, гомерлек дускынае Палта Миннуры иде.



**Мөхәммәт Мирза**

# ЯКТЫРТМАКЧЫ БУЛСАҢ ХАЛЫК КҮҢЕЛЕН

ГАЗӘЛЛӘР

***

**Коръән, бел, хаклык үрнәге—бердәнбер,**
**Раббым мәңгелек нурына төргәндер...**

**Дәгъва кылып дөньясына, малына,**
**Тәкәбберләр инкарь итеп, көлгәндер.**

**Санламый бер хәдис, аять, сүрәсен,**
**Мин-минлеген фәкать алга сөргәндер.**

**Кодрәте зур: гыйбрәтләр ал, и Мирза,**
**Кайсы кайда ни газаплар күргәндер.**

**Рәхмәте киң: ярлыканып меңнәре,**
**Тәүбә кылып, Хак юлына кергәндер.**

**Яралган җан—хозурында бер Хакның,**
**Фани дөнья—саваплар өченгәдер?!.**

***

**Үтеп бара заман, тузган чал чәче,**
**Таныйм аны: ул бит бабам яшьтәше.**

**Салкын көздә бергә килделәр җиргә...**
**Җирдә купты канлы җәнҗал—җир өчен...**

**Аямады кардәш, кавем бер-берсен,**
**Кот, иманы чыгып качты—җен эше?..**

**Ана улны, ата кызны белмәде:**
**Көпә-көндез кылынды бар төн эше.**

---

Мөхәммәт МИРЗА (1953) — *шагыйрь; "Турайгыр", "Киек каз юлында" һ. б. китаплар авторы. Казанда яши.*

Үтеп бара заман, йөзе—йөз яра:
Батып кергән кардәшенең теш эзе...

Яфрак ябар, чирәм басар эзләрен...
Тик хәтердән чыкмас кара кан исе...

***

Актарасың: һәр битеннән батыр чыга...
Алтын дисең, көмеш дисең—бакыр чыга...

Катламнарда казындисаң, янган шәһәр,
Сынган кылыч, киселгән баш—сабыр, чыда!..

Таш кыяда, мәгарәдә тамга-сыннар,—
Асылына төшенгәнчә акыл чыга...

Тузга язган, уйган ташка елъязмачы,
Бәхәс, ызгыш куптарасын уйламыйча...

Дәгъва кыла, гаугa кора галим—шаман,
Күрәзәче, сихерче һәм багучыга.

Хаҗәте ни, дан-шөһрәте кисекбашның...
Тарих—кизәк, кагылдисаң—исе чыга...

***

Килгәнсең дә төпләнгәнсең бу якта,
Ризалык та сорамый бездән хәтта...

Чир үтсә дә, гадәт кала диләрме,
Әр-җанҗалсыз тормыйсың бер сәгать тә.

Көнче дисең, мескен дисең халыкны,
Телисеңме булуын шул халәттә?

—Юләр,—дигән саен акыл артмый ул,
Сүзләмәктә—булыйк әле әдәптә...

Туганына тапмаган бер җылы сүз,
Үзе кала мескен үк кыяфәттә...

Яктыртмакчы булсаң халык күңелен,
Якынай һәм бул олы мәхәббәттә!

***

*...Әйләнә сәхнә, әйләнә,*
*Сибелеп кала еллар...*
Р. Фәйзуллин

Җир—тоташ бер сәхнә, тора әйләнеп,
Күренешләр бер-беренә бәйләнеп.

Суырылып килеп керә сәхнәгә
Котып, чүлләр... көз, кыш, язы, җәйләре.

Алышына ничек моң, зар—тамаша,
Төсләр, хисләрдән китә баш әйләнеп.

Уенчылар—патша, ханнар, вәзирләр,
Җарияләр, коллар кала шәйләнеп...

Бәрелешә холык, акыл, ихтыяр,
Сөю—мәкер, сагыш—нәфрәт, хәйлә бит...

Күкләр хөкемендә бөтен тамаша...
Тукталмасын, мәңге торсын әйләнеп!..

***

Газәл—гүзәллек бакчасы, уз, сылу:
Гөлләр сәламли, кулларың суз, сылу;

Сафлыкка чумган мең төсле манзара
Чакырып тора, икеләнмә—уз, сылу;

Тиңнәрең бар да: сызылган җәя каш,
Иреннәр—ачылган бөре, бүз сылу;

Тик тәкъдирдән кем дә китәлми качып,
Көнчеләр күзе көйдерер—түз, сылу;

Мәрхабәдән бер адымда—мәсхәрә.
Зинһар үзеңә бул колак-күз, сылу...

Тиңе юк бәхет—сафлык һәм матурлык...
Газәл—гүзәлләр бакчасы, уз, сылу!..

## Кыска шигырьләр

Бер Хакның ихтыярында:
Мәңгелек тәгәрмәчендә—
Читлектәге тиен кебек!—
Әйләнеп тора Кояш, Җир...
...Туктап калмасын берүк!..

***

Үч кодрәте аң-зиһенне томаласа,
Асыл затлар басылыр, йә асылыр...
Мисал дисәң—күз алдына килеп баса
Утыз җиденчесе үткән гасырның...

***

Күңеле каты кителгәнме...
Кызып ташлап кителгәнме?..
Шуңа җиде ят җирләрдә,
Зәһәрдән-зәһәр җилләрдә
Гомеркәйләр ителгәнме?..

## Моң

Җаннан бүленгән халәт—моң,
Җаннарга җитәр өчен.
Җырга-көйгә әверелеп,
Галәмгә китәр өчен...

Җаныңны тыңлап кара да,
Моңлан әле, и кешем:
Дөнья фани. Моңлы мизгел—
Мәңгелекнең бер төше...

***

Уеңда ни, гамәлеңдә,
Каләмеңнән ни тама?—
Барлап, белеп тора галәм—
Бер кыенлык юк аңа...

***

Беркем берни белмәс,—димә,
Беркем берни күрмәс,—димә...
Кемдер белеп, күреп торыр:
Каптырырга кармагына
Форсат кына көтеп торыр...

***

Гөнаһлардан арала, Бер Ходам,
Нәсел ыру, бала-чаганы...
Сакланганны саклаганың беләм,
Белә торып,
Онытып җибәрәм шул—чаманы...

***

Кояш—бер генә...
Күпме балкысаң да—
Син тиң түгел кояшка...
(Ул да оялып, кызарып,
Офык артына кача...)
Ай—бер генә...
Ул да: бер тула,
Бер кечерәя бетә...
Кеше булуга ни җитә?

***

Көмешкә бактым—күрдем үземне,
Алтынга бактым—күрдем үземне...
Күз алмаңа бактым—
Күзләрем камашты...
Шул көннән—белештермим үземне...

## Үр

Үр—тәүге корылма, димме?—
Тоткарлаган үтә җилне,
Борган—ташып аккан суны,
Йоткан—төзәп аткан укны...

***

Әле язлар төшкә генә керә,
Хөкем итә кырлач салкыны...
Боз-пыяла эчендә тал-бөре,
Өметемнең кузы-ялкыны...



Рашат
Низами

# БЕР МОГҖИЗА МИҢА ЕЛМАЯ...

## Төнге талпыну

Күзәтәм күкләрнең түрендә
Тын гына Ай-балык йөзгәнен...
Йолдызлар яшертен үбешә —
Бардыр бит синең дә күргәнең?

Атылган йолдызның эзләре
Акбурдай сызылып калганда,
Нәрсәдер сызылып кала бит
Шулвакыт безнең дә җаннарда!

Әллә соң бу шулай галәмнең,
Кешенең үзара сөйләше?
Миллион чакрымнар эченнән
Кардәшем куя күк эндәшеп.

Таралып китә дә гамьнәрем,
Әйләнеп кайталар кабаттан.
Арышлар исемә төшә дә,
Җирдәге хисләрне яңартам.

## Беренче көртләр

Ноябрьнең кыл уртасы иде,
Ә кыш җиргә карлар йөгерткән.
Йорт-рәшәткә буйларында инде
Балкып тора беренче көртләр.

Кичке тынлык... Эңгер-меңгер иңгән
Авыл читендәге йортларга.
Ай тулышкан чакта кыз балага
Кирәкме соң ятып йокларга?

---

Рашат НИЗАМИ (1950) — *шагыйрь, прозаик; "Кызыл җәй", "Йолдыз яңгыры" һ.б. шигырь китаплары, "Ут һәм җыр" исемле роман-хроника авторы. Казанда яши.*

Утларыңны кабыз, әйдә, кызый,
Карамыйча гайбәт-чүпләргә.
Кеше күләгәсе төшсен әле
Тәрәз каршындагы көртләргә!

Тәрәзәгә якын килә егет,
Капшап карый аның йөзлеген.
Ник дәшми кыз... Грипп котырган чак,
Ята микән әллә өзлегеп?

Көрт эчендә аунар иде егет,
Татлы-уртак сүзләр табылса;
Бер могҗиза булыр иде — әгәр
Бармаклары белән кагылса!

Бу — мин идем. Сине сакладым.
Унсигез яшь, юләр чакларым...

## Үткәннәрдән истәлек

Куе чәчләреңдә синең
Коенган чак бар иде.
Бөтен тылсымнарың белән
Сөеп туймас яр идең!

Күпме еллар үтелгән —
Толымнарың сүтелгән...

Күпме юллар үтелгән —
Алар бар да сүтелгән...

Йолдызлар адашып беткән,
Тоныкланган ае да.
Сүтелгән, ахрысы, безнең
Мәхәббәт сарае да...

## Ялгызлык

*Сиңа...*

Үз-үзеңә патша булып
Яшәп кенә ятканда,
Әллә ниткән бер кигәвен
Килеп керә арага.

Бызылдый, аркага куна,
Тынгы бирми уеңа.
Очлы борынын батырып,
Каның белән туена.

Яшертен бер көч җаныңны
Урталай ярып төшә!
Алсу-якты хыялларың
Упкынга барып төшә.

Ашауның тәме китә дә,
Яме китә яшәүнең.
Беркемгә дә кирәкмәс күк
Синең күкрәп яшьнәвең.

Нәрсә бу? Куркып калумы,
Әллә сагыш ташлары
Рухны сындырмак буламы
Кинәт шулай ташланып?

Башымнан сыйпады бугай,
Рәхмәт инде дөньяга, —
Аудым дигәндә, чү, миңа
Бер могҗиза елмая!

Мин керәсе карурманда
Учаклар күп, күрәсең.
Могҗиза булып елмая
Ерактагы сурәтең.

## Узып барышлый

Киндери, Яшел чирәмлек.
Беләкләрен уйнатып,
Бар дөньясын оныткандай,
Керләр элә бер хатын.

Кояшка үрелгән саен
Итәгенә җил бәрә.
Керләре белән гүяки
Уйларын да җилгәрә.

Җәймәләрен ап-ак иткән —
Күпме көчен түккәндер!
Җир шарында басып тора
Кояш белән бермә-бер.

Уйнак-житез кулларында
Күпме гайрәт бар сыман.
Кирәксә, нәҗес дөньяны
Агартып юар сыман.

Өендә ни: балалары
Караватта тәгәрәп
Ята микән?.. Мәхәббәте
Була күрсен түгәрәк.

Ә ире яшрен ләззәткә
Качырып төрә микән, —
Шундый япь-яшь хатынының
Кадерен белә микән?

Киндери. Яшел чирәмлек.
Киткән идем күз атып,
Ак җилкәндәй җәймәләре
Калды мине озатып...

## Абыну

Күзләремне текәп бер карасам,
Мин шигырьгә килеп абынам.
Илдә берәр ялгыш җибәрелсә —
Дары кебек дөрләп кабынам!

Нигә һаман бәя күтәрәләр,
Илне күтәрәсе урында?
Салымнарның әллә ничәмәсе
Чиртеп кенә тора борынга.

Чиновниклар чинап симерәләр,
Ә халыкның тишек кесәсе
Җилфер-җилфер килә...
Бу хәлләргә
Син, хакыйкать, ничек түзәсең?

Тукта, каләм! Мондый моң-зарлардан
Тетрәп тора инде һавабыз.
Чөкердәшеп яшәсеннәр, диеп
Җиргә безне яраткан бит ласа
Адәм белән Хәүвабыз.

Ил ялгыша, имеш... Уйлап баксаң,
Үземдә дә хата җитәрлек
Һәм синдәге хаталарны кушсак,
Башың, бәлки, Себер китәрлек!

Эшчеме син яки депутатмы,
"Тәртип!" диеп чакыру ташларга, —
Астан алып өскә кадәр, димәк,
Үзебездән кирәк башларга.

Күз текәп бер карыймын да кайчак
Матурлыкка килеп абынам.
Ә шулай да, илдә хата китсә,
Дары кебек дөрләп кабынам...

***

Рәшә кебек алдавычлар була.
Тормышта да азмы миражлар!
Ялган дигән эреле-ваклы нәрсә
Үрчи бездә кайчак тиражлап.

Дөреслек ул — кайнар бәрәңге күк:
Ташлап булмый, тотсаң — пешерә.
Дөрес яшәү фәнен кабат-кабат
Өйрәтәселәр бар кешегә!

Кемнәр нинди хәлдә калыр икән
Сирень агачыдай талангач...
Бозлар кебек бар да эреп бетә,
Бер хакыйкать кала ялангач.

## Мәрсия

*Вакытсыз киткән җаннарны,*
*Әй, килә кайтарасым!*
Харрас Әюп.

Ходай рәхмәт бирсен хатын-кызга:
Эштән бушап тормый куллары.
Таңнан торып, алар эзе белән
Чуарлана ферма юллары.

Өйдә тагын мең мәшәкать көтә,
Кышын — маллар, җәен — чебиләр.
...Офык буйлап кая таба бара
Бәхет күрми калган әниләр?

Шәһре Казан.
Мәчет эргәсендә
Басып тора әби-карчыклар.
Өметләре — сыңар бер сәдака,
Күзләр арган, йөзләр талчыккан.

Окоп казып сугыш елларында
Аяк-куллар чыккан "чебиләп".
...Шәфәкъ буйлап кая таба атлый
Бәхет күрми калган әбиләр?

## Сыерчык оясы

Бүрәнәле агач йортның
Түбәсендә, очында
Чут-чут итеп сайрый-сайрый
Бер сыерчык очына!

Хуҗа — балта остасыдыр:
Тактасын мач китереп,
Нинди оя ясап куйган
Көнләшерлек иттереп.

Көнләшә чыпчык: көзләрен
Сыерчык китү белән,
Шул тирәдә кайнашалар
Парлап йә көтү белән.

Егыла чыпчык сыерчыкның
Каурыена абынып;
Һаман сакау килеш кала
Сыерчыкның оясында
Яшәсә дә ябынып...

***

Печән чабам. Уйлар ерак китә...
Күңел сагыш белән тулганда,
Мин — яраткан аланыма киләм,
Чишмә исе аңкый урманда.

Тешне сындырырлык суларыннан
Авыз итәм. Битне чайкыймын...
Тоям — агачларның шаулавында
Гасыр моңын, еллар шаукымын.

Фәлсәфи бер уйга баткан сыман,
Абагалар гына тын тора.
Җилләр түгел, корыган агачларны
Еллар авырлыгы сындыра.

Яшәү — гаҗәп серле. Язмыш сиңа
Шундый итеп кайчак тондыра!
Кешеләрне, йомшак кешеләрне
Тормыш авырлыгы сындыра.

*Җиңүнең 60 еллыгына*

# СОҢАРГАН СӘФӘР

Ямьле язлар да үтеп китте. Россия халкы кабат Бөек Җиңү бәйрәмен билгеләп үтте. Сугыштан исән кайтып, бүгенгә кадәр сау булганнар мәртәбәле очрашуларда катнаштылар, тыйнак кына котлаулар алдылар.

Ә сугыштан кайта алмаганнар?..—Туган җирләрендә аларның истәлегенә исемнәре чокып язылган бер таш тора. Икенче таш алар һәлак булган төбәктә—берничә мең кеше сөяген җыеп, шуның өстенә урнаштырылган. Мондый ташлар минем туган төбәгем—Азнакай районы, Үчәлле авылы уртасында да һәм шуннан фронтка киткән әтиемә кабер булган Тверь өлкәсе, Ржев районы, Погорелки авылы янында да бар. Беренчесендә сугышта һәлак булган үчәлләләр исемлеге язылса, икенчесендә Погорелки авылы тирәсендә барган сугышларда һәлак булган сугышчыларның дивизияләре, полклары, берләшмәләрнең исәп саннары гына төшерелгән. Ул номерларның саны да өч дистәдән артык. Бүген сиксән биш мең кеше яшәгән Ржев районында ул чакта барган каты сугышларда йөз егерме алты меңнән артык сугышчы һәлак булган. Яраланганнарның һәм шул ялалардан үлгәннәрнең саны билгесез. Хәзерге әфган яки чечен сугышлары буенча күтәрелә торган мәгълүматларда яралланучыларның саны үлгәннәрнекенә караганда өч-дүрт мәртәбә артык булуын искә алганда, миллионнарның газизләре шушы Ржев җирләрен саклап туфрак булган дигән сүз.

Менә шулар турында уйланып кайттым мин Ржев—Казан юлында, әтием сугышта һәлак булган җирләрне манзара кылгач. Мин сугышып түгел, "сугышта һәлак булган" дип юкка гына әйтмим. Ул җирләр, аянычка, хәрби дан урыннары түгел. Чөнки кырык бернең ахыры—кырык икенең башында немец танклары, колонналарына каршы эшелон-эшелон китереп башланган коралсыз-нисез совет солдатлары ялан кырда—бомбалар ташкыны астында калып, яки юлда бомбага тотылып көл-күмер ителгән.

Мин үзем күптән инде әтидән өлкән яшьтә. Хәзер улларым һәм кызым да дәү әтиләре яшенә җиттеләр. Гаҗәп бит. Әткәм яшенә җиткәнче җаваплы эшләрдә эшләп, шул вакытта ук үземне өлкән яшьтә тоеп йөрсәм дә, әле бик яшь булганмын икән. Әти яше—аның гомере өзелгән яшь ул. Әтием Кәшиф, белешмәдә язылганча, 1942 елның 15 мартында Калинин (хәзерге Тверь) өлкәсе, Ржев районы Черново авылы тирәсендәге сугышларда, хәрби антына тугры килеш, кырык өч яшендә һәлак булган. Инде үзем балалар атасы, оныклар бабасы булуыма карамастан, аның рухы алдында үземне нарасый кебек хис итеп, һаман да күнелем сагышлана.

***

"Исәннәрнең кадерен, үлгәннәрнең каберен бел", ди халык. Бу изге әманәтне яшьтән үк күңелемә сеңдерүемә карамастан, аны вакытында үти алмадым. Күп еллар әтинең каберен зиярәт кылып кайтырга омтылып йөрсәм дә, башта дөнья мәшәкатьләре, соңрак авырулар мөмкинлек бирмәде. Ниһаять, Ржев районы хәрби комиссариаты белән алдан элемтәгә кереп юлга чыгарга булдым. Хәрби комиссариаттан: сугыш кырларын карау һәм сугышчылар каберлеген зиярәт кылу өчен иң кулай вакыт—9 май—Җиңү бәйрәме көне, ул көнне туганнар каберлегендә очрашулар, митинглар уздырыла, дип хәбәр иттеләр.

Нинди икән ул—бик каты сугышлар узып, безнең газиз әтиләребез башларын салган җирләр? Меңнәр гомерен корбан иткән төбәкләрдә бүген төзек авыллар, шәһәрләр гөрләп утырадыр. Басу-кырлар матур итеп җиренә җиткереп эшкәртеләдер. Андагы халык мул тормышта рәхәтләнеп яшидер. Минем уйда—шундый өметләр иде. Юлдашларым—улым Айрат һәм оныгым—Таһир гына ул хыялларга ышанып җитмәгәннәрдер, мөгаен. Үткән сугыш булып узган җирләрнең бүгенгесе өлкәннәрдә һәм яшьләрдә ике төрле тәэсир тудыруы гаҗәп түгел. Ул нигездә туган бәхәсләрне язу катлаулы. Ул—буыннар арасындагы мөнәсәбәтләргә барып бәйләнә. Мин бу язмамда үземнең кичерешләремне генә сурәтләргә тырышырмын.

## Исемдә калганнар...

Мин үзем 1937 елның июнь аенда туганмын. Әтине сугышка кыш көне озатканымны хәтерлим. Ул 1941 елның декабре булган.

Минем яшьтәшләрем! Йә, әйтегез әле, кайсыгыз шул яшьтә әтиегезне күрше авылга кадәр озата барды? Озата гына да түгел әле, бераз атны да алып бардым. Әйе, әти алдына утырып, аның кочагындадыр инде, шактый юл дилбегә тотып баруым да исемдә калган. Сугышка китүчеләр күп булгандыр, олаулар шактый иде. Без—озатып баручылар—күрше Ишкәй авылыннан кире борылдык. Атлы олаулар әтиләрне Бөгелмәгә кадәр илткәннәр. Сабур абзый хатыны Рабига түтәй сөйли иде: "Мин аларны Бөгелмәгә кадәр озатып куйдым. Яз житкәнче үк Кәшиф абзыйның, Шәйхразый абзыйның һәм Сабурның үлү хәбәрләре килгәч, авылдашлар: "Син, Рабига, өч мәет озатып кайткансың икән",—дип әйттеләр...

Тагын шунысын да уйлыйм. Дүрт яшь ярымнан атадан ятим калган малайның хәтерендә әтисе турында истәлекләр була микән?.. Малай, дим, сабый димим. Чөнки ятим бала сабыйлыктан тизрәк чыга. Әти исән чагында әти янында үткән гомер генә ул—сабыйлык. Шул бәхетле чаклар өзек-өзек кенә хәтергә уелган. Шуларның берсе—мәчет тавыннан әтинең ургычка өч ат жигеп менеп киткән көн. "Кәшиф урак башларга китте",—диештеләр капка төбендә торган түтәйләр. Бу—кырык бернең июнь ахыры булырга тиеш.

Икенче мизгел—әтинең мин ишә башлаган чыбыркыны очлап, сапка утыртып бирүенә куануларым. Аннан шул истә калган: әти эштән кайткач сәкегә тез чәнчеп ял итәргә ятар иде дә, мин, бер аның өстенә менеп, бер тез астыннан үрмәләп уйный идем.

Безнең ихатага урам аркылы гына булган бригада өендә балта остасы эшен башкарганын да онытмаганмын икән. Кыш көне аның янына бәләкәй чанамны тартып барганым, кар көрте өстеннән шуып төшкәч, агач чананың өй ишегенә барып бәрелгәне исемдә.

Иң хәтергә сеңгәне түбәндәге хәл булды. Әти үз өебездә моржа чыгара иде. Жәй көне. Өйнең ян тәрәзәсе алынган. Мин яртылаш өелгән мичкә каршы сәке өстендә утырам, янымда апам һәм әни дә бар. Әти ял итәргә яраткандыр, ул өй эчендә юк иде. Шулчак көчле яңгыр ява башлады. Кинәт дөнья яктырып китте һәм, бер утлы шар тәрәзәдән кереп, әкрен генә мичне әйләнде дә шул ук тәрәзәдән чыгып та китте. Мин куркырга да өлгерми калдым. Ул арада бик каты күк күкрәде, һәм шул ук минутта "Янгын!" дип кычкыра башладылар. Югары урам Фатыйма түтәйләрнең абзарын яшен суккан икән.

Монысы чыннан да булган хәл иде. Бәлки, калганнары ятим сабыйның сагынулы төшләре яки фантазия жимешедер. Барыбер алар минем өчен гомерем буена әти турында татлы хатирәләр булып тордылар. Шул янгыннан калган кара-күмер киртәләр без үскәндә аларның ихатасында сөялгән килеш торалар иде. Ә безнең әти чыгарган мич өебез тузганчыга кадәр чыдады. Димәк, Кәшиф Бикташев балта остасы булу өстенә, оста мичче дә булган икән, дип фикер йөртәм хәзер.

## Юлда

Без сигезенче май көнне бик иртә юлга чыгып, таң беленгәнче Идел аркылы салынган яңа күпергә килеп життек. Күпернең тимер юл өстеннән салынган турыннан үткәндә кабат әти күз алдыма килеп басты. Булачак сугышчыларны Бөгелмәдә "теплушка"ларга төяп шушы юллардан Мари иленең кара урманнары уртасында урнашкан Суслонгер хәрби лагерена илткәннәр. Бу лагерьда хәрби эшкә өйрәнергә тиешле адәм балаларының нинди авырлыклар, ачлыклар, жәберләүләргә дучар булуын без ул жәһәннәмнән һәм сугыш кырыннан имгәнеп кайтканнарның сөйләве һәм газеталарда басылган кайбер материаллар аша беләбез инде. Колхозның эш аты хезмәтенә күнеккән һәм өйләреннән таза-сәламәт чыгып киткән ир уртасы кешеләр шул лагерьга барып кергәч, берничә атна эчендә мыскыллы мөнәсәбәткә һәм ачлыкка түзә алмыйча, күпләп кырылганнар. Бу хәлләр турында хәләл жефетләре ачынып, әрнеп сөйләде. Үзләре анда булганнарның бик сирәге—меңнән бере генә сугыш кырыннан исән кайтып житә алгандыр. Аларның да авызларында "пичәт"

булды. Ә сүз ирегенә ирешкән елларда боларның күбесе фани дөньядан киткән иделәр инде.

Кәшиф Бикташев белән бергә Суслонгерда булып, сугыштан имгәнеп өенә кайткан Чаллы кешесеннән ишетүебезчә, әти мондагы вәхшилеккә түзәргә теләмәгән. Үзенең иптәшләренә: "Туганнар, без монда барыбер исән калмабыз. Монда ачтан интегеп үлгәнче, ичмасам яу кырында үлде, диярләр. Әйдәгез, безне тизрәк сугышка җибәрүләрен сорап гариза язабыз",—дигән ул. Шулай, өйдән чыгып киткәненә өч ай дигәндә, әткәбез сугышка да барып кергән, һәлак та булган.

Алга китеп шуны әйтим: Ржев район хәрби комиссариатында мин, безнең кебек, Татарстаннан әтиләренең каберен зиярат кылырга килгән ике кешене очраттым. Аларның берсе Казаннан, икенчесе Чаллыдан иде. Аларның да әтиләре Суслонгер лагерын үтеп, Ржев тирәсендә һәлак булган. Димәк, Татарстаннан алынган солдатларның күп өлеше яу кырына Суслонгер лагере аша озатылган.

Без фашистларның Европа территориясендә төзегән концентрацион лагерьлары турында язган китапларны ачынып-ачынып укыдык. Ә менә үзебезнең күршедәге Суслонгер лагере тарихын әлегә кадәр тулысынча белә алганыбыз юк. Шуны да исәпләп, сискәнеп куям: Татарстан белән чиктә лагерь корып, башлыча безнең республикадан җыелган кешеләрне туплап, йончытып, эшелоны-эшелоны белән немецларның иң зур көч белән һөҗүм иткән юнәлешенә тере калкан рәвешендә ыргыту, бәлки, очраклы хәл түгелдер. Безнең ир-егетләребез өчен беренче җәһәннәм булган бу лагерь тарихын өйрәнү һаман да гаярь йөрәкле язучылар һәм тарихчыларны көтә әле.

## Кем булган минем әти?

Мин нинди кеше баласы, дигән сорау миңа гомерем буе тынгы бирмәде. Һәркем ата-анасын абруйлы итеп күрергә тели. Яхшы әти-әнинең исеменә тап төшермәскә, аларга лаек булырга тырышу да мәгълүм.

Әтием Кәшиф Үчәлле авылында илле елга якын имам хезмәте башкарган мөхтәрәм Шәриф мулланың төпчек улы булган. Алты улының дүртесен муллалыкка багышлап, бабам әтиемне Бәйрәкә мәдрәсәсендә укыта. Ләкин заман ачысы ана мулла хезмәтен башкарырга насыйп итми. Авылның беренче комсомолы, беренче коммунисты булган Кәрәм абыйсының йогынтысы тигәндерме, әти гражданнар сугышында кызыллар ягыннан катнаша. Аннан кайткач, балалар укытырга керешә. Әмма мулланың төпчек улы булып, аның нигезендә яшәгәнгәдер, колхозлашу елларында кулак дигән сылтау табып, өч баласы һәм көмәнле хатыны белән өеннән куып чыгарыла. Кызыл сугышчы буларак, үз йортында яшәргә Казаннан рөхсәт алып кайтканда, өйләренең бер өлеше һәм түбәсе сүтелеп, күрше Стәрле колхозына илтелгән була. Аларның нәсел милке исәбенә Үчәлледә оешкан колхозда берничә ел дәвамында әтиемә дә, әниемә дә эшләргә рөхсәт итмиләр. Әтине озак вакытлар вербовкка разнарядкалары буенча төрле өлкәләргә урман кисәргә һәм башка мәҗбүри эшләргә җибәрәләр. Утызынчы еллардан башлап хакимият тарафыннан кагылган, сугылган, туган-үскән җирендә эшләп яшәргә хакы булмаган шул кеше, илгә куркыныч янагач, Ватанны саклау өчен кирәк булып чыга.

Әни аны һәрвакыт мактап һәм сагышланып: "Их, атагыз исән булса..." дип телгә ала иде. Күрше-тирә генә түгел, гомумән, авыл халкы әтине акыллы, иманлы һәм чоры өчен галим, тәрбияле, җор кеше дип хәтерләде. Хәер, мин аны үзем дә тоеп тордым.

Бәләкәй чакта әбиләр һәм бабайлар белән исемнәрен әйтеп, зурлап исәнләшкәч, арттан: "Кәшифнең малае үзенә охшаган—әдәпле бала",—дип калалар иде. Тагын шунысы: мин дөньяга өйрәнү күзе белән карый башлаганда әтидән калган бик күп балта эше коралларына юлыктым. Үз гомеремдә очраткан осталарның берсендә дә ул кадәр төрледән-төрле корал күрә алганым булмады. Ул өтергеләрнең, шомарткычларның, борауларның, пычкыларның саннары дистәдән артык булгандыр. Сугыштан соң, аларны авылның осталары, күрше бабайлар берәм-берәм әнидән сорап алып бетерделәр. Үзем агач кораллары җыя башлагач, әтинең шул байлыгы күз алдына килеп, уйланып куя идем: муллалар нәселенә андый һөнәри кирәк-ярак каян килде икән? Күрәсең, алар буын-буыннан җир кешеләре булганнар. Заманалар буталып киткәч, кечкенәдән үзләштергән һөнәрнең кирәге чыгып куйган. Әтинең район газетасында басылып чыккан фото рәсемендә аны арба тәгәрмәче ясаганда төшереп алганнар.

Мин үзем дә еш кына анын янына барып, тәгәрмәч бүкәннәренең ничек кырылуын, тәрәкләрнең ничек юнылуын кызыксынып карап тора идем. Үсмер чакта: "Әти исән булса, печән, утын ташыр өчен бәләкәй арба ясап бирер идем..." дип хыялланганым да исемдә. Хәер, әтиләр исән булса "уф-алла"лар кирәк тә булмас иде. Менә шундый өзек-өзек хатирәләргә әтиемнең яңгырап торган моңлы тавышы да килеп кушыла. Анын күкрәктән чыккан көр тавыш белән "Кара урман", "Ашказар"ларны сузуын исән калган яшьтәшләре еш сөйлиләр иде. Тимер юл вагоннарына төялеп сугыш кырына барганда җырлап барган ул. Юлдашлары: "Бу кеше үзенең кире кайта алмаслыгын сизеп җырлый инде",—дигәннәр анын турында.

*Утырдым атның биленә,*
*Киттем Герман җиренә.*
*Герман җире каты үлән,*
*Әллә кайтам, әллә үләм.*

Сугыш кырына таба баручы вагондагыларның барысы да җырлагандыр бу үзәк өзгеч татар җырын.

## Әниемнең күз яшьләре

Чын-чынлап еласаң, сукыр күздән дә яшь чыга диләр. Әниемнең бер күзе сукыр иде—яшьрәк чагында агач ботагы тиеп, агып чыккан. Шулай да китапны бик ярата һәм әллә нинди моңлы тавыш белән Коръән укый иде. Әти китеп бераз вакыт үтүгә үк әни еш кына елый башлады. Ул көндез яшен күрсәтми, төннәрен генә елый иде. Кышкы салкын өйдә сәкедә бер юрган астында ятканга анын сулкылдап-сулкылдап елаганын мин сизә идем. Башта бу хәлгә әлләни исем китмәде. Аннан миңа ишетелмәсен өчен чыш-пош әйтелгән сүзләр бераз колакка керә башлагач, аңладым: нииндидер хәтәр хәл булган, безнең өйгә авыр кайгы килгән. Апаларның да төсләре бозылды. Аларга кушылып мин дә елый башладым. Тик сәбәбен генә белмим. Әтинең нишләп алай озак сугышып йөргәнен аңламыйм. Әнә, без—малайлар—бераз сугышып алабыз да таралабыз. Иң хәтәре борын канау була. Барыбер икенче көнне бергә уйныйбыз. Кыш буена сугышкач, әти дә кайтып бераз ял итеп китсә, нәрсә була инде, дип уйлап куям беркатлылыгым белән. Якын кешеләрем белән бергә мин дә боектым. Ятимлек сабыйлыгымны басты.

## Ятимлек

Ятим төрлечә була. Тамагын тук, өстең бөтен, өең җылы, якыннарын, тирәдәгеләрең хөр күңелле булса, ягъни, бүгенгечә әйткәндә, комфортлы мохиттә яшәсәң, иң якын кешенне мәңгелеккә югалту, бәлки, көчле юксыну тойгысы белән генә аңлатыладыр. Ә югарыда саналганнарның берсе дә булмаса, әтиең вафат, әниең көне-төне эштә, апаларыннның берсе укуда, икенчесе вербовка белән читтә йөргәндә, ятимлек—сөйләп бетереп булмый торган авыр халәт икән.

Ятимлек ул, икенче яктан, яклаучысыз калу да. Колхозның иң авыр, иң унайсыз, иң тузанлы эше тол хатыннарга, әтисез балаларга төште. Әни сәнәк-көрәк сөйрәсә, олы апам Молотов (Пермь) өлкәсенә урман кисәргә, торф чыгарырга, Бөгелмәгә аэропорт төзергә, Чиләбегә чуен кою заводына җибәрелде. Өйдә булса, кышын үгез җигеп Сухаеш урманыннан утын ташырга йөрде. Ә аңа да ул елларда ни бары унбиш-егерме яшь кенә булган бит әле.

Ятимлеккә ияреп, сугыш еллары ахырына авылга кара ачлык килде. Берсе өстенә берсе өстәлгән заем, салым, лотореяләрнең меңәрләгән сумнарын түләр өчен келәттә әтидән калган ашлык сатылды. Аннан соң әтинең зур толыбы, итекләре, ястыклар, мендәрләр, сәкедәге паласлар озатылды. Без ятимнәргә ай саен килә торган кырык сум пособие дә шул салым хисабына тотылып калына иде.

Хәреф таный башлагач, миңа апаларым Тукай китабын алып биргәннәр иде. Зур форматлы, калын каты тышлы авыр китап иде ул. Ягылмаган салкын өйдә чишенмәгән килеш юрган астында үз сулышым белән җылынып ятканда, шагыйрьнең сүзләрен кабатлый идем:

*Көзге төн. Йокламый алмыйм. Өй түрендә җил җылый;*
*Җил җыламый, ач үлемнең куркусыннан ил җылый.*

Безнең ише сугыш ятимнәренең бүгенге көннәре ничек? Аянычка каршы, утнысуны кичкән ветераннар кебек, аларның да саннары азаеп бара. Күбесенең хәле ачынып телгә алырлык. Дәүләтебез дефолт игълан итеп, аларның картлыкка дип тиенләп җыйган акчаларын тузанга әйләндерде. Ә пенсия дип биргән акчалары ачтан үлмәслек кенә. Сугыш ятимнәренә әзрәк хөрмәт күрсәтергә кирәк иде, дигән фикерләр һаман сүздә генә кала бирә.

## Юлда...

Мәскәүгә машинада һәм тимер юлдан барган кешеләр беләләр: башкала тирәсен сазлыклы урманнар уратып алган. Бу якларда танк колонналарына һәм бронялы техникага таш түшәлгән каты юллардан чыгып хәрәкәт итәрлек мәйданнар юк диярлек. Безнең әтиләргә үлем келәймәсе баскан Ржев шәһәре дә, Волоколамск каласы да Мәскәү—Рига тимер һәм автомобиль юллары өстендә урнашкан. Соңгысында панфиловчыларга һәйкәл куелган. Кояш баер алдыннан гына Ржев каласына килеп җиттек. Хәрби комиссариаттагы кызу офицер безгә Җиңү көненә каралган программаны аңлаткач, автомобильне комиссариат ишек алдына калдырырга тәкъдим итте. Шәһәрдәге криминаль хәлнең катлаулы булуын кабаткабат сөйләп, кичен кунакханәдән чыгып йөрмәскә кирәклеген кисәтте.

Хәрби комиссариатның бер бүлмәсендә хәрби-тарихи музей оештырылган. Стенадагы планшетларда район картасы, каты сугышлар булып үткән урыннарның планы, төрле таблицалар эленгән. Зур өстәл өстендәге тартмалардагы картотекадан әтинең карточкасын табып алдылар. Анда солдатның исеме, туган елы, үлгән көне, урыны һәм кайда күчереп күмелгәнлеге күрсәтелгән. Шуның белән вәссәлам. Еракдардан килеп бу җирләрне яклаганда газиз башын салган сугышчыларның берсе турында да шуннан артык мәгълүмат юк. Шунысы гаҗәп: бик төпченеп карасам да, бу район җирләреннән узган сугыш турында хәрби комиссариатта җентекле мәгълүмат ишетә алмадым. Китап кибетләренә кереп эзләнүебез дә уңыш китермәде.

Хәрби комиссариатта тагын бер нәрсәгә игътибар иттем. "Б" хәрефле картотека тартмасыннан Бикмуллин, Биктагиров һәм тагын шуна ошашлы фамилияләр язылган картотекалар күп чыкты. Һәлак булучылар арасында татарлар күп булган икән шул. Вакыт кыска, хисләр буталчык булганлыктан, ул язуларны җентекләп карый алмадым. Кемнәрнең газизләре турында белешмәләр ята икән ул тартмаларда? Хәер, язып алсам да, ул хәбәрне кемгә җиткерәсең? Туган урыннары да теркәлмәгән бит ул мәрхүмнәрнең. Билгесезлектән килеп билгесезлеккә киткәннәр. Рәсми мәгълүматлар буенча, бүгенге Ржев районында сиксән биш мең, шәһәрнең үзендә җитмеш биш меңгә якын кеше яши. Аны икегә бүлеп Идел елгасы ага. Шәһәр эчендә елганың ярлары биек һәм текә, суының агымы бик көчле һәм үзе кызгылтболганчык төстә. Елга аша өч күпер салынган. Шәһәр кырыеннан көнбатыштан көнчыгышка таба Рига—Мәскәү, ә көньяктан төньякка юнәлеп, Мәскәү—Санкт-Петербург юлына чыга торган Смоленск—Торжок тимер юллары үтә.

Шәһәрнең үзәк мәйданында биек постаментка танк бастырып куелган. Үзәк күпер янындагы мәйданчыкта зенит тубы, "Катюша" һәм кырык биш миллиметрлы туп куелган. Сугыш вакытында Калинин шәһәре бары ике ай дәвамында—1941 елның 17 октябреннән 16 декабренә чаклы—немецлар кулында булса, Ржев шәһәре 1941 елның августыннан 1942 елның ноябренә чаклы—бер елдан артык оккупация астында тора. Район җирләрендә фашистларның Мәскәүне төньяктан камап алырга тырышкан "төньяк келәшчәсе" колонналарына каршы канкойгыч сугышлар бара. Бу бәрелешләрдә йөз егерме алты меңнән артык сугышчы һәлак була. Аларның җәсәдләрен соңгы елларда гына таралып бара торган авыллар кырыендагы егерме дүрт туганнар каберлегенә күчереп күмгәннәр.

Минем әти, белешмәдә язылганча, Черново авылы тирәсендә һәлак булып, шунда ук күмелгән. Район картасында ул төбәктә шул исемдәге ике авыл күренә. Хәзер бу авылларның берсе дә калмаган. Ул тирәгә барырга юл да юк, диделәр. Әлеге авыллар тирәсендәге хәрби каберләрнең калдыкларын Погорелки авылына күчереп, туганнар каберлеге оештырганнар. Бу каберлектә, әйтүләренчә, алты меңгә якын сугышчының җәсәде күмелгән.

Каберлек өч зур кабердән тора. Шуларның берсенә таш һәм аның өстенә бер кулына венок, икенчесенә каска тоткан солдат сыны куелган. Ташның йөз ягына утыздан артык дивизиянең һәм унбишләп бригаданың номерлары чокып язылган. Калган ике кабер өстендәге калкулыкка чәчәкләр утыртылган.

Үзем белән заманында әти ял итәргә яраткан карт нарат төбеннән казып алынган туфрак алып килгән идем. Туган нигездән алынган шул кара туфракны түгәрәк чәчәклек әйләнәли салып чыктым. Аксыл-соргылт төстә туфрак белән капланган каберләр читендә кара тасма хасил булды. Махсус ясалган кара тасма кебек. Авыл кешеләрен чакырып күрсәттем: күрегез, безнең Татарстан илендә җирләр менә нинди төстә! Алар бу кара туфрак тасманы күреп шаккаттылар, куллары белән тотып уып карадылар: буяу түгелме, янәсе.

Погорелки авылы анда-санда торып калган ике-өч дистә өйдән гыйбарәт. Авыл советы да, почта бүлекчәсе дә юк анда. Хәер, бу тирәдәге барлык авыллар да шулай— үлем белән яшәү арасында.

Көндезге сәгать уннарга туганнар каберлеге янына бераз халык җыелды. Алар арасында безнең кебек ерактан килгән җиде-сигез кеше бар иде. Җирле халыкны исә сугыш чорының кайгы-хәсрәтләрен кичергән авыл карчыклары белән мәктәп директоры, унбишләп укучысы һәм бер фронтовик тәшкил итә. Митингны күрше авылның җирле үзидарә рәисе алып барды, укучылар шигырьләр сөйләделәр, җырладылар, директор доклад ясады. Ватан сугышында катнашучы милләтләр арасында ул татарларны иң соңгылардан гына атап китте.

Мин үземнең чыгышымда йөз егерме алты мең сугышчы башын салган бу җирләрдә төзек, матур авыл һәм шәһәрләрдә мул тормышлы халык яши дип күз алдына китерүем хакында әйттем. Андый күренешкә юлыкмавыма үкенеч белдердем. Ржевлыларга, сезнең балаларыгыз, хезмәт куеп, бу җирләрнең йөзен үзгәртсеннәр һәм аларның киләчәге өчен һәлак булганнарның рухларын шатландырып яшәсеннәр иде, дигән теләк белдердем.

Митинг тәмамлангач, докладчыга татарларның бу сугышта кылган батырлыклары, бу милләт уллары-кызларының сугышта хәрби бүләкләр белән бүләкләнүчеләр һәм Советлар Союзы Герое исеме бирелгәннәр арасында, руслардан кала, икенче урында торулары хакында аңлаттым. Халык таралганда өч карчык минем янга килеп:

—Әллә сез яхшы яшисезме?—дип сорадылар. Мескенлек, монсулык һәм гаҗәпсенү иде аларның йөзләрендә. Ничек җавап бирергә белмичә, байтак кына сүзсез калып утырдым.

Ни дип әйтим?—"Юк", дисәм, дөрес булмас. "Әйе",—дип боларның кителгән күңелен тагын да китәргә телем әйләнми. "Бераз гына яхшырак",—дидем. Алар да Хакның бәндәсе, аларның да мул тормышка хаклары бар.

Халык таралгач, каберлек кырыендагы яшел чирәмгә кыйблага карап намазга бастым. Аннан соң озаклап Коръән укыдым. Үзем укыйм, үзем елыйм.

Яраткан шагыйрем әйтмешли, "Чишмә төсле, ихтыярсыз, акты-китте яшьләрем..." Алар ихластан иде. Тыймадым, тыелмадым. Янымда улымнан һәм оныгымнан башка кеше юк иде инде.

Соңыннан әтием рухына, бу җирләрдә бер гөнаһсызга җәберләнеп, кан коеп шәһит киткәннәр рухына дога кылдым. Кулымда әтинең үзеннән калып, күп еллар әнием файдаланган, күп авылдашларым рухына Коръән-хәтем чыкканда кулланылган, картаймыш көнемдә минем өчен дә серләрен ачкан изге Коръән иде. Аның үз яше дә бер гасырдан артык булыр.

Бәхил бул, газиз әтием! Гомерем буенча рухыңнан читләшмәскә, исемеңә тап төшермәскә, истәлегеңә лаек булып яшәргә тырыштым. Соңлап булса да, синең яшеңә җиткән оныгыңны һәм, инде дөньяны танып белә башлаган үз оныгымны ияртеп, янына килдем. Димәк, нәселең дәвам итә.

**Әдип БИКТАШЕВ,**
*техник фәннәр кандидаты.*

⁂

*Дискуссия: “Безнең заман герое”*



## Айдар Хәлим

# СЕЗ БЕЛӘМСЕЗ КАЯ БАРГАННЫ?

### СОРАУЛАР АНЫК КУЕЛГАНМЫ?

“Безнең заман герое”. Сөйләшүнең темасы яна булмаса да, аның нәкъ менә шушы яссылыкта куелачагы күптән көтелә иде: ул татар милләтенең киләчәк язмышына барып бәйләнә. Тукай раславынча, бетәбезме без, әллә... бетмибезме? Борчылуларым шул кадәр дә көчле иде ки, берничә тапкыр кулыма каләм дә алып куйгалаган чакларым булды. *(Кара: "Татар милләте өчен Кануннамә", “Ватаным Татарстан”, 16.02.1996; “Инде без дә бетәбез...” “Шәһри Казан”, 16.03.2001; “Исән калу хакына”. Президент М. Шәймиевкә ачык хат”, “Шәһри Казан”, 31 май 2002; “Бирегез мәйдан!”, “Мирас”, 2 , 2003).* Шуңа күрә, мондый ифрат та кирәкле, милләт өчен әҗәл даруына тиң сөйләшүне, ниһаять, башлап җибәргәне өчен “Казан утлары” редакциясенә рәхмәт әйтәсем килә. Бер башлагач, әлбәттә, җиренә җиткереп, тәфсилле итеп сөйләшү зарурдыр. Сөйләшүне вакыт кысасы белән чикләмичә, озайтырга кирәк. Безне ашыктырмыйлар бит. Киңәшнең азагында хөкүмәтебез, бәлки, берәр карар кебек нәрсә дә кабул итәр? Сүз бит глобализм заманында милләт кадәр милләтне коткару, дөньяның бер сирәк этносы—татарны саклап калу турында бара. Әле кызып кына барган бәхәс бары тик ***“герой эзләп табу”**** хакына куелган тар үзмаксат түгел, шуңа күрә аның Станиславский әйткән глобаль, “иң югары максаты” (“сверхзадачасы”) бер гамәли уртак фикергә килү белән тәмамланырга тиеш.

“***Күп дистә еллар буе яшәешебезнең асылын тәшкил иткән икътисади тотрыклылык бетү белән бергә, әхлак категорияләре дә сизелерлек какшады***...” диелә бәхәснең “Баш сүз”ендә. Ярлылык, икътисади тотрыксызлык кына әхлакый тотрыксызлыкка китерә дигән нәтиҗә ясалган сыман бирелә. Ай-һай. Тарихта шунысы билгеле: ярлы кеше Китап өстендә яшь койганда, бай абзый еш кына аның өстендә ятып йоклый. Еш кына ярлы илләр чагыштырмача югары әхлаклы, иманлы, бай Америкалар ифрат та әхлаксыз вә имансыз булып чыга. Үзебез күреп торабыз: Гыйракны бомбага тоткан Американың кайсысы иманлырак? Нигә Америкаларга китәргә? Үзебезне алыйк. Ислам кабул итеп, ун гасыр эчендә без ташпулатларда

Айдар ХӘЛИМ (1942) — *шагыйрь, прозаик, публицист; татар, башкорт, рус телләрендә күпсанлы («Беренчеләр», «Гомеремнең ун көне», «Биктырыш», «Минем түгәрәк Иманем» һ.б.) китаплар авторы. Чаллыда яши.*

яшәгән Болгар вә Казаннан сөрелеп чыгарылып, читән, салам түбәле алачыкларга кертелгән милләт, ыштыр урап, чабата киеп, ачлы-туклы яшәп иманлы-китаплы килгән булсак, хәзер технотрон заманның күп катлы, калай түбәле, таш, галәми интернетлы, телевизорлы өйләрендә, "Мерседес"ларда дөнья куып, имансыз-китапсыз торып калдык бит әле... Беркатлы тәпәш агач өйләрдә вөҗүдебезне югарыда саклап, күпкатлы бетон йортларда ул вөҗүдне бихисап түбәнәйттек. Бабайлардан калган иман безне хәтта Явыз Иван, Пуришкевич, Лука Канашевич-Каратуннар инквизициясе аша мең ел саклап килде-килде дә, совет "интернационализмы" һәм Ельцин "демократизм"ы чорында "ташлап" китте дә барды. Мондый шайтанлыкка каршы торырга без көчсез идек. Киштәбездә китап бар, ләкин ул... ***ж а н ы б ы з д агы иманга әверелмәгән...***

Әдәбият, әгәр ул әхлакый-тәрбияви сакланып килгән һәм ихластан да яши икән,ул беркайчан да "тормыш көзгесе" булудан туктамый, чөнки ул, объектив җәмгыятьнең Адәмзат каләме очындагы субъектив чагылышы буларак яши. Әмма аның булу-булмавы җәмгыятьнең бу әдәбиятка ***ихтыяҗына*** бәйле. ***"Менә шушындый катлаулы, байтак язмышларны ботарлап ташлаган, хәтта катаклизмнарга кадәр барып җиткән*** җәмгыятьтә әдәбиятның, анычрак әйткәндә, матур әдәбиятның роле кимеде ***түгелме?"***—дигән сорау куя безнең алга журнал. Бик тә вакытлы, бик тә катлаулы, бик тә кыю вә куркыныч сорау бу. Татар җәмгыятенең генә түгел, гомумкешелек җәмгыятенең дә әле моңа кадәр, бары тик матур әдәбияткә бәйләп, мондый сорау югарылыгына күтәрелгәне юк иде. Димәк, без исән!..

Танып-белүдә, хәбәрдарлык-тәрбия сферасына яшен чаткысы тизлеге белән килеп кергән электрон чаралары—телевидение, интернет, электрон элемтә, галәми телефон, "виртуаль чынбарлык" һәм башка шундый компьютер җанлы, милләтнең барлык Алпамша, Камыр-Батыр һәм Зөһрә-кызларын "башы-аягы белән ашый торган" "могжизалы Гарри Поттерлар" гомумкешелекнең менәр еллар буе сыналып килгән һәм мәңгелек дип исәпләнгән иске мәдәни мирасын сынау алдына куйды: алар булырга, сакланырга тиешме, сакланган хәлдә, электрон мәдәни-тәрбия чаралары белән ярышта нинди ысуллар сайлап исән кала алачаклар? Электрон революция бер үк вакытта дөнья белән идарә итүнең яңа, алдарак әйткән агрессив каһарманнары—Гарри Поттерларны һәм аларның фәлсәфи кануннамәсе булган глобализм гамәлен китереп чыгарды. Без, дәүләте һәм үз банк-интернет системасы булмаган татар җәмгыяте, глобализм һәм аның нәтиҗәләре турында уйлый башларга да өлгермәгән булуыбызга карамастан, инде аның потенциаль колына әвереләдек. Гади генә итеп аңлатканда, нәрсә ул—глобализм? Ә менә нәрсә: табигый байлыкларын юридик яктан синеке—ләкин фактик яктан синеке түгел. Телевидениең—формаль синеке, ул синең салым акчасына эшли—әмма фактта, андагы секс-бомба программалары белән синеке түгел. Глобализмның ерак һәм якын бөҗралары бар. Без аның ерак бөҗраларында биш йөз ел яшибез инде.Әйтик, Мәскәү сазлыкларыннан Тын Океанга кадәр җирләребез басып алынгач, алар "тыныч кына" "Рәсәй" дип атала башланды. Идел синеке, әмма син аның ярларыннан куылгансың. Иген синеке, аны син үстерәсең, әмма орлыклары—империя амбарларында. Мәчетләрең урынында—чиркәү, каберлекләрең урынында—хәрчәүнә. Күкрәгеңдә көчләп тагылган тәре. Менә безнең милләтнең моннан биш йөз елга якын элек кичергән беренче глобализм үрнәкләре. Без әле һаман да исәнме? Ничек?! Советлар алып килгән глобализм исә интернационализм күлмәген киеп, тагын да нечкәрде, телне, җанны, катнаш никахлары белән гаиләне басты. Ельцин демократиясе чорында совет чорыннан калган әчке глобализм халыкара глобализмның трансконтиненталь ятьмәсенә эләкте. Синең менә дигән әдәбиятың, мәдәниятең бар—ләкин китап кибетләреңдә әхлаксыз макулатура, анда Тукайларга урын юк. Сәхнәңдә үз Шүрәлеләреңә охшаган ят "Шүрәле"ләр бии, Илһам Шакиров кебек чын йолдызларга урын юк сәхнәдә "сүнгән йолдызлар" җырлый. Синең менә дигән милли ашларың—вак бәлешләрең, өчпочмак, (аны "интернациональ" татар, әлбәттә, һичшиксез "треугольник" дип атый), кечкенә цехлар, ашханә, чәйханәләр ачып җибәр, очсызга гына ашат, тукландыр, бае да бит—әмма юк "Кыстыбый" "корпорациясе" бездә. Аның каравы, барлык

Татарстанны эрзинкә кебек чәйнәлми, сус кебек өзелми торган "кызыл салам" сата торган "Макдоналдс"лар биләп алган. Әйтик, татар үз карынында йөртеп, тудырып, миллион расходлар тотып, балалар үстерә дә, аларны ят кияүләргә коллыкка сата, инде йөз ел катнаш никахларда башка милләтләрне арттыра. Татарның иң акыллы укыган баласы татарның үзенә түгел, чит Германия, Америка, Израильләргә хезмәт итә. Безгә гарьләнергә кирәк тә бит, әмма татар моның белән "горурлана". Мондый психологияне нинди әдәбият тәрбияләгән, "Заман геройлары булган" татар әдәбиятымы? Әйтик, шул ук нефтең синеке, ләкин аны татар түгел, урыс белән ябрәй сата, бәрәңгең, сөтең, итең юридик яктан синеке, әмма фактик яктан—синеке түгел, базарда аны әзәри белән ярышып әрмән сата... Кайчандыр империяләр бары тик үзләре басып алган территория һәм халыклар белән генә идарә итсә, электрон мәдәният чаралары белән коралланып алган Гарри Поттерларның халыкара идән асты империясе глобаль дөньяны күз ачып йомганчы глобаль масштаблар белән басып алды. Бу империягә әхлак кирәкми, ана Себерләргә очып, " виртуаль томанда" йөзеп, алданып, акча эшли торган алаканат, гидайлар, ихтыярсыз, беркатлы, тәрбиясез, тирән белеме булмаган, "музыкаль исерек" ахмаклар галәмияте кирәк.

Кайчандыр XIX гасыр азагында Закир Һади "Хәзер дә чыра заманнары үтмеш, шәм вә лампа заманнары да кичмеш, электрик заманнары килмеш" дип язган булса, без бүген электрик заманнарына беррәттән электрон, интернет, глобализм заманнары "килмеш", дияргә мәҗбүрбез. Татар язучысы милләтен исән калдырасы килсә, трансконтиненталь глобализмга каршы торырга, милләтнең умыртка сөяген ислам һәм иманлы нәфис сүз тәрбиясе белән ныгытырга тиеш. XX гасыр белән XXI гасыр арасында интернет белән коралланып өлгергән виртуаль кешелек үз тарихында беренче тапкыр "Китапсыз да яшәп була" дип яшәүгә күчте. Әйе, яшәп була торгандыр, тик мондый очракта Кеше Туганыбыз, сина кешелеклеген белән генә хушлашырга туры киләчәк. Мондый тирбәлешләргә бик тә сизгер шагыйребез, мөхтәрәм журналыбызның баш мөхәррире Равил Фәйзуллин 2000 елның гыйнвар санында ук "Баш мөхәррир сүзе" дигән баш астында чыккан башмәкаләсен һич тә юкка "***Китап гасыры китәме***?" дип атамаган иде. Интернетка әсир төшкән кешелекнең китап белән хушлашуы мәдәният тарихында мәдәнияткә каршы мондый глобаль масштабтагы беренче контрреволюция иде. "Әдәбиятның роле кимеде түгелме?" дип сорый "Казан утлары". Бу контекстта мина әлеге сорау аяусыз киная белән "Әле әдәбиятыбыз бармы? Ул кирәкме?" дигән сыманрак (тәүбә-тәүбә!) янгырый.

Яшермим, мина бик куркыныч. Бу мәкаләне язар өчен каләм алганда мин үземне дар агачына менгән кебек тойдым. Әмма төп курыкканым бу мәкалә чыкканнан соң алачак тукмакларым түгел. Курыкканым икенче. Сукмас зур күтәрә дигәндәй, зурдан дау кубып, иске әдәбиятны тар-мар китереп, яңасын тудыра алмыйча, тарих алдында болай да кыен хәлдә калган милләтебезне ярык тагарак алдына утыртмабызмы, дип борчылам. Бөек татар әдәбияты бар һәм ул буш урында тумаган. Әгәр урыс шигърияте Василий Жуковскийның 1802 елда инглизчәдән тәрҗемә ителгән утыз-кырык юллык "Авыл каберстаны" элегиясе белән нибары моннан ике йөз ел элек башланган булса, безнең татар шигърияте үлемсез Кол Галинең сигез мең юллык "Йосыф вә Зөләйха"сы белән моннан сигез йөз ел (!!!) элек башланды. Мондый бөек әдәбият барлыкка килсен өчен татар дигән бөек һуннутөрки милләткә тарихта аваз салырга, ничә мең ел тир түгәргә, мең еллык мәдәни катлам булдырырга, аның чәчмә-шигъри-драматик әдәбият өлкәсендәге Кол Гали, Мөхәммәдъяр, Сәйф Сараи, Котб, Габделҗаббар Кандалый, Шиһабетдин Мәрҗани, Каюм Насыйри, Муса Акъегет, Заһир Бигиев, Риза Фәхреддин, Гаяз Исхакый, Габдулла Тукай, Дәрдмәнд, Галиәсгар Камал, Фатыйх Әмирхан, Мәҗит Гафури, Фатыйх Кәрими, Мирхәйдәр Фәйзи, Фәтхи Бурнаш, Мәхмүт Галәү, Кәрим Тинчурин, Шәриф Камал, Галимҗан Ибраһимов, Нәкый Исәнбәт, Хәсән Туфан, Муса Җәлил, Таҗи Гыйззәт, Гомәр Бәширов, Ибраһим Гази, Әмирхан Еники, Сибгат Хәким, Фатыйх Хөсни, Нурихан Фәттах, Аяз Гыйлаҗев, Мөхәммәт Мәһдиев, кебек титаник фикер иясе һәм нәфис сүз осталары—язучы һәм шагыйрьләр

мәгърифәт-мәдәниятнең беренчел чирәмен күтәрергә тиеш булган.

Әмма мин бүген күп кенә остазларымнан, замандашларымнан һәм үземнән канәгать түгелмен. Үземнән аеруча.Үземне кыйнаган кадәр мин беркемне дә кыйнамыйм. Бер үк вакытта, остазларымны мин яратам да, "яратмыйм" да. Алар минеке дә, "түгел" дә. Алар мина якын да, "ерак" та. Үз дә, "чит" тә. Алар зур да, "бәләкәй" дә. Мин аларны яратып мактыйм да, тәнкыйтьләп, инкяръ да итәм. Менә ни өчен дарга менгән "җинаятьче" итеп тоям мин үземне. Бөек Байроннарга тинләшергә тиеш булган, әмма һаман да шул "вакытсыз үтерелгән" мәшһүр Такташыбыз әйтүенчә, "сүгенә-сүгенә кайтам урамнан". Бирердә бер-берсен макташудан, иренмәгән мәзәкчеләр, "фәлән-фәлән кытыклары" дигән юньсез бер жанр уйлап чыгарып, котыралар. Һәркайсы Бернард Шоуга әверелеп, берсен-берсе "кытыклыйлар"... Күк йөзенә карап, анда үзебезнең бүгенге эре йолдызларыбызны эзләп тапмакчы итәм. Юк, күренмиләр. Аптырагач, кулыма мәктәп микроскобы түгел, космик телескоп алып, вак йолдызларыбызны да галәми масштабта зурайтасым килә. Әмма зураймыйбыз, шайтан алгыры. Без—вак, без—тузан... Юк, безнең искиткеч талантлы, әмма изелгән, кол, колониаль милләтебез галәми масштабтагы үз Сервантес, Шекспир, Рабле, Бальзак, Ги де Мопассан, Джон Голсуорси, Теодор Драйзерларын тудыра алмады...

Минем үземне һәм барчабызны, беркемнең дә шәхесен кимсетмичә, тәнкыйтьлисем, каезлыйсым килеп китә. Бу минутта минем өчен классиклар бетә, бары тик милләтнең тигез балалары гына кала. Кинәт минем йөрәгемне кайнар пычак телеп төшә: ***язганым хакмы? нигә язам? нигә язып азапланам? ул кемгә кирәк? без төзегән бинаны ачып керүче-укучы табылырмы? алар туфракка без күмеп калдырган шартлаткыч матдәне таба, без күтәргән җиде кат күкне, без төшкән җиде кат җир катламын ача алырлармы?*** Бу сөаль, шатлыкка каршы, татар әдәбиятында бер мине генә борчымый. Әнә, шул ук баш мөхәррир "Йә, нишлибез, газиз каләмем?" дип исемләнгән башмәкаләсендә җәмгыятебезгә шундый ук сораулар куя ләбаса: ***"Әдәбиятның алтын гасырлары үтте түгелме? Үзен алыштырырлык роботлар ясаган, клонлаштырып, телэгән җан иясен укмаштырыр сәләткә ия XXI гасыр затлары өчен эмоциональ әдәби сүз, образлы сурәт кирәкме? Җәмгыятьтә әдәбиятка ихтыяҗ бармы? Ак кәгазьдәге язу буразналарын без дөрес сөрәбезме?"*** ("Казан утлары, 1, 2004).

Кем белә, бәлки без—сан ягыннан ун миллионнан ким булмаган милләтебез бар дип күкрәк каккан татар әдипләре—бәлки бу виртуаль, китапсыз томанда тугыз миллионыбызны "суга салып", бәлки бер миллионыбыз белән берәгәйле милләт булып туфан суларында калкынырбыз да, Нух пәйгамбәр көймәсеннән милли дәүләтле, милли интернетлы, милли банклы милләт булып коры җиргә аяк басарбыз?! Әнә бит, Сөләйман-Соломон падишаһ балалары ничегрәк итеп галәми глобализм хуҗалары булып киттеләр, ә?! Журнал битләрендә барган сөйләшүнең төп мәгънәсе, аңлашылуынча, әдәбиятның иҗтимагый-тәрбияви бурычларына кайтып кала. Без кемне, нинди кемсәне нинди әсәрләрдә, нинди тәмләткеч, нинди"витаминнарда" тәрбиялибез? Бу тәмләткечләр балаларыбызны кая алып бара? Җир йөзен басып алган глобаль мохитта, туфан томанында алар нинди маякларга, нинди кыйблага йөзләрен юнәлтәләр? Бу хакта уйланганда мәшһүр шагыйребез Хәсән ага Туфанның әле 1953 елда сөргендә язылган "Сүз кушасы килә талларга" дигән шигыре искә төшә:

*Уйга талган*
*Дәрья таллары...*
*Шундый уйчан аулак таңнарда*
*Сүз кушасы килә талларга:*
*—Сез беләмсез кая барганны,*
*Уйга талган дәрья таллары?*

Дөньядагы һәр халыкның үз иясе, тотем-билгесе бар. Ташмы, агачмы, үләнме, әллә берәр киек-җанвармы ул—барыбер. Без татарларның Ходай Тәгалә биргән милли агачы—тал. Тал-Ана. Өянке түгел, Тал. Мәңге яшь нечкәбил Тал. Тал белән Өянке бер матдә, бер үк агач булса да, алар ике яссылык, ике Вакыт, ике Аралыкта яшиләр. Шуна күрә дә, Талның кайчан картайганын һәм Өянкегә әйләнгәнен күреп булмый. Бу бөек сер. Таллар картаймый, үлми, кискән саен төптән янара, тамырлана.

Таллар—без ул. Татарлар. Кискәч тә ишәя торган агачлар нәселеннән. Өянкеләр гөрселдәп ава. Таллар аумый. Үсәләр, кискән саен үрчеп яшь туйрага әверелəләр...

## КЕМ УЛ “ЗАМАН ГЕРОЕ”?

Башланып киткән сөйләшүебез башыннан ук ут-ялкын белән дөрләп китмичә, менә сүнәм, менә сүнәм дип чыш-пыш килеп, төтен дисән төтен, ыс дисән ыс булмаган сусыл-ачы “нәрсә” чыгарып ятуын дәвам итә. Дөрес, Рәфыйк Шәрәфиев “Киләме, күрәбезме?”, 1, 2004), Рәшит Фәтхерахманов (“Татарга сатма матбугат”, 3, 2004) кебек авылда яшәгән бик җегәрле һәм “очлы күзле” тәнкыйтьчеләребез һәм, аларга өстәп, Рафаэль Мостафин (“Чорлар чатындагы үзгәрешләр”, 5, 2004), Рөстәм Зарипов (“Пегас кашына микән?”, 9, 2004), Револь Раков (“Укыр җаннар бетмәсен”, 9, 2004) кебек әдәбият сөючеләребез сөйләшүне ялкынландыру максатында юньле генә коры утыннар ыргытып, барыбер дә дөрләп китә алмаган учакны җанландырырга тырышып карасалар да, Радик Фәизов (“Алар безнен арада”, 2,2004) кебек “һаман да шул” авылдан, Әхмәт Рәшит (“ Зурдан кубып сөйләшкәндә”, 4, 2004), Мансур Вәли-Баржылы (“Күнел кемне көтә?”, 6, 2004), Илшат Вәлиулла (“Яна маяклар эзләгәндә”, 8,2004) кебек әзерлексез, тема стратегиясеннән ерак торып, еш кына клан-төркем макташуына гына кайтып калган мәкаләләр белән катнашкан “шәһәр тәнкыйтьчеләре”, Азат Әхмәдуллин (“Үрнәк геройлар сагындыра”, 7, 2004), Зиннур Мансуров (“Каләмебез илаһи антка тугрымы?”, 7,2004) кебек шулай ук “шәһәр”, әмма сөйләшүгә бөтенләй катнашы булмаган, әдәби ел йомгакларында укылган “докладлары” белән очраклы чыгыш ясаган тәнкыйтьчеләребез Рәфыйк Шәрәфиев белән Рәшит Фәтхерахманов кабызып җибәргән учакны сүндерү өчен зур гына тырышлыкларын күрсәттеләр.

Әмма бу юнәлештә иң зур “өлеш кертүче” мәхдүмебез нәкъ әнә шул сөйләшү өчен җаваплы, аны оештырырга, басмага әзерләргә тиешле “инсанымыз”—“Казан утлары”нын тәнкыйть-библиография буенча мөхәррире Мансур Вәли-Баржылы булгандыр. Мансур әфәнде “Күнел кемне көтә?” дигән мәкаләсендә (6, 2004) “...Сонгы елларнын реаль чынбарлыгында нинди сон ул безнен еллар герое? Бүгенге тормышта без кемнәргә—нинди типларга—чыннан да герой дип әйтә алабыз?”—дигән сорау куя да: “ Герой исеме ул, һичшиксез, зур батырлык, зур фидакарьлек белән бәйле,—дип шунда ук шартлатып “заман геройларын” атап та бирә.—...Батырлык, фидакарьлек дигәндә минем күнелгә ин башта сугыш елларыннан Шакирҗан Мөхәммәтҗанов, Газинур Гафиятуллин кебекләр, сиксәненче еллар армиясе тормышыннан Рифкать Миргазизов сыман асыл, кыю егетләр килә..” Менә ничек икән бит. Һәйбәт “провокация” бу. Шулай итеп, тәнкыйтьче җитди фәлсәфи сөйләшүгә фельетон мотивлары кертеп җибәрә. “Әдәбиятыбыздагы заман герое” ул һичшиксез “Кызыл армиянен кирза итеге” белән бәйләнешле булырга тиеш икән!.. Шакирҗан Мөхәммәтҗановнын кем икәнлеген беләсезме? Мин белмим. Хәтерлим: үткән гасырнын туксанынчы еллары башында илдә хәбәрдарлык урнашкач, матбугатта “дошманнын ут ноктасын күкрәге белән каплаган Советлар Союзы Герое Александр Матросовнын, имеш, яшь җинаятьче үсмерләр колониясендә үзе теләп “Александр Матросов” исем-фамилиясе алган урыс егете түгел, ә, имештер ки, Башкортстаннын Учалы районыннан ятим татар (башкорт?) баласы булганлыгы турында материаллар күренеп алган иде. Анын чынлап та башкорт яки татар булуын ары таба беркем дә архив документлары аша раслап маташмады—оныттылар. Рифкать Миргазизов дигән кеше, бәлки, чынлап та зур геройлык кылгандыр. Әмма анын да кем икәнлеген белмибез булып чыкты. Авторга бу мәсьәләдә бераз гына булса да ачыклык кертеп китәргә кирәк булгандыр, минемчә.

Хәтерлисездер, кичә генә Сталин төрмәсеннән чыгып, бүген шул ук Сталин тырышлыгы белән башланган империалистик сугыш корбаны булган шагыйрь Фатыйх Кәримнен “Мин—гуманист” дигән бик тә гыйбрәтле, без әле булса бер яклы анлаган шигыре бар. Анда лирик герой дошманын үтергәнгә куана да, эченнән генә “Бу кешенен гомерен нигә бетердем икән мин?” дигәндәй үкенеп куя... Бу мәсләктән чыгып карaганда, мәгънәсезгә амбразурага ташланган (ташланганмы?)

Газинур Гафиятуллин түгел, Фатих Кәримнең шушы гуманист сугышчысы "заманыбыз герое" булып кала түгелме? Сүз бирелә кемнең кем булуы, кемнең нинди батырлык кылуы, нинди батырлык өчен әдәбиятка керергә хокуклы булуы турында түгел, ә безнең әдәбиятта кемнең, ниндирәк образның "заман герое" буларак атала алуы турында барырга тиеш иде. Мансур әфәндене бу проблема, күрәсез, артык борчымый. Борчыса да, "заман герое" аның өчен сугышта мотлак та "Герой булыйм әле!" дип бер мәгънәсезгә амбразурага ташланучы "тиле", тыныч хезмәттә мотлак та сабанга җигелеп тартучы "йөк аты" булырга тиеш икән. Бу хакта моннан кырык елга якын элек шагыйребез бик зур кинаяле мәртәбә белән болай дигән иде:

*Үлеп күрсәттеләр безнекеләр!*
*Гомерләре булды, һай, кыска.*
*Ә бит үлеп үлемсезлек яулау*
*бердәнбер юл түгел тормышта...*

Кинәт кенә тәнкыйтьче үзе эзләгән "заман геройларын" җиңел генә итеп "уңай герой" образына алыштыра да, һәр уңай герой образы "заман герое" булып чыккач, Аяз Гыйләҗевнын "Җомга көн кич белән" дәге Бибинурын, Әмирхан Еникинең "Әйтелмәгән васыять"ендәге Акъәбиен, алардан алда Гомәр Бәшировның "Намус"ындагы Нәфисәсен, Мирсәй Әмирнең "Тормыш җыры"ндагы Минлекамалын, Габдрахман Әпсәләмовның "Ак чәчәкләр"ендәге Гөлшәһидәсен "татар әдәбиятының зур казанышлары, ачышлары" дип атый. Дөрес, алар "казанышлар", ләкин илле елга якын чорда тупланган чаңда чаңланган, әйләнештә йөреп искергән акча сымак иске "казанышлар". Без бит сөйләшүне соңгы егерме еллык әдәбиятыбыз турында алып барырга сөйләшкән идек?

Шуна күрә дә тәнкыйтьче моннан утыз-кырык ел элек университет аудиторияләрендәге уяулы-йокылы семинарларда алган белеме белән чикләнә. Шулай да, һәр "казаныш" "ачышка" тиң була аламы? Әйтик, заманы өчен Чичиков "ачыш" булганмы, "казаныш" булганмы, әллә "заман герое гына"мы? Аннан, теләсә нинди "казаныш", "ачыш" "заман герое", "уңай герой образы"на дәгъва итә аламы? Шулай итеп, бу сорауларга җавап эзләү белән шөгыльләнергә тиешле тәнкыйтьчебез, өч каен арасында адашып, шул әсәрләрне иҗат иткән авторларның үзләрен "заман геройлары" ясап куя. Баксаң, әдәбиятыбызда "заман геройлар"ын эзләп тә торасы юк, аларны тудырган язучылар үзләре үк "заман геройлары" икән бит!.. Юк, дөрес аңлагыз, әдәбиятта Николай Островский, Фәнис Яруллин кебек сирәк очраклар да бар, тик мин авторның һәр очракта авторга "геройлык" иммунитеты биреп, сөйләшүне ялгыш юлдан алып кереп китүен генә шик астына алам. Әйе, гомумән алганда, "татарча гел сонлап" булса да, шактый кызыклы "Таң җиле" романын язган Фоат Садриев, автор фикеренчә, геройммы? Герой икән. Ни өчен? Чөнки аның Нуриасмасы, тәнкыйтьче раславынча, ***"үзенең буй җитмәс биеклектә торуын"*** аңлаган. Шул гынамы? Әлегә шул гына. Мәдинә Маликова геройммы? Герой. Чөнки аның "Өермә"сенен ***"героинясы Җәүһәриянең ният-максатлары изге булса да, әйләнә-тирәсендә ерткыч табигатьле адәмнәр күп"***, ди. Радик Фәизов геройммы? Герой. Чөнки аның "Тәңре хөкеме" дигән фантастик (!) повестендагы Сәетҗан ага ***"татар халкы өчен генә түгел, бөтен кешелек җәмгыяте өчен гаять мөһим, гаять актуаль идеялар белән мавыгып йөри"***. Ә нигә Нәкый Исәнбәт герой түгел? Вахит Имамов геройммы? Герой. Чөнки Имамовның башланган да ташланган повесте "Могикан"дагы образлар ***"дуслыгы , аларның беренче чабышка чыгулары—болар шигырь дәрәҗәсенә күтәрелеп, автор үзе дә чын-чыннан илһамланып*** (стиль, җөмлә төзелешенә игътибар итегез—А. Х.) ***иҗат иткән урыннар! Бирелә В.Имамов "Алмачуар"ны тудырган Г. Ибраһимовлар, ат турында берничә гүзәл повесть язган Чыңгыз Айтматовлар дәрәҗәсенә үк күтәрелә..."*** икән. Чама кирәк түгелме? Менә бит, Чыңгыз Айтматовның үзе дә алалмаган Нобель премиясен тот та Вахит Имамовка бир. Җөмлә төзергә соңыннан да өйрәнербез.

Кызганычка каршы, бүгенге заман татар әдәбиятында "заман герое" гына түгел, беренче чиратта төзек җөмлә дефицитка әйләнде. Мин үзем һәр проза әсәрен сусап-

юксынып укый башлыйм да, стиль кытыршылыгы, җөмлә төзексезлеге күзәмә чалынса, авторы кем булуына карамастан, туктыйм. Әле безнең күпләребезгә кеше аңнарлык камил, нәфис, бар әгъза-буыннары да урынында булган җөмлә төзергә өйрәнергә кирәк. Әйткәндәй, "бу барыш белән барсак", Татарстан Язучылар берлегенә озакламый җөмлә төзү буенча бер остаханә ачарга туры киләчәк. Тик шунысы, җитәкче табарбызмы? Бу ВУЗ белеме белән генә түгел, сәләт, талант, тормыш-хаятне белү, шуннан килгән иҗтимагый эчтәлек белән дә бәйләнгән. ***"Яшьләр белемле—хәзер ВУЗ дипломы бар. Алар инде җөмлә төзи беләләр—белем зур!***—дип киная белән ачынып язган иде Мөхәммәт Мәһдиев моннан нәкъ егерме ел элек шул ук "Казан утлары"ның прозабызга багышланган бәхәсе унаеннан язылган "Җиләкле аланнар эзлим" дигән мәкаләсендә.—***Тик әсәрдә тормыш юк***". "Казан утлары", 3, 1984). Юк, Мөхәммәт абзый,ялгышкансыз. Без инде хәзер җөмлә төзи белмәгәннәрне дә язучы итеп бетердек. Безнең җөмләләребез чуерташ-җөмләләр. Мөхәммәт ага шундый җөмлә төзүчеләрне күз уңында тоткан бит. Шулай да сорау: ә нигә без геройларыбыздан иске, яуланган биеклекләрне яулатабыз да, шуның белән күкрәк кагабыз? Нигә безнең язучылар Чыңгыз Айтматовлардан да югарырак күтәрелми? Нигә, Айтматовлар Алланың кашка тәкәсемени? Безнең әдәбиятта, мәсәлән, соңгы елларда Айтматовның "Хуш, Гөлсары!" сы белән тиңләшерлек, хәтта аны уздырып җибәрерлек омтылышлар булмады түгел, булды. Тик, мәңге онытылмас Гамил Афзалыбыз әйткәнчә, һәр татарда утырган "штатный татар шайтаны"—татар көнчелеге, татар тарлыгыннан арынып, күрә генә белергә кирәктер.

Аяз Гыйләҗев соңгы утыз-кырык еллык әдәбиятыбызда "рухи баскынчылык, экспансиягә каршылык күрсәтү, җиһат-көрәш рухы" юнәлешен башлап китүче әдипләребезнең иң кәттәсе. Әмма сүз сәнгатебезгә искиткеч зур өлеш керткән Аяз Гыйләҗевны тәнкыйтьчебез "тәҗрибәле әдип" дип кенә атап китә. Аяз Гыйләҗев кебек әдип "тәҗрибәле генә" булалмый, чөнки әдәптән килгән әдиплек, талант ул—Аллаһтан. Бары тик уртакул язучы гына "тәҗрибәле" була ала, чөнки тәҗрибә бары тик хезмәткә бәйле. Әмма "тәҗрибәле әдип" Аяз Гыйләҗев "герой"мы? Мансур Вали-Баржылы уйлавынча, герой. Чөнки язучының тәмамланмаган, иң яхшы әсәрләреннән дә яхшырак булырга дәгъва дә ясый алмаган, башкаларыннан күпкә кайтыш "Кылдан нәзек, кылычтан үткен" романындагы геройларның берсе Асаф Сәхипович, Мансур Баржылы раславынча, "министр булу өчен кемнәрне генә сатмаган", ә менә икенчесе, Фаяз, "эчкерсез һәм ныклы җирлектәге шәхес, дан-дәрәҗә артыннан кумыйча, тыйнак кына эшләп йөри", икән... Менә бит эшләр ничек.

Авторга болар гына җитми. "Геройлар"ны ул бөтенләй күтелмәгән җирләрдән эзли дә, аларны, кызганычка каршы, татар тарихында булмаган "диссидентлык хәрәкәтендә" таба. "...Совет хакимияте елларында нинди каты сәяси һәм рухи басымга да бирешмичә, үзләренең эчке иманнарына, үзләренең олуг иҗат һәм намус юлларына бөек тугрылык саклап кала алган Әмирхан ага Еники һәм Нурихан ага Фәттах—алар безнең чорның геройлары түгел идемени?!—дип күпшы фразаларда тамак ерта тәнкыйтьче.—Күпчелек иҗатчылар партиянең өлкә комитетыннан ***өркеп яшәгәндә,*** хәйләкәррәк иҗатчылар үзләренә шәхси уңышлар яулау (һәм рәхәт тормышка ирешү өчен!) андагы түрәләр белән турыдан-туры яки "интеллигентлар"ча әшнәлек иткәндә һәм алар кулыннан төрледән-төрле медальләр алганда—болар бит бары тик милләт, халык хакына олуг Иҗат дигән Иманны гына таныдылар! Шуңа гына хезмәт иттеләр!.."

Дөрес тә, түгел дә. Язучының бурычы—гаделлек хәбәрчесе булу, гаделлек өчен көрәшү. Әгәр ул үз фикерен яшерә икән, ул язучы түгел. Монда тегe "Шакирҗан геройлыгының" ни катнашы бар? Нигә без куркак татарны "батыр, диссидент" күрсәтү хакына төшенчәләрне бутыйбыз? Әгәр бу "бары тик милләт, халык хакына олуг Иҗат дигән Иманны гына таныган" иҗатчылар безнең арада яшәмәгән, иҗат итмәгән һәм мин, шәхсән, аларның иҗатларын Рәсәй, СССР, бөтен дөнья масштабындагы әдәби ачышлар белән чагыштырып белмәгән булсам, бу күпшы фразаларга мөкиббән ышанган булыр идем. Нәрсә, Әмирхан ага белән Нурихан ага өлкә комитетына төкереп карап, җитәкчеләр белән даими конфронтациядә, диссидент халәтендә көрәшеп яшәдеме? Алар хакимияттән медальләр, премияләр,

татарның халык язучысы дигән мәртәбәле исемен алмадылармы? Өлкә комитеты кайсы татар язучысын тәнкыйть итмәде? Кем анардан өрекмичә яшәде? Аның тәнкыйтенә эләгү ул бит әле "диссидент" булуга тиң түгел. Йә, әйтегез, татардан кайсы язучыбыз, шул исәптән дәүләттән зур бүләкләр алган "диссидент" Хәсән Туфан да, чын мәгънәсендә "диссидент" идеме? Сер дә түгел, күп кенә очракларда Мәскәүдән төшкән "халыкара ишарәт" яктысында эшләгән өлкә комитеты безнең авыл мәктәбе һәм университетыннан башка бернәрсә күрмәгән, хәтта солдат шулпасын да эчмәгән хәлвәфруш язучыларыбызны еш кына гадел тәнкыйть итә һәм, дөрестән дә, иҗтимагый тормышны фаразлауда алардан күпкә алдарак бара һәм шуна чакыра иде!

Ни гаҗәп, кайчандыр җитмешенче-туксанынчы елларда тәнкыйтьтә мәйдан тоткан көчле тәнкыйтьчеләребезнең берсе, соңгы елларда шактый серле, шактый томанлы, шактый "экзистенциаль маржаизм" белән сугарылган хикәяләр язу белән мавыккан Мансур Баржылының бүген нишләптер, башкорт әйтмешли, "ялкавы килә", ул үзенең күзе алдында һәм кулы астында туган егерме еллык проза катламнарын актарырга иренә. Ягъни ул ***прозадан позага*** баса. Чынлап та, мондый унбиш-егерме елга бер тапкыр була торган академик сөйләшүдә әдәбиятның бер генә жанры, бер генә язучысы, игътибарга лаек булган бер генә каләмкяры да—кичәге аксакалы Әмирхан Еникидән башлап, кайдадыр Актанышта искиткеч матур хикәя, новеллалар иҗат итеп яткан Әмирҗан кардәшем Моталлапка кадәр берсе дә онытылмаска тиеш.

Әмма безгә бурыч куярга тиешле тәнкыйтьчебезнең күзенә соңгы егерме-утыз елда иҗат ителгән әсәрләр—Хәсән Сарьянның "Бер ананың биш улы" да, Гариф Ахуновның "Идел кызы" да, Мөхәммәт Мәһдиевнең "Фронтовиклар", "Торналар төшкән җирдә"се дә, Мәхмүт Хәсәновның "Язгы ажаган"ы да, Ибраһим Салаховның "Тайгак кичү", "Колыма хикәяләре" дә, Якуб Зәнкиевнең "Иртеш таңнары" да, Фәүзия Бәйрәмованың "Болын"ы да, "Күл балыгы" да, Айдар Хәлимнең "Өч аяклы ат", "Татар вакыты" да күренми. Тәнкыйтьче Аяз Гыйләҗевнең "Язгы кәрваннар", "Ягез, бер дога"сын да, Мөсагыйт Хәбибуллинның "Илчегә үлем юк", "Кубрат хан"ын да, Нурихан Фәттахның "Сызгыра торган уклар"ын да исләми ул. Гафу итегез, мәрхүм Тәбриз Мөбәрәковның тетрәткеч "Хәтер аланы", сирәк талантка ия язучыбыз Фәнис Яруллинның "Серле дөнья", "Көн сулышы", "Көзге моң"ын, Җәмит Рәхимовның олпат "Батырша"сы, Ринат Мөхәммәдиевнең "Сират күпере", "Кенәри—читлек кошы", Батулланың "Сөембикә"се, Тәүфыйкъ Әйдинен "Аһ, туган каумем газиз!", "Елан угы", "Йортә безне язмышлар"ы, Рашат Низаминың "Ут һәм җыр"ы, Миргазиян Юнысның гаҗәеп " Соңгы сулыш"ы, "Европа ат сагына"сы, Тәлгат Галиуллинның "Тәүбә"се, Флүс Латыйфиның "Хыянәт"е, "Ишелеп төшкән бәхет"е, Камил Кәримовның "Ком сәгате" романының беренче-икенче китаплары, Марат Әмирхановның "Тәкъдир", "Тояк эзе"нә дә тукталып тормый безнең тәнкыйтьчебез. Ә кирәк иде. Эдуард Касыймовның "Җир балкышы", Хисам Камаловның "Үлгәннән соң яздым", "Безне өйдә көтәләр", Салих Батталның "Сигезенчесе кем?", Ибраһим Нуруллинның "Тукай", "Әмирхан", Әсгать Сәлаховның "Каеннар юлы", Марат Кәбировның бер ачыш буларак кабул ителергә хаклы "Сары йортлар сере", Факил Сафинның "Саташып аткан таң", Рәшит Бәшәрнең "Бер йортта җиде кеше", "Изге этләр" дигән роман-повестьлары, Ризван Хәмид белән Рөстәм Мингалимнең "Идегәй" драматик-киносценарие, Әхсән Баян, Таһир Таһиров, Мәгъсүм Хуҗин, Фаил Шәфигуллин, Ркаил Зәйдулла, Марсель Гали, Нәбирә Гыйматдинова, Әхәт Гаффар, Рафаил Газизов, Галимҗан Гыйльман, Рәфкать Кәрами, Азат Ганиев, Таһир Нәбиуллиннар тудырган чәчмә әсәрләрнең сиксән-туксанынчы еллар активында үз урыннарын күрергә хаклары бар. Суфиян Поварисовның Галимҗан Ибраһимовка багышланган трилогиясе, Зәки Зәйнуллинның "Ат карагы", "Гарасатлы юллар", Кыям Минлебаевның "Бакый", Вахит Имамовның "Утлы дала", Гөлчәчәк Галиеваның "Тулгак", Зөлфәт Хәким һәм башкаларның роман, повесть, хикәяләре объектив һәм кырыс бәядән читтә калырга тиеш түгелләр иде.

Башланган бәхәс, шартларында игълан ителүенчә, "Әдәбиятыбызның барлык жанрларын да инләргә тиешле" булса да, ул кадимгечә һәм башлыча, һаман да шул

берьяклы—чәчмә әсәрләребез турында гына бара. Бу бер генә дә гадел түгел, әлбәттә. Иҗтимагый климаттагы үзгәрешләрне, җил-янгырларнын кая таба исешен—тирә-юнебездә "яна кеше, ят кеше" барлыкка килүен еш кына публицистлар, драматурглар, шагыйрьләр тотып ала, аннан соң гына прозаиклар килеп, "катламны тирәнгә бораулый башлый." "Яна герой" ул бит җирдә дә, күктә дә, утта да, суда да яши, ул бары тик бер, сайлап алынган жанрда гына гомер итә алмый. Бу мәсләктән чыгып караганда, Фәүзия Бәйрәмованын соңгы елларда дини-әхлакый һәм татар яшәгән төбәкләргә (диаспора түгел, татар бар Рәсәйдә җирле вә төп халык!) багышланган публицистикасы безнен әдәбиятта феноменаль күренеш. Бары тик язган, әмма бер-берсен укымаган бүгенге язучылар чынбарлыгында аны күрүче генә юк. Анын сирәк әһәмияткә ия булган "Хаҗ көндәлеге", "Заман. Милләт. Кеше", "Бәхет ачкычы", "Таралып яткан татар Иле" кебек дини-әхлакый, фәнни-иҗтимагый темаларга язылган һәм иманыбызга кире кайту юлында зур өлеш керткән китапларын милләт соңгы елларда тыны белән тартып алып укый.

Чәчмә әсәрләреннән тыш, Миргазиян Юныснын, Зөлфәт Хәкимнен, Аллер Тимергалиннын, Солтан Шәмсинен фәнни-фәлсәфи, Фәрит Яхиннын иҗтимагый-фәнни, Фәнзаман Батталнын әче сатирик публицистикалары бүгенге татар иҗтимагый фикеренен офыкларын киңәйтүче факторга ия. Акча тапсан, милләт игътибарын яуларлык бер әсәр тудырмыйча да күптомлыклар чыгарып, әдәбиятнын чүплек башына менү берни дә тормый башлады. Безнен бәхәс "геройсыз" күптомлыклар чыгару тәҗрибәсенә тиешле бәя биреп, бу өлкәдәге парадоксларга җентекләп тукталырга тиеш иде.

Бу мәкаләгә тотыныр алдыннан мин "Казан утлары"нын егерме еллык төпләмәсен актарып чыктым. Бу чорда минем "кара исәбем" белән 80 роман, 135 повесть, 200 хикәя, йөзләгән шигъри шәлкем, дистәләгән поэмалар, пьесалар, истәлекләр басылган. Болар безгә бер генә басмабыз—"Казан утлары"нда гына тупланган байлык. Араларында "йөзек кашлары" бик сирәк очраса да, алар, ни дисән дә, безнен байлык бит. Дөрес, аларнын күбесен чын әдәбиятны укыган кебек, онытылып, мөкиббән китеп укып булмый; кайбер үпкәләүдән үпкә ашатырлык авторларыбыз авыр кабул итмәсеннәр, бу уртак байлыкнын шактый өлешен күз йомып яндырган халдә әдәбиятыбыз бернәрсә дә югалтмыйдыр да бәлки... Юк, мин дискуссиядә катнашучыларны, шул исәптән Мансур Вәли-Баржылыны да, әсәрләрнен барысына уптым-илаһым бәя бирергә чакырмыйм. Бу мөмкин дә түгел. Сүз бәхәснен барышы өчен җаваплы булган кардәшләребездә шушы бәхәснен үзенә карата фәнни-концептуаль мөнәсәбәт булдыру, сөйләшүдән беркемне дә читтә калдырмау, тиешле җирдә гадел тәнкыйть аша айныту, хәтта кечкенә хикәя кебек әсәрләрдә дә, гәрчә алар Галимҗан Ибраһимовнын "Алмачуар", Әмирхан Еникинен "Матурлык", Миргазиян Юныснын "Безнен өй өянкеләр астында иде", Мирсәй Әмирнен "Мөстәкыйм карт йокысы" сыман әсәрләр рәтендә булмаса да, шулар арасыннан, мөмкин очракларда "заман геройларынын" сызат-чалымнарын сөзеп алу турында гына бара...

Мансур Баржылы мәкаләсенә кин тукталуымнын сәбәбе—анда безнен тәнкыйтькә хас булган җитешсезлекләрнен бүлтәеп чыгып торуында. Тәнкыйтьче вакыт-вакыт махсусән саксыз эш итә кебек. Әйтик, һич тә урынсызга безнен мажаралы әдәбият жанрында эшләүче язучыларыбызга ул болайрак итеп "тибеп" китә. "...Үз чиратында ***бусынын*** сәбәбе (гафу итегез, авторнын стиле!—А.Х.)—безнен прозаикларыбызнын—интеллектуаль дәрәҗәләренә, шул эчке рухи көчнен куәтенә, анын ***шәхес эченләге*** (?) потенциалына, анын ни күләмдә (?) булуына килеп ялгана. Әнә шул сәбәпле безнен проза әсәрләрендә... тирән мәгънәле вакыйгалар аз була. Соңгы елларда мафия һәм анын ***төрле-төрле вәкилләре*** (?) турында язылган күпсанлы роман-повестьларнын барысы да диярлек (***Мәскәүдә яшәүче Р. Мирхәйдәровныкыннан кала***) бу очракта мисал була ала." Бу аңлашылмаган, буталчык җөмләне кырмавычлардан арындырсак, "мафиягә багышланган яхшы әсәрләрне бары тик Мәскәүдәге авторыбыз Рауль Мирхәйдәров кына яза ала, чөнки безнекеләргә интеллект, акыл җитешми," дип аңларга кирәк.

Мондый гасабилык күнелне кырды. Нишләп без "Р. Мирхәйдәровтан кала" мафия турында язган барча авторларыбыз язган әсәрләрне кабул итмәскә тиешбез

әле? Нишләп без үз милли телебездә мафия һәм шулар шивәсе турында шактый кызыклы (мажаралы) әсәрләр язган Тәлгат Галиуллин, Фоат Садриев, Флүс Латыйфи, Госман Гомәр, Марат Әмирхан, Камил Кәримов, Рәфкать Кәрами һәм башкаларны бөтенләй бетереп ташлыйбыз? Кем соң ул "заман герое"? Бармы бүгенге татар әдәбиятында заман герое булган татар? Газинур Гафиятуллин, Шакирҗан Мөхәммәтҗановмы? Бәшировның Нәфисәсе белән Еникинең Акъәбисеме? Әллә, Баржылы раславынча, язучылар үзләреме "заман герое"?

Мин татарның мәңгелек "заман геройлары" дип Мөхәммәт пәйгамбәрне, Кол Галинең Йосыфын, Зөләйхасын, Болгарга мөселман өммәтен китергән даһи акыл иясе Алмыш-ханны, Казан ханлыгын ныгыту юлында һәлак булган Сафагәрәй хан белән шушы ханлыкны саклау өчен үзен һәм сөекле угылы Үтәмешгәрәйне корбан иткән мәшһүр Сөембикәне таныйм. Колшәриф, Батырша, берүзләре ун романга торган Мәрҗани, мәшһүр Каюм-баба, татарның тарихта булмаган фаҗигаи баласы Солтангалиев...Ике империя арасындагы бөкәндә башы киселгән дөньякүләм мәшһүр Муса Җәлил һәм аның ун көрәштәшеме? Татар төзегән һәм тараткан империяләрнең каһарманнары кая булган? Болар бит барысы да без белеп тә "күрмәгән", күрүдән дә курыккан мәңгелек "заман геройлары"! Кайсы милләттә бар мондый алыплар?!

Кая ди безгә Мөхәммәт пәйгамбәр кебек "каһарманнар", без—"тыйнак", мин, мәсәлән, укыганымнан илле ел үткәч, Кави Нәҗминең "Язгы җилләр"ен, Афзал Шамовның "Рәүфә"сен, "Алар өчәү иде"сен, Ибраһим Газиның "Онытылмас еллар"ын, Гариф Гобәйнен "Маякчы кызы"н, Гадел Кутуйның "Сагыну"ын, Мирсәй Әмирнең "Агыйдел"ен генә түгел, хәтта "Кәлимуллин да чүлт, мин дә чүлт" дигән мәзәкләренә кадәр сагынам. Алардагы телне, җөмләләр камиллеген, вакыйгалар тыгызлыгын, сурәтләү чараларын—балачагымны сагынам. Укый торгач, мин дә безнең иң яхшы романыбыз Кави Нәҗминең "Язгы җилләр"е икән дигән фикер дә уянды әле! Нишләргә?

Әйдәгез, бергә уйланыйк. Дүрт гасыр ярым коллык арбасын тартып, царизм тарафыннан гыйлемнән һәм цивилизация казанышларыннан читтә калдырылып, күн итек-читектән чабатага, үз университетлары саналган мәдрәсәләрдән буразнага куып кертелгән, Петербур сазлыкларына субай булып кадалып, империя төзегән, ата-бабалары дүрт гасыр буе диярлек үзләренә ят булган империалистик сугышларда ятып калган, инде, ниһаять, 1917 елда ирек таңы атты дигәндә, тагын да алданып, татарның дүрттән өч өлешен "сталинчыл милли сәясәт яктысында" махсус рәвештә Самара, Ульян, Киров, Пермь, Ырымбур өлкәләре, Башкортстан дигән көчләп ясалган республика составында буып калдырганнан соң, халкының кечкенә өлеше урыс, чуаш, мари, мукшы, керәшен туганнарыбыз арасында көч-хәл белән генә сакланып кала алган һәм аерым киная белән Татарстан дип аталган җөмһүрияттә яшәп, егерменче-утызынчы елларда ике тапкыр имля үзгәртеп, ярымнадан, китапсыз, динсез-имансыз, атсыз-сыерсыз калдырылып, тагын да яңа коллык—колхозга куып кертелеп, ата-бабалары халык дошманнары буларак Себергә куылган, әле егерме яше дә житмәгән гади авыл малае—милләт углын инде тагын да чит мәнфәгатьләр хакына яңа империаль сугышка куып кертеп, пушка ите буларак, "амбразурага үзләре үк капланган" Газинур Гафиятуллин, Шакирҗан Мөхәммәтҗановларны без татар милли әдәбиятының "заман геройлары" итеп кабул итә алабызмы? Тиешбезме? Дөресме? Димәк, өнсез пушка ите булу—каһарманлык? Милли әдәбият каһарманы булу өчен, тәнкыйтьче Мансур Вәли-Баржылы раславынча, үз милләтен алдында каһарманлык кылуның бөтенләй кирәге юкмыни?! Әгәр милли әдәбиятта сурәтләнсә, безнең милләт өчен кыл да кыймылдатмаган сукбай да, милләт өчен гомуммилли әһәмияте булмаган "каһарманлык" та әдәбиятка каһарманлык булып керә ала? Туктагыз, капланганнармы әле алар пулеметлар авызына? Капланса, кайчан, кайда, кем, ничек, ни өчен, нинди хозурлыклар өчен бирелгән бу мәгънәсез корбаннар? Танклар юлын гәүдәләр белән түшәү пропагандасыннан бар ителгән бу кадәр дә очсыз, бу кадәр дә юләр үлем кемгә кирәк? Сталин күтәргән бу мөһмәләт—мондый шәһидлек күмәк-масса күләмендә булган булса, моның саваплары бүгенге Чечняда акланамы? Нинди мәгънә, нинди

мәнфәгатьләр хакына капланырга тиеш иде империаль сугыш амбразурасына кол татар баласы? Ярый, сугыш кызуында адәмзат мондый шәһидлеккә барды да, ди. Империя бу адымга "каһарманлык" статусы бирде, ди. Һәм мондый "башсыз" адым иясе татар әдәбиятында "заман герое" итеп игълан ителде, ди. Нәрсә, без, менә бетәбез, менә бетәбез дип торган милләт, бүген дә үзебезне изгән, келгән, талаган, ашсыз-жирсез-телсез иткән империя хакына шундый башкитәр шәһидлек кылып, шуннан үрнәк алып, үзебезнен генетик фондыбызны—балаларыбызны бер мәгънәсезгә юк итү юлына басыйкмы? (Хәер, басканбыз инде—татар егетләренең Чечнядә кырылуы шуны расламыймы?!) Без мондый шәһидлекне үзебезнең көннәргә күчерсәк, гомумән, әкәмәт килеп чыга: үзе өчен сугышта мондый "смертник-шәһидләр"дән "герой" ясаган Рәсәй бүген килеп, үзләренең милли азатлыклары хакына Рәсәйгә каршы шәһидлек кылган адәмзатларны "террорист" дип атый. Нигә бүген үзләрен басып алган баскынчы, илбасарларга каршы үзләрен шартлаткан шәһидләрне алар герой итеп кабул итмиләр? Шуңа күрә, "Кем ул "заман герое" дигән сорауга жавап бирү өчен без әүвәлдә "Нәрсә ул әдәбият һәм ул милләткә ни өчен кирәк?" дигән сорауга жавап табарга тиешбез . Бу сорауга дөрес жавап тапсак, инде килеп, әдәбиятнын үзенә "заман герое"нын ни өчен кирәклеге үзеннән-үзе аңлашылыр. Ягъни, сез беләсез кая барганны? Без беләбез кая барганны.

Юк, классик мантыйктан чыгып караганда, нинди генә "физик" батырлык эшләсәләр дә, бернинди Газинурны да, бернинди Шакиржанны да әдәбиятыбызның "герое" итеп кабул итә алмыйбыз һәм тиеш тә түгелбез, чөнки татар кебек коллыкка төшерелгән милләтнен милли әдәбият каһарманы булып бары тик милли азатлык, милли мөстәкыйльлек, милли консолидация, милли тәрәккыят, милли дәүләтчелек өчен көрәшкән шәхес кенә исәпләнә ала. Менә шуна күрә Рәсәй хөкүмәте үз гаебе белән тончыктырылган "Курск" су асты көймәсе корбаннарыннан "герой" ясый. Нинди икейөзлелек!.. Милли дәүләтчелекнең координатлары, башта ук әйткәнебезчә, адәм баласына Аллаһтан бирелгән биш үлчәнештә: азат Жир, азат Күк, азат Су, азат Ут, азат Рухта (Диндә) ихтыярланган. Димәк, татарның әдәбияты, әгәр милләтне азат итәсе килсә, әүвәлдә анын Рухын (Динен), Рухы белән бергә анын тирә-як Мохитын азат итү идеясен шигарь итәргә тиеш. Димәк, без, әгәр "бары тик табигатьне" сурәтлибез икән, милләтсез, өнсез, сынсыз табигатьне түгел, ә саф, чиста, башка катнашмалардан азат, Рухны күккә күтәрә торган милли табигатьне сурәтләргә тиешбез!.. Без бүген нинди табигатьне сурәтлибез соң? Без бүген сурәтләгән Жирдә, Күктә, Суда, Утта—ягъни табигатьтә биш координатның нәкъ бишенчесе—Рухның үзе, азатлык өчен изге фетнә, жиһат юк. Табигатьнен энә очында да кеше рухынын азатлык витамины жәйрәргә тиеш. Анда әлегә йокы. Мәнсезлек, милләтсезлек, имансызлык. Ватансызлык. Безне Туган Тел азат итмәде, Ходай Тәгалә азат итәчәк!

Аһ, бу чиксез зур мәсьәләме? Шулай шул. Димәк, "коллар вә кол балалары" булган Газинурларны "милли каһарман итү" азатлык категориясен коллык категориясе белән алыштыру һәм тарих диалектикасына каршы килү дигән сүз? Дөрес, "Рус белән гомер кичердек сайрашып". Моны кем әйткән? Татарның беренче без белгән бөек халык шагыйре Габдулла Тукай әйткән. "Россияне хәл кадәре мактау кирәк". Монысын кем әйткән? Монысын татарның, кызганычка каршы, әле булса үз бәһасен алмаган, без башкортка биргән икенче бөек халык шагыйре Мәжит Гафури әйткән. Дөрес, болар бу кансыз империя шартларында чәй-шикәрлек хәер көтеп һәм йодрык төйнәп әйтелгән тәгъбирләр.

Дөрес, яшәгән жиренә, көчләп тагылган ватанына дошман явы килсә, туган жиренне һәм шушы көчләп тагылган Ватаныңны, кем кулы астында яшәвенә карамастан, Коръән-Кәрим дә якларга куша. Никадәр ихлас һәм изге күрсәтмә! Күршең хакына. Күрше хакы—тәнре хакы. Үзенең самими, ихлас интернациональлеге белән Жир шарының Карл Маркс, Фридрих Энгельс, Владимир Ленин кебек "бөек интернационалистларын" да таң калдырган интернациональлек бит бу!... Әмма онытмыйк, шушы ук Маркслар шушындый ук интернациональлек белән коралланып, шушы ук Жир шарын тагын да нindидер яна "Алласыз Азатлык"ка алып барырга хыялландылар һәм жиңелүгә дучар булдылар. Ни өчен? Шигарьләр гадел, офыклар ачык иде бит! Аһ, офыклар канлы, Алласыз, дәһри,

канлы Кояшыбыз даһи Александр Блок күрә алган унике дәһри большевикның штыкларына эленеп калган иде... Маркс, Лениннар азат дөньяны азат Рухтан—Аллаһтан башка төзергә маташтылар һәм шуңа күрә дә җимерелеп төштеләр бит.

Әмма читтән яна дошман явы килгәч, үзен кичә генә коллыкка төшергән һәм хәтта вакытлыча анын туган җиренә хуҗа булып алган кичәге дошманың якларга чакырган Коръән адәм баласын шушы бер шарты белән генә дә ширектән, бидгатьтән—икейөзлелек, сатлык җанлылыктан саклый һәм ихласлыкта тәрбияли. Коръән-Кәрим Адәм баласының рухын яна афәт, яна бәла-каза, яна фетнәләрдән азат итә. Бу никадәр мөһим!.. Чөнки Изге Китап та, Изге Китапта тәрбияләнгән һәм кичәге баскынчыларыбызны мөмкин кадәр "мактарга, сакларга" кушкан, ятлар белән "сайрашып гомер кичерүебез" турында шактый шомартып язарга мәҗбүр булган классикларыбыз, милли азатлык идеясеннән ваз кичәргә кушмый, чөнки бу үзе генә дә бидгать булган булыр иде. Хәтта шул исәптән теге дәһри Маркс, Энгельс, Лениннар да бит милли азатлыкны, шәхес иркен инкарь итми, ә киресенчә, аларны бөек шигарь итеп файдаланып, фиркаләр оештыра, бөек фетнәләр күтәрә, дөньяны кап урталай бүлеп, миллион корбаннар биреп, кешелекне милли һәм социаль азатлыкка чакыра!..Димәк, ике бөек идеалистик һәм материалистик тәгълиматлар да кешелекне азатлыкка өнди!.. Болар барысы да безнен позициябезнең никадәр тарихи объектив һәм тарихи гадел булуын раслый түгелме?!..

Безнен олуг дастаныбыз "Идегәй"дә "Ком җыелып таш булмас, кол җыелып баш булмас", дигән бик мәгънәле тәгъбир бар. Чынлап та, бәлки безгә "җыелып, баш булырга маташырга", теге энә очындагы азатлык витаминын эзләп азапланырга кирәкмидәдер? Безнең башыбыз болай да "бозык" бит!.. Бәлки безгә һаман да шул Тукаебызның "Вактында җирне селкеттек, инде беттек, инде беттек!" дигәне белән килешергә дә, ләхеткә кереп ятаргадыр? Укучыбызның хәтерендәдер, кайчандыр урта гасырларда шанлы вә данлы госманлы төрекләр төркиләргә хас дәүләт югалту, дәүләтсез калу мәнкортлыгына карата "башы бозык" (урыс тарихында "башибузук" буларак йөри) дигән төшенчә керткәннәр иде. Чынлап та, без шанлы вә данлы төрки-татарлар, биш-алты тапкыр дәүләт төзеп, аны һич тә "зарланмыйча" кулдан ычкындырган милләт—нәкъ менә шушы "башы бозык" милләттер? Әгәр безнең башыбыз "бозык" булмаган булса, без дошманнан Казан ханлыгының танау төбендә Зөя елгасы тамагында кальга төзеткән, үз кулыбыз белән патшабикәбезне саткан, Казан тәхетен үз кулыбыз белән Явыз Иванга биргән булыр идекме? Һәм "ике мең еллык тарихы, мең еллык әдәбияты-сәнгате, мәгърифәте бар" дип мактанган, соңгы чорларда инде әйтәсе дә юк, җитмеш ел буе "өч йөз язучыбыз, меңләгән яшь язучыбыз бар" дип күкрәк каккан һәм югарыда әйтелеп үтелгән вакыйгаларның берсе турында да бер чын трагедиаль роман, повесть, хикәя, сәхнә әсәре, поэма язмаган, язылган очракта (Гаяз Исхакыйның Зөләйхасыннан башка—әмма сәхнәдә әле булса юньләп куелмаган!), безгә билгесез калып, башка илләрдә, башка телләрдә чыгармаган милләт язучылары—кем без, "башларыбыз бозык" түгелме? Мин "халык" һәм "холык" сүзләренең бер тамырдан булуларына бүген килеп ышандым. Халык ул—холык дигән сүз. Бөек халык—бөек холык. Боек халык—боек холык. Түзем халык—түзем холык. Бозык халык—бозык холык. Халыкның холкы—халыкның милке.

Безнен шушы сөйләшүне моннан нәкъ унбиш ел алдан күргән кебек, тәнкыйтьчебез Мансур Вәли (ул чакта әле "Баржылы" түгел), ул чорда сәяси көрәшнең гөмбәзенә йолдыз булып атылган язучыбыз һәм җәмәгать эшлеклебез Фәүзия Бәйрәмова белән "Халкының холкы бозык булса..." дигән әңгәмә үткәргән булган. Син аның туры килүен кара!.. Тәнкыйтьченең "Фәүзия Бәйрәмованың милли каһарманга әверелүе өчен нинди шартлар ярдәм итте дип саныйсыз?" дигән соравына язучы "Фәүзия Бәйрәмова да милли каһарман түгел. ***Тарихта милли каһарман исемен алу өчен милләтең өчен тиңсез батырлыклар эшләү кирәк***",—дип җавап бирә дә шунда ук өстәп куя.—***Шарт түгел, шартсызлык, чарасызлык, татар милләтенең соңгы чиккә килеп җитүе ярдәм итте...*** " ("Казан утлары", 10, 1990). Нинди куркыныч парадокс, ә? Без, язучылар менә шушы " чарасызлык, соңгы чиккә килеп җитүебез" турында әсәрләр, романнар язган булсак, бәлки милләтебез, айнып, бераз алга киткән булыр иде.

Димәк, бозык башларыбызны төзәтми алга китеш юк. Җиде миллион татардан

житмеш жиде татар калсак та (тәүбә-тәүбә!), без Ходай Тәгаләдән чын татар, иманлы татар булып калырга тиешбез. Бәлки без юкка борчылабыздыр? Аксакалыбыз Әмирхан Еники "Алардан (бөек әдипләребездән—А.Х.) калган рухи байлыкны сакларга тиешле дәүләтебез бар, аның Фәннәр Академиясе бар бит әле...",—дип безне тынычландырган иде. ("Казан утлары", "Шәхес", 1, 1997). Ай-һай, бар микән?

***Милләтең хакына тиңсез батырлык эшләү...***

Милли әдәбиятның каһарманы (без өйрәнгәнчә әйтсәк, "заман герое") каһарманлыгының гомуммилли масштабтагы әһәмияткә ия булуы шарт булып тормый икән, ул чакта мен еллык әдәбияты булган милләткә ***милли әдәбият нигә кирәк булган һәм ул бүген нигә кирәк?*** Милли әдәбиятның нигезендә милли идея ята. ***Ул беренче чиратта тарихи милли идея***. Милли идея Ходай Тәгалә тарафыннан милләтнең үзе белән бергә яратыла. Жир йөзендә ничә милләт, ничә шивә, ничә кабилә-ыру булса, милли идеяләр дә шул кадәр була. Милли идеясез милләт булалмый. Милли идея милләтнең умыртка сөяге, дөресрәге, умыртка сөяген ныгыта торган мәгълән-витаминнар—Көч һәм Куәт, Гармония һәм Әдәп, Матурлык һәм Батырлык, Туган Жир һәм Ватан, Милләт һәм Ходай Тәгалә, Ата һәм Ана, Милли Горурлык һәм Ватанны Сөю, бар Дөньяны һәм аның Табигатен—барча милләт, барча жанвар, кош-корт, барча тереклекне сөю һәм башка бихисап "сөйдергеч зәм»нәрне үз эченә ала ул милли идея. Канун буларак, һәрбер милләтнең милли идеясе изгелек белән сугарылган. Гармоник үсеш алып, тарихта ниндидер эз калдырган бер генә милләтнең кануннарында башкаларны басып алу, кол итү, башкалар исәбенә баю, яшәү идеясе ятмый, мина билгеле булган бер-ике "асыл, сайланган" (яһүди һәм урыс) милләтләрне исәпләмәгәндә. Әмма мондый раслама бу милләтләр тоташы белән начар икән дигән сүз түгел, аларда һәйбәт, иманлы, татарына биргесез кешеләр бихисап. Сүз бары аларның милли амбицияләре чагылган һәм шулар буенча яшәүләрен дәвам иткән кануннар—"Тәүрат" һәм "Петр падишаһ васыяте" кебек кануннар турында гына бара.

Һәр милли идеянең төп бурычы һәм мәгънәсе—милләтне мәңгелек һәм үлемсез итү. Кешелекнең төп мәгънәви сере дә үлемсезлектә. Милләтне аның мәңгелек булуы яшәтә. Ахирәтнең булуына ышану аны иманлы, әдәпле һәм мәңгелек итә. ***"Ил гомере—бер көн. Үтә дә китә. Ахирәт—мәңгелек. Ахирәтне югалтмагыз"***,—ди остазыбыз Исхакый үзенең "Зөләйха"сында. Үлемсезлек Аллаһтан килә. Мөселман-татар үзен үлемсез итеп тоя, чөнки ул тарихта билгеле эз калдырган иманлы милләт, шуңа күрә дә ул ялгыз түгел, аның белән бергә гел Аллаһы йөри. Үлемсезлек һәр милләт баласында Тарихи Аң тәрбияләү белән тәэмин ителә. Тарихи Аң исә үткәнендәге тарихи шәхесләрен—ил агаларын һәм каһарманнарын, руханиларын һәм остазларын, матурларын һәм батырларын, чичәннәрен һәм жырчыларын, ханнарын һәм биләрен, байларын һәм ярлыларын турында тарихи хәтер саклау. Милләтең баласында матурлык, батырлык, изгелек, юмартлык сыйфатлары тәрбияләү. Әмма милли идеянең төп бурычы—милләттә Вакыт һәм Аралыкның, Батырлык һәм Матурлыкның камил чиксезлеген, ягъни аның ***без буллык, без бар, без булачакбыз*** дигән үлемсез перспективасын тәрбияләү. Шуңа күрә дә төрки-татар халкының атаклы дастаны "Урал-батыр"ның төп каһарманы мәңгелек чыганагы булган тере Жанчишмәдән су эчеп үлемсезлеккә ирешә һәм дастанның төп идеясе Жанчишмә суын бөркеп, барча милләтне, табигатьне мәңгелек һәм үлемсез итү, аны дию-дошманнардан саклауга барып тоташа. Ижтимагый ясссылыкка күчергәндә, шушы ук идея икенче бер бөек дастаныбыз "Идегәй"дә, халык әкиятләре һәм риваятьләрдә, жыру-бәетләребездә ярылып ята. Бу тарихилык тойгысы безнең төрки-һуннар—Ат Илле (Аттила) Бабабыз, Орхан-Йәнәсәйләрдән калган руник язмалы балбаллардан, Азау-Кафтау Болгары—Кубрат-хан, Идел буе Болгары—Алмыш-ханнар, даһи Кол Галиләр, Мәхмүд Кашгарый, Мөхәммәдъярлардан килә...

"Заман герое" дигән төшенчә әдәбиятның героен бары тик "шул заман герое" булуы белән генә чикләнми. Аның вакыт кысалары юк, тирбәнеш амплитудасы чиксез. Бүгенге заманның яп-яңа "герое"ның жебегән булып чыгып, иске, борынгы заманның бүген сурәтләнгән "Гали батыры" чынлап һәм ихластан "заман герое" булып чыгуы мөмкин. Шуңа күрә милли әдәбиятны яшәтә торган мәңгелек

категориясе ул һәрчакта һәм һәрдаим ***соклану, үрнәк алу объекты*** булып тора.

Үрнәк соклану һәм сокландыруның өч алтын баганасы бар: ул—Матурлык, Батырлык һәм Иманлылык. Шушы өч сыйфат белән өртелгән һәм милләтнең чын, чүпләнмәгән теле белән ышандырырлык чаралар һәм символлар аша сурәтләнгән образлар—"заман геройлары" һәрдаим, һәр чорга замандаш" булалар.

Булмаган коммунизмны мактаган йөзләгән романнарыбыз чүплек башында, ә менә "борынгылар" исән-саулар. Менә ни өчен Муса Акъегетнең моннан йөз егерме ел элек язылган беренче татар романы "Хисаметдин менла" бүген иң актуаль, иң милли, безгә иң замандаш әсәр, ә Хисаметдин менла исә мәңге сокландыра торган чын "заман герое" булып калуын дәвам итә һәм итәчәк. Ул хак мөселман, милләтпәрвәр, көрәшче, чын гашыйк. "Заманыбыз герое" Хисаметдин менла "мөселман кешесе хәер сорашып бер капка ачса, Ходай Тәгалә аңа фәкыйрьлеккә җитмеш җиде капка ачар", дип татар-мөселманда булмаган хәер сорашу гадәтен тамырыннан корытырга теләп, җан-кардәше Мохтарны "полисия"гә тапшыра. Нинди намуслы гамәл!.. Минем күзләремә яшь бәрә... Бүген безнең үзебездән үк хәер сорашып эчкән һәм фәкыйрьлеккә җитмеш җиде капка ачкан "татар-мөселманнар"ыбыз күпме икән? Әйе, милләтенә мәхәббәт вә нәфрәтнең гомерлек соклану мисалын калдырган Акъегет әсәренең үлемсез чыраен даһилык кауры чылаткан. Әсәр бүген дә искермәгән, киресенчә, заманнан-заманга өлгерә, яңара, ә "герое" исә сагындыра гына бара. Хисаметдин менла, Акъегетнең үз сүзләре белән әйтсәк, "бүген сюртук кигән венгр". Сез андагы телне карагыз, телне!.. Без бүгенге романнарыбызда мондый телне көндез чыра яндырып та таба алмыйбыз: ***"Йөзенә баксаң, бу егерме биш яшьлек егеткә гаҗәпләнерсең. Йөзе ачык гүзәл. Яңарак чыкмыш кечек сакалы вә мыеклары, вә кыска чәче коңгырт төстә булып, матур йөзенең гүзәллеген тагын да арттырадыр. Нурлы вә күк күзләре китап битенең юлыннан юлына йөгереп үтәрләр. Башында бәрхет такыясының көмеш ае ялт-йолт ялтырар иде...***"

Анда нинди бөек мәхәббәт сурәтләнә. Хисаметдин менла белән Ханифә арасындагы мәхәббәт, Кандалыйның "Сәхибҗамал"ындагы лирик геройның Сәхибҗамалга мәхәббәте—болар татар әдәбиятының мәңге искермәс сәхифәләре. Мин дөнья әдәбиятында Кандалыйдан да бөек мәгъшук-шагыйрьне белмим. Бездә милли патриотизм булган булса, без туган җире Кандалда гына түгел, Мәскәүләрдә әллә кайчан инде аңа дөньяда булмаган бер Илаһи Мәгъшук Һәйкәле утырткан булыр идек. Сез карагыз: ***"Милли патриотизм исә гаҗәеп эшләргә сәбәпче булып, һәр олуг эшләрнең чыганагыдыр***". Моны кем әйткән—Әхәт Гаффармы, әллә Муса Акъегетнең Хисаметдинеме? Ул, әлбәттә! Моннан соң Хисаметдин менланы ничек "заман герое" димисең? Сез карагыз, ул бит әле татар авылларында бушка мәгърифәт китаплары таратып йөри!.. Ә мин сезгә әйтим, Гаяз абзый Исхакыйның "Сөннәтче бабае"? ***"Менә, җәмәгать, хәзрәти Сәлман Фарси пәкесе!... Җитмеш мең мөселманның сөннәткә утыртылган пәкесе!... Хәзрәти Аксак Тимердән калган ул!.."*** дип аның илаһи сөннәт пәкесе белән бәрәңге арчыган надан хатынны эттән алып-эткә салып сүккән Сөннәтче бабай!..Бармы бездә хәзер мондый "сөннәтче бабайлар"? Бар, эзләп кара. Сагындырамы? Сагындыра. Заман героемы? Заман герое. Ә сөннәт пәкесе белән бәрәңге арчыган наданнар һәм ата-аналарын урамга чыгарып ыргыткан имансызлар—бармы алар бездә бүген? Чат саен.

Ләкин, шунысы сәер һәм аңлашылмый: Тукай әйтмешли, җирне селкеткән, империяләр тоткан татарның империя тарафыннан сөннәтсез пәке белән печелгән иҗтимагый тарихы ни итеп бу кадәр дә батырсыз, каһармансыз калган, ә?. Башка милләтләрдә мондый хрестоматик геройлар тулып ята. Ә менә бездә "юк"—һәм вәссәлам. Юк, бездә Андрей Первозданный, Илья Муромец, Серафим Саровский кебек уйлап чыгарылган, мифик геройлар да юк. Башкалар мондый каһарманнары булмаса, уйлап чыгарганнар, шул "чудотворный" потларга табындырганнар. Без үзебезнекеләрне дә хәтердә сакламаганбыз, булмаганнар икән—уйлап та чыгармаганбыз.

Йә, хуш, булган "Гали батырларыбызны" йөктән төшереп калдырдык, ди. Без XYI-XYII гасырларда өч гасыр буе Рәсәйне дер селкеткән татар восстаниеләренең

көчләп-көчләп "башкорт" восстаниеләре, татар каһарманнарының "башкорт каһарманнары" буларак тарихка кертелүләрен беләбез. Авызыбызга су капканбыз да, эндәшмибез-тындашмыйбыз. Хәтта безнең энекәшләребез булган башкорт та без, татар, үстергән, укыткан һәм милләте ягыннан, халык сөйләвенчә, типтәр булган Салават-батыр дигән батыр бар, башкорт Пугач-патшаның бу, бер абзый әйтмешли, "йомышчы малаеннан", аның кечкенә, ун-унбиш сәнәкче-фетнәчедән торган "әтрәт башлыгыннан", бу "малайның" авыл масштабындагы шаяруларыннан галәми кубарылу күпертеп, соңгы илле елда безнең күз алдында анардан грекларның Зевсыннан да бөегрәк Алла-пот ясый алды. Ә менә безнең үзебезнең Салаватлар, татар булганнары өчен генә тарихтан сызыла килделәр. Кем ул Салават? Үзебезнең төрки-татар тудырган-үстергән, төрки-татар мулласы укыткан, гамәлдә бер милләт булган татар-башкорт баласы бит ул!.. Имеш, урысның иң нык курыккан милләте татар гамәлдә шулкадәр дә "булмаган, пешмәгән" милләт ки, ул Рәсәй сабанында ат, Рәсәй өчен сугышта арыслан булса да, "каһарманнар тудыра алмый, чөнки кулыннан килми". Империя татар тарихының Кол Гали Йосыфы, Казан камалышы сугышындагы Колшәриф имамы, алар белән беррәттән иң бөек татар каһарманнары булган Батырша мулланы да, Акай мулланы да безнең елларда Сталин милләт ясап, соңыннан Ельцин-Путин татарга каршы котыртып, акылдан яздырган башкортка бүләк итте. Ләкин "башкорт зиһене" татар муллаларының бу грандиоз фигураларын "йота" алмады, татар иҗтимагый фәне исә аларның Рәсәй империясе, бөтендөнья азатлык хәрәкәте, гомумтөрки, татар-башкорт тарихындагы глобаль ролен гадел бәяләүдән тартынып, үз батырлары итүдән куркып читкә тибәрелде. Нәтиҗәдә, бүген татар баласы табыныр каһарманы да юк. Башкорт баласы иртән күзләрен ачу белән дөньяга " Минем бөек Салаватым бар!" дип кычкырса, татар баласы күзләрен "Миңа бүген нинди яңа күлмәк кидерерләр икән?" дип ача...Татарда меркантильлек милли патриотизмны йоткан. Нәтиҗәдә бүген татарның Батырша кебек бөек уллары әле булса бер игътибарсыз "тарих сукбае" булып кала килә бирә.

Татарстанның тарих институты, минемчә, Батырша исемен йөртергә тиеш иде. Мәрҗани Батыршаның фәнни дәвамчысы гына. Батыршаның милли көрәшче-каһарман буларак татар тарихында дәвамчысы булалмады. Бар һәм дә бихисап иде алар, Бәхтияр Канкаевлар, аларны колониаль татар хәтере саклаудан тайчынды. Татарстан хөкүмәтенең Батырша исемендәге милли каһарманлык ордены булырга тиеш иде. Нигә булдырмаска, Башкортстан хөкүмәтенең Салават Юлаев ордены бар бит! Патшага каршы көрәшкән Салават Рәсәй герое да, шул ук патшага каршы көрәшкән Батырша Рәсәйгә каршы "террорист" мыни? Кая ди татарга Батырша ордены? Бәлки аңа Муса Җәлил ордены булдырырга кирәк булгандыр? Кая ди татарга мондый патриотик орден, аңа алдынгы сыер савучы, күп балалы аналарга бирелә торган калай да ясаттырмыйлар. Ә башкорт менә биш ел инде Салават Юлаев орденын тарата. "Татар" Батырша булмаса, "башкорт" Салават беркайчан да булмас иде. Йә, Хода, алар бит икесе дә бер үк милләт баласы!.. Салаватның бишеген Батырша тирбәтте түгелме? Бу орден белән бүген иң атаклы башкортлар бүләкләнә бит. Шул исәптән күптән түгел ул орденны безнең атаклы "башкорт милләттәшебез" Мостай Кәрим дә алды. Бәй, Батырша да, Салават та империягә каршы көрәштеләр бит, Салават Батыршаның бер кечтеки энекәше генә, нигә берсенең хөрмәтенә орден булдырылган, икенчесе бөтенләй онытылган—шунысы кызык, туган татар-мишәр авылы Карыштагы кечкенә музеен карарга килүчеләр белән дә ул, Батырша каһарман, татар мулласы, бары тик башкортча сөйләшә?!

Бәлки безгә, язучыларга, Җәлил һәм җәлилчеләрнең катлаулы образларын тудырып, аларны бер юлы ике империягә көрәшкән милли азатлык көрәшчеләре итеп күтәрергә, мөстәкыйльлек өчен көрәш юлында бу мөмкинлекне халыкара шигарь кинлегенә чыгарырга кирәк булгандыр? Моның өчен татарга ләх, Балтыйк буе халыклары, һич югы чечен халкы менталитеты кирәк иде шул.

Сәясәт диярсез. Сәясәт. Татар әдәбияты әнә шул сәясәттән югарыга күтәрелеп, империянең пычрак уеннарын яңа образларда ачарга һәм империячел сәясәтчеләрне урыннарына утыртырга тиеш иде. 1945 елның 30 апрелендә Җиңү байраган Рейхстаг түбәсенә Егоров белән Кантариядә бер тәүлек диярлек алдан калаган Гази Заһитовка

багышлап, өч йөз язучыдан торган Татарстан Язучылар берлеге, башка иҗади берлекләр әгъзалары әллә кайчан инде романнар, повестьләр, хикәяләр, либреттолар иҗат итеп, җырлар, ораторияләр, опералар, балетлар, кинофильмнар тудырырга, Заһитов исемендәге урамнар, аның исемендәге медаль-орден булдырырга, аңа һәйкәлләр куярга тиеш иде. Авыз суларын корыта-корыта Әби патшаны данлаган өчен Казаныбызның ин үзәк мәйданына кунаклап алып, безгә авыз ерып утырган бакыр бабабыз—һәйкәлле "үз татарларымыз" Гавриил Державин, Федор Шаляпиннар белән "киңәшеп", әлбәттә!.. Казанның 1000 еллыгы килеп җитте. Менә илле ел инде Салих Сәйдәшкә, менә дүрт йөз илле ел инде Казан камалышында һәлак булган бабаларыбызга һәйкәлташ юк тек юк. Моннан соң безнең "каһарманнарыбыз" ничек итеп тарихта саклансын?! Кая безнең шундый канэчкеч империя шартларында татарга мәчет, мәдрәсә һәм китап сузган Рәмиевләр, Хөсәеновлар, Кәримовлар, Юнысовлар, Акчуриннар, шулар яктысында даһилык каһарманлыгы кылган Тукай, Газиз Гобәйдуллин, Бубыйлар, Фатих Кәрими, Һади Такташ, Муса Җәлил, Салих Сәйдәш, Гаяз Исхакый, Мирсәет Солтангалиев, Бакый Урманче, Нәҗип Җиһанов һ.б.ш. даһи агаларыбызның чын милли образлары? Кая?!

Чынлап та, минем генә түгел, укучыларыбыз, сезнең дә канлы тарихыбызның ничектер даимән "каһармансыз калуы" турында уйланганыгыз бардыр. Гүяки безнең әдәбиятта Кол Гали бабабыз унөченче гасыр уртасында безгә Йосыф белән Зөләйханы тудырып калдырган да, аннан хәтеребез урта гасырлардан Алтын Урда тарихы аша көч-хәл белән (дистә төрки милләтләр куллары аша!) Идегәйне, "Казанны алу бәете", "Сөембикә" бәетләрен саклап калган да, аннан соң гүя кемдер безнең әдәбиятны кылыч белән тураклап, утта үртәп чыккан. Гүя безнең яралып килгән яшь урыс империясе белән алты йөз еллык көрәшебез тарихында да, Казанны яулап алу тарихында да (Колшәриф һәм берничә исемнән башка) , инде басып алынгач, урыс патшасы бер үк вакытта "Казан падишаһы" дип аталып йөртелгән чорда һәм анардан соңгы дүрт йөз еллык империаль чорда—бихисап баш күтәрүләр, урыс алып барган йөзләгән (урыс-швед, урыс-ләх, урыс-төрек, урыс-француз, урыс-герман һ.б.һ.б.) сугышларда катнашып миллионнарча башын салган хәлдә дә, безнең татарның "тарихи каһарманнары" булмый калган... Әкәмәт бит"!.. Кызык бит!.. Ә нигә кирәк ул "каһарманнар" безгә?—дип сорарга телидер кемдер. Нигә булсын—милләтне үлемсез итү өчен кирәк! Милләтне өметле, бәхетле, киләчәкле, дәүләтле—димәк ки мәңгегә матур, батыр вә иманлы итү өчен кирәк!..

Империянең "сөннәтсез бабаларының" безнең тарихыбызны яндырулары, җимерүләре, юкка чыгарулары—"геройларыбызны" менә биш йөз ел инде "печеп" утырулары билгеле. Шул ук "Идегәй"дә кат-кат әйтелүенчә, "заман кемнең заманы?" Монда барысы да ачык. Мин империалистка үпкәләп вакланмыйм. Чөнки инабәт көтмим. Ул бит шуңа да империя. Мин бары рәнҗим, бары тик үзебезгә рәнҗим. Чөнки миңа татарның, аның язучысының тарихи аңы, ихтыяры, киләчәккә өмете, үлемсезлеккә претензия-дәгъвасының бөтенләй булмавы аңлашылмый. Аның язучысының җавапсыз, куркак, вак җанлы һәм үз-үзе белән сокланучы "позер" икәнлеге аңлашылмый. Мондый кыйланчыклыгы өчен мин аны, кем әйтмешли, агач мылтыктан атар хәлгә җитәм.

Милләтенең Батырлыгы сурәтләнми калгач, ничек итеп рухи батыр милләт тәрбияләргә мөмкин? Илаһияты, иманлылыгы сурәтләнми калгач, ничек итеп илаһи, иманлы милләт тәрбияләргә мөмкин? Милләтенең бәхете өчен көрәш әдәбияты булмаган милләтне ничек итеп көрәшче милләт итеп тәрбияләргә мөмкин?

Язучының чишмә башы аның милли фаҗигасендә. Без—татар фаҗигасе балалары. Әмма әдәбиятыбыз булып та фаҗигабез язылмаган. Бу икеләтә фаҗига түгелме?

Мең еллык тарихы булган татар әдәбиятындагы без эзләгән "заман герое" мәсьәләсенә, минемчә, менә шундый таләпләр аша килергә кирәктер. Шулай иткәндә генә безгә билгеле ике мең еллык тарихыбызга җан өрә, кан белән баектыра, сумит-мускул утырта алачакбыз. Без иҗади процессны ирекле, ул бернинди диктатка буйсынмый дип игълан итәргә яратсак та, әдәбиятка "заман герой"ларының күктән төшмәгәнен, бу төшенчәнең билгеле бер күләмдә идарә ителә торган дәүләти процесс икәнлеген төшенәбез. Дәүләте булмаган милләт әдәбиятында "заман герое"

булалмый. Дәүләте булмаган милләт дәүләте булсын өчен әдәбиятында "заман герое"н булдыру өчен ***көрәшергә*** тиеш. Тагын да көрәш, шайтан алгыры!.. Башкача булмый икән шул.***"Без күп еллар дәвамында, үзебез кыен сүз әйтү түгел, әйтә алганнарны да яклап чыга алмадык. Яшьләребезнең дә әдәбиятка шактый имгәнеп, икеле-микеле уйлар белән килүендә дә шушы йомшаклыгыбыз сәбәпчедер дип уйлыйм..."***—дип язган иде Аяз Гыйләҗев бу хакта уйланып Салих Батталга багышланган "Үкенечләрнең берсе..." дигән мәкаләсендә ("Казан утлары, 8, 1990)

Татар язучысы, әгәр ул үзен милли тарихы, милләте, иманы—Ходай Тәгаләсе алдында җаваплы тойган булса, "язучылар берлеге" дигән оешма оешкан заманнардан алып, нәкъ менә шул "идарә ителгән" шартларда татар тарихын кишәрлекләп-кишәрлекләп бүлеп алырга, сөреп чыгарга, татар әдәбиятының тарихи-әхлакый панорамасын тудырырга—шуның белән милләтне үлемсез итү өчен тырышырга тиеш иде. Милли әдәбиятның милләт уллары һәм кызларының милли азатлык хакына кылынган иманлы батырлыклары сурәтләүдән дә зуррак бурычы һәм мирасы юк. Иң мөһиме тамырлы һәм мәдәниятле булу. Тарихлы булу, мәгърифәтле булу. Болар булса, дәүләтең булмаса да сакланырга мөмкин. Милләтне бер Ходай Тәгалә "коллыгы" хакына башка барча төр коллыклардан азат итү—бу бит иң изге бурыч. Моны да сурәтләмәгәч, милли әдәбиятның, милли архивның нинди кыйммәте кала? Безгә бер-беребезне бәяли белергә кирәк. Әдәбиятта әдип булып калу өчен диплом кирәкми. Анда мәгърифәтне, культураны читләтеп кенә дә әдип булып булмый. Безнең бүгенге күп кенә язучыларыбызның "культураны читләтеп үтеп" әдип булырга тырышуы әдәбиятның бәясен төшерде.

Үткәнебезнең әдәби-әхлакый, иҗтимагый-сәяси тарихын тудыру ул һич кенә дә бары тик тарихи әсәрләр язу дигән сүз түгел, гәрчә безгә безне генә түгел, дөньяны ышандырырлык, таң калдырырлык тарихи әсәрләр бик кирәк булса да. Син, телисең икән, нниндидер унынчы гасырның яңа мөселманга кучкән Гөлбикәсенең язмышын яз. Ләкин ул, Михаил Лермонтов һәм үзебез әйтмешли, "безнең заман герое" гына булсын. Тарихи әсәрләребезгә килгәндә, аларны язу бер Нурихан Фәттахка, Мөсагыйт Хәбибуллинга, "Идегәй" дигән искиткеч яхшы киносценарий язган Рөстәм Мингалим белән Ризван Хәмидкә генә кирәкмәгәндер. Сүз биредә әсәрләрнең сыйфаты турында бармый, бу икенче мәсьәлә. Нигә без "Болгарның жылы жилләре" дигән фильм тудырабыз дип милләт миллионнарын ашап, инде дистә еллар буе милләтне алдап йөргән милләтсез татар балалары Булат Мансуров һәм аның "гөргөриле" иярченнәрен җавапка тарттырмыйбыз? Милләт кадәр милләтне алдау нәҗесенне ярга чыгарып бушатудан да җинел эшкә әйләнде. Бу җавапсызлыкны төптән уйланылган "провокация" дими ни дисең?! Соңгы елларда аерым язучыларыбыз һәм шагыйрьләребез, милләт алдында зур җаваплылык тоеп,"заман герой"ларын "үзебезнең арадан" эзләп карадылар. Ибраһим Нуруллин Габдулла Тукай һәм Фатих Әмирханга багышланган фәнни биографик китаплар, Җәмит Рәхимов Батыршага, Рабит Батулла Сөембикәгә, Ринат Мөхәммәдиев Мирсәет Солтангалиевкә, Рашат Низами Фәрит Яруллинга, Кыям Миңлебаев Бакый Урманчега, Факил Сафин дәүләт эшлеклесе Әхмәтсафа Дәүләтьяровка багышланган романнар, Фәүзия Бәйрәмова Такташка багышланган драма, Равил Фәйзуллин Сәйдәшкә, Әхмәт Рәшит, рәхмәт төшкере, бер юлы өч бөек шәхесебез—Сөембикә, Колшәриф, Мөхәммәдьярга, Кави Латыйп Гәүһәршадка, Эльмира Шәрифуллина Каюм Насыйрига, Габдулла Тукайга багышланган поэмалар, Зиннур Мансуров Хозыр галәйһес-сәламгә, Хәйретдин Мөҗәйгә, Мөдәррис Әгъләм Тукайга хәтләр һәм шигырьләр шәлкемен тудырдылар. Сүз, кабатлап әйтәм, сыйфат турында гына түгел, ә милләт алдындагы җаваплылык принцибы турында бара. Файдалана белеп файдалансаң, күпме байлык! Әмма милләтебезнең, әдәбиятыбызның зурлыгыннан, борынгылыгыннан чыгып караганда бик кечкенә бу исемлек!..

Фикеребез ачык булсын өчен бер фараз китерик. Бөек Ватан сугышында СССР-ның бер генә милләте дә татар милләте кебек шул кадәр күп язучысын югалтмады. Аларның исемнәре иске Матбугат Йортының гранит тактасында. Эш шуның белән беттеме? Утызынчы елларның культ афәтеннән дә татар милләте искиткеч зур зыян күрде. Суга төшкән балта кебек югалган Һади Атласый, Кәрим Тинчурин, Фәтхи

Бурнаш, Гомәр Гали, Мәхмүт Галәү, Афзал Таһиров, Имай Насыйри, Шамил Усманов, Гомәр Толымбай һәм башка шундый (һич арттырмыйм!) титаннарыбызның фәнни биографияләрен, аларны югалту аша милләтебез кичергән югалтулар турында татар язучылары—без язмасак, кем язар? Әгәр дәүләте булмаган милләтнең Язучылар берлеге бар икән, димәк, аның чикләнгән хокуклы булса да дәүләте бар булып чыга? Шулай булгач, нишләп безнең Язучылар берлеге югалтуларыбызны китапларыбызда булса да кире кайтару, милләттә киләчәккә ышаныч, үлемсезлеккә дәгъва булса да белдерү ниятендә бернинди чаралар күрми? Хәзер архивлар ачык бит! Нигә без ялкау? Нигә без үзебездән башка беркемне белмибез? Нигә без үзебездән башка беркемне укымыйбыз? Нигә татар язучысы тарихи романын юньлерәтле архивта казынып тормыйча, өстә-мөстән генә, бармактан суырып, ясалма тел белән "Византия" тарихларын яза? Нәрсә, без, язучылар, оешмабыз шундый башлангыч белән чыккан хәлдә, үтерелгән пәйгамбәрләр—үз каләмдәшләребезнең язмышларын архивлардан тикшереп, ачыклый, бергәләп "коллектив биографияләрен" яза алмаган булыр идекме? Алар тоталитаризмга каршы көрәшчеләр, ягъни "безнең заман геройлары" түгел идемени? Мәхмүт Кашгарый әйтмешли, "Тегермәндә тугмыш сычган күк күкрәгәндә курыкмас". Язучылар берлегенең бурычы купшы идарә утырышларында купшы фразалар ыргытып, өч каен арасында үткәрелгән әдәби очрашулар турында отчет тотып утыру белән чикләнмәскә тиештер бит? Шушы юлларны язганда "Казан утлары" журналында Рабит Батулланың "Җимерелгән бәхет" пьесасы басылып чыкты. Мин аны әсәрләнеп, йотлыгып укыдым. Анда язачак җирлекне белү белән тел, сюжет, әдәби культура гармоник рәвештә тигез тәңгәл килә. Бу безнең әдәбиятта зур вакыйга һәм Батулланың язучылык батырлыгы. Аны киносценарий дип атап булыр иде. Формаль яктан Кәрим Тинчурин, аның хәләл җефете Заһидә апаның фаҗигале язмышына багышланган булса да, гамәлдә бу әсәр XX гасырда кырылган татар интеллигенциясе турында чеңләү, зар елау, бөек бер Сага.

Равил Фәйзуллинның "Гыйбрәтләр алырлык үткән юл" ("Казан утлары", 8, 9, 2004) дигән искиткеч фәһемле хезмәте дә шушы казанышлар исәбенә керәдер.

## МӘХӘББӘТСЕЗ ӘДӘБИЯТ, ЯКИ ТӘНКЫЙТЬ ТӘНКЫЙТЬКӘ МОХТАҖ

Әдәбиятыбыздан заман каһарманнарын табарга тиешле тәнкыйди бәхәсебез баштан ук тәнкыйтькә лаек булып чыкты. Журналның гыйнвар-сентябрь саннарында тәкъдим ителгән унлап чыгышның, минем карашка, бары тик дүртесе—Рәфыйк Шәрәфиев, Рәшит Фәтхерахманов, Рафаэль Мостафин, Рөстәм Зарипов чыгышлары гына максатка яраклы булып чыкты. Калганнары ният ителгән бәхәс уңаеннан, предметны төптән өйрәнеп, махсус язылмаганлыктан, кайберләре исә артык комплиментар, очраклы, "юктан кодагый" гына булганлыктан, аерым кызыклы фикерләре белән күзгә чалынсалар да, башланган сөйләшүне тирәнәйтүгә хезмәт итмәделәр.

Рәфыйк кардәшебез "Киләме, күрәбезме?" дигән чыгышы белән ( "Казан утлары, 1,2004) сөйләшүне "мөгезеннән тотып", югары таләпләр түбәсеннән башлап җибәрде. Дөрес, "заман герое"на карата булган таләпләрен Шәрәфиев ачыклап маташмый, алар, ана, күрәсең, үзеннән-үзе аңлашыла. Минемчә, татар әдәбиятында яңа заман герое мәсьәләсе аның нинди булырга тиешлегеннән башланырга тиеш иде. Мавыктыргыч, милли мәнфәгать, борчулы тел белән язылган бу мәкаләне бер тында укып чыгуга миндә бәхәсебезнең уңышлы чыгачагына өмет ныгыган иде. Әдәбият яңа геройларга претензиоз, ягъни дәгъвачыл принциптан килергә тиеш, шулай булмаганда аның кирәге калмый. "Татар килә!" дип башлый автор үзенең сүзен. Ягъни "яңа татар". Никадәр тос, вакытлы ишарә!.. "Яңа" нәрсәләрне без, татар, гадәттәгечә, гел сонарып, ягъни "яңа татар"ны "яңа урыс"тан күчереп алырга өйрәнсәк тә, кызык бит—нинди икән ул, "яңа татар"? Без эзләгән заман каһарманымы, әллә букәйме? Марат Әмирханның 2003 ел башында басылган "Тояк эзе" романыннан Р. Шәрәфиевнең эскәге белән тартып чыгарылган бу мәгънәле

фраза безнең соңгы егерме еллык әдәбиятыбызның эчке претензиясе була алмыр. Әсәрнең төп каһарманы булган тарихчы Кәшшаф Муса Акъегетнең Хисаметдин менласы, Гаяз Исхакыйның Шәмсие, Гомәр Бәшировның Нәфисәсе, Әмирхан Еникинең Акъәбиеннән соң XXI гасырга нинди дәгъва белән үтә? Яшермик һәм дөресен әйтик: соңгы елларда бик тә актив эшләгән Марат Әмирханның соңгы романы яна сүзне әйтү хакына сизелерлек дәгъва ясый һәм Кабан күлен жиләс жил тыны белән шадралатырлык кына булса да унышка ирешә. Ул дөньяга бар иткән яңа герой—әсәрнең төп каһарманы тарихчы галим Кәшшаф әдәбиятыбыз тарихының "Кабан күле"ннән дә чынлап та беренче тапкыр Алтын Урданың ком вә чүп-чар тулган алтын бишеген күтәрергә тырышып карый. Әле кайчан гына без, "Бөек Болгар" жимерекләре, андагы "мунча юллары" турында гына язудан ары жибәрелмәгән татар, үзгенә Алтын Урда коллизиясен куеп, әдәби роман язу турында хыяллана да алмый идек. Бәхәстә катнашкан тәнкыйтьче Рафаэль Мостафин бу хакта уйланып сүзне шулайрак башлап жибәрә: ***"...Язучылар гына түгел, тарихчылар да Алтын Урда, Казан ханлыгы чорларын читләтеп үтәләр иде. Бу күренешне*** (нинди күренешне?—А.Х.) ***Марат Әмирхан.. бик ышындыргыч*** ( ничек?—А.Х.) ***итеп тасвирлый. Әмма аңа котычкыч интригалар, аяк чалулар, хыянәт һәм алдаулар аша үтәргә туры килә..."***

Кызганычка каршы, әсәр бер тында язылмаган. Ул тигез түгел. Урыны-урыны белән кызыксынып укылса да, ул мине нәкъ менә шул "аяк чалулар, интригаларының" сурәтләнеше белән жәлеп итеп житкермәде. Югыйсә, безнең заман әдәбиятының потенциаль герое Марат Әмирханның "Тояк эзе"ндә ята. Герой дөрес табылган, ул "килә", тик "күренми". Авторның художник-сурәтчелек куәсе житешмәве үзен сиздерә. Гамәлдә автор Кабан күленнән теге чын "геройны" чыгара алмаган. Анда исә—баткак. Автор мизгел эчендә "Генераль Штаб"лар масштабыннан бәрәнге казу барышы турындагы "район газетасы" масштабына төшә. Мондый темага алынгач, аны вакларга ярамый. Мондый халәт сандалга дөлдә (кувалда) белән тондырганны ярата. Галимнәрнең һәм карашларның бәрелеше тиешле матди һәм рухи киренкелектә, тирәнлектә, ышандырырлык итеп сурәтләнмәве, сурәтләрнең образга, детальләрнең символга житкерелмәве, авторның "күтәргән темасына күтәргән күсәге белән" каны чәчрәгәнче сукмавы, еш кына кытыклавы, аннан Казан галимнәренең тормыш рәвеше бик тә вак, туйдыргыч хәсет, күренешләрнең өзек-өзек булып, монументальлекнең житмәве, идеологик бәхәсләрнең күп тапкырлар кабатланган, ифрат та шау-шулы, көндәлек ыгы-зыгыда бирелүе төп каһарманны гына түгел , бөтен романны ваклый. Романда безнең соңгы еллардагы татар прозасына хас булган тел һәм сурәтләү чараларының төгәлсезлеге, шапшаклыгы тулып ята. Алтын Урда тирәнлекләренә, аның каһарманнарына глобаль масштаблар кирәк. Романга киң тарихи экспозиция, нәкъ менә шул глобаль масштабның житмәве үзен сиздерә. Кирәгеннән артык сузылган роман-язмада укучыны күкләргә алып менә торган илаһи тын юк. Шул тын безне күкләргә күтәргән һәм Шәрәфиев эзләгән "Яңа татар "ны табып биргән булыр иде, бәлки. Әмма дәгъва дәгъва булып кына кала. Шулай да тәнкыйтьче язучының ***"...Сурәтләү чаралары... байтак каһарманнарны әлеге газит битләрендәге конкрет шәхесләрдән аерып бетерә алмый. Алайса, "Татар килә!" дип шатланып, "Звезда Поволжья" каһарманнарының әдәбияттагы гәүдәләнешләрен генә көтеп алганбыз булып чыгамыни? Нәрсә соң бу, заман әдәбиятының тормышка якынаюы шушылай пародия төсен алды мәллә?"*** дип ачынса да, мин әсәрне пародия кимәленә төшереп ташламас идем. Автор урынында булсам, кире кайтып, романның йомшак урыннарын яңадан язган булыр идем. Бер тотынгач, Кабан күле төбеннән теге "чын геройны" алып чыгарга иде!.. Марат кардәшебез бүгенге татар әдәбиятында әлегәчә күтәрелмәгән темага батырларча тотынып, чирканчык алган да, гүя упкынның тирәнлеген чамалаганнан соң, нәкъ татарча алымнар белән аннан тиз генә чыгу ягын караган. Фатыйх Әмирханнардан йөз ел соңлап килгән бүгенге Әмирханнарга бу да зур батырлык бит әле!..

Р. Шәрәфиевнең "Әдәбият белән реаль тормыш үзара ярышып, бер-берсеннән өйрәнеп, казна караклары, мафия, азгынлык корольләре һәм королевалары, алар тирәсендә ялманып йөрүче мескеннәр үрчетә",—дигән гомуми "кара" нәтиҗәсе

белән теләр-теләмәс кенә килешәм. Безнең әдәбият соңгы егерме-утыз елда бары тик гел "азгынлык корольләре" генә үрчетеп ятмады. Дөрес, аны унтугызынчы гасыр азагы-егерменче гасыр башында җәдитчелек дулкынында башланган шайтанлык басты басуын, тик Аллага шөкер, тәмам басып китә алмады. Без "каһарман эзләгән" бу чорда гына да Гариф Ахуновның "Идел кызы"ндагы Нуриясе, Мөхәммәт Мәһдиевнең "Мәңгелек яз"ындагы Әхияры, Ибраһим Салаховның "Иманнәр тамыр җәйгәндә"сендәге Госманы, Җәмит Рәхимовның Батыршасы, Фәүзия Бәйрәмованың "Болын"ындагы Алсуы, Тәбриз Мөбәрәковның "Хәтер аланы"ндагы Тәүфыйгы, Айдар Хәлимнең "Өч аяклы ат"ындагы Кәбире, Мәхмүт Хәсәновның "Язгы ажаган"ындагы Иргалие, Нурихан Фәттахның "Сызгыра торган уклар"ындагы Албуга белән Туман каганы, Мөсәгыйть Хәбибуллинның Кубрат ханы һәм бу исемлектән читтә калган кайбер язучыларыбызның аерым-аерым истә калган образлары татар әдәбиятының әле шактый җегәрле булуын раслый.

Рәфыйк Шәрәфиев безнең соңгы егерме елда барлыкка килгән "яңа әдәбият"кә "азгын әдәбият" дигән исем кушты һәм аңа сизелерлек һөҗүм ясады. Мин үзем бүгенге "азгын әдәбият"ны укый алмыйм. Хәтта ул бик оста язылса да. Тыным буыла, йөрәгем кага башлый. Чөнки без аңардан тормышта да туйган. Каян килеп, кайчан кереп китте безнең әдәбиятка тормышны нәкъ үзе кебек аяныч, шәрә, пычрак сурәтләүләрнең "бүсерле" күренеше? Әдәбият кешене илһамландырырга, бер карыш булса да җирдән күтәрергә тиеш!.. Көньяк Америка сериалларында хыянәт белән шундук үбешү арасында чик булмаган кебек, чиксез "азгынлыкларны" сурәтләгән бу "әдәбият" татарга "заман каһарманнарын" бирә алмаячак. Бәлки... заман шул кадәр дә үзгәргән ки, бәлки нәкъ менә шулар безнең Нәфисәләр, Акъәбиләр васыять итеп киткән геройлар шулардыр? Бәлки "унай геройлар" хәзер "кире геройлар"дыр? Тәүбә, тәүбә!..

Рәфыйк Шәрәфиев кискен, аяусыз бәясе белән безне иманга китерергә, уятырга тели. Гомумән алганда, укучы тарафыннан чагыштырмача җылы, теләктәшлек белән кабул ителгән әсәрләребез—Тәлгат Галиуллинның "Тәүбә", Флүс Латыйфиның "Ишелеп төшкән бәхет", Зиннур Хөсниярның "Терсәк сугышы" романнары, Әсгать Сәлахнең искиткеч осталык белән "азгын мәхәббәтне" сурәтләгән "Каеннар юлы" повесте каһарманнарын да кызганмый утка тота ул. "Укучы җылы кабул иткән" дидем дә уйланып калдым. Кем әле ул укучы үзе? Һаман да шул онытылгысыз Аяз ага Гыйләҗев искә төшә. Моннан кырык ел элек Әхсән Баяновның "Яшьлегемне эзлим" повесте буенча кузгалган бәхәстә авторны "укучы исеменнән кыйнау" кызып киткәч, аның "Ә син үзең кем, укучы?" дигән мәкаләсе белән җәмәгатьчелекне айнытканы хәтердә. Тәнкыйтьченең җаны-тәне белән әрнеп чистартасы килә дөньябызны. Бу теләк "авыл мохитындагы тыйнак" авторны да Татарстанның милли азатлыгы, суверенитет темаларына алып кереп китә. Чөнки шунсыз мөмкин түгел. Милли әдәбиятның "заман каһарманы"—без телибезме-теләмибезме—ике мең еллык тарихыбызның патриотик чагылышына, милли дәүләтчелегебезнең булмышына барып бәйләнә. Шуңа күрә безнең әдәбиятка "укучы җылы кабул иткән", "гомумән яхшы" әсәр язу гына җитми. Аңа бар милләтне уята торган ялкынлы, илһамлы, мәхәббәтле герой кирәк. Баксаң, без мәхәббәтсез дә калганбыз икән бит. Безнең романнарда, повесть-поэмаларда, хәтта шигырьләребездә дә ялкынлы мәхәббәт сурәтләнүдән туктаган икән бит. Без хәзер шул кадәр дә "азып-тузып" яратмый-сөйми, бала тудырмый башладык микәнни?! Әле без үзебезне белә башлаганда әби-бабаларыбызның ин дәҗҗал кешегә дә "И-и, мәхәббәтсез!" дип әйтүләренең милләтебездә иң әшәке сүгенү булып яңгыравы искә төшә дә, безнең фаҗигабезнең—"геройсыз" калуыбызның башы мәхәббәтсез калуыбызда икәнлеге аңлашыла төшә.

Мондый мәхәббәтсез әдәбиятны укыган хәлдә, киләчәк буынның күзләре генә түгел кальбе дә сукыраячагы көн кебек ачык. Әгәр әсәрдә чын, кешене дулкынландырырлык мәхәббәт юк икән, ул язучыга ышанырга мөмкинме? Ул, гомумән, язучымы? Безгә инде хәзер шигырьләрендә һәм хикәяләрендә мәхәббәтнең нәрсә икәнен дә белмәгән язучы-шагыйрьләр буыны килә башлады. Бу нәрсә—катастрофамы, тәмам җимерелүме? Шәрәфиев белән бер авыздан шушы ук фикерне Рәшит Фәтхерахманов ("Казан утлары", "Татарга сатма матбугат", 3,2004) " та

билгеләп үтә һәм мәсьәләне тагын да конкретлаштыра төшә: ***“ Гөлчәчәк Галиева, Тәлгать Галиуллин, Әсгать Сәлахларның соңгы вакытларда “Казан утлары”нда басылган повесть-романнарын гына алып карыйк: зина үзенең бөтен формаларында гадәти яшәү рәвешенә әйләнгән, башка төрле бозыклыклар да табигыйләшкән, авторлар боларны талантлы каләм белән тәфсилләп һәм нечкәләп тасвирлыйлар***”. Мин әйтер идем хәтта: бер-берсе белән ярышып тасвирлыйлар. Шунысы кызык бит:. ***БӨЕК ИЛАҺИ МӘХӘББӘТ ЮК, Ә МЕНӘ БӨЕК БОЗЫКЛЫК, БӨЕК ЗИНА БУА БУАРЛЫК.***

Чөнки, имеш, тормышта шулай. Бездә “башыбозык”, язучыдан яна фикер, әдәп, иман таләп итә алмаган “азгын” укучыга вакыт үткәреп укырлык әсәрләр күп, тик җан чистартыр дәрәҗәдәге мәхәббәтле әсәрләр генә сирәк. Язучыларыбыз аңларга тиеш иде: Татарстан мөстәкыйльлеге өчен көрәш, “прусты тел өчен” генә түгел, биш гасыр элек бездән тартып алынган мәхәббәтебезне кире кайтару өчен көрәш иде ул. Шулай булмаганга күрә бездән аны җинел генә тартып та алдылар. Без аны җинел генә бирдек. Шуна күрә бу көрәш, мәхәббәт хакына, мәхәббәткә хокук хакына көрәш булгач, милләтнен санына карамый, беркайчан да тукталмаска тиеш. Латин әлифбасы өчен генә түгел, гарәп әлифбасы өчен көрәш тагын да мәһабәтрәк вә мәхәббәтлерәк булган булыр иде. “Чынлап та безме сон бу? ***Бигрәкләр дә пычранганбыз, гөнаһка батканбыз, миһербансызланганбыз, йөзебезне үк югалта барабыз икән бит***...”—дип уфыра да, аннан, мәкаләнен авторы, тешен кысып,— ***“Өергә каршы торырлык милли бердәмлек, милләтне бер максатка туплый алырлык каһарман житми бүген***”,—дип нәтиҗә ясап куя...

“Зина әдәбияты”на кагылып, тәнкыйтьче Р. Мостафин да башка тәнкыйтьчеләр белән үз теләктәшлеген белдерә. Исемлеккә М. Маликованың “Алтын ятьмә” романын да кертеп, ***“социалистик реализм “бозыклык реализмы” белән алмашынып килә. Әлбәттә мондый әсәрләрдәге персонажларны, никадәр тормышчан булмасыннар, чын заман герое дип атап булмый***”,—дип кистереп әйтә.

Шәрәфиев артыннан буразнага төшкән язучыбыз Радик Фәизовнын дөньясы да, мәхәббәте дә түгәрәк. Ул безнен кая барганны белми, беләсе дә килми. Нихәл итәсен, бәхетле. “Сыер үлсә—ит, арба ватылса—утын” диебрәк язылган “Алар безнен арада” дигән мәдхиясенең (Казан утлары”, 2, 2004) барлык пафосы түбәндәге өзектә аңлашылыр сыман: ***“...Мин үзебезнең Дусым авылында “колхоз эшенә соңга калам бугай!” дип, кулына сәнәген тотып югары очка йөгереп менгән кешеләрне хәтерлим. Социализмны аны коммунистлар гына түгел, бөтен совет халкы төзеде. Хәзерге көндә кайбер әдипләрнең “социализм халыкка көчләп тагылган иде!” дип пыскып торуы дөреслеккә хилаф салу ул”.***

Менә шулайрак эзлилэр әдәбияттагы “геройлар”ны Дусым авылы социалистлары. Гомумән алганда, Саба “урман хуҗалыкларында” Радик Фәизов, Тәлгать Нәҗмиев кебек тулаем канәгать патриотларның болай “кытыклап ятуы” үзе генә дә “дөреслеккә хилаф килү ул”. Соңгы елларда иң саллы тәнкыйтьчеләребезнең берсе булып киткән Рәшит кардәшем Фәтхерахманов бераз гына алда телгә алынган үткен мәкаләсендә Рәфыйк Шәрәфиев башлаган саваплы фикерне дәвам итеп, тәкъдимнәр дә кертә: ***“... Пычрак су белән уйнау хирыслыгы, аянычтыр, безнең милли әдәбиятка да яхшы үтеп керде. Нинди юллар белән булса да татар телле укучыны саклап калу, аны мавыктыру, үзенә тарту, киләчәктәге үсеш өчен ныклы җирлек булдыру, болгавыр чорны исән-имин үтү. Азгынлыкны чуар бизәкләп булса да, кешенең хайвани асылын уятып, әдәби табынга җим урынына фәхишлек һәм зина куеп булса да, милләт өчен ят булган идеяләрне, тискәре фәлсәфәне байрак итеп күтәрү хакына булса да...”*** Хак сүз. Хак сүзгә нәрсә дисең. Минемчә, кайбер язучыларыбыз әсәрләрен яза башлар алдыннан беренче чиратта идея-иман, тел-стиль “кирәк-яраклары”турында түгел, ә фәхишә-азгын, күрәзәче “каһарманнар” турында кайгырта. Андый авторларның мин әсәрнен төп матдәсе—тел, төп чыганагы—иман, төп халәте—саф мәхәббәт (юк, үбешеп яту түгел!) турында бөтенләй уйлап та бирмәүләренә хәйраннар каласың һәм безне ничек җир күтәрә дип куркып та куясың.

Ары таба Рәшит Фәтхерахманов Рафаэль Сибатның соңгы “Ялгызак”, “Инабәт” романнарына тирән анализ бирә. Миңа, Сибатның замандашына, күпмедер дәрәҗәдә

анын язмышташына һәм миллияти фикердәшенә, бик авыр, әрнүле операция булды хезмәтнең бу урыннарын уку. Әмма кирәк иде ул. Кызганыч, каләмдәшебез бу анализны үзе исән вакытта ишеткән булса, бәлки үзе ачтым дип уйлаган "Азия медиумы белән Европа прагматлыгы" теориясенә кереп батып, шайтани идеяләр белән мавыкмаган да булыр иде. Дөрес, Сибат әсәрләрендә "яна герой" эзләде. Аның эзләү стиле татарның Мәүлә Колый суфыйлыгы белән постмодернистик әдәбият кушылмасы иде. Ләкин алар без тәрбияләнгән әдәп һәм әдәбият контекстыннан ераграк торды. Анын әсәрләрен, текә киселгән фразаларын, еш кына бер генә сүздән торган "кисек" җөмләләрен укыганда, алардагы көтелмәгән фикри боткага, бу кадәр "ычкынуларга" тап булып, күзләр маңгайга менә иде. Сирәк кенә очрап куйган табышларны көчәнеп язылган чәчкәләүләр, купшылыклар, сүз боткасы белән эч китәрү, һаман да шул сихер, һаман да шул мәгънәсезгә мөгез чыгару, һаман да шул шапырыну, күнел чуарлыгы... Әгәр сиксәненче-туксанынчы елларда проза тәнкыйтендә мәйдан тоткан тәнкыйтьчеләребез Рафаэль Мостафин, Рифат Сверигин, Фәрваз Миңнуллин, Флүн Мусин, Сәгыйть Хафизов, Фоат Галимуллин кебек тәнкыйтьчеләребезнең берсе яшь язучының әсәрләренә гадел бәя биргән булсалар, бәлки Рафаэль Сибат, тумыштан искиткеч талантлы язучы, изге күнелле кеше, мондый "балалык уеннары" белән вакытында хушлашкан булыр иде? Бәлки без ялгышабыздыр да, анын керәшен Мәкчимнәре, Заһидуллалары, Малмыж муллалары киләчәкнең "заман геройлары"дыр? Бәлки бу без аңламаган даһилык, оригинальлектер? Алай була калса, ул Диас Вәлиев, сынчы Илдар Ханов кебек барлык диннәрне бер тагаракка салып "бутап", үзләрен "яңа Гайса пәйгамбәрләр" итеп игълан итү модасына ияреп, бидгатькә батмас иде. Сүз дә юк, Сибатның соңгы романнарында саташып, пәйгамбәри бөеклеккә дәгъва итеп, глобаль медиум тудырырга маташуы безгә рәнжештән, иблислектән башка бернәрсә дә китерә алмый иде. Күген вә җирен, суын вә утын югалткан, инде килеп житмеш ел эчендә иманын да мәҗүсилеккә алыштырып өлгергән, бүген килеп үлем белән яшәү арасында тартышкан татарга мондый медиумнар зыяннан башка нәрсә китерер икән?!

Без боларны авторга исән чагында әйтергә тиеш идек. Татар әдәбиятының мондый өзектә калуында тәнкыйть гаепле. Беренче итеп язучыга тәнкыйть сүзен тәнкыйть житкерергә бурычлы иде, чөнки безнең, язучының язучыга, мондый тәнкыйтьне әйтү ифрат та читен—чөнки барыбыз да шундый эзләнүләр вулканының субъектив магмасында кайныйбыз. Авторның исән чагында моны әйтү өчен күпме җәфалар кичердем мин. Һәм.. әйтә алмый калдым. Әгәр без, язучылар, бер-беребезнең әсәрләрен даими укып барган булсак, бу фикерләрне башкалар әйткән булыр иде. Юк, әйтмиләр, чөнки "бөекләребез" берсен-берсе укымыйлар. Менә ниһаять бу фикерне, соңлап булса да, миннән Рәшит Фәтхерахманов әйттерде.

***"Яшәеш турында фикер йөртергә тырышып, әлеге әдип, мода шаукымына ияреп, христианлык, мөселманлык, мәҗүсилекнең янәшә куеп булмый торган карашларыннан шундый коктейль оештыра: күз аллары караңгылана, наданлыкка, мәгърифәтсезлеккә таң каласың!..***—ди тәнкыйтьче.—***... Әдипнең иң соңгы романы "Инабәт" тә, фәлсәфи роман буларак тәкъдим ителүенә карамастан, үзенең синтетик характеры, "агач теле" белән күнелдә авыр тәэсир калдыра, авторның персонажлар телен индивидуальләштерергә тырышып артык көчәнүе дә ярдәм итми, колоритлы натуралар урынына сабын куыгы кебек буш образлар калкып чыга..."***

Рафаэль Сибат турында язарга кирәк. Һәм күптән язарга кирәк иде. Аның ачышларын, әгәр дә алар бар икән, ачып салырга, ижади, концептуаль ялгышларын күрсәтергә, димәк, автор шәхесе белән беррәттән ижаты турында язарга кирәк. Бу тумас борын мәхәббәтсезлеккә батып барган яшь каләмдәшләребез өчен аеруча мөһим. Күптән түгел тәнкыйтьчебез Фоат әфәнде Галимуллин мәрхүм язучыга багышлап ""Ашкынып яшәде дә, ашыгып китеп барды" *("Мәдәни жомга", 13.08.2004)* дигән мәкаләсе белән чыгыш ясады. Тик тәнкыйтьче буларак түгел, ә Татарстан Язучылар берлеге рәисе сыйфатында. Мәкаләсе дә мәрхүм белән хушлашу рәвешендәрәк. Монысы да кирәк. Тик мондый некрологиядә аеруча сак булу мөһим, анда авторны икейөзлелек сагалый. Каләмдәшебезне саклап кала алмау хафасы белән капланган булып, башта үзләренең ролен күпертеп күрсәтеп, язучыны без

эзләгән "заман геройларын" ачкан өчен түгел, ә менә, иҗатына бөтенләй кагылмыйча, "Казаннан йөз илле чакрымда, авылда" яшәп иҗат иткәне өчен авыз суларын корыта-корыта мактау абруйлы тәнкыйтьчене бер дә бизәми. Газета битен диярлек биләп торган чыгышында ул Рафаэль янына гел-гел барып йөреп, аның яңа әсәрләрен "идәннән җыеп алып", Казан матбугатында көчләп диярлек бастырып чыгарган үз урынбасары (нигә бармаска да, нигә бастырып чыгармаска—бу бит берлек хезмәткәрләренең гражданлык бурычы!) Шаһинур Мостафинны һәм тагын да шул үзен күкләргә күтәреп мактый... Имеш, алар булмаса, Рафаэль Сибат булмас иде. Рафаэль Сибатның иҗатының якты, сагышлы өлеше мондый очсыз язмаларга түгел, Фоат Галимуллин кебек тәнкыйтьчеләрнең язучылар иҗатына биргән объектив бәяләренә мохтаҗ. Ләкин бу бәяләмәләр, монографик хезмәтләр татар әдипләренең, Рәшит Фәтхерахманов әйтмешли, "пычрак су белән уйнау хирыслыгына" керү фаҗигасен, аннан чыгу тантанасын ачарга тиеш. Шунсыз без савыга алмаячакбыз. Мондый савыгу өчен без үзебезне безне батырган һәр авторның—исәнме ул, аллә түгелме—һәр әсәренә аяусыз бәя бирергә өйрәнергә тиешбез. Монда Казаннан ничә чакрымда яшәү факторы кызгандыру эффекты булып тора башласа, без һаман да шул "пычрак сулар" даирәсендә чайканачакбыз. Алайга китсән, татарның соңгы чорындагы күренекле шагыйрьләренең берсе Кадыйр Сибгат Казаннан ике йөз илле, Мәхмүт Хәсәнов дүрт йөз чакрымда, Ибраһим ага Салаховның "иҗаты" башта төрмәдә, аннан ике мең чакрымдагы казакъ далаларында үтте...

Безнең әдәбиятның секс—"зина"лашуы безнең әдәбиятыбызга беренче тапкыр Гаяз Исхакыйлар алып кергән "зиналар касәфаты" гына түгел инде. Бу безнең милли һәлакәтебез дәрәҗәсенә җиткән бәлабез инде. Бүгенге татар авылындагы зиначылык (кая ди анда ниндидер Монако кенәзлеге тәтәйләрен генә) борынгы мәҗүси зиначыларын һушыннан алырлык. Безнең татар "маржалары" инде хәзер маржа Зиналарның үзләренә сабак бирә алалар. Шагыйребез киная белән әйтмешли, ***"Зиналарга—зинага!" барабыз.*** Татардагы бүгенге зиначылык теге гасыр башындагы "зина" кебек беркатлы нәрсә түгел. XX гасыр башында мондый "бала урыслашу"ны Гаяз Исхакыйлар бер прогрессив күренеш итеп олы бер куаныч белән безнең кадимилектән котылып, җәдитчелеккә күчә бару дип күрсәтергә тырышканнар иде. Әгәр Татарстанның әлегә саклана алган дәүләтчелеге татар милләтен әхлакый тазарту, аның барлык милли институтларын милли мәдәни, дини-шәригати стандартка китерү турында җитди уйланып, махсус карарлар кабул итмәсә, безнең "гектарыннан алтмыш центнерлы уңышлар" ятлар кулына калачак.

Шул көннәрдән соң "нибары" йөз ел үттеме-юкмы, Уфа тәнкыйтьчесе, яналыкны тиз эләктереп ала торган язучы-тәнкыйтьчебез Сәгыйть Хафизов "Әдәбиятта базар мөнәсәбәтләре" дигән искиткеч яхшы мәкаләсе белән безне куандырган иде: ***"Секс-иблис тормышыбызга ушнан да, суллан да яңаган бер мәлдә әдипләребезгә, аңа капка ачу һәм уйнашчылык итү түгел, ә кешеләр күңелен шул иблистән арындыру, сафландыру гамәлен кылу шәригатьчәрәк булыр иде. Инде шәригатьне санга сукмасаң, аның кануннарына төкереп бирсәң, ахыр чиктә кеше язмышы, бала иминлеге хакында уйларга кирәк. Сабыйны бер ләкләк китерми..."***

Соңгы ун елда Уфада яшәп иҗат итүче авторыбыз Марат Кәбировның "Сары йортлар сере", Фәүзия Бәйрәмованың "Вакыйга юләрләр йортында бара" трагикомедиясе, Т. Мөбәрәковның "Хәтер аланы", Миргазиян Юнысның "Соңгы сулыш", Фәнис Яруллинның "Яралы язмышлар"(бу аерым бер мәкаләгә лаек!), Әсгать Сәлахның "Каеннар юлы"ннан кала иң яратып укыган әсәрем булды. Шушы рәттән Нәбирә Гыйматдинованың "Икебезгә дә авыр" повесте дә язучыда барган уңай иҗат эволюциясенә ышаныч тудырды.

Марат Кәбиров повестендә безнең өчен бөтенләй ят, яңа стиль, үзенчәлекле тел, стильләрнең төрләнеп кабатланышы ярылып ята. Безгә прозада бөтенләй яңа таныл-белү ысулы килде. Хәерле сәгатьтә!.. Авторның сурәтләү яссылыкларын шулай сиздерми үзгәртә алуы куандыра. Бер караганда, ул Фатыйх Әмирханның "Фәтхулла хәзрәт"ләренең сирәк, безнең башыбыз-акылыбыз җитмәгән дәрәҗәдәге дәвамчысы. Тик Кәбиров кулындагы безне "кыйный торган таягы" бүтән. Икенче караганда, дөрес, Кәбировта Көнбатыш әдәбияты һәм фәлсәфәсе, беренче чиратта Карл Ясперс,

Жан Поль Сартр кебек экзистенциаль философ-язучылар, Габриель Маркес, Хорхе Борхес кебек неомодернистларның йогынтысы көчле. Бу—кабердән, аның ләхете эченнән репортаж, Үлем турында үлемсез әсәр. Кәбиров тудырган "бала" да кашкерфекләренә кадәр милли татар. Аның мәрткә киткән Мәдинәсендә "заман каһарманы" эзләүдән бигрәк татарның әле бездә моңа кадәр туа алмаган, беренче булып күренгән "яңа заман антикаһарманы"н эзләп таптым кебек... Шунысы гына күнелне чеметеп куя: ай-һай, татарның бу кадәр "сихерче" әдәбиятыннан исәнаман кала алган укучысы мондый модернистик әсәрне капыл гына аңлый алыр микән? Ничек кенә булмасын, безнең әдәбиятның үсеш юлы Марат Кәбиров кебек егетләр кулында. Әгәр безнең тагын берничә шундый егетебез булса, алар яңа татар әдәбиятын эһ тә итмичә дөньяга балкыта алган булыр иде!

***"...Марат Кәбировның сатирасы гротеск дәрәҗәсенә житә, чынлыкта бу Гоголь һәм Чеховларны көнләштерерлек сатира. Һәлакәтне ваемсыз кабул итү—рухи имгәтелгән, үчле һәм мәкерле, кара эчле бүгенге җәмгыять әгъзаларының төп сыйфаты...*** —ди Р. Фәтхерахманов.—***...Бүгенге җәмгыятьнең милләткә яңа диннәр, яңа пәйгамбәрләр, аның өчен ят булган кыйммәтләр эзләү һәм тәкъдим итү белән мәш килгән катламының реальлектән никадәр ерак торуын, "сары йортлар синдромы" белән чирләвен дәлилли ул."***

Әхмәт Рәшитнең чыгышы "Безнең заман герое" башы астында һәм бик зур амбиция белән "Зурдан кубып сөйләшкәндә" *("Казан утлары", 4, 2004)* дип аталса да, безнең бәхәскә катнашы юк. Әдәбиятыбыз ел йомгакларында сөйләнеп, "син мине—мин сине" тәртибендәге хрестоматик мактауга корылган бу чыгыш бүгенге шигъриятебезнең чын, реаль халәтен чагылдырмый. Ул прозага кереп тә маташмый. Бу халәтне кичерү, аңлау өчен Казан коридорлары масштабларыннан читкәрәк чыгарга, тар татарлыктан арынырга, тетрәнергә кирәк шул. Аның каравы, автор анда үзендә шактый белем-эрудиция барлыгын күрсәтә. Бер генә мисал: ***"Күктән жиргә төшәм дә, "Бүгенге татар әдәбиятының каһарманнары кемнәр?" дигән сакраменталь сорауга килеп төртеләм. Соңгы егерме еллар белән чикләнергә тиешмен икән... Ләкин минем бүгенгене борынгыдан аерырга хакым юк. Без—шул ук Кол Галиләрнең, Сәйф Сараиларның, Мөхәммәдъярларның, Тукайларның, Туфаннарның дәвамчылары. Борынгыдан калган бөек мирас безгә ышанычлы таяну ноктасы булды. Иң сөенечлесе, без халкыбыз яулаган шул рухи биеклектә кала алдык,*** "—ди автор. Әйтерсең аңа кемдер бүгенгене кичәгедән аерырга куша. Андый кеше булмады бугай. Кол Галиләр турында бу төче сафсаталарны без күпме кабатладык һәм кабатларбыз икән?! Ә менә "халкыбыз яулаган рухи биеклектә калуыбыз" турында автор, минемчә, күзгә карап шыттыра...

Рафаэль Мостафинның бәхәс барышындагы чыгышы "Чорлар чатындагы үзгәрешләр" *("Казан утлары", 5, 2004)* дип атала. Әдәбиятыбызда килеп туган чагыштырмача тынлыкны "буыннар алмашы кризисы" дип атап, ул бер караганда, хаклы да кебек. Шулай да тәнкыйтьче бу урында буыннар алмашына артык зур формаль мәгънә биреп, андый алмашның теләсә нинди җәмгыятьтә дә даими барганлыгын онытып җибәрә кебек. "Буыннар алмашы кризисы" барлык җәмгыять кризисының нәтиҗәсе генә ул. Мостафин моны гына аңламый дип уйламас идем мин. Ул шушы кризиска китергән совет системасының иҗтимагый-сәяси сәбәпләрен яшереп, безне юату, йоклату ягын каера булыр. Өлкән буын язучыларыбызның бакыйга китеп, флангларыбызның бушап калуын без бары тик "коры алмаш" проблемасына гына кайтарып калдырып кына аңлата алмыйбыздыр? Димәк, без—ялкау, булдыксыз халык—милләт хадимнәре, үз аксакалларыбызның үлгәнен көтеп, мич башында ятканбыз һәм сабанга чыгарырга атсыз вә ир-егетләрсез калганбыз? Мостафин әйткән "буыннар алмашы"ның милли, социаль, иҗтимагый-психологик, хәтта икътисади сәбәпләре бар бит аның. Гади генә итеп әйткәндә, эш шунда ки, хәзер безнең әдәбиятка ныклы тотка булып совет хакимиятенең 60-80 елларында туган буын килергә тиеш иде. Әмма бу илсез буын советларның котырган интернационализмы корбаннары буларак, үз телендә белем һәм тәрбия алмыйча телсез, моңсыз, социаль җирлексез, хәтта аракы шаукымыннан яралып, җилкәнсез калган иде. Димәк, хәзер җәмгыять белән җитәкчелеккә генә түгел, мәгърифәт,

мәдәнияткә дә "жилкәнсезләр буыны" килде. Алар "культурага үтеп тормыйча гына" әдәбиятка үтте. Сиксән-туксан яшьлек аксакал әдипләребез китеп баргач, әдәбиятның әлегә исән 50-60 яшьлек, 30-40-нчы елларда туган "классиклары" белән ярымбуш калган ихатасына "традицион милли һәм совет торгынлыгы" нәтиҗәсендә деградация чорына кергән милләтнең ярым-йорты белемле, уртакул сәләтле, тәрбиясез, еш кына әдәбиятны белмәгән каләм хадимнәре һәм хадимәләре белән тулды. Сан бар—әсәр юк. Әсәр бар—сыйфат юк. Иске әдәбият бар—яңа әдип юк. Димәк, яңа әдәбият юк. Әдәбиятның исән тегермәне аларны янадан "он итеп тартырга, эшкәртергә" мәҗбүр булды. Шуларны күз уңында тотып булса кирәк, тәҗрибәле тәнкыйтьче "Әлбәттә, бу кризисның тамырлары бер буыннар алмашынуга гына кайтып калмыйча, шактый тирәнгә китә",—ди дә, кызганычка каршы, шуның белән чикләнә.

Әдәбиятка килгән яшь көчләр турында борчылу без "базар заманы"на кергәч тагын да көчәйде. Бу хакта уйланып, Марсель Гали әле моннан ун ел элек "Татар әдәби иҗатына "калдык-постык талантлар гына килә. Укырдай әйбер тапмыйм. Җаңга, аңга фикер бирә торган әйберләрне урыстан, ә бәлки Аурупа прозасыннан алганмындыр..." дип әрнегән һәм, Г. Ибраһимов, М. Гафури, К. Тинчурин иҗатларына бәя биреп, "бу язучыларда мин эстетик зәвык булуга шикләнәм..." дип, аерым бер кискенлек белән әлеге язучыларның әсәрләрен чүплеккә ыргытырга кирәк, дигән күрсәтмәсен дә биреп куйган иде. *("Идел", 9, 1996)* Минемчә, классикларыбызның бөеклегендә түгел, үзебезнең бөеклектә шикләнергә кирәк. Мин, мәсәлән, Кәрим Тинчуринның "Сүнмәс йолдызлар" белән "Американ"ын даһи әсәрләр рәтендә күрәм. Безнең сәхнәдә "Сүнгән йолдызлар" кебек режиссураны кызыксындырып торган, шуңа күрә теләсә нинди шартларда да яхшы куелган, актерлар тарафыннан бу кадәр дә яратып уйналган фаҗига юк әле. Әсәр буларак, аның белән Исхакыйның "Зөләйха"сы гына ярыша ала. Әмма "Зөләйха"га, татарча әйткәндә, "не везет". Аның әле тиешенчә куелганы юк.

Мин әдәбиятыбызда тарихи әсәрләрнең күбәюенә куанам. Сорау туа: сыйфат ничек? Совет чорларында бары тик революцион, төп каһарманнары еш кына "агылыйга тагылый" йөргән урыс белән татар булган романнар язып кына буын катырган язучыларыбыз демократик яңарыш чорында икенче сулыш алды. Бу жанрда хаклы рәвештә беренчеләребез итеп Нурихан Фәттах, Җәмит Рәхимов, Мөсәгыйть Хәбибуллин, Вахит Имамов, Таһир Нәбиуллиннарны атарга кирәктер. Мөсәгыйть Хәбибуллин күп яза, объектын өйрәнеп яза. Әмма аның романнарындагы күп планлылык, хәбәри мавыгучанлык, күпсүзлелек укучыны арыта һәм әсәр тукымасын авырайта. Тел, стиль йөгерек түгел, кайбер чакта җөмләләр су астындагы ләңгәр кебек өстерәлә. Архивлардагы беренчел, яңа чыганаклардан түгел, башка, әзер чыганаклардан информация туплау, аларны әсәр тукымасына дыңгычлап тутыру нәтиҗәсендә Мөсәгыйть Хәбибуллинның тарихи романнары информацион әкиятләрне хәтерләтә башлый. Бу романнар нәфис сурәтләү чараларына да такыр.

Шушындый ук житешсезлекләр Вахит Имамов романнарына да хас. Җәмит Рәхимов "Батырша"сы белән соңгы чор әдәбиятыбызга милләт бәхете өчен күптән көтелгән реаль көрәшче-шәхес образын бүләк итте. Житешсезлекләре булуга карамастан, "Батырша" романы безнең шактый зур уңышыбыз дип танылырга хаклыдыр. Батырша—безнең бүген иң төп "заман герое"быз... Ул үзенең йөзләгән сурәтчесен көтә. Батыршаның татар-башкорт милләтен азатлыкка өндәп, милләте, гаиләсе белән кырылып, Шлиссельбург крепостендә күтәргән бөек фетнәсе һәм аның Әби патшага язган гыйсъян хаты әле татарда аңа кадәр һәм анардан соң да була алмаган илаһи батырлык. Әмма шунысы сәер: безнең урта мәктәпнең әдәбият буенча әсбапларында тарихи романнарыбызга—шул исәптән "Батырша"га да!—урын бөтенләй дә бирелмәгән диярлек. Тарихи романнар да тәрбияләмәгәч, "милли каһарманнар"ыбыз каян килеп чыксын соң?

Тарихи роман язу—сирәк җаваплылык. Тарих аша ышандыру—сирәк батырлык. Тарих белән сокландыра алу—сирәк матурлык. Без бу өлкәләрдә сынатабыз. Тарихи роман язган татар язучыларының барысы өчен дә төп житешсезлекләр—ул әсәрнең абруен архив материаллары белән тәэмин итмәү, эш иткән халдә, ничектер балаларча, өстән-өстән генә кылану, тегеннән-моннан йолыккалап язу, йолыккаланган тарихны

бәгырь зәме белән сугармау; сюжеттагы ясалмалык, табигатендәге гасаби милләтсезлек, телнең шул замандагы симметриясен табабыз дип телдән эрзин сагыз ясау... .Укучыны Архив Галиәссәлам белән һәм канга сугарылган бәгырь белән генә ышандырырга кирәк!.. Тел чарлауга корылган диалогтан башка укучыга җан тетрәткеч монологлар кирәк! Шигърият кирәк! Мәхәббәт турында сөйләү түгел, тетрәтә торган мәхәббәт кирәк!..

Тәнкыйтьтәге чама турында берничә сүз. Кайчан без мактамыйча җылы сүз әйтергә, хурламыйча тәнкыйть итәргә өйрәнербез икән? Бу сыйфат татар милләтендә исән кала алган гражданлык әдәбенә, олпат ихтыяр булмышына барып бәйләнә, күрәсең. Бик сәер, Рафаэль Мостафин югарыда телгә алынган мәкаләсен шактый тәнкыйди тонда алып бара-бара да, кинәт кенә бер йөктән төшеп икенчесенә утыра һәм мәкаләсен көчли-көчли Факил Сафинның “Саташып аткан таң” романына багышлап язылган мәкаләгә әйләндерә, нәтиҗәдә сизгер укучы алда әйтелгән фикерләрне романны шаштырып мактау өчен элек язылган мәкаләгә өстәмәләр итеп кенә кабул итә һәм аптырашта кала...

Сүз дә юк, язучы үз әсәре турында җылы сүз көтәргә, ишетергә хаклы. Факил Сафин кебек сәләтле, актив язган язучы бигрәк тә. Бер үк вакытта һәр язучы гадел тәнкыйтькә мохтаҗ. Тик, һәр нәрсәдә чама, ышандыра торган үлчәм кирәк. Без мактауларга һич каршы түгелбез. Әмма, чуерташ мактаулар өчен дә тәнкыйтьче яшь романчының әсәрен шакмактан шакмакка сүтәргә тиеш иде. Тәнкыйтьче мондый “вак-төяккә” игътибар итеп азапланмый. Киресенчә, ул җитешсезлекләрне бөтенләй күрмәскә тырыша, тәнкыйтьтән качып, шикләнүләрен чуерташ фразалар белән чикли дә, әсәрне шулкадәр дә чамасыз күләмнәр мактый башлый ки, мондый “тәнкыйтьтән” бал һәм баллы келәй, ниндидер корпоратив мәнфәгать, бергәлек коммунасы исе килә башлый. Нишлисең, без бит анде барыбыз да заманның Печән базарыннан чыккан татар мөхәррирләре!.. Син—мөхәррир, мин—мөхәррир, мин—сиңа, син—миңа.

“Автор бу әсәрдә үзен көчле аналитик, зур акыл иясе итеп тә күрсәтә...” ди тәнкыйтьче. Тота-каба, маңгайга бәреп, сәбәпсезгә авторның шәхесен мактау урынына, тәнкыйтьче әсәрнең әхлакый-эстетик кыйммәтен ачарга тиеш иде дә бит. Шулай иткән хәлдә, мине дә бер сәбәпсез автор белән чәкештермәс иде. Бу юлларның авторы хәзер әсәрдә казынасы урында, имеш, әсәр авторының шәхесендә “казынган”, аның “зур акыл иясе” булуын инкяръ иткән булып чыгам! Татар әдәби тәнкыйте шулай итеп, төшенчәләрне һәм объектларны позитивтан негативка, негативтан позитивка әйләндерде. Бу, Тукай әйтмешли, “Алны-артны, уңны-сулны белмичә утын кискән” укучыларыбызның зиһенен томалау өчен эшләнә. Мондый ташка баскан мәдхия Габдулла Тукай премиясенә әзерлек инде. Хәер, мондый мактауны Тукай үзе дә, аның остазлары Александр Пушкин, Лев Толстой да ишетми үлеп киттеләр. “Факил Сафинның “Саташып аткан таң” романын мин соңгы еллар әдәбиятындагы иң җитди, иң уңышлы әсәрләрдән дип саныйм. Монда заман герое бөтен тулылыгы белән алдыбызга килеп баса. Иң мөһиме, автор заманча фикер йөртә, тарихны яңача күзли...” Әсәр үзе кая, үзе?! Бу инде мактау гына түгел, бу әле әдәбиятта “А”сын да, “Б”сын әйтеп өлгермәгән авторны очындыру дип атала. Әсәргә конкрет килгәндә, “заманча фикер йөртә”, “тарихны яңача күзли” кебек совет әдәбият гыйлеменнән калган буш фразалары төбендә нәрсә ятканлыгын аңлатса иде безгә Мостафин. Бу фразаларны “сөйләп” түгел,сурәтләп расларга кирәк бит!.. Чамадан артыкны ычкындыруын, “сөйләү” белән “образлы сурәтләү” арасында упкын ятканын аңлаган тәнкыйтьче хәзер “заманча фикер йөртә” кебек чуерташ фразаларга терәү тери башлый. “Әсәрне укып чыккач, аңлыйсың: сүз монда Октябрь инкыйлабы турында бара”. Кара син аны, имәндә икән чикләвек, ә мин сүз 1779 елгы Француз революциясе турында барадыр дип уйлаган идем. Болай булгач, роман, андагы “заман герое” турында бәхәсләшеп торуның да кирәге юк икән бит. Рафаэль Мостафин проблеманың төбенә төшеп тормыйча, “заман герое”на иннек-кершән сылый башлый. Төп каһарман—Татарстан хөкүмәтенең җитәкчеләреннән берсе Әхмәтсафа Дәүләтьяров “ясалма түгел, тормышчан, тирә-як мохитның үзеннән алынган... документаль нигезгә корылган... тырыш, эшчән, нәрсәгә тотынса да

булдыра ала торган кеше. ***Авылда үссә дә***, ул шактый укымышлы, ин атаклы татар шагыйрьләренең ижатын яттан белә..." Авылда үскән Мәржаниләр, Тукайлар, Исхакыйлар шәһәрдә үсеп кенә кеше булырга тиеш булганнар, күрәсең. "Ул искиткеч намуслы, кешелекле, алга омтылучан, туктаусыз үсә, камилләшә торган кеше...Бармы соң безнең әдәбиятта андый геройлар?"—дип сорый да, автор, бар, ди, "шундый геройны мин Факил Сафинның "Саташып аткан таң" романында күрдем",—ди.

Кызганыч, минемчә, укучы романда үзенә "үрнәк, илһам ала торган заман героен" күрмәде. Дәүләтьяров мисалында укучы үзенә милләтнең "героен" түгел, "нәрсәгә тотынса да булдыра ала торган кеше" була торып та, бары тик мәгънәсез, татар максаты өчен аңлашылмаган корбанын гына күрде. Чөнки укучыны, герой турында "ул яхшы" дип сөйләп түгел, сурәтләп ышандырырга кирәк. "Заман героебыз" "***үзе авылда үссә дә, үзе шактый укымышлы***", үзе җитмәсә "***туктаусыз үсә, камилләшә***" кылгач, без тәнкыйтьчебезне, ниһаять, без эзләгән "заман герое"н табуы белән кайнар котларга тиеш булабыз түгелме? Безгә хәзер авылда үсәргә дә ярамый икән"! Тәнкыйтьче безләрне "Авылда үссә дә..." дип кимсеткәч!.. Әгәр автор алдан ук бары тик мактауны түгел, беренче чиратта гадел тәнкыйтьне көткән булса, "Ватаным Татарстан" газетасында "Тезләнмичә дә яшәп була!" дигән бик тыйнаксыз язмасында ***"Үземнең әсәрләремдә XX гасырны башыннан азагына кадәр чагылдыра алдым..."*** дип язып чыкмас иде. *("Ватаным Татарстан", 6.02.2004).* Болай дип әйтергә Лев Толстой гына түгел, Максим Горький дә базнат итмәгәннәр иде. Билләһи, уңайсыз.

Романга якын килик. Билгеле булуынча, большевизм татар тарихында Явыз Иваннан кала икенче катастрофа булды. Бүген без нинди стагнациягә дучар ителгән булсак, бүген без нинди милли фаҗигадә утырган булсак, аларның сиксән-туксан проценты большевизм касәфаты бит. Большевиклар татар милләтенә Лука Канашевич-Каратун, Ильминскийлар китерә алмаган, алардан йөз тапкыр зуррак зыян китерде. Чукындырудан Себер урманнарына качып булса, коммунизмнан качарлык урын калмаган иде. Барлык җир шары буенча. Кичәге батрак булган татар большевигы урыс большевигыннан да явызрак иде—чөнки үзенең изелгән милләтен "үз итеп", аның барча нечкәлекләрен белеп, "сәнәктән көрәк булган нәчәнник" итеп, холуйларча өстеннән килеп, икеләтә-уңлата изә иде. Татар язучысы, җитмәсә, большевизмның сәяси көч буларак йөз елга якын хакимияттә булып, җимерелеп төшкән чорында—XX-XXI гасыр кучешендә (!!!) яшәгән татар язучысы, милләтебезгә большевизм китергән коточкыч бәлаләрне бар тирәнлеге белән ачып салырга, шуның белән беррәттән милли автономия демагогиясе белән алданган татар большевигының кан кычкырган фаҗигасен нәфис сүз, образлы сурәтләү—художестволы гәүдәләнеш аша күрсәтеп бирергә тиеш иде. Ә биредә—корбаннарның корбанына плебейләрчә, сукбайларча соклану! Утызынчы еллар башында Магнитка, Амурдагы Комсомольски төзелешләренә дистәләрчә мең татар мулласын, татар керәстияннәрен озатуны оештырган режимның җитәкчеләреннән берсен күккә күтәреп мактау!.. Татар большевигы, Татарстан хөкүмәтенең башлыгының озакламый үзенең башын кисәчәк Сталин, Троцкий, Политбюро әгъзалары белән таныш булуы белән горурлану!.. Без, татар, һаман да шул ак-салак аскан кыргый аборигенмыни? Тагын да шул Миргазиян Юныс әйтмешли, никадәр дә "бәхетле мескенлек!"

Шулай итеп, безгә әдәби бәһасы шикле, художестволы образ буларак оешмаган, бары тик "безнең шундый яхшы, изге күңелле большевигыбыз булган икән" дигән аборигеннарча горурлыктан үтмәгән әсәр персонажын татар әдәбиятының "заман каһарманы" итеп тәкъдим итәләр. Әдәбиятның изге принциплары кая? Кыеклатып булса да, безне шул режимга табындырырга, аны кире кайтарырга телиләр. Сүз дә юк, Әхмәтсафа абзый Дәүләтьяров бик тә шәп, яхшы кеше булгандыр, аның һәм аның кебек меңнәрнең шундый фаҗигагә тап булуы безнең бәхетсезлекнең мәңге кичерелмәс чыганагы бит. Аларның язмышы—безнең каны мәңге саркыячак ярабыз.Соң син бу темага тотынгач, шуны ач, милләтнең күзен ач!.. "Яхшы кеше" һәм алданган "татар большевигы"—болар икесе ике фактура бит! Язучының бурычы шушы фаҗиганың төбенә төшеп, милләтне киләчәк бәлаләрдән коткарырга тырышу түгелме? Биредә корпоратив мактаулар белән генә аллә кая китеп булмый!..

Дәүләтьяров—каһарман, тик ул иненә авыр гыйбрәт төшкән "каһарман". Әгәр язучы мескен татарның алданган кол улы, чираттагы корбаны түгел, ә бәлки шушы большевистик тиранияннең мен җәфада алданган корбаны образын тудырган булса, без геройны гына түгел, Факил кардәшне, Рафаэль Мостафин тәрәүләреннән башка да "заман каһарманы" итеп кабул иткән булыр идек. Бер нәрсә хак һәм мактауга лаек: ничек кенә булмасын, үзе өчен бу искиткеч авыр, катлаулы, көтелмәгән темага алынып, Факил Сафин зур җаваплылыкка барган. Һәм романының беренче кисәген ярыйсы гына беллетристик осталык белән башкарып чыккан. Әгәр ул егерменче гасыр башында Рәсәйнен чирек капиталын кулында тоткан, инде ил белән сәяси җитәкчелеккә дә үрләп барган бөек татар милләтенең улы булган төп героен, ул һәлак булганнан соң җитмешкә якын ел үткәч, инде киләсе поездлар килеп, китәсе поездлар китеп беткәч, яшерен архивлар ачылгач, үз каһарманының "Сталиннар белән бер партиядә торуы, Политбюро әгъзалары белән таныш булуы белән" малай-шалайларча соклanудан туктап, аның, гаиләсенең, татар авылының, мөселман диненең, шул исәптән барлык татар өммәтенең гомуммилли тирән фаҗигасен тетрәткеч масштабларда ачкан булса, мин бүген Факил Сафинны зур уңышы белән беренче булып котлаган һәм аның хакына бәллүр тотып җир шарын яланаяк әйләнеп чыккан булыр идем.

Менә шундый фаҗигаи, чынлап та күздән канлы яшьләр чыгарып, чын мәгънәсендә җанны яшькә сугара, елата, сокландыра, горурландыра, рухны күккә алып менә торган каһарман булып килеп чыга алган булса, ул безнең әдәбиятның чынлап та яна каһарманы, аның флагманы буларак кабул ителгән булыр иде. Әлегә ул бары тик кызгандыра гына ала. Йә, әйтегез, Илья Эренбург, Константин Симонов, Александр Чаковский, Валентин Пикуль, Виктор Суворов, Эдвард Радзинский, Дмитрий Волкогонов кебек совет классикасының "бүреләре" һәм постсовет чоры тарихчы-публицистлары иләгән Сталин темасында Мәскәү Кремленең иң яшерен архивларына кертелмәгән татар язучысы нинди ачыш ясый ала?! Нәрсә белән генә хәтердә калабыз? Татар әдәбиятында беренче тапкыр Сталинны, Политбюро әгъзаларын (образларын түгел, без аларны "артыбыз белән кадак суырсак та", яһүди Чаковскийлардан да артык беләлмибез!) сурәтләргә тырышкан язучы буларак кына хәтердә кала алабыз без. Бары шушы гынамы? Шул гынамы? Никадәр очсыз! Их, кая безнең югалган мөмкинлекләр!.. "Герой"ның объекты бар, ләкин ул безнең өчен "субъект" булалмаган. Ул бары тик татар һәм Татарстан Совнаркомы рәисе Әхмәтсафа Дәүләтьяров булганы, кызганычка каршы, алтмыш ел буе игътибарсыз тузанда аунап ятканы өчен генә "яна" күренә. Имеш, сурәтләнмичә калган—шуна "яна". Чынында исә ул безнең өчен бик иске "герой", бик иске персонаж, без урыс һәм башка халык әдәбиятларын укып, аның һәм аның кебекләр белән моннан илле ел элек үк таныш булганбыз. Безнең укучыбыз үзенең интеллектуаль халәте, хәбәрдарлыгы белән еш кына урыс зыялылары һәм дөньяның башка алга киткән халыклары укучыларыннан артка калды. Безнең укучыбыз "шулай булган икән, шулай дип әйткәннәр ди бит" дип сәясәт кора торган массовый гавам, икенчеллек түбәнлегенә төште. Безнең әдәбият ана яна этик-эстетик куәтләрне сонлап һәм башкаларныкын иләп-иләп, икенчел-өченчел сыйфатта бирде. Бу безнең укучыны—әйтергә мәҗбүрмен!—наданга һәм ангырага калдырды. Миргазиян Юныс бу хакта уйланып "...Без әдәбиятта хакыйкать эзләүче укучыбызны югалттык. Эзләсә дә, ул ***аны үзебездән түгел, чит әдәбияттан, чит телдә укып эзли..."*** дип язган иде.

Гыйбрәт бит бу. Без сонлыйбыз. Башкалар бездән иртәрәк өлгерәләр. Без алар күрсәткән-сурәтләгәнне дә сонлап, анда да ишек йозагының тишеге аша гына күзәтәбез. Башкалар әллә кайчан балын имгән теманы бер кырык-илле елга сонлап "эшкәртәбез" дә, сонлап эшләгән эшебезгә сокланып карап торабыз һәм"мин беренче—син икенче" дип талаша-талаша, башкаларнын да соклануын таләп итәбез. Әгәр Факил Сафин романын моннан бер утыз-кырык, хәтта егерме ел элек язган хәлдә дә ул әле чагыштырмача яна күренгән булыр иде.

*Ахыры киләсе санда*

Гэп
Фэн

## Адлер Тимергалин

# МИЛЛИЯТ СҮЗЛЕГЕ

***КАШ***—Нефрит – яшькелт яки ак төстәге мәгъдән. Борынгылар пычак һәм кыргыч итеп, шулай ук сугыш һәм сунарчы коралы сыйфатында кулланганнар, төркиләрдә сихер ташы итеп тә файдаланылган. XI гасыр авторы Мәхмүд Кашгарый үзенең "Диване лөгатет-төрк" җыентыгында бу минерал турында: "Әгәр ул ташны, бүзгә төреп, утка ташласаң, бүз дә, таш та янмый. Бу сыналган. Ташны кеше авызына капса, сусынын баса", – дип яза. Шул ук чыганакта "Кимиң билә каш булса, йашын йакмас" ("Кем дә кем үзе белән нефрит йөртсә, – яшен сукмас") дигән ышануга тап булабыз. Борынгы Кытай язма истәлекләрендә төньяктагы Илэу иле халкының кара тузлы каен агачыннан уклар ясарга оста булуы, бу озын укларга куелган таш очлыкның тимерне дә тишүе турында әйтелә. Бик ихтимал, бу таш нефрит (каш) булгандыр.

***КӘБИСӘ*** *г.* – **1**.Миляди календарьда феврале 29 көннән торган ел. Рус телендә "високосный" сүзе латинча "bissextus"ка барып тоташа, ә анысы "икеләтә алтынчы" мәгънәсенә ия. Сүз Борынгы Римнан килә: анда ай ахырында көн исәбен яңа айның башыннан, ягъни кирегә таба санаганнар (вакытны исәпләгәндә "унбиш минуттан өч тула" дигәндә без дә шушылай "киредән" исәпләгән кебек булабыз) һәм, мәсәлән, 24 февраль тагы "алтынчы көн" булып чыккан. Борынгы римлылар дүрт ел үткән саен кояш календарена бер артык көн өстәгәннәр. Аларда 29 февраль була алмаган, чөнки Аллалар ачуланыр дип курыкканнар. Шуңа күрә 24 февральне "икеләткәннәр". Шул рәвешле икеләтә алтынчы өстәмә көн барлыкка килгән һәм 366 көннән тора торган елны annus bissectus дип атаганнар. **2.** Һиҗри календарьда зөлхиҗҗә ае 30 көннән килә торган ел (һиҗри һәм миляди календарьларда кәбисә еллар гадәттә бер-берсенә туры килми, аларның кабатлану тәртибе дә төрлечә).

Халыкта "кәбисә ел" мәгънәсендә *урак ел* дигән атама да бар. Кәбисә елларның чиратланышы хәзерге рәсми календарьда – 4 елга бер, ә һиҗри календарьда ул төрлечә кабатлана (бу хакта "*Һиҗри календарь*"ны кара).

"Шәрык алынмалары сүзлеге"ндә "кәбисә" сүзе *февраль ае* дип аңлатылган.

***КӘГАЗЬ*** – Мөхәммәд пәйгамбәр заманаларында гадәттә пергаментка һәм Мисырда үйлап табылган папирус табакларына язганнар. Мәсәлән, Коръәннең тирегә (пергаментка) язылган экземплярлары сакланган.

Кәгазь ясау Борынгы Кытайда яки Көнчыгыш Төркестанда туган дип уйлыйлар. Кайбер чыганакларга караганда, мөселманнар кәгазь ясарга 751 елдагы сугышта әсир төшкән Кытай осталарыннан өйрәнгәннәр. VIII гасырда бу эш Сәмәркандта да җайга салына. (Харис Хәзрәт Салихҗанның "Ислам тарихы вә нигезләре" дигән китабында: "Кәгазьне 706 ичы миладида Мәккә шәһәренең абруйлы гыйлем иясе Йосыф бине Гомәр мамыктан ясаган. Соңра 850 елда аның үрнәгендә Бохара вә Сәмәрканд осталары кәгазьне ефәктән ясаганнар" дигән мәгълүмат бар.) Кәгазь ясау ысулы Якын Көнчыгышка Сәмәрканд яулап алынгач кына килеп җиткән. IX гасырда кәгазьне Мавараэннәһердә генә җитештерәләр, аннары кәгазь фабрикалары Дәмәшкътә, Фәләстыйнда һәм Ливандагы Триполида да эшли башлый. Гарәпләр кәгазь җитештерүдә чүпрәк куллануга күчеп, чимал сыйфатында тут агачы белән бамбук камышына бәйлелектән котылалар һәм бу яңалыкның дөньякүләм тарихи әһәмияте бар. Европага кәгазьне гарәбләр XI – XII гасырда гына алып килгәннәр, ә аның серен европалылар XIII гасырда гына белгәннәр.

Безнең якларда Җучи олысы канцелярияләрендә шәрыктән кайтартылган кәгазь

*Дәвамы. Башы журналыбызның 2004 елгы 1нче саныннан башлана.*

кулланганнар. Мәсәлән, Олуг Мөхәммәднең 1428 елгы хатнамәсе, А.Н.Курат фикеренә караганда, Урта Азиядән китерелгән ялтыравык кәгазьгә язылган. Сәхибгәрәйнең 1523 елгы тарханлык ярлыгы да тигезле-тигезсез Урта Азия кәгазенә язылганлыгын күрәбез. Шул ук вакытта Якын Көнчыгышта эшләнгән (Багдад) кәгазеннән файдаланганнар. Европа кәгазе дә кулланылган.

Кәгазь сүзен гадәттә гарәп теленнән кергән дип исәплиләр. Ләкин татар галиме Р.Әхмәтьянов бу сүзнең төркичә "къагыт" сүзеннән ясалуы ихтимал дип саный. Чөнки борынгы кәгазь нәкъ җиләк-җимеш кагы (кагыты) шикелле эшләнгән. Бик нык вакланган һәм суда болгатылган чүпрәк массасын махсус челтәргә җәеп саркытканнар, юкартып тигезләгәннәр һәм киптергәннәр. Гарәпләр төрки "кагыт" сүзен үз телләрендәге "кәгадә" (төпкә утырту) фигыле бабына кертеп, "кәгад" дип яза башлаганнар. Ләкин, чыганакларга караганда, әл-Хәрәзми, мәсәлән, *кагиз* дип язган. Фарсы телендә *кәгыйдь* (кәгазь) сүзе бар.

Болгар җирләрендә кәгазь XI гасырда ук эшләнә башласа да, ул бик кыйммәт торган. Аны башлыча дәүләт документлары өчен тотканнар. Укый-яза белү таралу белән язу материалына ихтыяҗ арта төшкәч, тузга язуга күчкәннәр (Р.Әхмәтьянов). Сарытау өлкәсендә борынгы төрки-уйгыр хәрефләре белән язылган язулар төргәге табылган. Гомумән, Идел буенда археологик казулар вакытында шырпыга, кадакка һ.б.га уратылган тузнамәләр табыла. Новгород шәһәрендә археологик казу эшләре вакытында табылган русча тузнамәләрнең саны меңгә якынлаша (алар XI – XIV гасырларга карыйлар). Тузга язу көньяк илләрдә дә булган дип уйларга кирәк. Рәсми документлардан күренгәнчә, 1594 елда Русия Персиягә 30 пот каен тузы саткан. Әлеграк мондый сәүдә Казан һәм Болгар йорты белән шәрык илләре арасында булган булырга мөмкин.

Электә татар телендә кәгазь форматлары түбәндәгечә билгеләнгән: кечкенә кулдагы карточка, уртакул кәгазь, зур кулда (59 кәгазь).

Тагын кара: ***ХӘТТАТ.***

***КӘГЪБӘ, ӘЛ-КӘГЪБӘ*** *г.* – *Куб* мәгънәсендә, ә күчерелмә мәгънәсе – *үзенә тартучы үзәк* (суфичылыкта күңелнең Аллаһы белән кавышкан җире).

Исламның башлангыч чорында Мәккә әле мәҗүсиләр кулында булганда, Кәгъбә тирәсендә 360 пот-санәм тезелеп торган. Бу Аллалар грек-рим мифологиясеннән алынган булып, күбесенчә хатын-кыз җенесенә караганнар. Иң өлкән алиһәләрнең берсе Мәнат исемле булган, ул кеше язмышын хәл итә дип уйлаганнар. Ә әл-Лут кояш алиһәсе исәпләнгән (аның исеме дә кояш мәгънәсендә). Мәккә халкы әл-Гоззә ("Кодрәтле") дигән алиһәгә һәм Кәгъбәне саклаучы Һубәл дигән Аллага табынган. Аларга корбан итеп хайваннар алып килгәннәр. Кәгъбәдә борынгы Ассирия-Бабил Аллалары Мардук, Ассор, Син, Самас һәм Астарта сыннары да торган икән. Чыганакларга караганда, монда ук борынгы еврейләр табынган Авраам (Ибраһим) һәм кулына Христосны (Гайсәне) күтәргән Мәрьям-ана сурәте дә булган имеш.

Кәгъбә үзе агачтан төзелгән булып, ишеге көньякка караган, түбәсе булмаган, эчтә Аллаларга корбан китерү өчен савыт торган. Төньяк-көнчыгыш почмагында диварга Кара Таш урнаштырылган булган. Мәҗүси гарәп кабиләләре елга бер тапкыр биреге хаҗ кылырга килгәннәр.

630 елда мөселманнар мәҗүси мәккәлеләрне җиңгәннән соң, Пәйгамбәр Кәгъбәгә килеп, табындык потларны юк итәргә әмер биргән. Бу вакытта ул түбәндәге Коръән аятен кабатлаган: "Хакыйкать килде, ә Батыйль-ялган китте, чөнки Ялган җиңелде." (17:81)

Кәгъбә – Исламда иң изге урын, барча мөселманнар гыйбадәт кылганда шул якка – *кыйблага* карыйлар. Аны башкача *Бәйтуллаһ* һәм *Бәйтуль мәгъмур* дип тә атыйлар. Кәгъбә Мәккә шәһәрендә төп мәчетнең (*әл-Мәсҗид әл-Хәрам, Кәгъбәтуллаһ*) үзәгендә урнашкан 15 метр биеклектәге һәм нигезе 12x10 метр булган таш бинадан гыйбарәт. Кәгъбәнең дүрт почмагы дөнья якларына юнәлгән диярлек. Түбәсе яссы, тәрәзәләре юк.

Көнчыгыш почмак *әр-рөкен әл-әсвад* ("кара почмак") дип атала. Аңа 1,5 метр чамасы биеклектә көмеш кыса эчендә "кара таш" – *әл-хәҗәр әл-әсвад* кертеп урнаштырылган. Кәгъбәдә ул иң мөһим табыну әйберсе булып исәпләнә. (Шуны да

әйтеп китик, гарәпләргә кадәр күп элек, борынгы Мисырда да Гелиополь шәһәрендә Феникс кошы гыйбадәтханәсендә колонна башына куелган конус шәкелендәге космик ташка табынганнар.)

Төньяк почмак *әр-рөкен әл-гыйраки* (Гыйрак почмагы) дип, көнбатыштагысы *әр-рөкен аш-шами* (Сүрия почмагы) дип һәм көньяктагысы *әр-рөкен әл-йәмәни* (Йәмән почмагы) дип атала.

Кәгъбә өстенә биеклегенең дүрттән өч өлешен капларлык итеп кара төстәге тукыма буйлары (*кисвә*) ябылган, аңа алтынлап Кәгъбәгә һәм хаҗга нисбәтле Коръән аятьләре чигелгән. Дөрес, Багдадта Мәгъмүн хәлифәлек иткән заманда кисвәне ачык төстәге тукымадан әзерләгәннәр һәм аны елга өч мәртәбә алмаштырырга туры килгән. 1349 елдан Мисыр идарәчесе Исмәгыйль кара төстәге кисвә бүләк итеп җибәрә башлаган.

Кәгъбәнең төньяк-көнчыгыш диварында 2 метр чамасы биеклектә ишек булып, ул да чаршау белән өртелгән. Әл-Кәгъбә эченә керү өчен ишеккә баскыч терәтеп куялар. Бина эчендә өч колонна бар, күпсанлы лампалар эленеп тора. Биредә Коръәннең бүләккә алынган күчермәләре саклана.

Насыйр-и Хөсрәү Кагъбә эченә халык шыгрым тулган вакытта аларның саны җиде йөз егермегә җиткәнлеген исәпләп чыгарган.

Диварның ишек белән "кара таш" арасындагы өлеше *әл-мөлтәзәм* дип атала. Аллаһыга аерата хуш булган доганы шуның янында укыйлар.

Төньяк-көнбатыш диварның түбәсеннән су агызу өчен алтынланган улак чыгып тора, аны *әл-мизаб* яки *мизаб әр-рәхма* дип атыйлар. Истанбулда Туб сараенда саклана торган иң кадерле әйберләр арасында Кәгъбә улагы да бар икәнен әйтеп китик. Әл-Мизаб белән Кәгъбәнең көнбатыш почмагы арасындагы төш нәкъ менә *кыйбла* дип санала.

Әл-Кәгъбә тирәсендә түшәлгән сукмак бар, тәваф кылучылар шуның буенча әйләнәләр.

Кара Ташка каршы диярлек җирдә изге *Зәмзәм чишмәсе* урнашкан. Аның суы тозлырак, "ләкин аны эчәргә була" (Насыйр-и Хөсрәү).

Риваятьләргә караганда, беренче Кәгъбәне Адәм галәйһиссәлам һәм аның хатыны Һәүва, Аллаһы Тәгалә үзләрен гафу кылганнан соң, Аллаһы бүләк иткән ак якутташ өстенә корганнар. Туфаннан соң ул Кәгъбә җимерелгән һәм аны яңадан Ибраһим белән Исмәгыйль төзегәннәр. Кәгъбәне бина кылганда алар көненә бер рәт кенә таш салганнар, ягъни ашыкмыйча, ышанычлы итеп төзегәннәр. Төзү эшләрен ансатлаштыру өчен, Җәбраил фәрештә Ибраһимга яссы таш китергән. Бу таш һавада үзе эленеп тора алган һәм Ибраһим, шуңа басып, үзе теләгән биеклектә эшләгән. Ибраһим пәйгамбәрнең аяк эзе уелып калган ул таш хәзер Кыйбла ишегенә каршы гына *Мәкам әл-Ибраһим* дип атала торган урында тимер сандык эчендә саклана.

Риваятьләр Кәгъбәнең төньяк-көнчыгыш дивары янында, *әл-һиҗер* дип аталган төштә, Исмәгыйль белән аның әнисе Һаҗәр җирләнгән дип сөйли.

Исламга кадәрге чорда Кәгъбә турында кайгырту хокукы бер кабиләдән икенчесенә нәүбәт буенча күчкән. VI гасырда Кәгъбәне корәеш кабиләсе саклаган һәм корәешләр аны барлык гарәпләрнең изге үзәге иткәннәр. Корәешләр кәгъбәсе диварларына Библия каһарманнарының сурәтләре ясалган була. Кәгъбә эчендә Мәккәнең илаһи химаячесе Һубәл сыны торган, Кәгъбә тирәсенә төрле гарәп Аллаларының күпсанлы сыннарын тезеп куйганнар.

Кәгъбәне мәҗүсилектән арындыруны Мөхәммәд Пәйгамбәр үзенең бурычы итеп куйган һәм 628 елда Мөхәммәд хаҗ кылган вакытта мөселманнар Кәгъбәдәге сын-санәмнәрне юк иткәннәр. 630 елда мәҗүсиләргә Кәгъбәгә хаҗ кылу тыела һәм шул вакыттан алып Кәгъбә фәкать Исламның гына изге урыны булып санала башлый һәм берләшү символы булып кала. Риваятькә караганда, Мөхәммәд 25-30 яшьлек чагында әл-Кәгъбәне ремонтлау эшләрендә катнашкан һәм Аллаһы тавышын беренче тапкыр шунда ишеткән.

Хәзрәти Гайшә сөйләвенчә, Мөхәммәд Пәйгамбәр аңар бервакыт: "О Гайшә, әгәр дә корәешләр җаһилияткә якын булмаган булсалар, мин Кәгъбәне җимерергә, аннары аңардан аерылып калганны кушып салырга, ишек тупсасын җиргә кадәр төшерергә боерыр һәм анда ике ишек – көнчыгыш һәм көнбатыш ишекләр ясатыр идем, Ибраһим

салган нигез өстендә кабат төзетер идем!" — дигән.

Кәгъбә кат-кат үзгәртеп корылган, аны әле зурайтканнар, әле кечерәйткәннәр, аның тирәсендә төрле корылмалар барлыкка килгән. Әл-Хәрәзми мәгълүматларына караганда, һиҗри 61 елның сәфәр аенда соңгы көнне (миляди 683 елның 27 октябрендә) Кәгъбәдә янгын чыккан. Шул ук автор һиҗри 139 елда (яңа стиль белән 756 ел) Кәгъбә мәчетенең ремонтлануы һәм киңәйтелүе турында яза. XX гасыр урталарында, Согуд Гарәбстаны хакимнәре үткәргән ремонт эшләре вакытында, әлеге корылмаларны сүткәннәр. Насыйр-и Хөсрәү заманында (XI гасыр) Кәгъбә стеналарының калынлыгы алты кул яссуы кадәр булган. Кәгъбә бинасы эчендә төньякта идәнгә кызыл мәрмәр плита урнаштырылган. Бу урында Рәсүл галәйһиссәлам намаз укыган дип сөйлиләр.

Елга берничә тапкыр мөселманнарга махсус чакыру буенча Кәгъбә эчендә намаз укырга рөхсәт ителә. Хәзерге вакытта Кәгъбә эченә Сөгуд Гарәбстанының короле яки аның вәкиле, башка мөселман илләреннән килгән илчелек миссияләренең башлыклары һәм рухани вәкилләре генә кертелә. Шиһабетдин Мәрҗани 1880 елда хаҗга баргач, юлдашлары Фәйзулла һәм Зәйнулла белән бергәләп "Кәгъбәтулла эченә керү белән кадерлеләндек" дип яза. Мөселман булмаган кешеләрдән Кәгъбә эченә инглиз шәрык белгече Ричард Френсис кына үтеп керә алган. Кәгъбә эчендә намаз укыган вакытта ишеккә таба юнәләләр, ләкин теләсә кайсы якка карасаң да ярый. Кәгъбә — мөселманнарның михрабы булмаган бердәнбер гыйбадәтханәсе.

Гомумән, Кәгъбәне Аллаһы тәхетенең җирдәге күләгәсе (проекциясе) дип саныйлар.

Мөхәммәд Пәйгамбәр "Кәгъбәне Хәбәшстаннан килгән кыска аяклы кеше җимерәчәк", — дигән *(Сахих Бохари)*. Бу хәл Кыямәт көне алдыннан булачак икән.

Мәккәдән ерак яшәүче халыклар арасында "кара таш" та, Кәгъбә үзе дә җир белән күк арасында эленеп тора икән дигән легенда ишетергә туры килгәли. Бу легенда ничек килеп чыккан? Билгеле булганча, Кәгъбә Мәккә шәһәренең үзәгендә, түбәнрәк җирдә урнашкан, аннан төрле якларга урам-тыкрыклар сузылып китә. "Һавада эленеп торучы" Кәгъбәнең серен аңлар өчен шул тарафка биегрәк җирдән карау да җитә. Кәгъбәне каплаган кисвә кәгъбә түбәсеннән метр ярымнар түбәнрәк бер метр чамасы киңлектәге пута белән каймаланган. Ялтыравык алтын хәрефләр белән Коръән аятьләре шул путага язылган. Көн уртасында югары урамнардан Кәгъбәгә күз салсаң, эссе кояш нурлары астында бу кисвә икегә бүленгәндәй булып, ә өске өлеше һавада эленеп торган шикелле күренә. Әлбәттә, кояш чыкканчы яки кояш баегач карасаң, бернинди могҗиза күрмисең.

Кәгъбә хезмәткәрләре кара кием кияләр.

Ибне Габбас Адәм галәйһиссәламнең уң кулы Кәгъбә туфрагыннан яратылган дип яза.

Мәүла Колыйда *кәгъбәханә* сүзе очрый.

Мишәрләрдә "кәбәм", ягъни "кәгъбәм" дип якын һәм кадерле кешегә әйтәләр. Керәшен сөйләшләрендә *ана-кәбә* — Мәрьям-ана мәгънәсендә йөри икән *(Р. Әхмәтьянов)*.

*Дәвамы киләсе санда*

Тагіх
Тарих

**Нурулла Гариф**

# БОРЫНГЫ ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЛЕГЕ БӘКЛЕК ҮЗӘГЕ БУЛГАНМЫ?

Казан ханлыгы тарихы начар өйрәнелгән. Аерым алганда, бу бигрәк тә андагы феодаль вассаллык мөнәсәбәтләренә кагыла. Әлеге проблема, гомумән, Алтын Урдадан соңгы төрки-татар дәүләтләрендәге феодаль вассаллык мөнәсәбәтләрен өйрәнү мәсьәләсендә чыганакларның үтә аз булуына бәйле. Җирле вассал феодаль биләмәләрне өйрәнү тәҗрибәсе, Казан ханлыгының дәүләти төзелешен һәм сәяси идарә системасын ачыграк күзалларга мөмкинлек бирер иде. Моннан тыш, әлеге мәсьәләне өйрәнү һәм аерым төбәкләрнең сәяси-сыйнфый, икътисади-хуҗалык тарихын, тарихи географиясен барлау, тулырак өйрәнү мөмкинлегенә дә юл ача. Бер үк вакытта Казан ханлыгындагы Чаллы вассал феодаль биләмәсен өйрәнү тәҗрибәсе дәүләттәге башка вассал—дәүләти феодаль берләшмәләрне өйрәнү өчен дә башлангыч җирлек тудыра.

Казан ханлыгындагы фоедаль вассаллык нигезләрен Чаллы төбәге мисалында өйрәнү Чаллы төбәгенең тарихи ядкярләргә бай һәм археологик яктан чагыштырмача яхшы өйрәнелгән булуы белән отышлы.

Чаллы бәклеге мисалында Казан ханлыгындагы феодаль вассаллык мөнәсәбәтләрен өйрәнү бу урта йөз дәүләте төбәкләре тарихын өйрәнүгә, ана игътибарны юнәлтүгә, тарихи ядкярләрне барлау һәм торгызуга да мәгълүм дәрәҗәдә өлеш кертә, халыкны, бигрәк тә яшь буынны тәрбияләүдә зур роль уйный, Татарстанның тулы канлы дәүләт буларак яшәү омтылышына хезмәт итә.

Казан ханлыгының яшәеш чорлары XV—XVI гасыр урталарына карый. Борынгы Болгар дәүләте варисы буларак, ул Алтын Урда—Җучи олысы таркалудан аерымланып калган дәүләт. Аның җирлегендә һәм халкының яшәешендә Алтын Урда мирасы белән бергә Болгар дәүләте чорыннан килгән үзенчәлекле, мирасы җирле шартлар да сакланган. Казан ханлыгындагы феодаль вассаллык мөнәсәбәтләрен ачыклауда, әлеге тарихи җирлекнең урыс дәүләте тарафыннан яулап алынуына актив каршылык күрсәтү чорын кертү дә әһәмияткә лаек. Бу вакыйгаларда ханлыкның төрле төбәкләре, халыклары актив катнашуы, алар арасындагы тарихи берлекне һәм үзара мөнәсәбәтләрне ачык чагылдыра.



*Әчке (Иске) Казан шәһәре. Фердинанд Халиков рәсеме.*

Шунлыктан Чаллы феодаль биләмәсе мисалында бу чордагы феодаль вассаллык мөнәсәбәтләрне тикшерү тәҗрибәсе Болгар, Алтын Урда дәверендәге тарихи дәвамчылыкны күзәтү, чагыштыру һәм нәтиҗәләр ясау мөмкинчелеген дә тудыра. Чаллы төбәгенең бәклек иисә аерым сәяси үзәк буларак тоткан урыны төрле хронологик чорларда искәртелә. Бу дәвамчылык Болгар, Алтын Урда чорында ук җирлек табып, Казан ханлыгына да күчкән.

Казан ханлыгы башка татар дәүләтләре кебек үк Алтын Урда дәүләтенең бер олысы буларак яшәгән җирлектә оешкан. Шул сәбәпле үзенең сәяси төзелеше белән Алтын Урда дәүләтенең бер өлеше,

аның кечерәйтелгән калыбы буларак санала. Казан ханнары, Алтын Урда дәвамчылары буларак, үз ярлыкларын уртак кагыйдәләр буенча башкарганнар *(Усманов М. А. Жалованные акты Джучиева Улуса XIV—XVI вв. Казань: Изд-во КГУ, 1979.— С. 78).*

Казан ханлыгының төп байлыгы булып җир-туфрак торган. Җир бүленеше дәүләт күләмендәге сәяси һәм икътисади эшчәнлекнең төп нигезен тәшкил иткән. Казан ханлыгы җирләре, хан һәм аның якыннары, дәүләт идарәсендә урын биләгән төрле дәрәҗәдәге бәкләр, хәрби углан-казаклар, дини эшчәнлеккә бәйле вакыф биләмәләре, җирле бәкләр һәм башка сыйнфый баскычта торучылар арасында бүленгән. Дәүләт идарә төзелеше эшчәнлегендә корылган феодаль-вассаллык мөнәсәбәтләр төп байлык—җир бүленешенә бәйләнгән. Җирләрнең төрле сәяси катламнар арасындагы бүленеше һәм әлеге биләмә-биләкләрдә бәкләр тоткан сәясәт тулаем дәүләт яшәешендәге төп рольләрнең берсен уйнаган.

Казан ханлыгының иң югары иерархик баскычында хан торган. Ул үз идарәсендә булган бар җирләрнең хуҗасы—җир биләүче иң зур феодал. Әлеге җирләр белән идарә итү хокукы, ислам дине аңлатканча, ханга Аллаһы Тәгалә тарафыннан вакытлыча бирелгән дип шәрехләнә. Ана шулай ук сугыш игълан итү, гасыр башында тору яисә ана житәкче билгеләү хокукы да бирелгән. Хан үз кул астындагы җирләрне бүләк итәргә, якыннарына—хезмәтчеләренә хезмәтләре өчен бирергә, аннан ясак һәм башка төрле салымнар җыю хокукына ия. Аның тарафыннан даими дәүләт хезмәтендәге углан, бәкләргә җиргә хокук бирүче ярлыклар таратылган. Үзәк һәм җирле *(төбәк)* идарә урыннарына феодал-бәкләр билгеләнгән. Хан үз кул астындагыларның хокукларын саклау һәм яклау хокукына ия булган.

Казан ханлыгының дәүләт төзелеше һәм икътисади нигезе:

1.Дәүләт эшчәнлеге хан һәм төрле дәрәҗәдәге түрәләр *(бәкләр)* тарафыннан алып барылган;

2. Дәүләт идарәсе җирле үзенчәлекләргә бәйле рәвештә төзелгән һәм бар җирләргә үз хакимият идарәсен керткән. Әлеге идарә алымнарында җирле үзенчәлекләр дә исәпкә алынган;

3. Дәүләт идарәсе гаскәр һәм хөкем системасы аша үзәк белән төбәкләр арасындагы бәйләнешне тәэмин иткән;

4. Дәүләт үз җирләрендә салым түләү системасын керткән. Салым түләү күләме ханлыкка кергән җирләрнең географиясенә, төрле халыкларның яшәешенә, сәяси һәм хәрби вәзгыятькә бәйле үзгәреп торган;

5. Казан ханлыгы дәүләт төзелеше феодаль вассал олыслар нигезендә корылган.

Ханлыкта идарә династиясе һәм хан биләмәләре нәселдән-нәселгә күчкән. Бәкләрнең дә идарә системасы үз биләмәләрендә, кечерәйтелгән күләмдә, шул ук шартларда барлыкка килгән. Бәкләр тарафыннан идарә ителүче биләмәләр—биләкләр *(кенәзлек)* дип аталган. Биләкләрнең хуҗасы үзенең биләмәләренә һәм анда яшәгән халыкка карата аерым хокукларга ия булган. Әлеге җирләр дә шул ук тәртиптә морза, казаклар—бәк нәселенең туган тумачалары, дәвамчылары арасында бүленгән. Биләк белән идарә итү хокукы атасыннан олы улына күчкән.

Казан ханлыгындагы биләкләр системасын Кырым ханлыгы җирлегендәге бәйлекләр белән чагыштырып карарга мөмкин. Казан ханлыгындагы кебек Кырым ханлыгы бәкләре дә үз бәйлекләрендә тулаем хакимлеккә ия булганнар. Алар кул астында хокук һәм финанс эшчәнлеге алып барылган. Бәкләргә әлеге хокукны шәхси гаскәр ярдәмендә дә саклау кирәк булмаган. Чөнки бәйлек чикләрендәге хокукый эшчәнлек хан тарафыннан бирелгән ярлык белән ныгытылган. Кырым җирлегендә хан тарафыннан бирелгән ярлыкта: "...әлеге хан ярлыгы карарын житкереп, бәкләргә биләмәләрен үлгәнче үзендә калдыру мөмкинлеген, җиреннән һәм анда яшәүчеләрдән төрле салымнар җыю хокукы бирәм. Әлеге җирлектә яшәүче барлык морзалар һәм башка буйсынучы кешеләр тыныч тормышта да, сугыш куркынычы туганда да ана буйсынырга тиешләр" дип хәбәр ителә *(Никольский П. А. От Крымского ханства до наших дней.—Симферополь, 1929.—С. 9).*

Биләкләр Казан ханлыгының төрле төбәкләрендә урнашкан. Мәсәлән: Мари "беляк"лары, Мокшы "билик"ләре кебек башка халыклар яшәгән төбәкләр җирле

татар бәкләре һәм морзалары тарафыннан идарә ителгән. Әлеге билек системасы Алтын Урда чорында аның үзәк җирләреннән көчәнгән феодал-бәкләре тәэсирендә формалашкан.

Казан ханлыгында феодал-бәкләр, җир биләүчеләр буларак сыйнфый бүленештә югары катламында торганнар. Дәүләт сәясәтендә уйнаган рольләре, үз биләмәләрендәге икътисади һәм шәхси эшчәнлекләрендәге уңышлыкларга бәйле алар хан һәм дәүләт советы эшчәнлегенә төрле дәрәҗәдә йогынты ясый алганнар. Дәүләт дәрәҗәсендә хан, сәяси идарә үзәге—диван тарафыннан төрле йөкләмәләр белән бәйлелеккә карамастан, һәр феодал үз биләмәсендә *(бәйлек, билек, бәклек)* тулы сәяси һәм хокукый хакимияткә ия булган.

Казан ханлыгы җирләре салым җыю системасы эшчәнлегенә бәйле аерым ясак җыю өлкәләренә—даругаларга бүленгән. Даругалар үз чиратында кечерәк берәмлекләр—олыс-йөзлекләргә, йөзлекләр исә уңлыкларга бүленгән. Уңлыклар дип, уң сугышчы бирерлек авыллар саналган. XVI гасырның икенче яртысыннан XVIII гасыргача яшәгән йөзлек берләшмәләрен күзәтеп, Р. Галләмов әлеге бүленеш дәүләт җирләренә караган биләмәләргә генә хас дигән фикергә килә *(Галлямов Р. Ф. Зеленодольская земля в эпоху Казанского ханства (Краткий очерк) Казань: Gumanitarya 2003.—С. 83)*. Даругалардан аермалы буларак, олыслар системасы төрле дәрәҗәдәге әмир, бәк-мирзалар һәм дәүләт иерархиясенең башка баскычларында торган катламнарның нәселдән-нәселгә күчкән биләмәләре булган. Даругалар белән салым җыю системасына караган хакимият җитәкчеләре—мәэмүрләр, мөхтәрәм хуҗалар идарә иткән. Әлеге даруга-өлкәләрнең җитәкчеләре бәкләр—дәүләт хезмәтендәге аксөякләр булган. Алар хан янындагы диван-киңәшенә дә кергәннәр.


Кызганыч, билек һәм даруга системасын тулаем өйрәнү өчен тарихи чыганаклар җитәрлек материал бирмиләр.

Алтын Урда таркалу чорында, үзәк идарә системасы йомшый. Шул сәбәпле Казан ханлыгы төзелгән төп җирлектә, ярымбәйсез җирле феодал үзәк—олысларның феодал таркаулык кичерүләре турында фикер йөртү урынлы. Әлеге бәклек үзәкләренең, даруга—салым җыю үзәкләре буларак яшәүләре дә мөмкин. Феодал берлекләрнең иң зурысы һәм көчлесе Казан төбәге булуы ихтимал. Әлеге бәклекләр—вассал феодаль үзәкләр исәбенә Арча, Алат, Мишә буендагы Җөри һәм көнчыгышта Чаллы белән Алабуга шәһәре төбәкләрен дә кертергә була. Бу фикер бигрәк тә Арча, Чаллы, Алабуга кебек олыс үзәкләре калгалары саклангыч урләренең төзелеш чоры Алтын Урда дәверләренә үк тоташуына бәйле рәвештә тагын да ныгый. Әлеге вассал феодаль үзәкләрнең—даругалар системасы эшчәнлегендә дә мәгълүм бер роль уйнаулары ихтимал. Соңрак әлеге олыслар—ясак җыю үзәкләренең Казан шәһәре җирлегендә, Олуг Мөхәммәд династиясе кул астында берләшүләре яисә берләштерүләре турында фараз кылырга була. Казан ханлыгы дәүләт идарәсе системасының эчке сәяси-административ төзелешен һәм икътисади нигезен Алтын Урда җирлегеннән калган яисә бүленеп чыккан олыслар—җирле вассал бәклекләр тәшкил иткән. Казан җирлегендә Олуг Мөхәммәд династиясе үзен Алтын Урданың төп варисы буларак таныта. Шул сәбәпле әлеге җирлектә идарә системасы һәм дәүләтнең эчке сәяси төзелешендә нинди дә зур үзгәрешләр булуы турында фикер йөртеп булмый. Даругалар турында Алтын Урда дәүләтендәге даруга үрнәкләре һәм ханлык җирлегендә рус чоры—XVI—XVIII гасырларга караган язмалар буенча гына фаразлый алабыз.

Ханлык тормышында һәм идарә эшчәнлегендә зур урын тоткан бәкләрне ике төркемгә бүлеп карарга мөмкин. Беренчеләре—җирле бәкләр *("Казанның җирле бәкләре һәм мирзалары һәм сәетләре һәм уланнары...". ПСРЛ. Т. XIII, 1965.—480 б.)*. Алар даругалар эченә кергән аерым олыслардагы үз биләмәләрендә яшәгәннәр һәм әлеге җирлектә тулы хокукка ия булганнар. Хан тарафыннан ярлык белән ныгытылып бирелгән җир өчен ул салам түләгән, хәрби ярдәм күрсәткән яисә башка төрле вазыйфа үтәгән.


Икенче бәкләр—дәүләт идарәсендәге бәкләр *("хан түләме белән яшибез..., без ханга үзебезгә файда булганда гына буйсынабыз..." (ПСРЛ. Т. XIII, 1965.—56 б.)*. Әлеге бәкләр хәрби хезмәт, идарә системасында һәм салым җыю эшчәнлегендә

хезмәт иткән. Әлеге бәкләр тарихи язмаларда даруга бәк, олуг бәк, бәкләр бәге, баш бәк—карачы атамаларында искә алыналар. Р. Галләмов Казан ханлыгының үзәк җирләреннән барлыгы унбер сәяси-административ өлкә: Арча, Алат, Гәреч *(Гәреш)*, Нугай, Югары-Урта-Түбән Чуаш *(Җөри)*, Үкрәч, Яке *(Җәке)*, Аты, Кырым (Бортас) даругаларын—салым җыю өлкәләрен бүлеп чыгарган һәм аларның чикләрен билгеләп картасын төзегән *(Галлямов Р.Ф. Административные даруга Казанского ханства: опыт реконструкции // Казанское ханство: актуальные проблемы исследования.—Казань, 2002.—С. 281)*.




Казан ханлыгы чорындагы юллар һәм кичүләрнең аңлатма картасы.

Казан ханлыгы үзәк җирләрендә, даруга-өлкәләрдә гаскәрләр урнашкан. Әлеге гаскәрләр хан карамагында саналып, бәкләр тарафыннан идарә ителгән. Гаскәр урнашкан олыс—билек шәһәрчекләрнен ныгытмалары күп очракта очланган бүрәнә казыклы коймалар белән әйләндереп алынган. Бәкләрнең торак урыннары тирәсендәге авылларда хан, бәкләрнең атлы гаскәре торган Хәрби гаскәрләр яшәгән төбәкләр, даруга-үзәкләрдән тыш борынгы зиратлар һәм алардагы эпиграфик кабер ташларының күплеге белән дә билгеләнә. Мәсәлән, Олы Әтрәч каберлегендә—50, Кирмәндә—27, Мәнгәрдә—22, Чаллыда—5 кабер ташы сакланып калган *(Юсупов Г. В. Введение в булгаро-татарскую эпиграфику М.: Изд. АН СССР, 1960. С.—165, 77 табл., 11 текстов)*.




Чаллы төбәгенең 1850 елгы картасы.

Ханлык чорындагы олыс үзәкләрен, торак урыннарны—шәһәрлекләр белән агач ныгытмалардан торган авылбистәләрне XIX гасыр уртасына чаклы сакланып килгән җир үрләр, торак урыннар янындагы борынгы ташлар сакланган зиратлар буенча да билгеләргә мөмкин. Бәкмирзалар еш кына шул җирбиләмәләрендәге авылларда яисә аларга якын урнашкан җәйге утар-резеденцияләрендә яшәгәннәр, ял иткәннәр. Вафат булган очракта аларны хезмәтчеләре, гади халык җирләнгән урыннардан аерым күмгәннәр. Бу зиратларда аларның туганнары белән бергә башка югары катлам кешеләре: тарханнар, дин әһелләре һәм башка җир биләүчеләр дә

жирләнгән. Казан ханлыгының үзәк жирләрендә бүгенгәчә билгеле булган борынгы зиратларның атамалары шул турыда сөйли: "Мортаза зираты" *(Теләче районы, Янсуар авылы)*, "Гаскәр башлыклары зираты" *(Апас районы, Кулгән авылы)*, "Ханнар зираты" *(Теләче районы, Тәмте авылы; Балык Бистәсе районы, Мәмле Казаклар Чаллысы авылы һ. б.)*.

Икътисади яктан ныгыган һәм үз хәрби көчләре булган феодаль вассаллар, хокукый яисә икътисади яктан кысынкылык туганда шәхси мәнфәгатьләреннән чыгып оппозициягә дә күчкәннәр. Сәяси вәзгыятькә бәйле, үз гаскәрләре ярдәмендә жирле бәкләр берләшеп ханга басым ясый алганнар. Әлеге каршылыклар нәтиҗәсендә вассаллар берләшеп яисә аерымланып, бәйсезлеккә омтылып, үзләрен хан буларак та игълан иткәннәр *(Возгрин В. Е. Исторические судьбы крымских татар.—М.: Мысль, 1992.—С. 176)*.

Икенче яктан ханнар үзләренең шәхси гаскәрләренә, жир биләмәләрендә утырган бәк-мирзаларның көченә, күрше дәүләтләрнең ярдәменә таянып, жирле бәкләрнең мәнфәгатьләренә каршы чыгып, ирекләрен дә чикли алганнар. Аерым алганда, Чаллы төбәгенең бәклек яисә аерым сәяси үзәк буларак тоткан урыны төрле хронологик чорларда искәртелә. Бу дәвамчылык Болгар, Алтын Урда чорыннан ук жирлек табып, Казан ханлыгына да күчкән.

Чаллы төбәген ханлык чорында вассал олыс биләмәсе буларак өйрәнү өчен жирлек бар. Чаллы шәһәре янәшәсендә XV—XVI гасырларга караган 5 кабер ташы сакланган. Язулары искәрткәнчә, әлеге ташлар Чаллы төбәгендә яшәгән бәк, мирзаларга куелган. Тарихи чыганаклар һәм археологик тикшерү нәтиҗәләре Чаллы шәһәре тирәсендәге ике дистәдән артык авылга ханлык чорында ук нигез салынганлыгын күрсәтә. Әлеге авыллар атамасында ханлык чорындагы иерархик бүленеш эзләре сакланып калган.



Чаллы төбәгендә 1999 елда табылган таш (1530 елларга карый).

Тарихи язмаларда Чаллы төбәге бәклек үзәге буларак күрсәтелә. М. Зәетовның "Чаллы шәһәрчеге турында" дигән язмасы белән "Хажи Гәрәй" дастанында китерелгән мәгълүматлар буенча Чаллы олысында идарәче булып Жан Гәрәй, Хажи Гәрәй һәм Хафиз Гәрәй хан-солтаннарның торуын фаразларга була *(Борынгы Чаллы / Жаваплы редактор Ф. Хужин, төзүчесе Н. Гариф.—Казан, 2000.—270.—272 бб.)*.

"Хажи Гәрәй" дастанында: "Хажи Гәрәй хан бине Дәлүк кыяс улан бине Дәүләт хужа улан, Таштимер улан, бине Тимер хужа улан, бине Каракунас Күбәк хужа улан Хажи Гәрәй ханның агасы Жан Гәрәй солтанны Кункерат биләр үлтергәндин соң Хажи Гәрәй солтан кечек кликәндер качып йөреп, чакырган байга ялга кереп йөргәндә, бикләр үз араларында бере берен улаша алмый, Хажи Гәрәй солтанны эзләп табып хан ясадылар",—дип хәбәр ителә *(Борынгы Чаллы.—Казан, 2000.—477 б.)*.

М. Зәетовның язмасында Чаллы бәгенең *(бий)* Казаннан аерылып чыгу омтылышы сурәтләнә: "Чаллы ханы Хажи Гәрәй үзен бәйсез хан дип игълан итә, ә берничә елдан Хафиз Гәрәй хан булганда Казан белән Чаллы арасында сугыш була. Казан ханы Чаллы шәһәрен ала, талый һәм юк итә" *(Зәитов М. Б. Чаллы шәһәре турында.—Казан, 1884.—277-280 бб.)*. Казан белән Чаллы арасындагы вәзгыятьне—феодал низагларның чишелеше буларак кабул итәргә мөмкин.

Чаллы төбәген олыс үзәге буларак расланганда, тарихта билгеле Арча бәкләре *("Арские князья")* тарихына да игътибар юнәлтү зарур. Арча шәһәрен бәклек—жирле хакимият үзәге буларак өйрәнүгә бәйле хезмәттә тарихчы Дамир Исхаков рус елъязмасының 1531 елга караган хәбәрләреннән чыгып: "Мәскәүгә баручы илчелек эчендә Арча бәкләре мостәкыйль сәяси көч буларак катнашкан"—дип яза


Чаллы шәһәрлеге күренеше. Фердинанд Халиков рәсеме.

*(Исхаков Д. М. Казан ханлыгында Арча кенәзләре.—Казан, 2002.—331 б.).*

Арча бәкләре беренче тапкыр тарихта 1489 елда искә алыналар. 1552 елгы вакыйгаларга бәйле, рус гаскәре тарафыннан Арча каласы яулап алынганда: 12 Арча бәге, 7 чирмеш хәрби житәкчесе һәм 300 тирәсе йөзбаш белән бергә яхшы кешеләр *(казаклар)* тоткынлыкка төшкән *(ПСРЛ, Т. XIX, 1903, 127 б.).* Әлеге чыганак искә алган житәкчеләрнең Арча олысы хакимияте вәкилләре, ә Арча шәһәрен феодал бәклек үзәге буларак күзалларга нигез бирә.

Д. Исхаков тарихи елъязмаларда чагылыш тапкан Арча, Нократ бәкләре исемнәрен, әлеге төбәктә сакланып калган кабер ташлары һәм шәжәрәләрдә искә алынган шәхесләрнең исемнәре белән чагыштырып, Арча даругасы хакимият берәмлеге буларак Кыпчаклар кланына караган дип фикер йөртә. Әлеге кланнарның Арча даругасын үз кулларында, Урда чорында ук Болгар вилаяте буларак тотуларын һәм соңрак—ханлык оешу чорында, аңа даруга—өлкә буларак кушылуы мөкинлеге турында фараз кыла *(Исхаков Д. М. Родословные и эпические произведения как источник изучения истории сословий Улуса Джучи и татарских ханств / Арские князья в Казанском ханстве // Источниковедение истории Улуса Ждучи (Золотой Орды). От Калки до Астрахани 1223—1556.—Казань, 2002.—С. 332-339).*

Чаллы шәһәрлеге бәклек үзәге буларак төрле чыганакларда һәм бу төбәкне өйрәнгән тарихчылар хезмәтләрендә искә алына. Мәсәлән, Ш. Мөхәмәдъяров, Казан ханлыгының идарә системасын өйрәнеп, Чаллы төбәген феодал-бәк биләмәсе буларак күзаллый *(Мухамедьяров Ш. Ф. Социально-экономический и государственный строй Казанского ханства (XV – первая половина XVI в.в.).—Москва, 1950.—С. 311).*

Чаллы төбәге ханлык чорында Чуаш *(бу очракта чуаш—ясак түләчеләр мәгънәсендә аңлатыла)* даругасына кергән. Чуаш даругасы Казан шәһәреннән башланып, көнчыгышка таба киңәя барган. Чуаш даругасының үзәк бер жирендә Чаллы шәһәре урнашкан. Р. Фәхретдинов Чаллы шәһәрен Жөри (соңрак чорда Нугай) даругасы—кече олыс-өлкә үзәге булган дип яза (Фәхретдинов Р. Г. Татар халкы һәм Татарстан тарихы.—Казан, 2001.—212 б.).

Географик урнашуы һәм шул чорда уйнаган роленә бәйле рәвештә, Чаллы шәһәрлеге аерым кенәзлек *(бәйлек)* үзәге, ягъни Нугайлар йогынтысындагы—"Мангыт йорт"ы булуы мөмкинлеге дә билгеләп узыла *(Исхаков Д. М. От средневековых татар к татарам нового времени (этнологический взгляд на историю волго-уральских татар XV—XVII в.в.).—Казань, 1998. С. 22-26.).*

Тарихи язмаларда икътисади, сәяси яисә жирле феодаль үзәк—билекләр (кенәзлек) урыны төрле нигезләмәләр буенча дәлилләнә.

Чулман елгасы аша салынган нугай кичүе белән янәшә Үкрәч—Култык ныгытмасы урнашкан. Әлеге хәрби ныгытма янәшәсендә халык шәһәр тормышы белән яшәгән. Ныгытмадан ерак түгел генә Лаеш торак жирлеге урнашкан һәм тарихи язмаларда анда күп хәрби тотыклар яшәгәнлеге турында әйтелә. Шул сәбәпле Е.И. Чернышев бистә тибында төзелгән Лаешны зур феодаль үзәк буларак билгеләп үтә *(Чернышев Е. И. Селения Казанского ханства (по писцовым книгам) // Археология и этнография Татарии.—Казань, 1971.—С. 276-277).* Е. И. Чернышев

Казан ханлыгы чорында Агач авылы урынында булган ныгытма турында да искә ала. Әлеге ныгытма тирәсендә ясаклы халык яшәгән һәм ул татар феодалларынын әһәмиятле, стратегик үзәге булган.

Тарихчы-археолог Н. Ф. Калинин Нократ шәһәрлегендә табылган тимер кою һәм эшкәртү, сөяк эшләнмәләре ясау остаханәләрен археологик яктан өйрәнеп, аларнын әлеге жирлектә яшәгән феодаль катламга хезмәт күрсәтүләрен фаразлый. Шәһәр ныгытмалары янында ике зур бистә урнашкан. Нократ шәһәре үз чорында зур икътисади һәм сәяси үзәк булган.

Казан шәһәре биләмәсендә урнашкан Кабан шәһәрлеге турындагы фаразлар да игътибарга лаек. Шәһәрлекне феодаль үзәк *(бәклек, бәк ныгытмасы)* буларак сурәтләгәндә тарихчы шәһәрлек эчендә табылган кабер ташларындагы "әмер", "солтан", "солтаннар ярдәмчесе", "жинүче" кебек титуллар булуына таяна. Кабан шәһәрлеге тирәсендә һөнәрчелек бистәләренә 12,14,28 чакрым ераклыкта урнашкан Кече, Олы, Татар Кабаны авылларын күрсәтеп, галим, шәһәрлекне бәк (кенәз) резеденциясе булган дип саный. Санап узылган үзенчәлекләргә бәйле Эчке Казан, Елантау, Кирмән кебек башка шәһәрлекләр дә феодаль үзәкләр буларак билгеләнгән *(Калинин Н. Ф., Халиков А. Х. 1945—1952 елгы археологик эшләрнен нәтижәләре.—Казан, 1954.—66-107 бб.).*


Чаллы кирмәне капкасы (реконструкция).

Әлеге билгеләмәләр буенча Чаллы шәһәрлегенең дә Болгар чорыннан башлап ханлык чорына чаклы төрле дәрәжәдәге феодаль үзәк *(бәклек)* ролен үтәгәнлеген нигезләргә мөмкин. Әлеге караш түбәндәге фактлар буенча раслана:

1. Чаллы шәһәре өлешчә биш кат ныгытма белән әйләндереп алынган һәм ханлык чорындагы шәһәрләр арасында анын ныгытмасы Казаннан кала иң ныклардан саналган. Археологик тикшерү нәтижәләренә караганда, Чаллы ныгытмаларының соңгы төзекләндерелүе һәм жимерелү вакыты ханлык чорына карый.

2. Чаллы ныгытмасы һәм янәшәсендәге бистәләрдә тимер кою һәм эшкәртү бинасы калдыклары, керамик яисә агачны кырып савыт-саба ясау, сөяк эшкәртү остаханәләре табылды. Казан ханлыгы чорында Чаллы шәһәре ныгытмалары янәшәсендә, тимерчелек остаханәсе белән янәшә, корал ясаучылар бистәсе урнашкан *(Хужин Ф. Ш., Нигамаев А. З. Чаллы шәһәрлеге тирәсендә уздырылган археологик эшләрнен нәтижәләре.—Казан, 1999.—114-142 бб.).*

3. Археологик материалларга ясалган анализ, башка чорлар белән чагыштырганда, Казан ханлыгы чорында ат тотуның күбрәк булуын күрсәтә, бу исә ныгытма тирәсендә атлы гаскәр торуына ишарә ясый.

4. Тирә-якгагы елгалар һәм аларда урнашкан ташландык һәм бүгенгәчә тормыш иткән татар авылларының исемендә Казан ханлыгы чорларыннан килгән дәрәжә атамалары чагылыш таба. Алар Чаллы шәһәрлеге янәшәсендә урнашкан: Шихазда *(Шәех залә)*, Котлы Бөкәш *(Котлы бәк)*, Бирдебәк, Бикчура *(Чураш)*, Пимәр, *(Би Әмир)*, Биектау *(Байхужа)*, Сатлыгын *(Би Йорт, Иске Йорт)*, Иске Мәмле *(Мәмле Хужа)*, Жанбатыр һ. б.

5. Казан ханлыгы чорына караган кабер ташларында искә алынган: "сәед", "ата бик", "бәк", "морза", "хажи", "угыл" кебек дәрәжә-атамалар жирле феодал-бәкләр турында мәгълүмат бирә. Чаллы шәһәре янәшәсендә сакланып калган 5 кабер та-

шының икесендә укылышы ачык сакланып калган дәрәҗәләр буенча без җирле феодал-бәкләр: Ата бик *(Үтәк бик)* Мәннән морза углы, Хажар Ходайяр бәк углы Жаруш мирзаны санап уза алабыз.

6. Тарихи язмаларда Чаллы шәһәре һәм төбәге тарихына бәйле Жан Гәрәй, Хажи Гәрәй һәм Хафиз Гәрәйләр дәрәҗәләре буенча хан-солтаннар буларак искә алыналар.

7. Чаллы шәһәре Чаллы белән Мәшлек елгалары кушылган урында иң үзәк җирдә урнашкан. Әлеге елгалар бассейнында ханлык чорында ике дистәгә якын авыл урыны билгеле.

8. Чаллы атамасының таралышы. Чаллы шәһәрлегеннән 6-7 чакрым ераклыкта урнашкан 13 авылның атамасында Чаллы кушымтасы сакланган. Алар: Чаллыбаш, Тәберде Чаллысы, Казаклар Чаллысы, Иске мукшы Чаллысы, Үр Чаллысы, Кечек Чаллысы һ. б.

9. Ханлыкның башкаласы Казан шәһәре яулап алынганнан соң, 1552—1556 елларда, Чаллы шәһәре җирлегендә баш күтәрүчеләрнең зур көчләре туплана һәм алар тарафыннан урыс баскынчыларына карата зур каршылык күрсәтелә. Әлеге вакыйгалар Чаллы төбәгенең ханлык чорында да феодаль үзәк буларак әһәмиятле сәяси роль уйнаганлыгы турында сөйли.

10. Ханлык чорында Чаллы төбәге Чуаш *(ясаклы халык яшәгән)* даругасына кергән. Казан ханлыгы яуланганнан соң да Чаллы шәһәре тирәсендәге бар татар авыллары ясаклы буларак искә алына. Төбәктә ясаклы халыкның җирләре киң таралыш алуы аның үзәге Чаллы шәһәренең феодаль—җирле бәклек үзәге ролен башкаруы турында сөйли.

11. Чаллы төбәге яулап алынганнан соң да, язма чыганаклар бу җирлектә XVII гасыр башыннан XVIII гасыр ахырынача дәүләт хезмәтендәге морзалар эшчәнлеге турында искәртә.

12. Чаллы каласы, Болгар, Алтын Урда чорларындагы кебек ханлык чорында да, традицион формада җирле үзәк—бәклек ролен үтәп килгән. Чаллы шәһәре биләмәсе Казан ханлыгы чорында хәрби ныгытма, атлы гаскәр тупланган урын һәм җирле феодаль үзәк—бәклек буларак күзаллана.

Чаллы шәһәрлегенең якын-тирәсендә ханлык чорына караган дистәдән артык авыл урыны билгеле. Әлеге авылларның, үз атамаларына һәм якын-тирәдә урнашкан аерым зиратларда сакланган кабер ташларына караганда, аларның җирле феодаллар—бәк, мирзаларның биләмәләре булганлыгы күренә. Әлеге феодаллар арасында дини җитәкчеләр дә, сәргаскәрләр һәм дәрәҗәле феодаллар: бәк һәм мирзалар да бар. Әлеге җирләрдәге җитәкчеләрнең, иерархик төзелешкә буйсынып, бер үзәктән—Чаллы шәһәрлегеннән идарә ителгәнлеге турында сөйли. Бу очракта Чаллы феодаль биләмәсе—җирле феодал бәклек үзәге буларак саналырга һәм өйрәнелергә тиеш.

Чаллы төбәге һәм аның үзәге Чаллы каласының Казан ханлыгы тарихында тоткан сәяси һәм икътисади урыны бар. Казан шәһәре яулап алынганнан соң, Чаллы каласы һәм төбәге 1556 елга чаклы баш күтәрүчеләрнең үзәге буларак хезмәт итә. Шул сәбәпле Чаллы төбәге тарихын ачыклау, болгар-татар халкының Мәскәүнең колониаль омтылышларына каршылык күрсәтүен һәм үз дәүләтен торгызу өчен барган Ватан сугышының объектив тарихын ачыклау мөмкинчелегенә җирлек тудыра.

Səngət
Сәнгать

**Шамил Монасыйпов,**
*профессор, Татарстанның халык артисты, Татарстан Республикасының Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты.*

# ЯҢАРЫШ ЧИШМӘЛӘРЕ

МУЗЫКАНТ ИЛЬЯС ӘУХӘДИЕВНЕҢ ТУУЫНА
ҺӘМ КАЗАН МУЗЫКА УЧИЛИЩЕСЫ ОЕШУГА 100 ЕЛ

Үзенең канкойгыч сугышлары, инкыйлаб китергән афәтләре, космоска юл яруы һәм кешенең геннар табигатенә үтеп керүе белән дөньяны тетрәткән XX гасыр татар халкының мәдәнияте тарихында да хәлиткеч әһәмияткә ия булган вакыйгалары аша истә калды. Ул чынбарлыкны догматик мөселман дини кабул итүен җиңүдән башланган куәтле барышында үзенә күрә бер этап булды һәм халкына мәдәниятнең барлык катламнарына мөрәҗәгать итәргә юл ачты, шул рәвешле яна милли поэзия һәм әдәбият, сынлы сәнгать һәм музыка өлкәсендә монарчы күрелмәгәнчә күтәрелеш өчен мөмкинлекләр туды. Аерым алганда, күп гасырлар дәвамында бер тавышлы халык авыз иҗаты традицияләре кысасында яшәп килгән татар музыка сәнгате, XX гасырда башлангыч халык музыкасы жанрларыннан алып, катлаулы симфоник формаларга кадәр чикне үтте һәм дөнья музыка сәнгате тарихында хаклы урынын яулады.



*Ильяс Ваккас улы Әүхәдиев (XX гасырның 50 еллары).*

**Ильяс Ваккас** улы **Әүхәдиев** шушы "яңарыш чишмәләре"нең башында торды; аның таланты үзенең масштаблылыгы һәм күпкырлы булуы белән замандашларын таң калдырды. Махсус югары белем алган беренче татар музыкантларының берсе буларак, ул камил осталыкка ирешкән скрипач, симфонияләр һәм опера дирижеры, талантлы педагог һәм менә дигән оештыручы булып танылды. Аның дирижерлык эшчәнлеге республикада симфония сәнгатенең чәчәк атуына, татар милли тамашачысының зәвыкын тәрбияләүгә ярдәм итте. И. Әүхәдиев шулай ук озак еллар Россиядә революциягә кадәр үк мәртәбәле музыкаль үзәк булып танылган Казан музыка училищесына җитәкчелек итеп, республикада музыкаль белем бирүгә үзеннән зур өлеш кертте: 1941 елдан 1948 елга кадәр, ягъни иң катлаулы һәм җаваплы чорда музыкант татар опера һәм балет театрында эшләде.

Хәзерге заман рухият фәне һәм культурология тикшеренүләреннән күренгәнчә, өченче меңъеллыкта нәкъ менә Россиядә Көнчыгыш һәм Көнбатыш башлангычларының синтезына ирешү өчен алшартлар туачак һәм бу, үз чиратында, Мәхәббәт, Иреклелек, Тигезлек һәм Туганлык принцибына нигезләнгән бөтендөнья мәдәниятенең өслүбен барлыкка китерәчәк

*(Штейнер. О России.—СП б.—"Дамаск", 1997.—С. 407).*

Бу күзлектән чыгып караганда, И. Әүхәдиев шәхесенең роле һәм эшчәнлегенең әһәмияте чиксез үсә һәм зурая төшә. Язмыш, әйтерсең лә, ана капма-каршылыклы ике традицияне берләштерү бурычын йөкли. Шул дәвернең башка мәдәният әһелләреннән аермалы буларак, музыкант Европача махсус белем алу белән бергә, милли традицияләрнең үзенчәлекләрен дә тирәнтен үзләштерә; алай гына да түгел, халык сәнгатенә дә, татар менталитеты үзенең тамырлары белән килеп тоташкан Көнчыгыш культурасына да мөрәҗәгать итә.

## Уку еллары

Ильяс Ваккас улы Әүхәдиев 1904 елның 25 ноябрендә Арча районының Яна Шашлы авылында дөньяга килә. Аның әтисе Садриваккас һәм әнисе Лотфикамал тумыштан ук гаҗәеп музыкаль сәләткә ия булалар. Аның әтисе халык җырларын бик оста башкара һәм тирә-юньдә халык җырларын нечкәләп белүче буларак таныла. Әнисе тальянкада уйный. Һәм, әйтергә кирәк, кечкенә Ильяс бала вакытыннан ук музыкага тартыла: музыка белән "шөгыльләнү" аның иң яраткан "уенына" әверелә. 1908 елда аларның гаиләсе бәхет эзләп Урта Азия якларына чыгып китә, баштарак алар Ташкентка, соңрак исә Чимкентка килеп урнашалар. Биредә яшь музыкант аскетик татар көнкүрешеннән күп бизәкле булуы, музыкаль традицияләренең байлыгы, музыкаль инструметларның күплеге белән аерылып торган шәрекъ дөньясына кереп чума. Малай озакламый үзбәк һәм казакъ уен коралларында уйнарга өйрәнә, шул ук вакытта традицион татар уен коралларын да кулыннан төшерми. Әтисе Ильяска чын концерт гармунын сатып ала, Әһлиулла Хәбиб дигән сәүдәгәр, малайның нечкә, озын һәм җитез бармакларына игътибар итеп, ягъни музыкага сәләтен күреп алып, аңа әйбәт скрипка бүләк итә. Ильяска музыка өлкәсендә уңышларга ирешүен теләп, чынлыкта фатиха биреп борынгы "Бибигайшә" җырын җырлап күрсәтә; И. Әүхәдиев бу җырны гомере буена күңел түрендә саклап килә:

*Скрипка ни дип әйтә?*
*Бибигайшә дип әйтә!*
*Мондый көннәр сирәк була,*
*Уйнап калыйк дип әйтә!*

Октябрь революциясеннән соң яшь музыкантның рус халык инструментлары белән танышу мөмкинлеге дә туа. 1918 елда ул рус-кыргыз техникумы каршында эшләп килүче оркестрга языла, биредә ул думбрада һәм мандолинада уйный, 1919 елда исә педагогик күпчелекне Санкт-Петербургтан чыккан музыкантлар тәшкил итүче яңа гына ачылган консерваториягә укырга керә. Шулай итеп, унбиш яшендә профессиональ дәрәҗәдә скрипка һәм тынлы уен коралларында уйнарга өйрәнә башлый, симфоник оркестрда уйный. 20 еллар башында Ильяс кабат Ташкентка күчеп килә һәм механика техникумына укырга керә. Мондый адым ясарга аны ачлык-ялангачлык хөкем сөргән елларда ипи-тозлык акча эшләргә өмет иткән әти-әнисе этәрә. Моннан тыш, ул елларда татарлар арасында профессиональ максатларда балаларын музыкага өйрәтү гадәткә кермәгән була. Шулай да Ильяс скрипкада уйнавын ташламый.

Тагын берничә елдан соң ул параллель рәвештә музыка техникумында укый башлый; шушы чорда яшь музыкант атаклы скрипкачы Л. Ауэрның шәкерте булган А. А. Берлинда белем алучы якташы һәм яшьтәше Каюм Байбуров белән таныша. Шул рәвешле ике яшь җилкенчәк тә язмышларын музыка белән бәйләргә карар кылалар һәм укытучылары артыннан Мәскәүгә юл тотып, бертуган Рубинштейннар исемендәге музыка техникумына укырга керәләр. Озакламый ике яшь скрипкачының юллары озак елларга аерыла. К. Байбуров Мәскәүдә

кала, техникумны тәмамлагач, 1929 елда профессор Л. М. Цейтлин классына (Л. Ауэрның шәкерте) консерваториягә укырга керә. Үзәк музыка мәктәбендә дәресләр бирә, шул ук вакытта филармониядә солист булып эшли (аның укучылары арасында З. Шихмурзаева, А. Киселев, А. Аренков кебек танылган музыкантлар бар).

И. Әүхәдиев Мәскәүдә ике ел укыганнан соң, 1926 елда Ленинград консерваториясенә укырга керә. Чөнки ул елларда элеккеге башкала советлар Россиясенең музыкаль тормышында алдынгы урынны тотып килә. 20 елларда Ленинградта Бах яшәгән чорлардан алып, Оннегерга чаклы иҗат ителгән музыка яңгырый, мәшһүр дирижерлар чыгыш ясый. Болар—Чайковский һәм Вагнерның бөтен әсәрләрен дә башкарган Б. Вальтер, О. Клемперер һәм "Бетховенның барлык әсәрләре" циклы белән дирижерлык иткән Г. Кнапперсбуш, Дебюсси, Сибелиус, Р. Штраус әсәрләрен башкаручы А. Никиш, Стравинскийны мәшһүр интерпритацияләүче Э. Ансерме, Төньяк башкалада танылган солистлар, аерым алганда Прокофьевның Беренче номерлы концертын башкаручы скрипач Сигети, Мендельсон концертын башкаручы Полякиннар килә. Консерватория студентларына филармониядә булган концертларга бушлай йөрү мөмкинлеге тудырыла һәм грамзаписьлар, тавышны кабаттан уйнатып карау аппаратлары булмау сәбәпле, алар бер генә концерттан да калмаска тырышалар.

И. Әүхәдиев исә концертларга иң теләп йөрүчеләр арасында була һәм ул Европа культурасының бәхәссез кыйммәтләрен йотлыгып үзләштерә. Консерваториянең күренекле рус композиторы һәм дирижеры А. К. Глазунов җитәкләгән педагогик коллективы да танылган музыкантлардан тора. И. Әүхәдиевкә Ауэр мәктәбенең иң күренекле вәкилләреннән берсе, Петербург консерваториясен 1889 елда тәмамлаган профессор М. Н. Гамовецкаяда скрипкада уйнарга өйрәнү бәхете тия. Гамовецкая классында уку-укыту мәшһүр Ауэр тарафыннан эшләнгән һәм Я. Хейфец, Е. Цимбалист, М. Полякин кебек күренекле скрипачларны биргән алдынгы методлар белән алып барыла. И. Әүхәдиев биш ел дәвамында Ауэр тарафыннан бәян ителгән шигарь нигезендә скрипкада уйнау серләренә төшенә: "Скрипкада башкаручының фикер йөртүен, хисләрен һәм ихтыярын тәрбияләүче бөек Рух уйный һәм бармакларны дөрес йөрергә өйрәнүдән битәр, башны дөрес фикерләүгә гадәтләндерергә кирәк; чөнки, ахыр чиктә, башкарудагы иркенлек нәкъ менә шуна бәйле. Бары тик Музыкага чын күңелдән бирелгән якты хисләр генә инструменттан осталарча файдаланугa китерергә мөмкин".

Консерваториядә музыка теориясе фәнен Б. Асафьев, профессор И. Соллертинский, Б. Струве кебек күренекле музыка белгечләре укыта. Оркестр классын А. Глазунов үзе алып бара һәм ул музыкант-башкаручы чын мәгънәсендә оста буларак өлгереп җитү өчен симфоник оркестрда уйнау зарур дип исәпли. Мәшһүр композитор һәм дирижер белән якыннан аралашу И. Әүхәдиевкә көчле йогынты ясый: ул дирижерлык күнекмәләрен үзләштерә башлый, башкарачак әсәрләрнең партитурасын җентекләп өйрәнә. Глазунов яшь скрипкачының болай кызыксынуына бик куана һәм әледән-әле студентлар оркестрының репетицияләре вакытында дирижерлык пульты артына басарга рөхсәт бирә. Төз буй-сынлы, карлыгандай үткен карашлы һәм кайнар йөрәкле егет дирижерлык вазифасына бик тиз күнегә, укытучысы аны "безнең татарчоноктан әйбәт музыкант чыгачак" дип үсендереп тора.

Ленинград И. Әүхәдиевнең иҗади шәхес булып формалашуында (эстетик караш тәрбияләп кенә түгел, җитди сынаулар аша чыныктырып та) мөһим роль уйный. "Революция бишеге" яшь музыкант карашында бөек культура традицияләре ишекләрен ачу белән бергә, үзенең профессиональ эшчәнлегенең үсерү юлында зәһәр киртәләр үтәргә туры киләчәген дә искәртеп куя. 20 елларның икенче яртысында Ленинградта сәнгатькә "буржуаз идеология" белән көрәшүче Россия пролетар музыкантлары ассоциациясе" (РПМА) үзенең эшчәнлеген активлаштыра. 1928 елда А. Глазунов мәҗбүри рәвештә чит илгә китеп баргач, консерваториядә "вак буржуаз элементлардан" арыну башлана, менә И. Әүхәдиев тә эләгә. Шул

ук вакытта музыкаль җитәкче булып эшләгән Шәрекъ халыклары мәдәнияте йортыннан "сөрелә".

## Сугышка хәтле Казан чоры

Туган иленә әйләнеп кайту И. Әухәдиев тормышында тирән эз калдыра. Музыкант кайтып төшү белән республиканың музыка дөньясына кереп чума: дипломлы скрипкачыны ул чактагы милли музыкаль көчләр тупланган татар драматик театры оркестрына концертмейстер итеп билгелиләр. Театрның музыкаль җитәкчесе булып мәшһүр композитор С. Сәйдәшев эшли; мәгълүм булганча, аның илһамлы эшчәнлеге нәтиҗәсендә музыкаль драма һәм комедия жанры чәчәк ату чорын кичерә, симфоник сәнгать аякка баса, болар барысы бергә татар иҗтимагый тормышында музыкаль мохитнең яңарышына сизелерлек йогынты ясыйлар.

Оркестр составында А. Глазунов мәктәбен үткән музыкантның пәйда булуы аның профессиональ дәрәҗәсен тагын да үстереп җибәрә. И. Әухәдиев тиз арада оркестрны формалаштыру, оркестрантлар белән эшләү, нота партияләрен редакцияләү вазифасын үз өстенә алып, С. Сәйдәшевнең "уң кулы"на әверелә. Нәкъ менә шушы чорда театрда Т. Гыйззәтнең "Наемщик" һәм К. Тинчуринның "Кандыр буенда" пьесалары уйнала; мәгълүм булганча, бу әсәрләрдә С. Сәйдәшевнең илаһи музыкасы да яңгырый. Оркестр шулай ук татар музыкасы концертлары белән тамашачылар алдында да чыгышлар ясый; үзенең музыкаль хәзерлеге белән ул шәһәр рус симфоник оркестрлары дәрәҗәсенә тиңләшә. Бу елларда И. Әухәдиевнең концерт эшчәнлеге оркестрда эшләү белән генә чикләнми, ул А. Литвинов һәм С. Сәйдәшев җитәкчелегендәге шәһәр оркестрына кушылып, Ф. Мендельсонның атаклы концерты белән солист буларак та чыгышлар ясый.



*Ильяс Әухәдиев хатыны Галия Кайбицкая белән.*

Театрда эшләгән чорында язмышын ул әйдәп баручы актриса һәм шәп җырчы, гүзәл Галия Кайбицкая белән бәйләп җибәрә; җырчы аның тугрылыклы юлдашы булып китә һәм музыкантны алдынгы карашлы татар зыялылары даирәсенә алып керә. Бу гармониягә ирешкән, гаҗәеп пар була: фәрештә канатлары кагылып киткән диярсең, алардан якты нур бөркелеп тора. Бу гаҗәп тә түгел: билгеле ки, Галиянең атасы Мотыйгулла хәзрәт алдынгы карашлы дин әһелләре нәселеннән чыккан шәхес, Мотыйгулла Төхфәтуллин хәзрәт мәшһүр Габдулла Тукайның атасы Гариф хәзрәт белән дус була, Тукай үзе исә "Мотыйгия" мәдрәсәсендә Мотыйгулла хәзрәттән белем ала. Тукай белән яхшы ук таныш булган Сәйдәшев Кайбицкая-Төхфәтуллиннар нәселенә дә зур ихтирам белән карый. Яшьләр бергә тормыш корып җибәргәч, композитор үзенең иркен фатирыннан аларга урып "бүлеп бирә" һәм биредә татар мәдәниятенең "каймагы" җыела торган булып китә: спектакльләрдән буш кичләрдә Г. Кайбицкая җырлый, И. Әухәдиев скрипкада уйный, С. Сәйдәшев аларга фортепианода аккомпанементлык итә; аларны тыңларга еш кына күршеләре К. Тинчурин да кереп утыра.

Әлбәттә, тиктормас холыклы музыкант башкару эшчәнлеге белән генә чикләнми: 1931 елда ул Көнчыгыш сәнгать техникумында эшли башлый, бераздан бу уку йортының директоры, атаклы дирижер һәм скрипач А. Литвиновның тәкъдиме белән музыкаль бүлекне җитәкли. 1934 елда техникум аерым музыкаль училище булып үзгәртелеп корылгач, И. Әүхәдиев аның директоры итеп билгеләнә. 30 еллар башында РПМАның тискәре эшчәнлеге нәтиҗәсендә әлеге уку йорты авыр дәвер кичерә һәм яңа директорга училище эшчәнлегенең какшаган нигезләрен торгызу, барыннан да элек, уку-укыту процессын кирәгеннән артык идеологлаштыру һәм пролеткульт кантарларыннан арындыру буенча зур эшләр башкарырга туры килә. Бу вакытта музыкаль бүлек кайчандыр училищега караган бинаның флигелендә генә урнашкан була, бары тик И. Әүхәдиевнең музыкага бирелгәнлеге һәм үҗәтлеге нәтиҗәсендә генә элеккеге бинаны кайтарып алу мөмкинлеге туа.

Яңа директорның эшләү стиле күп яклары белән Глазунов традицияләрен хәтерләтә. Бөтен барлыгын училищега биреп, ул һәр укучыны үз канаты астына ала, аеруча мохтаҗлык кичерүчеләргә хәтта үз кесәсеннән акчалата да ярдәм күрсәтә. Директор үзе өчен белгечлек буенча имтиханнарда һәм концертларда катнашу гадәтен кертә. Үзенең эш бүлмәсендәге өстәл каршына ул юлбашчыларның портретларын түгел, ә бәлки революциягә кадәр концертлар белән Казанга килгәч училищега үзе бүләк иткән А. Ауэрның сурәтен элеп куя. Үзара ихтирам итешүгә корылган әхлакый һәм эстетик атмосфера урнаштыру ана менә дигән педагогик коллектив тупларга мөмкинлек бирә.

Училищены үзгәртеп коруны И. Әүхәдиев РПМАчылар тарафыннан юк ителгән оркестр, вокаль, фортепиано бүлекләрен берләштерүче гомуми белем бирү һәм башкаручанлык бүлекләрен кабат торгызудан башлап җибәрә. Педагогик коллективның нигезен мәшһүр остазларда белем алган дипломлы музыкантлар тәшкил итә. Аерым алганда, җыр-вокаль бүлеген танылган җырчы, мәмләкәтнең әйдәп баручы театрларында солист булып эшләгән (ул Шаляпин белән дә бергә чыгышлар ясый) Е. Г. Ковелькова җитәкли; ул бик күп танылган җырчылар хәзерли, алар арасында профессор З. Хисмәтуллина да бар. Тынлы музыка уен кораллары бүлеге мөдире булып Мәскәү консерваториясе профессоры В. Н. Цыбинның иң талантлы шәкертләреннән берсе Л.М. Шлеймович эшли; шул рәвешле Казан флейта мәктәбе барлыкка килә, бирелә халыкара конкурслар лауреаты Н. Зайдель тәрбияләнә. Кыллы уен кораллары бүлегенә тәҗрибәле педагоглардан Д. Е. Френкин, Р. Н. Поляков (укучылары—И. Халиков, А. Монасыйпов, И. Хәйретдинов) һәм әле генә Ленинград консерваториясен тәмамлаган виолончелист В. П. Варшавский (укучылары—профессор А. Хәйретдинов, СССР ның Зур театры артисты Г. Шапошников) җәлеп ителә.



*Галия Кайбицкая белән "өй концерты" бирү вакытында (1932)*

И. Әүхәдиев үзе оркестр классында скрипкадан дәресләр бирә.

Шул рәвешле, әйткәнебезчә, элгәре А. Литвинов традицияләрен яңартып һәм ул калдырган симфоник әсәрләрнең бай китапханәсеннән файдаланып И. Әүхәдиев

озак та үтми яхшы хәзерлекле коллектив туплауга ирешә; симфоник оркестр оешу исә училищега талантлы яшьләрне тартырга мөмкинлек бирә. Нәкъ менә И. Әүхәдиевнең тырышлыгы нәтиҗәсендә училищеның күп кенә укучылары танылган музыкантлар булып китәләр. Әйтик, училищега гармунчы булып килеп кергән А. Хәйретдинов аның тәкъдиме белән үз язмышын виолончель белән бәйли, профессор дәрәҗәсенә ирешә. Директор шулай ук Мәскәү филармониясе солисты, халыкара конкурс лауреаты дәрәҗәсен алган Н. Неклюдовка киләчәк юлын дөрес сайларга ярдәм итә. Бу танылган музыкант И. Әүхәдиевкә юллаган бер хатында *(1964, 15 ноябрь)* менә нәрсәләр яза: "Мин Сез җитәкләгән училищеда укыган елларымны бик теләп һәм зур канәгатьләнү хисләре белән искә алам. Нәрсә сөйләп торырга! Мин бит Сезнең сизгерлегегез нәтиҗәсендә генә фаготист булып киттем. Мин 1937 елда Сез җитәкчелек иткән кабул итү комиссиясен бик яхшы хәтерлим, ул чакта мин флейта классына укырга керергә теләк белдергән идем. Сез минем янга килеп бастыгыз да, баштан-аяк күздән кичергәннән соң, кулбармакларымны күрсәтүемне үтендегез һәм фаготта уйнарга өйрәнергә тәкъдим ясадыгыз... Мин риза булдым һәм менә аның нәтиҗәсе!"



*Ильяс Әүхәдиев гаиләсе белән. Сулдан уңга: әтисе Ваккас, әнисе Лотфикамал, хатыны Галия Кайбицкая һәм Ильяс Әүхәдиев (1932).*

Училищеда җитди теоретик-композиторлык группасы оештыру И. Әүхәдиевнең мөһим башлангычы була; аны Казан композиторлык мәктәбе үсешенә үзеннән лаеклы өлеш керткән, Ленинград консерваториясен тәмамлаган Ю. В. Виноградов җитәкли. Х. Вәлиуллин, Ә. Бакиров, Х. Әбделмәнов, И. Шәмсетдинов аның беренче укучыларыннан булалар.

Яна бүлек ачылу композиторлык иҗатына башка бүлек студентлары арасында да зур кызыксыну уята. Мәсәлән, виолончель классында белем алучы А. Монасыйпов беренче иҗади тәҗрибәләрен училищеда укыган елларында ясап карый. Фортепиано классы укучысы С. Гобәйдуллина да шундый ук юл үтә. Яна заман музыкаль сәнгатенең реформаторы буларак дөньякүләм казаныш яулаган бу мәшһүр музыкантның өйрәнчеклек еллары нәкъ менә Казанда үтү бер дә очраклы хәл түгел. И. Әүхәдиев аны училищеда укыганнан тыш та яхшы белә, дөресрәге, анын кызы Рушания София белән музыкаль мәктәптә бергә белем алган була, Әүхәдиев исә үзе дә шул мәктәптә укыта. Ул еш кына аларның дәресләрендә була, бергәләп пионер лагерьларына озата, булачак композиторның иҗаты белән һәрдаим кызыксынып тора. Кыскасы, директор буларак, И. Әүхәдиев С. Гобәйдуллинаның иҗади шәхесе формалашуга зур йогынты ясый. Бу иҗади теләктәшлек, бер яктан, ике музыкантның да кызыксыну өлкәсе туры килү белән дә анлатыла.

Ильяс Ваккас улы шулай ук С. Сәйдәшев иҗатын туктаусыз пропагандалый, аның әсәрләрен радио аша да, концертларда да башкара, училищенын уку программасына да кертә. Анлашылса кирәк, булачак дөнья музыкасы корифееның укытучысы булып нәкъ менә С. Сәйдәшевнең китүе бер дә гаҗәп түгел. С. Годәйдуллина соныннан хәтерләп үткәнчә, С. Сәйдәшев беркайчан да училищеда дәресләр бирми, ләкин ул үзенең кабатланмас иҗаты белән (София аны яттан белә) ана композиция өлкәсендә юл ярырга ярдәм

итә (мона инану өчен С. Сәйдәшев музеендагы Истәлекләр кенәгәсенә күз төшерү дә житә). Икенче яктан, директор буларак, ул үзенең эшчәнлегендә кешеләрнең индивидуаль "Мин"ен югалтуга китергән шөкатьсез бер соры массага әйләндерүгә каршы көрәшә, һәр укучыны үз тавышы һәм омтылышлары булган шәхес итеп тәрбияләргә омтыла. Бу нәүбәттән, директорга партия һәм НКВД органнары тарафыннан алып барылган кысуларга каршы кыюларча көрәшергә туры килә һәм укучыларын XX гасырның бөек реформаторлары ижаты белән таныштырып килгән укытучылар аның тарафыннан яклау таба. Ул атеизм гөрләп чәчәк аткан бер чорда чиркәү хорларында жырлап йөрүче яки джаз белән мавыгучы укучыларны эзәрлекләү белән шөгыльләнми—югыйсә, И. Әүхәдиев джазны өнәп бетерми һәм аны пропагандаламый, "саксофоннан финкага кадәр нибары бер адым" дип исәпли. Үзенең "Советская Татария" газетасында В. Фраучинның "Джаз-вопли" дигән политик мәкаләсенә каршы язылган бер язмасында *(1963, 8 июнь)* ул болай дип яза: "Безнең көнкүрештән джазны куарга кирәк түгел. Ләкин, мина калса, эстрада музыкасы сәнгать икән, ана иң югары таләпләрне куярга кирәк". 30 елларда принципиаль карашлары өчен ана күп "кыенлыклар ашарга" туры килә: аны еш кына куркынычсызлык органнарына чакыралар, хәтта кайчак үзе житәкләгән коллектив әгъзаларына "донос чәпәп" кую максатыннан кыйнап та ташлыйлар. Әмма эш шуннан ары узмый. Чөнки И. Әүхәдиев берни белән дә пычранмаган репутациягә ия була—1935 елдан депутат булып сайланып килә, житәкче даирәләрдә дә, татар зыялылары арасында да хөрмәт казана.

И. Әүхәдиевнең 30 елларда училище директоры булып эшләгән хезмәтләре хөкүмәт тарафыннан югары бәяләнә, 1939 елда ана ТАССР ның атказанган сәнгать хезмәткәре дигән мактаулы исем бирелә, 1940 елда "Хезмәт даны" медале белән бүләкләнә. Ул житәкләгән уку йорты мәмләкәтнең музыка уку йортлары арасында мактаулы урын яулый; шул рәвешле Казанда консерватория ачылуга зәмин салына. И. Әүхәдиев бу идеяне гамәлгә ашырырга башлап йөрүчеләрдән була: ул төрле инстанцияләргә, шул исәптән яңа гына оешкан композиторлар союзына да хатлар белән мөрәжәгать итә. Әмма 1941 елда башланган Ватан сугышы И. Әүхәдиевнең планнарына да төзәтмәләр кертә.

## Үзгәртеп коруларның тантаналы аккорды

1941 елда Мәскәүдә татар сәнгате декадасы үткәреләчәк унайдан И. Әүхәдиевне, Казан музыка училищесында уңышлы эшләвен исәпкә алып, опера һәм балет театрының директоры һәм баш директоры итеп күчерәләр. Күрәсең, бу очракта аның театрны ачу кирәклеге турында башлап йөрүләрнең берсе булуын да исәпкә алганнардыр; бу хакта ул 1935 елда ук "Красная Татария" газетасында язып чыга. Театр 1939 елда ачыла һәм менә хәзер, нибары бер елдан артык вакыт үтү эчендә ул бик тә зәгыйфь организмны хәтерләтә, ягъни опера һәм балет труппаларын һәм оркестрны тернәкләндереп жибәрү сорала. Димәк, яңа директорга башкалада үтәчәк үтә дә жаваплы чыгышларга житди хәзерлек эшләре алып барырга кирәк булачак. Оркестрны оештыру вакытында И. Әүхәдиев концертмейстер итеп үзенең күптәнге танышы булган К. А. Байбуровны чакыра, бер үк вакытта ул 1 нче номерлы балалар-музыка мәктәбе һәм училище педагогы да булып хезмәт итә. Байбуров белән берлектә Мәскәүдән күп кенә оркестрантлар да килә һәм бу оркестрны терелтеп жибәрергә, яхшы башкару үзенчәлегенә ирешергә мөмкинлек бирә. Шул елларның театр артистлары һәм тәжрибәле тыңлаучылар спектакльләрнең музыкаль яктан югары дәрәжәдә бизәлүен, К. Байбуровның скрипкада аеруча оста уйнавын билгеләп үтәләр.

И. Әүхәдиевкә шулай ук кыска вакыт эчендә балет һәм опера труппаларын туплярга, талантлы куючыларны табарга туры килә, шулай итеп яңа спектакльләр кую өстендә эшләргә мөмкинлек туа. Декадага, мәсәлән, Н. Жиһановның

"Алтынчәч" операсы *(дирижеры Ж. Садриҗиһанов)*, Ф. Яруллинның "Шүрәле" балеты һәм Ж. Фәйзинең "Башмагым" музыкаль комедиясе *(дирижеры И. Әүхәдиев)* хәзерләнә. Әлеге барлык спектакль дә татар культурасында, чын мәгънәсендә, эпохаль күренеш буларак билгеләп үтелә: алар милли сәхнә сәнгатенең алтын фондын тәшкил итәләр һәм менә ярты гасырдан артык инде театр репертуарыннан төшмиләр. Опера театрында 1941 елдан алып 1948 елга кадәр эшләү дәверендә И. Әүхәдиев бик күп спектакльләргә дирижерлык итә, алар арасында "Евгений Онегин", "Царская невеста", "Риголетто", "Травиата" кебек дөнья классикасы әсәрләре дә бар. Тагын иң мөһиме шунда ки, ул театрга татар тамашачысын тартуга ирешә.

1948 елда И. Әүхәдиевне директор сыйфатында кабат туган нигезенә—музыка училищесына күчерәләр. Моңа кадәр ул шактый гына тетрәнүләр кичерә: 40 еллар уртасында ул театрның директоры һәм дирижеры вазифаларыннан азат ителә һәм гади дирижер гына булып кала, 1945 елда ачылган консерваториядә дә аңа урын табылмый... Шушы шартларда да ул югары сәнгатькә хезмәт итү идеалларына хыянәт итми, бөтен җаны-тәне белән яшь музыкантлар хәзерләү эшенә керешә һәм... авторитаризм галәмәтләрен җиңүгә ирешә.

50 елларда И. Әүхәдиев училище коллективын Мәскәү, Ленинград, Казан консерваторияләрен тәмамлаган талантлы яшьләр белән тулыландыра һәм музыка сәнгатенә милли кадрлар хәзерләүгә аеруча игътибар бирә. Бу нәүбәттән, ул Казанга авылдан килеп төшкән, беркемгә дә билгесез булган Илһам Шакиров язмышын уңай хәл итүдә зур роль уйный. Күз алдына китерегез: консультация бирүләрен үтенеп мөрәҗәгать иткән консерваториядә аның талантын "күрми" үтәләр. Кабул итү имтиханнары үтүне сылтау итеп, аны кабул итмиләр һәм үзешчән сәнгатькә әйләнеп кайтырга тәкъдим ясыйлар. Бәхетле очрак белән диимме, җырчы училищега, И. Әүхәдиев янына керә һәм ул тыйнак кына авыл егетендә олуг талант күреп ала: ахырдан "өстәмә набор" игълан итеп, аны училищега кабул итәргә мөмкинлек таба, шул рәвешле уникаль талантны саклап кала.

Икенче бер олуг җырчы—Әлфия Авзалова белән хәл башкачарак килеп чыга: уку йорты дирекциясе белән килешмичә генә аны җыр һәм бию ансамбленнән училищега укырга җибәрәләр. Җырчы бер ел укыганнан соң кинәт кенә тавышын югалта башлый. Шулчак И. Әүхәдиев җырчыны үзенә чакырып ала да, ул менә дигән җырчы һәм актриса була алачак, ләкин моның өчен аңа академия сукмагын ташлап, эстрада студиясенә укырга керергә кирәк, ди. Шушы киңәшне тотып, Ә. Авзалова татар сәнгатендә үз юлын таба һәм чын мәгънәсендә татар эстрадасының сүнмәс йолдызына әверелә.

И. Әүхәдиев училищега әйләнеп кайтканнан соң, теоретик-композиторлык группасы тагын да ныгый, талантлы укучылар белән тулылана һәм тора-бара мөстәкыйль бүлеккә әверелә. И. Әүхәдиев бер вакыт композиторлык белән шөгыльләнеп ала, җырлар, инструменталь пьесалар иҗат итә һәм иҗади сәләте булган яшьләргә һәръяклап ярдәм күрсәтергә омтыла. Башкаручы булып китәргәме яки композиторлык юлын сайларгамы дип ике юл чатында аптырап торган Б. Мулюков, Р. Еникеев һәм Р. Белялов аның турыдан-туры киңәше белән сәнгатьтә үз урыннарын табалар. Ул шулай ук композитор М. Яруллин язмышында да зур роль уйный. Яшь музыкант училищега килгәндә инде имтиханнар тәмамланган була һәм директор, бу династиянең нәселдән килгән сәләтен исәпкә алып, өстәмә имтихан оештыра. Композитор булып китүе белән Ф. Әхмәтов та шулай ук И. Әүхәдиевкә бурычлы: башлангыч музыкаль белеме дә булмаган егетне директорның катнашы белән башта башкару бүлегенә кабул итәләр; соңыннан, аягы гарип булуын исәпкә алып, композиторлык бүлегенә күчерәләр. Нәтиҗәдә, 50 елларда училищеда өметле яшь композиторлар плеядасы формалаша, нәкъ менә алар татар музыкасын, заманча яңа чаралар ярдәмендә язу хисабына, яңа биеклекләргә күтәрәләр, аны яңа бизәкләр белән баеталар.

Шунысы әһәмиятле, авторитаризм чәчәк аткан бер чорда, И. Әүхәдиев тарафыннан фикердә хөрлек һәм эш-хәрәкәттә хакыйкатьлек орлыклары салына.

Дөрес, мона ул махсус бераүне дә тартмый, әмма шәхси үрнәк күрсәтеп ул училищеда дөреслек һәм бәйсезлек атмосферасы урнаштыра. Соңгысы студент кичәләрендә, аларның аерылгысыз өлеше булган "капустникларда" ачык чагылыш таба, шуңа күрә дә аңа бөтен Казан яшьләре әләгергә омтыла.

Ильяс Ваккас улының кешелеклелеген, эчке рухи тәртиплелеген раслаучы бик күп мисаллар китерергә мөмкин. Мөгаен, бу нәүбәттән, укучы Рәүф Аббасов белән булган очрак аерым әһәмияткә ия. Ул—танылган татар җырчылары Азат Аббасов һәм Венера Шәриповалар гаиләсеннән чыккан егет—галәмәт зур вокаль сәләткә ия була, ләкин училищега укырга кергәч тә малайлыгыннан аерыла алмыйча интегә. Педагоглар аны үсендермиләр, киресенчә, акылга утыртырга теләп, аңа карата кирәгеннән артык кырыслык күрсәтәләр. Нәтиҗәдә, бер сессиянең нәтиҗәләре буенча ул "аттестацияләнми" һәм педсовет утырышында барлык коллектив Аббасовны куып чыгару турында сүз алып бара. Бөтен түземлелеген югалткан директор да коллективка каршы килмәскә ниятли. Шулай итеп, мәсьәлә тулаем хәл ителгән кебек тоела. Шулчак И. Әүхәдиев гомерендә беренче мәртәбә унбиш яшьлек үсмернең бас белән җырлавын ишетүне дәлил итеп, шикләнү-икеләнүләрен белдерә. Аның чыгышыннан, әйтерсең лә, бөтенесе дә айнып киткәндәй була һәм, бәхеткә каршы, яшь җырчының язмышы унай якка хәл ителә. Озак та үтми Р. Аббасов Мәскәү консерваториясенә укырга керә һәм халыкара конкурс лауреаты була.

Сугыштан соңгы елларда И. Әүхәдиев училищеда симфоник оркестр оештыру белән мәшгуль була, филармония каршында да оркестр булдыру турында хыяллана. Шушы максаттан чыгып ул 1949 елда Ленинград консерваториясендә экстрен рәвештә имтихан тапшыра һәм симфоник оркестр дирижеры дигән диплом ала. Шушыннан соң И. Әүхәдиев оештыру эшчәнлеген тагын да кинрәк җәелдереп җибәрә һәм хөкүмәт карары белән расланган профессиональ коллектив туплауга ирешә. Баш дирижер һәм сәнгать җитәкчесе итеп И. Әүхәдиев, икенче дирижер итеп Ленинградта укыган елларында ук дуслашып өлгергән, менә дигән музыкант И. Шерман билгеләнә.

Филармония оркестры 1951 елда беренче эре монографик концертларын бирә. И. Әүхәдиев Бетховен әсәрләре программасына дирижерлык итә, болар—"Эмонт", "Прометей", "Кориолан" увертюралары, шулай ук бөек немец симфонистының иң яхшы әсәрләреннән берсе 4 нче номерлы фортепиано концерты *(солист Лукомский).* И. Шерман җитәкчелегендә рус классикасы әсәрләре, аерым алганда, П. Чайковскийның Бишенче һәм Алтынчы симфонияләре башкарыла. Ике дирижер да чиратлашып Татарстан композиторларыннан С. Сәйдәшев, М. Мозаффаров, Н. Җиһанов, Р. Яхин, А. Леман әсәрләрен яңгыраталар. Аннары атна саен чит ил, рус, совет музыкасы концертлары булып тора: оркестрга кушылып менә дигән солистлар—скрипач Ю. Ситковецкий, пианистлар А. Гинзбург, Р. Яхин һ. б. уйныйлар.

Кызганычка каршы, 50 еллар уртасында оркестрның чыгышлары кими төшә. Финанслау белән кыенлыклар килеп туа, талантлы музыкантлар опера һәм балет театрына, консерваториягә китү сәбәпле квалификациясе музыкантларга кытлык туа башлый. Ләкин шулай да оркестрның сүнә баруына Казанда махсус концерт залы булмау төп сәбәпче була, оркестр сыярлык бердәнбер сәхнә опера театрында була. Бу коллективның эшен чиксез катлауландыра һәм оркестр аерым-аерым гына концертлар бирергә мәҗбүр була. Шундый концертларның берсенә гастролер сыйфатында танылган дирижер Натан Рахлин да чакырылган була. Ул концертны бик югары сыйфатта үткәрә һәм оркестр дәүләт статусы алгач, аның җитәкчесе итеп чакырыла. Шушы ук вакытта консерваториянең Зур концертлар залы да ачыла *(1967)* һәм шул рәвешле оркестрның язмышы унай якка хәл ителә.

Бу очракта да, консерватория ачылгандагы кебек үк, башлап йөрүчегә оркестрда урын табылмый. И. Әүхәдиевнең "кендеге" училищега береккән булгандыр, күрәсең, 50-60 елларда аның җилкәсенә республика балалар музыка мәктәпләре өчен кадрлар хәзерләү бурычы йөкләнә: бу икеләтә әһәмияткә ия, чөнки бу вакытта

республика Россиянең эре нефть һәм индустриаль төбәгенә әверелгән була. Директорның һәм ул житәкләгән коллективның актив эшчәнлеге нәтиҗәсендә шушы вакыт эчендә Татарстанда 36 яңа мәктәп *(шуның 5 се Казанда)* ачыла, аларда, нигездә, училищены тәмамлаган музыкантлар укыта. Шул рәвешле Әлмәт, Түбән Кама, Чаллы шәһәрләрен дә кертеп, сәнәгать һәм авыл районнарында музыкаль мәктәпләр челтәре барлыкка килә; бу үз чиратында халыкка музыкаль тәрбия бирү мөмкинлекләрен арттыра, Россиянең иң алдынгы музыкаль югары уку йортларыннан саналган Казан консерваториясенең базасын ныгыта.

Шушы ук елларда И. Әүхәдиев, элекке кебек үк, училищеның симфоник оркестрын яшәтүгә күп көч сарыф итә. Бу яшьләр коллективы—"аякка жинел", профессиональ коллектив була; ул атна саен Казанда—университет, авиация, медицина, авыл хужалыгы һәм финанс-икътисад институтлары студентлары каршында чыгышлар ясый; мәдәният сарайларында, хәрби частьларда, заводларда концертлар бирә, авыл районнарына барып чыга. Шулай итеп, ул татар халкын дөнья симфоник җәүһәрләре белән таныштырып, бик игелекле агарту эше алып бара.

Репертуар тыңлаучыларны үзенең байлыгы белән таң калдыра, ул үз эченә мәшһүр рус һәм чит ил симфонистларының әсәрләрен, шулай ук татар композиторларының иң яхшы язмаларын берләштерә. Оркестр Гендельнең "Пассакалья", Моцартның популяр "Төнге серенада" һәм атаклы Кырыгынчы симфониясен, Бетховен әсәрләрен, шул исәптән "Героик" симфониясен, "Эгмонт", "Прометей" увертюраларын, Чайковскийның кыллы серенадасын һәм симфонияләрен, Глинканың "Руслан һәм Людмила" операсына увертюрасын, Шубертның Тәмамланмаган симфониясен, Григның "Пер Гюнт" сюитасын, Калинниковның симфониясен һ. б. бигрәк тә еш башкара.

Оркестр репертуарын шулай ук бик күп аккомпанементлар тәшкил итә. Болар—Моцарт, Бетховен, Лист, Шопен, Чайковскийның фортепиано концертлары; Бах, Моцарт, Чайковский, Мендельсонның скрипка концертлары; Чайковский, Шуманның виолончель өчен язылган әсәрләре.



*Төбәкара симфоник оркестры нефть районнарының берсендә чыгыш ясый (XX гасырның 60 еллары).*

И. Әүхәдиев үзе дә солистларга кушылып уйнарга ярата иде һәм моны да зур такт, осталык белән башкарды. Училище оркестрына Д. Ойстрах, В. Пикайзен, Н. Школьникова, И. Бочкова, М. Яшвили кебек мәшһүр совет артистларының һәм әйдәп баручы Казан музыкантларының кушылып уйнаулары бер дә юкка түгел. Милли музыкадан И. Әүхәдиев "Сүнгән йолдызлар" драмасына увертюраны, С. Сәйдәшевнең "Наемщик" драмасына сюитаны, Н. Жиһановның халык темасына сюитасын, М. Мозаффаровның увертюраларын һәм скрипка концертын, Р. Яхинның фортепиано концертын яратып башкара. Моннан тыш концерт программасына ул татар вокаль җәүһәрләрен, операдан арияләрне, романсларны бик теләп кертә.

Дирижер буларак, И. Әүхәдиев музыканың сәнгати-образлар өслүбенә нечкә үтеп кереп, анда эмоциональ башлангычны табарга омтыла иде. Шуңа күрә дә ул

нинди генә әсәргә алынмасын, музыка якты буяулар белән өртелгән булыр иде. Һәм тыңлаучылар моны сизеп алып, оркестрның чыгышын чын күңелдән бирелеп һәм аңлап тыңлыйлар иде. Аерым алганда, танылган музыка белгече Я. М. Гиршман "Оркестр концерты" *(Советская Татария)* дигән мәкаләсендә бу күренешне бик оста тотып алган: "ТАССР нын халык артисты И. Әухәдиев җитәкчелегендәге Казан музыка училищесының симфоник оркестры концертлары концерт сезонының аерылгысыз өлешенә әверелде. Бу үсмерләр коллективының чыгышлары программасының күпкырлы булуы белән аерылып тора һәм үзешчән музыканы сөючеләр арасында зур популярлык казанды. Бу нәүбәттән университетның Актлар залында булып узган концерт аеруча игътибарга лаек һәм кызыклы булды. Листның оркестр белән фортепиано өчен концерты һәм Чайковскийның Итальян каприччиосы башкаручылардан иҗади өлгергәнлек һәм югары виртуоз осталык таләп итә.

Концерт бик шәп үтте. Залда күтәренкелек атмосферасы хөкем сөрде. Башкаручылардан өртелгән илһам, иҗади күтәренкелек тыңлаучыларга барыш ирешә, Лист һәм Чайковскийның сихри аһәңгә, эмоциональ киеренкелеккә ия, якты буяулы музыкасы зур дулкынлану һәм тирән кичерешләр белән кабул ителде".

Укучыларның оркестры белән эшләү дирижердан гаҗәеп фидакарьлек, тырышлык һәм түземлелек таләп итә. Чөнки 14-20 яшьлек яшь музыкантлар оркестрда уйнауны олыларча кабул итә алмыйлар; аларның туктаусыз шаяртулары, эмоциональ тотрыксызлыгы теләсә кемне чыгырыннан чыгарырга мөмкин. Ләкин И. Әухәдиев аларның барлык шуклыкларын да үткәреп җибәрә белә иде. Мондый вакытларда ул урындыктан торып баса да, көч җыйган кебек башын күтәрә төшеп, карашы белән оркестр өстеннән йөгереп үтә дә бер генә сүз кычкыра: "Прекратить!" Һәм шулчак бөтенесе дә тынып кала һәм репетиция тагын дәвам итә. Иң соңгы чиккә җиткән очракларда дирижер тәмам шашкан укучыларны репетициядән куып чыгара да тәнәфес игълан итә һәм "укучылар оркестры белән эшләгәнче, Дуровлар почмагында җәнлекләрне өйрәтү җиңелрәк",—дия-дия үзе дә ишеккә юнәлә.

И. Әухәдиев башка төр тәрбия чаралары да куллана, аерым алганда ул укучыларның филармония оркестрында уйнавы турында даими килешүләр төзи, радиода яздыра; бу, үз чиратында, аларның гамәли эшчәнлеге офыкларын киңәйтеп җибәрә. Нәтиҗәдә, И. Әухәдиевнең оркестр мәктәбен үткән күп кенә музыкантлар мәмләкәтнең әйдән баручы коллективларында эшли башлыйлар һәм танылган концертмейстерлар булып китәләр. Алар арасында Г. Эскин *(Австрия, "Моцартеум" оркестры)*, Е. Пустовалов *(Мәскәү, кинематография оркестры)*, Ж. Армоник *(Мәскәү, оперетта театры)*, Г. Крушельницкий *(Казан, дәүләт оркестры)* кебек танылган музыкантлар бар.

Кыскасы, И. Әухәдиевнең Татарстанның музыкаль культурасын үстерүгә керткән өлешен бәһаләп бетерү мөмкин түгел. Һәм язмыш аның шушы титаник хезмәте өчен уны белән кайтарып түли. Республиканың берничә буын музыкантлары бу Олуг затның якты истәлеген йөрәкләрендә саклап килаләр һәм аның бәрәкәтле традицияләрен уңышлы дәвам итәләр. Татар мәдәниятенең аксакаллары Б. Урманче, Г. Бәширов, Ә. Еники, Р. Яхин, Р. Еникеевның тырышлыгы белән Казан музыка училищесына, олы музыкант, талантлы педагог һәм арымас җәмәгать эшлеклесе И. Әухәдиев исеме бирелгән икән, бу бер дә гаҗәп түгел.

*

# ӘМИРХАН АГА ЯДКАРЕ

Әмирхан ага озын гомер юлы кичерде. Егерменче гасырның 90 елдан күбрәге аның иңнәрендә. Ул әдәбиятыбызның гүзәл үрнәкләрен калдырып китте. Күпме генә тарих зилзиләләрен кичерергә, кемнәр белән генә очрашырга, нинди генә тантаналарда катнашырга туры килмәгәндер аңа! 90 еллык юбилеена хәзерлек унаеннан, журналист буларак, мина да аның белән еш очрашырга, ул яшәгән Чехов урамындагы 53 йорт фатирында берничә тапкыр булырга, хәләл җефете Нәҗия ханым әзерләгән чәй өстәле янында ашыкмый гына, озын-озаклап сөйләшеп утырулар бәхете туры килде. Олуг әдип белән булган очрашуларны, аның турындагы якты истәлекләрне онытырга мөмкинмени?! Шуларны бәйнә-бәйнә көндәлек дәфтәремә язып барганмын. Хәзер шуларны укучыга тәкъдим итәм.

**21 декабрь, 98.**

Яңа елга санаулы көннәр калган. Шул уңайдан күренекле шәхесләребезгә, төрле һөнәр ияләренә анкета сораулары белән мөрәҗәгать итәргә булдык. Алар арасында әдәбиятыбыз аксакалы Әмирхан ага Еники дә бар. Иртән аңа шылтыратып йомышымны әйттем.

—Ярый, килегез, мин өйдә генә,—диде.

Сәгать ярымлап сөйләшеп утырдык. Сүзебез күбрәк төрки дөньяга кагылышлы хәлләр турында барды. (Чөнки мин ул елларда төрекләр Казанда нәшер иткән "Заман—Татарстан" газетасы хезмәткәре буларак килгән идем). Ул бу дөньяны, андагы вәзгыятьне яхшы белә. Истанбулда ике тапкыр булган. Сүз күбрәк әдәбият, сәнгать мәсьәләләренә кагылышлы иде.

—Безнең татар әдәбияты-сәнгате, төрекләрнеке белән чагыштырганда, бик югары, бик алга киткән,—диде ул. —Тик безнең зур кимчелегебез—мөстәкыйль дәүләтебез юк. Алар исә аерым дәүләт булып яши. Шуңа күрә алар аяк терәп сөйләшәләр. Менә күз алдында бит: алар Казанда "Заман" газетасын татар телендә чыгарып яталар, республикабыз шәһәрләрендә күпме татар-төрек лицейлары, төрек ширкәтләре эшли. Ә без, шулкадәр мәдәни, алга киткән халык булып, боларны Төркиядә эшли алабызмы? Юк, чөнки безнең куллар богаулы, аерым дәүләтчелегебез юк. Без үзебезнең кулдан килгәнне дә эшли алмыйбыз...

Ул көнне мин Әмирхан агага анкета сорауларын калдырып, җаваплар әзер булгач, редакциягә шылтыратуын үтенеп, саубуллашып киттем.

**23 декабрь, 98.**

Иртән Әмирхан ага редакциягә үзе шылтыратты.

—Наил энем,—ди йомшак матур тавыш белән акрын гына эндәшеп.

—Тыңлыйм, Әмирхан ага,—дим.

—Менә мин монда анкетаны тутырдым. Үзем кирәк дип тапкан сорауларга җавапларны яздым, кайчан килеп аласыз?—ди.

**25 декабрь, 98.**

Иртән туры Әмирхан ага фатирына киттем. Ишекне хатыны Нәҗия ханым ачты. Татар хатын-кызларына гына хас тыйнаклык, зыялылык, чибәрлек. Әмирхан агадан яшьрәк күренә. Әмирхан ага үз бүлмәсендә язу өстәле янында утыра иде. Өстәлендә ап-ак мәчесе сырпаланып йөри.

Әмирхан ага белән тагын иркенләп сөйләштек. Бу юлы ул үзенең төрекләргә булган мөнәсәбәтен яшермәде.

—Мин турысын сөйләргә яратам, эчемдәгене яшермим, дөресен әйтәм, мин туры кеше,—диде ул. —Төрекләрне яратып бетермим мин. Һәм үз сүзләрен болай дип дәлилләде.

—Ике тапкыр Истанбулда булдым, хатыным белән. Шул вакытта ике ел элек Ринат Мөхәммәдиев (ул чагында Татарстан Язучылар берлеге рәисе) тәкъдиме белән берничә әсәремне төрек теленә тәрҗемә итеп бастыру өчен төрки дөньяны өйрәнү вакыфы мөдире Туран Язганга калдырган идем. Менә, белмим, бернинди хәбәр юк... Монда төрекләр генә түгел, үзебезнең Язучылар союзы да гаепле,—ди.

Мин дә Әмирхан агага үз фикеремне, кинәшемне әйтми булдыра алмадым.

—Әмирхан ага,—дим. —Төркиядә Әхмәт Мәнгәр вакыфы бар. Аның кызы Суфия Имре. Аның белән сөйләшәсе булган.

—Сина ничә яшь соң әле?—диде ул көтмәгәндә.

—Житмеш була инде,—дигән идем, көлеп жибәрде.

—Наил энем, беләсеңме, картлык өч төрле була ул: яшь картлык—70 яшькә кадәр, урта картлык—70-80, карт картлык—80нән соң...

Шул сүзләреннән аңлашылганча, Әмирхан ага: минем инде китапларымны төрек теленә тәржемә иттереп чыгару өчен аның артыннан йөрер вакытым узган дип әйтергә теләде, күрәсең. Шуннан соң ул мина "Заман"—Татарстан" газетасы өчен Яңа ел унае белән тутырылган анкетаны сузды.

—Менә, үзегез карарсыз инде... Үзем кирәк дип тапкан сорауларыгызга җавапларымны яздым,—диде ул.



*Әмирхан Еники хатыны Нажия ханым белән. 1999 ел.*

Әмирхан аганың анкетага кайбер җаваплары "Казан утлары" журналы укучылары өчен дә кызыклы булыр дип уйлыйм. Менә алар:

—Сезнең өчен 1998 ел ил күләмендә нинди вакыйгалар белән истә калды?

—1998 елны ил күләмендә булып узган бер генә унай вакыйганы да мин хәтерләмим. Әмма бик зур тискәресе булды. 17 августта Русия кинәт икенче тапкыр икътисади тирән кризиска кереп батты. Хәзер без шунын авыр газабын кичерәбез.

—Узган ел шәхси тормышыгызда нинди үзгәрешләр, вакыйгалар булды?

—Шәхсән минем үзем өчен истә калырлык куанычлы вакыйга—ул да булса ак пароходта Казаннан Уфага баруыбыз булды. Жәй уртасында өч тәүлек буена уфалы якын дуслар белән бергә гүзәл елгалар буйлап дәвам иткән бу хозур сәяхәт матур төш шикелле хәтердә озак сакланачак әле.

Минем шәхси тормышымда бернинди үзгәреш булмады диярлек. Тагын бер елга картайдым, бары шул гына. Ел ахырында гына ике бик якын туганымны югалттым. Югалтулар һаман булып тора. Телгә алырлык бер эшем—"Санаулы көннәр" дигән язмамны бетереп, "Мәдәни жомга" газетасында бастырдым.

—Куян елыннан нәрсә көтәсез?

—Куян елына исән-сау керсәм, март башында мина 90 яшь тулачак. Менә бәлки шатланырга кирәктер. Ләкин мине күбрәк шушы яшькә житүем гажәпсендерә. Бәйрәм итү теләге дә юк. Минем заманым узды инде.

—Сезнеңчә, якынлашып килүче XXI гасырда кешелек дөньясын нинди вакыйгалар көтә?

—Русиянең киләчәген юрау гаять читен. Тотрыксызлык, башбаштаклык, җавапсызлык хөкем сөрә биредә. Аның фажигале вакыйгалары гасыр башында ук

башланган иде, гасыр ахырында да әле дәвам итмәктә. Шуңа күрә туачак XXI гасырның да тиздән бетәчәк XX гасырга охшаш булуы бик мөмкин... Һәрхәлдә, Рәсәйнең аякка басып, чын демократик һәм цивилизацияле ил булуы өчен кимендә бер илле ел кирәк булыр. Әгәр бөтенләй таралып китмәсә? Дөньяны җимерүе бик ансат, әмма яңадан торгызуы ай-һай бик авыр.

**5 гыйнвар, 1999.**

Әмирхан ага үзе шылтыратты. Сөйләшүендә ниндидер бер борчылу, канәгатьсезлек сизелә иде. Шуннан әйттем:

—Әмирхан ага, "Шәһри Казан" сезне ун елга яшәртеп чыгарган, әле 80 генә тула дигән.

—Анысы яхшы булган икән,—дип кеткелдәп алды.—Тик менә "Ватаным Татарстан" да интервьюны укып кәефем китте әле...

—Нәрсә булган соң?—дим.

—Һәр елны Яңа елда Хәйдәр Бегичевлар төшә торганнар иде,—дип язганнар (Хәйдәр Бегичев гаиләсе шул ук йортта, тик Әмирхан ага фатирыннан югарырак катта яши иде). —Мондый хәлнең гомердә булганы юк. Бу йортка 1994 елда күчеп килдек, шуннан бирле Хәйдәр белән икәү генә очраштык бугай. Алдашу инде бу. Мин моны кеше абруена сыену дип аңладым. Гаҗәпләнәм шундый алдашуларга! Мондый алдашулар беренче тапкыр гына түгел инде, кеше фикерен бозып чыгару. Бервакыт шулай булды, бер әдәбият белгече (исемен әйтмим инде) минем исемнән язып чыкты. "Беренче чәчәкләр" драмасының авторы Галимҗан Ибраһимов дип. Ибраһимовның андый әсәре юк. Ул—Кәрим Тинчурин драмасы. Мин аны яхшы беләм. Драматург кешенең шулай язуы мине бик гаҗәпләндерде. Шулай итеп мин бик надан булып калдым. Гафу да үтенмиләр бит соңыннан! Инде мин ялгышкан тәкъдирдә дә ул үзе төзәтергә тиеш иде, әгәр мин шул чаклы надан булсам. Менә шундый хәлләрдән соң мин кара-каршы утырып сөйләшүдән тәүбә иттем. Мондый ямьсез бозулар күп була. Моннан соң үз кулым белән генә язып бирергә булдым. Гел шулай гына эшләячәкмен...

Аннары Әмирхан ага Төркиядә булуы турындагы язмаларын "Шәһри Казан" газетасында бастырып чыгаруы турында сөйләде.

Мәгълүм ки, Әмирхан ага белән очрашып сөйләшүләрем моның белән генә тәмамланмады. Анкета сорауларына җавабыннан аңлашылганча, алда тагын бик мөһим дата—олуг әдипнең 90 еллык юбилее тора иде. Әлбәттә, республика матбугаты, шул исәптән "Заман"—Татарстан" газетасы да бу вакыйгадан читтә кала алмады. Әмма бу датаны ничек, нинди рәвештә яктыртырга, ничек билгеләп үтәргә?

Янә редакция белән аның фатиры арасында юлны таптау, истә калырдай очрашулар, сөйләшүләр башланды.

**10 гыйнвар, 1999.**

—1995 елның ноябрь аенда "Татурос" чакыруы буенча Истанбулга барып, хатыным Нажия белән бергә бер атна торып кайттык,—дип Төркиягә баруларын сөйләп алды Әмирхан ага. —Яхшы кунак иттеләр. Биш йолдызлы отельгә урнаштырдылар. Иртән машина белән килеп алдылар. Бөтен Истанбулны күрсәттеләр. Кич кенә машинада китереп куйдылар. Гаяз Исхакый кабересендә дә булып, Коръән укыттым. Төркиядәге илчебез Рево Идиатуллин да зур кунак итте, машинада гына йөртте. Әмма көннәр бик начар, салкын, җилле, яңгырлы булды,—диде ул.

Әмирхан ага шул вакыйгаларны хәтереннән кичереп булса кирәк, азрак уйланып торды да, сүзен дәвам итте:

—Истанбулга икенче баруыбыз 1996 елның октябрь башларында булды. Монысы инде үз исәбебезгә иде. Шунда мин шәхси китапханәмдә саклана торган, төрле повесть, хикәяләрем басылган 3-4 китабымны калдырдым. Дөрес, алар төрекчәгә тәрҗемә ителмәгән иде. Истанбулда әсирлектән соң Төркиядә калган Мәхмүт Урал дигән кеше белән очраштым. Аңа китапларым турында сөйләдем. Ул: "Белмим, бастырмаслар алар",—дигән иде. Чыннан да, Төркиядә дәүләт нәшриятлары юк. Барысы да шәхси кулларда. Төрекләр китапка товар итеп карыйлар. Сатылудан файда килерлек булмаса, китапларны чыгарып азапланмыйлар. Менә шуннан бирле китаплар турында бернинди мәгълүмат юк. Хотя бы, китапларны кайтарсыннар иде.

Әмирхан ага китапларын юксына, үзендә калмаганнар, күрәсең. Аннан соң күрсенеп кенә: "Советка каршы булса, басарлар иде. Хәер, андый әсәрләремне дә биргән идем инде. "Кояш баер алдыннан" нәкъ шундый әсәр,—дип өстәп куйды.

Менә ул язу өстәле янында торып, шкафтан кара тышлы бер китап алып килде.

—Бу—Оренбурда чыккан "Вакыт" газетасының баш мөхәррире Фатих Кәрими китабы. Ул "Истанбул мәктүпләре" (хатлары) дип атала. Фатих Кәрими 1912 елның 1 ноябрендә "Вакыт" газетасының хәбәрчесе сыйфатында Төркиягә бара. Ул Одессада дүрт татар кызын очрата һәм аларны да үзе белән Истанбулга алып китә.

Кызлар төрек лазаретларында яралы гаскәриләрне дәваларга эшкә урнашалар. Болар турында галим Мәсгут Гайнетдин язып чыккан иде инде.

Китап шактый калын һәм күләмле күренә, анда шактый гына рәсемнәр, шул исәптән татар хатын-кызлары фотосурәтләре дә урын алган. Ул 1913 елда Оренбурда нәшер ителгән. Гомумән, хезмәт Төркия тормышына багышланган. Гарәп хәрефләре белән язылган. Кириллицага күчерелеп бер кайда да басылмаган икән. Аны төрекләр дә чыгармаган. Бу китапта алар өчен тарихи бай материал бар, югыйсә.

Шул уңайдан Әмирхан ага да елмаеп кына: "Төрекләр китап укырга яратмыйлар алар. Анда татар язучыларыннан Ринат Мөхәммәдиев белән Роберт Батулладан башканы белмиләр дә",—дип әйтеп куйды.

**2 февраль, 1999.**

Кичке бишләрдә янә Әмирхан ага янына, 90 еллык юбилее уңае белән ана бирелгән сорауларга җавапларны алырга бардым.

—Мин шәхсән юбилеемны үткәрү ягында түгел. Сәламәтлегем бик начар. Алай үткәрәселәре булса, хөкүмәт комиссиясе төзелергә, аның чаралары билгеләнергә, хөкүмәт күпмедер күләмдә чыгымнар тотарга тиештер инде... Ә мин хәзер хастаханәгә ятарга телим. Бик талчыктым, үземне начар хис итәм. Бу турыда союзга шылтыраттым, бер атна элек. Ренатның урынбасары Әхмәт Гадел белән сөйләштем, әлегә җавап юк,—диде Әмирхан ага.

Шушы сөйләшүдән соң көндәлегемә болай дип язып куйганмын:

—Әмирхан ага алай ялагайланып, түбәнсенеп йөрмәде. Ул бик горур, үз дәрәҗәсен белә торган зыялы иде, морзалар нәселеннән бит. Шулай горур булырга, соңгы сулышында да халкының яраткан язучысы, кеше булып калырга кирәк. Ә ул кайберәүләр кебек кызыл авыз булмады, гомер буе халкына хезмәт итеп, берсеннән-берсе гүзәл әсәрләр калдырды.

**19 февраль, 1999.**

Әмирхан аганың 90 еллыгы уңаеннан редакция тарафыннан куелган сорауларга җаваплары "Татулыкны гаделлек белән тигезлек кенә саклый" дигән баш астында махсус бер сәхифә булып "Заман"—Татарстан" газетасында басылып чыкты. Анда аның татар әдәбиятының киләчәге турында уйланулары, гаделлек һәм тигезлек төшенчәләренә мөнәсәбәте, XXI гасырга фаразлары бәян ителгән. Әлбәттә, бу әңгәмә атналык газетада гына югалып, онытылып калмасын, "Казан утлары" журналында янә басылып, татар әдәбияты фондында сакланса иде.

**5 март, 1999.**

Әмирхан аганың 90 еллыгын Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында бик зурлап үткәрделәр. Ул иң югары дәрәҗәдә, республикабыз җитәкчеләре катнашында узды. Юбилейлары узганнан соң Әмирхан ага янә редакциягә шылтыратты. Ул гел шулай, хәлләрне белешеп тора иде.

**26 апрель, 1999.**

Җомга көн. Газетада басылган интервьюсы өчен Әмирхан агага гонорар илтәсем бар. Ана шылтыратып, киләсемне әйттем. Озак кына, матур итеп сөйләшеп утырдык. Әңгәмә барышында кофе эчеп алырга тәкъдим итте. Ризалыгымны белдереп өстәл янына утырдым. Нәҗия ханым кечкенә чынаякларда кофе һәм үзе пешергән пирогларны чыгарды. Сөйләшү узган юбилей, язучылар, Кол Гали бүләкләрен бирү, аның Гомәр ага Бәширов белән соңгы очрашуы турында барды.

—Кол Гали бүләген генә алыйк әле. Бөтенесенә дә гадел биреләме ул? Әдәбиятка, мәдәнияткә, әдәби мирасыбызга һичбер өлеш кертмәгән кешеләргә дә бирәләр бит шул бүләкне,—дип уфтанды Әмирхан ага.

Сөйләшү темасын икенче юнәлешкә бору өчен сорап куйдым:

—Юбилейлардан соң бераз тынычлангансыздыр инде, Әмирхан ага, сәламәтлек яклары, санаторийга юлламалар ничек?—дим.

—Инде әйткәнемчә, һич тә юбилейлар уздырырга уйламаган идем. Министрлар кабинетыннан Илгиз Хәйруллин шылтыратты, сез бер дә борчылмагыз, тыныч үткәрәбез дигәч—ризалаштым. Президент Шәймиев бик җылы сүзләр әйтте. Болай булыр дип уйламаган идем. Моңа чаклы, 90 яшемә кадәр, югарыда мине белүче дә, кызыксынучы да булмады. Инде бер көндә мине Алланың кашка тәкәсе иттеләр дә куйдылар.

Юллама мәсьәләсендә, өйгә килеп, кул куйдырып киттеләр, курорт картасын тутырдылар. Менә путевка көтәм, телефонда беркемне дә тотып булмый. Моңа, "Казан" санаториенда гына дәваланырмын инде. Әлегә путевка юк дип әйтәләр,—ди.

Гомәр ага Бәширов турында сорагач:

—Гомәр абый үзе генә яши. Әле бер көнне барып, озак кына сөйләшеп утырдык. Икебезгә бер кызылны бушаттык,—диде.

Аннары җәй айларында үзен Уфага, Мәскәүгә чакыруларын әйтте.

—Анда барасы булыр инде,—диде, Туран Язганда калдырган китапларын янә искә алды.

Мине озата чыкканда ул кызык кына итеп: "Зур башта кечкенә акыл, кечкенә башта зур акыл" дип язып куйдым әле диде. Нәрсә әйтергә теләвен аңламадым.

Тарихи шәхес, әдәбиятыбыз аксакалы белән очрашуларның кайбер мизгелләре менә шулар. Әмирхан ага турындагы хатирәләремне йомгаклап, көндәлекләремдә болай дип язып куйганмын:

**18 февраль, 2000.**

Әмирхан ага белән хушлашу көне. Авыр, бик авыр югалту. Бу көнне Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры бинасына үтәрлек булмады. Залда күңелләргә моң салып акрын гына музыка агыла. Хушлашу өчен театрга язучының якыннары, меңнәрчә укучылары, каләмдәшләре, җәмәгать эшлеклеләре, республика җитәкчеләре килгән. Табут янында почетлы каравыл алышынып тора. Иң соңыннан каравылга республика җитәкчеләре басты. Мәрхүм белән хушлашканда олы әдипне юксынып, тирән борчылу белән бик күп мактау сүзләре әйтелде.

Әйе, гомер—агымсулар кебек: Әмирхан аганың вафатына да биш ел тулып килә. Әле кичә генә аның белән очрашып, матур, иркен бүлмәсендә гапләшеп утырган кебек... Истә, барысы да истә, хәтердә.

Шулай да Әмирхан аганың үтәлмәгән бер вәгъдәсе калды, дөресе ул аны үтәп өлгерә алмады. Югыйсә, Әмирхан ага бик тә пөхтә, төгәл, биргән вәгъдәсен һәркайчан үти торган олпат зат иде.

Соңгы очрашуларыбызның берсендә ул миңа тарихи бер шәхес—Таһир Ильяси турында сөйләгән иде. Аның хатыны Нәгыймә—Шиһап Мәрҗанинең оныгы булган. Кызы Нәҗия ханым Нәгыймә кызы—Әмирхан аганың соңгы елларда яшәгән хатыны. Нәҗия ханымда әтисенең гарәп хәрефләре белән язылган зәңгәр тышлы калын гына көндәлек дәфтәре саклана. Ул тулаем Төркиягә багышланган һәм сәяхәтнамә рәвешендә язылган була. Нәҗия ханым ул көндәлекне матбугатта чыгару уе белән гарәп хәрефләреннән хәзерге графикага күчереп, машинкада баскан. Шуннан соң бу язмалар галим Марсель Әхмәтҗанов кулына кереп, ул бу турыда 1997 елда "Татарстан" журналының җиденче санында бит ярымлык мәкалә бастыра.

Әмирхан аганың әйтүенә караганда, Марсель әфәнде көндәлекләрне язучы Рабит Батуллага, анысы исә "Казан утлары" журналына тапшырган. Бу хакта Әмирхан ага бик борчылып кына:

—Минем алар артыннан йөрергә сәламәтлегем юк инде. Югыйсә, сәяхәтнамәләрдә төрки дөньяга караган, анда яшәгән татар зыялылары турында бай материал бар иде. Әмма журналда бу көндәлекләрнең дөнья күргәне юк әле,—диде.

Әмирхан аганы тынычландырып, шушы язмаларның очына чыгарга, аларның язмышы белән кызыксынырга вәгъдә бирдем. Вәгъдәмдә торып, "Казан утлары" журналы архивыннан шул сәяхәтнамәне табып, ике көндә укып та чыктым.

Икенче бер баруымда Әмирхан агадан Таһир Ильясиның кем булуы, ничек итеп Төркиягә барып чыгуы турында (ул анда Габдрахман Буби белән бергә барган икән) сәяхәтнамәгә кыска гына кереш сүз язуын үтендем. Шул кереш сүз белән "Заман"—Татарстан" газетасында сәяхәтнамәдән өзекләр биреп барачагыбызны әйттем. Ул бик теләп риза булды.

—Әзер булгач, үзем шылтыратырмын,—диде.

Соңгы вакытта сәламәтлеге начарланып китү яки вакыты тар булу сәбәплеме, ул бу вәгъдәсен үти алмады. Ни кызганыч, төрки дөньяга, зыялыларыбызга кагылышлы күпме тарихи бай мәгълүматлар аның белән бергә мәңгелеккә китеп барды.

**Наил ГЫЙЗЗӘТУЛЛИН,**
*Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре.*

## ШАГЫЙРЬ, ПУБЛИЦИСТ...

### РӘФИКЪ ЮНЫСНЫҢ "ТАТАРСТАН РЕФЕРЕНДУМЫ" ДИГӘН КИТАБЫН УКЫГАЧ ТУГАН УЙЛАР ЯКИ ӘДИПНЕҢ ИҖАТ ПОРТРЕТЫНА СЫЗМАЛАР

Күп шигырьләр, берсеннән-берсе кызыклы, фәлсәфи публицистик язмалар һәм күренекле шәхесләр белән уздырган тәфсилле әңгәмәләр авторы Рәфикъ Юныснын 2000 елны "Татарстан референдумы" дигән гаҗәеп китабы да дөнья күрде. Әмма, нигәдер, әдипнең бу күпкырлы матур иҗаты әдәби тәнкыйтьтә тиешле бәһасен алганы юк әле. Ул һаман да тәнкыйтьчеләр игътибарыннан читтә кала бирә.




Рәфикъ Юныснын үзенең 60 яшьлегенә багышлап язган менә бу шигыре дә, бәлки, юкка гына тумагандыр.

*Хыял төмен татып ымсынам мин,*
*Татлы төшләр күреп үртәләм.*
*Гөл-чәчәкле нурлы бу дөньядан*
*Шуып үтте бары күләгәм.*
*Шуып үтте салкын күләгәм.*

*Бүләк гомер, бердәнбер бу гомер*
*Башланмаган килеш азакта.*
*Канда тып-тын күпме гайрәт ята,*
*Җанда күпме кайнар наз ята.*
*Җанда әле күпме наз ята!*

*Тоям төптә тоныкгөрелтеләр.*
*Олы язмыш мине көткәндер.*
*Бөредәге "мин"не уятырга*
*Баштан сыйпау, бәлки, җиткәндер?*
*Чәчтән сыйпау, бәлки, җиткәндер?*

*...Өлгермәдем, ахры, табылып мин,*
*Өлгермәдем, ахры, кабынып.*
*Дөньягыздан, ахры, китәрмен мин*
*Уянмаган янар тау булып.*
*Янмый калган янар тау булып.*

Юк, Рәфикъ дус, ни өчен әле син: "...Өлгермәдем, ахры, кабынып",—дип язасың? Ничек кенә кабынгансың әле!.. Сөбханалла! 2000 нче елны дөнья күргән "Татарстан референдумы" дигән китабынны укыгач, бер генә укучы да тетрәнми калмагандыр. Һәм ул бик күп акыл иярен, хәтта гаҗәпләндерде дә. Әйе, гаҗәпләнмәслек тә түгел шул... Бер фәнни институт галимнәре бергәләп башкарырлык эшне—бу олуг тарихи хезмәтне Син бер үзен, нәкъ зур галимнәрчә (гел документларга гына таянып), нинди төгәллек һәм осталык белән башкарып чыккансың.

Татарстан китап нәшриятына да зур рәхмәт! Шушы үтә сәяси китапны, авторга хөрмәт илә теләктәшлек күрсәтеп, һәр укучыны кызыксындыра алырлык зәвык белән бастырып чыгарган. Ул—Казан ханлыгынын руслар тарафыннан басып алынуга нәкъ 450 ел тулар алдыннан укучы кулына килеп керүе белән дә аерым әһәмияткә ия. Р. Юныс, бу хезмәте белән, бәйсезлегебез өчен көрәшнең әле дә булса дәвам итүен һәм халкыбыз алдында тагын да катлаулырак һәм мәкерлерәк сынаулар торганын да

искәртә. Шигырендә әдип "Өлгермәдем, ахры, табылып мин", ди бит әле...

Китапның эчтәлегендә саналган бүлекләрнең исемнәре генә дә бик күп нәрсәне аңлата. Мәсәлән, "Петр патша васыять әйткән" дигәнендә—урыс менталитетының башка милләтләрне кысуга, бетерүгә нигезләнгәнен автор салды мисаллар белән дәлилли. Ә инде "...Татар башына татар житә" дигәнендә—үз татарларыбыз арасында да референдумга каршы көрәшүчеләрнең мәкерле эшләре фаш ителә. Мәсәлән, Казан университетында белем алып, унсигез ел Татарстанның партия өлкә комитеты беренче секретаре булып эшләп киткән Фикрәт Табеевның һәм кайбер шәүкәтле Мәскәү татарларының безнең референдумга катгый рәвештә каршы чыгуларын житди документларга таянып яза. Р. Юныс язмышыбыз кыл өстендә торган елларның һәр вакыйгасын жентекләп язып барган. Мисал өчен, референдум башланырга бары ике көн кала Россиянең Конституция суды рәисе В. Зорькинның Россия Югары Советы сессиясендә ясаган чыгышында "Башланырга мөмкин иксез-чиксез башбаштаклык Россиянең бөтенлегенә генә куркыныч тудырып калмый, ул канлы дулкын булып Татарстанның үзен дә тончыктырачак... Без хәзер упкын читендә торабыз",— дигән сүзләре китерелгән. Бу ясалма истериканың максаты, әлбәттә, Татарстан житәкчеләрен куркыту һәм халыкның башын бутау. Нинди генә коткылар булмасын, референдум үтте һәм ул бөтен татар дөньясын уятты. Аның татар язмышына, Татарстан язмышына тәэсире, бәлки, мәңгелек белән исәпләнер",— дип язды автор.

Әйе, дүрт гасыр ярым коллыкта яшәгән татар халкының, азатлык өчен, тагын бер мәртәбә житди талпынып караган еллары иде бу. Аның һәр вакыйгасы тарихи документларга нигезләнеп, бер китап булып тупланган икәндимәк, бу китапның кыйммәте еллар узган саен үсә генә барачак.

Күренекле язучыбыз Миргазиян Юныс бу китап турында язган мәкаләсендә: "Китапның эчтәлеге таныш иде дияргә була. Нишләп соң күңел шул таныш эчтәлекне янача кабул итә? Нигә шул унбер ел элек узган вакыйга тәнне чымырдата, тешләрне кысарга мәжбүр итеп тетрәндерә? Ә нигә соң без, татарлар, тыныч кына яши алмыйбыз? Нигә без көрәшергә тиеш? Менә бу сорауларга Рәфикъ Юныснең китабында йөрәк акылы һәм баш акылы белән эзләп тапкан дәлилле җаваплар бар. Ул җаваплар тышлыкны ачу белән, суверенитетка каршы листовкалардан, китапны укый башлаганчы ук, килеп бәреләләр",— дип язган иде. (*"Мәд. Җом". 2 сан, 2003 ел.*)

"Татарстан референдумы" китабы, шөкер, тәржемәче Гөлсирә Гайнанова тарафыннан рус теленә тәрҗемә ителгән. Аның чит телләрдә дә басылуы бик тә зарури.

Бу китапның тагын бер зур уңышы—авторның житди сәяси материалларны җинел укыла торган матур тел белән мавыктыргыч итеп яза алуында.

2002 елны референдумның 10 еллыгы унае белән җәмәгатьчелек тарафыннан үз бәһасен алыр әле бу китап, дип көткән идек, билгеле. Авторның, нәкъ үзе шикелле, тып-тын гына, 60 яшьлек юбилее дә үтеп китте. Ни хәл итмәк кирәк, референдум үзе дә инде күләгәгә күчә бара... Китапның авторы—шагыйрь үзе дә кирәгеннән артык тыйнаклыгы беләнме—никтер "шуып үткән күләгә" булыбрак яшәүне кулайрак күрә ахры. Ә аны язган көннәрендәге искиткеч күтәренке халәте һәм мөстәкыйльлек алабыз дип, сабыйларча шатланып һәм ышанып, хыялланып йөргәннәрен менә бу шигыре бик ачык аңлата.

**Сау бул, Рәсәй**

*Сау бул, Рәсәй. Аерылабыз.*
*Аерылабыз—рәнҗемә...*
*Каян килгән миңа бу көч?*
*Аптырыйм үз-үземә.*

*Азу түгел карт көнемдә—*
*Әйтмәсеннәр нахак сүз.*
*Бирнәм сиңа түгел иде.*
*Алдың мине никахсыз.*

*...Чәчем белән җир себердем,*
*Учым белән җир сөрдем.*
*Үзеңнән дә урысрак*
*Күпме малай үстердем—*

*Мантымадың! Гел хәерче!*
*Гел җитмәде юрганың.*
*Ә аякны һаман суздың.*
*Юл бастың йә урладың...*
*Сатып эчтең булганын.*

*Яратам дип биклəп тоттың,*
*Шикләндең гел, иснәдең,*
*Фарсыдан да, төректән дә,*
*Гарәптән дә көнләдең.*

*Соңгы елларда анысы*
*Яшәдек тату гына.*
*Чөнки "Татарстан" дигән*
*Калды тик атым гына.*

*...Инде ярты мәет идем.*
*Шунда могҗиза булды:*
*Төпчек малаемның теле*
*Үзебезчә ачылды!*

*Гүя шунда сихер кайтты,*
*Шартлап сынды зынҗырым.*
*Бар икән бит, сау икән бит*
*Үз иманым, үз җырым!*

*Аем кайтты—аны җаннан*
*Суырып алып кара син.*
*Сау бул, Рәсәй! Мылтык терәп*
*Яраттыра алмассың!..*

*...Тату яшик, асыл тормыш*
*Корыйк диеп ярыштан,*
*Кулын бирә сиңа күршең—*
*Ирекле Татарстан!*

Әмма референдумнан соң булган вакыйгалар, хыял күкләрендә йөзгән егетне шап итеп җиргә төшерде дә куйды. Аның үзенең дә бу турыда китабына әрнеп язган юлларын тыныч кына укып та булмый: "Дөньяның кызыгы китте. Элек, күзне тырнап ачу белән, радиога ябыша торган идем. Бар дөньямны онытып гәҗиткә чума торган идем. Татарстанга кагылышлы һәр хәбәр миңа үтә кызык иде. Дөнья хәлләрен дә жентекләп күзәтеп бардым, чөнки ул дөньяда минем Татарстаным бар иде.

Менә шул Татарстанны миннән урладылар. Әллә ниләр бүләк иткән төсле, барабаннар кага-кага урладылар аны... Мин "татар" дип, "милләт" дип көрәшеп йөргән кеше түгел. Ләкин миңа кинәт дөньяда яшәүләре күңелсез булып китте. Гүяки җанымның бер өлешен кисеп ташладылар... Минем илемне беркайчан да тәртип булмаган һәм булмаячак иләмсез олы илнен бәләкәй бер кисәгенә әйләндерделәр" *("Татарстан референдумы", 159 нчы бит).*

Көннәр үткән саен укучылар тарафыннан бу китапка игътибар үсә барды. "Нигә бу олуг тарихыбыз җәмәгатьчелегебезнең бәясен монарчы ала алганы юк" дигән сүзләр ешрак ишетелә башлады.

Ниһаять, Татарстан Язучылар берлегенең идарә карары белән "Татарстан референдумы" китабы өчен Р. Юныска Гаяз Исхакый премиясе лауреаты дигән исем бирелде.

Китапның соңгы 42 нче бүлегендә кыскача гына, референдумнан соң ниләр булганы тасвирлана. Бүлекнең исеме үк күп нәрсәне аңлата шикелле—"Референдумнан соң: мыек кына чыланды..." Без аны авторның "Чигенәбез" дигән шигырендә бик ачык күрәбез.

*Җиңеләбез, әйе, чигенәбез.*
*Чигенәбез.*
*Инде сафлардан*
*Шыбыр-шыбыр коела ыбыр-чыбыр*
*Качасыңмы син дә, каһарман?*

*...Меңнәр безне әзер өзгәләргә,*
*Яклап колбасалы коллыкны.*
*Йә, елыйкмы утырып?*
*Тынычланып,*
*Таш астында җәсәд булыйкмы?*

*..."Халык бит юк",— дисең.*
*Әйе, аны*
*Берәмтекләп әле җыясы:*
*Мәңге туңнан, казып сөңге белән,*
*Чыгарасы татар кояшын.*

*...Җиңеләбез, ләкин җиңдермичә,*
*Тез чүктерми җанны, вөҗданны.*
*Бер исән кул калса, байрак итеп*
*Шул күтәрер уртак иманны.*

*Бу төкәнмәс көрәш—җиңүгәчә,*
*Көчсезлекләр көчкә тоташа.*
*Саф арты саф, дулкын арты дулкын—*
*Бабайлардан оныкларгача...*

Әдип референдум карарларыннан чигенә башлауның сәбәпләрен дә эзли: һәм ул аны матбугат конференциясендә журналистлар тарафыннан куелган: "Хәзер Татарстан Россия составындамы? Юкмы?"— дигән сорауга М. Шәймиевнен: "Халык референдумга куелган сорауга: "әйе" диде, киләчәктә үзебезнең хокуклардан кирәк кадәр файдаланырбыз" ("Шәһ. Казан". 1992 ел, 25 март) "Күпләрне борчыган сорауга ачкычны менә шул сүзләрдә күргән идем мин. Файдаланырбыз. Кирәк кадәр. Ә кирәклек кимәлен кем хәл итә? Димәк, кирәк

санаган кадәр файдаланырбыз. Теләгебез, кыюлыгыбыз житкән кадәр, дип өстәсәң дә буладыр. Ләкин безнең референдум урныларына "әйе"ләрне тотыруыбыз—ул бит дәүләт житәкчеләребезнең кесәләренә сәяси капитал тутыру гына түгел. Без, халык, аларга бурыч йөкләдек, хокукларны бирсәк, шул бурычны үтәр өчен бирдек",— дип яза автор.

Үтәлдеме соң ул бурычлар? Үз вакытында бу сорауга мөхтәрәм язучы Әмирхан ага Еники болайрак дип жавап биргән иде. "...Безнен президентыбыз мөстәкыйльлек өчен көрәшкәндә үзен чын демократ итеп күрсәтте. Милли азатлык хәрәкәтенә таянып, Татарстанны суверен дәүләт итеп таныта алды. Бу анын Мәскәү белән килешүгә кадәрге эшчәнлеге. Килешүдән соң исә, демократлык артка чигенде, анын коммунистлыгы янадан алга чыкты. Нәрсәдән күренә бу? Барысыннан элек идарә итү ысулларында... Без гүя Обком заманасына кайттык. Шул ук өч кешедән торган пирамида: ин югарыда президент, икенче урында—Дәүләт Советы Рәисе, өченче урында—Премьер-министр... Фикри хөрлек, хәбәрдарлык заманнары үтеп бара". *(Ә. Еники "Кояш баер алдыннан", 1996 ел, 169-170 битләр.)*

Татарстанның язмышын хәл итүдә (бигрәк тә сонгы вакытларда губерналаштыру турында фикерләр йөргәндә) татар халкы, һичшиксез, үз сүзен әйтергә, үз таләбен куярга тиеш. Мөстәкыйльлек, милли азатлык халыкларга бары тик чын демократия аша гына килә. Әмма, ни кызганыч, чын демократия дигәнебез Россиядә һаман ераклаша гына бара шикелле...

Шулай да, Рәфикъ Юныс, үзенә генә хас үҗәтлек белән киләчәктә дә бернигә дә карамыйча, Татарстан референдумы тарихын туктаусыз өйрәнеп, аны тулыландырып торачагын белдерә. *("Татарстан референдумы", 161 бит.)*

Чыннан да, бу китап әле язылып бетмәгән шул. Ул елларда республиканын мөстәкыйльлеген саклап калу өчен, үзенең бай мөлкәтен булдыру аерата зарури иде. Русия карамагындагы 98% предприятиеләрне Татарстанның үз юрисдикциясенә кайтару өчен көрәш искиткеч катлаулы барды. Мәскәү тарафыннан, иң бай предприятиеләрне кулларыннан ычкындырмас өчен, кеше әйтеп ышанмаслык, үтә мәкерле чаралар күрелде. Үзәк телевидение һәм Мәскәүдәге төрле матбугат журналистлары, хәтта чит ил вәкилләрен дә тартып, безнең предприятиеләргә агылдылар. Цехлар буйлап эшчеләрне референдумга каршы ачыктан-ачык котыртып йөрүдән дә тайчанмадылар. Россия хөкүмәте тарафыннан нинди генә киртәләр, аяк чалулар, хәтта икътисади блокадалар ясалмасын, беренче булып, бу тәвәккәл адымны дөньякүләм әһәмияткә ия булган Казан компрессорлар заводы ясады. Үзебезнең гәзит битләрендә бу адымга сокланып, аны беренче карлыгач дип атасалар да, әмма Мәскәү бер көн эчендә заводка хәрби заказларны туктатты. Бер мең биш йөз кеше эшсез калды. Җибәрелгән продукцияләр өчен түләнергә тиешле акчаларны Россиянең үзәк банклары аша гына, ә түләү срокларын өчәр-бишәр, хәтта аннан да күбрәк вакытларга суза башладылар. Финанс хисаплары белән эш итүдә предприятие директорларынын хокукларын кисәргә тотындылар. Бу—чынбарлыкта, Татарстан юрисдикциясенә күчкән предприятиеләргә икътисади блокада иде.

Мәскәү ни генә кыланса да, барыбер бер-бер артлы Әлмәт насос заводы, Татнефть предприятиеләре, Түбән Кама химкомбинаты һ. б. предприятиеләр дә Татарстан юрисдикциясенә күчтеләр. Кемнәргәдер һич мөмкин булмагандай күренгән бу вакыйгалар, билгеле инде, Мәскәү өчен жан тартышына тин булгандыр. Ә татар халкы өчен, бу гасырлар буе хыялланып көткән чиксез горурлык хисләре тудырганын тасвирлый алырлык сүзләрне тапса, фәкать Рәфикъ Юныс кебекләр генә табар кебек.

Ни аяныч, Россиядә яна президент сайлангач, референдум яуланышлары юкка чыгарылды. Сонгы елларда Мәскәүдә тоталитаризм, унитаризм тенденцияләре көчәйгәннән-көчәя бара. Киләчәктә бу тарихи китапнын тулыландырылган һәм дәвам да ителгән яна басмасы туар әле дип ышанасы килә.

Рәфикъ Юнысның башка публицистик язмалары да бик тә үзенчәлекле. Житмеш-сиксәненче елларда Ш. Хөсәенов, Ш. Биктимеров, С. Садыйкова, М. Мәһди белән уздырылган әңгәмәләрендә, ә 1995 елдан башлап җибәргән зур күләмле "Тәфсилле әңгәмәләр"ендә бу үзенчәлек бик ачык күренә. Кемнәр генә юк әңгәмәдәшләре арасында...

Мәскәү гуманитар университеты ректоры Юрий Афанасьев, профессор Әгъдәс Борһанов, дума депутаты Фәндәс Сафиуллин, язучылардан—Әмирхан Еники, Равил Фәйзуллин, Фәнис Яруллин, Разил Вәлиев, Рәис Даутов, галимнәрдән—Миркасыйм Госманов, Фаяз Хужин, Рафаэль Хәкимов, Дамир Исхаков, "Азатлык" радиосыннан Фәрит Иделле.

Референдумнан соң илдә икътисад һәм сәясәтнең гел халыкка зарарга үзгәреп торуы аркасында Р. Юныс әңгәмәдәшләренең күбесе белән кабат тәфсилле-тәфсилле әңгәмәләр уздырып, аларны "Идел" аркылы укучысына җиткерә бара. Шулар арасында татар күңеленә хуш килгән, Рәсәйдә милли мәсьәләне гадел рәвештә хәл кылырга ярдәм итә алырлык күп фикерләр әйткән Ю. Афанасьев үзенең "Опасная Россия" дигән китабы чыгу белән бер китабын Рәфикъка бүләк итеп җибәрә. Татар халкының, гомумән, бөтен Русия халкының күзен ачарлык фикерләр тупланган бу китапта. "Идел" журналы үз укучыларын, аның татарчага тәрҗемә ителгән өзекләре белән дәвамлы рәвештә таныштыра бара.

Гомумән, Р. Юныснын бер генә әңгәмәсе дә—алдан әзерләп килгән сорауларга чиратлап җавап алу гына түгел инде. Бу—чын-чынлап гапләшү. Еш кына—фикерләр чәкәләшүе, бәхәсләшү дә. Кайчакта әңгәмә барышында һич көтелмәгән фикер-нәтиҗәләргә дә ирешелә, яки әңгәмәдәшнең монарчы һич игътибар ителмәгән яклары ачылып китә. Бу җәһәттән Равил Фәйзуллин белән әңгәмәсе бик кызыклы. Шагыйрьнең әдәбият белгечләре, тәнкыйтьчеләр һәм каләмдәшләре тарафыннан дистә еллар дәвамында һәр "маңгай сырына" хәтле эшләнеп, "Заман, иҗат, шәхес" дигән китап белән инде "пичәтләп куелган" образының әңгәмә вакытында ничек тагын да ачыла төшкәнен гүяки үз күзләрең белән күреп торасың.

Легендага тиң шәхес—Фәнис Яруллин һәм аның хатыны Нурсөя белән узган ел хастаханә шартларында уздырган әңгәмәсенең соңгы йомгаклау өлеше укучыларны нык уйландыргандыр. "...Фәнис Яруллин—Указ буенча гына түгел, чын-чынлап халык шагыйре, халык язучысы, татарның горурлыгы. (Фәнис язганны халык сеңдереп кенә бара. 37 китабыннан берәрсенең сатылмый ятканын күргәнегез бармы?) Ләкин ничә миллионлы татар халкы аны бергәләшеп тәрбия кыла алмый. Аерым-аерым, чиратка салып та карамаячак ул аны. Менә без, Язучылар берлеге аппаратында, редакциядә утыручылар да җәрәхәтләр, бинтлар белән кайнашырга теләмәбез. Әлегә мондый ихтыяҗ да юк. Кан басымы җәфалаган шушы ябыкчандыр хатын гына аяктан егыла күрмәсен. Ә без үзебезнең кулдан килгәнне эшлик. Бу соклангыч кешеләрнең кәефләрен көр тотарга тырышыйк... Һич югы, бүген урындык биләгәнгә, вакытлыча гына безнең карамакта булган гәҗит-журнал битләрен һәм юлларын кара көеп санап утырмыйк. Ауганнан соң могҗиза белән генә торып баскан җилкәнгә өргән җилне дә күпсенмик".

Бу фикерләрең өчен мең рәхмәт сиңа, Рәфикъ!

Рәфикъ Юныснын җитмешкә якын шигырен эченә алган беренче шигъри җыентыгы "Вакыт чылбыры" исеме белән дөнья күргән. Шушы җыентык белән танышкач, татар әдәбиятының классигы мәшһүр язучы Нәкый ага Исәнбәт шагыйрьнең иҗатына югары бәя бирә һәм болай дип яза. "...Ул җитди шагыйрь, башка күп кенә шагыйрьләребез кебек күп сүзле дә, буш сүзле дә түгел. Төрле якка чәчелми, түгелми, җыйнак. "Вакыт" дигән сүз Юныс өчен халиткеч тарихи этап.

*Ишетәм, күрәм:*
*Авыр шыгырдап*
*Әйләнеп тора вакыт чыгыры*
*Урала аңа тарих чылбыры!*
*Заманалар арты заман чорнала.*
*Хәзер безнең буын сынала.*
*Ныклык сорала!*

*Минем йомшаклык бик аз сизелер.*
*Ә без йомшасак—чылбыр өзелер!*

Вакыт, аныңча, аерым кешеләрнең генә түгел, аерым халыкларның да язмышын, аларның булачагын гына түгел, авыз ачып торсаң, булмачагын да хәл итеп яткан, бүгенге көн, безнең хәтәр һәм кайнар көнебез. Тарихны ясау урынына аны югалту яки соңга калу аркасында ике арада вакыт өзеклеге килеп чыгу, мирасны югалту һәм аны иясез калдыру. Сигез генә еллык "Алка таптым" шигырендә бу бик матур сурәтләнә.

*Югалттыңмы аны күршегә*
*Утырмага кереп барганда?*
*Табылмагач, "пәри тап!"— диеп*
*Ялваргансың булыр аңа да.*

*Табылды бит! Бүләк—бер убү!*
*Яулык читен ачып кара да...*
*Тик алканы ничек тапшырыйм—*
*Ике йөз ел безнең арада...*

Тарихта күпме кыйммәтле алкаларыбызны соңга калып таптык, ияләренә житкерә алмадык, күпмеләрен бөтенләйгә югалттык! Менә нәрсә ул вакыт һәм аны югалтуларыбыз.

Тарихта тагы да хәтәррәк—үткән белән киләчәк ара һәм нәсел күпере өзелү. Яшәп-яшәп тә, хәтта шәҗәрәң дә калмау мөмкин икән.




Шагыйрь андый хәлгә калмау өчен шәҗәрәсен ерак киләчәккә җибәрә һәм болай ди:

*Дөнья дигән урманда*
*Тормыш—оя корганда*
*Югалмасын мизгелләр!—*
*Җибәрәмен шәҗәрә!*

*Үткер вакыт хәнҗәре!—*
*Мин санаган кешеләр*
*Бар да тере иделәр...*
*Югалмасын исемнәр!—*
*Оныкбелсен бабасын!*
*Җибәрәмен шәҗәрә.*

Шагыйрь безнең замананың төрле дәһшәтле хәвеф-хәтәрләреннән кисәтсә дә, ул үзе алдагы тарихыбызга өметсез карамый. Киресенчә, киләчәкне яулап алырга чакыра.

*Киләчәккә барыйк, дуслар,*
*Һөҗүмгә барган кебек.*
*Елларны алыйк, кайчандыр*
*Калалар алган кебек!*

Нәкый ага Исәнбәт аның менә шушы шигырьләренә игътибар иткән һәм яшь шагыйрьнең киләчәгенә зур өметләр баглаган.

Рәфикънын шигъри җыентыклары: "Вакыт чылбыры", "Сүнгән яшен", "Син һәм мин" исемнәре белән, юка гына кәгазь тышлыкта, эчке битләре дә иң арзанлы сары кәгазьдән басылып чыкканнар. Кыяфәтләре белән бу китаплар мескенрәк булып күренсәләр дә, ач та укып кара син аларны (әгәр таба алсаң!). Андагы бай хәзинә таң калырлык. Ул бөтен нәселенә, баланның балаларына, оныкларына житәрлек. Фәнис Яруллин әйтмешли—кадерен белгәннәргә! Әйе, шагыйрьнең күпме уйланулары, хыяллары, үкенечләре, йөрәк яралары һәм укучысын кисәтер өчен күпме гыйбрәтле фикерләре сыйган кечкенә генә бу китапчыкка. Автор бу китабын "Вакыт чылбыры" дип юкка гына атамаган икән. Шагыйрь вакыт агышын аеруча үткен тоя, үзенең шигырьләрендә аның тарихи, фәлсәфи, лирик һәм драматик чагылышларын калку итеп күрсәтергә омтыла. Китапның эчтәлегендә шигырьләренә, темаларына карап, сигез бүлеккә бүлеп һәрберсенә берьюллык шигырь формасында исемнәр куйган. (Матур алым). Мәсәлән, "Туплар ярылганда туганбыз без...", "Туган яклар туган як ул..." һ. б. Ә соңгы "Син һәм мин" (1993 ел) дигән китабындагы бүлекләрнең исемнәре, минемчә, тагы да отышлырак, анда икешәр юллы шигырьләр куелган. Аларның үзләрен генә рәттән укып чыгуга күңелдә әллә никадәр фикер уяна, җан рәхәтләнә. Китапның иң соңгы битендә "син" белән "мин" шигыреннән түбәндәге юллар китерелгән.

*Алда—юллар: Ай-Кояшка,*
*Йолдызларга барасы.*
*Анысы булыр. Үтеп кара*
*"Мин" белән "син" арасын!*

"Мин" белән "син"—егет белән кыз, ир белән хатын яки ике күрше. Гүя ике дәүләт тә ул. Менә шул "мин" белән "син" чигендә монсу хәлләр дә, кайгылы хәлләр дә, мәзәк эшләр дә булып тора. Шагыйрь каләме аларны лирик, фәлсәфи һәм юмористик-сатирик шигырьләргә, жыр текстларына әйләндергән. "Син һәм мин" җыентыгы турында шагыйрь Зөлфәт: "Бу китапны төш кесәмдә йөртәсем һәм бүтәннәргә дә укыйсым килә. Сөенсеннәр-көенсеннәр әйдә, уйлансыннар-пошынсыннар..."— дип яза.

Рәфикъ Юныска күптән вакыт инде, барлык шигырьләрен бергә туплап, каты тышлы, яхшы кәгазьле бер затлы китап итеп дөньяга чыгарырга. Шигырь сөючеләр дә кинәнер иде...

Аның кайбер шигъри юлларында очрый торган сәерлек үзенең дә, шәхес буларак, сәеррәк кеше булуын раслый шикелле...

*Килә минем кулга аласым*
*Бер атналык тукран баласын.*
*Эрер иде кебек җанда боз*
*Әгәр шуны сыйпап карасам.*
*Куяр идем аны күкрәккә:*
*Зәгыйфь муйның йөртеп—*
*тук-тук-тук—*
*Әйдәле бер чукып карасын—*
*Йомшартмасмы йөрәк ярасын!*
*...Ләкин аны каян аласың—*
*Бер атналык тукран баласын?*
*Куркыр да ул әле аннан соң...*

Якын дусты шагыйрь Илдус Гыйләҗев тә "Шундый дустым бар минем" дигән шактый күләмле мәкаләсендә аның кайбер очракларда күрсәткән сәерлекләре турында шаярып язган иде. "Сәерлеге шагыйрь иткәнме, әллә киресенчәме, әйтүе кыен. Сәерлек аның ит ашамавында, аракы эчмәвендә, тәмәке тартмавында, коеп янгыр яуганда да йөгерергә чыгып китүендә, юк-бар төркемнәргә иярмәвендә генә түгел, ә фикер сөрешендә, яшәү рәвешендә. Ул үз фәлсәфәсен булдырган зат",— дип язган иде. *("Мәдәни җомга" 28.02.2003 ел)*

Рәфикъның тагын бер сәерлеген, дөресрәге, егетлеген "Татарстан яшьләре" гәзитендә эшләгән чагында Иделнең башланып киткән җиреннән Казанга кадәр 1500 чакрым җирне җәяүләп, бер ялгызы сәяхәт кылуында да беләм мин. Аның бу сәяхәте турындагы язмасын тыныч кына укып та булмый. Нинди генә хәлләргә тарымый ул анда, 35 көн буена. Кайбер урыннарында: әллә ничә чакрымнарга сузылган куе урман эченнән бара-бара төнгә кала, коеп янгыр ява, барган саен су башта тубыктан, аннан тездән, өстәвенә су тулы тирән-тирән чокырлар башлана. Кычкырып үлгән дә бер кеше ишетмәячәк тә, күрмәячәк тә. "Бетә бит инде бу, бетә", дип чынлап торып хафага төшәсен. Инде Казанга кайтып җитәм дигәндә Идел елгасы аша үтә торган тимер юл күперенә килеп җитә. Аны да җәяү үтү теләге белән күпергә таба юнәлә бу. Әмма анда мылтыклы сакчыны күреп туктап уйга кала. "Ярый да ул документларымны карарга риза булса... Якын килә башлауга сразу атып җибәрсә... Шулай итеп, күперне поезд белән үтәргә мәҗбүр була. Һәм моны ул җәяүле сәяхәтенә хыянәт керү дип кабул итә, гәрчә үзенең бер гаебе булмаса да.

Рәфикъ шәхес буларак тирән фикерле, зур мәгълүматлы, бай рухлы кеше. Күрә алмаганы: милләтебездә очрый торган хөсетлек, көнчелек сыйфатлары. Үзенә искиткеч таләпчән, кешеләргә ярдәмчел, киң күңелле булуы белән дә аерылып тора. Шул ук вакытта аны аңлап бетерүе дә кыен.

*Үзәмә дә җитми сүрән генә*
*Янган йөрәгемнең җылысы.*
*Күңелемдә минем начарлык юк.*
*Яхшылык аз. Начар шунысы!*

дип яза ул үзе турында.

Никадәр генә зур эшләр башкарса да, "Идел"е өчен җанын фида кылырга әзер булса да, ул үткән күп көннәреннән канәгатьсез кала һәм болай дип яза.

*И, мәгънәсез үтә көннәр!*
*Ай әрәмгә үтә лә,*
*Күпме өмет шытым килеш*
*Шиңеп калды тумалдә.*

*Күпме хыял кысыр калды!*
*Юк максат һәм теләк.*
*Хуҗасын җуйган сәгать күк*
*Текелди тәндә йөрәк.*

Аңларга да була кебек... Шәхси иҗатына вакыт житкерә алмавыннан тумый микән аның бу халәте? Күпләр әле белмәсә дә, үз күңелендә күпме әдәби байлыкның ак кәгазьгә сибелә алмыйча

бикләнеп ятканын тоймаса, болай ук дип язар идемени?

Ә кайбер шигъри юлларында хыялы белән генә булса да үзен юатып, тынычлана төшә кебек.

*...Чакырган бит—үги түгелмендер,*
*Урыным бар бугай дөньяда.*
*Цезарьларга карап көлгән кояш*
*Миңа да бит әнә елмая!*

*..."Син дә әле эзсез югалмассың,*
*Чагылышың яшәү күгендә*
*Шәфәкъ булып бераз янар әле!"—*
*Дип пышылдый хыял күңелгә.*

Юк, Рәфикъ дус: "Шәфәкъ булып бераз янар әле!"—дип кенә өметләнеп утырыр чак түгел хәзер. Сезгә күпләр: "Ижтиһат ит, эшкә башла, гомер узып барадыр",—дип әйтәчәкләр. Тәрҗемәи хәле белән дә таныштырып китим инде.

Рәфикъ Юныс—Арча районы, Кәче авылында 1943 нче елның 1 нче мартында якты дөньяга килә. Әтисе—Габделвәли улы Юныс 81 яшенә кадәр, диннең иң нык тыелган елларында да, халыкның зур ихтирамы белән, шушы авылда муллалык хезмәтен башкара. Ике якны да бертигез күреп, ике хатын, ике йорт тота. Беренче хатыныннан өч бала, икенче хатыны Гыйльмебаяннан алты бала тәрбияләп үстерә. Рәфикъ төпчек бала (әтисе дә Габделвәлинең төпчеге, Габделвәли бабасы Вәлид атлы дәү бабасының төпчеге булган. Кызык бит, ә?). Габделвәли бабасы турында мәшһүр Шиһабетдин Мәржани бик матур фикерләр язып калдырган. Рәфикъның олы апасы Галия (әтисенең өлкән хатыныннан туган беренче кыз) Ш. Мәржани мәчете имамы Хәбир Яруллинның никахлы хатыны. Шушы унайдан Рәфикъның бабасына багышлап язган шигыре белән дә танышып китик.

**Габделвәли бабама**

*"...диндар, бик игътибарлы, төзек фикерле.*

*Яхшы табигатьле, туры сүзле һәм укымышлы кеше иде. Хаҗ кылып хөрмәт казанды. Алдан күрүчәнлеге белән, китаплар тикшерү, хакыйкатьне эзләүдә көчле фикерле булуы һәм эшчәнлеге белән аерылып тора иде. Мелла Әбенасыр Әл-Курсавиның дусларыннан булды."*

Ш. Мәржани.

*...Якын да ара, ерак та*
*Әтиемә син—ата.*
*Төпчегеңнең төпчегемен—*
*Арада гасыр ята.*

*Упкын ята!—баласы мин*
*Тәһарәтсез дөньяның.*
*Сихерле бер йокыдан мин*
*Әле яңа уяндым.*

*...Ныклык эзләп, исемеңне*
*Дога кебек кабатлыйм:*
*...бине Вәлид, бине Максуд*
*Әл Кәчеви...*
*Ярабби!*

*Булмасамчы буш орлыгың*
*Нәселебез хурлыгы!*

.......................

Рәфикъ—күбрәк ачысын татып үскән сугыш еллары баласы. Өченче сыйныфта укыганда ук үз әнисе вафат була. Шул көннән башлап, әтисе беренче хатынын төп йортка күчерә. Икенче оя балалары аны электән үк дәү әни дип йөрткәннәр һәм тату, матур яшәгәннәр. Күрәсең, дәү әни үзе дә балаларны аермаган, тигез күргән. Шулай да, үз әниең—үз әни була инде ул... "Зәңгәр чардуган, ак каен..." дигән шигырендә моны тоймый мөмкин түгел.

*Зәңгәр чардуган, ак каен...*
*Үзгәрде барыр юлым.*
*Килдем, әнием, сизәсеңме—*
*Яраткан, төпчек улың!*

*...Кытыршы кулларың белән*
*Битемнән сөя идең.*
*"Алдашма, улым, гадел бул,*
*Әйбәт бул!" дия идең.*

*Зәңгәр чардуган, ак каен.*
*Бар да югалдымыни?*
*Синнән, әнием, әнием, синнән*
*Шул гына калдымыни?*

*Зәңгәр чардуган, ак каен,*
*Хушыгыз, ары китәм.*
*Әйтсеннәр кешеләр: "Кара,*
*Әнисе төсле икән бу,*
*Әнисе төсле икән!"*

Күп тә үтми Рәфикъ дәү әнисез дә кала. Әти кешегә тагын өйләнергә туры килә. Рәфикъ икенче үги әнисе—Факиһә ханымны да бик җылы, сагынып искә ала. Үги әнисенең бертуган сеңлесе

Хөснури Тукай-Кырлайда озак еллар башлангыч сыйныфларда балалар укыта. Аларның әтиләре Хәбибрахман, бабалары Фәтхерахман мәзин һәм имам хезмәтләрен башкаралар. Тукай үзенең бер язмасында Фәтхерахман бабай турында мондый юллар язган. "...әллә ул әтием белән дус булдымы икән, миңа еш кына, сәдака итеп, 5 әр тиен акча биргәләгәнен һәм шул акчага Әтнә базарыннан ак күмәч алып, юл буе тәмләп ашап кайтканын яза",—дип сөйләгән иде Рәфикъ.

Унбиш яше тулар-тулмаста ул әтисен дә югалта. Кәчедә VII нче сыйныфны тәмамлагач, шул сыйныфтан бер үзе, жиде чакрым ераклыктагы Арчаның 2 нче урта мәктәбенә укырга керә. 1960 нчы елны аны уңышлы тәмамлый. Анда татар теле һәм әдәбиятын укыткан, бик күп әлифбалар авторы булган Сәләй Гатич Вәлидовны горурланып искә ала. "Ул безне бары бер ел укытты. Әмма шул бер елда да безгә күпме мәгълүмат бирәп, татар әдәбиятына зур мәхәббәт тәрбияләп өлгерде",— дип остазына рәхмәт укый.

Армия хезмәтенә кадәр башта колхозда, аннан төзелештә эшләп ала. Армиядән соң Казан Дәүләт университетының журналистика бүлегенә укырга керә. 1969 елны аны уңышлы тәмамлап, "Татарстан яшьләре" газетендә 16 ел эшләгәннән соң, 1985—91 елларда Татарстан китап нәшриятында редактор һәм баш редакторның урынбасары, 1992 елдан инде 13 нче елын "Идел" журналы баш мөхәрриренең беренче урынбасары йөген жигелеп тарта. Бу журналның иң актив авторлары: "Идел"не Рәфикъ Юныстан башка күз алдына да китерә алмыйбыз",— диләр. Аның үтә дә таләпчән, шул ук вакытта, искиткеч кешелекле кеше булуын тирән хөрмәт итәләр. Табигатьнең олуг бүләге саналган Мәхәббәткә илаһи карашы, аерата саф мәхәббәткә гомере буе мәдхия жырлавы белән дә зур ихтирамга лаек ул.

*Могҗизалар күп дөньяда.*
*Тик кайда ул җиту сиңа!*
*И Мәхәббәт, берни тормый*
*Ташны алтын иту сиңа!*

Менә аның янә кечкенә генә бер шигырендә күпме матурлык...

*Кулымда нәни төенчек,*
*Анда нәни кешечек.*
*Бәйрәм кук күңелле бүген*
*Һәм сәер әллә ничек.*

*Нинди әти ди әле мин!*
*Тота да белмим менә...*
*Күлмәкләр таптым—мап-матурын!*
*Тапмадым исем генә.*

*Янымда бара әнисе,*
*Кыяфәтемнән көлеп.*
*Үзен дә бик сагындым шул,*
*Ул да бер бүләк кебек!..*

*Безнең нәни бүләмәбезне*
*Бизәдем бик тырышып.*
*Аш та пешердем. Өстәлдә*
*Өч тәлинкә, өч кашык.*

Шагыйрь үзе бу шигырен бик гадигә саный, бәлки, аның укучыга ничек тәэсир итү көчен уйлап бетермидер. Монда гажәеп чиста, саф мәхәббәт һәм шул мәхәббәтнең беренче татлы жимешен кулларына алу бәхете чагыла. "Өч тәлинкә, өч кашык" дигән юлларында инде тулы гаилә киләчәгенә ышанычлы Өмет салынган.

"Татарстан референдумы" китабын рус теленә тәржемә иткән Гөлсирә Гайнанованың шагыйрьгә биргән менә бу соравы да бик табигый шул:

—Рәфикъ, сезнең яшерен мәхәббәтегез кайсысы: поэзияме, әллә журналистикамы?

—Икесе дә тигез дәрәжадә,икесенә дә мәхәббәтем бер дә яшерен түгел. Алай дисән, минем әтием дә ике хатын белән яшәде һәм бик тату яшәделәр алар. Тудырган әниебезгә әни дип, әтиебезнең өлкән хатынына дәү әни дип дәшә идек.

Беренче мәхәббәтем поэзия булса да, әгәр миңа: "Кайсы сиңа кадерлерәк—сайла дисәләр, мин һичшиксез, референдум турындагы китабымны сайлар идем. Поэзиядә хисләр, журналистикада рациональ фикер булса, ә бу китапка алар икесе дә бер булып керде. Китабымда белем, фикер һәм хисләр—барысы бергә уралган. Бу хезмәтне халык онытмаячак һәм ул халкым язмышына аз гына булса да йогынты ясамый калмас, дип өметләнәм,—дип жавап бирә Рәфикъ. *("Идел" 2 сан, 2003)*

Киләчәктә дә эшләренә, шәхси ижатына да зур уңышлар юлдаш булсын, якташым!

**Гөлчәчәк ГАЛИЕВА**

*Муса Акъегетзадәнең тууына 140 ел*

# ЕГЕТЛЕК КҮРСӘТКӘН АКЪЕГЕТ

Без, гәрчә инде XXI йөздә яшәсәк тә, әле барыбыз да XX гасыр кешеләре булып кала киләбез. Бу безнең каныбызга сеңгән, фикерләвебездә тирән тамыр җибәргән. Безнең өчен XX йөз һаман да "безнең гасыр", ә XIX йөз—"узган гасыр". Муса Акъегетзадә (автор үзен Акъҗегетзадә дип йөрткән) нәкъ әнә шул күнегелгән вакыт төшенчәләре яссылыгында кабул ителә. Ул әле һаман да безнең өчен "үткән" һәм "безнең" гасыр кешесе.

Бу әдипне еллар чоңгылында калдырырга теләмәүнең икенче бер мөһим сәбәбе дә бар: аның эшчәнлеге, иҗаты һаман да заманга аваздаш, аның милләт өчен тырышып йөргән, намуслы Хисамеддиннәре, сөйкемле Хәнифәләре бүгенге укучы өчен дә үз һәм якын. Муса Акъегетзадәнең "бер адәмнең хәленә мәрхәмәт итсәк тә, бер миллион адәмгә—бер милләткә мәрхәмәтебез юктыр" сүзләре хәзерге Рәсәй һәм дөнья чынбарлыгы өчен актуаль янгырый.

Күп кенә әдипләрдән үзгә буларак, Муса Акъегетзадә бер генә әдәби әсәр яза һәм шуның белән тарихка кереп кала. "Хисамеддин менла" (1886)—аның тәүге дә, ахыргы да әсәре. Әмма анда 20 яшьлек егетнең яшәеш турында күзаллаулары, хыял-өметләре, тормышны аңлау дәрәҗәсе шактый тулы гәүдәләнеш тапкан. "Хисамеддин менла"—авторның чын мәгънәсендәге фидакарьлеге, егетлеге.

***

Күпчелек татар әдипләренең тәрҗемәи хәлләре бер-берсенә шактый охшаш. Мәсәлән, Октябрьгә кадәрге язучылар, нигездә, йә рухани, йә игенче гаиләсеннән, Казан, Уфа төбәкләреннән. Алар мәдрәсәдә укый, очын-очка ялгап тормышын алып бара, муллалык, мөгаллимлек кыла. Муса Акъегетзадә исә дворян семьясыннан, Пенза якларыннан. Әтисе—өяз шәһәре Чембарда дәүләт хезмәткәре. Тормышлары шактый мул.

Чембар төбәгендә бер-берсе белән бик якын урнашкан алты татар авылы бар. Аларны еш кына "Алтыавыл" дип тә йөртәләр. [Боларның берсендә—Качкаруда (Кутеевкада) без фәкыйрегез дә 1962-1963 уку елында мәктәптә эшләгән иде. Андагы авылларның зурлыгына шаккатуым әле хәзер дә хәтеремдә. Аларның кайберләрендә йортлар саны меңнән артып китә. Бу төбәк "мишәрләре" өчен тырышлык, үткенлек, хәрәкәтчәнлек хас. Алар элек-электән Ростов, Әстерхан, Баку, Мәскәү, Петербург калалары белән тыгыз бәйләнештә тора. Әгәр дә бу шәһәрләрдәге татарларның тарихы белән кызыксына башласаң, алар арасында Чембар төбәге белән бәйләнешләрне дә күпләп очратасың. Мин 1993 елда Әстерханда Алтын Урдага багышланган төбәкара фәнни конференциядә катнашкан идем. Шул чагында шәһәр татарлары белән дә очрашу кичәсендә мин заманында Качкаруда үзем укыткан берничә кешене очраттым. Мәскәүдә дә мондый хәлләр булгалады].

М. Акъегетзаденең нәсел-нәсәбе дә әнә шул "Алтыавыл"ның берсеннән—Мачалидан [Габдулла Баттал фикеренчә, Кабилдән (Кайбел), ягъни Кобылкинодан]. Булачак әдипнең биредә әби-бабалары яши. Аның бабасы Алтынбай 25 ел буе солдатта хезмәт иткән һәм 1812 елгы Ватан сугышында күрсәткән батырлыклар өчен "дворян" титулына лаек була. Муса балачак вакытының шактый өлешен авылда уздыра, татарча укырга, дингә, туган теленә шунда өйрәнә. Мөгаен, шуңа карап аны кайберәүләр авылда туган дип тә исәплиләр. Әмма Муса Акъегетзадә 1864 елның 3 декабрендә Чембарда туа. Әйткәнебезчә, әүвәл авылда укый, аннан—Чембардагы урыс телле башлангыч уку йортында (училищесында). Алга таба ул

Пензадагы урыс классик гимназиясендә белем ала һәм аны 1884 елда (аерым чыганакларда—1886 елда) унышлы тәмамлый.

Муса Акъегетзадә кечкенәдән төрле китаплар, аеруча әдәби әсәрләр укырга ярата. Гимназиядә уку елларында ул үзлегеннән төрек әдәбияты белән мавыга, төрек һәм урыс телләре аша Аурупа, аеруча француз сүз сәнгате белән дә шактый таныша. Мәгълүм ки, XIX йөзнең урталарыннан башлап Госманлы мәмләкәтендә француз теленнән тәрҗемәләр, Аурупа авторлары рухындагы әсәрләр киң тарала. Бу төр китаплар билгеле бер дәрәҗәдә татар зыялыларына да ирешә. Мәсәлән, аерым татар гаиләләрендә минем XIX йөздә Истанбулда дөнья күргән Жюль Верн, Виктор Гюго, Мопассан һәм кайбер башка Аурупа әдипләренең китапларын күргәнем бар.

Әлбәттә, әдәбиятны ярату, башкаларның әсәрләрен уку гына әле кешене әдип итми. Моның өчен адәм баласында иҗади талант, үз карашың, үз сүзең булуы кирәк. Муса Акъегетзадә, күрәсең, яшьтән үк, аеруча гимназиядә уку елларында милләт язмышы, инсаннарны бәхетле итү турында ныклап уйлана, энесе Хәсән, иптәшләре белән бу хакта әңгәмә-бәхәсләр кора. (Шунысын да әйтик: ике туганның яшь аермасы бик аз була. Алар бер чорда гимназиядә белем алалар. Яшь галим А. Ахунов сөйләвенчә, Хәсән, Пенза гимназиясен тәмамлагач, Казан ветеринария институтында укый.) Акъегетзадә үзенең фикер-хисләрен, өмет-хыялларын, мәсләки кыйбласын башкаларга да җиткерергә, үзгәләрне дә шулар хакында уйландырырга тели. Һәм нәтиҗәдә аның атаклы "Хисамеддин менла" әсәре туа. Автор Казанга килеп, 1886 елда аны татар мәркәзендә бастырып та чыгара.

***

"Хисамеддин менла"—50 битләр тирәсендәге эпик әсәр. Муса Акъегетзадә аны үзе "милли роман яки хикәя" дип атаган. Мондый исем аклана да. Чөнки Шәрык, шул исәптән татар сүз сәнгатендә күп гасырлар буе эпик, лиро-эпик характердагы чәчмә (кайчак шигъри, катнаш) әсәрләрне, кагыйдә буларак, хикәят дип йөрткәннәр ("Мең дә бер кичә", "Нәһҗел-фәрадис", "Гөлестан бит-төрки" китапларын, Мөхәммәдъяр, Әбелмәних Каргалый, Каюм Насыйри һ. б. язмаларын искә төшерегез!). Муса Акъегетзадә, бер яктан, бу традициягә тугры кала. Икенче тарафтан, төрек, урыс, Көнбатыш Аурупа романнарыннан хәбәрдар булган автор үз әсәренең татар әдәбиятындагы яналыгын үзе дә аңлый. Шуна күрә ул бу китабын "милли роман" дип атый.

"Хисамеддин менла" эчтәлеге, образлар системасы, сюжет-композициясе, урын-вакыт (хронотоп) бирелеше белән роман исеменә лаек. Әсәрдәге вакыйга-хәлләр авылда, шәһәрдә, тимер юл вокзалында, мөсафирханәдә, хосусый йортларда һәм башка урыннарда бара. Алар бер елга якын вакытны үз эченә алалар. Үткән чорларга да чигенешләр ясала. Романның үзәгендә—Хисамеддин, аның Хәнифәгә мәхәббәте. Башка вакыйга-хәлләр аларның характерын, үзара мөнәсәбәтләрен гәүдәләндерүгә буйсындырылган.

Биредә без романның идея-эстетик эчтәлегенә, образларына махсус тукталып тормыйбыз. Чөнки алар хакында әдәбият тарихы китапларында, дәреслекләрдә, безнең язмаларда *("Татар реализм әдәбиятының атасы" // Татарстан.—1996.—№5.—47-50 б.; Татар әдәбияты: рус мәктәпләренең 10 нчы сыйныфында укучы татар балалары өчен дәреслек-хрестоматия.—К.: Мәгариф, 1996.—154-159 б.)* шактый гына мәгълүматлар бар. Бу мәкаләдә без әсәрнең кайбер үзенчәлекләрен, яңалыгын, әдәбият тарихындагы әһәмиятен генә искәртеп китәбез.

Татар әдәбиятының мең елдан артык тарихы бар. "Хисамеддин менла"га кадәр үк бездә бик күп гүзәл әсәрләр иҗат ителгән. Әмма шуна да карамастан, бу роман татар сүз сәнгатендә яңа бер этапны ачып тора. Берлинда нәшер ителгән "Яңа милли юл" журналының 1931 ел, 11 нче санында "Муса Акъегетзадә" дигән мәкалә бу әдип "татар әдәбиятында яңа бер борылышның юлбашчысы" дип башланып китә.* Алга таба Г. Батталның "Казан төрекләре"ннән *(Истанбул, 1925)* һәм Г. Рәхимнең "Татар әдәбияты көтепханәсе" сериясендә чыккан *(6 нчы сан)* "Хисамеддин менла" басмасына кереш сүзеннән өзекләр китерелә. Роман турында Г. Рәхим болай яза: "Бу—безнең

*Бу санның тышлыгында һәм эчендә Муса Акъегетзадәнең фоторәсеме дә бар. Әмма аның астында әдипнең туган елы 1865 дип күрсәтелгән.

татарда Аурупа эзенә ияреп мәйданга китерелә башлаган яна әдәбиятның беренче әсәре. Бу әсәр шул дәвер әдәбиятының башлангыч заманы өчен чыннан да тип булырлык бер әйбер... "Хисамеддин менла" әдәби-шигъри яктан кытыршылыкларга һәм житешсезлекләргә бай булса да, татар әдәбиятының характерлы бер дәверен башлап китү өчен ул бик муафикъ, бик ярарлык; чөнки анда без киләчәктә Заһир Бигиев, Риза Хәзрәт, Фатыйх Кәрими һәм башкалар шикелле язучыларның әсәрләрендә киңәйтелеп мәйданга куелган, уянуның, тәрәккъыйның, укуның, хатыннар хөрриятенең кирәклеге турындагы яңа фикерләрнең орлыкларын күргәнебез шикелле, шул 1905 елга кадәрлеге арада житешкән яңа татар әдәбиятындагы бөтен ижаби (уңай) һәм сәлби (кире, тискәре) типларның прототипларын да без аның эчендә очратабыз".

Г. Рәхимнең бу юлларында "Хисамеддин менла"ның төп үзенчәлеге, татар әдәбиятындагы роле шактый тулы ачылган. Муса Акъегетзадә романының төп яңалыгы шунда: автор шул чордагы татар яшәешенең мөһим мәсьәләләрен тормышчан образларда, чынбарлыкка хас вакыйга-хәлләр, мөнәсәбәтләр аша гәүдәләндергән. Әдипнең инсаният, әхлак, тәрәккъыят турында уйланулары, өмет-идеаллары милли-ислами нигезгә корылган. Автор карашынча, милләтне үстерү өчен кешеләрнең инициативалы, белемле, һөнәрле, әхлаклы булуы шарт. Хисамеддин, Әбүзәр, Гайса, Хәнифә—нәкъ әнә шундый сыйфатларга ия. Өстәвенә алар матур да. Уңай каһарманнарның яшь булуы да игътибарга лаек. Чөнки аларда дәрт, энергия, тәвәккәллек көчле.

Хисамеддин, Гайса, Әбүзәр, Мохтар—төрле шөгыльле һәм табигатьле кешеләр. Аларның берсе—мөгаллим, икенчесе—эшкуар (промышленник), өченчесе—булачак чиновник, дүртенчесе—сәүдәгәр. Әмма аларны милләтпәрвәрлек берләштерә. Автор фикеренчә, бу дүрт шөгыль иясенең берлеге—милләтнең алга җибәрүнең төп факторы. Шунысы гыйбрәтле: М. Акъегетзадә үз халкындагы аерым кимчелекләрне дә күрә. Әмма ул, кайбер авторлар кебек, тәнкыйть белән артык мавыкмый, аларны бетерү юллары турында уйлана. Мәсәлән, хәерчелек юлына баскан Мохтар кәсепкә керешә, үз тырышлыгы белән баеый. Пәйгамбәрнең "кем иҗтиһад итәр, ул табар" хәдисе юкка гына әсәрдә китерелмәгән. Автор, гомумән, тырышлык, тәвәккәллек, эшлеклелек, белем-һөнәргә ия булуны инсаннарның яшәү принцибы рәвешендә аңлый.

Аның фикеренчә, буш сүздән файда юк, "эш"-гамәл кирәк. Гайсә авызыннан ул мондый сүзләр әйттерә: "...вакыт бик кыйммәтле шәйдер... Вакытны бушка сарыф итсән, гөнаһкяр булырсын". Роман халыкка, киләчәккә ышаныч рухы белән сугарылган. "Эстәек мәгърифәтне вә һөнәрне,—ди бер персонаж,—чөнки татар да яртиян (ярты) гакыл түгел, зиһене бик мөкәммәлдер. Зыялыланмага истигъдалы (сәләтле) бер кавемдер".

"Хисамеддин менла" хакында язучыларның күпчелеге ана госманлы әдәбиятының гына түгел, ә төрек теленең дә тәэсире хакында искәртәләр. Бу һич тә гаҗәп түгел, чөнки бу чорда төрек теленең, "Тәрҗеман" теленең йогынтысы башка авторларда да күзәтелә. Әмма М. Акъегетзадә романында татар теле өстенлек итә. Автор телебезгә хас булган сурәтләү чараларын, образлы гыйбарәләрне, мәкаль-әйтемнәрне, хәтта җырларны да уңышлы гына әсәр тукымасына кертеп җибәрә. Романда җирле шивә элементлары, этнографик детальләр күзгә ташлана. Хикәяләүдә, тел-стильдә, әсәрнең сюжет-композициясендә элеккеге хикәятләргә хас аерым күренешләр дә очрап тора. Мәсәлән, автор вакыйга-хәлләргә, геройларга турыдан-туры үз мөнәсәбәтен белдереп куя. Хәнифә "шәкәр иреннәргә", "энҗе тешләр"гә ия. Кыз үзенең хатында, "Кыйссаи Йосыф"тагы кебек, тышкы матурлыкка гына ышанмаска кирәклекне искәртә. Роман, нәкъ әкият-хикәятләрдәге шикелле, егет белән кызның гаилә коруы белән тәгаллинә. Эпилог-бетем рәвешендә бирелгән өлештә Хисамеддиннең хатыны белән Тифлискә китүе әйтелә (Ризаэддин Фәхреддиннең "Сәлимә"сендәге егет тә читкә китә). Романның эчке мантыйкы нигезендә төп каһарман халыкка хезмәт итү эшен туган җирендә дәвам итәргә тиеш иде.

Романда билгеле бер дәрәҗәдә авторның тәрҗемәи хәле дә гәүдәләнеш тапкан. Әбүзәр Дәүләтгилдиев өлешчә гимназист Муса Акъегетзадәне дә хәтерләтә. Хисамеддин образы әдипнең бу чордагы рухи халәтен, теләк-омтылышларын чагылдыра. Аерым мәгълүматларга караганда, Муса гимназиядә уку елларында Исмәгыйль Гаспралы карашлары белән мавыга, даими рәвештә "Тәрҗеман"ны укып бара. Болар исә әсәрдә дә телгә алына.

***

Габдулла Баттал һәм төрек галиме Хилми Зыя Өлкән *(1901—1974)* язуынча *(Казан утлары.—1996.—№4)*, М. Акъегетзадә гимназиядә уку елларында ук Төркиягә китәргә җыена. Әмма ул чакта аны әтисе туктатып кала. Яшь егетнең максаты, көрәсен, Төркиядә укып кайтып, халкына хезмәт күрсәтү булгандыр. Бу чактагы омтылышы гамәлгә ашмаса да, Муса Акъегетзадә аны Хисамеддин образында бар, булган рәвешендә тасвирлый. Бераздан бу каһарманның аерым эш-гамәлләрен үзе дә кабатлый. Әйтүләренә караганда, Муса бераз вакыт туган ягында мөгаллимлек кылып ала. Кырымда "Тәрҗеман" газитендә дә хезмәттәшлек итүе мәгълүм. Исмәгыйль Гаспралы киңәшен дә истә тотып, Муса 1888 Төркиягә китә. Әмма, Хисамеддиннән үзгә буларак, авторга туган якларына кайту насыйп әйләми. Ул 59 еллык гомереннән 35 елдан артыгын Төркиядә уздыра һәм аның җәсәде дә шундагы туфракка иңдерелә.

Төркия—Рәсәй колониаль изелүе астында яшәгән күп кенә татар яшьләрен элек-электән үзенә сыендырып килгән, аларга белем алу, эшләү мөмкинчелеге биргән, рухи таяныч булган мәмләкәт. Шунысы гыйбрәтле: безнең милләттәшләр биредә югалып калмаган, үзләренең тырышлыгы, сәләте, хезмәт сөючәнлеге белән шактый гына уңышка да ирешкәннәр. Араларында белем-мәгърифәттә, фәндә, иҗтимагый тормышта югары дәрәҗәләргә ирешүчеләр дә бар. Йосыф Акчура, Садрый Максудый, Рәшит Рәхмәти Арат, Акъдәс Нигъмәт Курат, Фуат Туктар, Закир Кадыйри һ. б.—әнә шундыйлардан. Муса Акъегетзадә дә болар арасында лаеклы урынны били.

Кызганыч ки, "Хисамеддин менла" авторның Төркиядәге тормышы һәм эшчәнлеге җентекләп өйрәнелмәгән. Аның гаилә хәлен, яшәү урыннарын, язмаларын да без тиешенчә белмибез.

Г. Баттал, Хилми Өлкән һәм кайбер башка авторлар язуынча, Муса Акъегетзадә, Төркиягә килгәч, Истанбулдагы бик тә дәрәҗәле "Мөлкияи Шаһания"* исемле югары уку йортына укырга керә. Анда ул тырыш, алдынгы, актив студентлардан санала. Нигездә, дәүләт хезмәткәрләре әзерли торган бу уку йортын тәгаллегәч, югары гаскәри уку йортларында *(Хәрби академиядә һәм Хәрбия мәктәбендә)* урыс теле һәм икътисад фәннәрен укыта. Шунысын да искәртик: Муса Акъегетзадә татар, урыс, төрек, француз телләрен камил һәм өлешчә гарәп, латин телләрен белә.

"Хисамеддин менла" авторы Төркиядә уку-укыту, эшләү елларында икътисад *(дөресрәге—"сәяси икътисад")* белән нык кызыксына башлый. Моның үзенә күрә сәбәбе дә бар. Әдип үзенең романында ук сәүдә, сәнәгать, акча кебек төшенчәләргә нык игътибар итә. Мохтар үз тырышлыгы белән аз-азлап акча туплап, сәүдәгәр булып китә. Әбүзәр бәк карашынча, "мәгыйшәттә иң бөек куәт акчадыр". Әсәрдән милли тәрәккыят белем-мәгърифәттә, әхлаклылыкта һәм матди муллыкта дигән фикер саркып чыга.

Мәгълүм ки, Муса Акъегетзадә укыган һәм эшли башлаган елларда барлык төрки кавемнәр диярлек колониаль изелүдә яши, алга киткән аурупалылардан шактый артта кала. "Хисамеддин менла" авторы мөстәкыйль дәүләт булып хисапланган Госманлы мәмләкәтенең дә тәрәккыяттән читтәрәк калуын күреп борчыла. Муса Акъегетзадә фикеренчә, төркиләрнең торгынлыкта яшәвенең төп сәбәбе—аларның икътисади яктан артталыгында һәм менә шушы факторлар талантлы әдипне икътисад белән шөгыльләнүгә китерә дә. Ул Адам Смит, Рикардо... исемнәре белән бәйләнешле классик экономика теорияләрен дә, шул чордагы Аурупа, урыс, төрек икътисадчыларының хезмәтләрен, дөнья экономикасын да нык.лап өйрәнә. Нәтиҗәдә, аның "Иктисад, яхуд Гыйльме сәрвит" *("Экономика, яки Байлык гыйльме")*, "Гыйльме сәрвит" исемле хезмәтләре дөнья күрә. Аларда автор икътисадның ирекле базар һәм химаячелек кебек мөһим мәсьәләләрен үзәккә куя, җәмгыятьне үстерүнең заманча экономик чараларын гыйльми дәлилли. М. Акъегетзадәнең икътисади карашлары Төркиянең алдынгы фикерле зыялылары тарафыннан хуплау тапса да, рәсми хакимият аларны гамәлгә ашырырга ашыкмый. Киресенчә, авторга кырын карашлар көчәя.

* Аны кайвакыт "Мөгаллиями Шаһания" дип тә йөртәләр. Бу уку йортында Төркиянең күп кенә дәүләт эшлеклеләре, әдип-галимнәре дә белем ала. Т. Әйди язуынча, алар арасында Х. Гүрпынар, Ә. Корыйөрәк, Ө. Ушаклы һәм башка күренекле язучылар да бар *(Казан утлары.—1996.—№4.—171 б.)*.

Бераздан ул Хәрби уку йортларыннан да китәргә мәҗбүр була. Үзе дә "Мөлкияи Шаһания"не тәмамлаган *(1921)* Х. Өлкән М. Акъегетзадәнең бу чордагы тормышы һәм эшчәнлеге хакында менә нәрсәләр яза *(1966)*: Үзенең "фикерләрен тагын да әтрафлырак исбатлар өчен, (ул) бер матбага кора *(Вәзирханында)* һәм "Мәтин" *("Мәтен"?.—Х.М.)* исемле гәзит чыгара башлый. 1910 елда бер-бер артлы ябылган гәзитләр арасында "Мәтин" дә булганлыктан, бүтән ике гәзит белән берләшеп, "Өч кардәш"кә нигез сала. Ул да ябылгач, хәрби хезмәткәр түгеллеген сылтау итеп, Муса Хәрби академия һәм Хәрбия мәктәбендәге укытуыннан азат ителә. Башта Измир, соңрак Һама шәһәрләрендә ябык биналар комиссиясе әгъзасы һәм рәисе вазыйфасына билгеләнеп, Истанбулдан ераклаштырыла. Бу тәшкиләттән *(оешмадан)* киткәч, көнчыгыш вилаятләрдәге каймаклыкларда *(өязләрдә) (Адилҗәвәз, Һошап)* хезмәт итә, иң ахырда, ул Чапакчур каймакамлыгында эшләгән чакта, Беренче Дөнья сугышы башлана. Урыслар Сиваска якынлаша. Муса Акъегет, хөкүмәт документларын бер чемоданга тутырып, поезд йөргән җиргә кадәр барып житә, әмма шул чакта тиф чирен йоктыра. Истанбулда аңа бик озак шифаханәдә дәваланырга туры килә. Сәламәтләнгәннән соң, Русиядән сатып алынган Катанов шәркыят китапханәсенә мөдир итеп тәгаенләнә. Шуннан ул пенсиягә чыга. *(Г. Баттал язуынча, әдип үлеменә кадәр биредә эшли.—Х. М.).* Гомере азагында бәйсезлек сугышында Истанбулның азат ителүен күрә һәм авыру хәлендә яшьләр оештырган факеллы нәмаешларда *(демонстрацияләрдә)* катнаша, озак та үтми *(1923 елның 24 сентябрендә.—Х.М.)* вафат була" *(Казан утлары.—1996.—№4.—173 б.)* Кайбер хезмәтләрдә әдипнең 4-5 еллап Госманлы империясе составындагы Сүриядә эшләве дә искәртелә.

Күрәсең, Муса Акъегетзадәнең Төркиядәге тормышы шактый катлаулы, сикәлтәле. Анда күтәрелү-төшүләр дә, куаныч-газаплар да җитәрлек. Әмма ул тулы канлы, нәтиҗәле яшәеш. Әгәр дә бу зат үз халкына да турыдан-туры хезмәт иткән булса, тагын да күркәмрәк булыр иде. Әмма нишлисең, тәкъдирдә шулай язылгандыр. Чыганакларда Муса Акъегетзадәнең "Төрек йорды" һәм "Төрек дәрнәге" *(җәмгыяте, оешмасы)* мәҗмугаларында мәкаләләр язуы да бәян ителә. Шулай ук М. Акъегетзадәнең "Аурупа мәдәниятенең әсасенә бер караш" *("Аурупа мәдәниятенең нигезенә бер караш")* хезмәте дә бар. Ул авторның Төркиядә нәшер ителгән тәүге китабы хисаплана. Бу хезмәттән аерым өзекләрнең "Әлгасрелҗәдид" мәҗмугасында да басылуы *(1906)* мәгълүм. Кызганыч ки, М. Акъегетзадәнең Аурупа мәдәниятенә мөнәсәбәте бу китабы кулыбызда юк. Аны табып, хәзерге татар укучыларына җиткерү дә зыян итмәс иде.

***

Муса Акъегетзадә—бәхетле дә, бәхетсез дә әдип. Ул бер әсәре белән әдәбиятта борылыш тудыра, үзеннән соңгы әдипләргә көчле йогынты ясый. Аның "Хисамеддин менла"сы кат-кат басыла, уку йортларында өйрәнелә. Төрекчәгә дә тәрҗемә ителә. Бу роман хакында инде туууыннан алып хәзергәчә күп төрле фикерләр әйтелгән. Г. Сәгъди аны "үзенең тарихи әһәмиятен бервакытта да югалтмый торган әсәр" дип атый. Г. Ибраһимов М. Акъегетзадәне "татар реализмының атасы" дип бәяли. "Яңа милли юл", "Азат Ватан", "Kazan" кебек мөһаҗирлектәге журналларда да әдипнең әсәре, эшчәнлеге унай бәяләнә. Әдип хакында И. Ильминский, Н. Ашмарин кебек урыс галимнәренең дә фикер-күзәтүләре бар.

Кызганыч ки, М. Акъегетзадә туган иленнән китәргә, әдәби иҗаттан аерылырга, башка ил-кавемгә хезмәт итәргә мәҗбүр була. Шунысын да әйтик: аның икътисади карашлары XX йөздән Төркия җәмгыятен реформалаштыруда иркен файдаланыла. Төрек галиме Х. Өлкән Муса Акъегетзадәне юкка гына "безнең каһарманыбыз", "юлбашчы" дип атамагандыр. "Хисамеддин менла" әсәреннән башка, әдипнең башка язмалары, тормышы, аеруча Төркиядәге эшчәнлеге әле ныклап, тиешенчә яктыртылмаган. Татар мәгърифәтчелек әдәбиятында, реалистик татар сүз сәнгатендә фидакарьлек, егетлек күрсәткән Муса Акъегетзадә исә тагын да тулырак, җентеклерәк өйрәнүгә лаеклы зат.

**Хатыйп МИҢНЕГУЛОВ,**
*филология фәннәре докторы*

*Шәйхи Маннурның тууына 100 ел*

# ТУГАН ЯК ҺӘМ ӘДИП КАДЕРЕ

Ул елларда безнең яклардагы сабан туе Шыя елгасы буендагы мәйданда ике авылга бер-уртак була торган иде. «Безнең яклар»—дигәнем—Мамадыш районының Тулбай һәм Дусай авыллары.

Мин Аны—Шәйхи Маннурны—тәүге тапкыр әнә шул сабан туенда күреп алдым. Әниемнең: «Язучы абыең әнә шул була инде, улым»,—дигәне хәтердә.

Минем—жиде яшьлек малайның—язучы дигән затны әле гомеремдә беренче мәртәбә генә күрүем иде. Шәйхи Маннур чак кына алга табанрак бөкрәя төшкән бик тә олпат гәүдәле, чал чәчле бабай булып күз алдында калган һәм бу бабайдан ниндидер үзенә күрә бер илаһи, әмма дә шул ук вакытта бик тә садә нур сирпелә сыман иде. Ул чагында әле мин язучы дигән затны бер дә ашамый-эчми торган, безнең күк гади кешеләрдән бөтенләй үзгә булган жан иясе итеп күз алдына китерә идем.



*Әмирхан Еники, Фатих Хөсни, Шәйхи Маннур һәм Гомәр Бәширов—«Чулпан» колхозында кунакта. 1965 ел.*

Янә берничә елдан соң мин Шәйхи Маннурның «Агымсуларга карап» дип аталган китабын укып чыктым һәм... шаккаттым. Теге чакта үз күзем белән күргән язучы бабай, бактың исә, нәкъ безнеңчә гап-гади авыл телендә яза вә сөйләшә икән ләбаса! Мин дигән малай, түтәй, әтәй-әнәй, Олы жиңги, Галиәттәй... Менә сиңа вәйт—безнең Дусай, күрше Тулбай, Шәмәк, Тәкәнеш авыллары турында да язылган икән бит әле монда!

Әлеге китапны укып чыкканнан соң, язучы дигән бу илаһи жан иясе минем өчен үтә якын, үтә үз, хәтта әйтер идем ки—үземнең бабамдай тоела башлады. Менә бит ул нишләтә—гап-гади, әмма хис белән акыл бергә үрелеп барган саллы сүз вә жөмләләрнең куәте-кодрәте!

Мәктәбебездә исә безне Шәйхи Маннурның эре хәрефләр белән язып куелган дүртьюллык шигыре каршы ала иде:

*Татарчаны да яхшы бел!*
*Русчаны да яхшы бел!*
*Икесе дә безнең өчен*
*Иң кирәкле, затлы тел!*

Бәлки әле ул чагында ук әдип татар телен рус теле белән бер дәрәжәгә күтәрү өчен киләчәктә хәл кадәри гамәли адымнар ясарга тырышачагыбызны чамалагандыр, шуңа өметләнгәндер. Һәрхәлдә, илдәге татар баласы укыган барча мәктәпнең иң түренә язып элгәндәй зирәк сүзләр бу.

...Инде янә берничә елдан соң безнең Олыяз—Тәкәнеш төбәгенә ел саен унбишенче гыйнварда төркем-төркем язучылар кайта башлады. Туган авылы Тулбай зиратында жирләнгән каләмдәшләре Шәйхи Маннурның кабере алдында баш ияргә кайталар иде алар.

***

Татар әдәбиятының күренекле вәкиле Шәйхи Маннурның тууына 100 ел тулган бу көннәрдә Мамадыш төбәгенә янә язучылар кайтты. Инде ике дистә елдан артык биредә әнә шулай 15 гыйнварда олуг әдибебезнең туган көне тантаналы рәвештә билгеләп үтелә, үзе васыять иткәнчә, яшь язучыларга, югары хезмәт күрсәткечләренә ирешкән якташларына аның премиясе тапшырыла. Төрле елларда бу бүләккә лаек булган һәм бүгенге көндә әдәбиятыбызның әйдәп баручыларына әверелгән кайбер исемнәр: Зөлфәт, Марсель Галиев, Рашат Низамиев, Мөдәррис Вәлиев, Нәбирә Гыйматдинова, Газинур Морат, Рафис Корбан, Зиннур Хөснияр, Ләбиб Лерон, Алмаз Гыймадиев...

***

Шәйхи Маннур—әдәби хезмәтләре өчен 1939 елда ук Хезмәт Кызыл Байрагы орденына—ул чагында илнең иң олы бүләгенә—лаек булган беренче татар шагыйре. Атаклы «Гайжан бабай» поэмасы, йөзләгән шигырьләре, лирик повестьлары, «Муса» романы белән халкыбыз күңелен яулаган әдип ул. Сүз уңаеннан, «Муса» романының бер өлешен ул, туган авылы Тулбайга кайтып, шунда ай дәвамында яза.

Шәйхи Маннур—бар гомерен иҗатка, әдәбиятка багышлаган шәхес. Һич тә гаҗәп түгел: туры һәм төртмә сүзле, уйлаганын ярып әйтә торган, бик тә принципиаль бу әдипне байтак кына яшь каләмдәшләре әле бүген дә үзләренә үрнәк вә остаз итеп саныйлар. Әмма ни гаҗәп: шигърият сафлыгы сагында торган әдипнең менә бу сүзләре һәр заман өчен дә искермичә яңгырый икән ләбаса:

*Сак булыгыз, гамьсез гулливерлар,*
*Лилипутлар килә шигырьгә!*

***

Шәйхи Маннур—вафат булгач та җәсәден туган авылы зиратына күмәргә, каләм хакыннан җыелган бар акчасын яшь язучыларга премия итеп бирергә васыять калдырган, әле исән чагында ук үз акчасына туган авылында китапханә төзеткән беренче татар язучысы. Мөгаен, әнә шул рәвешле ул туган төбәгенә башкалабызның игътибарын юнәлтергә тырышкандыр. Шөкер, зирәк әдип морадына ирешкән дә! Бит, уйлап баксаң, Казан—гаять зур эш-гамәлләргә сәләтле, кодрәтле урын. Мамадыш төбәгендәге соңгы ике дистә елдагы уңай үзгәрешләрдә, алгарышта Шәйхи Маннурның да өлеше бар, дип исәплим мин. Әйткәнемчә, инде чирек гасыр дәвамында татар язучылары өлкән каләмдәшләренең истәлеген олылап аның туган ягына кайталар һәм шул дәвердә Мамадыш төбәге, аеруча Олыяз-Тәкәнеш яклары, күзгә күренеп үзгәрде. Биредәге һәр авылга төзек, шәп юллар илтә, газ-су кергән, һәр авылда кибет, мәктәп, балалар бакчасы, медпункт, мәдәният йорты, мәчет балкып утыра. Иң мөһиме—Шәйхи Маннурның олпатлыгын гына түгел, ә бәлки аны хөрмәтләп кайткан язучыларны да таный-олылый белә торган житәкчеләр эшли биредә. Әдип үзе тәрбияләгән житәкчеләр! Шәйхи Маннурның



*Шәйхи Маннур—якташлары белән Тәкәнеш сабан туенда. 1969 ел.*

Тулбае да кергән "Чулпан" колхозы белән байтак еллар Галимҗан ага Җиһаншин җитәкчелек итте. Язучыларны олылый белү гадәте дә, минемчә, аннан башланды. «Аллага шөкер»,—диик, хәзер бу гадәт чын мәгънәсендә күркәм традициягә әверелде. Галимҗан аганың шәкертләре Ривал ага Гыйззәтуллин, Фәрит Хисмәтовлар да күркәм гамәлләре белән халык хөрмәтен казандылар. Сүз уңаеннан, төп әдәби журналыбыз «Казан утлары»н да бу як халкы һәрдаим яздырып ала, яратып укый.

Мәгълүм булганча, Шәйхи Маннур үзе дә заманында безнең журналда *(ул чагында—«Совет әдәбияты»)* эшләгән.

Янә шунысы куанычлы: заманында Мамадыш районын житәкләгән, язучыларның җәмгыятьтәге урынын, сүз җегәрен таныган-хөрмәтләгән Фатыйх Сибагатуллин, Экзам Гобәйдуллиннар бүген республикабыз күләмендә абруй казанган шәхесләр. Районның хәзерге хакиме Рөстәм Кәлимуллин да алар чорында башланган күркәм гамәлләрне уңышлы дәвам иттерә.



*Түбән Ушмы урта мәктәбенең унынчы сыйныф укучысы Зиннур Мансуров һәм шагыйрь Мәхмүт Хәсәен. Мамадыш шәһәре, «Агымсу» әдәби иҗат берләшмәсе. 1965 ел.*

Шәйхи Маннур Мамадыш районында туып-үскән яшь каләмдәшләренә дә һәрдаим игътибар юнәлтеп, хәерхаклы булып, ярдәм итеп яшәде. Район газите каршындагы «Агымсу» әдәби иҗат берләшмәсен дә әүвәл ул оештырып җибәрә. Казаннан тәҗрибәле-олпат әдипләрне алып кайтып, алар белән бергә әдәби иҗатка тартылучы яшьләргә кинәш-табыш иткән кеше ул. «Агымсу» да яшьли каләм чарлап үскән Ринат Мөхәммәдиев, Зиннур Мансуров, Нәзифә Кәримова, Шаһинур Мостафин, Рафаил Газизов, Вәрис Гали һәм дә янә дистәләгән әһле каләм якташ агаларын остазы итеп саный.

...Һәр ел саен унбишенче гыйнварда Мамадыш каласының кыл үзәгендәге Шәйхи Маннур һәйкәле янында шигырь бәйрәме үткәрелә. Монннан егерме еллар элек куелган бу һәйкәлнең дә үз тарихы бар. Аның авторы—Бакый Урманче үзе. Казан компрессорлар заводында бик тә затлы чуеннан коелган мондый һәйкәл—Россиядә бердәнбер. Беркайчан да тутыкмый, уалмый торган мәңгелек бу һәйкәлне заводның ул чагындагы директоры, милләтпәрвәр шәхес Әхмәт ага Галиев җитәкчелегендә бик тә үзенчәлекле алым-технология нигезендә койганнар. Хәер, бу хакта Әхмәт ага үзе дә *(«К.У.»ның 1998 еллагы 2 саны)* язып чыкты.



*Шәйхи Маннур һәйкәле янында уздырылган шигырь бәйрәменнән соң. Мамадыш шәһәре. 15 гыйнвар. 2003 ел.*

***

*«Ник янасың?»—диләр дуслар миңа,*
*Яшь алмыйм шул мин янмыйча.*
*Кешеләрнең күңел почмагына*
*Энҗедәй дә якты салмыйча»—*

дип язган Шәйхи Маннур моннан нәкъ ярты гасыр элек.

Гомере буе татар әдәбиятына, халкына хезмәт иткән әдип әлеге шигъри шигарена һәрдаим тугры калды. Милләтен, Ватанын, туган төбәген сине онытмый, кадерене вә каберене белә, яд итә икән, димәк, гомерен дә әрәмгә үтмәгән.

**Марат ЗАКИР**

# Алмаз Хәмзин

## ҮТТЕ ГОМЕРЛӘР

ХИКӘЯЛӘР, ПАРЧАЛАР

### ГАРМУН БЕЛӘН СӨЙЛӘШҮ

Гармуным минем! Ә син бүген үзенә илле яшь тулганын беләсеңме? Әтием сине миңа биш яшь тулган көнне юбилеема бүләк итеп: "Үземә алып бирмәделәр, мә, улым, уйна!"— дигән иде. Менә хәзер синә илле яшь, миңа илле биш. Үтте гомерләр... Әйдә, билгеләп үтәбезме?! Эндәшмисең. Син гел эндәшмәдең, моңландың гына. Шул эндәшмәвең белән акыллы булып калдың, ә мин җүләрлыгырдык Хәмзин, һәрвакыт дөресен сөйләп, туры әйткән туганына ярамаган, дигәндәй, бернәрсәсез калдым. Болай барса, пенсия дә бирмәсләр... Властька тегеләр кайтса гына инде...

Билгеле, синең Кирам Сатиев кулында уйналасың килгәндер инде, теге атказанган артистны әйтәм, яки Гран-при алган Рөстәм Вәлиев кулында. Ну, килеп чыкмады. Болтун Хәмзингә эләктең. Шулай да без үз эшебезне эшләдек. Авылдашлар: "Син булганда авылыбыз моңга күмелеп тора иде",— диләр. Иренми идек без синең белән урамнар әйләнергә. Ул Сабантуйлар! Ул яшьләр уенында ярыштырып биетүләр. Печән өстендә тургай моңнарына кушылып сайрауларың! Беренче мәхәббәт! Сөйгән кызларымны, йөрәк сагышларымны син генә беләсең, гармуным минем!

Бергә булган кичләр,
Без кичергән хисләр
Хәтерләтә монсу кояш баешын.
Капка төпләрендә,
Тамды күкрәгемә
Ачы күз яшьләрең, калды сагышың.

Әй типтерә идек тә инде яшь чакта! Ул "Чарльстон", "Твистларны".

Джон в Америке родился,
Джон в Америке и рос.
Джон в Америке женился,
Джон в Америке подох...

Армиягә дә бергә киттек. Сынатмадык. Урысларны чәчтереп кенә ыргыта идек җырлап. Тавыш бар.

Путь далек у нас с тобою
Веселей, солдат, гляди!
Вьется, вьется...

Армиядән кайткач, байтак кына буйдак булып йөрергә туры килде. Разве синең

белән өйләнеп була?! Гел кочактан төшмисен бит син! Авылдагы Фәхразый кызы Нурдидә бөтен кеше алдында рисвай итеп: "Гармунына гына өйләнерсең инде, карт алаша",— диде.

Әти гармун алып бирсә дә үзе: "Артист булма!"— дигән иде. Булынды шул, минем үземнең дә ният юк иде. Әлфия Авзалованың кечкенә чагымда башымнан сыйпап үтүеме, әллә Илһам Шакировның студент чагымда әйткән жылы сүзе мине шушы сәхнәләрдә тинтерәтеп йөртә инде... Гомерем булса, шулар янына басып гармунда уйнармын дигән идем. Бәлки синең дә хыялың шундый булгандыр. Их, булмады шул, булмады! Кирамнар, Рөстәмнәр, Рамилләр булып булмады.

Сөйгән кызлар күп иде минем. Беләсең син аларны. Казанга килгәч танышкан Ранияне дә синең белән саташып йөрүем куркытты ахрысы, ун ел да йөрмәдек: "Гармунына сәлам әйт!"— диде дә, кияүгә ычкынды.

Хәзер, Аллага шөкер, өйләндем, балалар да бар. Рания дә күренгәли, хатын да канәгать. Жырлар язабыз. Әле беркөн авылдан теге Нурдидә шылтырата: "Кил син, кил син, үзең кил..." дигән жырыңны син кемгә багышлап яздың?"— ди. "Сина!" — мәйтәм. Жылады да жибәрде. Рания дә сорады кемгә яздың дип. "Сина",— дидем. Хатынга да... Жылыйлар.

Менә шулай, дустым гармун! Музыканың көче зур аның. Миннән башка сине мактамаслар, мактыйм әле үзеңне һәм туган көнең хөрмәтенә сиңа "Алмазның халык гармуны" дигән мактаулы исем бирәм. Мәңге яшә, күңелләрне шатландыр, гармуным минем, яшьлек юлдашым!

## КАЙДА СИН, ХӘМЗИН?

Кемгә ничек, жәмәгать, без гастрольгә чыкканда Хәмзин очраса юл унмый. Бер вакыт Пермьгә киттек. Ул жәфаланулар: көн салкын, һава юеш, ач-ялангач... Килеп төштек, ни каршы алучы, ни куып жибәрүче юк. Телевизорда скрипка да скрипка, скрипка да скрипка... Брежнев үлгән икән. Биш көн яттык, ятмый нишлисең, куммичә концерт куйдыртмыйлар...

Күп тә үтмәде, гастрольгә Оренбургка юнәлдек. Качып кына китеп барадыр идек, кайлардан тагын шул Хәмзин очрады. Ни калган соң аңа вокзалларда?... Киттек инде, билет алынган. Ул жәфаланулар: салкын, юеш, ач-ялангач. Ни каршы алучы, ни куып жибәрүче юк. Телевизорда скрипка да скрипка, скрипка да скрипка— телем-телем теләү үзәкне. Ни-нәрсәгә юрарга моны, дисәк—Андропов үлгән икән. Биш көн яттык, ятмый нишлисең. Куммичә концерт куйдыртмыйлар. Ярый, монысы да шулай узды.

Кайтып бераз хәл алгач, тагын гастрольләргә китәргә йөрибез. Иртәгә китәбез, дигән көнне Хәмзин очрады. Бармадык. Ничек барасың инде, куралэтә... Китәсе көнне ни күрик, Хәмзин телевизорда—сурәте генә. Алайса, бернәрсә дә булмас дип, Чиләбегә ычкындык. Ул жәфаланулар: салкын, юеш, ач-ялангач... Ни каршы алучы... Телевизорда скрипка да скрипка... Черненко үлгән икән. Биш көн яттык. Ну бу Хәмзинне!...

Тагын шулай Ижауга барырга кирәк булды. Бер көн качып йөрибез, ике көн— юк Хәмзин. Ниһаять, поездга утырыр алдыннан соңгы тапкыр вокзалга морожный алырга керсәк, Хәмзин чыгып килә.

Билет алынган, акча түләнгән. Гел начар булмас әле дибез. Ул жәфаланулар... Килеп төштек... Телевизорда балет та балет, скрипка да скрипка. Чыдасың гына үзәк! ГКЧП икән. Переворот. Өч көн яттык. Ятмый нишлисең? Уен эш түгел. Тынычланмыйча концерт куйдыртмыйлар.

Соңгы вакытларда, никтер, очрамый әле Хәмзин. Гастрольләр дә юк. Акча да... Очраса ярап торыр иде. Түзәр идек әле дүрт-биш көнгә, айлар буе түзәр идек. Әй, Хәмзин, син кайда? Иртәгә Мәскәүгә китәбез. Чык әле каршыга, пажалысты! Ялындырма инде, ялындырма, Хәмзин! Иртәгә Мәскәү поездына кил, иркенләп озат әле! Көтәбез, Хәмзин! Юлыбыз унмаса унмас, кил! Вокзал тәрәзәләреннән генә булса да кара! Коткар безне! Без сиңа матур жырлар жырларбыз!..

# КЫСТЫБЫЙ ТУКТАЛЫШЫ

Абый, жаным, ал инде пажалыстә? Кап-кайнар кыстыбый! Нуршания, кызым, бар йөгер, әнә, Казаннан автобус килә. Гимадиягә махы бирмә! Гел аңа гына димәгән монда... Абый, жаным, кыстыбыйны машинаңа илтеп биримме? Хатынын бигрәкләр чибәр икән? Безнең татар хатыннары матур шул. И балаларың, күзләр тимәсен! Тфү, тфү! Абый, жаным, ничәне төрим, балалар бик ярата ул кыстыбыйны. Әйе шул, әйе шул, өйдә пешерсән кабып та карамыйлар, ә монда, ә монда шудыралар гына.

Мөжидә, нәрсә карап каттың, шул әрмәнгә? Әнә автобусың килеп туктады, Гимадиядән алдан илтеп тык кыстыбыеңны берәрсенең авызына! Мөжидә дим, Мөжидә кая кирегә чабасың?! Әнә, Чаллы автобусы, шунда йөгер! Беренче бул!

Абый, жаным, ал инде пажалыстә, ничәне төрим?! Бүгенге, бүгенге, әле генә пешереп китерделәр. Ирем ташып тора. Абый жаным, и абый жаным! Юлларыңа ак җәймәләр сина, борма саен бәхет көтеп торсын, сикертмә саен шатлыгың артсын, син узган урманнарда сандугачлар сайрап озатып калсын, каршы искән җилләрдән сөенечле хәбәрләр килсен, унай искәннәре сөйгәннәрең белән күрештерсен, хатынына әйбәт ир телим, балаларың зимагур була күрмәсен!

Бик майлы, дисеңме? И, жаным, гәжит бар бит, гәжит нәрсәгә?

Майлы нәрсә ярамый, дисеңме? Нишләп май булсын. Үз парында үз юеше генә ул. Ничәне төрим? Әни пешерә, әйе, әйе, әни пешерә! Эти булыша. Сыерыбыз бар. Җиде сыерыбыз, житмеш сарыгыбыз бар, абый жаным!

Врачлар кайнар кыстыбый ашарга кушмыйлар, дисеңме? Шулаймыни?! Әй, абый жаным, ничекләр кайнар булсын инде ул иртүк килгән кыстыбыйлар?! Суынып беттеләр инде алар күптән. Көне дә суык бит. Врачларга каршы килергә ярамый, врачлар белеп әйтә. Менә мин үзем, абый жаным, беркайчан да кайнар әйбер ашамадым. Кайнардан бит, абый жаным, теге "кысла" авыруы барлыкка килә ди. Менә мин шул авыруга каршы чиснук ашыйм. Кыстыбыйга да кушкалап җибәрәм. Абый жаным, ничәне төрим?

Нуршания, Гимадияне тыгылдырма алдыңа! Нахал! Болай да ике машиналары бар бит инде, трактор алабыз, дигәч тә ул хәтле. Төрт, касыгына төртеп җибәр, кертмә алдыңа!

Бик салкын кыстыбый туже ярамый дисеңме? Нишләп салкын булсын ди ул. Төреп кенә тотам. Кыстыбыйларым менә дигән. Алсуланып, кызарып пешкәннәр. Салкын кыстыбый сатырга кем дип белден син мине. Аллам сакласын, гөнаһлы булыр хәлем юк, Ходай каршында. Минем әле ожмахка керәсем бар. Менә, менә төптәнрәк алып бирим әле, жып-жылы. Абый жаным, ничәне төрим?

Мин сина абый да түгел дисеңме? Абый жаным, бездә әйбәт кешегә һәрвакыт абый дип эндәшәләр. Абый жаным, борыныннан жон чыгып тора, өзеп алыйм әле. Ату ямьсез! Үзең бик матур бит син, абый жаным! Чалбарынның төймәсен каптырмагансың, абый жаным, үзем төймәлимме?

Чалбарыңда синең, бер төймә, нигә төймәләмисен?..

Абый жаным, биеп тә күрсәтимме?! Абый жаным, ал инде кыстыбыемны, ничәне төрим?

Мөжидә, Мөжидә, аяк чал, аяк чал Гимадиягә, түгелсен, чукынсын сөте. Бас, бас, кыстыбыена бас!

Абый жаным, ничәне төрим? И, абый жаным, үзебезнең мөселман кыстыбый ярата шул. Иртәгә шешәләргә тутырып сөт тә алып килэм әле. Кыстыбыйны безнең якта сөт белән ашыйлар. И, тәмлелекләре шунын. Абый жаным, бармы синең жанын? Ничәне төрим?

Гимадиянең сыерлары чирле аларның. Сөтен ала күрмә! Үзләре дә эчмиләр. Монда чыгарып саталар. Кыстыбыйларын да ала күрмә. Камырын шул сөттән баскан бит инде аның.

Бик беләсең килсә, жаныкаем, кыстыбый ашамаган кеше ул дөньяда иң бәхетсез кеше. Мин шуңа күрә Америка президентын да, ничек әле исеме, Клинтонны да

бик бәхетсез кешегә чутлыйм. Абый жаным, ничәне төрим?

Иснәп карале! Исе нинди бит! Исе! Монда тирә-юнь урманнарынын шифалы дымы, чәчәкләренен ин ләззәтле балы сеңгән! Камырын кара! Камырын—коймак оныннан, өстәп гыйрак куркәсе кукәе сытылган, эче Голландский бәрәңгедән, мае ландыш чәчәкләре генә ашап йөргән үзебезнен сыердан. Сыерыбыз Аргентин токымы! Үгезебез—шведский. Абый жаным, ничәне төрим?

Нуршания, ташла әле шул әрмәненне! Автобуснын эченә үк кер! Мөжидә! Үткәрмә Гимадияне! Үткәрмә, тарт итәгеннән, жыртылса сон, жыртылсын.

Бәрәнгеле ризык белән генә тамак туймас дисенме? Иснәп карале син, иснәп карале! Син бит әле иснәмәден. Парланып пешкән бозау ите исләре! Их, абый жаным! Иснәле син, иснәле!

Итле кыстыбый булмый, дисенме? Нишләп булмасын! Ничек кенә була әле, жаныкаем, ничек кенә була. Әле белмисен икән.

Карале, шаяртырга да ярамый икән тагы. Нишләп кыстыбыйда ит булсын ди инде... Әле ул, жаныкаем, бездә өчпочмакка да итне бик чамалап кына салалар. Гимадияне син өчпочмакка ит сала дип уйлыйсындыр? Шиш сала ул өчпочмакка ит! Тот капчыгынны. Өчпочмакка ит түгел, кыстыбыена бәрәнге дә салмый әле ул!

И-и-и, абый жаным, ал т и з е р ә к, әнә тагын бер "жигули" килә.

Нуршания, Мөжидә, нәрсә күзегезне тондырып һаман шул әрмәнгә карап торасыз. Борын кемдә дә борын инде ул! Әрмән, уйди отсюдово! Абый жаным, ал инде, ничәне төрим? Абый жаным, бөтен гаиләмне бер үзем тартып барам: ирем эчә, әти эчә, ике кызым әнә әрмәнгә карап баккан, тыңламыйлар, бөтен авылга бер жүнле мужик юк. Әрмән, дим, уйди отсюдово! Не гляди на моя девушка!!

Абый жаным, әйдә вакыт уздырма, ничәне төрим? Дүрт сумга лучше булки алып ашыйм, дисенме? Соң алай булгач ни пычагыма башымны катырып торасын?

Пес итәргә туктаган идем, дисенме?

Минме мишәйтлим? Минме юлына аркылы төшәм?! Бик кирәген бар иде. Сигәк! Саран! Дүрт тәнкә жәлләгән кешене мин мужикка да санамыйм.

Бар, бар, баруынны бел! Куак арасына, урман саргайтучы, әнә, синен кебек ашамас борын эче китүчеләргә бәдрәф житкереп куйдылар. Машинанда утыручы килбәтсез маржан үз хатынын да түгелдер әле. Йөрисендер әле кеше балалары үстереп. Юлларында көпчәгенә кадак кергере! Белденме?! Пес итәргә туктаган ул... Туктамаска иде.

...Әй, кемгә кыстыбый, кемгә кыстыбый?!

Мөжидә, Нуршания!..

## *«Казан утлары» архивыннан*

ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР БЕРЛЕГЕНЕҢ
ЧАЛЛЫ БҮЛЕГЕ ОЕШУГА 25 ЕЛ



*Чаллы Язучылар бүлегенең оештыру җыелышыннан күренеш.*
*Президиумда **Гариф Ахунов, Эдуард Касыймов** (җитәкче), **Талгат Галиуллин.***
*Январь, 1980 ел.*



*Оештыру җыелышында зал күренешеннән: сулдан уңга—*
***Риф Якупов, Равил Вәлиев, Нәҗип Мадьяров, Рәшит Бәшәр, Мәхмүт Газизов;***
*икенче рәттә—*
***Рәүф Гыйззәтуллин, Фаяз Дунай, Ирек Диндаров, Кадыйр Сибгатуллин.***
*Январь, 1980 ел.*



*Рәсемдә—Чаллы Язучылар бүлеге әгъзалары һәм Казаннан килгән язучылар. Чаллы язучылар оешмасының яңа җитәкчесе итеп Разил Вәлиев сайланган җыелышта алынган фото. Май, 1981 ел.*



*Оешма җитәкчесе булып Ризван Хәмид эшләгән чордагы рәсем. Чаллы һәм Казан язучылары очрашуы. Сулдан уңга, арткы рәттә—* ***Марсель Галиев, Ризван Хәмид, … Гәрәй Рәхим, Вахит Имамов;*** ***утырганнар— Рашат Низами, Рөстәм Мингалим, Рахмай Хисмәтуллин.*** *1986 ел.*



*Шигырь бәйрәме көнне алынган рәсем. Сулдан уңга:* ***Факил Сафин, Нияз Вәли, Рафис Сәлимҗан, Рахмай Хисмәтуллин*** *(җитәкче),* ***Ямаш Игәнәй, Бари Дәүләтгәрәев, Мирһади Разов.*** *Апрель, 1996 ел.*





*Чаллы язучылары Вахит Имамов (җитәкче),* ***Факил Әмәк*** *Мөслимдә язучы* ***Флүс Латыйфиның*** *юбилей кичәсендә. Октябрь, 2003 ел.*



## Ренат Гаффар

*Ренат Габрахман улы Гаффаров 1951 елның 11 нче апрелендә Балык Бистәсе районының Олы Әшнәк авылында туа. Күпләгән каләм ияләренә канат биргән Олы Солтан урта мәктәбендә белем алып чыкканнан соң Казан дәүләт университетының журналистика бүлеген тәмамлый, һәм укытучысы, остазы Гази Кашшаф фатихасы белән "Социалистик Татарстан" газетасына (КПССның Татарстан өлкә комитеты органы) эшкә чакырыла. Шушы редакциядә 20 ел эшләве дәверендә яшь авторның республикада чыга торган төрле газета-журналларда (шул исәптән, "Казан утлары"нда да) байтак хикәяләре дөнья күрә, Татарстан радиосында еш яңгырый. Аның үзенчәлекле көлкеле әсәрләр иҗат итәргә һәвәсләнеп китүе, иҗади яктан ачылуы да шул елларга туры килә. Сатира-юморда фәкать үз стилен булдырырга омтылганлыгы, үзгәлеге белән укучыга (шул исәптән, тамашачыга — Равил Шәрәфи аның әсәрләрен сәхнәгә менгерде) якын ул. Төртмәле хикәяләре, эстрада миниатюралары кертелгән "Калай түбәдә эт эзе" дип исемләнгән юмор китабы 2004 елда Татарстан китап нәшриятында аерым китап булып дөнья күрде. Язучы балалар өчен "Яшен ташы" һәм өлкәннәр өчен "Әти чапкан печән исе" дип исемләнгән яңа китапларын әзерләп бетерде. Алар киләсе елларда басылып чыгарга тиеш.*

*90 нчы еллар уртасында "Татар иле" газетасында берара баш мөхәррир булып эшләгән каләм иясе бүгенге көндә "Мәдәни җомга" атналык газетасының әдәбият бүлеген җитәкли.*

*Татарстан Язучылар берлеге 2004 елның ноябрь аенда уздырылган утырышында Ренат Гаффарны Татарстан Язучылар берлегенә әгъзалыкка кабул итте (тәкъдимнамә бирүчеләр: Барлас Камалов, Шамил Рәкыйпов һәм Рашат Низами).*

# Ictimagi-mədəni tormışıbızdan
# Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан

## ИЛБАШЫ ФИКЕРЕ

### Ике телне белү мөһим

Татарстан Президенты Минтимер Шәймиев РФ Конституция Суды тарафыннан татар һәм рус телләренең тигез күләмдә укытылуының Россия Конституциясенә каршы килү мәсьәләсе каралуның республикабыз өчен мөһимлеген ассызыклады. Шуны исегезгә төшерәбез: 16 ноябрьдә Конституция Суды республиканың мәгариф учреждениеләрендә ике дәүләт теленең бер күләмдә укытылуы турындагы Татарстан законнары норматив нигезләмәләренең легитимлыгын таныды.

Республикабызда ике дәүләт теле булганга, Конституциябез нигезендә без аларның икесен дә белергә тиеш. “РФ Конституция Судының әлеге мәсьәләне чишүгә аңлап якын килүе бик яхшы, ул хокукларыбызны раслады,—диде Татарстан Президенты.—Бу проблема мине бик борчый иде,—дип сүзен дәвам итте ул.—Әгәр башка төрле карар кабул ителгән булса, моның хәтта гаиләдә дә фикер төрлелегенә китерүе бар иде. Республикабызда барлык өйләнешүчеләрнең өчтән бере—катнаш гаиләләр, һәм алар өчен дә бу проблема һәрвакыт кискен тора. Ата-аналарның кайберләре бала ике телне дә белергә тиеш дип исәпли, икенчеләре исә моны мөһимгә санамый. Минтимер Шәймиев фикеренчә, ике телне дә белү—тынычлык һәм килешү юлы. Мәсәлән, оныкларның ике як әби-бабайлары белән алар телендә сөйләшүе гаиләләрне берләштерә, аларны бәхетле итүгә булыша. Шуңа күрә дә әлеге мәсьәләгә мин конструктив якын киләм. Укучыларга телне өйрәнү нинди зур йөк булып төшүе исә, икенче мәсьәлә. Бу республикабызда яшәүче башка милләт вәкилләренә дә кагыла. Без программалар эшләү һәм балаларыбызның уку процессын килештерелгән нигездә алып бару өчен дә барысын да эшләрбез,—диде Минтимер Шәймиев.

### Без латиннан баш тартырга җыенмыйбыз!

РФ Конституция Судының республикаларның үз теле язма рәвешен мөстәкыйль билгеләү хокукына карата чыгарган карарына Татарстан Президенты М.Шәймиев үз мөнәсәбәтен белдерде. Аның фикеренчә, бу карар Татарстанны әлеге проблема белән шөгыльләнү хокукыннан мәхрүм итми. Димәк, бу—киләчәктә әлеге мәсьәлә федераль закон кабул итү аша җайга салынырга мөмкин, дигән сүз.

“Татар телен латин әлифбасына күчерү турындагы карарны, I Бөтендөнья татар конгрессы карарларын гамәлгә ашыру йөзеннән, ТР Дәүләт Советы кабул иткән иде. Әлеге карарларга Дәүләт Советы да, Республика Президенты да, әлбәттә инде, колак салмый кала алмады. Карар иң элек, ерак чит илләрдә яшәүче татарлар йогынтысында кабул ителде. Чөнки аларга латин әлифбасы мирасы буыннан-буынга күчеп килә. Шулай ук бүгенге көннәрдә күп кенә илләрдә латин әлифбасы нигезендәге инглиз телен куллану да зур роль уйнады. Әмма республика эчендә латин әлифбасына күчүнең ни дәрәҗәдә вакытлы булу-булмавы җәһәтеннән әлегәчә бердәм фикер юк. Мин, бу мәсьәләне ахыргача уйлап бетерү өчен, кайда яшәүләренә карамастан, иң элек татарларның үзләре арасында уртак аңлашуга килү өчен вакыт кирәк, дип исәплим. Бу мәсьәләне җентекләп өйрәнергә кирәк. Юкса без, бер яктан, бөтен дөнья татарлары белән рухи бердәмлекне сакларга тырышып, икенче яктан, калган барлык татарларны үзебездән аерачакбыз—алар татар телен кириллицада, ә Татарстан латин әлифбасында өйрәнүне һәм язуны дәвам итәчәк. Бүген Татарстан латинга күчкән тәкъдирдә, мисал өчен, Башкортстан татарларына нишләргә (ә алар бу республикада миллионнан артыграк бит)? Бу—Башкортстан парламентына яки татарлар яши торган башка төбәкләрдәге законнар чыгару органнарына тиешле карар кабул итәргә кирәк булачак, дигән сүзме? Ә бүгенге көндә татарларның күпчелеге кириллицадан файдалана бит.

Бу, әлбәттә, латиннан баш тартуны аңлатмый. Мин, республика бу җәһәттән, экспериментын дәвам иттерәчәк, дип уйлыйм. Ул әлеге мәсьәләне төптән аңлау һәм карар кабул итү өчен кирәк, чөнки биредә 7 миллионнан артыграк кеше язмышы турында сүз бара”,—диде Илбаш.

## ҖӘМӘГАТЬЧЕЛЕК ФИКЕРЕ

### Латин әлифбасына кайтуны яклыйк!

МӨРӘҖӘГАТЬ

Газиз милләттәшләр!

Россия Федерациясенең Конституция суды кабат безнең рухи мәнфәгатьләргә туры килми торган сәяси карар кабул итте. 2004 елның 16 ноябреннән соң татар әлифбасын, телнең иясе булган татар халкы үзе түгел, татар теленең яшәешен һәм язмышын хәл итүгә тулы вәкаләтле республика да түгел, ә халыкара хокукны санга сукмаган һәм Россия Конституциясен ихтирам итмәгән судьялар билгеләячәкләр. Безнең мәнфәгатьләрне яклау өчен дәүләттә бер мөмкинчелек тә калмады. Бу хәлдән соң, хәзер барлык ышанычыбыз һәм өметебез бары тик үзебезнең көчкә һәм ихтыярга бәйле.

Мәгълүм хакыйкать: халыкара кануннар буенча һәрбер халык үзенең телен һәм мәдәниятен үстерү юлларын ирекле рәвештә сайлау хокукына ия. Татар халкына латин имлясын тыю—шул хокукка каршы һөҗүм, дигән сүз. Әгәр моңа юл куйсак, алга таба республикаларның дәүләт телләренә кинәнмәсләрме, татар теле, гомумән, законнан тыш тел булып калмасмы. Бу һөҗүмнәрдән соң, мәктәпләрдә уку-укытуны тулысынча урысчага күчерүгә дә ерак калмый. Татарстан Республикасын бетерүгә Россия җитәкчелеге, шул исәптән Дума, ныклап кереште. Аны Ульяновск өлкәсе белән бергә кушып, Волга-Кама губернасы итү күздә тотыла. Әгәр дә без каршы тормасак, ул шулай булачак та.

Латин имлясы бүгенге көндә—халкыбыз һәм республикабыз язмышы өчен көрәшнең алгы сызыгына әверелде.

Гадел хөкем карарын без инде озак көттек. Әлегә булган мөмкинлекләрне ычкындырып, вакытыбызны әрәм итсәк, дөнья мәдәниятенең төп ызаныннан төшеп калуыбыз бик ихтимал. Үз сүзебездә тора белүебезне күрсәтер вакыт житте. Шуна күрә, кичекмәстән, мөстәкыйль рәвештә латин графикасын үзләштереп, аны гамәли куллануга күчик: мәктәпләрдә өйрәнүне дәвам итик, матбугат битләрендә латин шрифтында язу үрнәкләрен бирүне активлаштырыйк, интернет сәхифәләрендә үзара языйк... Конституция судының гаделсез карарына бездән җавап шул булыр. Милли горурлык тойгысы—ул безнең халкыбызга хас сыйфат. Аны югалтмыйк!

"Латин фронтына" тупланыгыз!

*"Мәгариф" ассоциациясе, Бөтендөнья татар конгрессы, Россия Федерациясе татарларының милли-мәдәни мохтарияте, Бөтентатар иҗтимагый үзәге, Татарстан Фәннәр академиясенең Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институты, Татарстан Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты, Татар ПЕН-үзәге, Татарстан Язучылар берлеге, "Казан утлары" журналы, "Мәдәни Җомга" газетасы, Татар халкының Милли Мәҗлесе, "Идел-Урал" иҗтимагый хәрәкәте, Башкортстан Республикасының татар иҗтимагый оешмалары берлеге (БР татарларының 22 иҗтимагый оешмасы исеменнән), "Ватан" җәмгыяте (Мәскәү), "Туган тел" җәмгыяте (Мәскәү), "Сарытау" татар мәдәнияте үзәге (Сарытау), Мәскәү Татар яшьләре советы, Бөтендөнья татар серверы TATARLAR.RU.*

## ЗУР ХЕЗМӘТКӘ—ЛАЕКЛЫ БӘЯ

Президентыбыз Минтимер Шәймиев "Россиянең Милли Олимпы" бүләгенә лаек булды.

Аңа милләтара һәм динара бердәмлек булдыруы, Татарстанны Европа дәрәҗәсендәге төбәккә әверелдергәне өчен "Ел Президенты" исеме бирелде. Башкалабыз Казан исә "Россия шәһәре—2004" дип аталды. Әлеге дәрәҗәле премия шәһәр хакимияте башлыгы Камил Исхаковка 20 ноябрьдә Мәскәүнең Кремль сараенда тапшырылды.

Шуны искә төшерү урынлы булыр: безнекеләргә мондый бүләкләр беренче тапкыр бирелми. Президентыбыз 2001 елда да "Ел Президенты" дип аталды. 1995 елда ук Камил Исхаков "Ел мэры" исеменә ия булды.

"Россиянең Милли Олимпы" премиясе төп иҗтимагый бүләк санала. Аны гамәлгә куючылар: федераль хөкүмәт, "Өченче меңьеллык" фонды, Фәннәр академиясе, Сәүдә-сәнәгать палатасы, Сәнәгатьчеләр һәм эшмәкәрләр берлеге, Бөтенроссия күргәзмә үзәге.

## ТАТАРСТАН МАТБУГАТЫ ХАЛЫКАРА КИМӘЛДӘ ЭШЛИ

Мәскәүнең Бөтенроссия күргәзмәләр үзәгендә XII халыкара "Матбугат—2005" күргәзмәсе узды. Анда меңнән артык вакытлы матбугат чаралары, типографияләр, мәгълүмат агентлыклары катнашты.

Әлеге күргәзмә-форум кысаларында "түгәрәк өстәл"ләр узды. Россиянең төрле төбәкләреннән килгән журналистлар һәм чит ил матбугаты вәкилләре Россиядәге медиа-базар, нәшрият бизнесы турында сөйләште.

Әлеге зур чарада Татарстаннан "Татмедиа" агентлыгы да катнашты. 70 кә якын мәгълүмат чарасын берләштергән стендны тәкъдир итүдә "Татмедиа" агентлыгы генераль директоры вазыйфаларын башкаручы Ф. Шаһиәхмәтов, Татарстан Дәүләт Советы Рәисе урынбасары, Журналистлар берлеге рәисе Р.Ратникова, РФ Дәүләт Думасы депутаты Ә. Кармиев һ. б. катнашты.

Очрашулар барышында "Россия Федерациясендә матбугат чараларына һәм китап басуга дәүләт ярдәме турында"гы федераль законның гамәлдән чыгуы җәһәтеннән зур сөйләшү булды. Ф. Шаһиәхмәтов төбәкләрдә матбугат чараларына ярдәм күрсәтү буенча җирле кануннар эшләү кирәк булачагын белдерде.

"Татмедиа" агентлыгының "Татарстан Республикасы матбугаты" экспозициясе ин яхшы дип табылды һәм безнекеләр XII халыкара күргәзмәдән диплом белән кайтты.

## МӘСКӘҮДӘ—ТАТАР СЪЕЗДЫ

27 ноябрьдә Мәскәүдә Башкортстан татарлары съезды булды. Мәскәү татарлары милли-мәдәни мохтәрияте бинасы булган Асадуллаев йортында үткән әлеге чараның көн тәртибендә төп мәсьәлә: Башкортстан татарларының региональ милли-мәдәни мохтариятен төзү һәм, әлбәттә, закон нигезендә теркәлү узу.

Съездга Башкортстанның 31 районыннан килгән 150 делегат тарафыннан кабул ителгән резолюциядә региональ мохтәрият төзелү сәбәпләре күрсәтелгән. Документта мондый юллар бар: "Беренчедән, республикадагы Татарлар—Россия Федерациясендә "үз" республикасыннан читтә яшәүче иң күп санлы җәмгыять (миллионнан артык кеше анда). Икенчедән, Башкортстанның бүгенге җитәкчелеге республикадагы барлык халыкларның хокукларын тигез күреп, татарларның милли мәсьәләләрен шул нигездә чишәргә теләми һәм, кызганыч ки, җирле хөкүмәт татарларның закон нигезендә үзләренә милли-мәдәни мәсьәләләрен чишү, мәнфәгатьләрен кайгырту өчен үзоешуларына каршы чыга. Шул сәбәпле, оешу съездын Мәскәүдә уздырырга булдык... Республика хакимиятенен кысуына да карамастан, республика район һәм шәһәрләрендә татарларның 31 җирле милли-мәдәни мохтәрияте оешты. Өч елга сузылган суд тикшеренүләреннән соң 2003 елда теркәлү узган Уфа милли-мәдәни мохтәрияте татар халкының милли-мәдәни мәнфәгатьләрен яклау һәм үстерү буенча эшен башлап җибәрде".

БТК Башкарма комитетының Россия Федерациясендәге татар иҗтимагый оешмалары белән эшләү бүлеге мөдире Фәрит Уразаев сүзләренчә, Башкортстаннан делегатларны татарлар съездына җибәрмәскә тырышуларына да карамастан, алар "Бердәм Россия" партиясе съезды узган бина янында пикет белән чыгып (съездның анысына, әлбәттә, Мортаза Рәхимов та килгән), таләпләрен җиткергәннәр һәм закон шартларына туры китереп, региональ милли-мәдәни мохтәрият төзүгә һәм теркәлүгә ирештеләр. Фидакарьлекләрен күрмәү мөмкин түгел, билгеле. Башкортстандагы татарлар өчен генә түгел, гомумән, тулаем татар тарихы өчен дә үзенчәлекле вакыйга бу. Шунысын да ассызыкларга кирәк: Россиядә 1996 елдан бирле милли-мәдәни мохтәриятләр турында закон гамәлдә булса да, хәзерге көнгә кадәр Башкортстанда әлеге законның эшли алганы юк иде. Шулай итеп, Башкортстан җирендә дә закон кысаларында татар мәнфәгатьләрен кайгыртучы янәча, конструктив эш башланды.

## ҖЫРЧЫ ЮБИЛЕЕ

Казанның С. Сәйдәшев исемендәге Зур концерт залында Татарстан, Каракалпак һәм Россиянең халык артисты Зилә Сөнгатуллинаның 55 яшьлек юбилеена багышланган тантаналы кичә узды.

ТР Премьер-министрының беренче урынбасары Равил Моратов юбилярны республика җитәкчелеге исеменнән котлап, Татарстан Президенты Минтимер Шәймиевнең Рәхмәт хатын укыды. "Сез талантыгыз һәм башкару осталыгыгыз белән тамашачылар күңелен Татарстан һәм Россиядә генә түгел, ә ерак чит илләрдә дә яулап алдыгыз. Яшь сәнгать әһелләрен тәрбияләүгә Сез керткән өлеш әйтеп бетергесез зур", диелә республика җитәкчесе котлавында.

Кичәдә Зилә Сөнгатуллина һәм аның шәкертләре, шулай ук Прага опера студиясе солисты Эдуард Трескин башкаруында операдан арияләр һәм романслар, халык җырлары яңгырады.

Зилә Сөнгатуллина 1973 елда Казан дәүләт консерваториясен тәмамлаганнан соң зур сәхнәгә аяк басты. Ул Муса Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет академия театрында куелган операларда төп партияләр башкарды, Габдулла Тукай исемендәге дәүләт премиясенә лаек булды.

Бүген профессор Зилә Сөнгатуллина Казан дәүләт консерваториясендә җыр кафедрасына җитәкчелек итә, тәҗрибәсе һәм белемен яшьләр белән уртаклаша.

## АЛИШ ИСЕМЕНДӘГЕ БҮЛӘК

Каһарман язучы Абдулла Алиш исемен мәңгеләштерү һәм балалар әдәбиятын тагын да үстерү ниятеннән берничә ел элек Татарстан Язучылар берлеге язучының туган ягы булган Спас районы хакимияте белән бергә әдип исемендәге бүләк булдырган иде. Ул балалар өчен язылган әсәрләре, китаплары өчен һәр ел саен балалар язучыларына бирелә.

Быел исә бу мәртәбәле бүләккә балаларга язылган шигырь китаплары өчен шагыйрә Мәрзия Фәйзуллина (ул күпьеллык иҗаты дәверендә балалар әдәбиятын үстерүгә зур өлеш керткән кеше), "Сабантуй" газетасында эшләүче шагыйрә Йолдыз Шәрәпова, балалар китапларын нәшер итүдә зур казанышлары һәм соңгы елларда А. Алиш иҗатын укучыларга җиткерүдә нәтиҗәле эшчәнлеге өчен "Мәгариф" нәшрияты коллективы (директоры—М. Җәлил исемендәге бүләккә лаек булган шагыйрь Мөдәррис Валиев) лаек дип табылды.

Шунысы күңелле: А. Алиш исемендәге бүләкне лауреатларга язучының туган төбәгендә тапшыру күркәм гадәткә

әйләнгән. Шушы максат белән 5 ноябрь көнне Татарстан Язучылар берлеге рәисе Фоат Галимуллин житәкчелегендә бер төркем язучылар—Галимҗан Гыйльманов, Мәрзия Фәйзуллина, Йолдыз Шәрәпова, Мөдәррис Вәлиев, Әхәт Хафизулла һәм күренекле җырчыбыз Рабига Сибгатуллина белән композитор, баянчы Фәрит Хатыйпов Спас районына юл тоттылар. Аларны район хакимият башлыгы Камил Әсхәт улы Нугаев каршы алды.

Башта язучылар А. Алиш туган Көек авылында булып (башка елларда лауреатларга бүләкләр дә шушында тапшырылган), анын һәйкәленә чәчәкләр салдылар. Аннан сон язучылар А. Алиш укыган Ямбакты авылы урта мәктәбендә укытучы һәм укучылар белән очраштылар. Лауреатларга Абдулла Алиш исемендәге бүләк тапшыру тантанасы да шушында узды. Язучылар, балалар алдында чыгыш ясап, үзләренең яна шигырьләрен укыдылар, мәктәпкә китапларын бүләк иттеләр, мәктәп музее белән таныштылар.

## ИСЕМНӘРЕ—КИТАПТА

"XXI гасыр хәйрия фонды" оешмасы Мәскәүнең "Авангард" нәшрияты белән берлектә Казан шәһәре хакимияте ярдәмендә "Гордость города Казани" дигән русча-инглизчә энциклопедик басма әзерли. Әлеге китапта бүгенге көндә исән-сау иҗат итүче йөздән артык күренекле шәхеснең исеме урын алачак.

Бу китап Казан юбилеена килгән кунакларга, шулай ук республика китапханәләренә һәм татар диаспораларына тапшырылачак.

## КОТЛЫЙБЫЗ!

***

Мәдәният өлкәсендәге хезмәтләре һәм күп еллар буе уңышлы эшләгәне өчен Татарстан Республикасы мәдәният министры **Тарханов Илдус Габдрахман улына**, Россия Федерациясе Президенты Указы нигезендә, "Россия Федерациясенең атказанган мәдәният хезмәткәре" дигән мактаулы исем бирелде.

***

Күпьеллык нәтиҗәле фәнни-педагогик эшчәнлеге өчен Башкорт дәүләт университеты укытучылары: татар теле һәм әдәбияты кафедрасы профессоры **Поварисов Суфиян Шәмсетдин улына**, татар теле һәм әдәбияты кафедрасы мөдире **Сибәгатов Радик Гали улына** "Татарстан Республикасының атказанган фән эшлеклесе" дигән мактаулы исем бирелде.

***

Удмуртиянең Воткинск шәһәрендә Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы, запастагы полковник, шагыйрь **Риза Закир улы Шәфиев (Риза Шәфи)** 2004 елның 3 декабрендә вафат булды.

## КИТАПЛАРНЫ—ПОЧТА АША

"Мәгариф" нәшриятында янадан-яна китаплар басылып тора. Яна гына "табадан төшкән" китапларны үзегездә булдырырга теләсәгез, әллә кая барып йөрисе дә юк. Бары тик нәшрият адресына, кирәкле китап исемен, авторын күрсәтеп, хат кына язып җибәрегез. 10-12 көн эчендә теләгән китабыгыз сезгә почта аша килеп ирешер. Ләкин почта аша китап алу якынча ике тапкырга кыйммәтрәк булуын искәртергә кирәк. Почта аша алырга мөмкин булган китаплар янына нәшрият бәясе куелган.

"Мәгариф" нәшриятында чыккан китапларны түбәндәге адреслар буенча сатып ала аласыз:

*Казанда:* **Бауман урамы, 19; Бауман урамы, 29/11 (Нур-маркет" кибетенең жир асты галереясы); Пушкин урамы, 3; Татарстан урамы, 13; Гвардейская урамы, 9а; Достоевский урамы, 13; Әмирхан урамы, 17; Сул Болак урамы, 42/2; Зур Кызыл урам, 68; Кремль урамы, 21.**

***Чаллыда:*** **Яңа шәһәр, 1 комплекс, 11; ГЭС поселогы, Центральная урамы, 9/3 б.**

*Түбән Камада:* **Школьная бульвары, 11/5.**
*Бөгелмәдә:* **М. Җәлил урамы, 42.**
*Лениногорскида:* **Куйбышев урамы, 37.**

Хат язу өчен нәшрият адресы:
**420111. Бауман урамы, 19 нчы йорт, а/я 447**

E-mail: **magarif@mail.ru**
тел.: (8432) 92-60-19
тел./факс: (8432) 92-57-48

## *Тышлыктагы сурәтләр*

*Тышлыкның беренче битендә:* Гасыр сәгате. Казан, Бауман урамы.
***Н. Исмәгыйлев фотосы.***

*Тышлыкның дүртенче битендә:* шагыйрь **Шәүкәт Гаделша**.

# ЯҢА КИТАПЛАР




Риза ФӘХРЕДДИН. **Нәсыйхәт** (әхлак гыйлеменнән дәреслек-кулланма).—Казан: "Мәгариф" нәшр., 2004. —104 б. Тиражы—1000 данә.

Бу китапка мәшһүр татар галиме Ризаэтдин бине Фәхреддиннен (1859-1936) "Нәсыйхәт" исемле төрле елларда, төрле шәһәрләрдә зур тиражлар белән басылган өч китабы бергә туплап бирелде. Халкыбыз тарафыннан дистәләрчә гасырлар дәвамында тупланып һәм басылып, ислам дине белән сугарылып килгән халык педагогикасына нигезләнеп язылган әлеге дәреслек-кулланма—һәртөрле һәм һәр дәрәҗәдәге тәрбия оешмаларында, уку йортларында эшләүче һәрбер тәрбиячегә, һәрбер укытучыга, ата-аналарга һәм, гомумән, милләтебезнен киләчәге өчен югары әхлаклы яңа буын шәхесләр тәрбияләү белән шөгыльләнүче һәр татар кешесенә тәкъдим ителә.

Китапны матбугатка әзерләүче һәм кереш сүз авторы—Әнвәр Хәйри.




Роберт ӘХМӘТҖАН. **Татар иртәсе**: Шигырьләр.—Казан: Татар. кит. нәшр., 2004.—287 б. Тиражы—2000 данә.

Күренекле шагыйрь, Татарстаннын Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Роберт Әхмәтҗановнын бу китабы ике бүлектән тора: беренчесенә, нигездә, халыкнын милли үзанын үстерүгә булышлык итә торган яна шигырьләр тупланса, икенчесендә—төрле елларда иҗат ителгән лирик-фәлсәфи әсәрләр урын алган. Китапка кергән шигырьләре турында автор үзе болай дип яза: "Шигырьләр бер шагыйрьнен гомер елъязмасы гына түгел, ә бәлки ул яшәгән чорнын, мохитнен тарихи елъязмасы да бит. Бирелә укучы яна формалар, аһәннәр төрлелеге белән бергә шул чорнын ритмнарын, рухын тояр дип ышанам. Әсәрләргә нигез итеп алынган вакыйгалар минем буыннын—Сугыш елы балалары буынынын шигъри биографиясен тәшкил итә".



Шәүкәт Гаделша

**КАЗАН УТЛАРЫ**
**QAZAN UTLARI**
**ОГНИ КАЗАНИ**

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
(на татарском языке)